**Фәүзия Бәйрәмова**

# Туфаннан таралган татарлар

*Маҗаралы роман, фәнни-популяр язмалар*

УДК 821.512. 145-3
ББК 84 (2Рос=Тат)-4
Б86

Урта һәм олы яшьтәге мәктәп балалары өчен

**Бәйрәмова Ф. Ә.**

Туфаннан таралган татарлар: Маҗаралы роман, фәнни-популяр язмалар / Фәүзия Бәйрәмова.— Казан: Мәгариф, 2004.— 448 б.
ISBN 5-7761-1450-0

Китапка тупланган әсәрләрдә татар халкы, аның үткәне, татарның борынгыдан килгән бөек шәхесләре, милли каһарманнары тарихи чыганакларга нигезләнеп тасвирлана.

Балалар өчен язылган фәнни-популяр язмаларында автор ислам нигезләрен аңлата, яшь буынны иманга, әхлакый сафлыкка чакыра.

ISBN 5-7761-1450-0
© «Мәгариф» нәшрияты, 2004

## *«ЙӨЗ ИРНЕҢ ЭШЕН ЭШЛӘР» ФӘҮЗИЯ*

*Урта гасыр татар шагыйре Котбның мәшһүр «Хөсрәү вә Ширин» романында (1342) ир-ат («ирлек»), хатын-кыз («тешилек») төшенчәләре хакында да сүз кузгатыла. Автор фикеренчә, бу төшенчәләр, җенси яктан бигрәк, кылган гамәлләр белән билгеләнә. «Теши улдыр,— ди Котб,— кем андин килмәс ирлек».*

> *Тәлим (күп.— Х. М.) хатун кем ирдин артукы бар,*
> *Йирен тапса — йөз ирнең эшен эшләр.*

*Ягъни «ирлек» — эш-гамәл, кыюлык, фидакарьлек, инсанилык, хезмәт кылмаган ир-ат «теши» сыйфатында. Күп хатын-кызларда исә йөз ирнең эшен башкарырлык «ирлек» бар. Фәүзия Әүхәди кызы Бәйрәмова да хатын-кызларның нәкъ әнә шул йөзләрчә (бәлкем, әле меңнәрчә) ирләрне алыштырырлык төркеменнән. Әмма ул «йирен», җаен гына көтеп тормый, һәрчак тәвәккәллек күрсәтә, алып батырдай, курыкмый, хәрәкәт итә, эш-гамәл кыла, кемнең кем булуына карамастан, күңелендәген туры, ачык, сеңдерерлек итеп әйтеп бирә.*

*Мин бу ханымның холкында һәм эшчәнлегендә «Туры Тукай» чалымнарын да, Гаяз Исхакый фидакарьлеген дә күрәм. Әмма шулай да ул һәрчак үзе булып кала.*

*Адәм баласын шәхес итүдә, кан-нәсел белән бергә, җирлек, мохит, чор да зур роль уйный. Фәүзия Бәйрәмова — Казан артыннан, элек-электән татар рухлы Саба якларыннан. Биредә ул ун балалы гаиләдә туып үсә (бишенче бала булып). Милли яшәеш, туган тел, татар моңы, гореф-гадәте кече яшьтән үк аның җанына сеңгән. Күрәсең, гаиләдә тел-әдәбиятка мәхәббәт аеруча көчле булгандыр. Бу гаиләдән алты баланың, шул исәптән Фәүзиянең дә, Казан университетындагы татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем алуы, әдәби иҗат белән теге яки бу дәрәҗәдә шөгыльләнүе дә үзе үк күп нәрсә хакында сөйли.*

*Фәүзиянең холык-фигыленә тырышлык, хезмәт сөючәнлек, җаваплылык, мөстәкыйльлек кебек сыйфат-гадәтләр хас. Яшьтән үк ул үз көнен үзе күрә башлый. 16 яшендә инде бу кыз — район газетасы редакциясе хезмәткәре. Урта белемне дә кичке мәктәптә ала. Алга таба — театр училищесы студенты, телевидение, нәшрият, төрле газета-журнал редакцияләре («Казан утлары», «Татарстан яшьләре»...) хезмәткәре.*

*Бу зат зыялыларга, иҗат ияләренә элек-электән билгеле бер дәрәҗәдә таныш. Әмма ул киң җәмәгатьчелеккә узган гасырның 80 нче еллар ахыры — 90 нчы елларда аеруча танылды. Әйтергә кирәк, ул иҗтимагый-сәяси тормышка атылган йолдыз кебек килеп керде, милли-азатлык хәрәкәте җитәкчеләренең берсенә әверелде: республика парламенты депутаты, «Иттифак» партиясе рәисе, Милли Мәҗлес җитәкчесе, күп төрле чараларны оештыручы Фәүзия ханымның ялкынлы чыгышлары күпләрне гафләт (ваемсызлык), манкортлык, коллык йокысыннан уятты, милләт язмышы турында*

*уйланырга, гамәл кылырга өйрәтте. Аның, Татарстан суверенлыгын, татар халкының ирек-хокукларын яклап, Казанның үзәк мәйданында атналар буе ач торуы чын мәгънәсендә олуг каһарманлык, фидакарьлек иде.*

*Мәгълүм ки, милләтебезнең тик дүрттән бер өлеше генә Татарстанда яши. Калганнары Россиянең, дөньяның төрле төбәкләренә, кыйтгаларына сибелгән, таралган. Фәүзия ханым республикабыздан читтәге татарларны туплау, яклау юнәлешендә дә гаять зур эш алып бара. Аның, мәсәлән, кайчандыр радиациягә дучар ителгән Мөслим төбәге (Чиләбе өлкәсендәге) татарларының аянычлы язмышын күтәреп чыгуы ил күләмендә көчле яңгыраш тапты. Фәүзия ханымның үз туган туфрагында үги, килмешәк хәлендә яшәргә мәҗбүр ителгән Әстерхан татарлары хакындагы чыгышлары да күңелләрне тетрәндерерлек. Ул, Гаяз Исхакый васыятьләрен истә тотып, төрки, мөселман бердәмлеген дә һәрчак яклап килә. Фәүзия ханым,— гомумән, илдә генә түгел, чит мәмләкәтләрдә дә мәгълүм шәхес. Аны, мәсәлән, Төркиядә яхшы беләләр, чыгышларына, язмаларына даими игътибар итәләр.*

*Фәүзия Бәйрәмованың иҗтимагый-сәяси гамәлләре аның фәнни-публицистик эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнешле. Авторның бу төр язмаларында тематика гаять киң һәм төрле. Аларда тарих һәм бүгенге көн дә, мәгариф һәм мәдәният тә, дин һәм әхлак та гәүдәләнеш тапкан. Болар арасында аеруча урыс профессоры Михаил Худяковка мөнәсәбәтле мәкалә-хезмәтләр кызыклы. Фәүзия ханым бу галимнең эшчәнлеге белән университетта уку елларында ук кызыксына башлаган иде. Ул М. Худяковның мәшһүр «Очерки по истории Казанского ханства» дигән хезмәтен татарчага тәрҗемә итте, аның тормышын һәм эшчәнлеген махсус өйрәнде, бу галимгә багышланган махсус конференция, укулар оештырды. Галимәнең фәнни-публицистик язмаларына үтемлелек, оригинальлек, фикер һәм хиснең табигый кушылуы хас.*

*Фәүзия бишенче сыйныфта укыган вакытта ук әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый. Шуннан соңгы вакыт эчендә ул күп санлы хикәя-повестьлар, роман-пьесалар, шигырьләр иҗат итә. Тәүге китабы («Болын») 1986 елда дөнья күрә. Бигрәк тә ул «Моң» (1991), «Кара урман» (1997), «Безне онытмагыз» (1998), «Соңгы намаз» (2000), «Ахырзаман афәте» (2001), «Бәхет ачкычы» (2002), Такташ турында «Мишәрнең бөек улы» (2001) һәм башка күп санлы китаплары, әдәби-публицистик язмалары белән мәгълүм. Фәүзия Бәйрәмова әсәрләрендә кызыклы әдәби-эстетик эзләнүләр һәм табышлар бар.*

*Ул — хәзерге татар публицистикасында дини-рухани әдәбият жанрын кабат тергезүчеләрнең берсе. Бу темага авторның махсус балаларга атап язган хезмәтләре дә бар. Мәктәп укучыларына ислам дине нигезләрен аңлаткан «Бәхет ачкычы» һәм «Нух пәйгамбәр көймәсе» әсәрләре әнә шундыйлардан.*

*Автор тормышта әхлакый сафлык, иман, инсаният кебек төшенчәләрнең очсызлануына әрни, икейөзлелек, милли нигилизм, манкортлык кебек күренешләрне кискен тәнкыйтьли. Гаделлек, хөрлек, матурлык, иманлылык — әдибә иҗатының төп принциплары.*

*Фәүзия Бәйрәмованың күпкырлы эшчәнлеген, мул иҗа- тын аның көчле рухлы, уй-кичерешләргә бай, милләтпәрвәр шәхесе үзара берләштереп, бербөтен итеп тота, аларга кабатланмас төсмер бирә.*

*Әдибәнең сеңлесе Гөлзада ханым язуынча («Сөембикә» журналы.— 2000.— # 2.—10—11 б.), Фәүзия Бәйрәмова «авылдан очучы булам дип чыгып китә». Самолетларны йөртмәсә дә, ул, иҗтимагый-сәяси тормышта, әдәбиятта соклandыргыч очыш-ачышлар ясап, халыкны коллык, ваемсызлык баткагыннан чыгаруга үзеннән зур өлеш кертте. Кылган гамәлләрен, холкын-фигылен күздә тотып, бу олуг затны Фәүзия Фидакария дип атарга мөмкин. Андый шәхесләр халкыбызда күбрәк булсын иде!*

***Хатыйп Миңнегулов,***
*филология фәннәре докторы, 2004*

# КАҺАРМАН ТАТАРЛАР

## ТУФАННАН ТАРАЛГАН ТАТАРЛАР...

Татарлар — дөньяда иң борынгы халыкларның берсе.

Аның төп Ватаны — Идел-Урал арасы, татарлар анда туфан таралганнан бирле яшиләр. Халкыбызның борынгы риваятьләреннән күренгәнчә, татарларның нәсел башы Нух пәйгамбәргә барып чыга. Нух пәйгамбәр — туфан суыннан исән калган изге бәндә. Аның улы Яфәстән безнең борынгы бабабыз Төрек (Терек) туган, Теректән — Алып, Алыптан — Болгар, ә алардан исә бүгенге татарлар дәвам иткән. Милләтебезнең акыл иясе Ризаэтдин Фәхретдин бу хакта менә нәрсә хәбәр итә: «Идел, Җаек һәм Дон сулары буйлары элек-электән төрек кавеменең яшәү урыны иде. Тарихчылар Нух

пәйгамбәрнең улы Яфәснең Идел белән Җаек елгалары арасында торганын сөйлиләр». (*Ризаэтдин Фәхретдин.* Алтын Урда ханнары.— Казан.— 1996.— 62 б.) Хәер, милләт исемен төрки, болгар дип атау ул шартлы рәвештә генә, каннары белән татарлар Нух пәйгамбәргә, туфан чорына барып тоташа. Риваятьләрдән күренгәнчә, «татар» сүзе тере дигәнне аңлата, ягъни мәңге тере милләт, тере суы эчкән кавем. «Татар» сүзенең тауире дигән мәгънәсе барлыгы да билгеле, бу исә татарларның Урал тауларында тормыш башлауларына ишарә. Бу хакта карачай галимнәре Лайпанов һәм Мизиев менә нәрсә язалар: «В настоящее время большинство тюркологов склонно считать прародиной тюрок Алтай, Южную Сибирь и Прибайкалье. Мы же склонны считать их первоначальной родиной Волго-Уральский регион, откуда тюркские племена в IV—III тыс. до н. э. расселились во многие регионы Азии и Европы». (*ЛайпановК.Т., МизиевИ.М.* О происхождении тюркских народов.— Черкесск, 1993.— с. 17.) Борынгы риваятьләрдән һәм истәлекләрдән күренгәнчә, татарлар, Урал тавының ике ягына төшеп, дөнья буйлап таралганнар. Көнчыгышта алар — Америка кыйтгасына кадәр, көнбатышта — Альп тауларына хәтле, төньякта — Кар диңгезенә, көньякта Каф тауларына чаклы барып чыкканнар. Бу хакта бөтен җир шары буйлап сибелеп калган татар атамалары, татар исемнәре, борынгы курганнар һәм шәһәрлекләр сөйли. Бу хакта дөнья тарихы сөйли, әмма татар дигән сүз яшерелә, татар даны башкаларга бирелә. Күп очракта татарлар үзләре дә борынгы тарихларын белмиләр, алар өчен башкалар язып биргән ялган тарихка ышанып яшиләр. Ә аларда татарлар вәхши һәм кыргый, надан һәм явыз итеп күрсәтелгән. Тарихтан билгеле: дошман үзенең көчле көндәшен һәрвакыт әнә шулай пычратып, ямьсез итеп тасвирларга тырышкан. Шулай итеп, ул аның тарихтагы данлы эзен юкка чыгарырга, аның урынын үзе алыр өчен көрәшкән. Европа, Кытай, урыс тарихчыларының татарга каршы шушы юнәлештә эшләүләре сәбәпле, без бүген дөнья тарихында лаеклы үз урыныбызны ала алмыйбыз. Ә бит дөнья тарихында скиф дип йөртелүчеләр дә, һуннар-гуннар-сөннәр дә, төрки дигән ясалма исем астына кертелүчеләр дә — борынгыдан барысы да татарлар булган, алар тарихта татарлар дип йөртелгән. V гасырга хәтле, гомумән, «төрки» дигән атама кулланышта булмаган, Кытай чыганаклары безнең эрага кадәр бары тик татарларны гына теркәп калдырган. Борынгы дөнья Евразия киңлекләренә хуҗа булган башка халыкны белмәгән, иксез-чиксез җирләрнең хуҗалары татарлар, бары тик татарлар дип аталган. Шуңа күрә татарларның бу җирләрдә төрле дәүләтләр оештырып, әле кодрәтле каганатлар, әле Ак Урдалар, әле Күк Урдалар, әле Алтын Урдалар, төрле ханлыклар төзеп яшәүләре бер дә гаҗәп түгел! Татарлар ил-җирләр биләп торган, дәүләтләр тоткан көчле халык булганнар. Алар Идел-Уралда, Себердә, кытай-монгол җирләрендә, Кавказда һәм Кырымда, Каспий һәм Кара диңгез буйларында, тагы бик күп урыннарда чын хуҗа булып яшәгәннәр. Бу мең ел элек тә шулай булган, ике, өч мең ел элек тә, хәтта иң борынгы чорларда — 40—50 мең ел элек тә бу җирләрдә безнең борынгы бабаларыбыз көн күргән, тормыш алып барган. Бу хакта дөнья тарихчылары дәшмәсәләр дә, борынгы табылдыклар, шәһәрлекләр, татарларның курган-каберлекләре, җир-су атамалары сөйләп тора… Бу хакта татар балалары да белергә тиеш.

Безнең борынгы бабаларыбыз зур гәүдәле, пәһлеван кыяфәтле, гайрәтле алыплар булганнар. Ислам дине әйтүенчә, алар буйга 60 терсәк (ягъни 30 метр), аркылыга 7 терсәк озынлыгы булганнар. Туфаннан соң тормышны, нигездә, шундый кешеләр дәвам иткән. Бу хакта бөтен дөнья халыкларының авыз иҗатында истәлекләр сакланган, татар халкында да алыплар турында риваятьләр күп. Татарларның алыплар турындагы хикәятләре бигрәк тә Идел-Урал буйларында, Себер якларында киң таралган. Бу кешеләр югары цивилизациягә ия булганнар, үзләреннән соң җир йөзендә зур шәһәрләр, бөек мәдәният, фән бүген дә җавап бирә алмаган серләр калдырганнар. Алып кешеләр Көньяк һәм Үзәк Америкадан алып томанлы Альбион дип аталган бүгенге Англия җирләрендә, Тын океандагы Пасха утравында үзләренең эзләрен — гигант корылмаларын калдырганнар, Альп тауларына үз исемнәрен биреп киткәннәр, Идел-Урал арасында исә дистәләгән курган-каберлекләрен калдырганнар… Аларны бүгенге көнгә хәтле шушы юнәлештә өйрәнүче, тикшерүче генә юк. Кытайдан — Кырымгача, Татар бугазыннан Әдрән диңгез буйларына кадәр җирләрдә борынгы татарларның тирән тарихи эзләре калган, исемнәре һәм эшләре калган… Элеккеге тарихта татар дигән зур исем астына борынгы скифлар да, сак-сарматлар да, һуннар да, хәзәрләр дә, кыпчаклар да, болгарлар да кертелгән, алар барысы да борынгы татар халкының исем-атамалары… Тарихчылар шулай ук Шумер цивилизациясе, Көньяк Америка индеецлары мәдәнияте белән дә уртак якларыбыз барлыгын күрсәтәләр. Моңа гаҗәпләнергә кирәкми, чөнки, чыннан да, безнең тамырларыбыз уртак, алар борынгы Нух пәйгамбәр заманнарына барып тоташа.

Тарихта, гадәттә, төрки-татарларны ат чаптырып, мал куып, анда-монда күчеп йөрүчеләр итеп кенә күрсәтергә яраталар. Имеш, аларның мәдәнияте дә, шәһәрләре дә булмаган. Бу — тамырдан ялгыш фикер, татарларга каршы махсус чыгарылган уйдырма-ялган. Меңнәрчә еллар буе дәүләтләр тоткан халыкның бөек мәдәнияте дә, зур шәһәрләре дә булган. Тарихта татарлар тарафыннан төзелгән

йөзләрчә бөек шәһәрләрнең булганлыгы билгеле. Менә аларның кайберләре — Аркаим, Лүнчән, Дайлин, Ханбалык, Каракорым, Сәмәндәр, Әтил, Самар, Болгар, Бүләр, Сувар, Җүкәтау, Казан, Кашан, Сарай, Хаҗитархан, Үкәк, Мохша, Маджар, Аккирмән, Ханкирмән, Синбир, Чаллы, Тубылгытау, Алабуга, Урмат, Калатау, Арча, Тора-Тау, Кашлык, Имән-Кала, Искер, Чимги-Тура, Тон-Тура, Бичек-Тура, Яулы-Тура, Кызыл-Тура, Касыйм-Тура, Ташкирмән һәм башкалар, һәм башкалар… Татарның соңгы дәүләте — Казан ханлыгында гына да 120 шәһәр булганлыгы билгеле. Болгар, Алтын Урда ханлыкларында да йөзләрчә шәһәрләр булган, аларда татарлар тимер койган, акча суккан, алтын-көмештән бизәнү әйберләре эшләгән, сугыш һәм эш кораллары ясаган. Хан-каганнар ил белән идарә иткән, шагыйрьләр шигырь язган, татар халкы бөек нәселне дәвам иткән… Кирәк чакта яу чапканнар, кирәк чакта яудан сакланганнар, Кытайдан — Кавказгача, Уралдан Альп тауларына чаклы үз илләрендә, үз җирләрендә аяк терәп яшәгәннәр. Гайрәтле татарларның дошманнары да күп булган. Далада адашып йөргән ач шакаллар кебек, алар даими рәвештә татарның алып гәүдәсе өстенә ташланып торганнар, Татар иленең калҗа-калҗа җирләрен умырып алганнар. Нәтиҗәдә Бөек Татар иле тәмам таркалып, хәлсезләнеп, шул ач шакаллар аяк астында ятып калган… Татар иленең нурлы кояшы батып, аның өстенә 450 еллык кара төн килгән… Таралып яткан Татар иленә инде башкалар хуҗа булып алган…

Бер төрле йомшак халык булса, бу хәтле озак тоткынлыктан соң, илсезлектән һәм дәүләтсезлектән соң, инде әллә кайчан басып алучылар арасында эреп-ашалып юкка чыккан булыр иде. Әйтергә генә җиңел бит ул — 450 ел!!! Дүрт йөз илле еллык коллык, башка милләтнең кануннары астында яшәү, башка дин, башка тел басымын һәр мизгелдә тоеп тору… Россия империясендә нинди генә зур сугыш булса да, үләргә беренче итеп татарны җибәргәннәр, татарларны көчләп чукындырганнар, монастырьларга япканнар, тел, дин дигән өчен очлы казыкларга утырткannar, телләрен, борыннарын кисеп алганнар, сөргеннәргә сөргәннәр, мәңгелеккә төрмәләргә япканнар… Шушы хәлләрдән соң да без исән калганбыз икән, һаман телебезне, динебезне саклыйбыз, данлы тарихыбызны беләбез икән, димәк, без, татарлар,— чыннан да бөек халык, тере суын эчкән мәңгелек халык… Коллыктан билләрне турайтып, бу хакта бөтен дөньяга хәбәр итәр вакыт җитте. Бигрәк тә татар балалары менә шушы канлы һәм шанлы үткәннәребезне белергә тиешләр. Татар илен кемнәр төзегән һәм тотып торган, кемнәр аны безнең көннәргә хәтле китереп җиткергән — татар балалары анысын да яхшы белергә тиешләр. Бу язмабыз әнә шул татар каһарманнары, Бөек Татар иле, данлы татар тарихы турында. Аллаһы Тәгалә шушы эшебездә ярдәмче булсын иде. Амин.

## АРКАИМ — ТАТАР ШӘҺӘРЕ УЛ

Безнең тарихыбыз гасырлар барышында бик күп таланды һәм юкка чыгарыла килде. Татар тарихын, бер яктан, кытайлар талады, алар бездән ил белән идарә итү системасын, гаскәр тәртибен алдылар, төрки халыклар уйлап тапкан кәгазь, дары кебек нәрсәләргә хуҗа булдылар. Икенче яктан, төрки-татар тарихын греклар үзләштерде, алар безнең борынгы мифларыбызны үзләренеке иттеләр, тарихи табылдыкларны үзләштерделәр. Өченче яктан, татар тарихын урыслар үзләренчә бозып, каралтып, кечерәйтеп яза башладылар. Чөнки без алар тарафыннан җиңелгән халык идек, дәүләт, рәсми идеология алар кулында булгач, урыслар бары тик үз файдаларына гына эшләделәр. Үзләренең басып алу сәясәтләрен аклау өчен, алар татарларны кыргый, надан халык итеп күрсәтергә тырыштылар, дәреслекләрдә шулай дип яздылар. Дөреслектә, бөтен Россия ул — татар җирләре, татарлар дәүләт тоткан борынгы биләмәләр. Һәм андагы бөтен тарихи табылдыклар да татар халкының рухи, мәдәни байлыгы булып саналырга тиеш. Урыс галимнәре исә бу байлыкны теләсә кемгә бирергә әзерләр, тик татарларга гына түгел. Алар хәтта Россия территориясендә, татар җирләрендә табылган археологик истәлекләрне әллә кайдагы индоираннарга, индоевропалыларга бирергә дә әзер. Мондый хәлне Кавказда да, Кырымда да, Идел-Урал буйларында да күзәтергә мөмкин. Аркаим — шушы тарихи талауның бер мисалы.

Борынгы Аркаим шәһәрлеге Чиләбе өлкәсенең көньяк-көнчыгышына, Россиянең Казахстан чигенә урнашкан. Галимнәрнең әйтүе буенча, ул моннан 4—5 мең ел элек барлыкка килгән. Биредә инде шул вакытларда ук тимер эреткәннәр, бакыр койганнар, алардан эш һәм сугыш кораллары ясаганнар. Боларның барысын да бүгенге Аркаим шәһәрлегендә күрергә була. Аркаим — моннан егерме еллар элек галимнәр тарафыннан җир астыннан казып чыгарылган борынгы шәһәрлек, түгәрәк таш шәһәр. Бу шәһәр биеклеге 4 метрдан да ким булмаган ике кат стена белән уратып алынган булган, аны хәзер дә күрергә мөмкин. Иң гаҗәбе: эчтәге йортлар да шулай түгәрәк ясап, олы түгәрәк тирәсенә күч-күч булып утырганнар, һәм барысының да ишекләре бер урынга — үзәк мәйданга чыккан. Түгәрәк өйләрнең түбәләреннән яңгыр суы шушы мәйданга аккан, ул су, махсус канаулар белән шәһәр читенә

чыгарылган, шулай итеп, дошман үтеп керә алмаслык су киртәсе барлыкка килгән. Сугыш-яу вакытларында исә кешеләр өй түбәләреннән торып сугышканнар. Һәр торак йортның эчендә коелар, мичләр, азык базлары булган, һәр йортка канализация үткәрелгән. Шәһәр читендә исә Аркаим халкы иген үстергән, мал көткән, эчтә һөнәрчелек белән шөгыльләнгәннәр. Казылмалардан күренгәнчә, бу шәһәрдә өч меңгә якын кеше яшәгән, ә андый шәһәрләр Урал тавының бу ягында гына да йөзләгән. Шуңа күрә бу тирәләрне «Шәһәрләр иле» дип йөртәләр. Аркаимда «Курган Тимер» дип аталган борынгы каберлекләр табылган, бүген дә төрки-татар халкы киеп йөри торган өс-баш, эш һәм сугыш кораллары чыккан. Шәһәрнең һәм өйләрнең түгәрәк рәвештә булуы да татар тормышына бик якын. Чөнки безнең халыкта әле узган гасырда гына да түгәрәк өйләрне күрергә була иде. Халкыбызда юкка гына «Түгәрәк өйнең түре юк» дигән әйтем сакланмаган бит…

Шәһәр үзе Карагай һәм Үтәгән дип аталган елгалар арасына урнашкан, ерак түгел Шаман тавы, Аркаим үзәнлеге җәйрәп ята. Бу тирәдә Яңа Ил, Карабулак, Сембер, Ерлыгач, Кондыр, Исмәгыйль дип аталган татар авыллары бар, якында гына Ильяс, Кызыл елгалары агып ята. Ягъни Аркаим урнашуы белән дә, эчтәлеге белән дә татар мохитендә, татарныкы. Ә ул борынгы шәһәрлекне тарихчы урыс һәм яһүди галимнәре кемгә биргәннәр соң? Татаргамы? Башка төрки халыкларгамы? Юк шул, Аркаим шәһәрлеге бөтен дөнья алдында индоиран, индоевропа мәдәнияте дип игълан ителде. Имеш, Уралтауның аръягындагы бу шәһәрләрне әллә кайдагы фарсы (Иран), индус (Һиндстан) илләреннән килеп, арий кыяфәтле нииндидер индоевропалылар төзегән икән. Төзегәннәр дә юкка чыкканнар, имеш. Кайда киткәннәрен беркем белми. Бу борынгы тарихи табылдыкларны төрки-татарныкы дип әйтмәс өчен, борынгы цивилизацияне татар мәдәнияте димәс өчен, әллә нинди тозсыз ялганнарга кереп баткан бу галимнәр. Аркаим үзәнлегендә тезелеп утырган төрки таш балбаллар да, курганнардан чыккан төрки өс-баш та, өйләрнең безнеңчә төзелеше дә, эш һәм сугыш коралларының нәкъ безнеңчә булуы да аларны ышандыра алмый. Чөнки Аркаимны татарга бирсәң, бөтен Урал буйларындагы борынгы табылдыкларны, курганнарны, алардан чыккан алтын-көмеш хәзинәләрне, иң мөһиме бу цивилизацияне, татарныкы дип әйтергә туры киләчәк бит! Ә бу урыс галимнәре гасырлар буе татарларны кыргый, бер нәрсәгә яраксыз халык дип язып, шуны исбатлап килделәр. Ә Аркаим моның нәкъ киресен күрсәтте. Татарлар моннан 4—5 мең ел элек, безнең эрага хәтле 3—2 меңьеллыкларда ук үзләренең Төп Йортларында — Урал буйларында менә шундый таш шәһәрләр төзеп яшәгәннәр, тимер койганнар, акча сукканнар, гөрләтеп тормыш алып барганнар. Аннан шушы мәдәниятне ярты дөньяга таратканнар. Бу нәкъ шулай булган. Татар халкының коллык шартларында да, бүгенгә хәтле бетмичә, югары мәдәният тудырып яши алуы — аның тамырларының бик тирәндә булуына, ныклы традицияләр белән яшәвенә, тарихы Аркаимнарга һәм Шумерларга барып тоташуын күрсәтә…

Галимнәрнең әйтүенчә, Аркаим халкы оста төзүчеләр һәм хәрбиләр, һөнәрчеләр һәм игенчеләр генә булмаган, ә галәмне күзәтерлек кояш обсерваторияләре дә төзеп калдырганнар. Шәһәрнең, бик төгәл рәвештә, галәм төзелешен күздә тотып салынуы, анда астрономик элементларның күзәтелүе галимнәргә шулай дип әйтергә мөмкинлек бирә. Бу җәһәттән ул Англиядәге Стоунхенд обсерваториясе белән бик охшаш икән — шундый ук сәер түгәрәкләр, айны һәм кояшны күзәтерлек географик мөмкинлекләр, бер үк чор… Ә аралары — 4 мең чакрым…

Аркаим ачылганчыга хәтле, бу тирәдә кыргый халык, күчмә көтүчеләр яшәгән, дигән фикер бар иде. Аркаим табылдыклары галимнәрнең бу фикерен чәлпәрәмә китереп ташлады. Юк, моннан 4—5 мең ел элек Урал буйларында яшәгән җирле халыклар кыргый кавемнәр булмаганнар, алар үз куллары белән зур шәһәрләр төзеп яшәрлек, архитектурада, сәнгатьтә, сәүдәдә рәт белгән, үз гаскәре, үз акчаларын суккан, Урал тауларына, аның алтын-көмешләренә, тимеренә, мәрмәренә хуҗа булган гайрәтле, мәгърифәтле халык булганнар. Алар йолдызларны күзәткәннәр, меңнәрчә чакрым арага үз хәбәрләрен җиткерә алганнар… Әйткәнебезчә, аларның бу шәһәр-крепостьлары, йөзәрләгән булып, Урал тауларының төньягына таба 400 чакрым ераклыкка сузылган. Әйе, чын мәгънәсендә, Калалар иле булган борынгы Татар иле — безнең төп Ватаныбыз… Уралтаудан төшкән Нух пәйгамбәр оныклары — безнең борынгы бабаларыбыз татарлар — бу җирләрдә менә шундый югары мәдәниятле, кодрәтле ил-дәүләтләр төзеп яши алганнар. Кызганычка каршы, хәзергә без ул каһарман татарларны исемләп атый алмыйбыз, ил башлыкларының исемнәре дә хәзергә безгә билгесез. Әмма килер вакыт, яшь буын бу җирләрнең, бу илләрнең, Аркаимның үзен дә татар цивилизациясе, татар халкының рухи һәм мәдәни байлыгы икәнлеген исбатлар әле, иншаллаһ!

## СКИФЛАР — ШУЛ УК ТАТАРЛАР АЛАР…

Кемнәр соң алар скифлар?

Скифлар дип греклар безнең эрага кадәр беренче меңьеллыкта Кара диңгезнең төньяк ярларында һәм Евразия киңлекләрендә яшәгән дала халкын атаганнар. Бу хакта тулырак мәгълүматны борынгы грек тарихчысы Геродот язып калдырган. Скифлар турында шулай ук башка грек һәм Рим галимнәренең дә хезмәтләреннән укырга була. Греклар күзенә бу көчле халык кыргый булып күренгән, аларны Азиядән килгән вәхшиләр дип уйлаганнар һәм скифларны түбәнсетә торган уйдырмалар да уйлап чыгарганнар, әмма аларның кодрәте һәм батырлыклары белән санлашырга мәҗбүр булганнар. **«Татары поделили между собой Скифию, которая тянется от Дуная до восхода солнца…»**,— дип язып калдырган XIII гасыр галиме Гильом Рубрук. Скифлар яшәгән барлык җирләрне дә, ягъни Себер, Урта һәм Үзәк Азия, Идел-Урал, Кара диңгез буйларындагы территорияне, фәндә «Скифия» дип йөрткәннәр һәм бу җирләргә «скифлар яки татарлар» хуҗа булуын язып калдырганнар. Әмма борынгы грек һәм латин телендә язылган бу хезмәтләр бүгенге көнгә тәрҗемәдә шактый бозылып, үзгәртелеп килеп җиткәннәр. Әйтик, XVIII гасыр тарихчысы Э.Гиббон үзенең «История упадка и разрушения Римской империи» китабында «скифлар һәм татарлар» сүзен, борынгыдагыча, бер мәгънәдә аңлатып, янәшә куя, «скифлар яки татарлар» дип яза. Узган гасырда исә бу хезмәтне урысчага тәрҗемә итеп, «скифлар һәм татарлар» дип язалар, ягъни бу ике атаманың бер халыкны — татарларны аңлатуын махсус рәвештә юкка чыгаралар. Югыйсә XIII гасыр галиме Гильом Рубрук: «Татарлар үзара Скифияне бүлештеләр, ә ул җирләр Дунайдан кояш чыгышына кадәр дәвам итә»,— дип, бик ачык һәм аңлаешлы язып калдырган бит!

Бүгенге фән раслаганча, скифлар шул ук һуннар булганнар, алар бүген татар халкы, төрки халыклар яшәгән җирләрдә көн күргәннәр. Бу скиф-татарларны кытайча — *хунну*, латинча — *гун*, фарсыча *туранлы* дип тә атап йөрткәннәр, аларның фәндә «Царские скифы» дигән атамасы да булган. III—IV гасырларда аларның биләмәләре Җаектан (Уралдан) — Днепрга чаклы, төньякта — Кама буйларына, көньякта Кавказга, Хәзәр (Каспий) диңгезенә хәтле сузылган. Бүгенге Себер җирләре дә ул заманнарда Скифиянең бер өлеше булып торган. Кыскасы, борынгыдан һәм бүген дә татарлар яшәгән бу җирләр татарларның патшалыгы булган, кайчагында аларны башка халыклар скифлар һәм һуннар дип атап йөртсәләр дә, нигездә, алар барысы да татарлар булган. Чөнки Евразия киңлекләрендәге төп халык меңнәрчә еллар буе татар исемен йөрткән, Октябрь революциясенә хәтле әле азәрбайҗаннар, үзбәкләр, кыргыз-казахлар да татар дип аталганнар. Себердә яшәүче төрки шор, телеут милләт вәкилләренең әле бүген дә паспортларында татар дигән язуны күрергә мөмкин, шул ук хәл төрки хакас, тува халыкларында да булган. Тува телендә «татар» сүзе «хуҗа», «господин» дигән олы мәгънәгә ия. Чын мәгънәсендә, татарлар бу олы даланың, олы дөньяның хуҗалары булганнар, шуңа күрә греклар аларны олылап «Царские скифы» дип йөрткәннәр.

Бүгенге көндә скиф курганнарыннан чыккан табылдыклар бөтен дөньяны таң калдырды. Бу затлы байлыкка, нәфислеккә, куәтле коралларга карап, борынгы скиф-татарларны бер дә кыргый халык дип әйтеп булмый. Кара диңгез һәм Сырдәрья буйларында, Ырынбур далаларында, Идел-Урал арасында, Тува җирләрендә, Алтайда һәм Монголиядә табылган алтын һәм көмеш савытлар, булат кылычлар, җиздән коелган казаннар, фирүзә кашлы беләзекләр ефәк һәм йон өс киемнәре, чиккән келәмнәр — болар барысы да скиф-татарларның гаять нечкә зәвыклы, матурлыкны аңлый белгән, шул ук вакытта гайрәтле, батыр халык икәнлекләрен күрсәтте. Кызганычка каршы, скиф курганнарының күбесе инде таланган, күбесе онытылган. Бүгенге көндә Чиләбе өлкәсенең Татар Караболагы авылы янындагы скиф курганы, Татарстанда «Алыплар кабере» дип аталган курганнар үзләренең өйрәнүчеләрен көтә. Әмма бүгенге көндә скиф тарихына, мәдәниятенә дәгъва кылучылар шактый, аны һаман татар халкына бирмәс өчен тырышучылар бар. Ләкин борынгы тарихчыларның: «Скифлар — шул ук татарлар алар»,— дигән сүзләрен онытмаска кирәк. Ә татар исемен, татар данын менә инде меңнәрчә еллар без — бүгенге татарлар йөртәбез. Бу затлы исемне, горурланып, килер көннәргә дә алып барырбыз, иншаллаһ!

## БАҺАДУР — БЕРЕНЧЕ ТАТАР ПАТШАСЫ

Тарихта татарларның беренче патшасы итеп Баһадур батыр теркәлеп калган. Дөрес, татарларның аңа кадәр дә көчле идарәчеләре булган булырга тиеш, ләкин бу хакта әле язма мәгълүматларның табылганы юк. Ә Баһадур патшаның куәтле Татар дәүләте төзеп, аның белән күп еллар идарә итүе турында Кытай елъязмаларына теркәп калдырылган. Чөнки Баһадур патша кытайларның дошманы булган, аларның борын төбендә татарларның дәүләтен төзеп куйган, кытайларны татарларга ясак түләп торырга мәҗбүр иткән. Шуңа күрә Кытай язмаларында Баһадур патшаны тарих алдында түбәнәйтеп күрсәтә торган мәгълүматлар да бар, имеш, дәүләт хакына аңа үз якыннарын үтертү берни тормаган.

Кытай чыганаклары артыннан бүгенге тарихчылар да Баһадур патшаны кимсетә торган шул хәбәрләрне сүзен-сүзгә кабатлыйлар. Дошман язган тарихта каршы як һәрвакыт ямьсез итеп күрсәтелә, шуны беркайчан да истән чыгармаска кирәк. Ә инде Баһадур патшага килгәндә, безгә ул көнчыгышта кодрәтле Татар дәүләте төзүе һәм аны тарихка кертеп калдыруы белән кадерле.

Тарихтан мәгълүм булганча, Баһадур патша яңа эрага кадәр 210 елларда идарә иткән. Ягъни моннан 2200 ел элек ул бүгенге Кытай җирләрендә тиңсез татар дәүләте торткан. Тарихи хезмәтләрдә аның исемен Мәте-Моде-Маодун-Босхор-Багадур дип тә күрсәтәләр. Аның патша буларак тулы титулы — Баһадур Тәңре Куду Жания булган, ягъни Бөек Күкнең Бүләге булган Җан Иясе Баһадур. Аларны фарсы чыганаклары — Туран уллары дип, Кытай чыганаклары хиен-ну, ягъни хунну, һуннар дип йөрткәннәр. Әмма Баһадур патшага карата, без белгән тарихи чыганакларда беренче буларак, татар сүзе кулланылган, шуңа күрә дә ул тарихка беренче татар патшасы буларак кереп калган.

Баһадур Төньяк Кытайда һун татарларының бәйсез дәүләтен төзи. Ул озак еллар бу Татар дәүләтен кытайлардан гына түгел, дунху-монголлардан, тунгуслардан, башка күчмә кабиләләрдән дә саклый. Ул гына да түгел, Баһадур патша, барлык төрки-татар һәм башка җирле кабиләләрне берләштереп, көч-куәттә Кытай дәүләтенә тиң булган татар патшалыгы төзи. Ул сугышта тиңсез батырлыклар күрсәткән кебек, дәүләт эшләрен алып баруда да зур зирәклек күрсәтә. Галимнәрнең әйтүенчә, туран әлифбасы да шул вакытта кертелгән булырга тиеш, чөнки мондый зур дәүләтне язусыз, әлифбасыз тоту мөмкин булмаган. Арами язуына нигезләнгән туран хәрефләре белән тутырылган эш-гамәл дәфтәрләре барлыкка килгән, яңа кануннар чыгарылган, аларны сөрәнчеләр көне-сәгате белән халыкка җиткергәннәр.

Борынгы язмалардан күренгәнчә, Баһадур патша үзе дә, аңа буйсынган һун татарлары да ул вакытта ук бер Аллага — Күк Тәңресенә табынганнар. Кайбер галимнәр аларны кояшка, айга, йолдызларга табынган итеп күрсәтергә теләсәләр дә, бу хакта бернинди дә мәгълүматлар юк. Баһадур патша һәр елны бик зур дини бәйрәм — корылтай уздырган, монда Күк Тәңресе рухына корбан итеп атлар чалынган. Көз көннәре исә халык саны алу һәм мал һәм җан башыннан ясак түләү буенча зур җыеннар уздырылган. Шулай ук борынгы татарлар ат ярышларын һәм дөя узышларын да бик яратып караганнар.

Баһадур патша дәүләтнең эчендә ныклы тәртип урнаштыру буенча зур көч куя. Аның дәүләте тышкы көчләрдән тулы бәйсезлек, илнең эчендә тулы гаделлек принципларына нигезләнгән була. Ил башлыгы белән халык арасында мөнәсәбәтләр ихлас һәм ышанычлы була. Яуда аяусыз булган татар ирләре тыныч тормышта эчкерсез, гади кешеләр булып калалар. Илне тәртиптә тоту өчен, Баһадур патша үзе дә нык тырыша. Ул татарлар арасында бердәмлек, татулык мәсьәләләрен төп урынга куйган. Әйтик, ул, татарлар арасында үзара ызгышны бетерү өчен, кискен чаралар күргән, бу хакта хәтта законнар да чыгарган. Бәхәсләшү вакытында берәр кеше, кызып китеп, коралына ябышса яки аны файдаланса, аны каты җәза, хәтта үлем көткән. Чөнки, Баһадур патшаның фикеренчә, татарлар үзара ызгышып, сугышып яшәргә тиеш булмаган, бу хәл илнең таркалуына, дәүләт бәйсезлеген югалтуга китерергә мөмкин булган. Бу Татар дәүләтендә урлашу, башка җинаятьләр дә каты җәзага тартылган. Әйтик, урлашкан кешенең бар мал-мөлкәте казнага тартып алынган, ул хәтта үз гаиләсеннән дә колак каккан. Авыр җинаять кылучыларны төрмә йә булмаса үлем җәзасы көткән, ә инде җиңелчә җинаять кылучыларның битләренә хурлык тамгасы салынган. Суд эшләрен карау атна-ун көннән дә артмаган. Борынгы Кытай чыганакларыннан күренгәнчә, бу татар дәүләтендә җинаятьләр бик аз булган.

Баһадур патша көчле гаскәр тотуга бик нык игътибар биргән. Ул үзе дә, аның кул астындагы хөкүмәт кешеләре дә бер үк вакытта гаскәр белән дә җитәкчелек иткәннәр. Шулай итеп, Баһадур патша даими рәвештә 300 мең кешелек атлы гаскәр тотуга ирешкән. Ул үзе сызгыра торган ук уйлап тапкан, аның бу уклары гаскәргә кай тарафка атарга юнәлеш биргән. Ул заманның татар яугирләре гаять дәрәҗәдә сугышчан рухлы, ныклы әзерлекле, кыю һәм җиңелүсез булулары белән аерылып торганнар. Алар сугышка тимердән койган сөңге, туры кылычлар, ук-җәяләр белән коралланып кергәннәр, атта чабып барган уңайга җәядән атып, дошманны бәреп төшергәннәр. Өзәңгегә баскан килеш, җәясен киереп, дошман явы уртасына атылып килеп кергән татар сугышчылары әле ике мең ел буе дөньяны шулай калтыратып торыр…

Үз җирләрендә хуҗа булып яшәү өчен, һун татарларына кытайлар белән гел сугышып торырга туры килә. Безнең эрага кадәр 200 елларда көч татарлар ягында була. Кытайлар, вакытлыча булса да, моның белән килешергә мәҗбүр булалар, әмма үзләре астыртын гына гел татарларга каршы эшлиләр, яңа сугышка әзерләнәләр. Яңа эрага кадәр 201 елны кытайлар белән татарлар арасында каты сугыш башлана — Кытай императоры татарларга каршы яуга чыга. Башта кытайлар җиңгән кебек тоелса да, Баһадур патша аларны алдалап, үз артыннан алга таба алып китә һәм 320 мең кешелек кытай гаскәрен камалышка ала. Бу чолганыш кытайларның котын ала — аларга таба көнчыгыштан бары тик ак атка

атланган татар сугышчылары ыргыла, көнбатыштан — алмачуарлар, төньяктан — кара атлылар, көньяктан бары тик җирән-соры атка атланган татарлар килә. 300 мең кешелек татар гаскәре Кытай императорын һәм аның гаскәрен җиде көн буенча камалышта тота. Әмма Баһадур патша, чын мәгънәсендә Бөек Җан Иясе, әсирлектә калган бу кытайларны юк итәргә ашыкмый, киресенчә, үз хурлыкларын үзләренә күрсәткәннән соң, Кытай императорын, гаскәре белән бергә, чолганыштан исән-имин килеш чыгарып җибәрә. Бөек дала ире — татар патшасы Баһадур егылганны кыйнамый, җиңелгәнне үтерми, ут күршеләренә яшәргә мөмкинлек бирә… Бу хәлләрдән соң Кытай дәүләте, озак еллар буе татарларга бүләкләр рәвешендәге яшерен ясак түләп, Баһадур патша каршында башын игән хәлдә яшәргә мәҗбүр була.

Күршеләре белән дус-тыныч яшәү максаты куйса да, Баһадур патша татар җирләре мәсьәләсендә үзен бик катгый тота. Күрше дунху-монгол кабиләләре аннан иң яхшы атын килеп сорагач, дуслык хакына ул аларга атын бирә. Алар, әрсезләнеп, Баһадур патшаның хатынын килеп сорагач, иминлек хакына ул дунхуларга иң матур җариясен биреп җибәрә. Ә инде бу кабиләләр, тагы да азып китеп, Баһадур патшадан буш яткан татар җирләрен килеп сорагач, ул аларга каршы сугыш ача һәм тар-мар итеп ташлый. «Җир — дәүләтнең нигезе,— ди ул, ярсып.— Ничек инде җирне бирергә мөмкин?! Җир һәр халыкка Тәңренең үзе тарафыннан бирелгән. Җир булса — ил була, халык була; җир булса — дәүләт тә төзергә мөмкин». Татар җирләрен монголларга бирергә дигән киңәшчеләренең ул башын чаптыра.

Кытайлар һәм җирле халыклар белән мәсьәләне хәл иткәннән соң, Баһадур патша тирә-юньдәге бөтен төрки-татар халыкларын берләштерү максаты куя. Тарихтан билгеле булганча, аның атлы гаскәре Байкал һәм Амур буйларына хәтле килеп җитә, Баһадур патша таркалган төрки-татар халкын бер байрак астына туплауга ирешә. Безнең эрага кадәр 192 ел белән 176 еллар арасында ул Идел-Җаек тирәләреннән Кара диңгез буйларына хәтле барып чыга, биредә яшәүче һун татарларын берләштерә, берләшергә теләмәгәннәрне кылыч белән буйсындыра. Безнең эрага кадәр 176 елны Кытай императоры Хяо-Выньга җибәргән хатында Баһадур патша бу хакта менә ничек тасвирлый: «Атлар көр, җайдаклар исән-сау булып, Тәңренең игелеге белән юечжыларны җиңдек. Ләүлән, Үсүн, Хәүсә һәм тагы 26 илне кылыч очына алдык, буйсындырдык. Бу биләмәләрдәге халыклар һуннар чәриге сафларына бастылар, һәм хәзер алар бер йорт тәшкил итәләр. Төньяк тарафтагы илләрдә тынычлык урнаштырганнан соң, яу чабуны туктатып, сугышчыларга ял бирергә, атларны утлауларга җибәрергә телим. Чик буенда гомер кичергән халыклар элеккеге кебек үк тыныч яшәсен өчен, үткәннәрне онытып, элгәрге килешүне яңартыйк. Яшь балалар үссеннәр, ә картлар калган гомерләрен иминлектә уздырсыннар һәм аймактан аймакка бар да иминлекнең рәхәтен күрсен…»

«Багадур теперь полностью признавался собственным народом как очень великий человек… Багадур был одним из великих завоевателей в мировой истории и справедливо может быть назван Ганнибалом Татарии»,— дип яза үзенең 1895 елда Кытайда басылып чыккан китабында күренекле инглиз галиме Эдуард Паркер. (Бу китап «Тысяча лет из истории татар» дигән исем белән 2003 елны урыс телендә Казан шәһәрендә дә басылып чыкты.)

Әнә шулай татарларны бер йодрыкка берләштереп, кытайларны авызлыкта тотып, Баһадур патша 36 ел Татар иле белән идарә итә. Ул үлгәч, Татар дәүләте башында Баһадурның улы Каяк кала. Моннан соңгы йөз еллар Кытай дәүләте белән даими көрәшеп, сугышып, бер җиңеп, бер җиңелеп уза. Яңа эраның 93 елында кытайлар Һун-татар дәүләтен тар-мар итәләр. Көнчыгыш Һун дәүләте таркалса да, аның урынына тиздән куәтле Төрки-татар каганлыгы үсеп чыга, ә көнбатышта исә шул ук һун татарларының Көнбатыш Һун (Татар) дәүләте төзелә. Бөек татар тарихын башка каһарманнар дәвам итә… Ә Баһадур патша безгә дөнья тарихында рәсми рәвештә теркәлеп калган беренче татар патшасы булуы белән кадерле, таралып яткан Татар илен бер милли байрак астына туплавы белән әһәмиятле.

## ҺУН ТАТАРЛАРЫ

Һуннар (гуннар) турында тарихта мәгълүмат күп. Әмма бу хәбәрләр безнең көннәргә хәтле бик буталып, кемнең кем булуын таный алмас хәлгә китерелеп килеп җиттеләр. Бу борынгы татар һуннарын кемдер — скифлар дип, кемдер гун, гунну, хун, хиен-ну, си-юнь дип тасвирлады, аларны сакларга, сарматларга бүлеп өйрәнделәр, алар арасыннан аргипейлар, массагетлар, тагы әллә кемнәрне эзләделәр. Борынгы татарларны нинди милләт вәкиле өйрәнсә, шул күзлектән чыгып бәя бирелде, исем-атамалар да кеше таный алмас дәрәҗәгә җиткерелеп үзгәртелде, бозылды… Бәлки, махсус да шулай эшләгәннәрдер, бу бөек тарих татарныкы булмасын, татар мәңге үз тамырларын эзләп таба алмасын өчен, шулай буташтырганнардыр… Әмма бу тарихны кем генә язса да — татарның мәңгелек

дошманы кытайлармы, татарлар тарафыннан хурлыклы җиңелгән римлылармы, тәкәббер греклармы, татар аягы астында калган көнбатыш дөньямы, әллә соңгы Татар дәүләтен җимереп, бар бөек тарихны үзенеке итәргә омтылган урыслармы — барысы да татарны түбәнәйтеп язарга тырышалар. Түбәнәйтә алмаган урыннарда, бу бөек тарихны тизрәк һичкем аңламаган, белмәгән ясалма милләтләрнеке, дип игълан итәләр… Татарныкы гына булмасын, тарихта татар гына бөек булып күренмәсен — аларның яшерен максаты әнә шундый…

Әмма чынбарлыктан беркая да китеп булмый — бөек һун-гун тарихы — ул татар тарихы. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: Кытай чыганакларында гун-һун атамасы инде безнең эрага кадәр III меңьеллыкта ук искә алынган булган. Ягъни моннан 5 мең ел элек дөньяда һун татарлары яшәгән! Кытай императоры Хуан-ти алар белән безнең эрага кадәр XXVII гасырда ук сугышлар алып барган, ул чагында бу халык гун-юе дип аталган, соңрак аларны хиен-нулар, ягъни татарлар дип атап йөртә башлаганнар. Боларның барысы хакында да Кытай чыганакларында язып калдырылган.

«Аларның иле — ат сырты»,— дип әйтергә яратканнар бу гайрәтле татарлар турында. Шушы ат сыртында алар Кытайдан Кырымга, Кавказга, Европага хәтле килеп җиткәннәр, бөтен дөньяга таралып яткан кан-кардәшләре — төрки-татарларны берләштереп һәм яклап йөргәннәр. Татарга каршы булганнарны көч белән буйсындырганнар. Моннан мең, ике, өч мең еллар элек бу дөньяда татарны җиңәрлек көч булмаган.

Тарихта һуннарны Көнчыгыш һәм Көнбатыш гуннарга бүлеп өйрәнәләр, шулай ук аларның көньяк һәм төньяк бүленешләре дә бар. Ягъни һун татарларының бер өлеше үз җирләре булган Кытай, Монголия, Байкал һәм Амур тирәләрендә яшәп калса, икенче өлеше яшәүләрен Идел-Урал тирәләрендә, Алтай белән Арал арасында, Көньяк Себердә, Каспий диңгезе буйларында, Кавказда һәм Европада дәвам итәләр. Моны һун татарларының бер урыннан икенче урынга күчеп йөрүләре белән генә бәйләп карарга ярамый, алар элек-электән дә бу җирләрдә яшәгән, көн күргән булганнар. Һун татарларының җир биләмәләре киңәйгән саен, бу исем астында йөртелүчеләр дә күбәя бара. Шулай итеп, безнең эраның башларында, ягъни 200—500 елларында, бөтен дөньяны тетрәтерлек куәтле Көнчыгыш Һун дәүләте барлыкка килә. Бары тик коллар хисабына гына көн күреп яткан, соң чиккәчә азган грек һәм Рим дәүләт системалары өчен һуннар көтелмәгән куркыныч тудыралар — алар бу бозык тормышның астын-өскә әйләндереп каплыйлар. Бу вакыйгалардан соң мең еллар үтсә дә, Европа тарихчылары үзләренең «кыргый татарлар»дан җиңелүләрен кичерә алмыйлар, шуңа күрә аларга тарихта лаеклы урыннарын да бирмиләр.

Тарихта бу һун биләмәләрен Скифия яки Германика дип тә атап йөртәләр, чөнки һун татарлары яңа эраның 376 елларында гот дип аталган герман кабиләләрен, тулысынча җиңеп, үзләренә буйсындыралар. Татарлар үз идарәләрен шулай ук Азов, Кара диңгез, Дон һәм Днепр буйларына да җәелдерәләр, Днестр тирәләрен кулга алалар. 378 елны Адрианополь янында римлылар татарлар тарафыннан хурлыклы җиңелүгә дучар була, ә Рим императоры Валет шул сугышта үлә. Шулай итеп, һун татарлары Рим империясе биләмәләренә бәреп керәләр, аның берничә шәһәрен тар-мар итәләр, Паннонияне (хәзерге Венгрия) тулысынча үз кулларына алалар. 434 елда һун татарлары Константинополь шәһәрен камап алалар, император Феодосий бик күп алтын биреп кенә шәһәрне саклап кала. Икенче тапкыр бу шәһәрне алырга легендар Атилла килә, румлылар монда да күп алтын биреп, татарларга ясак түләргә ризалашып кына исән калалар. Һун татарлары вакыты белән таш Европадан китсәләр дә, җиңелеп түгел, ат йөртерлек үз далаларын сагынып китә торган булганнар…

Һун татарларының Төньяк Кавказда идарә итүләре дә билгеле. Моңа гаҗәпләнергә дә кирәкми, чөнки бу тирәләр гомер-гомергә төрки-татар җирләре булган, көнчыгыштан бирегә кодрәтле һун гаскәре килеп чыкса да, алар үз кавемдәшләре янына ярдәмгә килгәннәр. V гасырда инде бөтен Каспий буйлары Һуннар иле дип аталып йөртелә башлаган, ә Дербент кирмәне исә «Һуннар капкасы» дип аталган. Татарлар ул заманда бирегә төп хәрби һәм сәяси көч булып исәпләнгәннәр. Шулай итеп, һун татарлары Кавказда Иранны, Армения, Грузияне, Албанияне үзләре белән хисаплашырга мәҗбүр итә. Кайвакытта бу илләр үзара сугышларында ярдәмгә һун татарларын чакыра торган булганнар. Кавказга үз планнары булган Византия бу хәлләрне зур борчылу белән күзәткән, һуннарның көчен сизеп, алар белән уртак тел табарга тырышкан. Вакытлар үтү белән, Кавказда сәяси көчләр үзгәргән, һун татарларының бу җирләр белән гасырлар буе идарә итүе, хакимлеге дә тарихта гына калган. Әмма дәүләтләре бетсә дә, милләт үзе калган, бүгенге көндә Кавказда яшәп ятучы төрки халыклар — азәрбайҗаннар, кумыклар, карачайлар, балкарлар, нугайлар кайчандыр бөек һун исемен йөрткән татар кавемнәре… Аларны да кайчандыр «татарлар» дип йөрткәннәр, хәтта чеченнарны да заманында «татарлар» дип атаганнар, бу хакта Лев Толстой әсәрләреннән укып белергә була… Тау халкы, нигездә, татар дигән горур исемне гасырлар буе йөрткән…

Безнең Идел-Урал буйларында һун татарлары яшәгәнме соң? Әлбәттә, Идел-Урал арасы бу татарларның төп Ана Йортлары булган бит, алар зур дөньяга шуннан таралганнар, шуның аша үтеп йөргәннәр, яңадан шунда җыелганнар һәм мәңгелеккә дә шунда яшәп калганнар. Бу тирәләрдән табылган күп санлы археологик истәлекләр татарларның скиф-һун чорына туры килә, алар хакында инде бөтен дөнья белә.  Әйтик, бүгенге Татарстанның Аксубай районыннан табылган бронзадан коелган борынгы һун казаннары, Пермь, Сембер, Ырынбур өлкәләрендә табылган шундый ук казаннар биредә элек-электән татарлар яшәгәнлеге турында сөйли. Татарстанның Турай авылы янында исә IV гасырның азагына караган дистәләгән борынгы һун курганнары табылган. Галимнәрнең әйтүенчә, бирегә һун сугышчылары күмелгән булган. Бу хакта курган-каберлекләрдән табылган искиткеч сугыш киемнәре, сугыш кораллары сөйләп тора, бер курганнан гына да шундый 40 төрле әйбер табылган. Алар арасында һун татарлары киеп сугышкан тимер бөҗралы көбә күлмәк, көмеш белән бизәлгән тимер баш киеме (шлем), бер метр озынлыктагы туры тимер кылыч, калкан һәм хәнҗәр, сөңге, бакыр акчалар, кызыл балчыктан яндырып эшләнгән чүлмәкләр, шулай ук чалгы, беләү, балта кебек эш кораллары бар. Болар барысы да — һун татарларының байлыгы, безнең байлык, татар халкының матди һәм рухи мирасы.

Кама елгасы буендагы Имәнкискә авылы янында да борынгы һун шәһәрлекләре, каберлекләре табылган. Биредә дә яңа эра башында һун татарлары яшәгән, алар үзләреннән зур шәһәр урыннары, тау кебек биек курганнар, сирәк табылдыклар калдырганнар. Бу археологик табылдыклар арасында шулай ук эш һәм сугыш кораллары, борынгы туран акчалары, затлы бизәнү әйберләре бар. Кызганычка каршы, Каманың түбәнге агымында урнашкан бик күп борынгы һун шәһәрләре, кирмәннәре, курган-каберлекләре, 1956 елда Куйбышев су саклагычы төзелгәч, Идел суы астында калдылар, тарих өчен мәңгегә юкка чыктылар… Идел суы актарылган вакытларда гына, яр буена борынгы татарларның баш сөякләре, сугыш кораллары, йорт кирәк-яраклары юылып чыга… Су астында калган бөек татар тарихы шулай үзе турында хәбәр бирә кебек…

Идел-Урал буйларында һун татарларының эш-сугыш кораллары гына түгел, бик затлы, алтын-көмештән ясалган савытлары да табылганы бар. Шунысы гаҗәп: алар — язулы савытлар, анда туран әлифбасы белән борынгы һуннарның дини тәгъбирләре язылган. Әмма бу курган-каберлекләрнең күпчелеге XVII—XVIII гасырларда Җаек казаклары булган урыслар тарафыннан таланып, тарихи алтын-көмеш савытлар эретелеп юкка чыга, беразы исә урыс патшасы кулына эләгә. Бүгенге көндә татарларның бу байлыгы Эрмитаж музеенда саклана. Әмма галимнәр монда да үз кирелекләренә баралар — бу алтын-көмеш савытларда туран язулары булса да, аларның эчтәлеге бүгенге татарларга бик яхшы аңлашылса да, урыс тарихчылары бу һун савытларын һиндларныкы дип исбат итәргә тырышалар. Татар тарихын талау дәвам итә… Югыйсә алтын-көмештән ясалган бу затлы һун савыт-сабалары барысы да борынгыдан һәм бүген дә татарлар яши торган җирләрдә табылган бит: Кама буйларында, Пермь, Ырынбур, тирәләрендә, Сергач мишәрләре яшәгән урыннарда… Чиләбе өлкәсенең элек-электән татарлар яшәгән җирләрендә скиф-һун курганнарының күплеген әйткән идек, аларның саны хәтта йөзләрчә. XIX гасырның ахырында зур татар авылы Мөслим янында борынгы һун хәзинәсе табыла, затлы алтын-көмеш савытлардан, туран акчаларыннан торган бу табылдыкны шундук Петербургка озаталар. Һун татарларының бу байлыгы хәзер Эрмитаж залларын бизи. Хәер, Россия музейларындагы күпчелек борынгы затлы әйберләр — һун татарларының каберләреннән табылган байлык бит ул. Әмма бу хакта әйтелми дә, язылмый да, сөйләнми дә…

Күргәнебезчә, һун татарлары, кайбер галимнәр язганча, атка атланып, гел сугышып кына йөри торган кыргый халык булмаган. Аларның тарихта зур-зур шәһәрләре булган, татарлар бу шәһәрләрдә тимер койганнар, шул тимердән, бакырдан эш һәм сугыш кораллары ясаганнар. Үз җирләреннән чыккан алтын-көмештән исә алар дөньяны сокландырырлык бизәнү әйберләре, савыт-сабалар ясаганнар. Аларның үз дәүләтләре, үз телләре, үз язулары, үз диннәре, үз акча берәмлекләре, үз патшалары, үз гаскәрләре, үз идарә системалары, үз шәһәрләре, үз мәдәниятләре, үз тарихлары булган. Бу чын мәгънәсендә татар цивилизациясе булган. Без, татарлар, шушы данлы тарихыбыз белән горурланырга, аны өйрәнергә һәм сакларга тиешбез.

## ӘТИЛ ПАТША

Дөнья тарихында аны белмәгән кеше юктыр — Атилла, ягъни Әтил патша… Үзенең атлы гаскәре белән Италия, Испания, Франция җирләренә хәтле барып җиткән, азгынлык үзәге булган Рим империясен тар-мар итүдә катнашкан, ул тирәләрдә, Дунай буйларында яшәүче күп төрки халыкларны Рим коллыгыннан азат иткән легендар шәхес…

Кайбер галимнәр аның исемен «Әтилле» — «Җиде илнең хакиме» дигән мәгънәдә аңлаталар. Алай булырга да бик мөмкин. Шул ук вакытта Әтил патшаның исеме аның Әтил-Идел елгасы белән ничектер бәйле булуына да ишарә ясый. Кайбер галимнәрнең язуынча, Атилла Дунай-Азов буйларындагы борынгы Дуло нәселеннән, Кубрат ханның да шушы нәселдән булуы билгеле. Ул чагында Әтил патшаның римлыларга каршы сугыш ачуын аңларга була, чөнки бу халыклар ул заманда Рим империясе кул астында газап чигәргә мәҗбүр булалар. Әмма кем генә булса да, тарихка ул Римны җиңгән, Европаны үзенә буйсындырган гун патшасы — т а т а р булып кереп калган. Бу хакта элек шулай ачыктан-ачык язганнар, шуңа күрә Европада татарны яратмаганнар, хәзер дә бу исемне өнәп бетермиләр. Әмма үзләренең кайчандыр татарлар тарафыннан хурлыклы җиңелүләрен хәзер исләренә төшерәселәре килми… Шул исәптән татарларны да…

Әтил патша 398 еллар тирәсендә туган һәм 56 ел яшәгән. Шунысын да әйтергә кирәк: Атилла һун тәхетендә очраклы кеше булмый, ул чыгышы-тормышы белән затлы татар ханнары, патшалары нәселеннән. Ә ул тарих менә мондый: тумышы белән Идел буйларыннан булган Баламирны 374 елда һуннар башбу итеп сайлыйлар. Ул вакытта әрсез герман кабиләләре һуннарның мәңгелек биләмәләре булган Кырым һәм Кара диңгез буйларына, Азов, Дон тирәләренә дәгъва кылалар, аны басып алалар. Баламир, зур гаскәр җыеп, кардәш һуннарны готлар коллыгыннан коткарырга юлга чыга. Ул үз юлында очраган барлык герман кабиләләрен кырып, җиңеп бара. Герман кабиләләренең бер өлеше Византиягә кача, римлыларга хезмәткә күчә, бер өлеше, һуннар кулы астында калып, алар белән берләшә. 378 елда һун татарлары Рим империясе чикләренә килеп җитәләр. Аларның башкалалары Идел буйларыннан Кара диңгез тирәләренә күчә. 395 елдан һун татарлары Рим империясенә һөҗүмне яңарталар — алар, Кавказ аша килеп, Анадалу далаларын алалар (хәзерге Төркия). Татарлар, юлда Рим гаскәрләрен тар-мар итеп, Сириягә барып чыгалар, аны тулысынча үз кулларына алалар. 400 елда Баламир үлә, тәхеттә аның улы Улдуз хан кала. 409 елны ул Византиягә каршы сугыш ача. Византия императоры һун татарларыннан килешү сорарга мәҗбүр була. 410 елны Улдуз хан үлә, аның урынына тәхеттә улы Каратун хан кала. Ул, сугышларны туктатып торып, Татар дәүләтен эчтән ныгыту белән шөгыльләнә. 415 елда Каратун хан үлә, аның урынына татар тәхетендә улы Мачуг хан кала. Ул тарихта һун татарларын берләштерүче буларак мәгълүм Олуг хан Балхаш күле буйларыннан Урал тауларында, Днепр тирәләрендә яшәгән һуннарны берләштерә ала. Атилла — менә шул Мачуг ханның улы инде. Һун дәүләте белән ул 20 ел идарә итә (434—454). Димәк, хакимияткә килгәндә әле аңа 40 яшь тә тулмаган була.

Атилла башта Рим белән тыныч яшәргә тели, әмма анда әсирлектә булган һуннарны һәм фетнәчеләрне кире бирүләрен таләп итә. Тик римлылар моны үтәмиләр, ул гына да түгел, һуннарның союзниклары булган Галлия җирләренә һөҗүм итәләр. Римлылар бу сугышта җиңелүгә дучар булалар, әмма һуннарга һөҗүмнәрен дәвам итәләр, килешүләрне даими бозып торалар. 442 елда Марг шәһәре епископы һуннарның борынгы курганнарын талата, андагы алтын-көмеш әйберләрне урлый. Горур Атилла инде монысына түзеп тора алмый: атлы гаскәре белән Рим җирләренә бәреп керә. Шушы кузгалыштан ул Балкан ярымутравына хәтле барып җитә, юлында очраган Рим гаскәрен тар-мар итә бара. Коты чыккан Рим каршына Атилла төп таләп куя: колларны азат итәргә, фетнәчеләрне кайтарып бирергә, контрибуция түләргә, һун җирләренә башка якын килмәскә. Әмма Рим Атилланың бу таләпләрен үтәргә ашыкмый, киресенчә, аны үтертергә план кора. Әмма аларның бу явыз планнары барып чыкмый. Рим һуннарга каршы мәкер коруын дәвам итә, Атилла куйган таләпләрне үтәргә ашыкмый. Һуннар белән Рим арасында сугыш котылгысыз була.

Борынгы тарихчылар күрсәткәнчә, Атилланың гаскәрендә ярты миллион кеше булган. Колбиләүчеләр империясенә каршы көрәшкә һуннар гына түгел, римлылардан газап күреп яшәгән герман кабиләләре дә, хәтта славяннар да катнашкан. Атилла үз юлында очраган бөтен шәһәрләрне ала барган, Франция аша Италиягә бәреп кергән, Әдрән диңгез буйларына барып җиткән, Аквелия, Милан шәһәрләрен яулап алган. Алда — Рим үзе, һәм аны алырга бернинди каршылык калмаган. Әтил патша бу сугышларның үзәгендә булган, һөҗүмнәрне даһи гаскәриләр кебек оештырган. Уртача буйлы, киң күкрәкле, зур башлы, бөркет карашлы мәгърур бу татар гаҗәеп дәрәҗәдә зирәк акыллы кеше булган, аның бу сыйфатын хәтта дошманнары да танырга мәҗбүр булганнар. Тарихчылар хәбәр иткәнчә, һуннар ягыннан бу сугышларда җирле кабиләләр, аларның башлыклары һәм корольләре дә катнашкан. «Атилла берүзе, шул корольләрнең короле буларак, алар арасында калкып тора һәм барысын да кайгырта,— дип яза соңыннан VI гасыр тарихчысы Иордан.— Бер күз ташлау белән, аларның һәркайсы, коты очып һәм тетрәнеп, берсүзсез шунда ук аның каршында пәйда була, ул ни боерса, шуны үти».

Тарихта Атилланың Каталон кырында «Халыклар сугышы» дип аталган канкойгыч, хәлиткеч сугыш алдыннан сөйләгән нотыгы да билгеле.

— Шулхәтле күп халыкларны җиңгәннән соң, сезне буш сүз белән дәртләндереп торуның мәгънәсе юк,— дип башлый үзенең сүзен Әтил патша.— Бүген дә җиңсәгез — бу бөтен дөньяны буйсындыру булачак. Сезнең өчен сугыштан да таныш тагы нәрсә бар? Каһарман ир өчен дошманнан үч алырга омтылудан да мөһимрәк нәрсә бармы? Рухыңны үч тойгысы белән тутыра алу — ул табигатьнең олуг бүләге. Шуңа күрә тизлек белән дошман өстенә ыргылыйк, чөнки һөҗүм иткән кеше — ул батыр кеше… Без бәрелешнең иң кызган җирендә тиз арада җиңүгә ирешергә тиешбез. Сеңергә чабылса — әгъзалар коелып төшә, әгәр сөяген суырып алсаң —гәүдә басып тора алмый. Рухыгыз уянсын, сезгә хас булган ачу кайнасын! Хәзер, һуннар, моны аңлавыгызны күрсәтегез, коралга ябышыгыз! Кем дә кем яраланса — дошманының үлеменә ирешсен, исән калса — аның канын койсын! Җиңүгә омтылганнарны бернинди дә ук алмый, ә үлем эзләп йөргәннәрне тәкъдир тыныч вакытта да шуңа дучар итә. Шушы сугыштан соң тантана итәрлек булмагач, нигә язмыш һуннарны күпме кабиләләрне җиңүче итеп билгеләде соң? Һуннар җир йөзенә сыймаслык булып монда җыелганнар. Бу сугышның нәтиҗәсе нинди буласына мин шикләнмим, әнә безгә җиңү вәгъдә иткән сугыш кыры! Дошманга беренче булып укны үзем атам. Кем Атилла бәргәндә кузгалмаса, ул инде җирләнгән!

Әйткәнебезчә, татар сугышчылары юлларында очраган бөтен шәһәрләрне ала барганнар һәм Рим капкасы төбенә килеп туктаганнар. Әмма акыл иясе Атилла Римны туздырып ташларга ашыкмаган, ул алар алдына тагы бер тапкыр үзенең таләпләрен куйган. Шәһәрне ярты миллионлы гаскәре белән чорнап алган бу татар патшасы каршында Рим үзенең көчсез, чарасыз икәнен танырга мәҗбүр булган. Эшнең ни дәрәҗәдә куркыныч икәнен аңлаган Рим папасы Леон, бөтен руханиларын һәм император Валентинның илчеләрен җыеп, Атилла каршына чыгып баш ияргә мәҗбүр булган. Алар бөтен христианнар исеменнән Атилланың шәһәргә кагылмавын үтенгәннәр, анда бөтен дөнья җәүһәрләре туплануын әйткәннәр. Зирәк акыл иясе Атилла Римга кагылмаган, алардан бары тик контрибуция өчен күп итеп алтын алган һәм йөз меңләгән әсирләрне, колларны азат иткән. Ике арада килешү төзелгән. Әйе, Атилла Римны алмаган, Паннониядә урнашып калган, әмма шул ук вакытта Көнчыгыш Рим империясе биләмәләрен — Византияне даими күзәтүдә тоткан. Константинопольнең һуннар патшасы Атиллага зур күләмдә алтын һәм ясак түләп торырга мәҗбүр булуын да онытмаска кирәк.

Римны, Византияне, бөтен Европаны үз каршында калтыратып торган, Дунай һуннарын һәм Европаның җирле кабиләләрен Рим коллыгыннан азат иткән зирәк һәм батыр һун патшасы Атилла 454 елны үз сараенда, яткан җирендә вафат була. Яшерен дошманнары тарафыннан үтереләме бу батыр татар, әллә тәкъдире шулай буламы — ул ерак Паннония җирләрендә мәңгелеккә ятып кала. Далада тагы бер курган калка… Һун татарлары өчен Әтил патшаның үлеме тиңсез зур кайгы була. Бөек Һун дәүләте аның үлеменнән соң таркала. Тарихта «Скифика яки Германика» дип йөртелгән куәтле Татар дәүләте юкка чыга. Әмма милләт бетми, башка җирләрдә, башка исемнәр астында, татарлар әле тагы дистәләгән дәүләтләр төзиләр, мәңгелектән килгән яшәүләрен дәвам итәләр… Тарих сәхнәсеннән, әкренләп, «һун», «скиф» дигән сүзләр төшеп калса да, мәйданга шул ук татарларның «төрки», «болгар», «хәзәр», «кыпчак» кебек яңа исем-атамалар килә. Сары диңгездән Кара диңгез буйларына хәтле сузылган яңа татар дәүләтләре күтәрелеп чыга: Төрки каганат, Хәзәр каганаты, Уйгур каганаты, Кимак каганаты, Бөек Болгар, Идел буе Болгарстаны, Алтын Урда, Ак Урда, Күк Урда, Казан ханлыгы, Себер ханлыгы, Әстерхан ханлыгы, Касыйм ханлыгы, Нугай Урдасы, Зур Урда… Боларның барысы белән дә татарлар идарә иткән, бу җирләрдә татар халкы яшәгән…

## ТАТАРЛАРНЫҢ ТӨРКИ КАГАНАТЫ

Яңа эраның башында, бигрәк тә III—V гасырларда, Европа халкы, тарихчылар татарларны гуннар-һуннар дип атап йөрткәннәр. Ә көнчыгышта исә шул ук борынгы һун татарларының исеме бу чорларда тарихка «төрки» «түрк» исеме белән керә башлый. Безгә калса, бу исем — һун татарларына карата бирелгән сыйфат атамасы, ягъни милләтнең терелеген күрсәтә торган билге, тереклек тамгасы… Чыннан да, ул заманда татарлар терекөмеш кебек тере булганнар, хәрәкәтчән, гайрәтле булганнар. Әйтерсең лә алар тере суы эчкәннәр һәм бу дөньяда мәңге тереклек итәргә тәкъдирдән әманәт алганнар… Әйткәнебезчә, тарихка бу татарлар төзегән дәүләтләр «Төрки каганат» буларак кереп калган. Әмма татарлар үзләре ул заманда дәүләтләрен башка төрлерәк атаганнар — аның исеме «Ил» булган. Ягъни Түрк иле. Моны Терек иле дип тә, Түр ил дип тә аңларга була. Түр, түрә, түрәлек ул дәрәҗә билгесен дә күрсәтә, хакимлеккә ишарә ясый… Кояш чыгышының түрендә, тәхетендә утырган бу татарлар Кытайдан Урал тауларына хәтле булган араларда җәелеп, хуҗа булып яшиләр, Каспий һәм Идел буйларын үз буйсындыруларында тоталар. Бу чын мәгънәсендә дөньяда тиңе булмаган, таралып яткан Татар иле була…

Һун татарларының яңадан куәтле ил, дәүләт булып оешулары VI гасырның урталарында, ил белән Бумын каган идарә иткән елларда була. Бу вакытта инде алар Алтай тауларында ныклап тимер чыгару, тимер эшкәртү белән шөгыльләнә башлаган булалар. Алар үзләре генә белгән алымнар белән корычтан корал коялар, кылыч, сөңге, ук, балта-пычаклар, казаннар ясыйлар. Тимерне татарлар Алтайдан гына түгел, хәзерге Тува, Хакасия җирләреннән, Урал тауларыннан да алалар, алар биредән шулай ук алтын һәм көмеш тә табалар, кургаш, җиз эшкәртәләр. Шулай итеп, бөтен Үзәк Азиядә татарлар беренче булып тимер эшкәртергә өйрәнәләр, бу исә аларны Кытайдан һәм башка илләрдән бәйсез хәлгә куя. Тарихи табылдыклардан күренгәнчә, татарларның атлы гаскәре тоташы белән тимергә төренгән була. Шушыннан файдаланып, 552 елны Бумын каган үзләрен гел ирексезләп торган явыз жужаннарны тар-мар итеп ташлый, хәзерге Монголия җирләренә барып чыгып, анда яшәүче төрки һәм монгол кабиләләрен үзенә буйсындыра. Биредә һун империясенең элеккеге башкаласы Әтүкән яңадан торгызыла, Бумын каган шунда яши башлый. Шушы бер ел эчендә Бумын каган Кытайдан Каспийгача сибелеп яткан һун татарларын берләштереп, бер Ил — тарихи Төрки каганат төзи һәм үзен Ил-Каган дип игълан итә.

Бу борынгы Татар илендә сугыш һәм тимер эшләреннән тыш, милләтнең рухи үсешенә, мәдәнияткә һәм мәгарифкә дә зур игътибар бирәләр. Алар, һун татарларының дәвамчылары буларак, Күк Тәңресенә табыналар, ханнарны исә «Күк Уллары» дип йөртәләр. Бу татарларның үз әлифбалары, язулары була, алар ташларга чокып, үз тарихларын, ил тормышы турында язып калдыралар. Татар халкында бу борынгы язу хәзер дә «чөй язу», «таш билге», «рун язуы» дип атап йөртелә, XIX гасырга кадәр әле бу язма татарларның нәсел тамгаларында сакланып калган. Һун татарлары кебек үк, төрки-татарларның да яшәү рәвеше, тормыш тәртипләре бер- төсле булган. Биредә дә кеше үтергән өчен, зина өчен үлем җәзасы көткән, шулай ук төрле фетнәләр, хыянәт, караклык, бигрәк тә ат урлау үлемгә хөкем ителгән. Татарларның үзләре төзегән хокук тәртипләре һәм судлары булган. Илдә бөтен эшләр дә киңәшеп эшләнгән, ханнан тыш, аның морзалары һәм бәкләре дә милләт тормышында зур урын тотканнар. Татар илендә галимнәрнең дә дәрәҗәсе бик зур булган, алар ханнарга үзләренең төпле киңәшләрен биргәннәр, халыкның әхлак сагында торганнар. Бу уңайдан Йосыф Баласагуниның «Бәхетле булу фәне» китабы бик кызыклы. Аны хәтта дәүләт белән идарә итү буенча трактат, күрсәтмә дип тә әйтергә була. Хан һәм аның тирәсендәге идарәчеләр нинди булырга тиеш —борынгы китап шул сорауларга җавап бирә. Халыкка гадел хезмәт итү, миһербанлы булу, алдамау — менә авторның татар түрәләре алдына куйган таләпләре. Бу таләпләр бүген дә бик урынлы яңгырый.

Менә шундый рухи нигезгә таянып, баштанаяк корычтан коралланып, татар ирләре бу дөньяда үзләрен генә түгел, хәтта башка кыерсытылган халыкларны якларлык дәрәҗәгә җитәләр. Бумын каганның улы Истеми каган атасы башлаган изге эшне дәвам итә — татарларны берләштерү өчен яңа яуларга күтәрелә. Бер яктан, астыртын Кытай, икенче яктан, мәкерле Византия тарафыннан гел кысрыкланып, таланып килгән чик буе төрки-татарларны яклап, Истеми хан дөньяның төрле кыйтгаларына барып чыга. Ул үзенең идарәсен, биләмәләрен, һун бабалары эзе буйлап, Көнбатышка да, Урта Азиягә, Идел буйларына, Төньяк Кавказга да җәелдерә. 558 елны алар Идел ярларына кабат татар байрагы кадыйлар. Бумын каганның уллары Муган каган белән Таспар каган исә Татар дәүләтенең чикләрен тагы да киңәйтә төшәләр — алар Үзәк Азияне һәм Көньяк Себерне үз кулларына алалар, анда да үз тәртипләрен кертәләр. Ул чагында ук дөньяның иң көчле дәүләтләреннән булган Иран Төрки каганат белән үз биләмәләрен бүлешергә мәҗбүр була — Амударьядан көнчыгышка һәм төньякка таба бөтен җирләр татарлар кулына күчә. Татарлар Бөек Ефәк Юлын үз кулларына алалар, аңа контроль оештыралар. Кытайның төньягындагы борынгы татар җирләре дә кабат татарлар кулына күчә, шулай итеп, Татар дәүләте Сары диңгездән Кара диңгезгә хәтле сузыла, һуннар империясеннән дә зур була. Көнбатышта исә татарлар тагы Константинополь капкасына хәтле барып җитәләр. 568 елны татар илчесе Маниахны император Юстиниан II кабул итәргә мәҗбүр була. Татарлар римлылар һәм греклар алдына үз таләпләрен куялар, аларны сәүдә һәм хәрби эшләрдә татарларга файдалы булган килешүгә этәрәләр. Шулай итеп, VI гасырның ахырында, татар ханнары, Татар дәүләте бөтендөньяга билгеле державага әйләнә. Ул Византия, Кытай, Иран белән хәрби һәм икътисади элемтәләр урнаштыра, Көнчыгыш белән Көнбатыш арасындагы сәүдә юлларын үз кулына ала. Бу чорда Татар иле үзенең чәчәк ату вакытын кичерә.

Билгеле булганча, татарларның Төрки каганаты Урта Азия һәм Көнчыгыш Европа халыклары тарихында зур роль уйный. Татарлар ул ил-җирләрне җимермиләр, анда яшәүче халыклардан ясак кына алып торалар. Бу ясакның төп өлеше шушы халыкларны ук тышкы дошманнардан саклауга, ягъни гаскәр тотуга китә. Татарлар, бөтен дөнья белән сәүдә итеп, үз кул асларында яшәгән халыкларга яңа тормыш, яңа сулыш алып киләләр, аларны дөнья цивилизациясе белән таныштыралар. Әлбәттә, татарларның үз алтын һәм бакырларыннан коелган үз акчалары да була. Татарлар язма мәдәният туды-

ралар, шушы мәдәният аша башка халыкларга да рухи азык бирәләр, аларны цивилизацияле тормышка тарталар. Татарлар бу чорда күп шәһәрләр төзиләр, архитектура бик нык үсә, сәнгать үсә. Бу чор шәһәрлекләреннән табылган алтын-көмеш бизәнү әйберләре күпләрне таң калдырырлык. Шулай ук халыкка аралашу җайлы булсын өчен, бу чорда күп кенә яхшы юллар төзелә, почта станцияләре барлыкка килә.

Әмма шул хәтле зур империя белән идарә итү елдан-ел кыенлаша бара. 581—603 елда Төрки каганат икегә — Көнбатыш һәм Көнчыгыш Татар каганатларына бүленә. Көнбатыш Татар дәүләтенә — Алтайдан башлап Кара диңгезгәчә җирләр, Көнчыгыш Татар дәүләтенә Алтайдан башлап Бөек Кытай стенасына кадәр җирләр керә. Әмма 630 елда бу ике Татар дәүләте дә яшәүдән туктый. Моңа, бер яктан, Кытай, Византия, Иран дәүләтләренең татарларга өзлексез һөҗүмнәре һәм милләтне таркату өчен алып барылган мәкерле эшләре сәбәпче булса, икенче яктан, татарларның үз арасында килеп чыккан таркаулык, эчке тәртипнең җимерелә башлавы этәргеч ясый. Бу Татар илендә, татарлар кул астында дистәләгән башка халыклар яшәгәнен дә искә алырга кирәк. Алар исә, идарә бераз йомшару белән, үзләренә мөстәкыйльлек даулый башлыйлар, олы Татар иленнән кисәк-кисәк булып аерылып чыгарга тотыналар. Әмма Татар иленең үзәге әле барыбер нык тора, милли һәм хәрби традицияләр элеккечә дәвам итә. Нәтиҗәдә шактый таркалган, өзгәләнгән дәүләт урынына, 680 елларда, үзәге хәзерге Монголиядә булган яңа Шәркый Төрки каганат, икенче төрле итеп әйткәндә Күктүркләр дәүләте барлыкка килә. Ул 740 елларга хәтле яши. Бу чорны без данлыклы Күлтәгин, Таньюкук, Билге каганнар чоры буларак беләбез… Бу чорны без аларның кабер ташларына чокып язылган татар тарихы аша беләбез… Бу чорны без куәтле Татар иленең таркала башлаган чоры буларак беләбез…

## КҮЛТӘГИН, БИЛГЕ КАГАН, ТАНЬЮКУК

Татар тарихында бу өч татар ирен, бу батыр һәм зирәк шәхесләрне аерып карап булмый. Алар бер чорда — VIII гасырда яшәгәннәр, Күктүркләр дәүләте белән идарә иткәннәр, бер вакытта — 731—734 елларда үлгәннәр… Бу өч баһадирның тарихы, әйткән сүзләре, васыятьләре кабер ташларына язып калдырылган һәм безнең көннәргә хәтле килеп җиткән…

Билге каган (Мәгыйлән) һәм Күлтәгин — легендар Кутлуг (Илтәреш) ханның уллары. Таньюкук исә Кутлуг ханның да, аның улларының да зирәк киңәшчесе, яубашы була. Бу шәхесләр барысы да — тарала башлаган Татар илен яңадан бер йодрыкка җыярга омтылучылар, үз чорларында зур уңышларга ирешкән яугирләр, каһарман ирләр. Бу чорның соңгы данлыклы ханы Билге каган булганлыктан, аның тормыш юлына тукталып үтәрбез.

Билге каган хан тәхетенә 716 елларда утыра. Энесе Күлтәгинне ул шунда ук гаскәр башы итеп билгели, ә кайнатасы, чал чәчле зирәк Таньюкукны үзенең киңәшчесе итеп куя. Билге каган хакимлегенең беренче көннәреннән үк таркау татар халкын берләштерү, ил эчендә тәртип урнаштыру максаты куя. Ул вакытта Кытай шымчылары, татарлар арасына үтеп кереп, мәкер һәм алдау белән аларны үз якларына аудара башлаган булалар, ягъни сатып алалар. Нәтиҗәдә ефәккә алданган татарлар күпләп Кытай ягына чыга башлыйлар һәм, әкренләп, милли йөзләрен югалталар. Билге каган бу мәкерле эшкә кискен каршы чыга, кытайларның мәкерен аңлатып, халыкка мөрәҗәгать итә. Күпләр, моны аңлап, илләренә кире кайталар. Кытай хөкүмәте, татарларны алдап үз ягына аудара алмагач, аларга каршы тагы сугыш ача, татарларга каршы сугышта кайбер төрки кабиләләрнең сатлык башлыклары да катнаша. Ул чакларда төрки уйгурларның да Кытай яклы булып сугышуын әйтеп үтәргә кирәк.

Каһарман Билге каган әлеге сатлык кабиләләрне дә, кытайларның үзләрен дә бу сугышта тар-мар итеп ташлый. Ул Кытай императорына, янәшә тыныч яшәү хакына, солых төзергә тәкъдим итә. Тәкәббер Кытай императоры, татарлар белән килешү төземәсә дә, тиз генә яңадан аларга һөҗүм итми. Билге каган да яңадан кытайларны сугышлар белән борчымый, чөнки аның төп максаты күршесе белән сугышып тору түгел, үз халкын саклап калу һәм иминлектә яшәтү була. Һәм ул өлешчә моңа ирешә дә, Билге каган идарә иткән 722—741 елларда Кытай янәшәсендәге Татар иле зур сугышларны белми, тыныч яши, нәсел калдыра, иҗат итә. Бу өч баһадир ир — Билге каган, Күлтәгин һәм Таньюкук — татарларны сугышлардан гына түгел, тыныч заманда кытайлашудан, милли йөзләрен югалтудан да саклап калалар. Аларның иң зур казанышлары — төрки бердәмлекне, татарның үз йөзен, үз мәдәниятен, үз бөек тарихын саклап калу була.

Зирәк карт Таньюкук, картаеп, 85 яшькә җитеп, 731 елда үлә. Батыр Күлтәгин, 40 сугышта катнашкан татар яугире, 46 яшькә дә җитмәгән килеш, дошманнар тарафыннан 731 елда үтерелә. Татарның зирәк, батыр ханы Билге каган 50 яшендә вакытта, 734 елда кытайларга сатылган төрк түрәсе тарафыннан агулап үтерелә…

Билге каганнан соң аның улы Юллыктәгин ил белән идарә итә, аннан тәхеткә япь-яшь, тәҗрибәсез Түрк-Билге каган утыра. Бу хәлдән оста файдаланып, татарлар кул астында яшәгән басмиллар, карлуклар, уйгурлар баш күтәрәләр һәм хакимияткә үз кешеләрен — уйгур Кутлуккул Билге каганны куялар. Шулай итеп, татарларның Төрки каганаты, Күктүркләр дәүләте, әкренләп, Уйгур дәүләтенә әйләнә башлый… Бөек Татар иле таркалу чорына керә… Соңрак Уйгур, Кимак, Кыргыз каганатлары барлыкка килер, алар, бер-берләре белән көрәшеп, бер-берләрен юк итәрләр… Соңыннан Кытай исә аларның күпчелеген тар-мар итеп ташлар…

Бу урында без Күлтәгин, Билге каган, Таньюкукларның кабер ташларына чокып язылган васыятькисәтүне урнаштырабыз. Чөнки анда Татар иленең тарала башлау сәбәпләре дөрес күрсәтелгән, милләт буларак исән калу өчен нәрсә эшләргә кирәклеге дә ачык әйтелгән. Шуны онытмыйк: бу сүзләрнең язылуына инде 1250 ел…

## ТАШКА ЯЗЫЛГАН ТАРИХ

Үзә көк тәңри
асра йагыз йир кылындукта
экин ара киши кылынмыш.

* * *

Өстә — зәңгәр күк,
аста көрән җир барлыкка килгәч,
ике арада кеше пәйда булды…

* * *

Тәңрегә охшаган, Тәңре булдырган
Тәрк билге каһан бу тәхеттә утырам.
Мин әйткәннәрнең барысын да тыңлагыз.
Тугыз-угыз кешеләре,
Минем сүзне игътибар белән тыңлагыз,
Аңларга тырышыгыз.
Алда — кояш чыгышына кадәр,
Уңда — көн уртасына кадәр,
Артта — көн батышына кадәр,
Сулда — төн уртасына кадәр
Яшәүче бар халык миңа буйсына.
Аларның тормышын мин җайга салдым.
Әтүкән халкының үзенә лаеклы хөкемдары юк иде,
Әтүкән халкы кабиләләрен берләштереп була иде.
Ләкин алар, табгачлар (кытайлар) күршесенә урнашып,
Табгачлар белән элемтәгә керделәр.
Алтын, көмеш, хәмер, ефәк өләшкән
Табгач халкының теле татлы,
Ефәге йомшак иде.
Татлы теле, йомшак ефәге белән
Ул башка халыкларны үз ягына аударды.
Юньле, акыллы кешеләрне,
Юньле, батыр кешеләрне табгач халкы
үз ягына аудара алмады.
Кабиләләре, хәтта туганнары ялгышканда да,
Алар төрки канунга тугрылыклы булып калдылар.
Татлы сүзгә, йомшак ефәккә алданып,
Син, төрки халкы, харап булдың.
Юньсез кешеләр сезгә мондый үгет бирделәр:
«Бездән ерак яшәүчеләргә начар бүләк бирәләр,
Безгә якын яшәүчеләргә яхшы бүләк бирәләр».
Наданнар, бу сүзләрне тыңлап,
Табгач җирләренә якын урнашып, күпләп харап булдыгыз.

Бу илгә барсаң,
Тәрк халкы, син харап булырсың.
Өтүкән җирендә яшәсәң,
Бу якка сәүдә кәрваннары гына озатсаң,
Бер хәсрәтсез яшәрсең.
Өтүкән җиреннән купмасаң,
Син башка кабиләләр белән мәңге тату яшәр идең.
Төрки халкы, син киләчәк турында уйламыйсың,
Бүген туйганчы ашасаң, иртәгә ач каласыңны белмисең.
Син үзеңне бергә җыйган каһанның сүзләренә
Колак салмаганга күрә, төрле урынга күчеп йөрдең,
Тәмам арыдың, йончыдың.
Тәңре рәхим-шәфкать күрсәтте,
Үземнең дә бәхетем бар икән:
Мин каһан тәхетенә утырдым.
Тәхеткә утыру белән мин ярлы халыкның
Барысын да бергә җыйдым.
Хәерчеләрне бай иттем,
Аз халыкны күп иттем.
Минем бу сүзләремдә ялган бармы?
Төркинең бәкләре һәм халкы, сүземне тыңлагыз!
Кабиләләрне ничек берләштерергә кирәклеген әйтеп,
Мин монда ташка чокып яздым.
Ялгышу нәтиҗәсендә таркалачагыгызны әйтеп тә
Мин монда чокып яздым.
Тәхеткә тугрылыклы бәкләр,
Сезнең ялгыша торган гадәтегез бар бит!
Мин мәңгелек таш һәйкәл ясаттым,
Табгач каһаныннан сорап, таш кисүчеләр чакырттым.
Алар ташны язып тутырдылар.
Мин әйткәннәрнең бер сүзен дә үзгәртмәделәр.

* * *

Башлыларның башын идерделәр, тезлеләрне чүктерделәр.
Алга — Кадыркан иңкүлегенә кадәр,
артка — Тимер Капыга кадәр алар (үз халкын)
урнаштырдылар.
Ике арадагы үксез күк түрк (халкын) җитәкләп,
алар менә шулай (тәхеткә) утырдылар.

* * *

Алгы яктан, кояш чыгышыннан,
Бөкли даласының ыруг берләшмәсеннән, табгач, тибет,
авар, румлы, кыргыз, өч курыкан,
утыз татар, кытан, татабларда
Түрк халкының бөтенесе шулай диде:
дәүләтле халык идем,
кайда инде дәүләтем?
Кем дәүләте өчен хәзер тырышам, диде.
Каганлы халык идем,
кайда каганым?
Нинди каганга хезмәтемне, көчемне бирәм, диде.
Анам, хатын, үги аналарым,
апаларым, сеңелләрем, хатыннарым,
күпме генә булсагыз,
барыгыз да тере көе кол булыр идегез,
үле көе өйләрегездә яки юлда ята бирер идегез,

Күлтәгин булмаса,
Күбегез үләчәк иде.
Каган әткәм очканда (үлгәндә),
энем Күлтәгин җиде яшьтә калды.
Умайга тиң хатынны сөендереп,
Ун яшьтә энем Күлтәгин ир-ат булды.
Ул заманнарда коллар колбиләүче булды,
Хатын-кыз коллар шундый колларга ия булды.
Энеләр үзләренең агаларын белмәде,
уллар үзләренең аталарын белмәде.

* * *

Аз гына түрк халкы күченеп йөри икән,
Каганы Алып икән,
Киңәшчесе зирәк икән.
Шушы ике кеше исән чагында, сине, табгач халкы,
бетерәчәкләр, дим мин.
Нечкәне җыю — җиңел,
йомшакны өзү — җиңел,
Нечкә калынайса, аны туплаучы — Алып,
йомшак ныгыса, аны өзүче — Алып.
Төнен йокламадым,
көндез утырмадым.
Кызыл канымны түгеп,
кара тиремне агызып,
үзем үз хезмәтемне һәм көчемне бирдем,
үзем үк һөҗүмнәрне еракларга юнәлттем.
Туй бүлмәсендәге хатыннарым, сездән,— ни үкенеч! —
үз улларым, сездән аерылдым.
Йөз ир кардәшемә тиң көчем булганга,
алар йөз үгез белән сугышырлык булганга аерылдым.
Зәңгәр күктәге кояшны, айны җуйдым,
җиремнән,— ни үкенеч! — сездән аерылдым,
Ханымны, илемне, сезне күреп туймадым,
ханымнан, илемнән — ни үкенеч! — аерылдым.

## ТАТАРЛАРНЫҢ БӨЕК БОЛГАР ИЛЕ ҺӘМ ХӘЗӘР КАГАНАТЫ

Көнчыгышта Бөек Татар иле шулай зур үзгәрешләр кичергән кебек, илнең башка өлкәләрендә — көнбатышта, Кара һәм Хәзәр диңгезе буйларында, Идел-Урал арасында да күп үзгәрешләр була. Төп халкы барыбер татар-төрки булып сакланган хәлдә, илдә дәүләтләр алышына, ханнар үзгәрә, аларның тоткан юллары үзгәрә. Ярый, хуш, Орхон-Енисей буйларындагы милләттәшләребезне калдырып торып, янә Кара диңгез буйларына, биредә борынгыдан яшәп яткан һун татарлары янына килик. Көнбатыш Төрки каганат таркалгач, биредә яңа мөстәкыйль татар дәүләтләре барлыкка килә. Хәзәр (бүгенге Каспий) диңгезе янындагы түбәнлекләрдә һәм Кавказ алдында һун татарлары яңа берләшмә төзиләр, алар үзләрен Төрки-татар каганатының варислары дип атыйлар. Тарихта, янәшәдәге диңгез исеме белән, Хәзәр каганаты дип йөртелгән бу дәүләт, нигездә, Татар дәүләте була, чөнки аның төп халкын татарлар тәшкил итә. Ә Кара диңгез һәм Азов (Азак) диңгезе тирәсендәге далаларда, Тамань ярымутравында һәм Кубань алдында татарларның Кубрат атлы берләшмәләре барлыкка килә. Тарихка бу дәүләт Бөек Болгар иле булып кереп калган, һун татарларының бу өлеше тарихта инде «болгарлар» дип йөртелә башлаган. Шунысын да әйтергә кирәк: Хәзәр каганаты да, Бөек Болгар иле дә — Көнбатыш Төрки каганатның төп варислары, аның дәвамчылары. Бу ике дәүләтнең дә халкы, нигездә, борынгы татарлар булган, алар бер телдә сөйләшкәннәр, бу дәүләтләрне кайбер вакытта икесен бер исем белән — «Бәхре Болгар» дип йөрткәннәр. Көнбатыш Төрки каганат, кызганычка каршы, шушы ике олы нәселнең —атаклы Дуло ыруы һәм Нушибилар токымының — туктаусыз бәрелешләре аркасында җимерелә. Дәреслекләрдән күренгәнчә, Кубрат үзе Византиядә, император сараенда тәрбияләнгән, шунда 619 елда чукындырылган. Ә ул үзе борынгы һун кабиләсеннән, атаклы Дуло

нәселеннән булган. Әтил патшаның да шушы ырудан икәнлеген әйтеп үтәргә кирәк. Атилла, әле үзе исән вакытта ук, 448 елда, олы улы Илләкне шушы тирәдәге җирләрнең патшасы итеп билгеләгән була. Шулай булгач, татарларның Бөек Болгарны да, Атилла империясен дә дәвам итүчеләр дип әйтергә мөмкин. Тарихта аларның 493, 499, 502 елларда Византия җирләрен басып алулары билгеле.

Татар болгарларының башкаласы Тамань ярымутравында була, Фанагория дигән исем йөртә. Әмма бу дәүләт озын гомерле булмый, аның 635 елдан 660 елларга хәтле генә яшәве билгеле. Кубрат хан үлгәч, аның уллары Кавказ алдындагы һәм Азов диңгезе тирәсендәге Бөек Болгар җирләрен үзара бүлешәләр. 679 елда Аспарух хан, Дунай буйларындагы славян кабиләләрен җиңеп, биредә Дунай Болгарын төзи, 681 елда ул Византия тарафыннан танылa. Бөек Болгарның бер өлешен исә хәзәрләр басып ала, аннан соң алар Хәзәр каганлыгына керәләр. Кубрат ханның бер улы Батбай төп җирләрдә — Кара диңгез буйларында кала, алар соңыннан Кырымны үз кулларына алалар, яу белән Днепр буйларына килеп чыгалар. Болгарларның, ягъни элеккеге һун татарларының, бер өлеше төп нигезгә — Идел-Урал арасына кайтып киткән дигән карашлар да бар. Әйе, теге яки бу сугышлардан соң, бигрәк тә каты җиңелүләрдән соң, татарларның төп нигезгә — Идел-Урал арасына чигенү очраклары тарихта булган. Болгар татарлары белән дә шул ук хәл кабатланган — алар Кубрат хан үлгәннән соң да, Хәзәр каганатында рәсми дин рәвешендә иуда дине кертелгәч тә, Хәзәр каганаты тәмам җимерелгәч тә, тынычлык эзләп, Төп Йортларына кайталар. Ләкин бу һич кенә дә Идел буенда болгарлар килгәч кенә тормыш башланган дигән сүз түгел. Тормыш биредә элек тә гөрләп торган, Идел-Урал буйларында яшәүчеләр элек-электән борынгы татар дәүләтләре составында булганнар, алар белән бергә ил тотканнар, нәсел калдырганнар, шәһәрләр төзегәннәр. Кара диңгез һәм Хәзәр диңгезе буйларыннан кайткан аз санлы болгарлар шул гөрләп торган татар тормышына килеп кенә кушылганнар…

Инде Хәзәр каганаты турында да бераз сөйләп үтик. Әйткәнебезчә, биредә дә төп халык элеккеге һун татарлары була. Бөек Болгар дәүләтенең җимерелүендә хәзәрләр зур роль уйный, аларның җирләре соңыннан Хәзәр каганатына керә. Хәзәрләр турында тарихта беренче тапкыр VI гасырда телгә алына башлый, алар турында «телләре болгар теленә охшаган» диелә. Ягъни хәзәре дә, болгары да борынгы һун татарларының варислары булалар. Хәзәрләрнең Барс иле дип аталган, хәзерге Дагстан территориясендә яшәүләре дә билгеле. VII гасырда алар, Төрки каганаттан чыгып, үз дәүләтләрен төзиләр, үзләрен Төрки каганатның бердәнбер дәвамчылары дип игълан итәләр. Дагстан, Кубань, Азов тирәләре, өлешчә Кара диңгезнең төньяк буйлары, Төньяк Кавказ, Кырым, Идел буйларына хәтле җирләр Хәзәр каганаты биләмәләренә керә, бу 4 айлык атлы юл була. Хәзәр татарларының беренче башкалалары булып Бәләнҗәр шәһәре тора, кирпечтән салынган бу зур шәһәр башнялар белән әйләндереп алынган була. Икенче башкалалары булып Сәмәндәр шәһәре тора, әмма алар монда озак калмыйлар. Хәзәр татарларының өченче башкалалары булып Итил шәһәре тора, ул Идел елгасының Каспийга коя торган урынында була.

Шунысын да әйтергә кирәк: Хәзәр каганаты Византия һәм Гарәп хәлифәтенең көндәше була. Хәзәр каганатының төп халкы төрки-татарлар булса да, идарәгә килгән яһүдиләр илгә үз диннәрен кертәләр. Халык моның белән ризалашмый, мөселман-татарларның бер өлеше Идел буйларына китеп бара. Гарәп-хәзәр сугышларының төп сәбәбе нәкъ менә шул яһүдиләрдә булган булырга тиеш. 737 елда гарәпләр каганатның башкаласы Сәмәндәрне алалар, хәзәр каган Иделнең түбән өлешенә качарга мәҗбүр була. Алга таба Хәзәр каганаты Гарәп хәлифәлеге белән килешү төзи, һәм ил халкы үз теләге белән ислам динен кабул итә. Шуннан соң Хәзәр каганатында иминлек урнаша. Итил шәһәрендә, мәсәлән, бер зур Җәмигъ мәчет һәм 30 гади мәчет булганлыгы билгеле. Мөселманнардан тыш, биредә иудилар, христианнар, мәҗүсиләр дә үзара тату яши. Каган үзе һәм аның даирәсе яһүдиләрнең иуда динендә булса, төп татар халкы һәм гаскәр ислам динендә була. Бу чорда Хәзәр каганатында сәүдә, шәһәр төзелеше, сәнгать нык үсә, төрки-татар халкының элек-электән килгән һөнәрләре — игенчелек һәм терлекчелек тә нык була, бакчачылык һәм балыкчылык һөнәрләре киң тарала. Көнчыгыш Европада беренчеләрдән булып хәзәр татарлары үзләренең тимер акчаларын чыгара башлыйлар. Халык элеккечә рун язуыннан файдалана, ислам дине кергәч, гарәп әлифбасы да киң тарала. Хәзәр татарларының бу чорыннан безгә рухи мирас булып бик күп шәһәр һәм авыл урыннары, тарихта «Салтово-маяцкая» дип аталган мәдәният, археологик табылдыклар калган.

Идел буйларында, Кавказда һәм Кырымда гөрләп чәчәк атып яткан, даны инде бөтен дөньяга таралып өлгергән Хәзәр каганаты нидән җимерелә, юкка чыга соң? Бөек Болгар илен дә үз эченә алган Хәзәр каганатын 965 елда Русь кнәзе Святослав җимереп ташлый. Урыслар аңа кадәр дә инде хәзәр татарларының биләмәләренә күп тапкырлар һөҗүм иткән булалар, алар Каспий диңгезендә угрылык кылалар (ушкуйниклар), хәзәрләрне талыйлар, үтерәләр. Икенче яктан, борынгы көндәш Византия дә җай чыккан саен татар җирләренә һөҗүм итә, аны тыштан һәм эчтән таркату өчен тырыша. Инде көчәеп, аякка басып килә торган Идел буе Болгарстанын да исәптән чыгарырга ярамый, чөнки алга

таба бөек татар дәүләтләренең төп варисы булып тарихта ул калачак. Бу елларда табигать бәла-казаларының күп булуын да искә алырга кирәк. Ул чорда Каспий диңгезе бик нык күтәрелә һәм хәзәр татарларының җәннәттәй җирләре су астында кала, алар үзләре күпләп Урта Идел буйларына һәм Дон тирәләренә күчәргә мәҗбүр булалар. Шулай итеп, X гасыр ахырына Көнбатыш Төрки-татар каганатының төп варисы булган Хәзәр каганаты тәмам таркала, Татар иле белән идарә Урта Иделгә — Болгар дәүләтенә күчә…

## ТАТАРЛАРНЫҢ ИДЕЛ БОЛГАРСТАНЫ

Идел буйларында Татар дәүләте Азов тирәләреннән болгарлар күчеп барлыкка килгән дигән ялгыш фикер бар. Әйтерсең лә аңа кадәр Идел — Урал арасында яшәүче татарларның дәүләтчелеге булмаган, әйтерсең лә алар кешесез кыргый далада яки тау тишекләрендә, дөньядан яшеренеп яшәп ятканнар. Бу һич кенә дә алай түгел. Идел-Урал татарларының дәүләтчелек тарихы меңнәрчә елларга сузыла, алар скиф, һун, татар каганатларының нигезен тәшкил иткәннәр, шушы дәүләтләрне оештыруда һәм алар белән идарә итүдә катнашканнар. Сары диңгездән Кара диңгезгәчә дәвам иткән Татар (Төрки) каганат Идел — Урал татарларының да дәүләте булган, патшалыкның көнчыгышыннан көнбатыш биләмәләренә юл Идел-Урал аша узган. Ә инде һун татарларының Көнчыгыш һәм Көнбатыш каганатлары таркала башлагач, милләтнең төп көчләре тагы Идел — Урал буйларына тупланган. Бер төркем Европа һуннарының (аларны тарихта болгарлар дип йөртәләр), бабаларының эзе буйлап, Идел буйларына килеп чыгуы — тарих өчен гадәти хәл. Алар ныклы нигезе булган, татар тормышы белән гөрләтеп яшәп яткан милләттәшләре янына килгәннәр. Ул вакытта инде Идел — Урал арасында, бигрәк тә Урта Иделдә, татарларның зур-зур шәһәрләре дә, шул шәһәрләрне сакларлык яугирләре дә, шул сугышчыларны тоташ тимердән киендерерлек металл эшкәртү осталары да, искиткеч һөнәрчеләре дә, бизәүчеләре дә, алтынчылары да, язучылары да, язулары да булган. Кубрат хан үлгәннән соң һәм Хәзәр каганаты таркалганнан соң, тарихта болгарлар дип аталган Европа һуннары менә шушы әзер шәһәрләргә, әзер цивилизациягә килеп төшәләр. Кемнеңдер җиңел кулыннан, дөресрәге чит ил тарихчылары тарафыннан, Идел буендагы бу борынгы татар цивилизациясенә «болгар» тамгасы сугыла. Әйтерсең лә алар килгәнче монда татарлар яшәмәгән! Татарның нинди зур тарихы булганлыгын, ул биләгән җирләрнең ярты дөньяны алып торуын без инде язып үткән идек, аны кабатлап тормыйбыз. Шуны гына кабат-кабат ассызыклап әйтәбез: Идел буе Болгарстаны ул — шул ук Татар дәүләте, болгарлар дип йөртелгән кавем — шул ук һун татарларының дәвамчылары. Безнең өчен бирегә болгарларның кайчан, ничек, ничә тапкыр килүләре мөһим түгел, аларның шушы татар җирләрендә, татарлар белән бергә дәүләт тотып яшәүләре мөһим. Чөнки без Идел буе Болгарстанына тарихи татар каганатларының дәвамчысы, варисы итеп карыйбыз.

Тарих дәреслекләрендә күрсәтелгәнчә, Идел Болгарстанының мөстәкыйль дәүләт буларак яшәү чоры IX—XIII гасырның 30 нчы елларына туры килә. Идел Болгарстаны Көнчыгыш Европада иң зур дәүләтләрнең берсе була. Аның төп җирләре — Идел — Урал арасы, көнбатыш Кама аръягы, Идел, Кама, Свияга, Шушма елгалары буйлары, бүгенге Ульяновск, Самара, Пенза өлкәләре җирләре, төньяктан Пермь тирәләре. Идел Болгарстаны ул, нигездә, Калалар иле булган, бөек шәһәрләре, аларда гөрләп торган сәүдә, мал, һөнәрчелек, мәгърифәт белән бөтен дөньяны ул таң калдырган. Бу дәүләтнең иң борынгы һәм данлыклы калалары булып Болгар, Биләр, Сувар шәһәрләре тора. Моннан тыш тагы Җүкәтау, Кашан, Тубылгытау, Тухчин, Әшил, Казан, Ташкирмән һәм башка бик күп эреле-ваклы шәһәрләр булган, галимнәрнең әйтүенчә, аларның саны 170 кә җиткән. Аларның кайберләрендә хәтта унар мең кеше яшәгән, ул заманнар өчен бу инде бик зур сан. Идел Болгарстанының башкаласы булып торган Биләр каласы исә территориясе буенча урта гасыр шәһәрләре Киев, Париж, Лондоннан да зуррак булган, бу хакта тарих китаплары сөйли. Биләр шәһәре ул чагында 800 гектар җирне биләгән, Париж, Милан һәм башка Европа шәһәрләре исә 200—400 гектар җир биләгәнлеге билгеле. Ә Киев һәм Смоленск, Суздаль, Владимир кебек шәһәрләрнең мәйданы нибары 100 гектар җирне биләгән. Бүгенге көндә иген кыры астында калган Биләр шәһәре урыны үзенең зурлыгы белән, чыннан да, хәзер дә таң калдыра. Галимнәрнең әйтүенчә, Биләрнең үзәгендә Хан сарае булган, шунда ук Җәмигъ мәчет эшләп торган, янәшәдә ханнар каберлеге булган. Шәһәр ак таштан, яхшы кирпечтән салынган булган, арада агач йортлар да очраган. Биләр-Болгар шәһәрләре үзләренең кәрвансарайлары, базарлары, сәүдәгәрләре белән гөрләп торган. Биредә Ираннан, Һиндстаннан, Кытайдан, Урта Азиядән, Көнбатыш Европадан, Скандинавия илләреннән, Киев Русеннан килгән байлар сәүдә иткән, алар үз йортларын салып яшәгәннәр. Сәүдә куәте буенча Идел Болгарстаны, Греция белән Ираннан кала, дөньяда өченче урында торган.

Әйткәнебезчә, Идел Болгарстаны югары икътисадлы дәүләт була. Авыл хуҗалыгы һәм сәүдәдән тыш, биредә һөнәрчелек бик нык үсә. Биш меӊ еллык борынгы Аркаимнан килгән традицияләрне дәвам итеп, болгар татарлары биредә тимер чыгаралар, чуен коялар, тимер эшкәртәләр, аннан эш һәм сугыш кораллары ясыйлар. Биредә шулай ук бакыр һәм бронзадан савыт-саба ясау да бик киӊ таралган була, борынгы археологик табылдыклар шул турыда сөйли. Ә инде болгар татарлары ясаган бизәнү әйберләренә дөньяда тиӊнәр булмый, бүгенге көндә дә алар үзләренеӊ нәфислеге, затлылыгы, эчке мәгънәгә ия булулары белән таӊ калдыралар. Болгар татарлары шулай ук кирпеч, төзелеш кирәк-яракларын да үзләрендә бик яхшы сыйфат белән җитештерәләр, ул заманда салынган биналарныӊ бүген дә нык торуы шул хакта сөйли. Бүгенге көнгә хәтле сакланып калган мәчет манаралары, хан төрбәләре, хөкем палаталары шуны аӊлата. Болгар шәһәрендә мәшһүр җәмәгать мунчалары булганлыгы, болгар татарларыныӊ ул чакта ук канализациядән оста файдаланулары билгеле. Алар пыяланы, бигрәк тә төсле пыяланы, бик оста итеп файдалана беләләр, шулай ук сөяктән һәм тиредән әйберләр ясап, аларны бөтен дөньяга саталар. 902—908 елларда болгар татарлары үз акчаларын суга башлыйлар, бу исә дәүләтнеӊ ни дәрәҗәдә бай, бәйсез һәм көчле булуын күрсәтә.

Идел Болгарстаныныӊ шаулап чәчәк ату чоры дәүләт ислам динен кабул иткәннән соӊ башлана. X гасыр башында ук Багдад хәлифлеге белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштырган болгар татарлары 922 елда, алар тәэсирендә, үз ирекләре белән ислам динен кабул итәләр. Кайбер галимнәрнеӊ әйтүе буенча, Урта Иделдә яшәүче татарлар ислам динен пәйгамбәребез Мөхәммәт салаллаһу галәйһиссәлам үзе исән вакытта ук кабул иткән булганнар. Хиҗри белән 9 елны, ягъни 630 елларда ук, хәзерге Болгар-Биләр тирәләренә сәхабәләр килеп, халыкны ислам диненә өндәгәннәр. Нәтиҗәдә Тукый хан һәм аныӊ даирәсе ислам динен кабул итә, сәхабәләр биредә өч ел яшиләр, мәчетләр салдыралар. Ә бер сәхабә, ханныӊ кызы Туйбикәгә өйләнеп, Идел буйларында яшәп кала. Бу хакта XII гасыр галиме Әбү-Хәмид әл-Гарнати хәбәр итә. Шуӊа күрә 922 елда болгар татарлары инде бөтен ил белән исламны җиӊел кабул итәләр, чөнки алар бу дин белән инде таныш булалар.

Ислам белән бергә Идел буйларына мөселман цивилизациясе, системалы мәгърифәт, дини һәм мәдәни китаплар, әдәбият, яӊа әлифба үтеп керә. Ташка чокып язылган рун хәрефләре гарәп язмасына алыштырыла, кәгазь керә. Бу чорда Идел Болгарстанында фәннеӊ бик нык үсеп китүе күзәтелә. Халык беренче тапкыр астрономия буенча Әл-Бируни, медицина буенча Әбүгалисина, философия буенча Әл-Фараби, математика буенча Әл-Харәзми хезмәтләре белән гарәп телендә таныша. Нәтиҗәдә тиз арада болгар татарларыныӊ үз араларыннан да күренекле табиблар, тарихчылар, галимнәр, шагыйрьләр үсеп чыга. Бүгенге көнгә хәтле Таҗетдин әл-Болгариныӊ «Агуланудан иӊ яхшы дәва» дип аталган китабы, табиб Хаҗи Болгари хезмәтләре билгеле. Шулай ук тарихчы Якуб ибн Ногманныӊ «Болгар тарихы» китабы, Борһанетдин әл-Болгариныӊ «Җәмигъ» хезмәте, Хаҗи Әхмәт-Болгариныӊ «Тәрикать» китабы, Идрис әл-Болгариныӊ дини хезмәтләре билгеле. Әмма шушыларныӊ барысы арасында да, әлбәттә, узган гасырлардан йолдыз кебек нур сибеп торучы шәхес — атаклы Кол Гали һәм аныӊ «Кыйссаи Йосыф» китабы. Кол Гали ул Идел Болгарстаны ханы Габдулланыӊ оныгы булган, аныӊ Урта Азиядә ныклы дини белем алганы билгеле. Шуӊа күрә Кол Галинеӊ Коръәннеӊ «Йосыф» сүрәсенә нигезләп, болгар татарлары телендә шигъри әсәр язуы бер дә гаҗәп түгел. Галимнәр фикеренчә, «Кыйссаи Йосыф» әсәре 1212 елда, Идел Болгарстаны үзенеӊ мөстәкыйльлеген югалтканчы язылган, һәм ул бүген дә татар халкыныӊ яратып укый торган китабы булып тора.

Болгар татарларыныӊ бик күп илләр белән сәяси һәм икътисади элемтәләрдә торганлыгы билгеле. Бу элемтә бигрәк тә Шәрык илләре белән көчле булган. Заманында Хәзәр каганатына бәйле булган Идел Болгарстаны, каганат җимерелгәч, бу бәйлелектән котыла, әмма көчәеп барган икенче як күршеләре аӊа тыныч яшәргә ирек бирмиләр. X гасырда Киев Русеныӊ Идел Болгарстанына каршы 4 тапкыр сугыш оештырганлыгы билгеле — бу 977, 985, 994, 997 елларда була, бу хакта урыс елъязмаларында теркәлеп калынган. 985 елны Киев Русе белән Идел Болгарстаны арасында мәӊгелек килешү төзелсә дә, күргәнегезчә, ул кәгазьдә генә кала, урыслар болгар татарларына тыныч яшәргә ирек бирмиләр. Алга таба да бу бәрелешүләр гел кабатлана, болгар татарлары да каршы һөҗүмнәр оештырырга мәҗбүр булалар. Тарихта болгар татарларыныӊ 1088 елда Муром шәһәрен алулары, 1107 елда Суздальгә, 1218 елда Устюг шәһәренә һөҗүм итүләре турында хәбәрләр бар. Болгар татарларыныӊ Константинополь шәһәренә хәтле сугыш белән барып җитүләре турында да әйтелә. Әмма аларныӊ төп дошманнары булып барыбер янәшәдәге урыслар кала. 1121 елда Юрий Долгорукий Болгарга җимергеч һөҗүм ясый. Шул ук гасырныӊ уртасында урыс князе Андрей Боголюбский 2 тапкыр Болгар шәһәренә, 2 тапкыр Биләргә коточкыч һөҗүм ясый, татар шәһәрләрен талый, халкын суя, үтерә. 1205 елда урысларныӊ Всеволод Юрьевич дигән князьләре тагы Болгар өстенә килеп, аны суеп, талап чыга. 1220 елда урыслар болгар татарларыныӊ Әшил каласына һөҗүм итә. Батый хан Болгарны яулап алганчы, урыслар белән болгар татарлары арасында 16 сугыш булганлыгы билгеле.

1224 елда, көнчыгыштан татар гаскәрләренең басып алу куркынычын тоеп, Идел Болгарстаны урыслар белән ике арада килешү төзи һәм 1228 елда ул тагы 6 елга озайтыла. Әмма урыслар Болгарга ярдәмгә килергә ашыкмыйлар, киресенчә, болгар татарларының көчсезләнүен теләп, аның көнчыгыш җирләренә һөҗүм итәләр. Батый хан басып алганда, Идел Болгарстаны җирләре урыслар тарафыннан таланып, эштән чыгарылып бетерелгән була, бу хакта тарихи елъязмалар сөйли.

Идел Болгарстанының дәүләт мөстәкыйльлеге 1236 елның көзендә, Батый хан гаскәре яулап алганнан соң юкка чыга. Татар тарихында, милләт тормышында әлеге вакыйга шактый каршылыклы фикерләр тудырганга, бу хакта үз фикеребезне әйтеп узабыз. Берәүләр Батый ханның Болгар-Биләрне басып алуын дөнья бетүгә тиң фаҗига итеп тасвирларга тырышалар, икенче берәүләр Болгарның Алтын Урда составына кергәч, киресенчә, тагы да көчәюен, дөньяга танылуын күрсәтәләр. Әйе, Алтын Урда составына кергәч тә, Болгар-Биләр җирләре, татар халкы үзенең яшәвен дәвам итә, сәяси, мәдәни һәм икътисади тормышында тагы да зуррак уңышларга ирешә. Ул Алтын Урда составында үз автономиясенә ия була, Урда ханнары биредә яши, Болгар исеменнән акчаларын чыгаралар. Әмма 1236 елның көзендә көнчыгыштан килгән татар кардәшләре белән бәрелешләр халык күңелендә шундый тирән эз калдырган икән, моны искә алмыйча да булмый. Кемнәр белән бәрелешкән соң болгар татарлары — бу хакта сүз алдагы бүлекләрдә булыр, иншаллаһ!

## ЧЫҢГЫЗ ХАННЫҢ ТАТАР ИМПЕРИЯСЕ

Көнчыгыш һун татарлары турында сөйләвебезне без VIII гасырның ахыры — IX йөзнең башы белән тәмамлаган идек. Әйе, дөньяны тетрәткән татар каганатлары таркалды, аның урынына ваграк төрки дәүләтләр барлыкка килгән иде —Уйгур, Кимак, Кыргыз каганатлары, Урта Азиядә караханидлар, газнәвиләр, сәлҗуклар, харәземшахлар, бүгенге Монголия җирләрендә — Чыңгыз хан империясе… Тарихта төрле исемнәр белән йөртелсәләр дә, болар барысы да татар дәүләтләре, аларның халкы да, нигездә, татарлар булган. Бу хакта дистәләгән борынгы елъязмалар, Кытай, урыс, фарсы, гарәп, рум, Европа чыганаклары сөйли, ханнарның һәм дәүләтләрнең төрки-татар исемнәре сөйләп тора. Әмма без, бүгенге мәкерле сәясәткә ияреп, аларның алдауларына ышанып, бу бөек татар тарихын, аның милли каһарманнарын әле монголларга, әле иараннарга, әле башка халыкларга бирәбез. Тарих битләреннән бу каһарманнар үзләре: «Без — татарлар!» — дип, җир тетрәтеп кычкырып торсалар да…

Кытайның төньяк читләренә урнашкан Чыңгыз хан империясе дә Татар дәүләте булган, халкы исә — без белгән һун татарларының дәвамчысы, варислары. Бу җирләр, бу халык гомер буе һун татарларының дәүләтен тәшкил иткән. Бу тирәләрдә аларның төп дошманнары кытайлар булган, һәм татарлар гомер буе алар белән сугышканнар. Бу һун татарлары Сары диңгездән Кара диңгезгә кадәр булган җирләргә хуҗа булганнар, ярты Европаны үз кулларында тотканнар. Соңыннан гына монгол дип атала башлаган Чыңгыз хан ыруы — менә шул һун татарларының бер тармагы инде, шул баһадир нәселне дәвам итүче токым. Һәм легендар Атилла артыннан, нәкъ 700 елдан соң, таралып яткан Татар илен берләштерү максаты белән, яңадан Европага юл тоткан каһарман татар ирләренең юлбашчысы ул — Чыңгыз хан. Тарихта Монгол империясе дип аталып йөрткән Татар дәүләтенең дөньяга билгеле ханы, нигез салучысы.

Чыңгыз хан татар җирләре булган монгол далаларында 1155 елда туган. Яшьтән атасыз калып, ул нибары үзенең кул көче белән яши, акылы һәм гайрәте белән ул бик тиз үз тирәсенә ырудашларын туплый ала. Кайда сугышлар юлы белән, кайда аңлатып, ул таркалып бетеп барган дала халкын, татарларны һәм монголларны, башка төрки халыкларны үз кул астына җыюга ирешә. Андагы гайрәтне һәм батырлыкны, зирәклекне күреп, халык аны үзенең ханы итеп сайлап куя. Бу хәл 1206 елны татарларның борынгы башкаласы Каракорым шәһәрендә була, чөнки Чыңгыз хан үзенең станын шунда күчерә. Чыңгыз ханны, борынгы йола буенча, ак киезгә утыртып, югары күтәрәләр. Ул халык алдында кануннарны сакларга һәм алар буенча яшәргә ант итә. Чыңгыз хан хакимияткә килү белән, татарларның борынгы дәүләтчелек традицияләре тагы яңара, төрле халыклар тарафыннан йотылып, бетеп барган милләт җанлана, уянып китә. Чыңгыз хан хакимияте белән тарихта татарның яңа чоры башлана.

Әлбәттә, Чыңгыз ханның элеккеге татар җирләрен яңадан кире кайтарырга теләвен, милләтне бер байрак — татар байрагы астына тупларга тырышуын аңларга була. Ул үз халкын Кытай кул астында да, Византия коллыгында да, Иран аягы астында да яшәтергә теләми. Шушы ният белән ул, Шәркый Төркстанга бәреп кереп, кытайлар кулыннан берничә борынгы татар шәһәрен, шул исәптән данлыклы Кашгарны да ала, гасырлар буе әсирлектә яткан төрки-татарларны коткара. Кытайлар аңга килеп өлгергәнче, ул үзенең гаскәре белән аларның башкаласы Енкинны (хәзерге Пекин) ала. 1219—1220 елларда Чыңгыз хан Урта Азияне буйсындыра, аннан, татарларның борынгы юлы белән, Төньяк

Кавказга барып чыга, Дербент һәм Шәмахә шәһәрләрен ала. Үзе яулап алган барлык җирләрдә дә ул яңадан татар тәртибен урнаштыра. Шулай итеп, кыска гына вакыт эчендә Урта Азия, Иран, Азәрбайҗан, хәзерге Әрмәнстан һәм Грузия Чыңгыз хан гаскәре тарафыннан яулап алына. Аннан ул үзенең атларын Көнчыгыш Европага — элек-электән татар җирләре булган Азов диңгезе буйларына таба бора. Әмма монда кыпчак татарлары, урыслар белән берләшеп, үзләренең кан-кардәшләренә каршы тормакчы булалар. 1223 елның 31 маенда Калка елгасы буенда Чыңгыз хан гаскәре аларны туздырып, тар-мар итеп ташлый. Шулай итеп, Каспий, Көньяк Урал, Түбән Идел тирәләре дә бик тиз Чыңгыз хан кулына күчә. Әмма шунысын да әйтергә кирәк: Чыңгыз хан исән вакытта, алар Идел Болгарстанын тулысынча ала алмыйлар. 1227 елда башта Чыңгыз ханның олы улы Җучи үлә, аннан, Тангут дәүләте башкаласы Чжунсинга һөҗүм вакытында, Чыңгыз хан үзе дә үлә. Дөньяда тиңе булмаган зур Татар дәүләтенең җирләрен, үзе исән вакытта ук, Чыңгыз хан улларына бүлеп биргән була. Соңыннан Алтын Урда дип аталачак Җучи олысы биләмәләре Чыңгыз ханның оныгы Батыйга кала. Дөньяны тетрәткән татар тарихын, алга таба, ул дәвам итә.

1235 елны Каракорым шәһәрендә уздырылган корылтайда Европага яу чабу турында карар кабул ителә. Ә Идел Болгарстаны шушы юлның нәкъ өстендә яткан, кайчандыр данлыклы Татар дәүләтенең бер өлеше булган. Һәм монгол татарлары яу белән олы юлга чыкканда, Идел буе татарлары да, элеккечә, үзләренә кушылырлар, элеккечә, бер Татар иле булып яши башларлар дип уйлаганнардыр. Әмма мөстәкыйльлекнең тәмен татып өлгергән болгар татарлары, көнчыгыштан килгән кан-кардәшләре белән берләшәсе урынга, соңыннан үзләренең башларына җитәчәк урыслар белән берләшүне артыграк санаганнар, монгол татарларына каршы бергәләп көрәшергә алар белән килешү төзегәннәр. Шуңа күрә Болгар һәм Биләргә каршы монгол татарларының җавабы кырыс булган — алар, ярты миллионлык гаскәр белән килеп, Болгар һәм Биләрне тезләндергәннәр. Әмма бер телдә сөйләшә торган бер үк татарлар булганлыктан, алар, соңыннан уртак тел табып, башта Татар империясе составында, аннан уртак ил — мөстәкыйль Алтын Урда дәүләте төзеп яши башлаганнар…

Тагы Чыңгыз хан төзеп калдырган Татар империясенә кайтыйк әле. Аның биләмәләре көнчыгыштан һәм көнбатыштан элеккеге Төрки-татар каганаты җирләренә хәтле киңәя. Идел Болгарстанын буйсындырганнан соң, монгол татарлары урыслар өстенә китәләр. 1237—1238 елларда алар Рязань, Владимир кнезьлекләрен үзләренә буйсындыралар, урысларның егермеләп шәһәрен алалар. 1239—1240 елларда Чернигов, Переяславль кнезьлекләре алына, Киев шәһәре татарлар кулына күчә, ул чагында кечкенә бер шәһәрчек булган Мәскәү яндырыла. Әмма шунысын да әйтергә кирәк: урыс шәһәрләренә һөҗүм итәр алдыннан, Батый хан аларның тыныч юл белән бирелүләрен һәм үзенә буйсынуларын таләп итә. Үзләре теләп сугыш юлы сайлаганнар белән сугыша һәм һәрвакыт җиңеп чыга. Шулай итеп, ул урыслардан татар җирләрен талап торганнары өчен үч ала. Моннан соң Батый гаскәрләре Үзәк һәм Көньяк Европа илләренә ыргылалар, 1240—1242 елларда Венгрия, Польша, Далмация җирләрен тар-мар итеп ташлыйлар, кайчандыр бу җирләрнең һун татарлары кулында булуын искә төшерәләр. Әдрән диңгез буйларына килеп җиткәч, Батый бөек каган Угедейның үлгәнен ишетә һәм атларын кире бора. 1241—1242 елларда Батый гаскәрләре Иделнең түбән агымындагы Дәште Кыпчак далаларына килеп җитә, һәм ул шунда тукталып кала, гаскәренең бер өлеше исә Каракорымга кайтып китә. Батый хан идарә иткән бу җирләр 1240—1260 елларда, Татар империясеннән аерылып чыгып, мөстәкыйль Алтын Урда дәүләте булып оеша. Шундый кыска чорда шундый зур гайрәт белән тупланган Татар иле тагы, әкренләп, вак дәүләтләргә таркала башлый. Хәер, мондый зур ил белән бер үзәктән идарә итү шактый авыр эш булыр иде. Татар иле дә шушы хәлне кичерә — Чыңгыз хан кылыч белән туплаган империя, аерым дәүләтләргә бүленеп, аның уллары, оныклары, нәселе тарафыннан идарә ителә башлый.

Чыңгыз хан төзегән Татар империясе турында Европа, кытай, фарсы, гарәп, урыс тарихчыларының түбәнәйтеп язу сәбәпләре билгеле — алар татарлар тарафыннан җиңелү хурлыгын кичерә алмыйлар. Шуңа күрә Чыңгыз хан нәселен кыргый, варвар, аттан һәм сугыштан башка берни белми торган надан кавем итеп тасвирларга тырышалар. Әмма тарихи фактлар моның киресен сөйли — татарлар искиткеч оешкан, куркуның нәрсә икәнен белми торган гайрәтле, ныклы тәртип, әхлак белән яши торган халык булган. Чыңгыз хан гаскәренең Европага, Кавказга, Идел буйларына яу белән килүе — ул заманында шушы җирләрдә яшәп яткан татарларны яңадан берләштерү, бер дәүләт, бер милләт булып яшәргә омтылу күренеше. Өлешчә Чыңгыз хан һәм аның варислары моңа ирешкән дә. Оештыру сәләте ягыннан, шәхси батырлыгы һәм зирәк акыл иясе булуы белән Чыңгыз ханны һун татарларының патшалары Баһадуршаһ һәм Атилла белән янәшә куярга була. Чыңгыз ханның халык арасында дәрәҗәсе искиткеч зур булса да, ул дәүләт эшләрен киңәш белән алып барган, күп мәсьәләләрне, бигрәк тә сугыш-солых эшләрен, корылтай карамагына чыгарган. Корылтай исә татарларның үз Конституциясенә — «Яса»га таянган. Ясау сүзеннән алынган «Яса» ул — кануннар һәм кагыйдәләр

җыентыгы, ул Коръәнгә, башка дини һәм мәдәни китапларга нигезләнеп эшләнгән, анда Чыңгыз ханның үз фикерләре дә чагылыш тапкан. Чыңгыз хан үзе бу кануннарга катгый буйсынган, башкалардан да шуны таләп иткән. Язма булып биредә уйгур татарларының әлифбасы хезмәт иткән, язу-сызу белән бәйле түрәлек эшләрендә дә күбрәк уйгурлар булган. «Яса» буенча, Татар империясенең ханы бары тик Чыңгыз нәселеннән генә сайланырга һәм корылтайда расланырга тиеш булган һәм бу катгый таләп Алтын Урда дәүләтендә дә, аларның варисы булган Казан ханлыгында да һичшиксез үтәлеп килгән. Чыңгыз ханның диннәргә мөнәсәбәте дә бик сабыр, хәзергечә әйтсәк, демократик караштa булган. Ул барлык диннәргә дә тигез итеп караган, нинди дин тотуына карап, беркемне дә җәберләргә ирек бирмәгән.

Милләтнең эчке эшләре дә катгый тәртип, әхлак кагыйдәләре нигезендә алып барылган. Хәмер эчү катгый рәвештә тыелган, гаиләдә өлкәннәрнең урыны бик дәрәҗәле булган, балалар ата-аналарын берсүзсез тыңларга һәм аларга буйсынырга, шулай ук байлар ярлыларга булышырга тиеш булганнар. Һәр татар үз иленең, милләтенең патриоты итеп тәрбияләнгән, чакырылу белән, алар атка менәргә һәм илне сакларга тиеш булганнар. Чыңгыз хан үз нәселеннән, улларыннан, оныкларыннан да шуны таләп иткән. Гаиләдәге ныклы тәртип җәмгыятькә, дәүләткә, гаскәргә дә күчкән, шуңа күрә курку белмәс әхлаклы татар яугирләре каршында нәфес чиренә баткан черек дөнья кан калтыраган, җимерелеп төшкән. Мондый зур илләрне һәм җирләрне коры кылыч, кыргыйлык белән генә алып та булмый, тотып та булмый. Мәкерле Кытай хәтле Кытайны, сугыш осталары булган Иран хәтле Иранны, Идел-Урал татарларын талап көн күрә башлаган урысларны бер селтәнүдә тезләндерү өчен, ай-һай, нинди гайрәт, осталык, өстенлек кирәк булгандыр! XIII гасыр Кытай елъязмачысы татар гаскәре турында менә нәрсә язып калдырган: «Татар гаскәрендә көч һәм тәртип шул хәтле көтелмәгәнчә иде, алар бөтен дөньяны үзләренә буйсындыра алыр кебек иде». 1241 елның ике аенда Польша, Силезия, Моравия, Богеми, Венгрия кебек илләрнең гаскәрләрен тар-мар итеп ташлаган Субәдәй батырны һәм ярты дөньяны татар кул астына туплаган Батый ханны тарихчылар, хаклы рәвештә, Александр Македонский, Юлий Цезарь һәм Наполеон белән тиң куялар. Чыңгыз хан төзеп калдырган Татар империясе әнә шундый батырлары, җир тетрәткән җиңүләре, татарны берләштерергә омтылган зур максаты белән безгә бүген дә якын, үзебезнеке, татарныкы һәм шулай булып калыр да, иншаллаһ!

## АЛТЫН УРДА — ТАТАР ДӘҮЛӘТЕ УЛ

Алтын Урда — Бөек Татар империясеннән аерылып чыккан мөстәкыйль Татар дәүләте ул. Бу аерымлану процессы берничә көндә генә булмый, ә дистә елларга сузыла. Зур Татар дәүләтеннән кечерәгенең аерылып чыгуы фетнә-гаугаларсыз, тыныч юл белән башкарыла. Бүленеп чыгуның беренче сәбәбе — гаять зур булган империяне, бигрәк тә Идел-Урал җирләрен, Днестр һәм Дунай буйларын, Арал, Азов, Каспий һәм Кара диңгез тирәләрен, ерактагы бер үзәктән — Кытайдан торып идарә итү кыен булганлыктан, бу биләмәләр Чыңгыз ханның олы улы Җучига бирелгән була, Җучи үлгәч, аның улы Батыйга кала. Әкренләп, төп дәүләттән аерылып чыгуның икенче сәбәбе — Татар империясенең төрле олысларында, бигрәк тә Алтын Урдада, ил белән идарә итәрлек көчле шәхесләрнең үсеп чыгуы. Әмма бу өлкәләр, әкренләп, Төп Йорттан аерылып чыксалар да, Чыңгыз нәселенең төп законына тугры булып калалар — кайда да ханнар бары тик шушы нәселдән генә куела, халык «Яса»ны үти, уртак эшләр киңәшеп эшләнә.

Алтын Урда дәүләте 1240 еллардан алып 1266 елларга кадәр, әкренләп, Татар империясенә бәйле булудан арына, шушы чордан мөстәкыйль дәүләт булып яши башлый. Батый хан үзе исән вакытта Татар империясеннән рәсми рәвештә чыкмый, бу хәл хакимияткә Бәркә хан килгәч була. 1246 елда Татар империясенең башкаласы Каракорымнан Ханбалыкка (Пекин) күчерелә, шушы вакыттан үзәк белән өлкәләр арасында бәйләнешләр өзелә башлый. Бәркә хан Ханбалыкка Алтын Урдадан җыелган ясакны җибәрми башлый, суккан акчаларына татар каганы Хубилатның исемен кертми. Ягъни тулысынча ислам дине кабул иткән Бәркә хан христиан дине алган һәм христианнар белән союзда торган Хубилатка бәйле булырга теләми, шулай итеп, Алтын Урда, әкренләп, сугышсыз гына, бәйсез дәүләткә әйләнә. Рәсми тарихта аның яшәү вакыты итеп 1243—1481 еллар күрсәтелә, ягъни 238—240 еллар тирәсе. Зур тарих өчен бу күп тә түгел кебек, әмма татар тарихының бу, чыннан да, алтын чоры дип әйтергә мөмкин. Нәкъ үзебезнең җирлектә, үзебезнең татар ханнары тарафыннан идарә ителгән бу илне бөтен дөнья таныргa, аның каршында баш иярга мәҗбүр була. Алтын Урда бу дан һәм танылуга сугышлар белән түгел, илне ныклы тәртиптә тота белүе, көчле икътисады, мәгърур шәһәрләре, гүзәл мәдәнияте, әдәбияты, галимнәре булуы белән ирешә.

Алтын Урда дәүләтенең җирләре ярты Азия һәм Европаны били. Бу җирләр көнчыгышта — Иртыш елгасына кадәр, көнбатышта — Днестр һәм Дунайга хәтле, төньякта — хәзерге урыс, мордва, мари, удмуртлар яшәгән җирләр, көньякта Арал, Азов, Каспий һәм Кара диңгезгәчә була. Һәм, әлбәттә, ханлыкның үзәгендә Идел-Урал төбәге тора. Алтын Урда җирләре көнчыгыштан көнбатышкача 5600 чакрым, ә көньяктан төньяккача 4000 чакрымга сузылган була. Батый ханның беренче тукталган җире, ставкасы Болгар шәһәрендә булуын да онытмаска кирәк, 1236 елдан 40 нчы еллар башына кадәр ул Җучи олысының башкаласы булып тора, биредә бөек каган исеменнән дәүләтнең беренче акчалары сугыла. Монда шулай ук урыс, әрмән, болгар татарлары һәм Җучи олысының башка халыклары үз илләре белән идарә итү өчен Батый хан кулыннан ярлык алалар. Батый хан тарафыннан яулап алынса да, ул урыс кнәзьлекләрен үз дәүләтенә мәҗбүри кушмый, әмма аларны Алтын Урдага бәйле рәвештә тота. Ягъни урыс кнәзьләре, үз җирләре белән идарә итү өчен, Алтын Урда ханнарыннан рөхсәт ярлыгы алырга тиеш булалар һәм татарларга ясак түләп торалар. Бу бүген татарларның Мәскәүгә салым түләп торуын һәм үз җирләре белән идарә итәргә рөхсәт сорауларын хәтерләтә. Әмма Алтын Урда татарлары урыслардан 10 процент кына ясак түләтсәләр, бүгенге татарлар Мәскәүгә 99 процент налог түлиләр… Бабайлар алып биргән алтын дәүләтләребезне тота алмагач, безнең хәлләр урысларга бәйле булып калды…

Инде тагы Алтын Урда чорларына кайтыйк. 1240 еллар башында Алтын Урданың башкаласын Болгардан Иделнең түбән агымына күчерәләр. Тарихта Сарай-Бату яки Сарай әл-Мәхрүсә дип аталган бу шәһәр йөз ел буе Алтын Урданың башкаласы булып тора. (Ул бүгенге көндә Әстерхан өлкәсенең Харабалинск районындагы Селетринное городище дип аталган урын.) Сарай шәһәре дөньяда иң зур шәһәрләрдән исәпләнә, аның бер башыннан икенче башына ярты көн барырга кирәк булган. Анда 75 мең кеше яшәгән, 13 мәчете барлыгы билгеле. Борынгы тарихчылар язуынча, өйләр кирпечтән һәм агачтан салынган булган, эчәргә су өйләргә кертелгән, биредә ул вакытта ук су үткәргечләр һәм канализация эшләгән. Салкын вакытларда исә өйләр астан, идән аша җылытылган, өй эчләрендә зур бассейннар булган. Бирегә татар ханы кулыннан рөхсәт ярлыгы алырга Александр Невский һәм башка урыс кнәзьләре килгәнлеге билгеле. XIX гасыр тарихчысы Абульфред бу Сарай каласын «Татар дәүләтенең бөек шәһәре» дип атый. Алтын Урданың икенче башкаласы —Сарай әл-Җәдид, ягъни Яңа Сарай, Сарай-Бәркә, хәзерге Волгоград өлкәсенең «Царевское городище» дип аталган урынында булган. Аңа XIV гасыр башында атаклы Үзбәк хан тарафыннан нигез салына.

Алтын Урда, гомумән, шәһәрләр иле булган. Бүгенге көндә археологлар тарафыннан Алтын Урда чорыннан калган 110 шәһәр урыны казып табылган. Идел һәм Кама ярлары шәһәрләр һәм хәрби кирмәннәр белән тулган булган. «В этот период число городов и горожан Золотой Орды было сопоставимо с таковыми в Западной Европе, а уровень бытовой городской культуры степных городов империи по многим параметрам превосходил таковые в Западной Европе. Население формировалось из представителей всех народов государства, но язык большинство горожан и культура были тюркским, религия — ислам, именовали их татарами»,— дип яза күренекле галим Э.Л.Кульпин үзенең «Эволюция славяно-тюркского суперэтноса» дигән хезмәтендә. («Гасырлар авазы» — «Эхо веков».— 1999.— № 2.— С.174.) Ягъни Алтын Урда дәүләтендә татар телле мөселман-татарлар яшәгән, алар югары шәһәр мәдәниятенә ия булганнар, бу мәсьәләдә хәтта Көнбатыш Европаны да узып киткәннәр. Бу татар шәһәрләре Урта Иделдә, Кырымда, Харәземдә, кыпчак далаларында, Кавказ алдында, Днестр, Каспий, Кара диңгез тирәләрендә бигрәк тә күп була. Тарихка кереп калган шәһәрләрдән Болгарны (Урта Идел), Хаҗитарханны (хәзерге Әстерхан шәһәре), Үкәк (Саратовтан ерак түгел), Мохша (Пенза өлкәсе), Маджар (Ставрополь крае), Аккирмән (хәзерге Белгород шәһәре), Солхат (Кырым) һәм башка бик күп шәһәрләрне мисалга китерергә була. Монда бигрәк тә Алтын Урда составында мөстәкыйль өлкә булып яшәгән Болгар биләмәләренә аерым тукталасы килә. Алтын Урда чорында, бигрәк тә Үзбәк хан идарә иткән заманнарда, борынгы болгар җирләре яңадан чәчәк ата, тиңсез күтәрелеш һәм бәхетле көннәр кичерә. Бу заманда Болгар шәһәре 10 тапкыр зурая, бик күп таш йортлар, административ биналар салына. Бүген архитектура истәлегенә әйләнгән Хан мәчетенең 30 метрлы манарасы да шул вакытларда төзелгән булган. Моннан тыш данлыклы «Кара пулат», «Ак пулат», Болгар мунчалары, Кече манара да Алтын Урда чорында — XIII гасырның ахырында — XIV гасырның башларында төзелә. Болардан тыш, борынгы Болгар шәһәрләре — Җүкәтау, Биләр, Сувар — яңа урында торгызыла, Казан, Чаллы, Кирмән, Алабуга, Урмат шәһәрләре яңа сулыш ала. Әмма Алтын Урдага каршы күтәрелгән аерым кешеләрнең, шул исәптән болгар татарларының да, рәхимсез бастырылуларын әйтеп үтәргә кирәк. Чөнки бердәм Татар иле идеясе аерым кешеләрнең һәм нәселләрнең мөстәкыйльлегеннән өстенрәк булган һәм дәүләт бу бердәмлекне кирәк тапканда кулына корал тотып та саклаган.

Алтын Урда дөнья тарихына үзенең көчле икътисады һәм тиңсез мәдәнияте белән кереп калган, дидек. Ә милләтнең әхлак сагында исә ислам дине торган. Бәркә һәм Үзбәк хан заманнарында Алтын

Урдада ислам дине тагы да көчәеп киткән, бу чорлар дәүләтнең дә иң көчле вакыты булган. Ил халкына төп байлык, керем сәүдәдән, һөнәрчелектән, игенчелек һәм терлекчелектән килгән. Илдә, элеккечә үк, тимер эше белән шөгыльләнгәннәр, үзләренә кирәкле коралларны татарлар үзләре ясаган. Алтын Урда дөньяның бик күп илләре белән сәүдә иткән, Бөек Ефәк Юлы һәм Бөек Идел Юлы татарлар кулында булган. Алтын Урда Кытай белән ике арада торган көчле сәүдә үзәге булып торган, бу илләр арасында күпер ролен үтәгән. Кытай, Һиндстан, Урта Азия, Урта диңгез илләре, Мисыр, Багдад, Иран һәм башка бик күп илләр Алтын Урда белән сәяси һәм икътисади элемтәләрне яхшы тотарга тырышканнар. Татар Сараеның үз акча берәмлеге була, ул дирһәм дип атала һәм Алтын Урдадан читтә дә үз көченә ия булып кала. Алтын Урда җирләрендә тимер дә, бакыр да, мәрмәр дә, алтын-көмеш тә мулдан була, ханнар да, халык та бу байлыктан оста файдалана.

Галимнәрнең әйтүенчә, Алтын Урда ул заманның **иң югары цивилизацияле** дәүләтләреннән берсе була. Дәүләт системасының үзәкләштерелгән булуы, шәһәрләрнең күплеге һәм байлыгы, сәүдәнең зур булуы мәдәниятнең дә бик нык үсүенә китерә. Монда, нигездә, өр-яңа шәһәр мәдәнияте туа. Алтын Урда ханнары башка җирләрдән илгә зур галимнәрне, акыл ияләрен, дин әһелләрен, шагыйрьләрне, укымышлы кешеләрне чакырталар. Бигрәк тә Бәркә, Үзбәк, Җанибәк ханнар заманында Алтын Урда мәдәнияте нык алга китә. Алар күп санлы мәчет-мәдрәсәләр, фән сарайлары, уку йортлары салдыралар. Алтын Урда галимнәре һәм шагыйрьләре күп телләр белгән, гарәп, фарсы телләрендә яхшы сөйләшкәннәр, әмма төп язма әдәби тел булып хәзерге татар теленә бик якын кыпчак теле файдаланылган. Рәсми хан ярлыклары да шул телдә язылган, әдәби ядкарьләр дә шул телдә. Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (1342), Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» (1358), Хисам Кәтибнең «Җөмҗөмә солтан» (1369), Сәйф Сараиның «Гөлстан бит төрки» (1391) әсәрләре әнә шундыйлардан.

Әйткәнебезчә, Алтын Урда мөселман иле була. Галимнәр язуынча, ханнардан беренче булып Бәркә хан ислам динен кабул итә һәм мөселман илләре, бигрәк тә Багдад белән нык якынлаша. Бәркә хан ислам дине сагында нык тора, дин хакына, туганнан туганы Хулагу белән дошманлаша, чөнки христиан дине тарафдары Хулагу бөтен ислам дөньясына сугыш игълан итә, хәлифәтнең башкаласы Багдадны җимерә, мөселманнарны үтерә. Хулагуның Мисырга сугыш белән барырга җыенуын белгәч, Бәркә хан аңа каршы сугыш ача, 1261 елда Хулагу гаскәрен Дербент тирәләрендә тар-мар итеп ташлый. Бәркә хан үзе дә хулагучыларга каршы көрәштә 1266 елда Тбилиси тирәсендә вафат була. Христианлыкка чыккан Хулагу нәселе бик озак еллар буе мөселман татарларга каршы сугышлар оештыралар. Бүгенге кайбер гарәп галимнәре, татарлар узган заманнарда ислам диненә каршы сугыштылар, дигәндә, менә шушы чукынган татарларны күздә тоталар, алардан мөселман татарларының да зыян күрүен белмиләр, барысын да бер чыбыктан сөреп, татарны тарихта ислам дошманы итеп күрсәтергә тырышалар. Әмма тормыш күпкә катлаулырак шул, татар тарихы бигрәк тә катлаулы, каршылыклы, данлы һәм фаҗигале…

Ислам дине белән бергә Алтын Урдага мәгърифәт, мәдәният килә, әхлак ныгый, тәртипле ил, милләт бик нык баеп, үсеп китә. Чыңгыз ханнан калган «Яса» инде заман таләпләренә җавап биреп бетерми һәм халык үз тормышы өчен яхшырак булган кануннар нигезендә яши башлый. Чын мәгънәсендә тәкъва мөселман булган Үзбәк хан заманында Алтын Урда үзенең иң яхшы чорын кичерә, моның шулай икәнлеген бөтен галимнәр раслый. Аның заманында Алтын Урдада ислам дине дәүләт дине булып китә. Халык бу гадел ханны шул кадәр ярата ки, ул заманда Алтын Урданы хәтта Үзбәк иле дип тә атап йөртә башлыйлар. Үзбәк ханга да дин дошманы Хулагу нәселе белән Азәрбайҗанда һәм Хорасанда сугышлар алып барырга туры килә, шуңа күрә Урта Азиядә яшәүче халык, Үзбәк ханның вассаллары буларак, үзбәкләр дип йөртелә башлыйлар. Әмма Үзбәк хан үзе Чыңгыз нәселеннән килгән татар кешесе була, чын күңеленнән ислам дине тота. Шул ук вакытта ул башка диннәргә дә ирек бирә. Бәркә һәм Үзбәк ханнарның ислам дошманы Хулагуга һәм аның нәселенә каршы сугышуларын һич кенә дә аларның христиан диненә каршы көрәше дип аңларга ярамый. Татарлар кулы астындагы урыс җирләрендә урыс чиркәүләре эшләүләрен дәвам итә, алар ясак та түләмиләр. Сарайда урыс епископиясе оештырыла, монастырьлар ачыла. Чын мөселманнар буларак, татар ханнары үз кул асларында яшәгән христианнарга карата яхшы мөнәсәбәттә булганнар, диннәрен тыймаганнар, ирекләрен кысмаганнар. Бу хакта да тарихи фактлар сөйли. «Из всех династий, правивших на Руси, только чингизиды не проводили по отношению к Церкви «жесткого курса». Напротив, именно Орда создала православной церкви режим наибольшого благоприятствования — такой, какого церковь не имела ни при Романовых, ни при Рюриковичах»,— дип яздылар урыс галимнәре Ю.Пивоваров һәм А.Фурсов «Русская система. Очерк третий» дигән хезмәтләрендә. («Рубежи»,— 1995.— № 3.— С. 53.) Бу фикерне күренекле урыс галиме Н. М. Карамзин, тагы да тирәнәйтеп: «Татары не вступали в наши судные дела гражданские»,— дип яза. (*КарамзинН.М.* История государств Российского.— М., 1989.—Кн. 2.— Т. V — VIII.— С. 15.) Ягъни Алтын Урда чорында татарлар

урысларның эчке эшләренә катнашмаганнар, диннәрен кысмаганнар, ил чикләрен саклау өчен, алардан бары тик ясак кына түләткәннәр. Бу чорда урыслар күбрәк үзара сугышкан, бер-берләренә каршы ярдәм сорап, гел татарларга мөрәҗәгать иткәннәр, татар ханнары, киресенчә, аларны берләштерергә тырышканнар. Әмма бу берләшү соңыннан аларның үз башларына җиткән.

Үзбәк хан христианнарга карата яхшы мөнәсәбәттә булса да, Алтын Урданың көчәюеннән котлары чыккан христиан дөньясы 1329 елда, Рим папасының котыртуы буенча, Татар иленә каршы тәре походы оештырып карый. Татарларга каршы сугышка Польша белән Венгрия дә кушыла. Илен, динен, милләтен саклау өчен, Үзбәк хан бу берләшкән Европа гаскәрләрен тар-мар итеп ташлый, яңадан Татар иленә борын тыкмаслык итә.

Алтын Урданың дәүләт төзелеше турында да әйтеп үтәргә кирәк. Шундый зур илне тәртиптә тоту өчен, әлбәттә, системага салынган идарә органнары булырга тиеш булган. Баштарак чорларда хан һәм «Яса» иң зур хокукларга ия булса, заманнар үтү белән, бигрәк тә Үзбәк хан вакытында, үзәкләштерелгән җирле үзидарә киң тарала. Ханнан тыш, киңәш советы, ягъни диванга кергән әмирләр дә идарә итүгә хокуклы булалар. Җирле үзидарә исә урыннардагы җитәкчеләр кулына күчә, алар турыдан-туры үзәккә буйсыналар. Акча, финанс мәсьәләләренә баш вәзир җавап бирә, ә хәрби эшләр белән бәкләр бәге җитәкчелек итә. Шул ук вакытта боларның барысы өстеннән дә даими күзәтчелек итүче, эшне тәртиптә тотучы кешеләр — хан баскаклары була. Һәр өлкәнең үзендә җирле казыйлар, мөфтиләр, тамгачы-таможниклар, сәркәтипләр, ясак җыючылар, каравыл һәм башкалар булуын да әйтеп үтәргә кирәк. Алар барысы да бер максатка — Алтын Урда дәүләтен көчәйтү һәм яшәтү өчен эшлиләр. Хан шулар белән идарә итә, илнең эчке һәм тышкы сәясәтен билгели, сугыш һәм солых мәсьәләләрен хәл итә һәм ил-җир белән урыннарда идарә итү өчен аерым кешеләргә ярлыклар бирә. Бәркә хан вакытында, тарихта беренче буларак, Алтын Урда дәүләтендә, татар кул астындагы урыс кнэзьлекләрендә, болгар җирләрендә халык саны алу үткәрелә. Бу ясак җыю өчен, илнең финанс һәм гаскәри эшләрен планлаштыру өчен кирәк була. Шуннан соң бу җирләрдә ханның баскаклары пәйда була, алар җирле түрәләрнең бөтен эшләрен күзәтүдә тоталар.

Үзенең 240 еллык гомере эчендә Алтын Урда белән 41 хан идарә итүе билгеле. Алар арасында Алтын Урданың беренче ханы Батыйдан башлап, үзләренең акыл һәм гайрәтләре белән татар тарихына кереп калган Бәркә хан, Үзбәк хан, Җанибәк ханнар, шулай ук дәүләтнең җимерелү чорына туры килгән Туктамыш, Олуг Мөхәммәт, Әхмәт хан кебек билгеле шәхесләр дә бар. Шулай ук тарихка кереп калган Мамай морза, нугай татары Идегәй дә бар… Алар барысы да Алтын Урданың яшәешенә яки таралуына тәэсир иткәннәр, үз өлешләрен керткәннәр… Шул хәтле зур дәүләтнең таралуына нәрсә сәбәпче булган соң? Без бу сорауларга да җавап табарга тиешбез.

Алтын Урда дәүләте бер көн эчендә барлыкка килмәгән кебек, аның таралуы да айларга гына түгел, елларга сузыла. Бу процесс 1395 елларда башланып 1481 елларга хәтле дәвам итә. Галимнәрнең язуынча, 1346 елны Кытайдан килгән чума чире ярты Европа халкын кырып сала, бу афәттән шулай ук Дәште Кыпчак далалары, Кырым, Идел буе да зур зарар күрә. XIV гасырның 30 нчы елларында чума чире тагы Алтын Урда җирләренә әйләнеп килә, илдә корылык, ачлык башлана, йөз меңләгән кеше үлә. Польша, Литва, Кырымда татарлар белән бәрелешләр булып ала. Моның өстенә, Үзбәк хан улы Җанибәк хан үлгәннән соң, тәхет тирәсендә талаш һәм үтерешләр китә. Явыз хан Бирдебәк белән Туктамыш арасында 25 хан алышына. Илне ныклап кулда тотарлык шәхес булмау сәбәпле, үзәк белән өлкәләр арасында элемтәләр өзелә, ханлыкның үз эчендә аерым олыслар бәйсезлек таләп итә башлый, аерым мөстәкыйль биләмәләр барлыкка килә. Җүкәтау, Норовчат, Әстерхан аерымлана, Харәзем һәм Күк Урда Алтын Урдадан аерылып чыгалар, Күк Урда үз акчаларын суга башлый. Алтын Урданың зәгыйфьләнүен сизгән кайбер урыс кнэзьләре аңа ясак түләүне туктаталар, урыс ушкуйниклары Болгар, Җүкәтау, Кашан, Казан шәһәрләрен талый башлыйлар. 1361 елда кнэзь Булат-Тимер Болгарны һәм Идел буендагы күп кенә шәһәрләрне ала, үз акчасын чыгара башлый.

Бу чорда тарих мәйданында Мамай морза дип аталган шәхес пәйда була. Аның исеме тарихка Куликово кыры сугышы белән кереп калган. Башта ук шуны әйтергә кирәк: Мамай морза беркайчан да Алтын Урда тәхетендә хан булмаган, ул Чыңгыз нәселеннән түгел, ә Бирдебәк ханның кияве, төмән башы. Яу вакытларында ул үзен гайрәтле сугышчы итеп күрсәтсә дә, ханлык эшләренә артык кысылуы аны Алтын Урда ханнарының, бигрәк тә Туктамышның, дошманы итә. Аның урыс кнэзьләре белән үз исәп-хисабы була, ул алар белән Алтын Урда исеменнән түгел, үз исеменнән сугышып йөри. Урыс галимнәре бик шапырынып язарга яраткан Куликово сугышында алар Алтын Урда ханын түгел, Мамай гаскәрен җиңә. Галимнәр язуынча, 1380 елның 8 сентябрендә Дон суы буенда Куликово кырында барган бу сугышта ике яктан да 200 мең кеше үлә, 10 чакрымга кеше каны елга булып ага… Мамай җиңелә, урыс кнэзе Дмитрийга, шушы нисбәттән, «Донской» исеме бирелә. Урысларны танымаган кебек, Мамай морза Туктамышны да танымый, бу ике татар Калка елгасы буенда бик каты сугышалар.

Мамай Кырымга кача, һәм аны анда үтерәләр. Ә урыслар әле мәшһүр Куликово кырыннан соң да йөз елга якын Алтын Урда кул астында булалар, аңа салым түлиләр, җирләре белән идарә итү өчен ярлыкны да, Сарайга барып, татар ханнары кулыннан алалар…

1380 елны Алтын Урда тәхетенә Туктамыш хан килгәч, илдә кыска вакыт эчендә тәртип урнашкан кебек була, Алтын Урда яңадан бер үзәккә туплана башлый. Ил белән идарә итүдә ул, бер яктан, Харәзем хакиме Аксак Тимер ярдәменә таянса, икенче яктан, Туктамыш янында батыр әмире Идегәй була. Әмма бу бергәлек озак дәвам итә алмый, чөнки Аксак Тимернең үзенә Алтын Урда тәхете кирәк була, һәм ул ике татарны — Туктамыш белән Идегәйне — гел бер-берләренә каршы котыртып тора. Нәтиҗәдә Туктамышның зирәклеге җитми, ул тугрылыклы әмире Идегәйне үзенең кан дошманына әйләндерә. Идегәй Аксак Тимер янына кача, 1391 елда алар Туктамыш өстенә сугыш белән киләләр. Туктамыш исә Литва князе белән Аксак Тимергә каршы берләшә һәм аның өстенә сугыш белән китә. Моңа җавап итеп, 1395 елда Тимер Туктамышка каршы сугыш ача, Туктамыш җиңелә, Болгар ягына кача. Нәтиҗәдә Аксак Тимернең гаскәре, килеп, Болгарны җимерә, талый. Аннан соң Тимер гаскәре Алтын Урда шәһәрләрен җимерә башлый, Кырым, Сарай, Әстерхан шәһәрләрен талый. 1395 елдан Алтын Урдада бер үзәктән идарә итү зәгыйфьләнә, әмма әле ул дәүләт булудан туктамый, яңадан йөз елга якын шулай яши. Ил белән Кырымда — Туктамыш, Җаекта — Идегәй, Әстерхан тирәсендә — Тимер Котлык, Сарайда Көерчек идарә итә башлый. Тимер Котлык белән Идегәй Туктамышка каршы берләшәләр, 1399 елда зур бәрелеш була, һәм Туктамыш гаскәре җиңелә. Алтын Урдада Тимер Котлык позициясе көчәя башлый, бөтен князьләрнең князе булып тагы Идегәй кала. Тик Идегәй, Чыңгыз нәселеннән булмаганлыктан, ил белән турыдан-туры идарә итә алмый, башкалар аша эш йөртә. Идегәй соңгы тапкыр Алтын Урданың бөтен олысларын бер үзәккә туплый, 1408 елда Урдага буйсынмый башлаган Мәскәүгә яу белән бара. Ул юл өстендәге Переяславль, Ростов, Дмитриев, Серпухов шәһәрләрен ала, әмма Мәскәүгә солых тәкъдим итә. Мәскәү халкы Идегәйгә зур күләмдә акча түли, ул кире Сарайга кайтып китә. Әмма Чыңгыз нәселе Идегәйгә ил белән идарә итәргә ирек бирми, аның белән гел сугышып тора. Идегәй, Кырымга китеп, аны Алтын Урдадан аерып ала. Үзара сугышларда 1419 елда Идегәй Туктамыш хан нәселе тарафыннан үтерелә. Идегәй үлгәннән соң, хан тәхетенә Олуг Мөхәммәт утыра, бу чорда Алтын Урда бераз ныгып ала. Әмма үзара тарткалашулар нәтиҗәсендә, 1437 елда Олуг Мөхәммәт Сарайдан китәргә мәҗбүр була. Аннан соң Алтын Урда белән 10 ел буе Кече Мөхәммәт идарә итә. 1447 елда тәхеткә аның улы Әхмәт утыра. Ул үзенә ясак түләми башлаган Мәскәү князьләрен акылга утырту өчен юлга чыга, әмма Дон елгасы тирәсендә аларга Кырым ханы Хаҗи Гәрәй гаскәрләре һөҗүм итә. 1465 елда кайчандыр бер Татар дәүләте составында булган татарлар меңәрләп бер-берләрен үтерәләр… Кырым ханнары Мәскәү белән килешүгә керәләр. Әхмәт хан берничә тапкыр урыслар өстенә гаскәр белән барса да, аңа арттан кырымлылар һөҗүм итә. Алтын Урда үзенең бөтенләй таркалып бетү чорына керә. 1481 елда Әхмәт хан түмәнле Ибәк тарафыннан үтерелә. Алтын Урда яңадан көчәеп китмәсен өчен, бөтенләй бетсен өчен, Кырым ханы Миңле Гәрәй, 1502 елда килеп, Сарай шәһәрен ахыргача яндырып, талап, җир белән тигезләп китә. Мәскәү патшасы Иван III гә бу хакта шатлыклы хәбәр җибәрелә. Әмма кырымлылар бу урысларның алга таба үзләрен дә юк итеп ташлыйсыларын белмиләр әле… Татар ханнарының үзара тыныша алмавы, читләрнең коткысына бирелеп, үз милләттәшләренә каршы мәкер корулары, һәр кабиләнең, бөтен бер милләттән аерылып чыгып, үз дәүләтен корырга омтылуы, хәлиткеч мизгелдә милләт сагында Чыңгыз хан, Батый хан, Үзбәк хан кебек акыл ияләренең булмавы Алтын Урда дәүләтенең таркалуына китерә.

Алтын Урда дәүләте бетә, алга таба аның җирләрендә мөстәкыйль Кырым, Әстерхан, Казан, Себер ханлыклары, Нугай Урдасы һәм Зур Урда барлыкка килә. Үзенең кыска гомерендә бар дөньяны тетрәткән Алтын Урда дәүләте юкка чыга, әмма милләт бетми, татар халкы үз дәүләтчелеген башка исемнәр астында булса да дәвам итә. Алга таба сүзебез шул хакта булыр, иншаллаһ!

## ТАТАРЛАРНЫҢ КАЗАН ХАНЛЫГЫ

Казан ханлыгы — татарларның соңгы бәйсез дәүләтләренең берсе, тарихта гаять тирән һәм фаҗигале эз калдырган чоры. Казан ханлыгының яшәешендә, ил белән идарә итү системасында тулысы белән борынгы татарларның гадәт-традицияләре чагылыш тапкан. Шулардан чыгып, без хаклы рәвештә, Казан ханлыгы борынгы һун, скиф татарларының дәүләтчелеген кабул итеп алган һәм дәвам иткән, дип әйтә алабыз. Чөнки Идел — Урал буйларында яшәүче татар халкы ул вакытларда шушы дәүләтләр составында көн күргән. Казан ханлыгы, нигезле рәвештә, Алтын Урда дәүләтенең дәвамчысы гына түгел, төп варисы да булып тора. Бу хакта тарихчы Фирсов: «Возникновение Казанского царства можно почесть восстановлением самой Золотой Орды»,— дип язган.

Галимнәрнең әйтүенчә, Казан ханлыгының яшәү вакыты 1437—1556 елларга туры килә. Казан шәһәренә кимендә 1000 ел икәнен искә алсак, биредә аерым мөстәкыйль өлкәләрнең борынгы заманнардан ук булганлыгын аңларга була. Галимнәрнең әйтүенчә, биредә Болгар, Алтын Урда чорларында ук аерым Казан кенәзлеге булырга тиеш. Ягъни Казан ханлыгы буш урында барлыкка килмәгән, ә ныклы дәүләти традицияле, көчле җирле элитасы, идарәчеләре булган, иң мөһиме, төп халкын татарлар тәшкил иткән Идел — Урал арасында барлыкка килгән. Казан, Алтын Урда кебек үк, көнчыгыш белән көнбатышны тоташтыру ролен үтәгән, ике арада күпер булып торган. Казанны халык ул чакта ук Шәрык башкаласы дип атап йөрткән.

Казан ханлыгы үзенең территориясе белән дә бик зур биләмәләрне алып торган. Әйтик, көнчыгышта ул Агыйделгәчә барып җиткән, көнбатышта Сура, Ветлуга елгаларына ук барып чыккан, төньякта — Каманың югары өлешенә, көньякта Олы Чирмешән елгалары тирәләренә кадәр сузылган. Казан ханлыгы көньяк-көнчыгышта — Нугай Урдасы белән, көньякта — Әстерхан һәм Кырым ханлыклары белән, көнбатышта — Мәскәү җирләре, төньякта Нократ һәм Чүпчә елгалары буйлап, фин-угор җирләре белән чикләшә. Хәзерге Татарстан, Мари, Чуваш, Удмурт Республикалары җирләре, шулай ук Ульяновск, Пенза, Сарытау, Тамбов өлкәләренең һәм Киров өлкәсенең бер өлеше, Пермь өлкәсенең көньяк өлеше, көньяктан хәзерге Волгоград шәһәренә хәтле җирләр Казан ханлыгына кергән. Казан ханлыгы биләмәләре Франция һәм Польша җирләреннән зуррак булган.

Һун татарларының, Болгар, Алтын Урда дәүләтләренең традицияләрен дәвам иткән Казан ханлыгы ил һәм дәүләт төзелешендә, гаскәр тотуда, икътисадта, һөнәрчелектә, сәүдә эшләрендә дә шул борынгы дәүләтләргә охшаган була. Казан ханлыгында да, борынгы һун бабалары кебек үк алымнар белән, чуен коялар, тимер эретәләр, сугыш һәм эш кораллары ясыйлар. Биредә шулай ук күз явын алырлык алтын-көмеш бизәнү әйберләре эшләнә, тиречеләр, күнчеләр бөтен дөньяга дан тота, савыт-саба, чүлмәкләр ясала, төзүчеләр исә таштан хан сарайлары, мәчет-мәдрәсәләр, китапханәләр, төрбә-мавзолейлар, җәмәгать мунчалары, торак йортлар төзиләр. Бик нык алга киткән авыл хуҗалыгы исә Казан ханлыгының үзен генә түгел, бик күп күрше илләрне, хәтта чит мәмләкәтләрне дә ашлык, ит-сөт, бакча җимешләре белән тәэмин итә. Казан ханлыгының тоташ урманнардан, Идел, Нократ (Вятка), Кама кебек зур елгалардан да торганлыгын искә алсак, аның Европа һәм Азиягә яхшы балык, затлы җәнлек тиреләре сатып ятуына гаҗәпләнергә кирәкми. Казанның зур сәүдә үзәге булып торуын да онытмаска кирәк. Биредә Мәскәү, Кавказ, Урта Азия, Себер һәм бик күп чит илләр белән сәүдә иткәннәр. Казанда ел саен, июнь аенда халыкара ярминкәләр уздырылган, ул бик тиз Көнчыгыш Европаның төп сәүдә үзәгенә әйләнеп киткән.

Казан ханлыгы дәүләт төзелешендә дә Алтын Урда традицияләрен дәвам итә, дидек. Бу бигрәк тә хан билгеләүдә ачык күренә. Кай вакытта еш кына «Казанның үзендә хан булырга лаеклы кешеләр булмаганмыни, нигә ханны читтән чакырткannar?» дигән сораулар ишетергә туры килә. Казан ханлыгы Алтын Урданың дәвамчысы буларак, биредә тәхеткә хан бары тик Чыңгыз хан нәселеннән генә куелырга тиеш була. Һәм Казан белән йөз елдан артык алар идарә итә дә. Казан ханлыгына нигез салган Олуг Мөхәммәттән башлап Казанның соңгы ханы Ядегәргә хәтле Казан тәхетендә 21 хан булган, кайберләренең берничә тапкыр идарәгә килеп киткәнен исәпләсәк, бу сан 15 кә кала. Урыс документларында бу татар ханнарын «царь»лар дип йөрткәннәр, аларны Рим һәм Византия императорлары белән тиңләгәннәр. Шулай ук Казан ханнарының мөселман булулары да мәҗбүри шарт булган. Алтын Урда дәүләтендәге кебек үк, биредә дә ханны, ак киезгә утыртып, югары күтәргәннәр. Ханның нәселдән нәселгә тапшырыла торган алтын таҗы булган (хәзер ул Мәскәүдә саклана), шулай ук хан таягы, тамга-печате (нишан), казнасы булган. Хан Казан Кремлендә яшәгән. Биредә аның сарае булган, шулай ук гаскәре, казнасы, дәүләт архивлары, китапханәләр, кунак йортлары, мәчетләре һәм хан каберлекләре дә Кремльдә урнашкан.

Ханның көче, хакимияте чиксез кебек күренсә дә, ул ил белән идарә итү мәсьәләләрендә үзлегеннән генә эш итмәгән. Аның янында, Алтын Урда дәүләтендәге кебек үк, дәүләт шурасы — диван булган. Бирегә бары тик затлы татар нәселләреннән генә 4 карачи-әмир кергән. Алар казнага налог керүне һәм аны нәрсәләргә тотуны күзәткәннәр, бу карачи-әмирләр шулай ук җирле администрация, гаскәр белән идарә итәләр, ханлыкның тышкы эшләрен кулда тоталар.

Милләт тормышында бик мөһим булган чакларда корылтай дип аталган халык җыеннары уздырылган. Монда бөтен Казан җирләреннән җыелган әмирләр, бәкләр, эре җир биләүчеләр, гаскәриләр, морзалар, уланнар, дин әһелләре катнаша. Алар хан билгеләү, сугыш һәм солых, җир мәсьәләләре буенча мөһим карарлар кабул итәләр. Бу халык корылтайларының сүзе бигрәк тә Казан тәхете хансыз калган заманнарда, сугыш-фетнә вакытларында бик мөһим була. Мондый очракларда корылтай ил белән идарә итүне вакытлы хөкүмәткә тапшырган. Илдә ханнан соң икенче урында торган кеше ислам дине башлыгы — сәед булган. Ул бары тик Мөхәммәт галәйһиссәлам нәселеннән булган

мөселманнардан гына билгеләнгән. Дин әһелләре ил, милләт тормышында дәрәҗәле урын тотканнар, алар милләтнең аң-белеме, мәгърифәте, әхлагы өчен җавап биргәннәр, уку-укыту системасы тулысынча алар карамагында булган. Сәедләр шулай ук, Казан тәхете хансыз торган вакытта, вакытлы хөкүмәт җитәкчесе вазифаларын башкарганнар, Мәскәүгә һәм башка илләргә илчеләр итеп җибәрелгәннәр. Казан ханлыгында шулай ук башка дин тоткан кешеләргә дә тулы ирек бирелгән, ул бу яктан да Алтын Урда гадәтләрен кабатлаган.

Казан ханлыгы үзенең югары дәрәҗәдәге мәдәнияте белән бөтен тирә-юньгә дан тота. Бу мәсьәләдә дә аның Болгар һәм Алтын Урда традицияләрен дәвам итүен әйтергә кирәк. Бередәге мәдрәсәләрдә, күп санлы уку йортларында дини һәм дөньяви белем алалар, моның өчен Урта Азиядән, Кырымнан, хәтта Якын Көнчыгыш илләреннән белгечләр чакырталар. Казан ханлыгының идарәче татар элитасы шулай ук гарәп, фарсы, башка тугандаш төрки халыкларның да телләрен яхшы белә, ә милли интеллигенция исә шушы телләрдә үлемсез әсәрләр иҗат итә. Бу чор Мөхәммәдьяр, Мөхәммәт Әмин, Кол Шәриф, Өмми Камал, Әмин Гариф кебек шагыйрьләр һәм акыл ияләре белән билгеле. Бу чорда халык авыз иҗаты да бик көчле була, әйтик, без бүген дә яратып укый торган «Алпамша», «Чура батыр», «Әхмәт турында кыйсса», «Җик Мәргән» әсәрләренең шул елларда халык тарафыннан иҗат ителүе билгеле. Казан ханлыгы галимнәре, акыл ияләре, дин әһелләре Төркестан, Иран, Төркия, Гарәп илләре белән даими элемтәдә торалар, шуңа күрә бередә Шәрык мәдәниятенең тәэсире бик көчле була. Казан ханлыгында китап культурасы киң тарала, гарәп хәрефләре белән китап язучылар, дини китаплар күчерүчеләр, кабер ташы язучылар бик популяр була.

Казан ханлыгының, Алтын Урда кебек үк, үзәктән идарә ителә торган, нык җирле администрациясе, шушы эшләрне башкарып чыга алырлык оста түрәләре булган. Хан бары тик дәүләт эшләре, казна, сугыш һәм солых мәсьәләләре белән эш иткән, аерым өлкәләр белән идарә итәргә ярлыклар биргән, калган барлык эшләрне шушы түрәләр башкарып чыккан. Бередә, Алтын Урдадагы кебек үк, тамгачылар да, салым җыючылар да, җир үлчәүчеләр дә, баш саны алучылар да, язып-теркәп баручылар да булган. Соңыннан урыслар, татарлардан күреп, кеше санын исәпкә алуны үзләренә дә керткәннәр. Татарларга шулай ук дипломатия өлкәсендә дә тиңнәр булмаган. Алтын Урдадагы кебек үк, Казан ханлыгында да чит илләр белән элемтә югары дәрәҗәгә куелган булган. Бу илче татарлар күп телләр белгәннәр, бик югары гыйлемгә һәм әхлакый сыйфатларга ия булганнар, эшне бары тик дәүләт һәм милләт файдасына гына алып барырга тырышканнар. Шуның нәтиҗәсендә, Казан ханлыгы озак еллар, урыслардан кала, беркем тарафыннан да җәбер-золым күрмәгән, тирә-як күршеләре белән татулыкта яши алган. Казан ханлыгында гаскәр торышы Алтын Урдага караганда бераз кайтыш була, әмма охшаш яклары да бик күп. Әйтик, Алтын Урдада да, Казан ханлыгында да атлы гаскәр бик көчле була, татар җайдакларының даны еракларга тарала. Әмма артиллерия һәм башка утлы кораллар мәсьәләсендә Казан татарларының заманадан шактый калышканлыгы билгеле, бу хәл исә 1552 елда зур фаҗигаләргә китерә.

Казан ханлыгының сәяси хәле бөтен чорларда да бер төрле булмый. Аның 1445—1487 елларда, тулысынча бәйсез килеш, Мәскәүне ясак түләп торырга мәҗбүр иткән вакытлары була. Бу заманнарда Казан белән Мәскәү арасында берничә сугыш була, Мәскәү Татар дәүләтенә каршы гаять активлана, Казанның эчке эшләренә туктаусыз тыкшынып тора. Һәм бу хәл 1487—1521 елларда Казан ханлыгының Мәскәү протекторатына калуы белән бетә. 1487 елның 18 маенда Иван III гаскәре Казанга һөҗүм итә, 9 июльдә аны ала, халкын кырып сала. Илһам (Гали) хан гаиләсе белән әсир итеп алына һәм Вологда тирәсенә сөргенгә сөрелә. Хан һәм аның гаиләсе шунда үлеп кала, исән калган бер улы чукындырыла. Казан тәхетенә Мәскәү тарафдары Мөхәммәт Әмин куела. Мәскәү Казанга ясак түләүдән туктый. Казан үзенең тулы бәйсезлеген югалтмаган кебек булса да, ул инде Мәскәүгә бәйле була, Мәскәү алып барган сәясәтне тотарга тиеш була. Мәскәү рөхсәтеннән башка, Казан үзенә хан сайлап куя алмый. Шулай итеп, Казан Мәскәүнең нугай һәм Кырымга каршы союзнигына әйләнә. Халык бу хәл белән һич кенә дә риза булмый, җай чыккан саен, Мәскәү куйган ханнарга каршы күтәрелә. Нәтиҗәдә Казан халкы, ярдәм сорап, Кырымга мөрәҗәгать итә, тәхет өчен Чыңгыз нәселеннән булган хан сорый. Шулай итеп, 1521 елдан, Казанга Сәхип Гәрәй гаскәре килеп, хан тәхетеннән Мәскәү яклы Шаһ Галине куу белән, Казан ханлыгында кырымлы Гәрәйләр идарәсе чоры башлана, һәм ул 1551 елга кадәр дәвам итә. Соңгы чор — Казан ханлыгының җимерелү чоры. Бу хәл 1551 елның 11 августында Сөембикә ханбикәне һәм аның улы Үтәмеш Гәрәйне тотык итеп, Мәскәүгә биреп җибәрүдән башлана һәм 1552 елда Казанны урыслар алу белән тәмамлана.

Казан өчен көрәш татар тарихында гына түгел, дөнья тарихында иң канкойгыч сугыш булып исәпләнә. Урыс патшасы Явыз Иван IV 150 меңлек гаскәре белән Казанны камап ала. Ике яктан да каты сугышлар башлана. 4 сентябрь көнне Кремль асты шартлатыла, халык эчәр сусыз кала, ризык бетә. 1 октябрь көнне соңгы канлы сугышлар була, икенче көнне урыслар Казан Кремленә бәреп

керәләр. Шәһәр эчендә һәр йорт, һәр урам өчен канлы сугышлар башлана. Көчләр тигезсез була. Татарлар соңгы көрәшчеләренә хәтле сугышалар, әмма күзләрен кан баскан, татар байлыгын талау уе белән исергән урыс чирүен җиңә алмыйлар… Казан җиңелә, татарның кояшы сүнә… Урыс гаскәре Казанда бер генә ир-атны —Ядегәр ханны гына исән калдыра, калган барысын да суеп чыга. Хатын-кызларны көчлиләр, урыс гаскәриләренә әсир, кол итеп бирәләр. Хан казнасы, халык байлыгы талана, китапханәләр, архивлар утта яндырыла, мәчет-мәдрәсәләр җимертелә, исән калган татар халкы Казан тирәсеннән куыла… Казансу, Идел елгасы татарларның мәетләре белән тула…

Бу хакта бөек тарихчы Михаил Худяков менә нәрсә яза: «Чудовищное избиение жителей взятой Казани составляет одну из самых тяжелых страниц русской истории. Такою колоссальною гекатомбою человеческих жертв закончился «крестовый поход» христолюбивого воинства против казанцев, первое выступление русского государства на путь территориальных завоеваний. Кроме огромного количества человеческих жизней, насильственно унесенных в могилу, кроме бесчисленных слез, страданий и горя, пережитых казанским народом, печальный день 2 октября знаменовал собою гибель материального благосостояния, накопленного целыми поколениями, и утрату культурно-бытовых ценностей, которые теперь были безжалостно извлечены из укромных уголков, где они бережно сохранялись, без сожаления были изломаны, изуродованы, потеряны, уничтожены. Тысячи драгоценностей, ювелирных украшений, тканей, произведений высокого мастерства и искусства безвозвратно погибли. Богатству народа был нанесен страшный удар, от которого он едва-ли мог бы оправиться. Громадный город сделался жертвою солдатского грабежа». (*М. Худяков.* «Очерки по истории Казанского ханства».— Казань, 1923.— С. 155.)

Бәйсезлек өчен көрәш ханлыкның читләрендә дәвам итә, 1557 елларга хәтле тарихта «Казан сугышы» дип аталган канкойгыч сугышлар бара. 1554 елның кышында Арча ягында 15 мең татар юк ителә, Мишә буендагы Өтернәс кирмәне алына. Казан ханлыгын яңадан торгызу, Казанны кире кайтару өчен, татарлар 1570—1580 елларга хәтле көрәшәләр, урыслар белән тигезсез яуларга кат-кат күтәреләләр, әмма күтәрелгән саен, кара канга батырылалар. Урыслар бу җирләргә, кылыч һәм тәре тотып, китмәс өчен килгән булалар…

Алтын Урданың төп варисы булган Казан ханлыгы 120 елга якын яши. Моңа кадәр булган татар дәүләтләреннән аермалы буларак, ул тышкы көчләр тәэсирендә канга батырылып юк ителә. Һәм Казан ханлыгы бу җирдә яшәүче татарларның соңгы бәйсез дәүләте була. Аның җимерелүенең төп сәбәбе — урыс экспанциясе, ягъни урысларның явызларча басып алуы. Ханлыкның юкка чыгуына татарларның үзара тыныша алмавын да сәбәп итеп күрсәтәләр. Әйе, андый хәл булган, әмма бу төп сәбәп түгел. Кайсы илдә дә, кайсы милләттә дә төрле фикер тарафдарлары яши, әмма тыштан җимергеч көч булмаса, алар тарих мәйданыннан юкка чыкмыйлар. Ә безнең очракта Мәскәү, урыслар Казан ханлыгын, бәйсез Татар дәүләтен җир йөзеннән юк итү максаты куялар һәм шуңа ирешәләр. Бу — дәүләтләр сугышы гына түгел, милләтләр, диннәр сугышы да иде, чөнки православный Мәскәү мөселман Казанына каршы тәре походы игълан итте. Казан ханлыгын яулап алгач та, исән калган татарларны көчләп чукындыру башланды, хатын-кызларны монастырьларга яптылар. Мәскәүнең бу чукындыру сәясәте XIX гасырга хәтле дәвам итте. Казан ханлыгы чорында Мәскәү белән Казан арасында дистәләрчә сугыш булган, күбесенең сәбәпчесе — урыслар. Урыс галиме В. Похлебкин билгеләп үткәнчә, ул сугышларның унбишен — урыслар, бишесен татарлар башлаган. Бу хакта ул менә нәрсә яза: «Только на рубеже 40-х —50-х годов XVI в. в области русской внешней политики в отношении стран Востока, и в отношении Казанского ханства, в частности, происходит существенный перелом. Возникает идея проведения завоевательной активной политики к востоку и югу от среднего течения Волги и о присоединении к Московии пространств от Волги до Урала и от Казани до Каспийского моря включительно. Орудием этого нового внешнеполитического направления Русского государства (царства) должна была стать не активная дипломатия, а неприкрытая, явная и притом цинично проявленная сила. Территориальные присоединения должны были добываться в основном вооруженной рукой. Именно это было «новым словом» в русской внешней политике во второй половины XVI в.». (*ПохлебкинВ.В.* Татары и Русь. 360 лет отношений. 1238—1598. Москва.— Изд-во «Международные отношения», 2000.— С. 116—117.)

Татарлар да урысларга каршы җавап сугышлары оештырганнар, шәһәрләрен җимергәннәр, әмма беркайчан да урысларны, аларның дәүләтләрен җир йөзеннән юк итү максаты куймаганнар, хәтта бу шәһәрләрдә яшәп тә калмаганнар. Ә урыслар Казанга китмәс өчен киләләр, ул гына да түгел, Казаннан соң аларга Идел буйларына, кыпчак далаларына, Уралга һәм Себергә, Урта Азиягә, Кавказга юл ачыла. Россия империясе вәхшиләрчә басып алу сугышлары белән үзенең җирләрен киңәйтә, яулау юлы белән, җир шарының алтыдан бер коры өлешенә ия булып ала. Шунысын да әйтергә кирәк: бу җирләр заманында барысы да борынгы татарларның биләмәләре, дәүләт тоткан җирләре булган…

## КАЗАННЫҢ КАҺАРМАН ХАННАРЫ ҺӘМ МИЛЛИ КӨРӘШЧЕЛӘРЕ

ОЛУГ МӨХӘММӘТ ХАН. Казан ханлыгына нигез салучы. Казан ханлыгы белән 1437—1445 елларда идарә итә. Чыңгыз хан нәселеннән. Аңа кадәр Сарайда Алтын Урда ханнарының берсе була. 1437 елда, Сарайдагы фетнә сәбәпле, аннан китәргә мәҗбүр була, юлда үзенең мең кешелек атлы җайдагы белән үзенә һөҗүм иткән 40 меңлек урыс гаскәрен тар-мар итеп ташлый. Бу сугыш тарихка Белев сугышы буларак кереп кала. Шул елны ук Олуг Мөхәммәт Казан шәһәре тирәләренә килеп чыга. Аның батырлыклары турында ишеткән Казан халкы Чыңгыз нәселеннән булган бу татар ханын үзенең тәхетенә утырта. Моңа кадәр Казанны талап яшәгән урыслар койрыкларын кысарга мәҗбүр булалар, киресенчә, Олуг Мөхәммәт үзе урыс шәһәрләрен акылга утыртып кайта, хәтта аларның бөек князьләре Василий II не әсир итеп ала. Олуг Мөхәммәт Казан ханлыгын ныгытуга бик күп көч куя. Казанның беренче ханы Олуг Мөхәммәт 1445 елны үлә.

МӘХМҮТ ХАН. Олуг Мөхәммәтнең улы Казан белән 1445—1464 елларда идарә иткән. Бу ханлыкның иң куәтле чаклары булган. Олы Урда ягыннан да, Мәскәү ягыннан да яшь Казан дәүләтен борчулар булмый диярлек, чөнки Мәхмүт ханның батырлыгы турында дан тирә-якка таралган була. Ул Казан дәүләтен атасы кебек үк зур акыл һәм көчле гайрәт белән алып бара, үз янында көчле татар гаскәре туплый, ил белән идарә итүне бер системага сала. Мәхмүт хан заманында Казан Көнчыгыш Европаның сәүдә үзәгенә әйләнә, бирегә Кавказ, Иран, Ирак, Мисыр, Урта Азия илләреннән, Себердән, Идел буйларыннан зур сәүдәгәрләр килә. Мәхмүт хан заманында урыслар аның белән сугышуга караганда сәүдә итүне кулайрак күрәләр. Мәхмүт хан 1464 елны Казан шәһәрен- дә үлә.

ИБРАҺИМ ХАН. Мәхмүт ханның улы. Казан белән 1467—1479 елларда идарә итә. Бу чор урыс гаскәренең берничә тапкыр Казан өстенә килүе һәм хурлыклы җиңелүләре белән билгеле. Казан тәхетеннән Ибраһим ханны бәреп төшереп, аның урынына Касыймны кую сылтавы белән, Иван III гаскәре 1467 елны Казан өстенә килә. Әмма Ибраһим хан урысларга Идел аша чыгарга ирек бирми, бик күпләрен кырып сала. Тик урыс гаскәре, явызланып, татар җирләренә һөҗүмен дәвам итә. Ибраһим хан, аларга каршы чыгып, яңадан Вятка буйларын, Хлынов шәһәрен сугышып үзенә кайтарып ала. 1469 елны Иван III гаскәре, Казанны алу нияте белән, татарларга каршы зур сугыш ача, урыслар ханлыкны ике яктан келәшчәгә алырга уйлыйлар. 1469 елның 21 маенда алар Казан Кремле янына килеп җитәләр, аңа ут төртәләр, юлларында очраган татарларны суя, үтерә башлыйлар. Моны белеп алган Ибраһим хан гаскәре аларга каршы сугыш башлый, урыслар, татарларның һөҗүменә түзә алмыйча, чигенергә мәҗбүр булалар. Ибраһим хан гаскәре аларны куа чыга һәм Идел суы өстендә тар-мар итеп ташлый, нәтиҗәдә бик күп урыслар суга батып үлә. Әмма Иван III һаман Казанны алу ниятеннән кире кайтмый һәм 1469 елның 1 сентябрендә Казан өстенә тагы зур сугыш белән килә. Халкын сугыш афәтеннән саклап калу максатыннан, Ибраһим хан урысларга солых тәкъдим итә. Иван III моңа тиз генә риза була, чөнки артында Литва һәм Бөек Новгород белән низаг туып килгәнен белә. Бу солых нәтиҗәсендә сигез ел ике ил арасында тынычлык була, әмма аны беренче булып тагы урыслар бозалар. 1478 елның февралендә алар башта Вятка җирләренә, аннан Казанга һөҗүм итәләр. Бу вакытта Иван III нең 150 меңлек көчле гаскәре була. Әмма шуңа карамастан алар Казан астында тагы хурлыклы җиңелүгә очрыйлар, Ибраһим хан урыс гаскәрен ут белән каршы ала һәм кире үз җирләренә чигенергә мәҗбүр итә. Ибраһим хан 1479 елда үлә. Татар тарихына ул Казан өчен каһарманнарча көрәшкән, үз дәүләтен, халкын баһадирларча саклаган хан булып кереп калган.

СӘХИП ГӘРӘЙ ХАН. 1521—1524 елларда Казан белән идарә иткән Кырым шаһзадәсе. Ул Кырым ханы Миңле Гәрәйнең улы була. Сәхип Гәрәй Казан тәхетенә утыру белән, ул Мәскәүгә каршы сугыш ача, ягъни урысларга бәйле булып тору шартларын өзә. 1521 елның 30 июлендә, Кырым ханлыгы белән берлектә, Казан ханы Сәхип Гәрәй Мәскәүне утлы боҗрага ала. Татарлар Мәскәүне алалар һәм Иван III каршына үз таләпләрен куялар. Куркудан коты чыккан Мәскәү хөкүмәте Сәхип Гәрәй ханга солых тәкъдим итә, татарлар моңа ризалаша. 1521 елның 6—8 августында Мәскәү белән Казан арасында солых килешүе төзелә, аның нәтиҗәсендә Мәскәү, Алтын Урда чорындагы кебек, татарларга ясак түли башлый. Иң мөһиме, бу килешү нигезендә, Казан Мәскәүнең протекторатыннан котыла, ягъни аннан бәйсез була. Сәхип Гәрәй хан Казан белән озак идарә итми, әмма бу чорда ул урысларга Казанга борын тыгарга ирек бирми. Шул ук вакытта ул Мәскәүнең Казанны тынычлыкта калдырмаячагын да яхшы аңлый һәм, ярдәм сорап, турыдан-туры Төркиягә мөрәҗәгать итә һәм 1524 елның язында шушы мәсьәләләр белән Истанбулга китә. Ул Казан тәхетендә үз урынына 13 яшьлек туганнан туганы Сафа Гәрәйне калдыра. Сәхип Гәрәй соңыннан Кырым ханы булып тора һәм 50 яшендә Кавказда үтерелә. Казан тарихына ул татарларны Мәскәү коллыгыннан коткаручы буларак кереп кала һәм «Сәхип Гәрәй хан ярлыгы» белән билгеле.

САФА ГӘРӘЙ ХАН. Ул Казан ханлыгы белән өч тапкыр —1524—1531, 1535—1546 һәм 1546—1549 елларда идарә итә. Сафа Гәрәй Казан тәхетенә татарлар өчен бик авыр бер вакытта утыра. Мәскәү тагы Казанга каршы зур сугыш әзерли һәм 1524 елның җәендә 150—180 меңлек гаскәр белән яуга чыга. 7 июль көнне урысларның бер төркеме Казан янына килеп җитә, калганнары төрле җирләрдә татар чолганышында кала. Ягъни Казан гаскәре урысларны бик нык әзерләнеп каршы ала, аларның атлы җайдакларын, флотилиясен тар-мар итеп ташлый, Иделдә урысларның 90 су көймәләрен, коралларын, дарыны кулга төшерә. Казанны алырга килгән урыс гаскәренең бер өлеше суга батып үлә, бер өлеше әсир төшә. Бу хәл 1524 елның август аенда була. Нәтиҗәдә Мәскәү татарлардан солых сорарга мәҗбүр була. Бу килешү буенча, Василий IV Казан ханы Сафа Гәрәйне танырга һәм Казан ханлыгының төрек протекторатына күчүе белән килешергә мәҗбүр була. Әмма урыс патшасы Казанга каршы һөҗүм ниятеннән беркайчан да баш тартмый һәм 1530 елда тагы Сафа Гәрәй ханга каршы сугыш ача. Казан ханы моны алдан ишетә һәм яуга бик нык әзерләнә. Аңа ярдәмгә нугайлар, чирмешләр, әстерханлылар килә. Әмма урыс гаскәре бу юлы да Казан янында хурлыклы җиңелүгә дучар була, бу сугышта бик күп мәетләр һәм әсирләр калдырып, Мәскәүгә качарга мәҗбүр була. Татарларны сугыш белән җиңеп булмасын аңлаган урыс патшасы аерым казанлыларны сатып алу, Сафа Гәрәй ханга каршы котырту юлына баса. Нәтиҗәдә 1531 елның маенда, аерым кешеләрнең фетнәсе сәбәпле, Сафа Гәрәй хан, Казан тәхетен калдырып, Кырымга китәргә мәҗбүр була. 1533 елда ул, Кырым гаскәре белән берлектә, урыс җирләренә яу чаба, аларның берничә шәһәрен ала, урыс гаскәриләрен кылычтан үткәрә. Урыс патшасы Василий III бу кайгыдан үлә. Ул арада Казанда Мәскәү тарафдары Җан Гали дә үтерелә. Казан халкы тәхеткә яңадан Сафа Гәрәйнең кайтуын сорый. 1535 елны Сафа Гәрәй яңадан Казан ханлыгы белән идарә итә башлый. Бу ханлык өчен бик тынгысыз вакыт була. Казанның Мәскәү яклы төркеме һаман тынычланырга теләми, алар, Сафа Гәрәйне бәреп төшереп, урыслар ярдәмендә Казан тәхетенә үз кешеләрен кую турында хыялланалар, Мәскәү белән Сафа Гәрәй ханга каршы яшерен сөйләшүләргә керәләр. 1536—1537 елларда Сафа Гәрәй, мәскәүлеләрнең һөҗүмен туктатып калу өчен, Түбән Новгород, Кострома, Муром шәһәрләренә яу чаба, урыслар үлемгә караганда әсирлекне артык күрәләр һәм бөтен гаскәрләре белән татарларга бирeләләр. Ул арада урысларның сугыш-сәясәт мәйданында Явыз Иван үсеп чыга һәм Казанга каршы яуга әзерләнә башлый. 1545 елның маенда урыс гаскәре Идел һәм Кама елгалары буйлап Казанны алырга юнәлә, әмма татарлар тарафыннан тотылып, юлда ук тар-мар итеп ташлана. 1546 елны Казан коткычылары, тагы Сафа Гәрәйне тәхеттән төшереп, Мәскәү курчагы Шаһ Галине хан итеп куялар. Әмма Шаһ Гали анда берничә ай гына утырып өлгерә, Сафа Гәрәй, нугай татарлары гаскәре белән кайтып, бу фетнәчеләрне тар-мар итеп ташлый һәм яңадан законлы тәхетенә утыра. Ул хәзер илнең эчке эшләренә зур игътибар бирә, тышкы һөҗүмгә дә һәрвакыт әзер тора. Явыз Иван да тик ятмый — 1548 елның декабрендә тагы Казанга яу белән чыга, әмма күп гаскәре катып бетмәгән Идел бозы астына китә, урыс патшасы күз яшьләре белән киредән Мәскәүгә кайтып китә. 1549 елның мартында ул Казан өстенә тагы гаскәр җибәрә, Казан тирәсендә шактый бәрелешләр була, ике яктан да гаскәр кырыла. Әмма урыслар бу очракта да җиңелеп, кире кайтып китәргә мәҗбүр булалар. 1549 елны, көтмәгәндә, Сафа Гәрәй хан вафат була. Бу вакытта ул нибары 40 яшьләр тирәсендә була һәм гомеренең 25 елын Казан ханлыгы белән идарә итүгә бирә. Ул урыс гаскәрләренең, урыс патшаларының, Явыз Иванның Казанга каршы берничә явын җиңә, үзе хан вакытта татар халкын урыска кол булып төшүдән арысланнарча саклый. Әмма үз янында булган хыянәтчеләрдән ул сакланып бетә алмый, Мәскәү яклы казанлылар аны берничә тапкыр тәхеттән төшерәләр, бәлки Сафа Гәрәй ханның кинәт үлеменә дә шул сатлыкҗаннар сәбәпче булгандыр… Хатыны Сөембикә һәм кечкенә улы Үтәмеш Гәрәйне мәңгелеккә калдырып, Сафа Гәрәй җир куенына кереп ята. Кабере Казан Кремлендә, Сөембикә манарасы тирәсендә булырга тиеш.

СӨЕМБИКӘ ХАНБИКӘ. Сафа Гәрәй үлгәч, аның 2 яшьтән узган улын хан итеп куялар, ә Сөембикә регентша итеп билгеләнә. Ягъни 1549 елдан алып үзен әсирлеккә биреп җибәргән 1551 елга кадәр Сөембикә ханбикә кечкенә улы исеменнән Казан ханлыгы белән идарә итә. Бу вакыт Казан ханлыгы өчен иң авыр һәм куркыныч заманнарның берсе була. Әмма шуңа карамастан үзе исән чагында Сөембикә ханбикә Казанны урысларга бирми, Явыз Иванның берничә һөҗүмен кире кага. Явыз Иван тарафыннан Казанга беренче һөҗүм, Сафа Гәрәй үлү белән үк, 1549 елның 17 ноябрендә оештырыла. 150—200 меңлек урыс гаскәре 1550 елның февраль аенда Казанга килеп җитә һәм аны камап ала. Явыз Иван үзе дә сугышчылары арасында була. Аның, тизрәк Казанны алып, дан казанасы килә. Казан өстенә урысларның ядрә яңгыры ява башлый. Әмма татарлар да зур гайрәт белән сугышалар, урысларның бөтен атакаларын кире кагалар. Тарихчы Зәки Вәлиди язганча, «Ошбу куркынычлы вакытларда Казанның гайрәтле, акыллы мәликәсе Сөембикә, крепость өстенә менеп, үзе командалар биреп йөри». Әмма җиңелүдән куркып, урыслар ягына чыгучылар да шактый була. Урыс ягыннан татарларга каршы сугышучылар арасында Шаһ Галинең һәм аның тарафдарлары касыймлыларның да

булуын әйтергә кирәк. Урыслар, никадәр күп һәм көчле кебек күренсәләр дә, бу сугышта хурлыклы рәвештә җиңеләләр, Явыз Иван, тешләрен шыгырдатып, яңадан Мәскәүгә кайтып китәргә мәҗбүр була. Әмма урыс патшасы Казанны тиз арада алу ниятеннән кире кайтмый һәм моңа ныклап әзерләнә башлый. Беренче эш итеп ул 1551 елның язында, берничә тәүлек эчендә, Казан ханлыгы территориясендә Зөя (Свияжск) шәһәрен салдырып куя. Шулай итеп, ул татар ханлыгыннан Иделнең уң ягын тартып ала, халыкны исә чолганышта калдыра. Аннан Казанга илтә торган бөтен зур су юллары урыслар кулына күчә, җирле чуваш-мари халкы сатып алына. Бу хәлләрне күреп, Казанның үз эчендә дә чуалышлар китә, Кырым морзалары һәм Сөембикә халыкны урысларга каршы сугышка өнди, ә Мәскәү яклы татарлар урыслар белән килешергә чакыра. Бу вакытта Явыз Иван да тик ятмый, Казанның борын төбендә үзенең тылын ныгыта, шәһәргә шымчылар, провокаторлар, сатлыкҗаннарны җибәреп кенә тора. Казан халкының урысларга каршы сугышмасларын белгәч, кырымлылар шәһәрне ташлап чыгалар, әмма юлда тотылып, Мәскәүгә алып барып үтереләләр. Сөембикә ханбикә Мәскәү яклы милләттәшләре белән бер ялгыз кала. Казанның җитәкче даирәсе, солых сорап, Явыз Иванга илче җибәрә. Урыс патшасы моңа ризалаша, әмма аның шарты татарлар өчен хурлыклы һәм аянычлы була — Явыз Иван Казан ханы Үтәмеш Гәрәйне һәм аның әнисе Сөембикә ханбикәне, аның тарафдарларын Мәскәү кулына тапшыруларын таләп итә, ягъни әсирлеккә алырга тели. Ул шулай ук Иделнең уң як ярындагы җирләрне үзенеке дип игълан итә, Казан тәхетенә Шаһ Галине куярга теләвен әйтә. Казанның җитәкче даирәсе Явыз Иванның бу шартларына риза була, бу хакта килешүгә башта Свияжск шәһәрендә (1551, 6 июль), аннан Мәскәүдә (1551, август) кул куела. Казанның вакытлы хөкүмәте 1551 елның 12 августында Сөембикә ханбикәне, аның улы Үтәмеш Гәрәйне, кырымлы угланнарны урыслар кулына әсир итеп тапшыра һәм Мәскәүгә биреп җибәрә. Бер елдан соң Казан ханлыгы урыслар тарафыннан тар-мар ителә, Сөембикәне әсир итеп биреп җибәргән татарлар да шушы сугышта һәлак булалар… Сөембикәнең улы Үтәмеш Гәрәйне, җиде яшендә әнисеннән аерып алып, 1553 елда Чудово монастыренда чукындыралар, аны урыс-христиан итеп тәрбияли башлыйлар. Үтәмеш Гәрәй 1566 елның 11 июнендә 20 яшендә урыс арасында үлә һәм Мәскәү Кремленең Архангель соборында урыс-христиан буларак күмелә. Ә Сөембикә ханбикәнең алга таба язмышы билгесез. Кайбер тарихчылар әйтүенчә, ул, чукындырылып, монастырьга ябылган булырга тиеш. Аны Шаһ Галигә кияүгә биргәннәр, ул Сөембикәне бик җәберләп торган, борынын кисеп алган, үтергән, дигән хәбәрләр дә бар. Хаклыкны бер Аллаһы Тәгалә генә белә. Татар халкы үзенең соңгы ханбикәсен онытмый, гасырлар буе аның хакында бәетләр чыгарылган, мөнәҗәтләр әйтелгән, әсәрләр иҗат ителгән. Һәм Казан шәһәренең уртасында, борынгы Кремль эчендә Сөембикә ханбикәнең моңлы истәлеге булып мәшһүр Сөембикә манарасы утыра…

ЯДЕГӘР ХАН. Ул Казанның соңгы ханы. 1552 елның мартыннан 1552 елның 2 (15) октябренә хәтле, ягъни Казан алынганга кадәр, ханлык белән идарә иткән. 1552 елның февралендә Мәскәү Казан ханлыгын тулысынча юкка чыгарырга планлаштыра. Казан ханы Шаһ Галине, янәсе, «үз теләге» белән, тәхеттән баш тартырга мәҗбүр итәләр. 1552 елның 6 мартында Казанда Иван IV нең Казан ханлыгын юкка чыгаруы (ликвидация) турында грамотасын укыйлар, наместник итеп Свияжск воеводасы князь Семен Иванович Микульский билгеләнә. 9 март көнне, иртә белән, ул Свияжсктан Казанга килергә чыга, әмма Казан халкы аңа капка ачмый. Үзенең бәйсезлеген югалтмас өчен, Казан Мәскәү белән сугышырга әзерләнә. Казан ханлыгы тәхетенә Әстерхан шәһәреннән шаһзадә Ядегәр-Мөхәммәт чакыртылып алына. Явыз Иван исә Казан ханлыгын тәмам җимереп, юкка чыгарып, җирләрен Россиягә кушуны үзенә төп максат итеп куя һәм шул сугышка әзерләнә башлый. Ул 1552 елның май аенда Казанга каршы яуга чыга, 108 көн эчендә, канкойгыч сугышлардан соң, 1552 елның 2 октябрендә, Казанны ала. Сусыз, ризыксыз калган Казан халкы Ядегәр хан җитәкчелегендә соңгы тамчы канына хәтле урысларга каршы сугыша. Явыз Иванның: «Бирелсәгез, барыгызны да гафу итәм»,— дигән сүзләренә каршы татарлар: «Без Аллаһы Тәгаләдән башка беркемнән дә гафу сорамыйбыз»,— дип җавап бирәләр, урысларга каршы иң соңгы сулышларына хәтле сугышырга ант итәләр. Бик күп көч куеп һәм корбаннар биреп, урыслар Казанны ала, Ядегәр ханны әсир итеп, Мәскәүгә алып китәләр. Казанның калган ир-атын барысын да суеп үтерәләр. Казанның соңгы ханы Ядегәрне Мәскәүдә чукындыралар, Симеон дигән исем бирәләр. Кайбер тарихчылар Ядегәрне батырларча сугышып үлмәүдә гаеплиләр. Мәскәү яклы булса, ул шундый тынычсыз заманда Казанга хан булып килмәс тә иде. Ядегәр хан Казанда сараенда качып ятмаган бит, урыслар белән сугышның котылгысыз буласын белеп, ул халыкны шуңа хәзерләгән, 15 меңлек татар гаскәре белән 150 меңлек урыс гаскәренә ай буе каршы торган, алар каршына кул күтәреп чыкмаган, ә сугышта әсир төшкән! Аны махсус үтермәүләре, бөтен Мәскәү алдында бозлы суларга төшереп чукындырулары — бу да Россиянең мәкерле сәясәте бит! Күрегез, янәсе, без җиңелгән татар ханнарын ни эшләтәбез! Мөселман кешесе буларак, ул үз-үзен үтерә алмаган, ә сугыш вакытында аны яугирләре саклаган. Инде Казан тәмам җиңелгәч кенә, алар

Ядегәр ханны урыслар кулына тапшырганнар — сугышның тәртибе шундый булган… Һәм Ядегәр хан җиңелү фаҗигасен тулысынча бер ялгызы күтәргән… Бөтен татарлар өчен…

КОЛ ШӘРИФ. Ул хан булмаган, татар тарихына милли көрәшче, дин әһеле буларак кереп калган. Кол Шәриф Казан ханлыгының сәеде, ислам дине җитәкчесе булган, хансыз калган заманнарда вакытлы хөкүмәт белән җитәкчелек иткән. Шуңа күрә 1551 елның 6 июлендә Свияжск шәһәренә, Мәскәү белән килешү төзү өчен, нәкъ менә аңа барырга туры килгән. Шушы килешүдә Сөембикә ханбикәне Мәскәү кулына биреп җибәрү турында каралган… Бу килешүгә Мәскәү ягыннан Касыйм ханы Шаһ Гали, Казан ягыннан сәед Кол Шәриф һәм князь Бибарс Растов кул куйганнар… Дини юлбашчы, шагыйрь Кол Шәриф бу фаҗигале ялгышны тиз аңлаган булырга тиеш, Казан өчен көрәштә ул инде, кулына кылыч тотып, урысларга каршы сугышка беренче булып ташлана. Бу хакта тарихчы М.Пинегин менә нәрсә яза: «Свежее, бодрое войско победоносно ударило на татар и оттеснило их снова за Тезицкий ров; здесь все духовенство во главе с Кульшарифом отчаянно защищало каждый шаг, не пуская русских к мечетям. Но главный мулла был убит, татары отступили». (*Пинегин М.* Казань в ее прошлом и настоящем.— СПб., 1890.— С.73.) Кайбер тарихчыларның әйтүләре буенча, Кол Шәриф хәзрәт, чигенә-чигенә, мәчет манарасына менеп сугышкан һәм шуннан чәнчеп төшерелгән. Аның белән бергә йөзләгән шәкерте, муллалар дин һәм милләт өчен кяферләр белән сугышып шаһит киткәннәр… Бу милли каһарманнарыбызның сөякләре бүген дә Казан Кремле туфрагына сибелгән килеш ята… Әйткән яхшы сүзләребез алар рухына дога булып барсын иде. Амин.

ГАЛИ ӘКРАМ ЙОСЫФ улы. Нугай Урдасы хакиме Йосыф морзаның улы, Сөембикә ханбикәнең бертуган энесе. Тарих китапларында: «Казан җиңелгәч, 1553—1556 елларда мари ягындагы Чалым каласында ханлык итә»,— дип язылган. Казан канга батырылып яулап алынса да, татарлар моның белән килешергә теләмиләр. Ханлыкның төрле почмакларында урысларга каршы баш күтәрүләр башлана. Татарлар урысларга буйсынырга теләмиләр, халыкны талап йөрүче ясакчыларны үтерәләр, урыс гаскәриләренә каршы корал күтәрәләр. Идел һәм Кама буйларында, Арча, Биектау тирәләрендә татарларның чын мәгънәсендә урысларга каршы Ватан сугышлары башланып китә. Мишә елгасының башланган җирендә кирмән төзелә, аның тирәсенә сугышчы татарлар туплана. Мондый крепость-кирмәннәрнең тагы берничә урында булуы ихтимал. Бу күтәрелешләрнең башында Мамыш Бирде исемле татар батыры тора. Ул халыкны урысларга каршы көрәшкә туплый, Казан ханлыгын яңадан торгызу нияте белән, татарлар Гали Әкрамны тәхеткә чакыралар. Гали Әкрам 300 кешелек нугай атлысы белән Кама буйларына килеп төшә. Кайбер тарихчыларның әйтүе буенча, ул хан ставкасы итеп Кама буендагы Чаллы шәһәрчеген сайлый. (Бу урынны Идел буендагы Чалым шәһәре дип тә, Мишә елгасы буендагы Калатау-Өтернәс дип тә әйтәләр.) Шушыннан торып, Казанга урысларга көчле һөҗүмнәр башлана. Нугай Урдасыннан Йосыф морза да улына ярдәм итәргә тели, Казан ханлыгын яңадан торгызырга ниятләп, Йосыф морза гаскәр туплый башлый. Әмма ул моны эшләп өлгерә алмый — аның үзен үтерәләр, кече улларын Мәскәүгә тотык итеп озаталар… Гали Әкрам гаскәре исә урысларга тынгы бирми, Казан ханлыгының бөтен төбәкләрендә халык бәйсезлек өчен көрәшкә күтәрелә. Мәскәүдән татарларга каршы җибәрелгән барлык урыс гаскәрләре дә юк ителә. Бу хәлдән котлары очкан Мәскәү хөкүмәте Явыз Иванга Казанны кире татарларга кайтарып бирергә тәкъдим итә. Явыз Иван, соңгы көчен җыеп, тагы татарлар өстенә ябырыла. 1553 елның җәендә башланган бу канкойгыч сугыш бары тик 1556 елның июль-август айларында гына тәмамлана. Идел, Кама, Вятка, Мишә елгасы буйларына Адашев җитәкчелегендә җәза отрядлары җибәрелә, алар халыкка каршы чын мәгънәсендә террор оештыралар: үтерәләр, асалар, яндыралар, суялар… 1553 елның сентябрендә Мәскәүдән Казан ханлыгы җирләренә каршы даими армия юлга чыга, алар рәттән бөтенесен яндырып, кырып баралар. 1553—1554 елларның кышында Мишә елгасы буендагы кирмән яндырыла, 6 мең ир-ат, 15 мең хатын-кыз әсир ителә, бик күпләре үтерелә… Урысларның ни дәрәҗәдә явыз һәм кансыз икәнлеген күреп, татарларга ярдәмгә мари, чуваш, удмурт халыклары да кушыла. Казан ханлыгы җирләре тоташ сугыш мәйданына әйләнә. Гали Әкрам һәм Мамыш Бирде гаскәре Казанга һөҗүмнәрен дәвам итә. Әмма ничә еллар сугыштан интеккән, чәчмәгән һәм урмаган халык ачыга, хәлсезләнә башлый. Бу хәлдән урыслар бик оста файдаланалар һәм 1556 елның язында, бик озак сугышлардан һәм шартлатулардан соң, Чаллы (Чалым) крепосте урыслар тарафыннан алына. Гали Әкрам хан үтерелә, Мамыш Бирде хәйлә белән кулга төшерелә һәм Мәскәүгә алып китеп, җәзалап үтерелә. Әмма татарларның бәйсезлек өчен, Казан өчен көрәшләре әле озак еллар дәвам итә. Сугыш бетсә дә, Россия белән Татар иле арасында бернинди дә солых килешүе төзелми, Казан ханлыгы биләмәләре, бернинди рәсми актсыз, Россиягә кушылып куела. Шуңа күрә без: «Казан ханлыгының дәвамчысы булган Татарстан бүген дә Россия белән сугыш хәлендә»,—дип әйтә алабыз, чөнки бу ике дәүләт арасында үз заманында солых та төзелмәгән, яулап алу да рәсмиләштерелмәгән…

## ТАТАРЛАРНЫҢ ӘСТЕРХАН ХАНЛЫГЫ

Әстерхан ханлыгы әле Алтын Урда таркалганчы ук барлыкка килә. 1459 елның ахыры — 1460 елларның башында Алтын Урда ханы Мәхмүтнең энесе бу җирләрнең мөстәкыйль хуҗасы була. 1481 елда Алтын Урданың соңгы ханы Әхмәт үтерелгәч, Әстерхан ханлыгы аерым мөстәкыйль дәүләткә әйләнә. Әмма бу ханлык күләме ягыннан зур булмый, аның җирләре дә, кешесе дә аз була. Заманында Хәзәр каганатларын, Сарай-Батуларны үзенә сыендырган Әстерхан җире, Каспий диңгезе даими күтәрелеп тору сәбәпле, бик тиз сазлыклы һәм тозлы яланнарга әйләнә. Кешесе аз булганлыктан, Әстерхан ханлыгында гаскәр дә кечкенә була, шунлыктан бу Татар дәүләте зур гаугаларда катнашмаска тырыша, аның язмышы күршеләре Нугай Урдасына һәм Кырымга нык бәйле була. Әстерхан ханлыгының төп халкын татарлар тәшкил итә.

Әстерхан ханлыгы көньяктан — Терек елгасына кадәр, төньяктан — Переволоккача, көнчыгыштан — Бузан елгасына кадәр, көнбатыштан Кубаньгача һәм Дон елгасының түбәнге өлешләренә кадәр сузылган була. Ханлыкның башкаласы булып Әстерхан шәһәре тора. Борынгы заманнарда Әтил яки Идел исемендә йөргән бу торак урын башта Иделнең югарырак агымында булган, Алтын Урда заманында исә башка урынга күчерелеп, башка исемнәрдә йөргән. Әстерхан ханлыгы зур булмаса да, аның географик яктан җайлы урнашуы, диңгезгә һәм зур елгаларга якынлыгы күпләрдә аңа карата кызыгу хисе уяткан. Әйткәнебезчә, Нугай Урдасы да, Кырым ханлыгы да Әстерханны үз тәэсирендә тотарга тырышкан. Мәскәү исә беренче көннәреннән үк су юлларына бай бу Татар дәүләтенә күз сала һәм, җае чыккан саен, аны үз кулына алырга тырыша. Шуңа күрә Мәскәү әле 1533 елда ук Әстерхан ханлыгы белән үзара ярдәм итешү турында килешү төзи, шулай итеп, татар ханлыгының эчке эшләренә катнашырга бер юл ачыла. Мәскәү, гадәтенчә, тәхет тирәсендәгеләрне сатып алулар, татарларны бер-берләре белән чәкәләштерүләр, Әстерханны — Казанга һәм Кырымга, Нугай Урдасын Әстерханга каршы котыртулар башлана. Имеш, Әстерхан тәхетендә кырымлылар утырырга тиеш түгел, имеш, нугайлыларның моңа күбрәк хакы бар.

Казан алынгач, Мәскәүнең бу итәк асты уеннары барысы да юкка чыга — ул Әстерхан ханлыгын яулап алырга җыена. Халыкны куркыту өчен, Казан татарларын дарларга асып, саллар белән Идел буйлап, Әстерханга таба агызып төшереп җибәрәләр. «Әзер булыгыз, безгә каршы торсагыз, сезне дә менә шушы хәл көтә!» дигән хәбәрләре була бу урысларның. Сугыш өчен «сәбәп» тә табыла: имеш, нигә әле Әстерхан тәхетендә кырымлы Ямгурчы утырырга тиеш? Әнә бит Нугай Урдасы ханы Исмәгыйль моны теләми икән, Ямгурчыны бәреп төшерү өчен, Мәскәүдән ярдәм сорый, ди. Һәм 1554 елның язында, елга боздан ачылу белән, Явыз Иванның 30 меңлек гаскәре Әстерхан ханлыгы өстенә ябырыла. Урыслар Әстерханны тиз алалар, Ямгурчы ханны әсир итәләр, аның урынына үзләре яклы Дәрвиш Галине куялар. 1554 елда Мәскәү белән ике арада солых төзелә, Әстерхан ханы Мәскәүнең вассалы була, ягъни аңа буйсына, татар ханлыгы шулай ук Мәскәүгә ел саен 40 000 алтын ясак түләргә тиеш була. Һәрвакыттагыча, Әстерханга да урыс гаскәре кертеп тутырыла.

Әмма халык бу хәтле ясакны түләрлек хәлдә булмый, ханлыкта ыгы-зыгылар, баш күтәрүләр башлана. Дәрвиш хан Кырымнан ярдәм сорарга мәҗбүр була, алар ханны сакларга мең кешелек гаскәр һәм корал җибәрәләр. Бу хәл урысларга Әстерханны тар-мар итеп ташларга җитә кала. 1556 елның язында Мәскәүдән җәза отрядлары кузгала. Алар көтмәгәндә Әстерханга һөҗүм итеп, аны җимереп ташлыйлар, хан исә башка урында булып чыга. Каспий диңгезе буйларында урыс башкисәрләренең Дәрвиш хан белән көчле бәрелешләре булып ала. Әмма татар ханы җиңелә һәм Азов диңгезе аша Төркиягә качарга мәҗбүр була. Әстерхан ханлыгы тулысынча урыс аяк астында кала. Нәтиҗәдә Әстерхан ханлыгы юк ителә, 1556 елның 26 августында ул Россиягә кушыла. Татарларга хәтта кечкенә генә мөстәкыйльлек тә калдырмыйлар, өлкә белән идарә итәргә урыс воеводасы утыртыла, татарлар белән урыс хакимияте идарә итә башлый. Тарихта 100 ел яшәгән, тәхетендә 13 ханы булган Әстерхан татар дәүләте әнә шулай юкка чыга. Әмма бу җирләрдә татар халкы юкка чыкмый, алар бүген дә борынгы туфракларында яшәп яталар…

## ТАТАРЛАРНЫҢ СЕБЕР ХАНЛЫГЫ

Себер җирләре борын-борыннан татарларның таралып яшәгән, ил-җирләр, зур дәүләтләр тоткан урыны булган. Бу җирләр һун татарларының һәм скиф атларының тояк эзләрен дә, төрле бәрелешләрне, ил-җир тоткан татар ханнарын, аларның кальга-кирмәннәрен, шәһәрләрен дә яхшы хәтерли булыр. Урыс тарихында Себер татар дәүләтләре тарихы бик аз яктыртыла, барысы да Ермак белән Күчем ханның сугышларына гына кайтарылып калдырыла. Югыйсә бу җирләрдә татарлар, аларның дәүләтләре меңнәрчә еллар яшәп килгән бит, бүген дә биредә татарлар яши. Ә шул халыкның зур тарихы калын пәрдә артында кала бирә…

Себер — Сабир — Саба Ирләре җире — борынгы татарларның төп җирләре, Ана Ватаннары. Кайбер галимнәрнең әйтүенчә, безнең эрага кадәр IV меңьеллыкта ук, биредә төрки телле халыклар, ягъни татарлар яшәгән. 500—600 ел вакыт эчендә алар шушы тирәләрдән, Урал тауларының ике ягыннан бөтен дөньяга — Байкалдан Кытайгача, көньяктан — Үзәк Азиягәчә, көнбатыш тарафка исә Дунай, Карпатларгача таралалар, барып җитәләр. Бу галимнәрнең әйтүенчә, Көнчыгыш Европага һуннар, кыпчаклар, угызлар һәм скифлар, бәҗәнәкләр килгәнче үк, биредә инде төрки кабиләләр, ягъни татарлар яшәгән. Зәки Вәлиди дә шуны раслый, төрки-татар халыкларының эзләрен ул борынгы Шумерда, Мисырда, Кече Азиядә таба, аларның анда Идел-Урал буйларыннан килгәнлекләрен әйтә. Габдулла Баттал Таймас исә: «Юго-Восток Европы — древний тюркский юрт»,— ди һәм аларны Идел-Урал татарлары белән бәйләп карый. «Сибирия ул — борынгы Скифиянең бер өлеше»,— дип язган XX гасыр башында тарихчы Һади Атласи. Бу, чыннан да, нәкъ шулай. Күргәнебезчә, Себер иле ул — борынгы Татар иленең бишеге, нигезе, бер өлеше икән. Әле Алтын Урдага кадәр үк, биредә Уйгур, Кимак, Кыпчак, Кыргыз каганатларының гөрләтеп яшәп ятканлыгын да әйтеп үтәргә кирәк. Аларның җирләре иксез-чиксез, маллары хисапсыз, ирләре курку белмәс, хатыннары йорт һәм бала җанлы булган. Татарның бөтен борынгы дәүләтчелекләрен дә диярлек Себер үз җаны аша уздырган, шуларның үзәгендә торган. Алдагы бүлекләрдә бу турыда җентекләп язганлыктан, боларга туктап тормыйбыз.

Алтын Урда чорларында ук Себер татарларының үз хакимнәре булган. 1420 елга хәтле биредә Төмән ханлыгы булганлыгы билгеле. 1396 елны бирегә Алтын Урда ханы Туктамыш кача һәм тәхеткә утыра, биредә ул 1406 елга кадәр Себер белән идарә итә. Аннан соң Төмән тәхетендә Чәкри хан (1407—1413), Шәйбани хан (1413—1428), Әбелхәер хан (1428—1458), Ибак хан (1464—1495), Мамук хан (1496—1530), Колык Солтан (1502—1530), Тайбугилар нәселеннән Бикбулат хан һәм Ядегәр (1530—1550), Ядегәр хан (1552—1563), аннан тагы Шәйбаниләр нәселеннән Күчем хан (1563—1598), Али хан (1598—1604) идарә итәләр. Бу ике зур нәселнең тәхет өчен үзара тарткалашып яшәгәнлекләре билгеле.

Тарихчылар язганча, Себер ханлыгының биләмәләре бик зур була — XVI гасыр урталарында аның җирләре бөтен Көнбатыш Себерне үз эченә ала. Урал тауларының көнчыгыш итәкләреннән башланган бу биләмәләр көнчыгышта Надым һәм Пима елгаларына хәтле барып җитә, төньякта — Пермь җирләре белән, Көнбатыш Уралда — Казан ханлыгы белән, Көньяк Уралда Нугай Урдасы белән чикләшә, ә көньякта исә Иртыш елгасының югары агымына һәм Обь елгаларына хәтле барып чыга. Себер ханлыгының төп халкы, әлбәттә, татарлар була, шулай ук биредә җирле ханты-мансы кабиләләре дә яши. Җирләре тоташ урманнардан торганлыктан, Себер ханлыгында кеше күп яшәми, әмма зур су буйлары, ачык урыннар шәһәрләр һәм торак урыннар белән тулы була. Биредә борынгыдан Тура елгасы буенда Кызыл-Тура (Усть-Ишим), Касыйм-Тура, Яулы-Тура, Тон-Тура, Чимги-Тура шәһәрләре булганлыгы билгеле. Соңгысы — Чимги-Тура XIII гасырда Себер татарларының башкаласы булып тора, бүгенге көндә ул Төмән шәһәре. Бу шәһәрләрдә, нигездә, Тайбуги нәселе яшәгән һәм идарә иткән. Ә Шәйбани хан нәселе исә Иртыш елгасы буенда үз башкаласын булдырган. XIII гасырда хәзерге Тубыл шәһәреннән 16 чакрым ераклыкта татарларның Искер шәһәре булган, XV гасыр башында ул Кашлык дип үзгәртелгән. XV гасырда Себер ханлыгының башкаласы Искер-Кашлык һәм Чимги-Тура шәһәрләрендә була.

Казан ханлыгы урыслар тарафыннан алынганда, Себер тәхетендә Ядегәр хан утыра. Ул бу фаҗигагә гадәти бер сугыш дип карый, ахры, 1555 елның гыйнварында Мәскәүгә үзенең илчеләрен дә җибәрә. Урыс тарихчыларының әйтүенчә, имеш Себер ханы Явыз Иванны бу җиңүе белән котлый һәм үзенең дә аның кул астына керәсе килүен белдерә. Моңа бик үк ышанып бетәсе килми, әлбәттә, кемнең үз теләге белән коллыкка керәсе килсен икән? Моңа кадәр Себернең кайда икәнлеген дә белмәгән урысларга бу байлыкларны таларга юл ачыла — Явыз Иван Мәскәүгә Себер ханлыгындагы һәр кеше исәбеннән затлы кеш һәм тиен тиреләре җибәреп торуны мәҗбүр итә, үзенең ясак җыючыларын Себергә юллый. Әмма халык бу хәтле тирене җыя алмый, шул сәбәпле татар илчеләре Мәскәүдә кулга алына. Ул арада Себердә Ядегәр ханны Шәйбани нәселеннән булган Күчем хан яугирләре үтерә. Күчем хан шулай ук Мәскәүнең ясак түләүне күзәтергә килгән вәкилен дә үтертеп ташлый, шулай итеп, Мәскәү белән араларын өзә, аңа буйсынмавын белдерә. Ул арада Пермь җирләренә, алтын-көмешкә, тимергә бай Урал тауларына урыс эшмәкәрләре борын суза башлаган була. Сукбай казак Ермак та зур булмаган отряды белән бу җирләргә килеп төшә һәм урыс байларын сакларга яллана. 1581 елда Күчем гаскәре белән менә шушы казак атаманы арасында бәрелешләр башлана. Бу бәрелешләр алга таба зур сугышларга әйләнеп китә, чөнки патша Россиясе башкисәр Ермакны Себер ханлыгын җимерү өчен файдаланырга уйлый һәм моның өчен акчасын да, коралын да, хәтта үз урысларын да кызганып тормый. Кара урман эчләрендә, адәм үтә алмаслык сазлыкларда, язгы һәм көзге юл өзеклекләрендә

урысларның татарлар белән аяусыз сугышлары башлана. Урыслар талау өчен килә, татарлар үз җирләре өчен көрәшә… Урыслар кулында утлы корал, мылтык була, татарларда — ук һәм җәя… Шунлыктан Ермак башта шактый уңышларга да ирешә, Тура һәм Тубыл елгалары буена урнашкан татар авылларын һәм шәһәрләрен туздыра. 1582 елның 26 октябрендә ул хәтта Себер ханлыгының башкаласы Искерне ала, анда кыш чыга. 1583 елның җәендә, шушы уңышларыннан башы әйләнеп, ул Мәскәүгә, Явыз Иванга Себерне тулысынча яулап алуы турында хәбәр җибәрә. Имеш, ул Күчем ханны җиңгән, аның улы Мәмәтколны әсир итеп алган, татарларның башкалаларын алган, бөтен тирә-юньне үзенә буйсындырган. Мәскәү патшасы бу хәбәрне алгач, үзенең ике воеводасын, сугышчылары белән бергә, Себергә җибәрә, имеш, алар Ермак кулыннан Себер ханлыгын рәсми рәвештә кабул итеп алырга тиеш булалар. Күчем хан аларны Себер урманнарында көтеп тора һәм берәм-берәм барысын да үтереп бетерә. 1584 елның 5—6 август төнендә башкисәр Ермак үзе дә татарлар тарафыннан үтерелә, ә исән калган берничә урыс гаскәрие Урал аша чакка-көчкә Россиягә качып котыла.

Шулай итеп, Себердә яңадан татар ханы Күчем хакимлек итә башлый. Ә урыслар Ермакның үлгәнен белмиләр, аңа ярдәмгә тагы гаскәр арты гаскәр җибәрәләр. Ул арада Явыз Иван да үлеп китә. 1585 елның җәендә Мәскәү тагы Себерне яуларга юлга чыга. Алар яулап алуны нәкъ Казандагы кебек кирмән-крепостьлар төзүдән башлыйлар. 1586 елда Төмән, 1587 елда Тобол крепостьлары калкып чыга, Тура, Пышма, Тубыл, Тавды, Лозовье, Пельма, Сосьва, Тара, Кети, Обь елгалары буенда дистәләгән урыс ныгытмалары төзелә. 1586—1597 еллар эчендә Себер, әкренләп, урыс хәрби кирмәннәре белән тула. Боларны күргән Күчем хан илнең көньяк чикләренә чигенергә мәҗбүр була. Ул, көч туплап, Себердә калкып чыккан урыс крепостьларына һөҗүм итеп карый, әмма утлы корал көче каршында, җиңелергә һәм чигенергә мәҗбүр була. 1598 елның августында Күчем хан гаскәре урыслар тарафыннан тар-мар ителә. Хан үзе Нугай далаларына китә һәм шунда үтерелә. Аның урынына улы Гали хан булып кала, 1604 елда ул урыслар тарафыннан кулга алына һәм 1618 елда урыс төрмәсендә үлә. Шуның белән борынгы Себер җирләрендә тагы бер Татар дәүләте бетә, тагы бер йолдыз сүнә… Әмма аңа карап, татар халкы бетми, ул бүген дә үзенең туган туфрагында, борынгы Себер җирләрендә, һун татарларының, скифларның, кыпчак һәм төркиләрнең Ана Ватанында яшәп ята… Себер беркайчан да килгән-килмешәк урысларның туган җире булмады, алар монда талау өчен генә килделәр, бүген дә анда табигатьне талап көн күрәләр… Һәм урыс патшалары татар Себерен гомер буе төрмә итеп файдаландылар, аны яратмадылар, аңа тартылмадылар… Чөнки ул аларның ил-җирләре түгел иде, ул мәңгелектән Татар иле, татар җирләре булды, һәм, иншаллаһ, шулай булып калыр да…

## ТАТАРЛАРНЫҢ НУГАЙ УРДАСЫ

Нугай Урдасы тарихы чагыштырмача аз өйрәнелгән һәм аның турында мәгълүмат күп түгел. Булган кадәресе дә шактый каршылыклы. Урыс тарихчылары Нугай Урдасына бер төрле бәя бирсәләр, Казан галимнәре — икенче төрлерәк, ә инде Төньяк Кавказда яшәүче аз санлы нугайлар бу мәсьәләгә бөтенләй башкача карый. Без исә, тарихта булып үткән хәлләргә һәм фактларга таянып, моңа кадәр әйтелгәннәрне дә искә алып, Нугай Урдасы тарихы буенча үз фикеребезне әйтергә тырышырбыз.

Иң беренче шуны әйтергә кирәк: нугайлар — шул ук татарлар алар. Күрше казах-кыргыз халкы татарларны әле хәзер дә кайвакытта нугай дип атый. Аларның төп яшәгән урыннары — Идел — Урал арасы була, ягъни татар милләте барлыкка килгән урын. Биредә татарларның борынгы бабалары Нух пәйгамбәр заманнарыннан бирле яшәгәннәр. Тарихның төрле чорында алар, бәлки, төрле исемнәр йөрткәннәрдер, әмма аларның телләре татар теле булган, бу турыда борынгы язмалар, сүзлекләр, шәҗәрәләр сөйли… Себер ханлыгы татарлары кебек үк, соңыннан Нугай Урдасына кергән татарлар да үз тарихларында милләт үткән бөтен чор-юлларны да үткәннәр. Алар шулай ук һун татарларының асыл нигезен дә тәшкил иткәннәр, скифлар, сөннәр, сарматлар, саклар, кыпчаклар, угызлар булып та йөргәннәр, бөтен бөек татар дәүләтләренең, каганатларның, ханлыкларның үзәгендә торганнар. Моңа гаҗәпләнергә дә кирәкми, чөнки сүз бер тарихи чорында нугай дип аталган шул ук татар халкы турында бара бит.

Ә инде Нугай Урдасының үз тарихын Идегәй морза эшчәнлеге белән бәйләп өйрәнәләр. Ягъни шушы исемдәге Татар дәүләте Алтын Урда таркала башлаган чорда, аның җирләрендә XV гасыр башларында барлыкка килә. Нугай Урдасының дәүләтчелек башында Идегәй би һәм аның нәселе тора. Бу Татар дәүләтенең биләмәләренә хәзерге Ырынбур өлкәсе җирләре, бүгенге Башкортстан Республикасы, Җаек (Урал), Агыйдел, Уфа елгалары тирәләре керә. Нугай Урдасының җир биләмәләре бик зур була, аның чикләре көньякта — Бохарага, төньякта — Пермь тирәләренә, көнбатышта — Идел һәм Дунай буйларына кадәр, ә көнчыгышта Иртыш елгасына кадәр сузыла. Урданың башкаласы булып

Сарай (Сарайчык) шәһәре тора. (Ул урын хәзер Казахстанның Гурьев шәһәре тирәсендә.) Урыс галимнәренең язуынча, имеш, Нугай Урдасы бик көпшәк, таркау дәүләт булган, алар мал-туар артыннан гына күчеп йөргәннәр, Сарайчыктан башка шәһәрләре дә булмаган… Шушы фикер татарлар язган хезмәтләргә дә үтеп кереп бара. Без моның белән килешмәс идек. Беренчедән, Нугай Урдасының халкы ул вакытлар өчен бик күп була, галимнәрнең әйтүенчә, 300—400 мең, ә Әстерхан һәм Себер ханлыкларында бу сан нибары 30 мең генә иде. Бу хәтле халык мал артыннан гына ияреп йөри алмый, бигрәк тә салкын кыш айларында. Аңа, һичшиксез, туктау, яшәү өчен торак урыннары, шәһәрләр, аларны саклау өчен, хәрби кирмәннәр, гаскәр кирәк булган. Әлбәттә, болар барысы да Нугай Урдасында булган. Нугай Урдасына тиз арада 200 мең атлы гаскәр җыю бернигә тормаган. Нугай Урдасы, кирәк чакта, Казанга да, Әстерханга да, Кырымга да ярдәмгә килгән, үзара бәрелешеп алган вакытлары да булган. Җаек, Агыйдел, Иртыш, Идел, Самара, Бузан елгалары буйларындагы борынгы татар шәһәрләре, хәрби кирмәннәр барысы да Нугай Урдасы биләмәләрендә булган.

Шунысын да онытмыйк: Нугай Урдасы — дәүләт тоткан ил бит. Биредә аның үзенең хан дәрәҗәсендәге морза-князьләре булган. Шулай ук, Чыңгыз хан заманындагы кебек, нугай татарлары үзләренең корылтайларын уздырганнар, анда ил белән идарә итәргә башлыклар билгеләгәннәр. Хан ил белән үзе генә идарә итмәгән, киңәш өчен, морзалар советы тоткан. Ягъни хакимият системасы биредә дә нәкъ башка татар дәүләтләрендәге кебек булган. Нугай Урдасы халкының укымышлы булуын да әйтеп үтәргә кирәк, бу хакта нугай татарларының безнең көннәргә хәтле килеп җиткән мең еллык нәсел шәҗәрәләре сөйли. Халык ислам динендә булган, гарәп әлифбасын кулланган, димәк, биредә мәчет-мәдрәсәләр, уку йортлары да булган дигән сүз. Болар инде үзләре үк Нугай Урдасы халкының шәһәр культурасына ия булуын күрсәтә.

Урыс тарихчыларының икенче ялгыш фикере — алар Нугай Урдасын башка татарларга, бигрәк тә Казан ханлыгына дошман итеп күрсәтергә яраталар. Имеш, Нугай Урдасы, нигездә, Мәскәү белән эш йөрткән, татарлар арасында Мәскәү агенты ролен үтәгән, шуңа күрә урыслар башта аңа тимәгәннәр, дип язалар. Мәскәү ул вакытларда ук бөтен татарларның, шул исәптән Нугай Урдасы белән Казан ханлыгының, дошман булуын бик теләгән, шуңа омтылган булырга тиеш. Монда аерым кешеләрне сатып алу яки куркыту алымнары, сәяси кодалашу, махсус туганлашу юллары да киң кулланылган. Кыскасы, Мәскәүгә бөтен татар җирләре кирәк булган һәм, моңа ирешү өчен, ул барысын да эшләгән. Ул хәтта туган белән туганны, ата белән улны бер-берләренә каршы кую, котырту, үтертүләргә хәтле барып җиткән. Нугай Урдасы белән дә нәкъ шулай булган.

Нугай Урдасы белән Йосыф морза идарә иткән вакытта, ул Казанның союзнигы була. Сөембикә ханбикәнең Йосыф морза кызы икәнлеген онытмыйк, аңа кадәр дә Казан белән Нугай кыз биреп, кыз алышып, туганлашып яшиләр. Казан ханлыгы җимерелгәч тә, аны яңадан торгызырга хан булып Йосыф морза улы Гали Әкрам килә. Тарихчылар язуынча, 1553 елның октябрендә Йосыф морза, 120 меңлек гаскәр җыеп, Мәскәүгә яу белән чыга. Әмма ул Мәскәүне ала алмый, Серпухово-Каширово тирәсендә сугышларда кире чигенә. 1554 елда Йосыф морза үтерелә, урыс тарихчылары аны туганы Исмәгыйль үтергән дип баралар. Моны бер Аллаһ кына белә. Йосыф морза үлгәннән соң, Нугай Урдасы тәхетендә Исмәгыйль кала, ул тулысы белән Мәскәү ягына борыла. Ул Йосыф морзаның калган балаларын Мәскәүгә тотык итеп бирә, Казанга ярдәм итүдән баш тарта, Мәскәү хөкүмәтен тану йөзеннән, анда күп бүләкләр җибәрә. Урдада бу хәлгә ризасызлык күрсәтүчеләр дә күп була. Нәтиҗәдә 1556 елда Нугай Урдасы өчкә бүленә: Мәскәү яклы, Мәскәү вассалы Исмәгыйль җитәкләгән, төп җирләрне үз эченә алган Олы Нугай, Төньяк Кавказга күчеп киткән нугай татарлары оештырган Кече Нугай (алар Төркия һәм Кырымга йөз тоталар) һәм Нугай Урдасының Алтыавыл олысы дип аталган, соңыннан халкы каракалпаклар дип атала башлаган иң көньяк өлеше. Татар дәүләте берничәгә бүленеп ташлый, кайберләре христиан динен дә кабул итә… Әмма аларның һәрберсен бу тарих мәйданында фаҗигале хәлләр, аянычлы язмыш көтә…

Нугай Урдасы, ягъни Олы Урда, күпме генә Мәскәү белән килешеп яшәргә теләсә дә, Мәскәүгә ул кирәк булмый. Мәскәүгә татарларсыз гына аларның бай җирләре кирәк була. Һәм ул моннан нугай татарларын чыгарып җибәрү өчен барысын да эшли. Җитмәсә, Иштерәк хан, Мәскәүгә йөз тотуын ташлап, Төркия, Кырым ягына борыла башлый. Татарларны бу җирләрдә ахыргача юк иттерү өчен, урыслар алар өстенә калмыкларны котыртып чакырып китерә. 1630—1634 елларда 50 меңлек калмык гаскәре Алтай буйларыннан Идел — Урал арасына килеп чыга һәм нугай татарларына үтергеч һөҗүм ясый. Бу бәрелешләрдә нугай татарларының күп өлеше үлә. Татарларның калган өлешен исә Дон казаклары килеп туздыра. Исән калган нугай татарлары Кырым ханлыгы җирләре булган Кара диңгез буйларына, Кубань тирәләренә, Төньяк Кавказга качалар. Калмыклар исә, урыс гаскәрләре белән берләшеп, 1661 елда Кырымга һөҗүм итәләр, алга таба Иранга, Төркиягә каршы сугышырга Мәскәү алдында ант итәләр. Шулай итеп, мәҗүси-буддачы калмыклар христиан урыслар кулында татарларга

ислам диненә каршы корал булып торалар, бу халыкларга бик күп җәбер салалар. Алар нугай татарларына Төньяк Кавказга күчеп киткәч тә тынгылык бирмиләр, халыкның яртысын кырып, үтереп, яндырып чыгып китәләр.

Кече Нугай Урдасы Төньяк Кавказда 1783 елга кадәр яши. Әби патша заманында Потемкин белән Суворов соңгы нугай дәүләтчелегенә дә чик куялар. Октябрь революциясеннән соң да нугайларга якты көн килми, аларны төрле өлкәләргә бүлгәләп ташлыйлар, аерым милли республика булып оешырга ирек бирмиләр. Бүгенге көндә дә нугайлар шушылай таркатылып ташланган хәлдә яшиләр — бер өлешләре Ставрополь краенда, кайберәүләре — Дагстанда, өченчеләре Чечняда көн күрә, алар Әстерханда, Карачай-Черкесиядә дә бар. Бүгенге көндә шартлы рәвештә Нугай далалары дип аталган җирләрдә 50 меңгә якын нугай яши, калган 40—50 меңе дөньяның башка илләрендә көн күрәләр. Ә Идел-Уралда калган нугайлар күптән инде үз асыл исемнәрендә — татар дип йөртеләләр, арада типтәр дип аталучылары да бар. Бүгенге көндә Чиләбе өлкәсендә яшәүче нугайбәкләр дә шушы тамырдан — татар тамырыннан чыккан кешеләр… Шулай дәүләтләр беткән, милләт калган… Татар калган… Хәтер калган…

## ТАТАРЛАРНЫҢ КЫРЫМ ХАНЛЫГЫ

Тарихтан күргәнебезчә, Кара диңгез буйларында, Азов тирәләрендә бик борынгы заманнардан төрки телле халыклар, ягъни татарлар яшәгән. Аларны һуннар дип тә, гуннар, скифлар, сарматлар дип тә атап йөрткәннәр, әмма аларның телләренең төрки, ягъни татар теле икәнлеген барысы да ассызыклап үткән. Бу хакта безнең эрага кадәр үк Геродот та язып калдырган, башка грек, Европа, фарсы, гарәп тарихчылары да хәбәр биргән. Безнең өчен Кырымның бик борынгы заманнардан ук Татар иле икәнлеге бәхәссез, әмма аның олы тарихына хуҗа булырга теләүчеләр бүген бик күп.

Ә инде Кырым ханлыгына килгәндә, Алтын Урда таркала башлаганчы ук, биредә инде татарларның мөстәкыйль биләмәләре була. Дәүләт буларак исә ул Хаҗи Дәүләт Гәрәй ханлык иткән заманнан, 1420 еллардан исәпләнә башлый. Шунысын да әйтергә кирәк: Кырым тәхетендә бары тик Чыңгыз хан нәселе генә хан булып утыра алган. Дәүләт Гәрәй ил белән кырык ел идарә иткән, Кырымда бик күп мәчетләр, мәктәпләр салдырган, ислам динен киң җәелдергән. Ул хан булып утырганда, Кырым икътисади яктан бик нык үсеп киткән, төрле илләр белән сәүдәләр гөрләп торган. Шул ук вакытта беренче Кырым ханнарының Алтын Урда дәүләтенә карата дошмани позициядә булганлыкларын, аны ахыргача таркатуда зур көч куйганнарын да әйтергә кирәк. Дәүләт Гәрәй ханның улы Миңле Гәрәй хан Алтын Урданың Кырымны тануына сугыш юлы белән ирешә.

Алтын Урдадан тыш та, Кырымга кызыгучылар һәм аны үзләренә буйсындырырга теләүчеләр күп була. Кырым ханнарына Төркия, Литва, Польша, Генуя, Мәскәү белән дипломатик сөйләшүләр, ә кайберләре белән сугышлар да алып барырга туры килә. Ханнар нәселенең үз арасында да тынычлык җитеп бетми, тәхет өчен көрәшкәндә, алар бер-берләренә кул күтәрүгә яки дошман көчләргә таянуга да барып җитәләр. Әмма ил белән идарә итүдә хан барлык мәсьәләләрне дә бер үзе генә хәл итми. Барлык татар дәүләтләрендәге кебек үк, биредә дә киңәш советы — диван була, аңа дүрт затлы нәселнең вәкилләре керә. Илнең идарә структурасы шулай ук Алтын Урданы һәм башка татар дәүләтләрен кабатлый.

1454 елда Кырым, үзенең мөстәкыйльлеген өлешчә югалтып, Төркия кул астына керә. Әмма моннан Кырым әллә нәрсә югалтмый, киресенчә, госманлылар йөзендә көчле яклаучылар, союзниклар таба. Төркия белән сәяси, икътисади, хәрби, мәдәни якынлык, бергәлек Кырымның алга таба бөтен тарихында тирән эз калдыра. Төркиянең бәрәкәтле канаты астында Кырымда чын мәгънәсендә гүзәл архитектура туа, сәнгать әсәрләре барлыкка килә, бер-бер артлы кальга-шәһәрләр үсеп чыга. Моңа кадәр, нигездә, мал асрап, иген игеп, балык тотып, бакча җимешләре үстереп яшәгән халыкның офыклары, мөмкинлекләре тагы да киңәеп китә. Хәер, бер телдә сөйләшкән, бер дин тоткан, тамырда бер халык — һун татарлары булган кырымлы һәм госманлыларның аралашып яшәү нәтиҗәсе башкача була да алмас иде. Кырымның Төркиягә карата вассаллык хәле исә ханнар билгеләүдә ачык чагылган, сугыш һәм солых мәсьәләләрендә Кырым Төркия мәнфәгатьләрен дә истә тотарга тиеш булган.

Кырымда ханнар династиясе Гәрәйләр нәселе белән башланып китә. Аның башында Хаҗи Гәрәй, Миңле Гәрәй ханнар торса, алга таба Кырым тәхетендә Мөхәммәт Гәрәй, Сәгадәт Гәрәй, Сәхип Гәрәй, Дәүләт Гәрәй I, Мөхәммәт Гәрәй II, Ислам Гәрәй, Гази Гәрәй, Сәламәт Гәрәй, Җанибәк Гәрәй, Каплан Гәрәй, Кырым Гәрәй, Арыслан Гәрәй ханнар утырган. Казан тәхетендә исә Гәрәй ханнар нәселеннән Сәхип Гәрәй һәм Сафа Гәрәй утырганнар, берничә ел Сафа Гәрәйнең улы кечкенә Үтәмеш хан булып

торган, әнисе Сөембикә исә ханлык иткән. Моннан күренгәнчә, Кырым заманында Төркия кул астына керсә, Казан, үзе теләп, Кырым канаты астына сыена. Бу өч ил сәясәт мәйданында союзниклар булсалар да, Казан өчен иң авыр көннәрдә — 1552 елда Кырым белән Төркия аңа ярдәмгә килә алмыйлар. Дөрес, 1567 елда төрек солтаны Сәлим, Әстерханны алырга, бөтен Идел буен яңадан мөселманнарга кайтарырга дип, юлга кузгала, әмма аның бу сәяхәте уңышсыз тәмамлана.

Кырымлылар, соң булса да, Мәскәүгә һөҗүм итеп, Казанны, Әстерханны кире кайтарырга тырышып карыйлар. Бу хәл 1571 елның язында була. Кырым ханы Дәүләт Гәрәй 120 меңлек татар гаскәре белән Мәскәү шәһәренә һөҗүм итә. Явыз Иван, бу хәлдән коты чыгып, Мәскәүне ташлап кача, татар гаскәре киткәнче, Ростов шәһәрендә качып ята. Дәүләт Гәрәй Мәскәүне яндыра, бик күп урысларны кырып сала, байлыкларын үзе белән алып китә. Һәм ул Кырымга кайткач, Явыз Иванга түбәндәге эчтәлекле хатны юллый: «Казан белән Әстерханнан кала, бөтен җирне җимереп ягачакмын. Бөек Тәңрегә тапшырып, бөтен җиһан байлыгын җир белән тигезләячәкмен. Мин сиңа каршы бардым, башкалаңны яндырдым, таҗың белән башыңны да алачак идем, син безгә каршы чыкмадың, якын килмәдең. Әле үзең хөкемдарлык иткән буласың. Синдә оят һәм намус булса, чыгар идең, безгә каршы торыр идең. Безнең белән җан дуслар булырга телисең икән, безнең илләребез булган Казан белән Әстерханны кире бир! Безнең максатыбыз — Казан белән Әстерхан! Акча һәм хәзинә белән котыла алмассың, дөнья байлыгын бирсәң дә кабул итмәм. Ә дәүләтеңнең юлларын исә мин күрдем һәм белдем».

Бу хаттан соң шактый пошаманга төшкән Явыз Иван Дәүләт Гәрәй ханны җайлый, майлый башлый, аңа күп итеп бүләкләр җибәреп карый. Урыс патшасының вакыт сузарга гына теләвен сизеп алган Кырым ханы 1572 елда 120 меңлек татар гаскәре белән тагы Мәскәү өстенә килеп карый, әмма Ока елгасы тирәсендә җиңелә. Бу хәлдән соң инде Явыз Иван да батыраеп китә, Казан белән Әстерханны кире кайтарырга уйлап та карамый. Ул Кырымнан кала тагы ике кылычның, ягъни Казан белән Әстерханның, дөньяга килүенә юл куймаячагын әйтә. Һәм юл куймый да. 1591 елда Кырым ханы Гази Гәрәй тагы бер тапкыр Мәскәүгә яу чабып карый, әмма уңышка ирешми. Шуннан соң ул Мәскәүгә илче җибәрә һәм урыс патшасына: «Безнең ханыбыз Казанны да, Әстерханны да кире алырга теләми, тик патша ханыбыз теләгән бүләкләрне генә җибәрсен»,— дип әйтергә кушкан. Шуның белән Кырым өчен Казан темасы ябыла.

Кырымлылар өчен Казан темасы ябылса да, Мәскәү өчен Кырым темасы ябылмый, киресенчә, еллар үткән саен, Мәскәүнең Кырымны яулап алу теләге көчәя генә бара. 1735 елда 40 меңлек урыс гаскәре Кырымга һөҗүм итә, әмма уңышка ирешә алмый. Икенче елны бу һөҗүм тагы кабатлана, һәм урыслар Кырымда зур вәхшилекләр эшлиләр. Алар тыныч халыкны суеп чыгалар, Бакчасарайны ут төртеп яндыралар, мәчетләрне, хан сарайларын җимерәләр. Могҗиза белән исән калган татарлар тауларга качалар. Урамда аунап яткан мәетләрдән яман чир тарала, нәтиҗәдә Кырымга һөҗүм иткән 30 мең урыс гаскәренең 27,5 меңе эпидемиядән үлә, татарлар исә тауда исән калалар.

Икенче елны тагы 35 меңлек урыс гаскәре Кырымга килеп керә һәм тагы исән калган татарларны суярга, авыл һәм шәһәрләрне яндырырга тотына. Урыс гаскәренә ашарга ризык калмый. Инде Россия сөйләшүләр юлы белән Төркиядән Кырымны үзенә таләп итә башлый, әмма Төркия баш тарта. Ул арада Россия тәхетенә Елизавета Петровна килә, һәм Төркия белән ике арада дуслык чоры башлана. Бу исә Россиянең Кырымга мөнәсәбәтен дә үзгәртә. Яндырылган шәһәр һәм авыллар Арыслан Гәрәй хан заманында (1748—1756) яңадан торгызыла, мәчет-мәдрәсәләр эшли башлый. Кырым Гәрәй хан идарә иткән елларда исә (1758—1764) биредә фән, сәнгать, мәгариф бик нык үсеп китә. Тышкы сәясәттә дә бу татар ханы зур активлык күрсәтә, ул Европа илләре белән ныклы элемтәгә керә, алар арасыннан үзенә союзниклар эзли. Әмма ул Кырым тәхетенә Төркияне саннамыйча килгән була, һәм, бер җай чыгу белән, алар аны алып та ташлый. Ул арада Төркия артык узынган Россиягә каршы сугыш игълан итәргә мәҗбүр була, Кырым Гәрәйне яңадан Кырым тәхетенә кайтаралар һәм урысларга каршы сугышка җибәрәләр. Әмма 1764 елда Кырым Гәрәй ханны шушы яу юлында агулап үтерәләр. Аның үлеме белән Кырымның да сәяси үлеме якынлаша…

Россия Кырымны бөтенләе белән басып алу һәм үзенә буйсындыру планыннан беркайчан да баш тартмый һәм аны тормышка ашырырга тотына. Хәйлә һәм мәкер юлы белән Кырымны Төркиядән аерып ала алмагач, Россия тагы көч куллануга күчә — 1771 елның җәендә 30 мең кешелек урыс гаскәре тагы Кырымга бәреп керә. Ике атна вакыт эчендә алар Кырымны баштанаяк яндырып, кырып чыгалар. Утраудан төрек гаскәре куыла, Кырым ханы Истанбулга кача. Тәхеткә исә урыслар яклы Сәхип Гәрәйне утырталар. Урыслар кулыннан Кырымга мөстәкыйль «автономия» бирелә, шул хакта 1772 елның 1 ноябрендә ике яктан куллар куела. Бу уен Кырымны Төркиядән ахыргача аерып алу өчен эшләнә. Әмма халык Кырымга кереп тулган урыс гаскәреннән һич кенә дә риза булмый, алар әле күптән түгел генә булып үткән вәхшилекләрне яхшы хәтерлиләр. 1774 елның 10 июлендә Төркия белән

Россия арасында Кючук-Кайнар солыхы төзелә, аның буенча Кырымның Төркиядән дә, Россиядән дә бәйсезлеге таныла, ханнарны халык үзе куярга тиеш була. Кырым халкы шунда ук урыслар куеп киткән Сәхип Гәрәй ханга каршы баш күтәрә, аны бәреп төшерә һәм тәхеткә Дәүләт Гәрәй III не утырта (1775—1777). Мәскәү, әлбәттә, бу эштән риза булмый һәм тагы үзенең мәкер пәрәвезләрен үрә башлый. Кырымга тагы урыс гаскәрләре бәреп керә һәм Дәүләт Гәрәйнең 40 меңлек гаскәрен җиңә. Кырым тәхетенә исә урыслар яклы, урыс арасында үскән Шаһин утыртыла. Ул Татар дәүләтен, милли байлыкны теләсә кемгә тарата, бигрәк тә урысларга, грекларга, яһүдиләргә бирә, туздыра башлый. Халык аңа каршы баш күтәрә, әмма урыслар тарафыннан ерткычларча бастырыла. Шуны сәбәп итеп, бөтен Кырымны урыс гаскәре баса, алар 12 мең татарны суялар, күпләр ачлыктан һәм суыктан өшеп үлә. Әмма халыкара җәмәгатьчелекнең кискен таләбе нигезендә, урыс гаскәре Кырымнан чыгып китәргә мәҗбүр була. Шаһин моннан соң Кырымга урысларны тыныч юл белән тутыра башлый, бирегә музыкантлар, сатучылар, табиблар, дигән булып, әллә кемнәрне китереп тутыра. Алар белән бергә, Кырымга хәмер керә, нәкъ Россиядәге кебек кабаклар ачыла. Бу хәлләргә түзә алмаган халык 1781 елда тагы баш күтәрә, Шаһин качарга мәҗбүр була, халык тәхеткә Баһадир ханны утырта. Кырымда тәртип урнаштырырга Россиядән князь Потемкинны җибәрәләр. Кырымны басып алуның соңгы этабы башлана. Екатерина II сәбәпнең дә шәбен таба, имеш, татарларга бәйсез булу хас түгел икән, имеш, алар мөстәкыйль булып, Россиягә эш кенә арттырганнар. Шуңа күрә Кырымны Россиягә кушарга кирәк икән… Һәм 1782—1783 елларда Кырымны Россиягә кушу буенча патша манифесты эшләнә. Ул арада куылган Шаһин, яңадан Кырым тәхетенә менеп утырып, халыкны кыра башлый. Аңа ярдәмгә урыс генераллары киләләр. Алар бу тиранга яңа тәхет — Иран тәхетен тәкъдим итәләр. 1782 елда ул, үз теләге белән, Кырым тәхетеннән баш тарта, һәм Кырымга урыс гаскәрләре бәреп керә. Шуны гына көтеп торган Әби патша 1783 елның 8 февралендә үзенең «О принятии полуострова Крыма, острова Тамана и всей Кубанской стороны под Российскую державу» дип аталган манифестын бастырып чыгара. Шаһин исә, урыс шәһәрләрендә бәрелеп-сугылып йөргәннән соң, Төркиягә китә һәм шунда җәзалап үтерелә. Кырымга исә Россия һәм урыслар хуҗа булып ала… Алар Кырымны оятсызларча талый башлыйлар. Бу хакта галим С.Бахрушин менә нәрсә яза: «Они опустошили страну, вырубили деревья, разломали дома, разрушили святилища и общественные здания туземцев, уничтожали водопроводы, ограбили жителей, надругались над татарским богослужением, выкинули из могил и побросали в навоз тела их предков и обратили их гробницы в корыта для свиней, истребили памятники старины… и установили свое отвратительное крепостное право». (*Бахрушин С.* Основные моменты истории Крымского ханства // История в школе.— 1936.— № 3.) Бу хәлләргә түзә алмыйча, татарлар баш күтәреп карый, әмма аларны бик тиз үтереп бетерәләр. Могҗиза белән исән калган татарлар күпләп Төркиягә китә башлыйлар.

Россия империясе, Кырым белән генә канәгатьләнеп калмыйча, Төркияне басып алырга да әзерләнә. 1787—1791 елларда бу ике ил арасында канлы сугышлар булып ала. Урыслар Кырымны калдырырга җыенмыйлар. Гаҗизлекнең чигенә килеп җиткән татар халкы меңәрләп Төркиягә китә. Бу бөек һиҗрәт 1792 елда башлана, һәм 100 мең тирәсе татар Кырымны ташлап китәргә мәҗбүр була. Аларның барысы да Төркиягә барып җитә алмый, күпләр Кара диңгез суларында батып үлә…

Патша Россиясе Кырымдагы татарларны менә шундый коточкыч газапта яшәргә мәҗбүр иткән, әмма халыкның барыбер тамырын корыта алмаган. Ә менә Россия империясенә алмашка килгән СССР, Совет власте Кырымда татарларның тулысынча тамырын корытырга уйлый. «Сугыш вакытында немецларга ярдәм иттеләр» дигән, үзләре уйлап тапкан мәкерле ялган белән 1944 елның 18 маенда Кырым татарларын илләреннән сөрәләр. Аларга җыенырга нибары 10—15 минут вакыт бирәләр һәм бер кат кием белән, мал вагоннарына төяп, бөтен милләтне сөргенгә озаталар! Бөтен милләтне — яшенкартын, балаларны, хатын-кызларны, сугыштан яраланып кайткан ир-атларны, ак чәчле әбибабайларны, үләргә дип, ач далаларга сөрәләр. Татарлар өйләреннән чыгу белән, аларның йортмалларын урыслар басып ала… Кырымда татарларның мәчетләреннән психбольницалар ясыйлар, хан сарайларын дуңгыз абзарларына әйләндерәләр, мөселман кабер ташларыннан юллар түшиләр… Ул вакытта 200 меңнән артык Кырым татары иленнән сөрелә, шуның 46,5 проценты юлда һәм ач далада беренче елны ук үлеп бетә… Мәетләрне хәтта күмәргә дә рөхсәт бирмиләр — сакчылар аларны вагон ишегеннән атып кына баралар… Казах далаларында, Үзбәкстан чүлләрендә 100 мең татар баласы үлеп кала…

Менә шул татарларның могҗиза белән исән калганнары кырык еллык сөргеннән соң бик зур авырлыклар белән яңадан Кырымга кайтты. Башта Совет хөкүмәте, Мәскәү, аннан биредә яшәүче урыслар татарларны үз туган илләренә кайтартмас өчен барлык явызлыкны да эшләделәр һәм эшләп торалар. Әмма шуңа карамастан татарлар, дәрья булып, Кырымга кайта. Хәзер биредә инде алар 250 мең, Кырымдагы халыкның 12 процентын тәшкил итәләр. Кырым татарларының үзидарә органы —

Милли Мәҗлес эшләп килә, ил белән идарә итәрлек ир-егетләре бар. Татарлар биредә кабат үзләренең мәктәпләрен ачалар, бай архивлары, китапханәләре бар, үз телләрендә газета-журналлары чыга, китаплар бастыралар. Болар барысы да диярлек халык хисабына эшләнә, Кырымда татар булып яшәү өчен, татар булып калу өчен һәр көн, һәр сәгать авыр көрәш бара… Россия һаман Кырымны кабат үзенә кушу турында хыяллана, аның Украина составында калуына ризалаша алмый. Әйе, тарих шаһит — биредә хуҗа булу өчен, Россия татарларның канын күп койды, хәтта илләреннән дә сөреп карады. Әмма барыбер аныңча булмады, Кырымда татар бетмәде, бетмәс тә, иншаллаһ! Әле Кырым татарлары, Аллаһ теләсә, бу изге туфракларның мәңгелек хуҗалары булачак, чөнки алар монда мәңгелектән яшәгән халык, гайрәтле һун татарларының дәвамчылары…

## ТАТАРЛАРНЫҢ КАСЫЙМ ХАНЛЫГЫ

Татарларның Касыйм ханлыгы 1445 елның көзендә Казан ханы Олуг Мөхәммәт урыс патшасы Василий II не җиңеп, әсир иткәннән соң төзелә. Урыс патшасын әсирлектән коткаруның бер шарты булып Ока елгасы тирәсендәге мишәр җирләрен Олуг Мөхәммәтнең улы Касыймга бирү каралган була. Татар әсирлегеннән котылу өчен, Василий II моңа риза була, ул гына да түгел, исән калу өчен ул Казан ханлыгына бик зур күләмдә акча түли (бөтен казнасын биргән, диючеләр дә бар), урыс шәһәрләрендә салым җыярга татар түрәләрен билгеләргә рөхсәт бирә. Касыйм ханлыгы Казан белән Мәскәү арасында буфер дәүләт булып торырга тиеш була.

Касыйм ханлыгы уртача зурлыкта була, җирләре хәзерге Рязань өлкәсенә туры килә, шулай ук мишәрләр яшәгән Түбән Новгород, Мордовия, Пенза тирәләренең дә бер өлеше кергән булырга тиеш. Бу җирләрдә элек-электән, таралып, мишәр халкы яшәгән була. Тарихта бу яклар Мишәр Йорты дип аталган, һәм ул XIV—XV гасырларда мөстәкыйль ил булып яшәгән. Алтын Урданың бер өлкәсе булган XIV гасыр Мухшы олысы һәм XV гасырда барлыкка килгән Касыйм ханлыгы арасында, дәүләт булып, шушы Мишәр Йорты торган. Олуг Мөхәммәтнең улы өчен нәкъ менә шушы мишәр-татар җирләрен таләп итүе бер дә гаҗәп түгел, чөнки бу җирләр борынгыдан татарларныкы булган. Һәм Касыйм, үз якыннары, янычарлары һәм түрәләре белән, әнә шул мишәр-татар җирләренә хан булып килә. Хәзерге Касимов шәһәре ул заманда Хан Кирмән дип аталган. Урысларның борын төбендә Казанга ярдәм өчен торгызылган бу Татар дәүләте, кызганычка каршы, тарих барышында аңа каршы файдаланыла башлый.

Бу хәл беренче тапкыр 1467 елның августында, Казан тәхетенә Ибраһим хан килгәннән соң була. Мәскәү патшасы моның белән ризалашмый һәм Казан тәхетенә үз кешесен — Касыйм ханны куярга уйлый. Ул татар җирләренә кат-кат һөҗүм ясый, ни кызганыч, бу канкойгыч сугышларда урыслар ягыннан казанлыларга каршы инде Касыйм татарлары да катнашырга мәҗбүр булалар. 1469 елда Иван III Казанга хәтле килеп җитә, әмма бу юлы эш тыныч килешү белән бетә. Алга таба, Казан тәхетендә хан алышынган саен, урыс патшалары бу урынга үз кешеләрен — Касыйм ханнарын утыртырга тырышалар һәм кайбер очракларда моңа ирешәләр дә. Шулай итеп, Касыйм ханлыгы урыс патшалары кулында Казанга каршы бер коралга әйләнеп китә.

1518 елда Казан ханы Мөхәммәт Әмин үлгәннән соң, Мәскәү Казан тәхетенә тагы үз кешесен — Шаһ Галине тәкъдим итә. Шаһ Гали Касыйм ханы Шәех Әүлиярның олы улы була, ул 1505 елда туа. 1516 елда Шәех Әүлияр үлгәч, 11 яшьлек Шаһ Гали Касыйм тәхетендә кала. Аның энесе Җан Гали әтисе үлгәндә туып кына кала. 1519 елның мартында Шаһ Гали Мәскәү ярдәме белән беренче тапкыр Казан тәхетенә утыртыла һәм 1521 елга кадәр Казан ханлыгы белән идарә итә. Әмма, Татар иле белән, нигездә, 14 яшьлек үсмер түгел, аңа ияреп килгән урыс илчесе Федор Андреевич Карпов идарә итә. Ул вакытта Казан урыс гаскәриләре белән тулган була, алар татар җирендә ни теләсәләр шуны кылана, талый башлыйлар. Бу хәл татар халкын бик ярсыта, һәм алар Шаһ Галине бәреп төшерергә җыеналар. Казан тәхетенә Кырымнан Сәхип Гәрәйне чакыралар. Сәхип Гәрәй Кырым гаскәре белән Казанга килеп, урысларны һәм 5000 Касыйм татарын кырып сала, Шаһ Гали исә чак Мәскәүгә качып котыла. Касыймда ул вакытта аның энесе Җан Гали идарә иткәнлектән, Шаһ Гали Мәскәүдә урнашып кала һәм яңадан Казанга хан булып кайту җаен көтә башлый.

Мәскәү беркайчан да Казанны басып алу өметен өзми һәм шушы юнәлештә эш итә. 1531 елда, кырымлы Сафа Гәрәй Казан тәхетеннән куылганнан соң, Мәскәү бирегә тагы үз кешесен — Касыйм ханы Җан Галине китертеп утырта. Аның белән ияреп, Казанга тагы урыслар кереп тула, алар арасында Мәскәү илчесе Морозов һәм күп санлы гаскәриләр дә була. Җан Галигә нибары 15 кенә яшь булганлыктан, аңа регентша итеп Гәүһәршад бикә билгеләнә. 1534 елның 25 сентябрендә Җан Гали үтерелә. Казан тәхетенә яңадан Сафа Гәрәй хан кайта. 1546 елны аны тагы тәхеттән төшерәләр, һәм

Казанга Касыймнан тагы Шаһ Гали кайтарыла. Моңа кадәр Шаһ Гали, артык мөстәкыйль кыланганы өчен, өч ел сөргендә дә булып өлгерә, үзен аклау өчен, урыслар белән бергә Казанга каршы берничә сугышта катнаша. Әмма бу юлы ул Казан тәхетендә нибары 4 ай гына утырып кала — Сафа Гәрәй хан кайтып, аны Казаннан куып чыгара. Шаһ Гали тагы Касыймга кайтып егыла.

Өченче тапкыр Шаһ Гали Казан тәхетенә 1551 елның 16 августында утыртыла, аның белән бирегә Касыйм татарлары һәм күп санлы урыслар да ияреп килә. Шаһ Гали Казан тәхетендә 1552 елның мартына кадәр утыра. Бу вакытта аның инде Мәскәүгә кирәге калмаган була, чөнки Явыз Иван, Казан ханлыгын тәмам бетереп, аны урыс дәүләтенә кушарга уйлый һәм татар ханын урыс наместнигы белән алыштырырга ниятли. Шул максат белән 1552 елның февралендә Казанга урыс илчесе А. Ф. Адашев килә һәм Шаһ Галигә шушыларны тәкъдим итә. 1552 елның мартында Шаһ Гали Казан тәхетеннән баш тарта һәм якыннары белән Свияжскига китә. Шушының белән Касыйм ханнарының Казан белән идарә итүләре туктала, аларның инде урыс патшаларына бирелә кирәге калмый, диярга була.

Касыйм татарларының Казан өчен кирәкләре бетсә дә, Мәскәү, аларны үзе алып барган бөтен сугышларда да файдаланып, татарлар исәбенә зур җиңүләргә ирешә. Әйтик, шул ук Шаһ Гали, 1557 елга хәтле Касыймда яшәгәннән соң, гаскәре белән Ливон сугышына җибәрелә. Бирелә ул Мәскәү армиясенең башкомандующие була. Алар монда зур җиңүләргә ирешәләр, Ливонияне яулап алалар, немецларны җиңәләр, Ригага һәм Ревельгә хәтле килеп җитәләр. Бу җиңүнең даны урысларга була, ә вәхшилекләрен татарларга сылтыйлар. Шаһ Галине Мәскәүдә җиңүче итеп кабул итәләр һәм тагы Касыймга җибәрәләр. Бирелә ул 1562 елга хәтле яши һәм тагы сугышка, полякларга каршы җибәрелә. Ул Явыз Иван оештырган башка сугышларда катнашырга да мәҗбүр була. 1565 елда Шаһ Гали, тагы Касыйм шәһәренә кайтып, тәхетенә утыра һәм тиздән үлә.

Шаһ Гали үлгәч, хан итеп Касыйм тәхетенә Саин Булат утыртыла. Ул да шулай ук Мәскәү оештырган бөтен сугышларда катнашырга мәҗбүр була. 1572—1573 елларда ул үзенең касыймлылар гаскәре белән шведларга каршы сугышларда катнаша, Эстония җирләрендә зур җиңүләргә ирешә. Әмма Саин Булат хан тәхетендә озак утырмый, 1573 елның 15 июлендә ул христиан динен кабул итә һәм Симеон исемен ала. Христиан буларак, ул Касыйм ханлыгы белән идарә итәргә хокукын югалта. Әмма Явыз Иван аны Мәскәү һәм Тверь шәһәрләренең бөек князе итеп билгели. Симеон Бек-Булатович 1616 елны гади монах булып үлә. Алтын Урданың соңгы ханы Әхмәт хан оныгы Саин Булат, әнә шулай динен һәм милләтен югалтып, бу якты дөньядан китә. Алга таба бу язмышны чукынган күп татарлар кабатлый…

1577 елда Касыйм ханлыгы тәхетенә Мостафа Гали утыртыла. Явыз Иван бу татарны да сугышларда күп файдалана. Ул елларда Мәскәү Ливония тарафыннан җиңелүләргә дучар була. Иван IV татарлардан торган зур гаскәр туплый, аларны Казан, Әстерхан, Нугай Урдасыннан, Касыймнан җыеп алалар һәм Ливон сугышына җибәрәләр. Гаскәр башына Касыйм ханы Мостафа Гали үзе баса, аның янәшәсендә туганнары Будали һәм Арыслан Гали була. Татарлар, кайда җибәрсәләр дә, урыслар өчен арыслан кебек сугышалар, чөнки җиңелсәләр, аларны Явыз Иванның җәзасы көтеп торганын алар яхшы беләләр. Бу сугышларда меңләгән татар ире мәңгегә ятып кала…

Касыйм ханы Мостафа Галине Төркия белән ике арада илче сыйфатында да йөртәләр. Аның бурычы Мәскәүне төрекләр алдында яхшы итеп күрсәтү була, имеш, Мәскәү мөселманнарны кысмый, әнә борын төбендә татар дәүләте асрап ята, анда мәчетләр эшләп тора. Шуңа күрә Казан-Әстерхан турында буш сүзләрне туктатырга кирәк икән… Мәкерле Мәскәү бу очракта да үз дигәненә ирешә, татарны татарга каршы сәясәттә оста файдалана.

1600 елда Борис Годунов тарафыннан Касыйм тәхетенә Ураз Мөхәммәт утыртыла. Ул арада тарих мәйданында Ялган Дмитрий патша барлыкка килә. Ураз Мөхәммәт һәм Касыйм халкы аның ягына баса һәм сугышка керә. Касыйм татарларының бер өлеше, Казан тирәсенә килеп, хөкүмәт гаскәрләренә каршы баш күтәрәләр, аларга җирле халыклар да кушыла. Бәлки Касыйм һәм Казан татарлары, урысларның чын йөзен аңлап, ялган патшага ияреп булса да, элеккеге ирекләрен, мөстәкыйльлекләрен кире кайтарырга уйлаганнардыр… Әмма моның өчен алар каты җәза ала. 1609 елда урыс патшасы Василий Шуйский гаскәрләре Касыйм шәһәренә һөҗүм итәләр. Татарларның ярсып каршы торуларына карамастан, урыслар шәһәрне ала, бик күп татарларны суя, үтерә, җәзалый.

Бу вакытта Ураз Мөхәммәт ялган патша — Дмитрий II янында була. Әмма урысның ялганы да, чыны да бер төсле — Дмитрий үзенә иң тугрылыклы хезмәт иткән Ураз Мөхәммәтне мәкерле рәвештә үтерә һәм «Касыйм ханы мине үтерергә теләде һәм качты» дигән ялган хәбәр тарата. Татарлар моңа ышанмыйлар, киресенчә, аның татар ханын үтергәнен беләләр һәм, беренче җай чыгу белән, Ялган Дмитрий II не үтереп ташлыйлар. Бу хәлләрдән соң татарларның бер өлеше Кырымга кача, бер өлеше татар җирләре буйлап тарала.

1614 елда Касыйм тәхетенә Алып Арыслан утыртыла (Күчем ханның әсирлеккә төшкән оныгы) һәм 1627 елга хәтле хан булып исәпләнә. Әмма ул да гаскәре белән сугыштан кайтып керми. Урыс патшасы

аны әле шведларга каршы, әле Кырым татарларына каршы сугышларга җибәрә, әле Ливон сугышына китереп тыга. Алып Арыслан үлгәч, Касыйм тәхетенә аның өч яшьлек улы Сәед Борһан утыртыла. Ул кечкенә булганлыктан, ил белән аның энисе — Фатыйма солтанбикә идарә итә. 1653 елда Мәскәү хөкүмәте Сәед Борһан ханны көчләп христиан дине кабул иттерә, ул Василий Арслановичка әйләнә. Чукынган булса да, Мәскәү аны хан иттереп калдыра. Чукынган татар Василий хан булган бу заманда бөтен Касыйм җирләре чиркәүләр һәм моныстырьлар белән тула, халыкны тоташ чукындырулар башлана. Татарлар моңа каршы чыгалар һәм күпләп үтереләләр. Василий хан хатынын, 8 баласын да чукындыра. 1679 елда Касыймның чукынган ханы үлә һәм аның урынына карт энисе — Фатыйма солтан-бикә калдырыла. 1681 елда ул да үлгәч, Касыйм ханлыгы бөтенләе белән бетерелә һәм Мәскәү дәүләтенә кертелә.

## ДӘҮЛӘТЕН ЮГАЛТКАН ТАТАРЛАРНЫҢ ИРЕК ӨЧЕН КӨРӘШЕ

Татар халкы беркайчан да үзенең бәйсезлеген югалту белән килешми һәм, җай чыккан саен, гасырлар дәвамында ирек өчен изге көрәшкә күтәрелә. Казан канга батырылганнан соң, XVI гасыр татарларның тоташ көрәше, ирек өчен сугышлары белән тәмамлана. XVII—XVIII гасырларда да татарлар бик күп тапкыр Мәскәү хакимиятенә, урысларга каршы баш күтәргәннәр һәм патша гаскәрләре тарафыннан явызларча бастырылганнар. Халыкны көчләп чукындырулар, мәчет-мәдрәсәләрен җимертүләр, татарларны асу-кисүләр бу гасырларда бер дә туктап тормаган. Урыс тарихында чын исемен яшереп, «Крестьян сугышлары» дип өйрәнелгән сугышлар — алар барысы да татарларның патшага каршы сугышлары, ярсып баш күтәрүләре. Патшага каршы көрәштә татарлар хөкүмәттән канәгать булмаган урысларның көченнән дә оста файдаланганнар. Бу чорда Россиядә нинди «ялган патша — самозванец» барлыкка килә — татарлар шуның ягына басканнар, ягъни шулар ярдәмендә, Мәскәү патшаларын бәреп төшереп, татар җирләрендә үз идарәләрен урнаштырырга омтылганнар. Татарлар, XVII гасыр башында качкын крестьян Болотниковка ияреп тә, Ялган Дмитрий патша ягында да патша гаскәрләре белән сугышалар, шул гасыр азагында, Степан Разинга ияреп, урыс хакимиятенә каршы яу чабалар, XVIII гасыр башында Булавин дигән казак белән бергә Мәскәү хакимиятенә каршы күтәрелеп карыйлар, 1773—1774 елларда Пугачев явының үзәгендә булалар. 1606—1610 елларда татарлар хәтта яңадан Свияжск (Зөя) каласын да урыслардан тартып алалар, Казанның үзе өчен каты көрәш алып баралар. 1616—1619 елларда Казан, Арзамас, Муром тирәләрендә кабат татарлар баш күтәргән, бу күтәрелешнең үзәгендә Җан Гали исемле татар кешесе торган. Шушы күтәрелешләрнең берсендә, татарлар Казанны яңадан алган, дигән хәбәрләр дә бар. Әмма Мәскәү, бөтен көчен җыеп, бу якларны яңадан басып алган. 1645 елда татарлар Идел буйларында гына түгел, Кама аръягында да зур күтәрелеш оештырганнар. Шул елны алар урыслар төзегән Минзәлә крепостен яндыралар, 1661—1669 елларда кабат Минзәлә, Чишмә, Биләр, Ерыклы һәм башка крепостьларга һөҗүм итәләр. Урысларны Урал тауларына җибәрмәс өчен, татарлар барысын да эшли, шушы юлда меңәрләгән кеше һәлак була.

1670—1671 елны Россиядә дөрләгән Степан Разин восстаниесенең дә үзәгендә татарлар була. Бу хакта бик күп тарихи документлар, шул исәптән хөкүмәт гаскәрләре башлыгы Ю. Барятинскийның патшага рапортлары да сөйли. Татарлар инде 1668 елда ук Пенза, Әстерхан, Кадом (Касыйм ханлыгы), Урал тауларында баш күтәргән булалар. Дон буйларында туып үскән Степан Разинны Мәскәүгә каршы боручы, Казанны алырга өндәүче кеше — Касыйм татары Хәсән Карачурин була. Ул Степан Разинга күп санлы татарлар, мордвалар гаскәре белән 1670 елның азагында Сембер шәһәрендә килеп кушыла һәм шунда ук бу яуның оештыручысы һәм идеологына әйләнә. Ул, татар халкын Мәскәүгә каршы яуга күтәрелергә чакырып, дистәләгән хатлар язган, халык арасында аңлату эшләре алып барган, урысларга каршы сугышларда башлап йөргән. 1670 елның азагында аның кул астында инде 15 меңлек баш күтәрүчеләр гаскәре була, аңа Самара, Сарытау, Саранск, Пенза, Алатырь, Курмыш татарлары керә, бу хакта тарихи документлар саклана. 1670 елның 8 декабрендә Хәсән Карачуринның инде 20 меңлек татар гаскәре Юрий Долгорукий гаскәре белән бәрелешә. Соңыннан Юрий Долгорукий патшага мактанып яза: «Без 68 әләм, 20 туп кулга төшердек, качучыларны 15 чакрым куа бардык, күпләрне кырдык, восстание җитәкчесе Асан Айбулатов сын Карачурин мордва авылына качты»,— дип яза. Аннан Хәсән Карачуринны тотулары, Юрий Долгорукийның бу батыр татар кешесен дүрткә чабып өзәргә кушуы турында хәбәр ителә. Шул ук вакытта патша бу хәбәргә ышанмый һәм әле 1693 елда да Хәсән Карачуринны эзләүне дәвам итәләр. Степан Разин исә үзеннән газаплап сорау алган вакытта: «Мине Казанга барырга Хәсән чакырды, әгәр баш күтәрүчеләр һөҗүм итеп бара башласалар, Казан татарлары тик ятмаслар, дип әйтте»,— ди. Димәк, Хәсән Карачурин, максатчан рәвештә, гаскәр туплап, Степан Разин восстаниесеннән файдаланып, Казан шәһәрен алырга дип килгән. Бу көннәрдә Казан,

чыннан да, баш күтәрүчеләргә каршы көрәшнең үзәгенә әйләнә, аны сакларга Мәскәүнең иң көчле гаскәриләре, шул исәптән князь Урусов һәм Барятинскийлар да килеп төшә. Алар Мәскәүдән — Казанга, Казаннан Сембергә хәтле юлны һәр көн авыр сугышлар белән генә уза ала. 1670 елның 3 октябрендә Степан Разин җиңелеп, Донга кайтып киткәч, урыс генералларына каршы сугыш алып бару тулысы белән Хәсән Карачурин өстендә кала. Хәсән Карачурин, Казанны ала алмаса да, халыкны Мәскәүгә, урыс басып алучыларына каршы көрәшкә рухландырып калдыра.

XVII гасыр азагында яуларның башында да татарлар тора. Шулар арасында дин әһеле Сәед Садурны әйтеп китәргә кирәк. Ул 1680 елларда Идел-Урал татарларына өндәмәләр белән чыга, халыкны урысларга буйсынмаска, аларга каршы сугышка күтәрелергә өнди. Идел-Урал татарлары 1681 елда патша хөкүмәте бөтенләй көтмәгәндә баш күтәрәләр. Алар кыска вакыт эчендә хәзерге Удмуртия һәм Татарстанга кергән Кызыл Яр, Пьяный Бор, Каракүл, Ловашное авылларын алалар, Пермь җирләрендә булган Кунгур шәһәренә һөҗүм итәләр, Самарага барып чыгалар, Уфаны камап алалар. 1682 елның маенда баш күтәргән татарлар инде бөтен Идел —Урал арасына җәелеп өлгерәләр, Казанга юл тотарга җыеналар. Баш күтәргән һәр татар кешесенең төп хыялы, максаты Казанга бару, Казанны алу икәнен онытмыйк, чөнки бөтен татар яулары да Казан ханлыгын торгызу, дәүләт бәйсезлеген кайтару өчен бара. 1682 елның июнендә Сәед мулла гаскәре дә Ык елгасына хәтле килеп җитә. Биредә патша гаскәрләре белән көчле сугышлар була, ике як та зур югалтулар кичерә. Патша хакимияте татарларга карата кайбер ташламаларга барырга мәҗбүр була, көчләп чукындыру бераз кими төшә. Халыкның бер өлеше, бу алдауларга ышанып, коралын куйса да, күпчелек ирек өчен көрәшен дәвам итә. Восстание Кама буйларыннан нугай далаларына хәтле җәелә, анда 50—60 меңгә якын татар катнаша. Сәед мулланың илчеләре, ярдәм сорап, хәтта Кырым ханына хәтле барып җитәләр. Әмма аларга Казанны алырга насыйп булмый, патша хакимияте, кайда көч кулланып, кайда ташламаларга барып, Сәед мулланың явын бастыра.

Урысларга каршы татар яулары XVIII гасырда яңа бер көч белән кабынып китә, яу башында Сәгыйть Җәгъфәр һәм Теләкәй батыр тора. 1705—1711 елгы татар яуларының башында Теләкәй улы Күчем батыр, 1735—1740 елгы татар күтәрелешләрендә Күчем улы Акай батыр һәм Акай улы Габдулла булалар. Татарлар бөтен нәселләре, авыллары, ил-җирләре белән урыс басып алучыларына каршы аяусыз көрәшәләр. Алар татар җирләренең һәр карышы өчен урыс гаскәрләре, алпавытлары, җир биләүчеләре, завод тотучылары, кыскасы, урыс талаучылары белән тиңсез көрәш алып баралар. Идел — Урал арасы ике гасыр дәвамында татар каһарманнарының каны белән сугарыла, татарларның Ватан сугышы Казаннан Уралгача җәелә.

XVIII гасыр тоташы белән татар восстаниеләреннән тора. 1708 елда татарлар зур көчкә әйләнеп китәләр, Самара, Камышлы һәм Сергеевск шәһәрләрен урыслар кулыннан тартып алалар, Саратовка һөҗүм итәләр. Солтан Морат исемле татар каһарманы, гаскәр туплап, хәтта Төньяк Кавказга хәтле барып җитә, 1708 елда Терек шәһәрен камап ала. Бу Морат мулланың Төркиягә, Казан өчен хан сорарга барышы була. Мондый җитди эшкә ул, әлбәттә, Идел-Урал татарлары белән киңәшеп, алар фатихасын алып юлга чыккан. Әмма нугай далаларыннан Кавказга хәтле килеп җитә алган Солтан Моратка Төркиягә барып җитү насыйп булмый — аяусыз сугышларда әсир төшкән каһарман татар Солтан Моратны урыслар Казанга алып кайтып асалар. Әмма аларның бу күргәзмә вәхшилеге татарларны туктата алмый, киресенчә, ярсуларын гына арттыра. 1707 елның ахырында — 1708 елның башында Идел-Урал татарлары, Казанны алып, ханлыкны яңадан торгызырга дигән ният белән зур яуга чыгалар. Нәкъ шушы елларда татарлар, урысларның ныгытылган линияләрен җимереп ташлап, Яңа Чишмә, Зәй хәрби крепостьларын алып, Кама суын кичкәннәр һәм Казанга ыргылганнар. Алар Казан — Чаллы юлындагы бөтен җирләрне урыслардан азат итеп барганнар, бу урыннарда патша администрациясе бетерелгән, халык салым түләүдән азат ителгән. Татарлар хәтта үзләренә хан сайлап куюны да планлаштырган булганнар, әмма үзара килешеп бетмәгәннәр. Тарихчыларның язуынча, 40 меңлек татар гаскәре, Чаллы юлы белән килеп, Казанга 40—50 чакрым ераклыкта туктап калган. Кайбер галимнәрнең язуынча, алар Казанны алган да булырга тиеш. Әмма ни генә булса да, моны урыс тарихчылары бик нык яшерәләр, чөнки алар бөтендөньяга, бигрәк тә ислам илләренә, Россия империясендә татарлар яхшы яши, дип ышандырмакчы булалар. Коты алынган Петр патша үзенең бөтен хәрби көчен яңадан Казанга, Идел-Кама буйларына ташлый. Баштанаяк чит ил кораллары белән коралланган урыслар баш күтәргән татарлар өстенә ябырылалар. Кайда сугышып һәм юк итеп, кайда куркытып, кайда ялган вәгъдәләр белән, алар татарларны тагы Агыйделнең аръягына чигенергә мәҗбүр иткәннәр. 1707—1708 елларда Казанны кире кайтару өчен башланган татар явы да аларның җиңелүе белән бетә. Әмма бу яу татарлар арасында яңадан илле, ирекле булырга өмет уята һәм тагы йөз елга якын патша хакимиятенә каршы көрәшерлек көч-дәрт бирә.

## 1600—1750 елларда Идел — Урал арасында милли бәйсезлек өчен көрәшүче татар каһарманнары

***Җан Гали Шөгеров, Батырша Җангалиев, Хәсән Карачурин, Сәед Садур, Иштирәк** абыз, **Исмәгыйль Исяшев, Ишеләй Ертышев, Тимай Ишеляев, Санбай Елмасов, Досай Булаев, Чурабай Чуракчин, Сәгыйть Җәгъфәр, Теләкәй батыр,** аның улы **Күчем батыр,** аның улы **Акай батыр,** аның улы **Габдулла, Алдар Исәкәев, Килмәк Нурышев, Кара Сакал, Солтан Морат мулла, Якуб Колмәмәтов, Исмәгыйль** абыз, **Үрмәт, Азамат, Имам батыр, Дими Ишкеев, Уразай, Сәет батыр, Габдрахман Туйкин, Гомәр Туктаров, Йосыф Арыков, Җиянбай, Төлкечура Алдагулов, Солтанморат Дусиев, Исәнгол Мәмбәтов, Сабан Сәфәрколов, Сәгыйть Корычев, Мөслим Сарманаев, Тукай Исмәкәев, Габдулла Мәмәков, Колмәмәт Корычев, Габдрахман Манычев, Сәетбай Алкалин, Рысай Игембәтов, Габдулла Акаев, Күчәп Солтанколов, Бәпәнәй Торыпбирдин…***

Һәм бик күп билгесез каһарманнар… Аларның кайсылары яу кырында һәлак булган, кайсыларын патша гаскәрләре тотып алып җәзалаган, кайсыларының телләрен, борыннарын кисеп алганнар, очлы казыкларга утыртканнар, кабыргаларыннан асып үтергәннәр… Күп татар каһарманнарын мәңгелек сөргеннәргә сөргәннәр, алар шунда үлеп калганнар… Ил өчен изге көрәштә һәлак булган, шәһит киткән бу мөселман-татарларның урыннары җәннәттә булсын. Амин.

## БАҺАДИРШАҺ

Батырша — Баһадиршаһ…

Унсигезенче гасыр уртасында татар халкын урыс илбасарларына каршы җиһадка чакырган, мөселманнарны дин һәм ирек өчен изге көрәшкә күтәргән һәм патша зинданында кяферләр белән бәрелештә шәһит киткән татар каһарманы...

Татар тарихына Батырша исеме белән кереп калган Баһадиршаһ (Габдулла Галиев) 1710 елны (15 нче дип тә әйтүчеләр бар) Казан губернасының Уфа өязендә, Карышбаш авылында дөньяга килә. Бу чорлар — Россия империясендә мөселман-татарларга каршы котырынган иң кара чукындыру һәм җәза еллары… Явыз Иван басып алганнан бирле, татарларны көчләп чукындырулар, мәчет-мәдрәсәләрен җимерүләр, хатын-кызларны көчләп монастырьларга ябулар һәм урысларга кияүгә бирүләр, татарларның җир-мөлкәтләрен талап алулар дәвам итә. Татар халкы иманын бирмәс өчен үлемгә дә бара. Кара урманнарга, тау араларына, сазлыкларга куып кертелгән татарлар, күз карасы кебек, Коръәнне, изге гыйлемне саклыйлар. Дәүләтен югалткан татар халкы дин тирәсендә берләшеп исән калырга тырыша. Әмма патша Россиясе татар халкын тынгылыкта калдырмый, аның дәүләтенә генә түгел, иманына да хуҗа булу өчен көрәшә. 1742 елның 19 ноябрендә татарларның барлык мәчетләрен җимерергә, яңаларын салдырмаска, дигән патша Указы чыгарыла. Шушы вәхши фәрман нигезендә генә дә Казан губернасында 536 мәчетнең 418 е җимертелә һәм яндырыла, Себер губернасында һәм Тоболда, Тарада 133 мәчеттән — 98 е, Әстерхан губернасында 40 мәчетнең 25 е юк ителә, Казан һәм Ырынбур губерналарында 270 мең кеше көчләп чукындырыла. Идел — Урал арасындагы татар халкы бу көчләүләргә баш күтәрүләр, фетнәләр, чуалышлар белән җавап бирә.

Тарихка теркәлеп калган бер генә мисал: урыс генералы Урусов кул астындагы җәлладлар 1740 елның 25 августында 6 мең татарны, Ырынбур тирәсендәге үзәнлеккә куып китереп, халык алдында җәзалыйлар. Биредә 85 татар дарга асыла, 21 татарның башы чабыла, 11 кешене кабыргасыннан асып үтерәләр, 5 татарны очлы казыкка арты белән утырталар… Шул ук көнне Сакмар крепостенда тагы 170 татар җәзалап үтерелә, 301 татарның телләре, колаклары, борыннары кисеп алына. Үтерелгән татар ир-атларының хатыннары, балалары урысларга кол итеп өләшенә. 1740 елның июнь аеннан сентябрь аена кадәр вакыт эчендә Уфа өязендә 725 татар авылы яндырыла, 5298 ат, 5736 сыер талап алына. Генерал Урусов белән янәшәдә урыс генералы Соймонов та татарларны җәзалауда Явыз Иваннан да ким кыланмый — аның фәрманы белән 3665 татарны яу кырында үтерәләр, 404 татарны җәзалап үтерәләр, 802 татар сөргенгә сөрелә, 3026 татар хатын-кызы һәм балалары урысларга кол итеп таратыла. Әле бу —теркәлеп калган бер тарихи факт кына, ә андый хәлләр Идел —Урал арасында йөзләгән, меңләгән булган бит, һәр авыл, һәр татар бу фаҗигаләрне күргән! Батырша менә шушы канлы чорда яши һәм үз халкының бәхете өчен кяферләргә каршы сугышырга кирәк дигән кискен фикергә килә.

Батырша хәзрәт озак еллар буе муллалыкка укыган бик гыйлем дин иясе була. Ул, туган теле татар теленнән кала, гарәп-фарсы телләрен, төрек телен дә яхшы белә, Коръәнне дөрес аңлый һәм халыкка да дөрес итеп аңлата. Иң мөһиме, Батырша хәзрәт халкының бу газаплы, хокуксыз тормышында төп

гаепле кешеләрнең басып алучы кяферләр икәнлеген яхшы аңлый, аларны Татар иленнән куып чыгармый торып, татар халкының бәхетле булмаячагына төшенә. Ул, Идел — Урал арасында яшәүче татарларны, мөселманнарны дин өчен изге көрәшкә — җиһадка өндәп, халыкка мөрәҗәгать белән чыга. Дөрес, бу җирләрдә элегрәк тә дистәләгән күтәрелешләр, фетнәләр булып торган, әмма урыс басып алучыларына каршы дин исеменнән зурлап җиһад игълан итү ишетелмәгән. 1755 елның язында Батырша хәзрәт мөселман-татар халкына түбәндәге мөрәҗәгать белән чыга: «Мин, Абдулла Мәзгытдин, бар вә бер Алланың һәм пәйгамбәребезнең мәрхәмәтенә өмет итеп вә аның сәхабәләренең юлын дәвам итеп, сезне, Рәсәй мәмләкәтендә яшәүчеләрне вә хыянәтче йомышлы урыслар тарафыннан һәр төрле мәкерләр вә фетнәләр күреп кимсетелгән, чиктән тыш алҗыган хак диндәге бәндәләрне болай дип үгетлим. Хак диннәреннән язган кяферләр белән килешүдә булмаска, залимнәргә кала вә кальгалар салмаска, йомышлы урысларны авылдан авылга, каладан калага олаулар белән озатып йөрмәскә, ясак түләмәскә вә атларына азык бирмәскә. Янә дә килеп, кяферләрнең үзебезгә кул күтәрүләренә юл куймаска, халкыбызны төрле җәберләрдән, салым-алымнан сакларга вә хак динебезне мәсхәрәләүгә юл куймаска. Сез, бер Аллага ихластан инанучы чын дусларым минем, тырышыгыз, тырышыгыз, тырышыгыз! Чирү атлары вә корал хәзерләгез, кылыч-сөңге, җәя-ук вә шуңа охшаш кирәк-яракны мөмкинлегегез барынча әзерләгез һәм Алла боерыгына буйсыныгыз, Хак Тәгаләдән мәдәт сорап, аңа өмет вә ышаныч баглап һәм дә аның катына пәйгамбәребез Мөхәммәт рәсүлуллаһны юллап, теге кяферләрне кыйрата башлыйбыз. Ул зобаниларны җиребездән куып, йорт-илебездә мәчет-мәдрәсәләр гыймарәт кылырбыз, хак динебезне ныгытуны кайгыртырбыз... Сез, бер Аллага табынучы яшьләр һәм картлар, җайдаклар һәм җәяүлеләр, тизрәк тупланыгыз һәм озын-озакка сузмыйча кузгалыгыз! Хак Тәгалә пәйгамбәребез аша җиткергәнчә, җаныгызны вә йорт-җирегезне аямагыз. Ул кяферләрдән куркып калмагыз, бер Аллага өмет баглагыз! Аның кодрәте илә явызларны тар-мар итәрбез. Сез, исламны яклаучылар, без хак диндәгеләр аз, кяферләр күп, дип, шикләнеп-шөһбәләнеп калмагыз тагын. Аллаһы Тәгалә кимсетелгәннәрне яклар. Аның рәхмәте белән хак динебез юлында күп санлы дошманны да җиңәрбез. Аллаһ кодрәтле ул, аның мәрхәмәте белән саф диндәге егерме кеше ике йөз кяферне юк итәргә сәләтле. Сафларында бердәмлек һәм килешү булгач, пәйгамбәребез Мөхәммәт сәхабәләре уникe меңле яуны да кырып салганнар бит… Хак Тәгалә һәм аның безгә җибәргән пәйгамбәре Мөхәммәт тә кяферләрне юк итәргә кушалар вә барлык галим-голәмә шул киңәштә торалар… Шушы 1168 (1755 ел.— *Ф. Б.*) елның күк ут вакытында, ягъни чиллә аеның берендә, ураза бәйрәменнән соң кузгалырбыз дип торам. Пәйгамбәребез юлына тугры булып, Хак Тәгалә боерыгын үтәп, шул көнне кяферләрне кыйрата башлыйк».

Батырша хәзрәт шушы ялкынлы мөрәҗәгатен бөтен Идел — Урал арасына, Ырынбур далаларына, Пермь, Чиләбе тирәләренә тарата, үзе дә ул җирләрне аяклары белән йөреп чыга. Халык бөтен җирдә урысларга каршы яуга, баш күтәрергә хәзерләнә. Әмма патша түрәләре дә тик ятмый, алар бу хатны кулга төшерәләр һәм яуга әзерләнә башлыйлар. Ул арада Уралтауда яшәүче бөрҗән кабиләләре, җиһадның билгеләнгән вакытын көтмичә, урыс түрәләре белән бәрелешкә керәләр һәм берничә кешене үтереп ташлыйлар. Аларга каршы һәм, гомумән, яуга әзерләнгән мөселман-татарларга каршы патша армиясе кузгала, Идел-Урал арасына гаскәр арты гаскәр җибәрелә. 1755 елның май, июнь, июль, август айларында Идел-Уралда яшәүче татарлар яуга күтәрелә, әмма патша гаскәре тарафыннан рәхимсез бастырылалар. Урал тауларында яшәүче бөрҗән кабиләләренең, нигездә, икътисади таләпләр генә куйганлыгы ачыклана, ягъни алар дин өчен түгел, тозны бушка алу өчен яуга күтәрелгән булып чыгалар. Дин, ирек дип яуга чыккан татарларга каршы патшага хезмәт иткән башкорт һәм мишәр старосталарын җибәрәләр, ягъни Казан ханлыгы чорындагы кебек, татарларга каршы татарларны, башка төрки халыкларны куялар. Шулай итеп, Батырша хәзрәт күтәргән изге яу, башланып китмәс борын, рәхимсез бастырыла. Аның үзен исә бер елдан соң, 1556 елның 6 августында тотып алып, Уфа, Ырынбур, Самара, Арзамас, Муром, Владимир төрмәләре аша көчле сак астында Мәскәүгә китерәләр. Заманында каһарман татарлар җир тетрәтеп үткән данлы юлны Батырша хәзрәт аяк-кулларына богау кигән килеш уза… Аннан аны Санкт-Петербургка китерәләр. Биредә ул бер ел хөкем көтеп ята. Татар халкын урысларга каршы көрәшкә чакырган Батырша хәзрәткә карата патша хөкүмәтенең карары кискен була — аны мәңгелеккә Шлиссельбург төрмәсенә ябалар, борынын кисеп алалар, камчы белән яралар. Утрау уртасындагы таш төрмәдә аяк-куллары богаулы, теле өзелгән хәлдә Батырша хәзрәт 1762 елның 24 июленә кадәр утыра. Шул көнне ул качарга ниятли, юлына каршы чыккан дүрт урыс каравылчысын тоткын татар балта белән чабып өзә, шул вакытта үзе дә, йөрәге туктап, җиргә ава…

Батырша хәзрәтнең гаиләсе дә зур фаҗигаләр кичерә. Аның хатыны Зөлхәбирәне ике кызы белән Санкт-Петербургка китерәләр, Таҗетдин исемле уллары юлда үлеп кала. Зөлхәбирәне урыс башкаласында чукындыралар, Мария Александровна дигән исем бирәләр һәм мәңгелеккә Девичий монастырена ябалар. Кызлары Зөләйханы, чукындырып, Наталья исемен бирәләр, Зәйнәптән Вера

ясыйлар һәм шул ук монастырьга ябып куялар. Батырша хәзрәтнең шәкертләре һәм тарафдарлары да шундый ук аянычлы язмышка дучар булалар.

Тарихта Батырша хәзрәтнең патшага язган хаты билгеле. Биредә ул җирле хакимиятнең явызлыгы, татар халкының ни дәрәҗәдә газап чигүе, көчләп чукындыруларның хаксызлыгы турында бик җентекләп хәбәр итә. Батырша хәзрәт шулай ук вөҗдан иреге, халыкларның тигез хокукы, диннәргә тигез караш турында да сүз күтәрә. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: Батырша восстаниесе, аның татар халкын җиһадка өндәп язган мөрәҗәгате һәм патшага хаты Россия хөкүмәтен нык куркуга сала. Алар Идел — Урал арасында яшәүче халыкларга карата басымнарын, явызлыкларын киметә төшәргә мәҗбүр булалар. Урыс булмаган халыкларны көчләп чукындыру бераз туктап тора, яңадан мәчетләр салырга рөхсәт ителә, чукынганнар өчен мөселман татарларның армиягә баруы туктатыла, чукынмаган өчен татарларны авылларыннан кумый башлыйлар. Уралтауда яшәүче бөрҗән кабиләләре исә үзләре таләп иткән икътисади ташламаларга да ия булалар —тозны тагы бушка ала башлыйлар һәм вотчина җирләренә яңадан үзләре хуҗа булалар… Патша хөкүмәте, вакытлыча булса да, татар бугазыннан үзенең тимер келәшчәләрен ычкындырып тора… Инде үлем чигенә килеп җиткән татар халкы бераз иркен сулыш ала, тагы мәчет-мәдрәсәләрен сала башлый, гыйлем ала, тормыш итәргә тотына… Милләт шушы рәвешле яңадан яшәп китсен өчен, Батырша хәзрәт һәм аның тарафдарлары дин юлында башларын салалар… Урыннары җәннәттә булсын бу каһарман татарларның. Амин.

## ТАТАРЛАРНЫҢ ПУГАЧЕВ ЯВЫНДА КАТНАШУЛАРЫ ҺӘМ КАЗАННЫ АЛУЛАРЫ

Батырша хәзрәтнең явыннан соң патша хөкүмәте куркып калып бераз ташламаларга барса да, тора-бара татарларның хәле тагы кыенлаша, түзеп тора алмас хәлгә җитә. Бер яктан, аларның көчләп чукындыру белән җаннарын таласалар, икенче яктан, коточкыч салымнар, 25 еллык солдат хезмәтләре, җирсезлек, лашманлык, юк өчен дә мәңгелек каторгага җибәрелүләр татарларның бәгыренә тия. Җитмәсә, алар гомер-гомергә төпләнеп яши торган Урал тауларына, Урал аръягына урыслар заводлар китереп сала башлыйлар, татарларны тимер, файдалы казылмалар чыга торган җирләрдән куалар. Шулай итеп, Кыштымда, Каслида, Белоретта тимер кою заводлары барлыкка килә, татарларның җәннәттәй җирләре, әкренләп, чүп базына әйләнә башлый. Аның өстенә, Идел — Урал арасын урыс гаскәрләре басып китә, алар тыныч халыкка тын алырга да ирек бирмиләр.

Менә шундый шартларда Җаек буйларында, Ырынбур далаларында үзен Петр III патша дип игълан иткән Емельян Пугачев пәйда була. Ул үз тирәсенә хөкүмәттән канәгать булмаган Җаек казакларын (аларның күпчелеге нугайбәк керәшеннәре, ягъни татарлар була) һәм Идел-Урал татарларын туплый. Алар 1773—1774 елларда бөтен Россияне дер селкеткән зур көчкә әйләнәләр, Ырынбур, Богырыслан, Бозаулык, Уфа, Урал буйлары, Троицк, Магнитка, Җаек, Чиләбе, Пермь тирәләре, Ижау, Воткинск, Әгерже, Зәй, Алабуга, Мамадыш, Арча, Казан, Цивильск, Курмыш, Алатырь, Саранск, Пенза, Петровск, Саратов Камышлы, Царицын һәм башка бик күп шәһәр һәм авыллар өчен сугышлар алып баралар, күбесен кулга да төшерәләр. Саналган шәһәрләрдән күренгәнчә, болар барысы да — татар җирләрендә урнашкан, элек-электән татар калалары булган урыннар. Болар барысы да — Алтын Урда һәм Казан ханлыгы җирләре. Пугачевка бу борынгы татар җирләре нигә кирәк булган соң? Эш шунда: бу җирләр Пугачевка түгел, аның гаскәрендә үзәк көчне тәшкил иткән татарларга кирәк булган. Алар, Пугачевны Мәскәүдә патша итеп утыртырга ышандырып, аның ярдәмендә элеккеге татар җирләрен әкрен генә үз кулларына кайтарырга омтылганнар, Идел белән Урал арасында яңадан Казан ханлыгын торгызырга хыялланганнар. Шуңа күрә аларның төп ыргылган урыннары да Казан булган. Югыйсә алар Урал аръягыннан Себергә качарга да яки башка юл белән Мәскәүгә һөҗүм итәргә дә мөмкиннәр иде. Яки үзләре хуҗа булып алган урыннарда озакка тукталып калып, шунда төпләнергә дә мөмкиннәр иде. Юк, Пугачев һәм аны чорнап алган татар явы туп-туры Казанга килгән, Казанга кайткан, Казанны алган! Бер көнгә булса да, татарлар яңадан үз башкалаларын кире кайтарганнар…

Пугачев гаскәре һәм аның тарафдарлары вакыты-вакыты һәм урыны-урыны белән 200 меңгә хәтле җиткән һәм шуның 150 меңе татарлар булган. 1773 елның көзендә беренче булып Пугачевка «ышанучылар» һәм аңа 500 атлы сугышчы бирүчеләр дә Ырынбур өлкәсенең Татар Каргалысы авылы татарлары булган. Алар бөтен татар дөньясына аның «чын патша» булуы, аңа ярдәм итәргә кирәклеге турында хәбәр бирәләр. Әлбәттә, татарлар Пугачевның кем булуын беләләр, әмма хөкүмәт гаскәре белән сугышкан, урысларның заводларын, хәрби крепостьларын җимергән бу кеше аларның уй-теләкләренә туры килә. Татарлар үзләре дә ничә гасырлар буе шушы турыда хыялландылар бит, бу җирләрдән урыс гаскәрләрен куу, аларның завод-фабрикаларын салдыртмау өчен көрәштеләр. Хәзер исә менә шул көрәш башында үзен патша дип атаучы Дон казагы тора. Һәм татарлар, бөтен авыллары,

ил-җирләре белән кубарылып, аның белән яуга кузгалалар, берәм-берәм татар җирләрен патша әсирлегеннән коткаралар. Алар үткән җирләрдә татарлар авыллары-авыллары белән бу яуга кушылалар, халык гаскәренә ат, ризык, башка кирәк-яраклар бирәләр. Хәзерге Татарстан территориясендә генә дә Пугачевның татарлардан торган 70 отряды булганлыгы билгеле.

Әлбәттә, хөкүмәт гаскәрләре бу татар явы белән пычакка-пычак килеп сугышалар. Яңа татар явыннан тәмам коты алынган Екатерина II аларга каршы үзенең иң көчле генералларын, иң зур армиясен җибәрә, ул үзе әйткәнчә, «Бу хәтта күрше дәүләтләргә дә куркыныч салырлык» көчле гаскәр була. Алар арасында урыс генераллары Кар, Бибиков, Щербатов, Голицын, Мансуров, Деколонг, Ларионов, Фрейман, Миллер, подполковник Михельсон һәм башкалар була. Әмма хөкүмәт гаскәре Уфа-Ырынбур тирәсендә генә Пугачевка каршы тора ала, Каманы кичеп, хәзерге Удмуртия, Татарстан җирләренә килеп кергәч, татар явын беркем җиңә алмый. Урыс генералларына каршы татар яугирләре, полковник һәм атаманнар Канзафар Усаев, Бәхтияр Канкаев, Мәсәгуть Гомәров, Габделфаикъ Усманов, Габделҗәлил Сөләйманов, Муса Галиев, Идеркәй Мәхмүтов, Садыйк Сәгыйтов, Габделкәрим Рахманкулов, Аит Уразмәтов, Исхак Әхмәтов һәм йөзләгән, меңләгән татар каһарманнары сугыша… Пугачевның фәрман һәм әмерләре дә татарлар тарафыннан татарча языла һәм халык арасында таратыла.

Пугачев гаскәре, ягъни татар явы, хәзерге Татарстан территориясенә 1774 елның 29 июнь көнне Әгерҗе аша килеп керә. Халык аларны, зурлап, аш-су белән каршы ала. Аннан татар явы Тирсә, Сарсак-Омга, Аккүз, Сукман, Алнаш, Камай, Бондюг авыллары аша Алабугага килеп чыга. Аларга авыл-авыл татарлар кушыла. Алабугадан Пугачев явы Мамадышка, Мамадыштан Арчага юнәлә, татарлар кайда да үз тәртипләрен урнаштыралар, гаскәргә яңа кешеләр туплыйлар. Бигрәк тә Казан арты авыллары — Саба, Теләче, Арча, Питрәч, Балык Бистәсе тирәләре бу татар явына авыл саен 50 шәр кеше бирәләр. Алар барысы да зур дәрт белән «Казанны алырга!» дип баралар. Казанны алгач, яңадан татар тормышы, татар тәртибе кайтасына, дәүләтле буласыларына чын күңелдән ышаналар. Һәм 1774 елның 11 июль көнне Пугачев җитәкчелегендәге 25 меңлек татар явы Казан капкасы төбенә килеп туктый.

12 июль көнне иртәнге сәгать 6 да Казанга һөҗүм башлана. Татарлар һәм Җаек казаклары, дүрт төркемгә бүленеп, сугыша-сугыша, шәһәргә бәреп керәләр. Хөкүмәт гаскәрләре аларга ярсып каршы торганнар, әмма тупларын, коралларын ташлап, әкренләп чигенергә, качарга мәҗбүр булганнар һәм Кремльгә кереп бикләнгәннәр. Кремльдән кала, бөтен Казан татарлар кулына күчкән. Татарлар тиз генә Кремльне дә чорнап алган, Кремль эчендәгеләр аларны ут яңгыры белән каршылаган. Шул чакта һич көтелмәгән нәрсә була: шәһәр 12 җирдән дөрләп яна башлый. Пугачев бу ут-янгын арасында Кремльне штурмлавын туктатып торырга мәҗбүр була, эшен ахырына кадәр китереп җиткерә алмый, һәм бу көтелмәгән тукталыш соңыннан барысын да хәл итә. Кем төрткән бу утны шәһәргә, Казан инде болай да татарлар кулында булгач? Кайбер тарихчылар утны татарлар үч алу өчен төрткән дип баралар, әмма без моның белән килешеп бетмәс идек. Татарларның, шул исәптән Пугачевның да төп максаты — Казанны алу иде, һәм алар аны алдылар. Ут төртеп, шәһәрне юкка чыгару аларның планнарына керми. Татарларның бирегә Казан ханлыгын торгызырга дип килүләрен дә онытмаска кирәк. Безнең уебызча, утны шәһәргә Мәскәү яклы урыслар һәм гаскәриләр төрткән булырга тиеш, чөнки алар, гадәтенчә, чигенгән чакта бөтен нәрсәне җимереп, юк итеп китәләр. Бу очрак та нәкъ шуңа охшаган. Урысларга вакыт сузу да бик мөһим була, чөнки алар үзләренә ярдәмгә хөкүмәт гаскәрләренең барыбер килеп җитәселәрен яхшы беләләр.

Һәм бу нәкъ шулай булып чыга да: Уфада калган Михельсон гаскәренең Вятка аша чыгып, Казанга якынлашып килүе турында хәбәр килә. Пугачев, дөрләп янган Казанны калдырып, Арча кырына хөкүмәт гаскәрләре белән сугышырга чыга. 12 июль көнне алар кара төнгә хәтле бугазга-бугаз килеп сугышалар, әле бер як, әле икенчесе җиңә. Икенче көнне Михельсон исә сугышып тормый, Казан Кремленә кереп качкан генерал һәм губернатор, хөкүмәт гаскәрләре янына ашыга. Пугачев аның юлын кисеп өлгерә алмый, бу ике көч, бергә кушылып, татарлар өстенә ыргыла. Пугачев чигенеп торырга һәм якын-тирә татар авылларыннан кеше җыярга була. Казан өчен канлы сугыш барганын ишеткән татарлар йөзәрләп-йөзәрләп бирегә агыла башлыйлар. Һәркем бу сугышның милләт өчен хәлиткеч булуын яхшы аңлый. 15 июль көнне Казан тирәсендә татар явында инде 15 меңләп кеше була. Казан өчен канлы сугыш башлана. Татарлар Казан өчен юлбарысларча сугышалар, бу хәл хәтта патша генералларын да нык гаҗәпләндерә. Алар татарларның үз илләре, үз җирләре, үз газиз шәһәрләре өчен сугышуларын аңлап бетмиләр, моңа ялган «патша»ның гадәти һөҗүме итеп кенә карыйлар. Ә татарлар бу сугышның, җиңелә калсалар, соңгы сугыш буласын яхшы аңлыйлар һәм Казан өчен соңгы сулышларына кадәр көрәшәләр. Пугачев чигенеп, качып котыла алса да, татарларның, бигрәк тә бу тирә татарларның, чигенер урыны булмый. Һәм Арча кыры аларның канлы гәүдәләре белән тула…

Татарлар җиңелә. 5000 нән артык кеше әсир итеп алына, соңыннан аларның күбесен мәңгелек сөрген, каторга, газаплы үлем көтә… Пугачев исә исән калган кешеләр белән Идел аръягына кача. Әле ул Идел аръягында тагы бик күп шәһәрләрне алыр, хәрби крепостьларны яндырыр, урыс байларын үтерер, аңа юлда тагы меңәрләгән татар кушылыр… Урыс коллыгыннан ничек котылырга белмәгән Пенза, Саранск, Саратов, Камышлы, Курмыш, Алатырь татарлары тагы Пугачев явының үзәгенә әйләнер… Әмма Царицын (хәзерге Волгоград) өчен барган сугышларда Пугачев явы тар-мар ителә, күп татар ирләре шунда мәңгелеккә ятып кала, 6000 кеше әсирлеккә алына. Пугачев исә йөздән артык кешесе белән Иделнең икенче ягына качып котыла. Нияте яңадан Җаекка, Ырынбур далаларына кайту, шунда көч туплау һәм яңа яуларга әзерләнү була. Шушы уй белән, ул Җаек (хәзерге Уральск шәһәре, Казахстанга керә) шәһәренә юнәлә. Әмма янындагы Җаек казаклары аңа хыянәт итә — Пугачевны тотып, Җаек шәһәренә илтәләр һәм патша гаскәрләре кулына тапшыралар.

1774 елның 4 ноябрендә Пугачев Мәскәү каласына китерелә һәм 10 гыйнвар көнне мәйданда аның башын чабып өзәләр. Әби патша моның белән генә дә канәгатьләнми — Пугачевның киселгән башын колгага кидерәләр, гәүдәсен 4 кисәккә чабып, Мәскәүнең төрле почмагына илтеп яндыралар…

Пугачев белән бергә ирек өчен яуга күтәрелгән татарларның да күбесен шундый ук кара язмыш көтә… Аларның кайсының шунда ук башлары киселә, кайсыларының колак-борыннары, куллары киселеп алына, маңгайларына, яндырып, тамга салына, бу татар көрәшчеләре чыбыркылар белән кыйналып, исән калганнары мәңгелек каторгага сөрелә… Аларның гаиләләре дә шундый ук җәбер-җәзага дучар була… Татарның ирек өчен соңгы күтәрелеше менә шулай канга батырылып, нәсел-тамырлары корытылып, инде мәңге кузгала алмаслык булып бастырыла… Ләкин татарлар ирек өчен көрәшнең башка юлларын табалар, Татар дәүләтен торгызу өчен көрәшкә башкача күтәреләләр… Әмма моның өчен тагы йөз еллар үтүе, коллыкның ни икәнен белмәгән яңа буыннар, каһарман татарлар үсүе кирәк була... Һәм XX гасырда татар халкы кабат дәүләт бәйсезлеге өчен изге көрәшкә күтәрелә…

## ПУГАЧЕВ ЯВЫНДА КАТНАШКАН ТАТАР КАҺАРМАННАРЫ

МӘСӘГУТЬ ГОМӘРОВ. Хәзерге Татарстанның Кукмара районы Пычак авылында 1746 елда туган. Лашманлыкта булган. 1773 елда Пугачев явына катнашып киткән. Казан артында — Кукмара, Саба, Арча, Мамадыш, Питрәч, Балтач тирәләрендә — татарлардан үз отрядын төзи, алар белән Иж буйларындагы урыс заводларын барып кулга төшерәләр, алардан күп корал, хәтта туплар алалар. 3000 кешелек татар гаскәре белән Казанга һөҗүм итәргә җыенганда, Пугачев аны Минзәлә һәм Алабуганы штурмлау өчен җибәрә. Мәсәгуть Гомәров бу бурычны үти, шуның өчен Пугачевның полковнигы дигән дәрәҗәгә ирешә. Әмма ул Идел-Кама буйларында төп көчләрдән аерым һәм еракта була, патша гаскәре аның белән туктаусыз сугышлар алып бара. Артыннан куа килгән урыс гаскәрләре белән сугыша-сугыша, Мәсәгуть Гомәров 1774 елның 10 мартында Уса, Көнгәр якларына чигенә. Аны, тотып алып, Уфага китерәләр, аннан, богаулап, Казанга озаталар. Казанны урыслар кулыннан тартып алырга җыенган татар ире бирегә богаулы хәлдә, әсир булып кайта. Восстание бастырылгач, аны чылбырланган хәлдә, туган якларына алып кайтып, кыйный-кыйный авылдан авылга йөртәләр. Туган авылы Пычакта, бөтен кеше күз алдында, 150 мәртәбә чыбыркы белән суктыралар, маңгаена, ике битенә ут белән кыздырып бурлык тамгасы сугалар. Татар халкының каһарман улы Мәсәгуть Гомәров мәңгелек каторгага җибәрелә, гаиләсе дә шул ук хәлне кичерә. Алга таба аларның язмышлары билгесез.

БӘХТИЯР КАНКАЕВ. Уфа провинциясенең Ака авылы татары. Пугачев явына 1773 елның ноябрендә кушылып китә, походный старшина, бригадир, полковник дәрәҗәсенә ирешә, халык аны, яратып, «мишәрләр полковнигы» дип йөртә. Бәхтияр Канкаев, тирә-юнендәге татарларны җыеп, үз отрядын төзи, алар белән Санар заводын барып ала, Красноуфимск шәһәренә керә. 1774 елның май-июнь айларында 5000 кешелек татар-мишәр отряды белән ул Бөре шәһәрен яулап ала. Июль башында исә Пугачев артыннан Казан юлына чыга, алар Мамадышта очрашалар. Бәхтияр Канкаевка гаскәргә яңа кешеләр туплау бурычы куела. Ул, Саба, Теләче, Мамадыш, Балык Бистәсе авылларында булып, 3000 татарны яуга алып китә. Бәхтияр Канкаев Пугачев гаскәрен тылдан саклауга, бигрәк тә Вятка, Кама сулары аша кичүләрне күзәтүгә дә җаваплы була. Казанга Михельсон гаскәре якынлашуы турында хәбәрне дә Пугачевка Бәхтияр Канкаев махсус җибәргән чапкын җиткерә. Пугачев Казан тирәсеннән җиңелеп киткәч тә, Бәхтияр Канкаев хәзерге Татарстан җирләрендә үзенең көрәшен дәвам итә. Әмма җәза отряды да аның эзенә бастырып килә. 1774 елның 27 июлендә хәзерге Теләче районының Иске Җөри авылы янында Бәхтияр Канкаев отряды һәм җәзачылар арасында канкойгыч сугышлар

була. Бәхтияр исән калган 400 кеше белән чигенергә мәҗбүр була. Аны күпме генә эзләтсәләр дә тота алмыйлар. Безнең өчен дә аның язмышы билгесез булып кала.

КАНЗАФАР УСАЕВ. Уфа өязенең Чакмагыш авылы татары. Укымышлы мулла, авылның йөзбашы булган. Пугачев явына башында ук катнашып китә. Ырынбур, Көнгәр, Екатеринбург, Уфа өчен сугышларда зур батырлык күрсәтеп, полковник дәрәҗәсенә ирешә. 1774 елның гыйнварында Канзафар Усаевның, нигездә, татар-мишәрләрдән торган отряды Ачыт крепостен һәм Суксун заводларын сугышып ала. Яз айларында ул Пугачев фәрманы буенча Нугай, Себер юлларында үзенә гаскәр туплый, урыс гаскәре белән туктаусыз сугышлар алып бара. Июнь аенда ул Пугачев белән бергә Красноуфимск каласын һәм Усаны алуда катнаша. Үзе Казанны алырга киткән Пугачев данлыклы полковнигы Канзафар Усаевны һәм тагы берничә полковнигын Уфа провинциясендә яуны дәвам итү өчен калдыра. Канзафар биредә татар-мишәрләрдән тагы меңнәрчә кешелек гаскәр туплый, шулар белән Уфага һөҗүм итәргә хәзерләнә. Ул Дим, Үршәк, Авыргазы, Үзән елгалары буенда хәрәкәт итә, туктаусыз хөкүмәт гаскәрләре белән сугыша. 3 август көнне бу каһарман татар хыянәт юлы белән тотыла һәм Бөгелмә аша Казан төрмәсенә озатыла. Пугачев белән бергә, богаулар салып, 1775 елның гыйнварында аны да Мәскәүгә китерәләр. Шул мәйданда 10 гыйнвар көнне Канзафар Усаевны да җәзалыйлар, халык алдында чыбыркы белән суктыралар, маңгаена һәм битенә кыздырып тамга салалар. Аннан аны мәңгелеккә Рогервик төрмәсенә илтеп ябалар (хәзерге Эстония җирләре). Канзафар Усаев шушында 25 ел зиндан газабы кичерә, 1804 елның 10 июлендә биредә 66 яшендә үлә.

ГАБДЕЛҖӘЛИЛ СӨЛӘЙМАНОВ. Тирсә волостеның Тоба авылы татары. 1773 елның 3 декабре көнне Минзәләгә барып, Пугачев явында катнашырга теләгән белдерә һәм походный старшина итеп билгеләнә. Тиз арада шул тирә татарлардан 500 кешелек отряд туплап, сатлык Тәфкилев утарын һәм заводны туздырып ташлый. Вятка провинциясендә күрсәткән батырлыклары өчен, ул Пугачев тарафыннан бирелгән полковник дәрәҗәсенә лаек була. 1773 елның 23—26 декабрендә Габделҗәлил Сөләйманов һәм аның отряды Минзәләне штурмлау өчен чакыртып алына. Алга таба ул Тирсә, Пьяный Бор тирәләрендә җәза отрядларына каршы көчле сугышлар алып бара. 1774 елның башыннан ул Тирсә волостенда татарларның үз хакимиятен урнаштыра, алар ярты ел шулай яшиләр. Әмма урысларның җәза отрядлары аларны тынычлыкта калдырмый, һәм 14 май көнне, хыянәт юлы белән, аны җәзачылар кулына тотып бирәләр. Башта аны, богаулап, Казанга озаталар, аннан Усага баручы урыс майорына биреп җибәрәләр. Ул татар каһарманы Габделҗәлил Сөләймановны 12 июньдә Тирсә авылында дарга асып үтерә. 23 июнь көнне Пугачев майор Скрипицынның үзен дарга асып үтерә.

МУСА ГАЛИЕВ. Ырынбур өлкәсендәге Каргалы авылы татар бае. Бирегә Пугачев килгәч, ул аңа 500 кешелек татар гаскәре төзеп бирә. Аннан Муса Галиев Пугачев белән бергә бөтен яуларда, сугышларда, бәрелешләрдә катнаша, Ырынбурдан Казанга хәтле озын юл үтеп, татар полклары белән җитәкчелек итә. Ул татар явы белән бергә Казанга бәреп керә, Казанны алуда катнаша, соңыннан, 15 июль көнне, Казан янындагы канлы сугышта әсир төшә һәм җәзалана. Муса Галиев төп чыгышы белән хәзерге Саба районыннан булырга тиеш, чөнки Ырынбур өлкәсендәге Татар Каргалысы авылына Саба кешеләре нигез салган. Пугачевны Казанны алырга өндәп, шушы Татар Каргалысы авылы кешеләре алып килгән булырга тиешләр. Ул вакытта халык телендә Пугачев станы урнашкан Бирдә крепостен — Мәскәү дип, ә Татар Каргалысын Петербург дип атап йөрткәннәр. Ул заманда Россия империясе башкаласы Петербург булуын онытмыйк, димәк, Каргалыны татарлар үзләренең рәсми булмаган башкалалары дип исәпләгәннәр һәм шуннан Казанны кайтарып алырга планлаштырганнар…

ГАБДЕЛКӘРИМ РАХМАНКУЛОВ. Хәзерге Азнакай районындагы Чалпы авылы татары. Пугачев явының башыннан ук була, Уфаны камауда катнаша. Аннан туган якларына кайтып, татар гаскәре туплап, Нагайбәк крепостен камап ала. Шушындагы җиңүләре өчен полковник дәрәҗәсенә ирешә. Габделкәрим Рахманкулов шулай ук Минзәлә камалышында да катнаша. Алдагы язмышы билгесез.

АИТ УРАЗМӘТОВ. Бөгелмә төбәгендәге Абдул авылы татары. Пугачев явына инде өлкән яшьтә — 56 яшендә катнашып китә. Бик укымышлы, хәлле кеше була. Бертуган энесе Тимербулат Уразмәтов, улы Габдрәшит белән алар Бөгелмә тирәсендәге татар авылларыннан Пугачев явына 3000 кешелек татар гаскәре туплыйлар. Күп тапкырлар хөкүмәт гаскәрләре белән очрашып, сугышлар алып баралар. Рәҗәп авылы тирәсендәге бәрелешләрдән соң Пугачев Аит Уразмәтовка «корпус старшинасы» дәрәҗәсен бирә, ягъни ул татар гаскәренең атаманы һәм полковнигы була. Аитның энесе Тимербулат «походный старшина» исеменә, улы Габдрәшит полковник дәрәҗәсенә лаек була. 1774 елның гыйнварында бу татарлар Чирмешән, Нурлат тирәләрендә патша гаскәрләре белән бик авыр сугышлар алып баралар, татар җирләренең һәр карышы өчен урыслар белән канга батып сугышалар. Әмма көчләр тигез булмый, һәм шул елның 20 гыйнварында Аитовлар гаскәре урысларның җәза отрядыннан җиңелә, бу сугышта бик күп татарлар үлә. Аит Уразмәтов исә урыслар кулына эләгә, һәм аны, Казанга

алып китеп, бик нык газаплыйлар. Шушы газапларга түзә алмыйча, ул 7 февраль көнне Казан төрмәсендә үлә.

ГАБДРӘШИТ АИТОВ. Бөгелмә төбәге, Абдул авылы татары, Аит Уразмәтовның улы. Пугачев явына этисе белән бергә кушылып китә, сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен полковник дәрәҗәсенә ирешә. Әтисе Чирмешән тирәсендә урыслар кулына эләккәндә, Габдрәшит Пугачев янында, Бирдә бистәсендә кала. Моннан ары ул гел Пугачев янәшәсендә була, аның белән бергә бөтен сугышларда, бәрелешләрдә катнаша. Ул бигрәк тә Бозаулык, Сорочинск, Татищев крепостьлары өчен сугышларда үзен баһадирларча тота. Әмма 1774 елның 2 апрелендә, Ырынбур тирәсендәге каты сугышларда Габдрәшит Аитов җәза отряды кулына эләгә һәм Ырынбур төрмәсенә ябыла. Алга таба аның язмышы билгеле түгел…

Каһарман татарларның бу исемлеген йөзәрләп, хәтта меңәрләп дәвам итәргә булыр иде… Һәр карыш татар җирен урыслардан азат итү, татарның башкаласы Казанны Мәскәү кулыннан тартып алу, Казан ханлыгын яңадан торгызу өчен, алар кан коеп сугыша, меңәрләп-меңәрләп корбан була… Безнең өчен бу көрәш, тарихчылар язганча, Пугачев яки крестьян восстаниесе генә түгел, бу — татар явы, татарның ил өчен, дәүләт өчен изге сугышы… Татар халкы моны яхшы белергә һәм бу каһарманнарны беркайчан да онытмаска тиеш.

## ЕГЕРМЕНЧЕ ГАСЫРДА ДӘҮЛӘТ БӘЙСЕЗЛЕГЕ ӨЧЕН КӨРӘШ

Татарларның ирек өчен, дин өчен гасырлар дәвамында ярсып күтәрелүләреннән соң, Россия империясе алар бугазыннан кулларын бераз ычкындырып тора. 1788 елгы Указ нигезендә Екатерина II ислам динен рәсми таныырга мәҗбүр була, үзе Казанга килеп, бередә беренче мәчетне салырга рөхсәт бирә. Ул шулай ук татарларга бераз җир ирегe һәм чит илләр белән сәүдәгә мөмкинлекләр бирә. Татарлар бу мөмкинлекләрдән файдаланып калырга тырышалар — Россия буйлап йөзләгән мәчет-мәдрәсәләр ачыла, татарлар үз завод-фабрикаларын төзеп куялар, сәүдәләр гөрләп китә. Россиядә мөселманнарның үз дини нәзарәте барлыкка килә, дини һәм милли интеллигенция үсеп чыга. 1799 елда, татарларның соравы буенча, Петербургтан Казанга Шәрык типографиясе күчерелә, инде XIX гасыр башында татарлар китап басу белән шөгыльләнә башлыйлар. 1867 елда беренче татар календарьлары чыга, 1855—1864 елларда инде татарлар 1 084 320 нөсхә татарча китап бастырып чыгаралар. Моның өчен аларның үз кулларында берничә типографияләре була, татарларның 1812 елда Вятка губернасында ике, Казанда бер кәгазь фабрикалары эшләп тора. Әле генә кан эчендә батып яткан татар халкы, бик ерактан килгән асыл тамырлары сәбәпле, тиз арада тагы күтәрелеп китә, аякка баса. Бу чорда милләтнең аңын уятуда Шиһабетдин Мәрҗани, Исмәгыйль Гаспралы, Каюм Насыйри, Хөсәен Фәезханов кебек шәхесләр күп хезмәт башкаралар. Милли аң ныгу белән бергә, милли капитал, байлык та үсә. Чөнки ислам динендә булган тәртипле татарлар сәүдәне гадел алып барырга тырышалар, шуңа күрә аларның эшләре дә бик тиз алга китә. Бу хәл, әлбәттә, урыс байларына бер дә ошамый, алар татарларга каршы тагы хөкүмәтне котырта башлыйлар. Патша хакимияте үзе дә татарларның кинәт кенә болай күтәрелеп китүеннән курка, аны бастырырга җай эзли башлый. Нәтиҗәдә XIX гасырның икенче яртысында татарларга каршы яңа репрессияләр башлана. Мәчетләр салу туктатыла, кайбер мәктәп-мәдрәсәләр ябыла, татарча китап бастыру көчле патша цензурасына эләгә. Татар сәүдәгәрләренә дә урыслар һәр төрле каршылыклар чыгарып, эшләренә аяк чалып торалар. Шушы хәлдә татарлар XX гасырга килеп керәләр.

Дөньяның кайсы якка барганын аңлаган акыллы татарлар Россиядәге сәясәт эшләренә бик нык керешеп китәләр. Алар 1905—1906 елларда ук инде үзләренең «Иттифак» партияләрен төзиләр, бу мөселман партиясенә Россиянең урыс булмаган шактый милләт вәкилләре керсә дә, аны оештыручылар һәм башында торучылар татарлар була. Рәшит Ибраһимов, Исмәгыйль Гаспралы, Йосыф Акчура, Садри Максуди, Гаяз Исхакый, Сәедгәрәй Алкин, Закир Рәмиев, Муса Бигиев, Галимҗан Баруди, Абдулла Апанаев һәм башка алдынгы татарлар «Иттифак» партиясе аша Россия сәясәтенә үтеп керәләр, аның алдына үз таләпләрен куя башлыйлар. Һәм, әлбәттә, беренче таләп — татарларга мөстәкыйльлек, ирек, диннәр тигезлеге мәсьәләсе була. 1912—1913 елларда татар милләтчеләре хәтта «Дини автономия» мәсьәләсен дә күтәреп чыгалар, әмма бу теләкләренә ирешә алмыйлар. Татарлар шулай ук Россия Дәүләт Думасы сайлауларында актив катнашалар, анда үзләренең депутатларын уздыралар. 1906—1917 елларда Россия Дәүләт Думасының дүрт чакырылышында җитмешкә якын мөселман депутаты була, шуларның яртысы — татарлар. I Думада — 12 татар депутаты, II Думада — 15, III Думада — 7, IV Думада 4 татар депутаты эшли. Алар арасында Садри Максуди, Сәедгәрәй Алкин, Гариф Бадамшин, Гайса Еникеев аеруча активлык күрсәтәләр. Татар депутатлары Россия Дәүләт Думасында милли һәм дини тигезлек, мөселман халыкларының мәгарифе һәм мәдәнияте,

телләрнең үсеше кебек бик җитди мәсьәләләр күтәрәләр, шулай ук татарларның социаль хәлләре, күп мәсьәләләрдә хокуксызлыклары турында да Дума мөнбәреннән ялкынлы чыгышлар ясыйлар. Бу заманда Россиядә сәяси яктан иң актив халык — татарлар була.

XX гасыр башында татарлар Россиядә иң укымышлы халыкларның берсе була, грамоталык ягыннан алар хәтта урыслардан да өстен тора. Бу чорда инде һәр авылда мәчет һәм мәдрәсә (мәктәп) була, анда татар балалары гарәпчә, фарсыча, төрекчә укыйлар, ныклы белем алалар. Гасыр башында Россиядә һәр елны 400—500 исемдәге татарча китап чыга, аларның гомуми тиражы 2 миллионга җитә. 1905 елдан 1924 елга кадәр Россиядә татарча 310 исемдәге газета һәм 89 исемдәге журнал бастырып чыгарыла. Милләтнең аңын уятуда Габдулла Тукай, Дәрдемәнд, Риза Фәхретдинов кебек шәхесләр күп хезмәт куялар. Шулай итеп, татарлар Россиядә генә түгел, дөньяда иң күп укый торган белемле халыкка әйләнәләр. Моңа гаҗәпләнергә дә кирәкми, борын-борыннан тамырларында затлы кан аккан, тирән гыйлемле, иманлы, тәртипле, аек татар халкы бөтен тырышлыгын белемгә һәм һөнәргә биргән. Россия империясендә, кяфер кавемнәр чолганышында һәм тәэсирендә ул шулай гына исән кала алган, шулай гына үзенең кеше икәнлеген дөньяга таныткан…

Шушы урында тарих фәннәре докторы М. А. Водолагинның татарлар турында атаклы сүзләрен язып үтәсе килә, чөнки бу безнең милләтебезгә карата бирелгән бик гадел бәя: «Татары?! О, этот могучий народ, им только дай возможность, сразу активизируют свою деятельность — и весь мир в их цепких объятиях, не приди Ульянов вовремя, опоздай он хотя бы на тридцать лет, вся власть уже перешла бы в руки трехсот непьющих миллионеров татарских. Ведь почти все —и золото, и уральские руды, и нефть, и камни — все было уже перешло в их руки, Тазиевы и Азимовы, Рамиевы и Шакуровы, Скуратовы и Строгоновы… Урал, Кавказ, Сибирь… кони, хлеб и недра — все, все! Опасно это!!! Акчурины… Файзуллины, Мансуровы, Ишмуратовы… Морозовы, Дягиловы!!! Страшно это! — А какая идеология?! Зеленая! — Скромность, образование, кротость, величье… И в то же время храбрость, неустрашимость, мужество, достоинство, богатство, сила, могущество, верность, чистота».

1917 елгы революцияне татарлар менә шундый хәлдә каршы алганнар. Аларның инде, дәүләт мөстәкыйльлегеннән кала, барлык нәрсәләре дә булган — байлык та, байлары да, алтын да, нефть тә, татар байлары хисабына тотыла торган үз мәгариф системалары да, мәктәп-мәдрәсәләре, галимнәре, китаплары, язучылары да… 1917 елгы революция менә шуларның барысын туктата, туздырып ташлый, әйтерсең лә татар күтәрелеп китмәсен өчен генә эшләнгән революция була бу… Дөрес, татарлар шушы шартларда да милләт файдасына нидер эшләп калырга тырышалар, бигрәк тә Февраль һәм Октябрь революцияләре арасында… Әмма вакытның гаять азлыгы, чорның бик дәһшәтле булуы, Мәскәүнең мәкере татарга үз дәүләтен торгызырга ирек бирми. Татар ирләре, тарихи мизгелдән файдаланып, нәкъ шушы мәсьәләне күтәрәләр, берләшеп эш итү өчен һәм бу болганчык дөньяда милләт буларак исән калу өчен, үз милли дәүләтең булу кирәклеген алар яхшы аңлый инде. Һәм шушы олы эшкә керешә.

1917 елның җәендә Казанда берьюлы татарларның өч зур җыены үтә — Россия мөселманнарының II съезды (июль), Россия мөселман хәрбиләренең съезды (22 июль) һәм Россия дин әһелләре корылтае. Һәм бу җыеннарда Идел-Урал төрки-татарларының милли-мәдәни автономияләре игълан ителә. Бу тыныч, законлы юл белән империя эчендә яңа татар дәүләтчелеген торгызуның беренче адымы була. Яшерен тавыш бирү юлы белән Идел-Урал татарлары арасында Милли Мәҗлес корылтае өчен вәкилләр сайлау уздырыла. 1917 елның 22 ноябрендә Уфа шәһәрендә татар халкының Милли Мәҗлесе үзенең эшен башлап җибәрә. Милли Мәҗлеснең төп максаты — татар халкының милли үзбилгеләнүе, ягъни дәүләтчелек мәсьәләсе була. Һәм 1917 елның 29 ноябрендә Милли Мәҗлес татар халкының Идел-Урал штатын төзү турында карар кабул итә. Бу инде чын мәгънәсендә дәүләт игълан итү була! Идел-Урал штатына татар халкы күпләп яшәгән Казан, Уфа, Ырынбур губерналары тулысынча керергә тиеш була, шулай ук Пермь, Самара, Сембер, Вятка губерналарының да татарлар яшәгән өязләрен Идел-Урал штатына кертү карала. Бу җирләрдә 4 миллион татар, 2,5 миллион урыс һәм башка халыклар яшәгән була. Әмма татарларның бу омтылышларына урыслар, большевиклар, башкортлар каршы төшә һәм булачак Идел-Урал штатына да, Милли Мәҗлескә дә каршы эшләр башлана. Бу вакытка инде ныгып алган Совет хакимияте милли автономияләрне үз кул астында, социалистик нигездә оештырырга уйлый, аларга милли төсмерле Идел-Урал штатлары кирәк булмый. Милли Мәҗлес җитәкчелеге исә Совет хакимиятен кабул итә алмый.

Бу чорда татарларның үзләренең мөселман гаскәрләре булганлыгын һәм Хәрби Шура эшләп килгәнлеген дә әйтергә кирәк. Бер Уфада гына да 10 000 татардан торган гаскәр тора. Мөселман-татар полклары Идел — Урал арасында тәртип урнаштырып, татар халкын төрле бәрелешләрдән саклап килгәннәр. Татарлар 1918 елның 28 февралендә Казанда үтәчәк Хәрби Шура җыелышында Идел-Урал штаты төзелүне игълан итәргә җыеналар. Бу нисбәттән хәрбиләр дә, мөселман-татарлар да икегә — Совет яклыларга һәм алардан башка милли дәүләт төзергә теләүчеләргә бүленәләр. Ул арада

башкортлар, Ырынбурга җыелып, үзләренә аерым милли штат төзү турында карар кабул итәләр, нигездә, татарлардан гына торган Уфа губернасын да анда кертергә уйлыйлар. Большевикларга нәкъ шул гына кирәк була — «Бүлгәлә һәм хакимлек ит!» — алар, башкортларны яклаган булып, татарларга каршы төшәләр. Нәтиҗәдә Идел-Урал штаты игълан ителмичә кала, Совет хакимияте 1918 елны аны гамәлдән чыгара. Татарларны юату өчен, большевиклар тиз арада «Татар-Башкорт Совет Республикасы» дип аталган уенчык идея тәкъдим итәләр, әмма Зәки Вәлиди җитәкчелегендәге башкортлар моңа да риза булмыйлар, үзләренә «Бәләкәй Башкортстан» сорыйлар һәм 1919 елда Ленин кулыннан аны алалар. 1920 елда Татар Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелә. Шулай итеп, татар милләтчеләре рухланып тотынган Идел-Урал штаты да, хәтта Татар-Башкорт Республикасы да булдырылмыйча кала, аның урынына Идел-Урал халыклары милли төсмерләре булмаган, совет көенә җырлый торган «курчак автономияләр» алалар. Татар милләтенең рухи җитәкчеләре бу хәлләрдән соң чит илләргә эмиграциягә китәргә мәҗбүр булалар. Идел-Урал төбәге, татар халкы большевикларның 70 еллык төрмәсенә ябыла…

## МИЛЛИ АЗАТЛЫК ӨЧЕН КӨРӘШКӘН КАҺАРМАН ТАТАРЛАР

САДРИ МАКСУДИ-АРСАЛ (1879—1957). Танылган дәүләт эшлеклесе, сәясәтче, язучы, юрист, профессор. Нәселе хәзерге Татарстанның Лаеш районындагы Хәерби авылына барып тоташа. Башта Казанда урыс-татар укытучылар мәктәбендә укый, 1902 елда белемен дәвам итәргә Парижга китә. Ул анда Сорбонна университетының юридик факультетында укып диплом ала, әдәбият буенча да белемен күтәрә. 1906 елда Казанга кайтып, милләт эшләренә чума. Садри Максуди — «Иттифак» партиясен оештыручыларның берсе, 1907 елдан ике чакырылыш Россия Дәүләт Думасы депутаты. Ул, анда татар халкын яклап, француз телендә ялкынлы һәм дәлилле чыгышлар ясый. Ул татар халкының Милли Мәҗлесен оештыручыларның берсе була. 1917 елның ноябрендә Садри Максуди «Идел-Урал» штатының Милли Идарә рәисе итеп сайлана, аны татар халкының беренче Президенты дисәң дә ярый. Әмма большевиклар Милли Мәҗлесне танымыйлар һәм юкка чыгаралар, нәтиҗәдә Садри Максуди чит илгә китә. 1918—1919 елларда ул Финляндиядә, аннан Швециядә, Берлинда була, 1919 елда Парижга килеп җитә. Ул кайда барса да, кайда яшәсә дә дөнья халыкларына татарларның Россиядәге хәле турында сөйли, большевиклар режимын фаш итә. 1925 елдан — Садри Максуди Төркиядә. Биредә ул иң югары даирәләрдә кабул ителә, Төркия президенты Ататөрекнең милли мәсьәләләр буенча киңәшчесе була, Төркия Парламентына депутат итеп сайлана. Биредә ул үзенең татар тарихы турында иң зур хезмәтләрен яза, скифларның төрки халыклар булуын исбат итә. Ул шулай ук төрек тарихын язарга да ярдәм итә, тел мәсьәләләрендә бик күп эшли, Анкара, Истанбул университетларында укыта, профессор дәрәҗәсенә ирешә, фәлсәфә һәм хокук буенча дәреслекләр яза. Садри Максудиның төрек-татар тарихы, хокук, тел, фәлсәфә, милли идеология буенча дистәләгән китаплары, йөзләгән мәкаләсе бар, аны чын мәгънәсендә татар милли азатлык хәрәкәтенең идеологы дип әйтергә мөмкин. Аның бигрәк тә «Искетлар —сакалар» (1938), «Урта Азиядә төрек дәүләтләре» (1934), «Төрек тарихы вә хокукы» (1947), «Төрек теле өчен» (1930), күп санлы дәреслекләре һәм 1955 елда язган «Милләт тойгысының социологик әсаслары» дип аталган хезмәтләре бүген дә үзенең актуальлеген югалтмаган. Садри Максуди, күп илләрдә халыкара киңәшмәләрдә катнашып, иң югары дәрәҗәдә төрек-татар проблемаларын күтәрә. Ул 1957 елда Истанбулда вафат була һәм 21 февраль көнне шунда җирләнә.

ГАЯЗ ИСХАКЫЙ. (1878—1954). Танылган татар язучысы, милли азатлык көрәшенең юлбашчысы. Хәзерге Чистай районы Яуширмә авылында мулла гаиләсендә туа, башлангыч белемне туган авылында ала, аннан укуын Чистай мәдрәсәсендә дәвам итә. 1893 елдан Казанның Күл буе мәдрәсәсендә укый, 1898 елдан 1902 елга кадәр Татар укытучылар мәктәбендә белем ала. Шул елны ул Ырынбурда «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта башлый, аннан туган якларына кайта. Патша жандармериясе бу тынгысыз, талантлы татарны дөньяга чыгу белән эзәрлекли башлый, күп тапкырлар зинданнарга яба, сөргеннәргә сөрә. Әмма Гаяз Исхакый халык арасында патша хөкүмәтенә каршы сөйләүләрен, эшчәнлеген туктатмый. Бу эшләре өчен ул 1907 елда Архангель якларына өч елга сөргенгә җибәрелә. Истанбулда, Петербургта яшәп ала, аннан — тагы сөрген. Патша хөкүмәте Гаяз Исхакыйга Казанда яшәргә рөхсәт итми, шуңа күрә ул әле авылында, әле башка урыннарда, шул исәптән Петербургта һәм Мәскәүдә дә яши. Гаяз Исхакый беренче татар газеталарын чыгаруда катнашучы буларак та билгеле. 1905 елда ул «Казан мөхбире» газетасында эшли, 1906 елда үзе «Таң йолдызы» газетасы чыгара, аны патша хөкүмәте япкач, 1907 елда «Тавыш» газетасын чыгара башлый. Сөргеннән кайткач, 1913 елның октябрендә Петербург шәһәрендә Гаяз Исхакый «Ил» дип аталган татарча газета чыгара. Бу газета да ябылгач, ул Мәскәүдә «Сүз» (1915—1916), «Безнең юл» (1916—1917) газеталарын чыгара башлый. Бу

татар газеталарының барысында да Гаяз Исхакый патша идарәсенә каршы чыга, татар халкының милли азатлык идеяләрен күтәрә, милләтне үз бәхете өчен көрәшкә әзерли. 1917 елгы Февраль революциясен ул ышанып каршы ала, татарларны милли байрак астына тупланырга өнди. Гаяз Исхакый бу елларда Мәскәүдә, Казанда һәм Уфада уздырылган барлык мөселман-татар съездларының түрендә була, үзе аларны оештырып йөри, кирәкле документларын әзерли, төп докладларны ясый. Шушы тарихи мөмкинлектән файдаланып, Гаяз Исхакый татарларга милли дәүләт төзеп калдырырга тырыша, әмма Россиядә моңа каршы нинди куркыныч көчләр хәрәкәткә киләсен хәтта ул да күз алдына китерә алмый. Гаяз Исхакый Милли Мәҗлес төзүне дә башлап йөри. Ул Идел-Урал штатының Тышкы эшләр департаменты башлыгы итеп билгеләнә. Әмма Милли Мәҗлес 1918 елның 11 февраленә кадәр генә эшли, большевиклар аны тар-мар итеп ташлыйлар. Бу хәлләрдән соң Гаяз Исхакый 1918 елның җәендә Ерак Көнчыгыш аша Кытайга китә, аннан Франциядә, Германиядә, Польшада яши. 1939 елда Төркиягә китә һәм гомеренең азагына хәтле шунда яши. Ул милләт эшләре белән күп илләрдә була, бик күп халыкара киңәшмәләрдә катнаша, чыгышлар ясый. 20—30 нчы елларда Гаяз Исхакый Варшава һәм Берлин шәһәрләрендә «Милли юл», «Яңа милли юл» журналларын чыгара. 1935 елда инде Кытайда татар мөһаҗирләре өчен «Милли байрак» газетасын чыгара. Берлинда исә «Милли юл» дип аталган нәшрият оештырып җибәрә. Шулай итеп, мөһаҗирлектә дә ул татар халкының, милләтнең юлбашчысы, оештыручысы, идеологы булып кала. Аның «Идел-Урал» исемле тарихи хезмәте бөтен дөньяга татарлар турында дөрес хәбәр тарата. 1933 елда бу китап татар телендә Берлинда, шул ук елны урыс һәм француз телләрендә Парижда, 1934 елда япон телендә Токиода, 1938 елда поляк телендә Варшавада, 1988 елда урыс телендә Лондонда басылып чыга. Гаяз Исхакый бу хезмәтендә татар халкына, аның бөек тарихына, милли азатлык идеяләренә тугры булып кала. Гаяз Исхакый — үзенең әдәби әсәрләре белән татар дөньясын уяткан, елаткан һәм тетрәндергән әдип. Проза, драматургия, публицистика өлкәләрендә аңа тиңнәр булмаган, һәм бүген дә ул татар әдәбиятының түрендә. Гаяз Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре, «Теләнче кызы», «Мулла бабай» романнары, «Остазбикә» повесте, «Зөләйха» драмасы, «Өйгә таба» һәм башка дистәләгән әдәби әсәрләре, хикәяләре, меңләгән ялкынлы мәкаләләре, чыгышлары бүген дә йотылып укырлык, гыйбрәт алырлык, уйланырлык. Әдәби әсәрләрендә булсын, публицистикасында булсын, Гаяз Исхакый бер генә максат куя: татар халкын коллыктан коткару, азат итү, бәхетле итү… Татар халкының милли юлбашчысы, талантлы язучысы Гаяз Исхакый 1954 елның 22 июлендә 76 яшендә Анкара шәһәрендә үлә, Истанбулда Йосыф Акчура кабере янәшәсендә күмелә. Үзгәртеп кору чоры башлангач, Исхакыйның якты исеме һәм әсәрләре яңадан татар халкына кайта, инде мәңге китмәскә дип кайта…

Совет хакимияте татарның бөтен мәчет-мәдрәсәләрен җимереп бетерә, меңләгән дин әһелләрен сөргеннәргә сөрә, Сталин лагерьларында черетә, аттыра һәм кистерә. Бу илдә ислам дине тыела, динсезлек, милләтсезлек пропагандалана. Милли интеллигенция, күренекле татар галимнәре, милләтчеләре, язучылар, акыл ияләре барысы да диярлек Сталин лагерьларына ыргытыла… Татар зыялылары өчен тагы Явыз Иван чоры башлана… Иң күренекле татар тарихчылары Һади Атласи, Газиз Гобәйдуллин, татарлар турында иң дөрес хезмәтләр язган урыс кешесе Михаил Худяков һәм башкалар шәхес культы елларында атып үтерелә, хезмәтләре юк ителә. Иң талантлы татар язучылары Хәсән Туфан, Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Гомәр Гали, Мәхмүт Галәү, Шамил Усманов, Фатих Кәрими, Сәгыйть Сүнчәләй, Ибраһим Салахов, галимнәр Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Толымбайский, Борһан Шәрәф, Җамал Вәлиди, Фатих Сәйфи-Казанлы, тагы бик күп талантлы татарлар Сталин лагерьларына ябыла, күпләр шунда мәңгегә ятып кала… Могҗиза белән Сталин тырнагыннан котыла алган татар язучыларын, галимнәрен 1941 елны Бөек Ватан сугышына җибәрәләр, аларның 80—90 проценты шунда үлеп кала… 1944 елда Германиядә фашист төрмәсендә шагыйрь Муса Җәлилнең һәм тагы дистәгә якын татарның башы чабып өзелә…

Бу чорда шәһәрләрдә бөтен татар мәктәпләре ябылып бетә, авыл халкы паспортсыз, хокуксыз, бушка эшли торган кол хәленә куела. Милләтләрне, урыс теленнән кала башка телләрне бетерү максаты куйган совет системасы татар халкын яңадан 1552 елгы хәленә төшерә. Татарларның җәннәттәй җирләренә гигант заводлар салына, агулы химия промышленносте объектлары кертеп тутырыла, Совет хакимияте елларында Татарстан җирләреннән бушка 2 миллиард тонна нефть суырып алып, Россиягә озатыла. Нефтьтән кергән доллардардан Мәскәү чәчәк ата, ә татар халкы 70 ел буе газсыз, юлсыз, хокуксыз яшәргә мәҗбүр була. Һәм СССРда үзгәртеп кору чоры башлану белән, татарлар илдә беренче булып дәүләт бәйсезлеге мәсьәләсен күтәрәләр, Россиядән аерылып чыгуны куялар.

1988—1989 елларда Татарстанда һәм СССРның татарлар яшәгән барлык төбәкләрендә милли оешмалар, иҗтимагый хәрәкәтләр барлыкка килә. 1989 елның февралендә Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең (беренче рәисе тарихчы-галим Марат Мөлеков) 1 нче корылтае була. Аларның төп максаты

Татарстанның дәүләт статусын үзгәртү, татар милләтенең хокукларын саклау, татарның дөрес тарихын торгызу, татар теленең куллану мөмкинлекләрен киңәйтү була. Татар милләтчеләре шулай ук социаль-икътисади таләпләр дә куялар, Татарстанның байлыгын татар халкына бирү, салымнарны Татарстанда калдыру, нефтькә хуҗа булу кебек мәсьәләләрне күтәрәләр. 1990 елның мартында «Иттифак» татар милли бәйсезлек партиясе оеша, 1991 елның апрелендә Казан шәһәрендә аларның беренче корылтайлары була. (Партиянең рәисе — язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмова.) Татар иҗтимагый үзәгеннән аермалы буларак, «Иттифак» партиясе Татарстан өчен тулы бәйсезлек таләп итә, Россиядән аерылып чыгу мәсьәләсен көн тәртибенә куя. Татар халкының һәм татар милләтчеләренең көчле тәэсире астында, Татарстан Югары Советы 1990 елның 30 августында **«Татарстан Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация»** кабул итә. 440 еллык Мәскәү коллыгыннан соң, шушы гасырлар барышында ирек өчен алып барган дистәләгән канлы сугышлардан соң татар халкы законлы рәвештә үзенең дәүләт бәйсезлеген игълан итте! Декларациядә республика статусының халык мәнфәгатенә туры килмәве, татар милләтенең үзбилгеләнүгә аерылгысыз хокукы булуы, демократик хокукый дәүләт төзергә омтылуы билгеләп үтелә һәм Татарстанның дәүләт суверенитеты игълан ителә. Бу Декларация буенча Татарстанның җир һәм аның байлыклары, башка табигый байлыклар һәм башка ресурслар бары тик аның халкының милке булып тора дип белдерелә. Шулай ук Татарстан Республикасында «тигез хокуклар һәм кеше иреге гарантияләнә», татар һәм урыс телләре дәүләт теле сыйфатында тигез хокукка ия булуы әйтелә. Иң мөһиме, «Татарстан ССР Конституциясе һәм законнары Татарстан ССРның бөтен территориясендә өстенлекле» булуы турында белдерелә. Бу исә Татарстан кануннарының Мәскәүнекенә караганда беренче урында торуы, өстен булуы турында сөйли, Татарстанның алардан бәйсез булуын күрсәтә.

Әмма бу хәлләр берсе дә тыныч кына үтми. Башта — СССР, аннан Россия органнары, матбугат чаралары Татарстан, татар халкы, милләтчеләр өстенә ябырыла. Мәскәү Татарстанга танклар кертү белән дә, ач калдыру, милләтара сугышлар белән дә яный башлый. 1991 ел бигрәк тә киеренке һәм хәвефле үтә. Татарстанның халык депутаты, язучы Фәүзия Бәйрәмова 1991 елның 14 маенда Казан шәһәренең Ирек мәйданында Татарстанда Россия президентын сайлауга каршы сәяси ачлык игълан итә. 14 көн буе барган бу ачлыкка тагы егермегә якын кеше кушыла, Татарстан Югары Советы бинасын 50 мең татар чорнап ала. Нәтиҗәдә 1991 елның 27 маенда Югары Совет Татарстан территориясендә Россия президентын сайлауларны рәсми рәвештә уздырмау турында карар кабул итә. Бу татар халкының зур җиңүе була! Мәскәү күпме генә янап, куркытып торса да, татар халкы үзенчә эшли: ул 1991 елда Россия президентын сайламый, 1993 елда Россия Конституциясен референдум юлы белән кабул итми, ягъни сайлауларга бармый.

1991 елның 12 июнендә Татарстан халкы **Минтимер Шәймиевне** үзенең Президенты итеп сайлап куя. 1991 елның 24 октябрендә, Татарстан Югары Советында **«Татарстан Республикасының дәүләт бәйсезлеге турында акт»** кабул ителә! Шул ук елның 26 декабрендә Югары Советта «Татарстан Республикасының бәйсез дәүләтләр берлегенә керүе турында Декларация» кабул ителә. 440 еллык Мәскәү коллыгыннан татар халкы әнә шулай ярсып көрәшеп котылырга тырыша, әмма империя бу бай республиканы үз тырнагыннан җибәрергә теләми. Татар милләтчеләрен кыйнатулар, үтерүләр башлана, республика җитәкчеләрен куркытулар һәм үз якларына аударырга тырышулар тотына…

Декларацияне халык теләге белән ныгытыр өчен, 1992 елның 21 мартында Россия-Татарстан мөнәсәбәтләре буенча Татарстанда референдум үткәрелә, халык хөкеменә «Согласны ли Вы, что Республика Татарстан — суверенное государство, субъект международного права, строящее свои отношения с Российской Федерацией и другими республиками, государствами на основе равноправных договоров?» дигән сорау чыгарыла. Референдумда катнашучыларның 61,4 проценты бу сорауга уңай җавап бирә. 1992 елның 6 ноябрендә суверен Татарстанның яңа Конституциясе кабул ителә, аның нигезен Татарстанның мөстәкыйль, суверен дәүләт булуы турында статьялар тәшкил итә. Дөрес, Мәскәүнең көчле басымы астында бүгенге көндә бу статьяларның күпчелеге үзгәртелде, Россия законнары белән тәңгәлләштерелде, әмма 1990 елның 30 августында кабул иткән Декларация һәм 1992 елгы референдум нәтиҗәләре үз көчендә кала, татар халкы аларны теләсә кайсы вакытта күтәреп чыга ала.

СССРда һәм Россиядә беренчеләрдән булып Татарстан, татар халкы үзенең дәүләт бәйсезлеге мәсьәләсен күтәрде, бу юнәлештә шактый эшләр башкарды. Бу тарихи чорда татар халкы үзенең яңа каһарманнарын тудырырга сәләтле икәнлеген күрсәтте. Татарстан Югары Советының 1990—1995 елгы чакырылыш депутатларының күпчелеген әнә шул исемлеккә кертеп була, чөнки Мәскәү ут белән куркытып торганда да, алар милләт өчен гаять мөһим булган карарлар кабул итә алдылар. Монда татар милли хәрәкәтенең роле гаfive зур булуын тагы бер тапкыр ассызыклап үтәргә кирәк. 1992 елда татар халкының Милли Мәҗлесе төзелү һәм Бөтендөнья татар конгрессы оешу милләт эшләрен җайга салуда

нык ярдәм итте. Күп вакытта дәүләт эшли алмаганны шушы оешмалар эшләде, Татарстан җитәкчеләре әйтә алмаган сүзне Мәскәүгә алар әйтте. Бу урында Милли Мәҗлестә һәм Бөтендөнья татар конгрессында төрле елларда җитәкчелектә булган милләтпәрвәрләрне дә санап үтәргә кирәк:

**Тәлгат Абдуллин** — Милли Мәҗлес рәисе (1992—1994 еллар).

**Фәүзия Бәйрәмова** — Милли Мәҗлес рәисе (1994—1997 еллар).

**Айдар Хәлим** — Милли Мәҗлес рәисе (1997—2001 еллар).

**Габдулла Галиулла** — Милли Мәҗлес рәисе (2004 елда сайланды).

**Индус Таһиров** — Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты рәисе (1992—2002 еллар).

**Ринат Закиров** — Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты рәисе (2002 елда сайланды).

Татар халкы, Татарстан бу елларда гамәлдә тулы бәйсезлеккәирешә алмаса да, теоритик яктан ул үзенең киләчәген югарыда телгә алган кануннар, декларация һәм референдум нәтиҗәләре белән ныгытып куйды. Хәзер аларны тормышка ашыру — киләчәк эше, яңа буыннар өчен көрәш мәйданы. Бу елларда татар халкының яңа милли идеологик нигезе булдырылды, Татарстанда меңнәрчә мәчетләр, дини уку йортлары, йөзләрчә татар мәктәпләре һәм гимназияләре ачылды, югары уку йортларында өлешчә булса да татарча укытыла башланды. Дөрес, болар безгә аз тоела, әмма нәрсәдән башлаганны онытмаска кирәк. Моннан 15 ел элек урамда үз телендә сөйләшергә куркып торган татарлар бүген балаларына, оныкларына туган телне өйрәтә, васыять итә. Иң мөһиме, татарда милли аң уянды, ул хәзер үзенең борынгы тарихы белән кызыксына, күпләр аны өйрәнә, белә, бу бөек тарих белән лаеклы рәвештә горурлана. Татар халкының дингә омтылуы, Россиядә һаман имам милләт булып торуы да игътибарга лаек. Татар бугазыннан Кырымгача меңләгән мәчетләрне һаман татарлар салдыра, татарлар тота. Ислам илләрендә дә һаман иң күбесе татарлар укый. Тарихта туган форсаттан файдаланып, татар халкы үзенең бәхете, теле, дине, иреге өчен көрәшүен дәвам итә. Туфаннан исән калып, бөтен дөньяга таралган татарлар — Нух пәйгамбәр варислары — тере суы эчкән мәңге тере милләт. Аларның кан тамырларында җиһан ирләре Баһадиршаһ, Атилла патша, дөньяны тетрәткән һуннар һәм скифлар, Чыңгыз хан, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы каһарманнарының гайрәтле каннары ага. Бүгенге татарларның хәтер күзәнәкләрендә Батырша мулла, Солтан Морат, Бәхтияр Канкаевларның ил, милләт өчен күрсәткән батырлыклары турында хатирәләр саклана. Мең елдан артык ислам динен тоткан бу милләт, Идел-Кама буйларына тезләнеп намаз укыган, дин өчен үлемгә дә барган бу татарлар җаннарында әле һаман иман нурын саклыйлар. Ул изге нурны урыс балтасы да, Мәскәүнең утлы кораллары да, басып алулар, суга батырулар, телләрне, башларны өзеп алулар да юк итә алмады — әлхәмдүлиллаһ, татар һаман азан әйтә! Шулай булгач, кем кемне җиңде? Мең еллар буе әле Кытай, әле урыс тегерменендә тартылып та, без, татарлар, һаман яшибез икән, һаман Аллаһ биргән татар телебездә сөйләшәбез икән, һаман дөньяның уртасына басып, ислам динен тотабыз икән, димәк, без, чыннан да, бөек милләт, мәңгелек милләт!

Таралып яткан Татар иле… Кытайдан Кавказларгача сузылган татар җирләре… Аларны бүген җиһан югарылыгыннан гына карап, бер карашка сыйдырырга була… Кайчандыр шуларның барысына да безнең татар бабаларыбыз хуҗа булган бит! Бүген без чит кавемнәрнең җимергеч тәэсире астында яшәргә мәҗбүрбез. Телебез, динебез, ирегебез өчен көрәшмибез икән, барысын да югалтуыбыз бар. Шуңа күрә без бүген яшьләргә татар халкының дәүләт бәйсезлеге өчен көрәшне васыять итеп әйтәбез. Татарның үз милли һәм дини дәүләте булырга тиеш!

Ул башка халык кул астында кол булып яшәү өчен туган милләт түгел! Без татар яшьләренә татар телен, татар тарихын, ислам динен әманәт итеп тапшырабыз, бәйсез Татар дәүләтен булдыруны васыять итеп әйтәбез.

Атлантида! Атлантида баткан,
Эз калмаган бөек халыктан…
Ә без — исән! Татар яши әле!
Без батырган саен калыккан!
Без батырган саен калыккан!!!

*2004 ел, июль ае*

# НУХ ПӘЙГАМБӘР КӨЙМӘСЕ

* * *

**…Тетрәде җирләр, ярылды күкләр, ике арада җилләр улады…**
**Астан ут бәрде, өстән су акты, беркайда качар урын калмады…**

**Ата — баланы, бала ананы күрер булмады, белер булмады…**
**Бер-берләренең басып башына исән калырга алар тырышты…**
**Әмма бу көндә качу юк иде, туфан суында бар да тончыкты…**
**…Тик сездән кала — сезгә Аллаһның рәхмәте инде —**
**Ышанган өчен, буйсынган өчен сезгә бирелде тылсымлы көймә…**
**Утта да янмый, суда да батмый, буйсынып бары Аллаһ иркенә,**
**Тылсымлы көймә килеп туктады күгәреп торган тауның читенә…**
**Сезнең өегез шушы тау булды, су белән бергә таудан төштегез…**
**Җирдә кешелек икенче тапкыр сездән таралды — шуны белегез!**
**Туран тавының ике ягында, карлы илдә дә, кайнар чүлдә дә**
**Аллаһ гыйлемен сез тараттыгыз, хаклыкны җирдә сез аңлаттыгыз…**
**Шуның өчен бит җирдә калдыгыз, туфан суыннан исән калдыгыз —**
**Аллаһ нәкъ сезне сайлаган өчен…**
**…Бу юлдан әгәр читкә чыксагыз — әгәр Аллаһны сез онытсагыз —**
**Тетрәнер җирләр, ярылыр күкләр, ике арада җилләр уларлар…**
**Астан ут бәрер, өстән су агар, беркайда качар урын тапмассыз…**
**Ата — баланы, бала ананы бар дип тә белмәс, газабын күрмәс…**
**Бер-берләренең басып башына, исән калырга алар тырышыр…**
**Әмма бу көндә котылу булмас, туфан суында бар да тончыгыр…**

Малай, кычкырып, урыныннан сикереп торды…

Тагы шул төш, тагы шул тавыш, тагы шул күренеш! Менә ничә көн рәттән ул шушы төштән интегә, әллә нинди куркыныч нәрсәләр күрә, һаман шушы бер үк сүзләрне ишетә… Әле аның өстенә су таулары ишелеп төшә, әле ул, әтисенең кулынаябышып, ниндидер көймәгә үрмәли… Өстә яшен яшьни, күкләр үкерә, аста җир улап яна, кешеләр ут белән су арасында бәргәләнә… Барысы да көймәгә ыргыла, әмма дулкын таулары аларны читкә алып бәрә, сытып китә…

Малай әтисенең кулына чытырдатып ябышкан, дулкын аларны читкә какмый, киресенчә, көймәгә таба куа… Менә инде алар сәер көймәнең эчендә… Ул бик зур, өсте тоташ каплаулы, су өстендә дә, су астында да йөзә алырлык икән… Аларның барлык туганнары да монда, әмма бер абыйлары гына юк… Бабасы котырынган су дәрьясы эченнән күзләре белән улы Түлгәнне эзли… Әнә ул туганнары, бата-чума, көймәгә тотынмакчы була, әмма дулкын аны якынайган саен читкә бәрә… Бабасы кулларын күккә күтәреп ялвара, әмма улына ярдәм итә алмый — егетне кара чоңгыл йота…

Каплаулы каек, аларны утыртып, төн караңгылыгына кереп югала… Алар бата-калка йөзәләр дә йөзәләр, бер су өстенә чыгалар, бер төпкә китәләр… Көймәнең аскы өлешендә — мал-туар, өске катында — кешеләр, кая барасыларын, кайчан туктасыларын белмичә, язмыш дәрьясы буйлап йөзеп баралар… Ә өстән, җиде кат күкләрдән, әнә шул дәһшәтле тавыш яңгырап тора…

**Тетрәде җирләр, ярылды күкләр, ике арада җилләр улады…**
**Астан ут бәрде, өстән су акты, беркайда качар урын калмады…**

Бу тавыш малайга таныш та кебек, таныш түгел дә… Ул әле бабасының тавышын ишеткән кебек була, әле ул тавыш әтисенеке булып тоела… Хәер, ул әтисенең тавышын онытып та бара инде… Аны күрмәгәненә дә биш ел… Ул мәктәпкә керәсе елны юкка чыкты әтисе. Армиядә хезмәт иткән җиреннән… Хәзер кайда икәнлеген беркем белми, хәтта бабасы да… Бәлки бабасы белә торгандыр да, әмма ул берни әйтми, һаман, барысы да Алла кулында, ди, бу хакта сөйләшми. Ә әбисе елый… Еламассың, ике улың берьюлы юкка чыксын әле. Җиһангир бабасы нидер белә инде, әйтми генә…

Малай инде төшен онытты, әтисе, әнисе турында уйлый башлады. Үзенең авылда торган чакларын исенә төшерде. Әй, күңелле чаклары бар иде аның! Аларның авыллары кебек авыл дөньяда тагы бармы икән? Малай ләззәтләнеп күзләрен йомды… Шуны гына көтеп торгандай, каршына Урал таулары йөгереп килеп басты… Аларның өйләре авылның иң читендә, кыя-ташлар асылынып торган тау буенда иде. Алар бабаларының бу иске нигезенә Аксудан, әби-бабалары яныннан күчеп кайттылар. Ул чагында малай кечкенә иде әле, әмма өй өстенә асылынып торган ул кара ташларны һаман хәтерли. Ул ташларга, чокып-чокып, нидер язылган иде… Әти-әнисе аны анда ялгыз гына җибәрмәскә тырышалар иде… Үсә төшкәч, күп менде ул теге кара ташлар янына, алардан бәреп торган кырыс салкынлык бераз шомландырса да, гел шунда бара иде… Ул ташлар малай өчен гаять серле булып тоела иде, әйтерсең лә алар күктән төшкән һәм Атасал авылы башына утырып калган… Аларның җаны, хәтта телләре бар кебек тоела иде малайга. Әмма, бу язулы ташларның яшерен серен белер өчен, аның үзенә үсеп җитәргә кирәклеген, язмышның аның өчен зур сынаулар әзерләгәнен ул белми иде әле… Үзенең төшендә күргән серле көймәне эзләп табасын, аңа утырып, дөньяның читенә китәсен дә белми иде әле бу малай… Аның әле бу дөньяда Урал тауларыннан кала берни дә күргәне юк иде шул…

Аңа эти-әнисе бик сәер, кешедә юк исем кушканнар: Әтил. Үскәч, Бәндәбикә әбисеннән генә ишетеп белде ул, Әтил — бик борынгы исем икән, элек Идел суын шулай атап йөрткәннәр. Урал тауларының үзәгеннән башланган Агыйделне дә Идел-Әтил дип атап йөрткәннәр. Әле бик борынгыда, татарларның һуннар дип аталып йөртелгән заманнарда ук, Атилла дигән патшалары да булган, монысын этисе сөйләгән иде. «Атилла кебек батыр булырсың, улым, татарларның данын яңадан кайтарырсың!» — дия иде… Урал тауларына менгән саен, кыя-ташларга утырып, этисе аңа шундый берәр нәрсә сөйли иде… Их, хәзерге вакыты булса Әтилнең, этисенең һәр әйткәнен тыңлап кына түгел, язып барыр иде! Шул хәтле күп аның этисенә сораулары, тик ул юк шул, моннан биш ел элек Чечняда юкка чыкты… Уралда туды, Кавказда югалды…

Кавказ таулары исенә төшүгә, Әтилнең күз алдына тагы әле генә күргән төше килеп басты… Ул, бик тырышып, нәрсәнедер исенә төшерергә азапланды, әмма хәтерли алмады… Тукта, хәтерләде, хәтерләде! Әтисе солдат хезмәтеннән җәйге ялга кайткан вакыт иде, Атасалга кунакка Бәндәбикә әби дә килгән иде. Бәндәбикә әби — Җиһангир бабасының бертуган апасы, шушы Атасалда туып үскән, хәзер Каһарман авылында яши. Бәндәбикә әбисенең дөньяда белмәгән нәрсәсе юк, ул әкиятләр, бәетләр, әллә нинди борынгы тарихларны Әтилгә көне-төне сөйли торган иде. Әле дә хәтерли Әтил — Бәндәбикә әбисе аңа Нух пәйгамбәр көймәсе турында тарих сөйләде. Әтисе, әнисе дә шунда иде Әтилнең. Авыл янындагы биек тауда, язулы кара таш-кыя янында сөйләгән иде Бәндәбикә әбисе ул хикәятне. Әтил аны тетрәнеп, куркып тыңлаган иде…

«Кайчандыр, бик борынгы заманнарда, кешеләр бик бәхетле яшәгәннәр,— дип сөйләгән иде Бәндәбикә әбисе.— Алар бик зур гәүдәле алыплар булганнар, бу таулардан атлап кына йөргәннәр… Менә мондый зур-зур карагай агачларын төбе-тамыры белән йолкып кына ала торган булганнар… Аллаһ, аларга рәхәт яшәсеннәр өчен, иксез-чиксез җирләр, хисапсыз киек җәнлекләр, кош-корт биргән… Җирләр алтын-көмеш белән тулы булган… Кешеләр озак яшәгәннәр, авырмаганнар, мең яшькә хәтле җиткәннәр… Шушы нигъмәтләр өчен Аллаһка рәхмәт әйтеп яшисе урында, кешеләр аны оныта башлаганнар, азганнар, тузганнар, төрле сыннарга табынырга тотынганнар, бик-бик явызланганнар… Аллаһ боларны күреп торган һәм кешеләрнең үзләре арасыннан иманга чакырырга бер изге бәндәне билгеләгән. Нух пәйгамбәр булган ул. Ул үзенең кавемдәшләрен көне-төне иманга чакырган, Аллаһның барлыгын һәм берлеген исләренә төшерергә тырышкан, азгынлыктан тыелырга чакырган. Әмма кешеләр аны тыңламаганнар, кычкырып көлгәннәр генә… «Без бу рәхәт тормышка үзебез көчле булганга ирештек, безне юк белән куркытма!» —дигәннәр… Нух пәйгамбәр аларны һаман иманга өндәвен дәвам иткәч, кешеләр аны тотып кыйнаганнар, тагы юк-бар сөйләп йөрсәң үтерәбез, дигәннәр. Шуннан соң Нух пәйгамбәр, ярдәм сорап, өмет итеп Аллаһка мөрәҗәгать иткән. Аллаһ аңа бер көймә ясарга кушкан, тиздән дөньяны су басасын, аның һәм иман китергән кешеләрнең, шушы көймәгә утырып, исән каласыларын белдергән. Нух пәйгамбәр көймә ясый башлаган, кешеләр аннан көләләр икән, пәйгамбәр балта остасы булды, дип… Көймә ясалып беткәч, җир астында ут кайный башлаган, өстән коеп-коеп яңгыр яварга тотынган. Дөньяның асты-өскә килгән — туфан башланган… Нух пәйгамбәр һәм аның гаиләсе, бер хатыныннан һәм улыннан калганнары, көймәгә кергәннәр, алар белән бергә бу салга иман китергән берничә кеше дә кергән. Һәр төрдән берәр пар мал-туар да кергән көймәгә… Калган бөтен кеше туфан суында батып үлгән… Ә бу көймә исә, бик күп вакытлар суда йөзеп йөргәннән соң, Аллаһ аны бер тау янына туктаткан, тоташ су эченнән шул тауның башы гына күренеп торган, ди. Алып кешеләр шунда төшеп, яшәп киткәннәр. Без шулар нәселен дәвам итәбез икән, шуңа күрә безнең авыл да Атасал дип атала икән… Ягъни Ата салына, көймәгә утырып исән калганнар нәселе һәм авылы…»

Әтил әле дә хәтерли — шунда Бәндәбикә әби белән Әтилнең эти-әнисе арасында бераз бәхәс тә булып алган иде. Әтилнең әнисе:

— Нух пәйгамбәр көймәсен Кавказда, Арарат тауларында туктаган, дип яза бит китаплар,— дигән иде.

Моңа исә Әтилнең этисе каршы төшкән иде:

— Нух пәйгамбәр көймәсенең кайсы тауда тукталганын беркем дә төгәл белми,— диде ул.— Кавказдамы, Алтайдамы әллә инде башка урындамы… Әмма безнең нәсел шәҗәрәләре Нух пәйгамбәрдән башлана — анысы бәхәссез… Болар — меңәр еллар буе телдән телгә күчеп, ташларга чокып язылып, бозау тиреләрендә, каен тузларында, соңрак саргайган кәгазь битләрендә сакланган нәсел тарихлары…

— Әмма аларда Нух пәйгамбәр көймәсе биредә — Урал тауларында туктаган, дигән сүз юк бит,— дип, каршы төшкән иде әнисе ул чагында.

— Моны бер Алла гына белә инде, Туран улым, сүз көрәштермик,— дип, аларны бик тиз туктаткан иде Бәндәбикә карчык…

Әтисе хәзер янында булса, үзенең бу төшен иң беренче булып Әтил аңа сөйләр иде. Оялып та тормас иде, чөнки әтисенең аннан көлмәгәнен белә Әтил. Урал тауларының да бик күп серләрен белә иде ул, татар тарихының да. «Боларны сөйләсәң дә, язсаң да, ышанучы, аңлаучы булмаячак,— дия иде ул Әтилгә еш кына.— Безнең тарих шулкадәр зур, улым, әнә шул Урал таулары кадәр… Аны беркемнең дә безгә бирәсе килмәячәк… Көрәшеп алмасаң…»

Аның әтисе белән дә, әнисе белән дә Уралтауның түбәсенә үк менгән чаклары булды… Ә аннан инде бөтен дөнья күренә! Тик бөтен дөньяда — уңда да, сулда да, алда да, артта да — таулар, таулар, таулар… Берсе бетә, икенчесе башлана, аларның кайсы урман белән, кайсы тоташ таш кыялар белән капланган… Кайсыларының түбәләре каралып, очлаеп тора, кайберләрен җил-яңгыр ашап, түгәрәкләп, шомартып бетергән… Ә аяк астында нинди генә матур ташлар юк! Ниндиләрен генә җыймый иде Әтил ул Урал ташларының — зәңгәрсу-караларын да, диңгез суыдай яшькелтләрен дә, нәфис алсу-акларын да, сарыларын, көрәннәрен, хәтта кызгылтларын да! Авылда малай яши торган бөтен өйләре, чоланнар, хәтта ишегаллары да шул матур ташлар белән тулган иде. Авыл малайлары таш җыймый икән, алар аннан: «Тиле таш җыя»,— дип көләләр генә иде… Ә үзләре аның ташларына барыбер кызыгып, көнләшеп карыйлар иде…

Шундый матур авылны, Урал тауларын ташлап, әнисе нигә аны монда алып килде икән? Монда, кайсы тәрәзәдән карасаң да, завод торбалары, кап-кара төтен, тау да юк, урман да юк… Урам тулы кеше, барысы да ашыга, карап йөрмәсәң, өстеңә менеп китүләре дә бар… Әле ярый укый торган мәктәбе якын, юл аша чыгасы түгел, җәяү генә йөгереп барып кайтасы… Мәктәпне дә яратып бетерми Әтил, башта урысча өйрәнә алмый интекте, шуның өчен гел көлделәр, мыскыл иттеләр, әле «Бабай» дип, әле «Малай» дип үртәделәр… Үзен яклап, кара-каршы сугыша башлагач кына бәйләнүдән туктадылар. Аннан урысчага да өйрәнде, үзе кебек татар малайларын да тапты, бергәләп, бер-берләрен яклый башладылар… Бу шәһәрдә татарлар күп, әнисе, утыз меңнәр булыр, ди. Әмма татар мәктәпләре юк, шуңа күрә әнисенә эш тә юк. Татарча балалар укытасы урында, ул хәзер яңа байларга, төрле оешмаларга ашарга пешереп йөри… Әтисе булса, аларны бу хәлдә яшәтмәс иде, әлбәттә, монда тотмас та иде, Ырынбурга алып китәм, дигән иде бит башта ук… Әтисе кайтса, бу зур шәһәрдә аларны ничек эзләп табар икән? Кайтса, башта Аксуга, бабаларына кайтыр инде ул, аннан аларны эзләп табар… «Татарчаңны онытма,— дигән иде аңа әтисе, солдат хезмәтеннән ялга кайткач.— Кайда гына яшәсәң дә, үзеңнең татар икәнеңне, мөселман кешесе булуыңны онытма. Кайтуга, беренче сораган сүзем шул булыр, белеп тор…»

Тукта, ә теге… төштә ишетелгән тавыш, ул кайсы телдә иде соң? Русча түгел дә түгел инде, ә башка чит телне малай белми. Ә ул нәрсә әйткәннәрен аңлады бит, аның бөтен сүзләре дә татарча кебек иде. Әллә түгелме? Менә ничә төн рәттән аңа кайсы телдә әллә нәрсәләр сөйлиләр соң?

Әтил төштә ишеткәннәрен исенә төшерергә тырышып карады… Төш инде, томан кебек таралып, юкка чыга башлаган иде… Сүзләре дә хәзер андый кырыс тәртип һәм дәһшәт белән яңгырамый, алай да куркыта, искә төшкәч үк калтырата…

**Тетрәде… җирләр, ярылды… күкләр…**

Әйе, җирләр, күкләр диделәр шул, татарча әйттеләр, башка сүзләре дә татарча иде, әмма… шигырь кебек… көйле… Бабасы Җиһангир картның, әбисе Җанбикәнең сөйләшенә бераз тартым кебек, бабасының апасы Бәндәбикә әби сөйләгәнгә дә охшаган… Әмма Бәндәбикә әбисе дә, әтисе дә болай куркыныч итеп сөйләмәгәннәр иде бит, Әтил аларны әкият тыңлаган кебек кенә тыңлаган иде. Ә төшендә җир белән күкләр үкереп, актарылып торды, югарыдан кургаш кебек сүзләр агылды… Менә хәзер, исенә төшергәч тә, тәннәре кымырҗып, өшеп киткән кебек булды. Әллә нинди куркыныч тавыш, куркыныч төш иде бу! Әбисенә сөйләсәң, ул аңлатыр иде инде нәрсә икәнен, әмма әбисе дә ерак шул, Урал тауларының теге ягында, көн дә барып йөреп булмый…

«Их, эти булса!» — дип уйлап куйды малай, сыкранып. Әтисе булса, әллә кайчан аны әбиләренә илтеп куяр иде инде, җәйге каникулда бу таш шәһәрдә яткырмас иде. Йә авылга, Атасалга алып кайтыр иде… Дөрес, ул өй инде шактый искергән, әмма җәй көне рәхәтләнеп торырга була әле анда. Зуррак булса, ул үзе кайтып өйне рәтләр иде, әмма әтисеннән башка ул анда берни эшли алмый шул әле. Бабасының да, нигәдер, Атасалга кайтып торасы килми, Аксуда аның үз өе, үз эше, үз мәшәкатьләре… Һәркемнең үз эше, анда гына беркемнең дә эше юк кебек… Хәер, әби-бабасы турында ул алай уйлый алмый, алар аны да, әнисен дә гел чакырып торалар. «Монда гына яшәгез»,— диләр. Әнисе риза түгел, «Безнең үз тормышыбыз булырга тиеш»,— ди. Әнисенең әйтүе буенча, хәзер алар яшәгән Тимертау шәһәре Аксуга караганда күпкә зуррак икән, монда укырга керергә дә, эшкә урнашырга да җайлырак булачак. Укырга керү — кайчан әле ул? Әтил белә — әнисе Аксуга кайтырга курка, чөнки анда әби-бабасы түгел, әтисенең игезәк туганы Түлгән хуҗа. Дөрес, ул да хәзер өйдә юк, аның да кайда икәнен белүче юк, әмма ул теләсә кайсы вакытта кайтып керергә мөмкин. Малай әле кечкенә чагында, аның

эти-әнисе, шул Түлгән белән тыныша алмыйча, Аксудан чыгып киткәннәр бит, Атасалдагы иске нигезгә кайтып егылганнар… Шуның аркасында этисе юкка чыккач та, алар Аксуга түгел, менә бирегә килеп урнаштылар. Әмма аларның биредә бернинәрсәләре дә юк, менә бу квартираны да алар акча түләп, вакытлыча гына алып торалар. Шуңа түләү өчен, әнисе берничә җирдә эшли, шуның өчен аны да җәйләрен бер җиргә җибәрми, чөнки Әтил дә аңа ярдәм итә, вак-төяк эшләрен эшләп тора…

Шулай уйлауга, малай урыныннан сикереп торды. Урал таулары да, авыл да, әби-бабалары да, хәтта теге куркыныч төш тә сыпырып алгандай юкка чыкты. Ул бит әле әнисе әйтеп калдырган эшләрне эшләмәде! Ике чиләк бәрәңге әрчеп куярга, бер тау кишер чистартырга, чөгендер пешерергә, суган әрчергә… Әнисе өйдә өйлә ашы әзерләп, шуны төрле оешмаларга таратып чыгарга тиеш. Иртәнге якта ул базарда була, ризыклар ала, ә Әтил ул кайтышка әйткәннәрен эшләп куя. Чөнки ул күрә бит: әнисенең үзенә генә бик авыр, кичләрен ул утырган урыннан йокыга китә… Ә кайчан гына Урал тауларының башына йөгереп менә иде бит ул!

Әтил, ашыгып, сәгатькә карады һәм җиңел сулап куйды: юк, әле соң түгел икән, әле өйләгә хәтле бик күп вакыт бар. Ул тынычланып китте, әнисеннән калган чәйнек әле суынмаган иде — утырып чәй эчте. Аннан шкафка тезеп куйган ташлары янына килеп, алар белән бераз кайнашып алды. Әтил алар янына көненә әллә ничә килә, алар белән сөйләшә, киңәшә… Аларның кайсы боз кебек сап-салкын, кайсылары җып-җылы, кулга рәхәт… Кайсылары шоп-шома, ә кайсылары чокыр-чакырлы, кытыршы… Алар да малайны таныйлар кебек, әйтерсең лә аның якын килгәнен көтеп кенә торганнар, кулга алуга, сөенеп, аның учына сыендылар, үзләренчә, кыштырдый, пышылдый башладылар… Әтил аларны колакларына да куеп тыңлап карады… Эчтән жу-у-у итеп, гүләп торалар, яз көне Урал суы ташыган кебек… Су, диюгә, малайның күз алдыннан тагы тау-тау дулкыннар, бата-чума йөзгән кешеләр, ялгыз көймә чагылып үтте… Әйтерсең лә аның учларына сеңгән Урал ташлары да шул хакта сөйли иде… Әйтерсең лә Урал ташларының да үз хәтерләре бар иде…

Урал ташлары…

Ә нигә Урал ташлары? Төшендә бит аңа Туран таулары турында әйттеләр… Ә дөньяда Туран таулары барлыгын Әтил бөтенләй белми, ул Урал тауларын гына белә… Туран — аның этисенең исеме бит ул, борынгы Туран иле исеменнән алып куелган, бабасы шулай дигән иде. Ә төшендә «Туран тавы» диделәр бугай шул, Урал димәделәр…

Малай, исенә төшерергә тырышып, кашларын җыерды, күзләрен йомды. Хәтер күзәнәкләре уянып, тагы шул сүзләрне кабатлый башладылар…

**Туран тавының ике ягында, карлы илдә дә, кайнар чүлдә дә**
**Аллаһ гыйлемен сез тараттыгыз, хаклыкны җирдә сез аңлаттыгыз…**

Туран тавы…

Нинди тау икән соң ул — Туран тавы? Әллә Әтил белми генәме, бәлки бу хакта мәктәп дәреслекләрендә бардыр? Быел тарих дәресендә бу хакта аларга нидер сөйләделәр дә бит, әмма аны легенда, әкият, диделәр, шуңа күрә Әтил бик игътибар да итмәгән иде. Имеш, кайчандыр дөньяны су баскан, көймәдә берничә генә кеше исән калган… Дөньяда бөтен кешелек икенче тапкыр шулар нәселеннән дәвам итә икән… Укытучы әкият дигәч, Әтил үзенең бу хакта инде белүен әйтергә оялды. Бәндәбикә әбисе моннан да остарак итеп, бик җентекләп сөйләгән иде бит дөньяны су басу турында. Әмма ул аны әкият димәгән иде. «Безнең Нухайлар нәселе шуннан китә»,— дигән иде. Бу турыда мәктәптә әйтсәң кычкырып көләрләр, этисе дә әйткән иде бит: «Татар тарихы Урал таулары хәтле булса да, аңа беркем ышанмаячак»,— дигән иде… Көлкегә калмас өчен, дәрес вакытында Әтил бу хакта белүен әйтмәде, ә соңыннан онытты. Ничә көн рәттән, кат-кат төшенә кереп, исенә төшермәсәләр, ул инде туфан суы турында да, нииндидер Туран таулары, тылсымлы көймә турында да инде оныткан булыр иде… Әмма аңа, нигәдер, онытырга ирек бирмиләр, гел исенә төшереп торалар… Болар әкият түгелме икәнни? Чыннан да, кайчандыр дөньяны туфан суы басканмы? Берничә кеше шуннан көймәдә котылып калып, дөнья яңадан шулар нәселеннән дәвам иткәнме? Кемнән сорарга икән бу турыда? Тукта, ул дәреслекләр тапшырылмады бит әле, тарих китабының шул җирен генә ачып карасын. Әле бәрәңге әрчергә, чөгендер пешерергә вакыт бар, ул тиз генә, карап кына ала…

Әтил учындагы ташларны тиз генә урынына куйды да шкафның икенче бүлегеннән дәреслекләрен карый башлады. Менә тарих китабы, менә аның туфан суы турындагы урыны… Әтил аны, тын да алмыйча, бер сулышта укып чыкты. Укыган саен, аның гаҗәпләнүе арта гына барды, әкият чынга әйләнде, чынбарлык әкият кебек күренә башлады…

«Адәм белән Һаваның күп санлы балалары, балаларының балалары туган,— дип язылган иде 6 нчы класс өчен борынгы заман тарихы китабында.— Кешеләр җирдә таралып яши башлаганнар. Тормыш җиңел булмаган, ризыкны авыр хезмәт белән тапканнар. Кешеләр начарлык, хәтта җинаятьләр эшли

башлаганнар. Адәм белән Һаваның олы улы игенче Каин үзенең энесе терлекче Һабилне үтергән, шулай җирдә явызлык арткан. Шунда Алла, бөтен дөньяны су басу (туфан) оештырып, тереклекне юк итәргә уйлаган. Бары тик Ной (Нух) исемле бер игелекле кешене генә кызганган. Алла кушканча, Нух зур көймә төзегән. Шунда ул хатынын, өч малаен, аларның хатыннарын, һәр төрле җәнлектән берәр пар алган. Яңгыр кырык көн яуган. Бары тик Арарат тавының түбәсе генә судан күренеп торган. Нухның көймәсе шунда барып терәлгән. Көймәдәгеләрдән кала, бөтен кеше һәлак булган. Хәзер дөньяда яшәүчеләр шуларның нәселләреннән инде».

Бу язманың башына «Дөньяны су басу турында миф» дип куелган иде. Әтил тиз генә әнисенең студент елларыннан калган сүзлекне алып карады. «Миф — аллалар, легендар батырлар һәм дөньяның, җирдәге тормышның килеп чыгуы турында борынгы халык әкиятләре» диелгән иде анда. Икенче бәя тагы да кискен иде: «Фантастик әйбер, уйдырма, хыялый нәрсә; чынбарлыкка туры килми торган караш» дип кистереп әйтелгән. Менә ни өчен укытучылары бу турыда өстән-өстән генә сөйләп үткән икән! Хәер, һәр көн саен төшләренә кереп интектермәсә, Әтил үзе дә бу хакта күптән оныткан булыр иде инде. Ә төшендә күргәннәр, менә бу китапта язылганнар, Бәндәбикә әбисе сөйләгәннәр барысы да туры килә бит, бер дә әкияткә охшамаганнар. Әкият, гадәттә, матур бетә, ә бу — куркыныч, дәһшәтле, шомлы хәлләр… Әйе, ул төшендә дә нәкъ шулай күрде: дөньяны су басты, кешеләр батып үлделәр, бер нәсел генә исән калды… Чөнки аларның тылсымлы көймәләре бар иде… Тарих китабында Нух диелгән, ә төшендә ул урында аның әтисе иде… Аның игезәк туганы Түлгән көймәгә утыра алмыйча батып үлде. Китапта: «…көймә Арарат тауларына килеп туктады»,— диелгән, ә ул төшендә көймәнең Туран тауларына килеп туктавы турында ишетте… Аның бер генә китабында да, географик карталарда да Туран таулары күрсәтелмәгән, димәк, ул юк… Арарат таулары да әллә кайда,—әбисе әйтмешли, Кафтау артында… Димәк, тарих китабында дөрес язылган, укытучысы дөрес әйткән, бу —уйдырма, әкият кенә икән… Ә төшләре… алар саташу гына. Әнисе кайткач, аннан төш сорамас, бәрәңге, кишер турында сорар. Аның кәефен бозмыйча, әйткәннәрен тизрәк эшләп куярга кирәк.

Ул, китабын ташлап, кухняга керергә өлгермәде, ишектә, сискәндереп, кыңгырау чылтырады. Кем булыр икән бу? Әллә әнисе шулай иртә кайтып җиткәнме? Алай дисәң, аның үзенең ачкычы бар бит, ул үзе Әтилнең өстеннән бикләп чыга, ачып керә, шылтыратып тормый.

Ул арада кыңгырау тагы да кискенрәк, озаграк чыңлап алды. Малай, батыраеп, ишек янына килде.

— Кем бар? — диде ул, тавышын мөмкин кадәр олыларга охшатырга тырышып.

— Почта. Телеграмманы алып калыгыз,— диде ишек артындагы тавыш.

Әнисе үзе югында ишекне беркемгә дә ачмаска кушса да, Әтил ишек төбеннән борылып китә алмады. Ә бәлки әтисеннән берәр хәбәр бардыр? Юктыр, әтисе аларның кайда торганнарын белми бит. Аларның кайда торганнарын әби-бабалары гына белә, бәлки алардан берәр хәбәр бардыр? Ишек артында хатын-кыз тавышы, ә ул егет башы белән куркып ачмый торсынмы? Ул бит телеграмманы, ишекне ачып бетермичә, чылбыр аша гына да ала. Әтил, ишеккә эленгән тимер чылбырларга чорнала-чорнала, әллә ничә төрле ачкычны борып, хат ташучыдан телеграмманы алып калды. Телеграмма, чыннан да, Аксудагы әби-бабасыннан иде. Анда кыска гына итеп: «Тиз кайтып җитегез, әбиегез авыр хәлдә»,— дип язылган иде.

Малай урындыгына барып утырды. Күз алдына Җанбикә әбисе килеп басты. Гаҗәеп изге күңелле, йомшак, җылы куллы, Әтилне һәрвакыт тәмле ризыклар белән сыйлый торган Җанбикә әбисе… Нәрсә булган аңа? Әллә…үлгәнме икән? Бу уеннан малай үзе үк куркып куйды. Юк, юк, аның әбисе алай ук карт түгел бит әле, җитмеше дә тулмаган. Бабай аннан картрак, Бәндәбикә әбисе бөтенләй дә карт, әмма барысы да йөгереп йөриләр. Җанбикә әбисе соңгы вакытта еш авырый башлады, ике игезәк улы берьюлы юкка чыккач, бөтенләй бетеренде. Бер-бер хәл булмаса, бабасы бер дә юкка аларны борчымас иде, болай телеграммалар сугып, аның әле аларны беркайчан да чакырып кайтарганы булмады.

Малай уйга калды…

Аксуга автобуслар йөреп тора, әмма әнисе эшеннән китә алырмы? Аның бит кешеләрне ашатасы бар. Ул хәзер бу бәрәңгеләрне чистартып куярга тиешме икән инде? Бәлки әнисе кайтуга ук, Аксуга китеп барырлар? Бәлки әбисе анда үлеп ятадыр, кеше ашатасы бар, дип кайтмый калып булмый бит инде. Юк, әнисе шунда ук кайтырга җыеначак, ул да аларны бик ярата һәм кызгана бит. Әтисенең игезәк туганы Түлгәннең кыланышлары булмаса, алар Аксудан китмиләр дә иде бит. Һаман бергә-бергә яшәп ятарлар иде әле… Түлгән абыйсы үзе дә кеше кебек яши белмәде, башкаларга да ирек бирмәде, әнисенең әйтүе буенча, алардан кара көнләшү белән көнләште. Хәзер менә икесенең дә кайда икәнлекләрен белүче юк. Әбисе шулар кайгысыннан авырый да инде…

Уйга мавыгып китеп, малай әнисенең кайтып керүен сизми дә калды. Әнисе керә-керешкә бер кухня ягына, бер урындыкта утырган улына карап алды. Башка вакытта аны кухняда су аккан, савыт-саба шалтыраган тавышлар, ризык исе

каршы ала иде, бу юлы исә өйдә тып-тыныч, әүлы урындыкта боегып утыра иде. Кулынданиндидер кәгазь. Аның йөрәге кысылып, чәнчешеп куйды, әллә иреннән бер-бер хәбәр бармы?

— Әби авырып киткән, әни, тиз кайтырга кушканнар,— дип, малай телеграмманы аңа бирергә ашыкты.

Әнисе эшне тиз аңлады. Телеграмманың көнен, сәгатен-вакытын карады, берни әйтми, уйланып торды. Аннан, ниндидер карарга килгәндәй, ашыгып кына кухняга кереп чыкты, таратып ташлаган ризыкларын барлады.

— Кайтырбыз, улым,— диде ул, тиз-тиз алып кайткан әйберләрен урнаштырып.— Ризыкларга тотынмыйча, дөрес эшләгәнсең, әрәм булмасыннар... Китешли эшкә кереп, әйтеп чыгарбыз — бу көннәрдә мине көтмәсеннәр, башка җирдә ашау оештырсыннар... Хәл авыр булмаса, бабаң телеграмма сукмас иде... Инде бер-бер хәл генә булмасын... Өлгерсәк кенә ярар иде, улым...

Әнисенең каушавы, борчылуы малайга да күчте. Ул әбисен әле үлгән итеп, әле җан биреп яткан кебек күз алдына китерде. Бу кайгылы күренештән аның тамагына төер утырды, борыны йомшарып чыкты, күзләренә яшь килеп тыгылды.

— Йә, йә улым, сабыр ит,— диде әнисе, аның йомшара баруын күреп.— Бәлки әле алай ук куркыныч хәл дә түгелдер, авырып кына киткәндер... Үзең беләсең, ул хәзер еш авырый бит... Әллә кайчан кайтып киләсе калган аны, җәйгә керү белән үк... Эш дип, бөтенләй бетәбез инде...

Алар тиз генә җыендылар да ишекне бикләп, чыгып та киттеләр. Малай, нигәдер, каерылып-каерылып, үзенең ташларына, китапларына, бүлмәсенә карады... Ул үзенең бу йортка яңадан беркайчан да әйләнеп кайтмаячагын белми иде әле... Иртәнге төше төш кенә булмыйча, алда күрәчәкләренә кисәтү дә икәнлеген Әтил исемле татар малае белми иде... Ул, үзенең җиде кат җир асларына төшеп, җиде галәм серләрен ачасын да белми иде... Ул Агыйдел башына урнашкан Аксу шәһәренә, Урал тауларының иң биек түбәсенә таба кайтып бара иде... Бу юлдан җитәкләп, аны язмыш үзе йөртә иде...

* * *

Алар кайтып кергәндә, Җанбикә карчыкны кыйблага таба борып куйганнар иде инде...

Тик өйдә бабалары Җиһангир карттан кала, беркем дә юк, андый вакытта була торган күрше-күлән, карт-карчыклар да күренми иде. Карчыгы янында бер көйгә «Ясин» чыгып утырган карт аларның килеп керүен сизми дә калды, ахры, укуын туктатмады. Малай белән ана ап-ак булып сузылып яткан карчык янына килеп бастылар, бу хәлне күреп, шыпырт кына еларга тотындылар.

— Ә-ә, Сәрмәния килен, Әтил улым, кайттыгызмы?

Карт, урыныннан кузгалып, алар янына килде. Аның кыяфәте, нигәдер, бик кайгырганга охшамаган иде.

— Нәрсә булды соң, эткәй? — дип өзгәләнде килене Сәрмәния.— Нигә әнкәйнең авырганын алданрак әйтмәдегез... Бәхилләшеп тә өлгерә алмадык бит менә... Мәете өстенә кайтып кердек, и Аллам!

Җиһангир карт аңа сәер генә карап куйды. Аннан аларны карчыгы яныннан читкәрәк алып китте.

— Үлмәгән ул, кызым, борчылма,— диде ул шыпырт кына.— Әбиегез мәрткә киткән... Элек тә аның белән андый хәлләр булгалый иде, кешегә әйтеп тормый идем... Бу юлысы менә озагракка китте, үзем дә курка калдым, шуңа күрә сезне дә чакыртырга булдым.

Ана белән малай, гаҗәпләнеп, бер-берләренә караштылар, аннан, ашыгып, Җанбикә карчык янына килделәр. Җанбикә карчык, мәет кебек ап-ак булып, сузылып, тын да алмыйча ята иде. Җиһангир карт та алар янына килеп басты. Өстәл өстеннән бер түгәрәк көзге алып, Җанбикә карчыкның борын астына куеп карады — көзге парланып чыкты.

— Менә бары тик шуннан гына беләм мин аның исән икәнлеген,— диде Җиһангир карт.— Йөрәк тибеше дә сизелми аның, сулышы да ишетелми... Мәет инде, беткәнче мәет... Теге заманнар булса, шулай күмеп тә куярлар иде...

— Врач чакырттыгызмы соң? — дип сорады килене Сәрмәния, шиккә калып.— Бигрәк җан әсәре юк бит. Бәлки уятып карарга, нәрсәдер эшләргә кирәктер?

Карт кискен генә баш чайкап куйды.

— Бераз көтик,— диде ул, карчыгының салкын кулларын учына алып.— Белер-белмәс кагылып, чынлап та үтереп куюыбыз бар.

Әтил әле һаман берни аңламый иде. Әбисе үлгән дә кебек, үлмәгән дә икән... Ничә көн шулай яшәү белән үлем арасында ята икән соң ул? Ашамыйча-эчмичә ничек түзә икән?

— Бабай, әби ничә көн шулай үлгән кебек ята соң ул? — дип сорады Әтил, гаҗәпләнеп.

— Өч тәүлек була инде, улым,— диде карт, аны үз урынына утыртып.— Өченче көн ахшам намазы укыганнан соң, һаман тормый бу. Мин аны башта шулай озаклап дога кыла дип торам. Йорт-җирләрне

дә бер урап кердем — әбиең һаман утыра, яны белән диванга сөялгән… Нидер булганын мин аңладым инде, элек тә шулай булгалаганы бар иде. Әкрен генә урынына илтеп салдым… Икенче көнне дә уянмый бу, өченче көнне дә… Иртәгә дә уянмаса, врач чакыртмыйча булмас инде… Уен эш түгел бит…

Шулай диде дә Җиһангир карт намазга әзерләнә башлады. Алар карчыгы белән шактый еллар инде бергәләп намаз укыйлар, Җиһангир карт Казанга барып, берничә ел читтән торып мәдрәсәдә дә укып йөрде. Хәзер ул әнә каршыдагы агач мәчеттә казый булып тора, азанын әйтә, имам югында намазын да укыта. Хәер, намазга берничә кеше генә йөри, карт, нигездә, үзе мәчеткә кереп азан әйтеп, бер ялгызы намаз укып чыга. Бүген исә ул кичке намазын өйдә генә укырга уйлаган, ахры, әнә шаулатып азан да әйтә башлады. Әгәр белсә, Әтил дә бабасы белән бергә намаз укыр иде, әбисенең терелүен сорар иде. Әбисен бик тә уятасы, терелтәсе килә аның, этисен дә бу йортка яңадан кайтарасы килә… Әллә соң Әтил белмәгән килеш тә сорап карасынмы икән? Менә шулай әбисенең кулыннан тота да бабасы намаз укыганда гел теләп утыра… Татарча теле… Аллаһ бөтен телләрне дә аңлый, ди бит бабасы… Татарча аңлый да аңлый инде ул, чөнки бөтен татарлар да татарча сорый бит…

Әтил килеп тотынгач, әбисенең боздай бармаклары селкенеп куйган кебек булдылар. Малай аларны учларына ныграк кысты, әбисенең кардай ак йөзенә карап, аның терелүен сорап ялвара башлады. Әллә улыннан күреп, әллә күңеле шулай кушканга, Сәрмәния дә кайнанасы янына килеп утырды, үзенчә догалар укып, Җанбикә карчыкның чәчләреннән сыйпады… Ул аның терелүен, яшәвен бөтен җаны-тәне белән тели иде. Чөнки кайнанасы аңа үз әнисе кебек якын һәм кадерле иде…

Сәрмәния эти-әнисез үскән ятим бала булды. Аның эти-әнисе, әле ул кечкенә чагында ук, моңа кадәр нәселдә булмаган кан рагыннан берәм-берәм үлеп киттеләр… Бик газапланып, тилмереп, күзгә карап үлделәр, беркем берни белән булыша алмады. Аларның ярты авыллары шулай көтмәгәндә кырылдылар да беттеләр — кайсы ак канга әйләнеп, кайсылары сөякләре череп, үпкә-бавырлары эштән чыгып, берәм-берәм авыл башындагы зиратларга күчеп беттеләр… Әйтерсең лә авыл өстеннән үләт чире үтте, тугыз зират мәет белән тулды, моның сәбәбен беркем әйтә алмады… Сәрмәниянең эти-әнисе, барлык туганнары да шунда ята, үзен исә, дөм ятим калгач, Ырынбур балалар йортына илтеп тапшырдылар. Авылдан киткәне аркасында гына Сәрмәния исән калды, институтка укырга керде, шунда Туран белән танышты… Һәм күп еллар үтеп, шушы үзгәртеп корулар башлангач кына билгеле булды: аларның авыллары өстендә, Ырынбур далаларында, илленче елларда беренче совет атом һәм водород бомбаларын сынап караганнар икән… Ягъни аларны татар авыллары өстендә шартлатканнар, тәҗрибә уздырганнар… Ибрай авылы өстеннән дә кара атом болыты үтеп киткән, кара яңгыр яуган… Халыкның нинди фаҗигале хәлдә калганлыгын белсәләр дә, бу хакта аның үзенә әйтмәгәннәр, башка урынга күчермәгәннәр, махсус дәваламаганнар… Авыл халкы кан рагыннан авыру һәм үлү буенча СССРда беренче урынга чыккач та, моны яшергәннәр, шулай күпләп кырылуны татарларның үзләреннән күргәннәр… Имеш, дөрес яшәмиләр, дөрес тукланмыйлар, дөньядан артта калганнар… Югыйсә Сәрмәниянең әби-бабасы йөзгә җитеп үлгән иде, бу татар авылы заманында бөтен тирә-якка үзенең озак яшәүчеләре белән мәгълүм иде… Хәзер исә 40—50 яшькә дә җитмиләр, тумыштан гарип булып туалар яки бөтенләй нәселсез булып калалар… Авылда калса, Сәрмәнияне дә бәлки шул көн көткән булыр иде… Аны яшьли череп үлүдән менә шушы гаилә коткарды, ятим кыз балага җан җылыларын бирделәр, үзләренә сыендырдылар…

Сәрмәния кайнанасының кулларыннан, башыннан сыйпап куйды, боздай маңгаена иреннәрен тидереп алды. Ул кечкенә чагында үз ата-анасының үлемен күрде, барлык туганнары да аның күз алдында бу дөньядан китте… Ул 25 яшендә ирсез калды, Туранын югалтты… Аның бу дөньяда хәзер, менә шушы карт-карчыктан һәм улы Әтилдән кала, беркеме дә юк. Әле студент елларында өйләнешкәч тә, Туран аны шушы йортка алып кайтты. Кайнатасы белән кайнанасы әле ул чакта яшьләр иделәр, Сәрмәнияне үз балалары кебек күтәреп алдылар, кадерләделәр, яраттылар… Шушы йортта Әтил туды, ул шушы идәндә, Җанбикә әбисенең кулына тотынып, тәпи йөреп китте… Туранның игезәк туганы Түлгән булмаса, аннан зыян-җәбер күрмәгән булсалар, әле һаман шушы йортта яшәп яткан булырлар иде… Урал таулары арасында адашып калган Атасалга да шул Түлгән аркасында гына кайтып китте бит алар… Туранны армиягә алулары да шул Түлгән аркасында гына булган, дип сөйләделәр, шул солдат хезмәтендә юкка да чыкты Туран… Җанбикә карчыкның менә болай чирләп китүе дә шул уллары кайгысыннан бит инде, икесенең берсе юк янында, кайда икәнлекләрен дә белүче юк. Исән булса, теләсәләр, Түлгәнне табарлар, ул милициядә, органнарда хезмәт итте, ә менә Туранны кем табар? Югары белемле, акыллы, иманлы, милләт җанлы бер татар баласы кемгә кирәк бу илдә? Менә шушы карт ата-анасына, хатынына һәм улына кирәк, һәм шуның белән бетте. Туран бу тормыш турында, милләт язмышы, дин турында артык күп белә иде, белгәнен башкаларга да аңлатырга тырыша иде. Бу кара дөньяда шулкадәр саф, эчкерсез булып, ничек сакланып

кала алгандыр… Югыйсә бер ата-ананың ике улы, игезәк туганнар, ә аермалары — җир белән күк арасы… Моны табигать ялгышы, мутация димичә, тагы ни дисең?

Өйгә, әкренләп, кичке эңгер кереп тулды. Озак кына пәрдәләрне тартмыйча, ут яндырмыйча, һәркем үзенекен уйлап утырды. Урал таулары арасына кандай шәфәкъ таралган иде… Вакыты-вакыты белән, ачы итеп, завод торбалары кычкыртып җибәрә… Аксуда аның заводлары да, торбалары да бихисап күп. Чал тауларның мәңгелектән килгән җанын актарып, биредән тимер эзлиләр, бакыр табалар, алтын юдыралар, мәрмәр чыгаралар… Шуны эшкәртәләр, корал ясыйлар, саталар, эчәләр, акча беткәч, тагы тау актаралар, тагы чуен коялар, корал ясыйлар, саталар, эчәләр… Шундый байлык өстендә утырса да, халык хәерче яши, шәһәр пычрак, кешеләр чебен урынына кырыла, үлә… Кайсы газлы һавадан, кайсы агулы судан, кайсы яман шештән, рактан үлә, кайсы асылына, эчеп үлә, бер-берләрен үтерәләр… Биредә татарлар аз яши, нигездә, шушы тирәдәге борынгы авылларның халкы. Ә башкалар —бирегә завод белән ияреп килгән халык, бу тирәләрдә корал империясе тотучы кавем… Ә завод торбалары әнә һаман үкерә, пары, газы, агуы шулай шәһәр өстенә яргыла, Аксу өстенә, саф Агыйдел буйларына, Урал тауларына тарала…

Җиһангир карт килеп, тәрәзә пәрдәләрен тартып куйды, утны яндырды. Урамдагы дәһшәтле күренеш каядыр еракта калган кебек булды. Өй эчендә мәрткә киткән Җанбикә карчык ятып калды. Барысы да кабат аның тирәсенә җыелдылар.

— Балалар кайгысы шулай бетерде инде аны,— диде Җиһангир карт, мәет кебек яткан карчыгына кызганып карап.— Әле нык иде ул, бергәләп дингә кереп киткән идек, сезне дә үз яныбызга алдырырбыз дип тора идек… Менә бит…

Оныгы белән киленен карт инде берничә тапкыр Аксуга чакыртып та караган иде, әмма Сәрмәния ризалашмады. Теләсә кайсы вакытта Түлгән кайтып керер дә аларны эзәрлекли башлар, куарга тотынып кебек тоела иде аңа. Алар бит ире Туран белән бу йортка бүтән кайтмаска дип чыгып киттеләр, авылдагы иске нигезгә кайтып егылдылар, шунда бала үстерделәр… Туран юкка чыккач та, Сәрмәния Аксуга кайтмады, Уралның аръягына — Тимертауга китеп барды. Чөнки бу йортка теләсә кайсы вакытта Түлгән кайтып керергә һәм аларны килгән килмешәк дип гаепли башларга мөмкин иде…

— Безнең монда кайтмасны беләсең бит инде, әткәй,— диде ул йомшак кына.— Без үзебезнең тормышны төзеп карыйк инде… Әтил дә әйбәт кенә укып йөри, мин дә ияләндем инде…

— Укыганың буенча эшең юк бит,— диде карт, аңа каршы төшеп.— Укытучы башың белән, яңа байларга аш пешереп йөрисең… Үзеңне кызганып әйтүем, килен… Бергә-бергә барыбер җайлырак булыр иде, диюем…

— Шулай, әткәй, анысы, шулай,— диде Сәрмәния, аның белән килешкән кебек булып.— Әнкәйнең болай булып китүе генә начар бит әле менә… Иртәгә врачка бармый булмас, әткәй, бәлки аңа бер-бер ярдәм кирәктер? Организмына су, ризык кертергә кирәктер? Уен эш түгел бит бу…

Сәрмәния шулай дип әйтеп өлгермәде, улы Әтил чәчрәп урыныннан сикереп торды. Аның күзләре шар булып ачылган, иреннәре дерелдәп тора иде.

— Әби минем кулымны кысты! — диде ул, әллә куркып, әллә сөенеп.— Ике тапкыр менә шулай, шулай кысып куйды…

Барысы да карчык өстенә иелделәр. Чыннан да, карчыкның мәеттәй йөзе үзгәреп киткән, иреннәре нидер әйтергә теләп кыймылдый иде. Карт каз каурые белән аның күгәргән иреннәренә су тидерде, карчык, моны сизгән кебек, иреннәрен селкетеп куйды. Аның сулган йөзеннән шәүлә кебек болыт үтеп киткәндәй булды, иреннәре артыннан йөзе дә үзгәрде, хәрәкәткә килде. Әле ул кырыс, дәһшәтле кыяфәткә керде, әле тынычланып, язылып китте… Әйтерсең лә карчыкның йөзендә ул күргән-кичергән шомлы вакыйгалар да, шатлыклы хәлләр дә чагылыш таба, язылып бара иде… Аннан, кое төбеннән килгән кебек, тонык тавыш ишетелә башлады: Җанбикә карчык чит тавыш белән нидер сөйли иде…

**Тетрәде… җирләр… ярылды… күкләр… ике арада… җилләр улады…**

Шушы тонык, шомлы сүзләрне җаныннан кысып чыгарды да, карчык тынып калды… Йөзенә тагы мәет төсе керде, гәүдәсе озынаеп, сураеп калды. Әйтерсең лә карчык соңгы сүзләрен әйткән һәм җан биреп ята иде…

Җиһангир карт, йөгереп килеп, көзгене аның борын төбенә куеп карады — көзге парланмады… Карт, калтыранып, Җанбикә карчыкның кулларын, аякларын уа башлады, әмма карчыкның бу дөньядан ераклаша баруы сизелә иде… Өйгә кинәт кенә боздай мәет салкынлыгы кереп тулды…

Әллә үлем җиле килеп кагылды, әллә башка сәбәптән Әтил дә баскан урынында чайкалып куйды, күз аллары томаланып китте. Аның колагына диңгез шавы килеп бәрелде, күңелендә кабат кисәтүле куркыныч сүзләр яңгырый башлады. Ул, үлеп барган әбисенең кулларыннан алып, төштә кебек шул сүзләрне кабатлый башлады…

**Астан ут бәрде, өстән су акты, беркайда качар урын калмады…**
**Ата — баланы, бала ананы күрер булмады, белер булмады…**
**Бер-берләренең басып башына, исән калырга алар тырышты…**
**Әмма бу көндә качу юк иде, туфан суында бар да тончыкты…**

Өй эче шомлы тынлык белән тулды. Сәер хәл иде бу — кыйблага карап, Җанбикә карчык җан биреп ята, аның янында оныгы, әбисенең җансыз кулларыннан тотып, чит тавыш белән нидер сөйли… Карчыгының инде китеп баруын сизеп, Җиһангир карт кулына, ашыгып, Коръән алды… Соңгы бәхилләшү авазы булып өй эченә «Ясин» сүрәсе яңгырады…

«Йәәсииин. Вәлкурәәнил хәкиими иннәкә ләминәл мүрсәлиинә гәләә сыйраатыйм мүстәкыйм…»

Карт моңлы тавышы белән үзәкләрне өзеп укыды, өй эчендә әллә адәм балалары, әллә фәрештәләр сулкылдап елый башлады… Малай да айнып киткән кебек булды, күз алдында томан таралды, колагындагы диңгез шавы юкка чыкты. Ул, соңгы тапкыр күргәндәй, әбисенә текәлде. Димәк, әбисе дә соңгы мизгелләрендә шуны күрә, аңа дөньяны туфан басуын күрсәтәләр… Менә әбисенең йөзеннән тагы ниндидер шәүлә үтеп киткән кебек булды, балавыздай битенә башка төс керде, иреннәре тагы кыймылдый башлады. Җиһангир карт та моны сизде, тавышын әкренәйтте, әмма Коръән укуын туктатмады… Хәзер инде барысы да Аллаһ кулында иде…

Менә Җанбикә карчыкның кипкән иреннәре тагы ачылды, бик тирәннән, кое төбеннән килгән кебек, тагы чит тавыш яңгырады. Ул бик ачык итеп, ашыгып-ашыгып, нидер әйтеп калырга тырыша иде…

**… Сезгә Аллаһның рәхмәте иңде —**
**Ышанган өчен, буйсынган өчен**
**Сезгә бирелде тылсымлы көймә…**
**Утта да янмый, суда да батмый, буйсынып бары Аллаһ иркенә,**
**Тылсымлы көймә килеп туктады күгәреп торган тауның читенә…**
**Сезнең өегез шушы тау булды, су белән бергә таудан төштегез…**
**Җирдә кешелек икенче тапкыр сездән таралды — шуны белегез!**

Шул сүзләрне әйтеп бетерү белән, карчык әкрен генә күзләрен ачты… Аларда бернинди җан әсәре юк иде… Аның карашы җиде кат җир астыннан җиде кат күккә киткән иде… Тере кешедә мондый караш булмый, әмма ул үлгән дә түгел —сөйләшеп ята иде!

Җиһангир карт «Ясин» чыгуыннан туктап калды. Малай, әсәрләнгән кебек, кыймылдый да алмыйча басып торуын дәвам итте. Сәрмәния кайнанасына кагылырга да, кагылмаска да белмәде, ялгыш бер сүз әйтсәң, орынсаң да, карчык, күкнең җиденче катыннан егылып төшеп, җан бирер кебек тоела иде… Ул хәзер җир белән күк арасыннан үтеп бара иде… Барысы да, дәшмичә, вакыйганың азагын көттеләр. Карчык, күктән йолдызлар чүпләгән кебек, зур авырлык белән сүзләр табып, аларны кабатлый башлады. Әмма аның бу сүзләрен инде беркем дә аңларлык түгел иде — Җанбикә карчык көтмәгәндә башка телдә сөйли башлады…

«Яүмә юдәггүүнә иләә нәәри җәвәннәмә дәггә. Һәәзиһи ннәәрул-ләтии күңтүм-бивәәтү-кәззибүүн-ә-фәсихрун һәзәәәә-әм-әңтүм лә түбсыйруун. Исләүһәә-фәсбирүүүү әүләә тәсбируу сәвәәүн гәләйкүм иннәмәә түҗзәүнә мәә күңтүм тәгмәлүүн».

Әтил белән Сәрмәния, берни аңламыйча, Җиһангир картка карадылар. Ул Җанбикә карчыктан да болай агарынып, катып калган иде. Җиһангир карт, үзе белгән догаларны укып, карчыгын өшкерергә тотынды, әмма аның нәрсә дип әйткәнен берәүгә дә әйтергә ашыкмады. Чөнки Җанбикә карчык, саташып, бик куркыныч, коточкыч нәрсәләр турында сөйли иде. Әнә аның маңгаена эре тир тамчылары бәреп чыкты, тавышы тагы да тонykланды, карлыкты, гыжлауга әйләнә башлады… Әмма ул сөйләвеннән бөтенләй туктый да алмый иде, әйтерсең лә аны үлем алдыннан шушы сүзләрне әйтергә кемдер мәҗбүр итә, өйрәтеп тора иде. Менә ул тирән итеп соңгы сулышын алды да инде барысына да аңлаешлы булган ап-ачык телдә сүзләрен тәмамлады:

**Туран тавының ике ягында, карлы илдә дә, кайнар чүлдә дә**
**Аллаһ гыйлемен сез тараттыгыз, хаклыкны җирдә сез аңлаттыгыз…**
**Шуның өчен бит җирдә калдыгыз, туфан суыннан исән калдыгыз —**
**Аллаһ нәкъ сезне сайлаган өчен…**

Җанбикә карчык соңгы сүзләрне оныгы Әтил белән бергә әйтеп бетерде. Дөресрәге, карчык туктап калды, аның сүзләрен, ятлап алган кебек, Әтил дәвам итте. Сәрмәния белән Җиһангир карт, аптырашып, бер-берләренә карадылар, әмма карчык белән оныкның сәер сөйләшүен бүлдерергә курыктылар. Чөнки болар берсе дә алар ишеткән сүзләр түгел иде, теге дөнья белән бу дөнья арасына адашып килеп кергән күренеш иде…

Әллә оныгының тавышын ишетеп, әллә инде әйтер сүзе беткәнгә санап, Җанбикә карчык туктап калды. Әйтерсең лә аның өстеннән бастырып куйган авыр ташны алып атканнар иде. Аның йөзенә җан иңде, күзләрендә тереклек билгеләре чагылып үтте. Әмма ул әле барыбер бик хәлсез иде, әйтерсең лә теге дөньядан әйләнеп кайткан, яңадан үлеп терелгән. Ул, чыннан да, үлеп терелгән иде, үзенең теге дөньяда күргәннәрен башкаларга да әйтер өчен, яңадан бу дөньяга кайткан иде… Әмма аның бу дөньядан инде үтеп барышы иде, бу тукталышы — соңгы тукталыш иде. Тик әле бу хакта беркем дә, хәтта Җанбикә карчык үзе дә белми иде…

Гаять кызганып һәм яратып, Әтил әбисенең кулын кысыбрак тотты. Әбисенең куллары инде җылына башлаган иде, ул бармакларын әкрен генә кыймылдатып куйды, оныгына үзенең исәнлеген хәбәр итте.

Карчыгының элегрәк тә мәрткә киткәнен күргәне булганга, Җиһангир карт аның мондый халәтен белә иде инде. Әмма бу юлы ул да курыкты, шомланды, карчыгы белән мәңгегә бәхилләшә башлады. Карчыгы бу юлы, гомер булмаганны, саташып, әллә нинди шигырьләр сөйли башлады, туфан басу, дөнья бетү турында сөйли, нииндидер Туран таулары, ди, кемнәрнедер нәрсәдәндер кисәтергә тели…

Шулчак Җиһангир картның тәне эсселе-суыклы булып китте. Тукта, карчыгы гади шигырь генә сөйләп ятмады бит, бу хәбәрләр барысы да Коръәндә бар, ул шулар хакында кисәтте түгелме соң? Дөньяны туфан басу, Нух пәйгамбәр көймәсе, кешелекнең шул нәселдән дәвам итүе турында Коръәндә ачык хәбәрләр бар бит! Һәм… җәһәннәм турында сөйләде ул! Анысы гарәп телендә, Коръәннән аятьләр иде… Кайдан белгән ул боларны, аның диннән гыйлеме ул дәрәҗәдә үк түгел бит… Ә бу бала аңа ияреп нәрсәләр сөйләде? Икесе дә бер үк нәрсә сөйләде бит алар, берсе — теге дөньядан, берсе — моннан… Бу ни хикмәт, бу ни хәл?

Шул чагында Җанбикә карчык тагы телгә килде.

— Мин җәһәннәмне күрдем,— диде ул ап-ачык итеп.— Ул безнең шәһәр астында… Аннан ут өскә бәреп чыкты, бөтен шәһәр гөрләп яна башлады… Аксу җәһәннәм казанына әйләнде, быкырдап, улап, кара төтеннәр чыгарып янарга тотынды… Бөтен кешеләре, заводлары, йортлары белән… барысы да… Бар дөнья гүләп тора… Мин җәһәннәмне күрдем… Безнең шәһәр җәһәннәм чокырында иде…

Ул башка сүз әйтмәде, тынып, туктап калды. Сәрмәния тиз генә кайнанасына чәй ясап китерде, урыннарын җайлап куйды, маңгаендагы тирләрен сөртеп алды. Өйдәгеләрнең барчасына да җан керде. Җанбикә карчык нинди генә куркыныч, саташулы сүзләр сөйләсә дә, ул исән иде. Монысы — иң мөһиме, ә калганы — авыру галәмәте, дип уйладылар алар. Мәрткә киткән кеше уянгач, нәрсә сөйләмәс… Кайвакытта төшкә дә әллә нинди куркыныч нәрсәләр керә, ярты көн айный алмый йөрисең... Карчык та, бераз ял иткәч, бу мәхшәрне онытыр, искә алмас, дип уйладылар. Әмма барысының да күңеленә бу хәлләрдән ниндидер хәвеф, шом кереп калган иде.

Җанбикә карчыкның әкренләп терелә, тернәкләнә баруын күреп, юк-бар уйлар онытылды, борчулар юкка чыкты. Бу мизгелдә иң мөһиме — аның исәнлеге, исән булуы иде. Менә ул килене китереп биргән чәйне бернichә тапкыр йотып куйды. Оныгын янына утыртып, аның аркасыннан сыйпады, килененә яратып карап алды. Аннан тагы, саташкандай, үзенекен сөйли башлады, үзенә китте…

— Анда… атаңны күрдем, балам,— диде ул тирән сагыш, газап белән.— Атаң җир астында… таулар арасындагы җир асты шәһәрендә… Алар барысы да актан, барысында да үлем аклыгы… Атаңда да…

Карчыкның күзләренә яшь бәреп чыкты. Җиһангир карт аны тынычландырырга, юатырга ашыкты:

— Саташу гына ул, әнисе, борчылма әле,— диде ул, аның чал чәчләреннән сыйпап.— Төш кебек, бер саташу гына… Ул күргәннәреңне онытырга тырыш, исеңә төшереп, үзеңне газаплама… Мәрткә китү бит ул — үлеп терелү, анданиләр күрмәссең… Сиңа хәзер терелергә, ныгырга кирәк… Уйлама анда күргәннәрең турында, уйлама, яме? Менә оныгың, киленең килде, шуңа шатлан, шул турыда уйла, яме?

Төн җитте. Җиһангир карт ястү намазына әзерләнә башлады. Башка көнне булса, ул намазын мәчеттә укыр иде, әмма бүген карчыгын ташлап чыгып китәргә яхшысынмады, өйдә генә укып алырга булды. Ул арада килене өстәл тирәсен карый, чәй әзерли башлады. Ничә көн инде бу өйгә ризык исе, табын яме кергәне юк иде, килене белән оныгы кайту йортка бәрәкәт, тормыш алып килде…

Кайнатасының рәхмәтле уйларын сизгәндәй, Сәрмәния тиз генә табын әзерләп җибәрде, өстәлгә үзе белән алып кайткан бөтен тәмле-төмлене чыгарып тезде. Өйгә ризык исе таралды, ямь кереп китте. Җиһангир карт намазын укып бетерүгә, барысы да өстәл янына утырдылар. Җанбикә карчыкка чәйне яткан урынына гына ясап бирергә уйлаганнар иде, әмма ул торып карарга булды. Килене белән картының кулларына таянып, башта юынып, чистарынып килде, аннан хәлсез аякларына чак кына басып, өстәл янына килеп утырды. Картының сабырлыгы һәм ныклыгы, килененең элеккеге кебек бөтерелеп йөрүе, оныгы Әтилнең саф, мәхәббәтле күзләре аны терелтеп, җанландырып җибәрде. Теге дөньяда күргәннәр

белән бу дөнья арасына, әкренләп, пәрдә төште, бу дөньяның яктылыгы, якыннарының яратуы теге дөньяның дәһшәтле караңгылыгын җиңде… Алар, элеккеге кебек гөрләшеп, табын янына утырдылар… Туран белән Түлгәннең түрдәге урыннары гына буш, күңелләрне борчып, үткәннәрне искә төшереп тора иде…

Карчык, бик яратып, лимонлы чәй эчеп куйды. Үзенең теге дөньядан үрмәләп кайтып, якыннары белән чәй эчеп утыруына ул әле үзе дә ышанып җитми иде, ахры, вакыт-вакыт онытылып уйга калды… Бу мизгелләрдә аның кулына тоткан чынаягы калтырап, чәе чайпалып китә иде.

— Котны алдың син, карчык,— дип, Җиһангир карт аны кирәкмәгән уйларыннан арындырырга тырышып.— Борчылып, киленне дә чакыртып кайтардым менә…

— Анысы бик яхшы булган,— диде Җанбикә карчык, авыр уйларыннан арынып.— Анда да шушы баланың тавышын ишеттем… Шуның артыннан ияреп кайттым…

Карчыкны борчып, бу турыда сөйләттерәселәре килмәсә дә, ул әле саташулы уйларыннан арына алмый иде, сүз сөреше гел шул якка борылды. Барысын да гаҗәпләндереп, саф татарча сөйләшеп утырган җирдән, берничә тапкыр гарәпчәгә күчеп сөйли башлады. Карчыгының элек гарәпчәне намаз-догалык кына белгәнен Җиһангир карт белә иде, чөнки үзе урыс хәрефләре белән язып өйрәтте. Ә ул әнә хәзер саф гарәпчә сөйләшеп утыра.

— Син, әнисе, гарәпчә белә башлагансың, димме? — дип сорап куйды ул сак кына.

— Анда кирәк ул,— диде Җанбикә карчык бик җитди итеп.— Анда шул телдә сөйләшәләр.

— Әби, син мәрттә вакытта, без аңламаган телдә нидер әйттең, ул да гарәпчә идеме? — дип сорады Әтил дә.

— Анысы Коръән аятьләре иде, җәһәннәмне күрсәткәндә өйрәттеләр. «Тур тавы» сүрәсеннән… «Ни үкенеч һәм ачы хәсрәт, каты газаптыр ул көндә Коръәнне ялган диючеләргә яки аның белән гамәл кылмаучыларга. Алар хакны инкарь итеп, бозык эшләрне эшләү белән һәм ялган сөйләү белән уйнаучылардыр. Ул көндә кул-аяклары богауланып, җәһәннәмгә өстерәлерләр. Вә аларга әйтелер: «Бу ут — сез аны ялганга тоткан идегез, сез дөньяда вакытта Коръәнне сихер дияр идегез, бу ут газабы да сихерме? Әллә ут газабын күрмисезме? Бик яхшы күрәсез, ләкин дөньяда хакны күрергә теләмәдегез. Инде керегез ул утка һәм газабын татыгыз! Кирәк — чыдагыз, кирәк — чыдамагыз — сезнең өчен бертигездер, газабыгыз җиңеләймәс, сез фәкать кылган явызлыгыгыз өчен җәзаланырсыз»,— дип».

Җанбикә карчыкны бүлдерергә берсе дә батырчылык итмәде. Ул тыныч, сабыр, моңлы тавыш белән өйдәгеләргә шушы сүзләрне сөйләде. Әмма Җиһангир карт төнгә таба карчыгының мондый куркыныч күренешләр белән борчылуын теләми иде. Шуңа күрә ул, чәй эчеп бетергәч, барысына да бераз йоклап, ял итеп алырга тәкъдим итте.

— Килен дә юлдан кайткан, мин дә ничә төн ял итмәгән, үзең дә бик йончыгансың, бераз ятып, ял итеп алыйк,— диде ул, карчыгына каты бәрелмичә генә.— Сөйләшүне иртәгә сөйләшербез, иншаллаһ, шулай бит, улым?

Әтил инде диван читенә башын төртеп, йокымсырап утыра иде. Тиз генә барысына да урын җәйделәр, Әтилне әтисе бүлмәсенә алып кереп салдылар. Җанбикә карчык, килене ярдәмендә тәһарәтен алып, яткан урыннан гына төнге намазын укып алды. Барысы да йокларга яттылар. Әмма алар күзләрен йомганчы ук, каршыларына үткән гомерләре, бергә кичергән шатлык һәм кайгылары килеп басты. Бу төндә, бу өйдә алар янында тагы ике кеше — Туран белән Түлгән дә бар иде… Бу икәү аларның тормышларына китмәс өчен килгәннәр иде…

* * *

Туран белән Түлгән бер көндә, бер ата-анадан тусалар да, алар туганда ук икесе ике төрле иде. Юк, монда сүз тышкы кыяфәт, буй-сын турында гына бармый, балалар холык-фигыльләре белән дә икесе ике төрле иде. Башта алар төс-битләренең төрле булулары белән барысын да аптырашта калдырдылар, әйтерсең лә алар игезәкләр түгел, хәтта бертуганнар да түгел, төрле ата-ана балалары иде! Туран туганда ук ак, эре бала иде, чәчләре коңгырт төстә, күзләре әтисенеке кебек зур һәм яшькелт-зәңгәр иде… Түлгән исә кечерәк буйлы, каратут йөзле, бераз кысыграк кара күзле, шомырт кара чәчле булып туды. Балаларның атасы Җиһангир тышкы кыяфәте белән Туранга охшаган алып бәдәнле татар-мишәр ире, әниләре Җанбикә каратут йөзле татар-типтәр хатыны иде. Әмма Түлгәнне әнисенә охшаган дип тә әйтеп булмый, чөнки Җанбикәдән нииндидер әчке бер матурлык, җан җылысы бөркелеп торса, Түлгән кечкенәдән әллә нинди кире, үҗәт, төртмә телле булып үсте. Балалар арасындагы бу аерма торган саен ныграк беленә башлады, тышкы кыяфәттән дә бигрәк, холык-фигыльләренең капма-каршы булуы ата-ананы бик борчыды. Туран тәртипле, тыныч, уйланучан бала булып үссә, Түлгәндә әллә нинди астыртынлык, хөсет, усаллык ярылып ята иде, әйтерсең лә аны бишегендә үк җен алыштырган! Үч

иткән кебек, ул Туран эшләгәннең гел киресен эшләде, ике арадагы аерманы күңеле белән сизенеп, туганына тартыласы урынга, аннан һаман ераклаша гына барды… Ата белән ана Түлгәнне күпме генә тәртәгә кертергә тырышып карасалар да, малай баш бирмәде, чөнки ул үзен бер очракта да гаепле санамады, Туран яхшы булып кыланганга мин начар күренәм, дип уйлады. Ата-анасы Туранны мактасалар, аны эчтән генә хурлыйлар кебек тоелды. Алар Түлгәнне гел тәртипкә чакырып торсалар да, Туранга каршы бер сүз әйтмиләр иде, чөнки Туран алар өчен игелекле, әйбәт бала иде…Үз туганы Туранны узып китү, аста калдыру, җиңү Түлгәннең төп максатына, яшәү рәвешенә әйләнде. Мәктәпкә ул барса барды, бармаса — юк, укыса укыды, укымаса — юк… Көне-төне заводта, тимер кою цехында эшләгән ананың, завод эше белән командировкалардан кайтып кермәгән атаның балаларга вакыты аз кала иде. Малайлар күп вакыт ялгыз — бергә-бер калып үстеләр. Туранның җилкәсеннән генә булса да, Түлгән аңа очып-очып куна, җайсыз чагын туры китереп, бәреп тә ега, Туран тыпырчынмаса, муенына менеп тә атлана иде. Түлгән көч белән түгел, күп вакыт астыртынлык һәм мәкер белән алдыра иде… Үз туганы дип, Туран аңа күп вакыт юл куйды, аңа беркайчан да кул күтәрмәде, ата-анасына да Түлгән хакында әләкләмәде, аларны борчымаска тырышты. Мәктәптә укыганда ук инде Түлгән наркотикларын да капкалап караган иде, эчеп, сугышып, берничә тапкыр милициягә дә эләкте, үзен хисапка да алып куйдылар. Туран исә башын китаптан күтәрмәде, әти-әнисенә йорт эшләрен карарга ярдәм итте һәм игезәк туганы белән җәфаланды. Туран аңлы бала иде, монда, аның янында калса, башы Түлгән оештырган фетнә-гаугалардан чыкмасын иртә аңлады ул. Ата-анасын бик нык кызганса да, урта мәктәпне тәмамлауга, укырга дип, Аксудан чыгып китәргә уйлады…

Ырынбур педагогия институтының тарих бүлегенә ул имтиханнарын бишкә генә биреп керде. Ә Түлгәнне тоттылар да армиягә алып киттеләр. Бандит дип тә тормадылар, наркотиклар белән шаяруына да игътибар итмәделәр, ялгыз ата-ана турында да уйламадылар — план үтәргә кирәк иде, бөтен шәһәр шпанасын җыйдылар да алдылар… Ата-анасы һәм Туран эчтән генә моның белән килештеләр дә, бәлки анда бераз тәртипкә кереп үзгәреп кайтыр, дип өметләнделәр… Шушы китүдән Туран белән Түлгәннең тормыш юллары ике якка китте, яшәү рәвешләре капма-каршыга әйләнде… Ата-ана йортыннан чыгып киткән ике ир туганны тормыш үзенчә калыплады, әмма һәркем үз теләгәнен алды, үз омтылганына иреште…

Туран Ырынбурда укый башлауга, Сәрмәнияне очратты, ата-анасыз бу ятим кызны ул өзелеп кызганды, яратты. Ул аны әти-әниләренә дә алып кайтып күрсәтте, алар исә Сәрмәниягә ике куллап ябыштылар, кызыбыз, киленебез бул, дип сорадылар. Шулай итеп, алар беренче курста укыганда ук өйләнешеп куйдылар, икенче елны исә Әтил туды… Туранның әти-әнисе Сәрмәния белән оныкларын бер көнгә дә читкә җибәрәселәре килмәде, Сәрмәния белән Туранның барыр җире дә юк иде… Сәрмәния читтән торып укырга күчте һәм баласы белән Аксуга кайтты, ә Туран исә көндезгедә укуын дәвам итте, чөнки ул читтән торып укырга күчсә, аны армиягә алачаклар иде…

Ә Түлгәнне туп-туры Кавказга алып киттеләр…

Ул арада чечен сугышы башланды, кире һәм үзсүзле егетне, ике дә уйлап тормыйча, ут эченә ыргыттылар… Ул үлсә дә, калса да, ата-анасыннан кала, беркемнең йөрәге өзелмәячәк, аның өчен өзгәләнмәячәк иде… Егет моны үзе дә сизде, бу дөньяга кирәксезлеген, файдасызлыгын, кадерсезлеген аңлады, әмма мондый хәлгә калуына үзе гаепле икәнлеген танырга теләмәде. Аның атасы белән дә, игезәк туганы Туран белән дә аралары салкын иде, җылынып китә дә алмады. Ул арада Туранның өйләнгән хәбәре килеп ишетелде… Түлгән көн саен үлем белән очрашканда, Туран аның өендә яшь бикәч кочып ята иде! Тагы Туран өскә чыкты, тагы Туран җиңде, дөнья тагы Туранга — алдын, Түлгәнгә артын күрсәтте!

Ул бу сугышта берничә тапкыр яраланды, берничә тапкыр үлемнән калды, әмма башкалардан берничек тә, бернәрсәсе белән дә аерыла алмады. Үзен ут эченә тотып аткан «Ватан-анасы» аның күкрәгенә хәтта бер күгәргән калай кисәге дә такмады… Ул башкалар кебек беткә баткан бер ач солдат иде… Түлгәннең мондый мескен кыяфәттә ата-анасы янына кайтып керәсе килмәде, һәм ул үз теләге белән тагы бер елга Чечняда калды… Ул Аксуга герой булып кайтырга үз-үзенә сүз биргән иде… Ул инде үз теләге белән, бар дөньядан үч алу максаты белән, ут эченә ыргылды… Аңа кемне үтерсә дә — инде барыбер иде…

Ул арада Тураннарның баласы туу хәбәре килеп ишетелде… Аның хатыны һәм яшь баласының Аксуга, төп йортка кайтып яши башлавын ишетеп, Түлгән үзенең урамда калганлыгын аңлады… Егерме бер яшендә ул инде йортсыз-җирсез, ата-ана яратуын күрмичә, хатын-кыз мәхәббәтен татымыйча, үз гомерендә бер яхшы нәрсә белмичә, бу дөньяда япа-ялгыз бер сукбай хәлендә торып калган иде… Туран, аның игезәк туганы, әнә ата йортының түрендә яшь хатын кочып ята, ә ул монда, ут эчендә, үлемгә бара… Аны анда да көтеп торучы юк, монда да кирәге юк…

Бу уй аны тагы да усалландырды, явызландырды… Ул әйтерсең лә үлемне үзе эзләп йөри башлады, явыз үлем белән килешү төзеде, җанын шайтанга сатты… Инде өстәгеләр дә кысык күзле бу Урал егетен тиз күреп алдылар, аның куркусызлыгына таң калдылар. Аны иң куркыныч урыннарга үлемгә җибәрделәр, ә ул барган саен исән кайтты… Бу хәлне күреп, аңа инде үз кеше итеп карый башладылар, алга таба «особый заданиеләр» өчен генә тоттылар, күкрәген ул күптән көткән тәреле орден-медальләр белән бизәделәр… Ниһаять, Түлгән теләгенә иреште — ул Россия Герое булды… Бу исемне нәрсә өчен биргәннәрен ул үзе һәм берничә хәрби җитәкче генә белә иде… Беренче чечен сугышы беткәч исә, зур дәрәҗәләр белән, аны иленә озаттылар. Аксудан наркоман булып чыгып киткән башкисәр егет, күкрәге тулы орден-медальләр белән, туган өенә кайтып төште. Уралтау араларында төтенләп яткан бу кечкенә шәһәргә ул зур герой булып кайтып керде. Ул, чыннан да, инде икенче кеше иде, бу дөньяда ни өчен яшәгәнлеген аңлаган һәм үзенә ни кирәген яхшы белгән Түлгән иде…

Әйе, ул үз өенә генә түгел, бу шәһәргә дә хуҗа булып кайтып керде. Кайтуга ук, милициягә барып эшкә урнашты, хезмәте буенча читтән торып укырга керде. Кайчандыр хулиганлык өчен үзе бикләнеп яткан камераларга ул инде аяк белән генә тибеп керә иде, бирегә инде башкаларны тибеп кертә иде… Чөнки чечен сугышында катнашу, герой исеме алып кайту аңа шундый хокук бирде… Дөньялар үзгәргән, дөнья белән бергә кешеләр дә бик нык үзгәргәннәр иде шул, яхшы — начар, начар яхшы булып күренә башлаган заманнар җиткән иде… Органнардан махсус юллама белән кайткан, аларга хезмәткә ялланган, түш тулы орден-медале булган Россия Героена нәрсә әйтәсең — ул кайчандыр шушы шәһәрнең башкисәре булса да… Аңа сүз әйтмәделәр, шулай итеп, ул милициянең түренә менеп утырды… Хәзер биредә ул хуҗа иде… Әмма аның үзенең дә органнар кулында курчак кына икәнлеген, аны теләсә кайчан, теләсә кайда, теләсә нинди этлек эшләргә җибәрергә мөмкин икәнлекләрен күпләр белми иде… Каф тауларында Түлгән җанын иблискә саткан иде, һәм аның тормышы да хәзер инде алар кулында иде…

Шәһәргә шулай аяк тибеп килеп керсә дә, өйдәгеләр арасында үз тәртибен урнаштыру җиңел булмады аңа. Бу өйдә аңа элек тә кырынрак карыйлар иде, хәзер исә дөнья бөтенләй үзгәргән кебек тоелды аңа… Әтисе белән әнисе дингә кереп киткәннәр, җитмәсә, карт өй каршында мәчет төзетәм дип тилереп йөри… Түлгән тегендә күрде инде ул мөселманнарны, хәзер монда, борын төбендә, шуларны үрчетеп яткырыргамы? Алар дин дип йөри, өйнең түренә Ырынбур ятиме менеп утырган, аяк астында елак баласы чуала… Солдаттан кайткан көнне, шатлыгыннан күңеле йомшарып, Түлгән алар белән кешечә сөйләшергә тырышып карады — бер яртыны уртага куеп, Ырынбур ятимен кочаклап, бер җырлап утырасы килде аның… Әмма тегесе, баласын төреп, өйдән үк чыгып йөгерде, карт-карчык күренгәнче, өйгә дә кермәде. Ата-анасы да, һаман элеккечә, аңа акыл өйрәтергә тотындылар, аны, Россия Героен, утны-суны кичкән кешене ничек яшәргә өйрәтеп азапландылар!! Монда кем хуҗа икәнлеген ул сезгә тиз аңлатыр! Һәм ул Туранның гаиләсе белән өстәл төеп, ишеккә күрсәтеп сөйләшә башлады. Ата-анасы Ырынбур ятимен якларга тырышып караганнар иде, ул аларны да бик тиз үз урыннарына утыртты. Түлгән белә иде: боларны бүгеннән үз урыннарына куймасаң, иртәгә монда Түлгән үзе артык булачак, ягъни чыгып китәргә мәҗбүр булачак… Ә аның моннан чыгып китәргә исәбе юк иде, элеккеге вакыттагы кебек, үз исеменә төрле гаепләү сүзләре ишетеп яшәргә дә теләге юк. Бу өйдә тормыш бары тик Түлгән теләгәнчә генә була ала һәм булырга тиеш тә иде…

Ул кышны ничек кирәк, алай чыктылар, болар хакында Ырынбурга язып, Туранны борчып тормадылар. Сәрмәния генә ябыкты, сулды, өй эчендәге шәүләгә әйләнде. Әнисеннән күреп, кечкенә Әтил дә тынып калды, Түлгән өйдә вакытта, хәтта көлмәс, еламас та булды… Сабый күңеле үзен ярат-мауларын сизә иде шул…

Өйдәге хәлләрне Туран кайтып керүгә аңлады. Туганы Түлгәнне солдат хезмәтендә күргәннәре дә, тормыш та үзгәртмәгән, киресенчә, ул тагы да үҗәтләнеп, дөньяга үчләшеп кайткан иде. Әмма ул, элеккечә, астан этлек эшләп йөри торган Түлгән түгел, дөньяның уртасына басып, ачыктан-ачык үзе теләгәнне эшли торган кешегә әйләнгән иде. Әмма бу вакыт эчендә Туран да үзгәргән иде, ул хәзер бала атасы, нәселе һәм милләте турында кайгырта торган бер шәхескә әйләнеп бара иде. Ырынбурда уку еллары аның күп нәрсәләргә күзен ачты, ул бу илнең ни дәрәҗәдә черек икәнлеген аңлады, милләтенең зур һәм фаҗигале тарихын өйрәнеп тетрәнде, яңадан туды, борынгы нәселенең тарихын белеп таң калды… Туран хәзер тулысынча милләт тарихы белән яши иде, аның укуы да, эзләнүләре дә бары тик шушы юнәлештә — бөек татар тарихын яңадан торгызу юнәлешендә бара иде… Шушы кыска берзаман игезәк туганнардан ике төрле кеше әзерләп чыгарган иде, берсе — империя ялчысы, икенчесе — аның дошманы… Кем нәрсәгә әзер һәм сәләтле булса, күңел савытларына шул салынган иде… Әмма бу билгеләр хәзергә туганнарда тулысынча ачылып бетмәгән, үз вакытын көтә иде…

Хатыны белән улының боегып калган кыяфәтен, әти-әнисенең шыпырт кына йөрүләрен, кача-поса намаз укуларын күреп, Туран өйдәге хәлләрнең ни дәрәҗәдә җитди, катлаулы икәнен бөтенләе белән

аңлады. Ул игезәк туганы белән икәүдән-икәү, ирләрчә сөйләшеп карарга булды. Өйдә һәрвакыт кеше булганга, алар бакча башындагы таллыкка төшеп киттеләр. Түлгән, гадәттәгечә, сүзне бер яртыдан башламакчы булган иде, Туран аны кырт кисте.

— Исән-сау кайтуың яхшы булган, Түлгән,— дип, олыларча сүзен башлады ул.— Әмма «бер ярты»ларыңны куеп тор. Ул, беребезгә дә килешә торган нәрсә түгел…

Түлгән үзен чак тыеп калды. Ничек сөйләшә ул аның белән?! Һаман элеккечә, акыл сатып, ничек яшәргә өйрәткән булып маташамы?! Ут эченнән кайткан, шушы шәһәрнең хуҗасы булып торган кешене өйрәтәме? Россия героен?! Бу өч ел эчендә нәрсә күргән ул, тулай торакта каткан ипи кимереп ятып?!

Әмма Түлгән үзен тыеп кала алды. Чөнки Тураннан ниндидер тынычлык, олылык һәм сабырлык бәреп тора иде. Ул, үзенә нык ышанып, ниндидер бер эчке гайрәт белән сөйли, бер дә элеккеге юаш Туран түгел. Түлгән шунда гына аңлап алды: Туран бик нык үзгәргән, бөтенләй җитдиләнеп, хәтта кырысланып калган иде… Ике туган шулай, бер-берләренә карап, шактый эндәшми утырдылар. Алар элек тә аерым иде, хәзер исә — икесе ике дөнья… Түлгәннең кан һәм үлем, хыянәт һәм җинаятьтән торган тормышы Туран өчен ят дөнья, Туранның татар тарихы, фән дип йөрүләре Түлгән өчен кирәк түгел. Әйтерсең лә алар бөтенләй ят кешеләр… Әмма аларны ата-ана йорты, бер гаилә, уртак мәсьәләләр берләштерә, бергә утырып сөйләшергә, бергә яшәргә мәҗбүр итә иде.

— Эшкә урнашуың да, читтән торып укырга керүең дә әйбәт булган,— дип дәвам итте Туран, сүз дилбегәсен үз кулында тотып.— Әмма өйдә тынычлык бетеп киткән бит, туган… Әти-әни дә бик борчулы, Сәрмәния дә ятим кебек йөри…

— Соң, ятим булгач, ятим кебек йөрер инде. Ха-ха-ха! — Үзенең оста сүз әйткәненә куанып, Түлгән тешләрен ыржайтып көлеп җибәрде.

Туранның өстенә бозлы су сипкән кебек булды. Димәк, Сәрмәниянең әйткәннәре барысы да дөрес икән, бу «Рәсәй герое» кыш буе аларның канын эчкән икән. Ичмасам, кыш көне үк бу хакта хәбәр биргән булсалар, Туран берәр чарасын күргән булыр иде…

— Аның ятим булуына ул үзе гаепле түгел, синең яраткан Ватаның шул хәлдә калдырды аны, белеп тор, «Рәсәй герое»! — диде ул, үзен кулда тотарга тырышып.

Түлгәннең каратут йөзе тимгел-тимгел булып чыкты. Бөтен Чечняны, бөтен шәһәрне дер калтыратып торган Россия Герое белән шулай сөйләшәләрме?! Һәм кем диген?! Үз туганы булмаса, ул аны инде әллә кайчан бөтереп төрмәгә тыгып куяр иде, авызын да ачмас борын!

— Син Герой исеме белән авыз чайкама,— диде Түлгән, үзен чак тыеп.— Без аны кан коеп алдык…

— Кемнекен?

Туганының бу соравы Түлгәннең башына китереп суккан кебек булды. Аннан әле беркемнең дә болай төрәп сораганы юк иде… Ул бер мәл телсез торды, аннан Туранны әтәчләнү белән җиңеп булмаганын аңлагач, шаяруга күчкән булды.

— Әгәр мин дә өйләнеп куйсам, брат,— дигән булды ул, сүзне икенчегә борып.— Бер Наташаны алып кайтып утыртсам, ә?

— Ата йорты зур, барыбызга да урын җитәр,— диде Туран, җитди мәсьәләләргә артык тирән кереп килмичә.— Үзең беләсең, безнең башка барыр җиребез юк иде… Әти-әни дә каршы булмады, үзләре чакырып кайтардылар.

Түлгән эченнән генә тагы бер кайнап алды. Үзләре чакырып кайтарганнар! Түлгән анда үлем эчендә йөри, ә болар өйгә хуҗа булып ята. Түлгән белән киңәшү юк, нитү юк, кайтыгыз да торыгыз, имеш… Менә моннан соң алай булмас, моннан соң бу йортта Түлгән әйткәнчә булыр!

Туран аның эчендә нинди өермәләр кайнаганын аңламыйча калды, сүзне, нигәдер, өйләнү темасына борды.

— Чыннан да, сиңа өйләнергә кирәк, Түлгән,— диде ул туганнарча якынлык белән.— Тик Наташа дигән сүзеңне куй син, оныт. Аксуда сиңа татар-мөселман кызлары да җитәрлек, Наташалардан башка да…

Өйләнү, хатын-кыз мәсьәләсе Түлгәннең иң авырткан җире, яшерен ярасы иде. Чечня сугышы аны күп нәрсәләрдән мәхрүм итте, әмма моны ничек кешегә аңлатасың?! Үзенең итәк тутырып бала сөя алмаганлыгын ничек башкаларга әйтәсең, хәтта ул бертуганың булса да?! Тагы Туранның җиңгәнлеген, өскә чыкканлыгын танысынмы, үзенең бу мәсьәләдә дә җиңелгәнлеген, беткәнлеген күрсәтсенме?

— Минем өйләнү синең эш түгел инде, брат,— диде ул, сер бирергә теләмичә.— Һәм минем өчен милли мәсьәлә юк —ул әнә анда, Чечняда, кан эчендә батып калды! Понял?! Миңа динеңне дә, милләтеңне дә такма! Минем өчен барысы да бер, һәм мин монда сезгә милләтчеләр үрчетеп ятарга ирек бирмәм. Аңладыңмы?

Бу ямьсез сүзләрдән Туран урыныннан ук сикереп торды. Ул аңлады: туганы Чечнядан тәмам бозылып, холыксызланып, явызланып кайткан иде. Элек ул рәттән бөтен кешегә бәйләнеп йөрсә, хәзер әнә милли мәсьәләгә очып куна, дин дип авыз ачтырмый. Ул туганын кызганды, әмма аңа ничек ярдәм итәргә белмәде. Аның белән көн саен бергә яшәргә мәҗбүр булган ата-анасын, хатыны Сәрмәнияне, боларны күреп үскән улы Әтилне кызганды һәм алга таба болай яшәп булмаячагын аңлады. Ярар, ул Сәрмәния белән Әтилне алып, чыгып та китәр, ә ата-анасы нишләр бу Түлгән белән? Ул бит аларга суларга да ирек бирмәячәк, картларны гел үз кубызына биетергә тырышачак. Әти карт әнә мәчет ачтырам дип йөри, әни карчык та инде намазлык өстендә… Бер өйгә сыеп, ничек алга таба яшәрләр алар?

Бәлки сугыш Түлгәнне шулай каты бәгырьле, динсез, имансыз иткәндер, милләттән, нәселдән читләштергәндер? Бәлки аңа башка дөньяны күрсәтергә, башка нәрсәләр белән кызыксындырырга кирәктер? Дөнья бит әле Чечня сугышыннан һәм милициядәге җинаятьләрдән генә тормый… Анда мәхәббәт бар, анда милләт бар, анда дин, тарих бар, анда таң калырлык табигать бар… Ничек итеп туганы Түлгәнгә шуларны күрсәтергә соң, ничек итеп аны бу үте сытылырлык үчлекле дөньясыннан тартып чыгарырга?

— Тынычлан, Түлгән, сине беркем дә көчләп өйләндерергә җыенмый,— диде ул, аның мәгънәсез сүзләрен ишетмәгәнгә салынып.— Кемне яратсаң, шуңа өйләнерсең… Гомумән, өйләнергә өлгерерсең әле… Минем сиңа бер кызыклы тәкъдимем бар, тыңла әле…

Түлгән шикләнеп туганына карады. Тагы нәрсә акыл сатарга җыена икән инде бу интеллигент кисәге? Институтта укып йөргәч, әллә ул үзен барысыннан да акыллы дип уйлыймы икән? Менә ул Түлгән күргәннәрне күрсә, муеннан кан эчендә йөзсә, нинди булыр иде икән, нәрсә әйтер иде икән? Ә шушы мәмигә «везет» бит — ата-анасы да аны ярата, хатынның да чибәрен эләктергән, шәһәрендә аңа тиң юк, инде балалары үсеп ята… Бәләкәй чакта Туран һәрвакыт Түлгәнне сабырлыгы, акылы белән җиңә иде, көч кулланган булса да, Туран аны бер чиртүдә җиргә сеңдерә ала иде… Әмма ул беркайчан да Түлгәнгә кул күтәрмәде, ә Түлгән аңа этлекне күп эшләде… Ә ул аларның әнә, берсен дә хәтерләмәгән кебек, тагы Түлгәнгә ярдәм итмәкче булып кылана, акыл сата… Йә, тыңлап карыйк әле, нәрсә тәкъдим итәр икән бу студент кисәге?

Алар, малай чактагы кебек, яшел чирәм өстенә сузылып яттылар. Әйтерсең лә арада этләшеп үткән дистә еллар да юк, канлы чечен сугышы да юк, гаилә мәшәкатьләре дә юк… Алар, Җанбикә карчык белән Җиһангир картның игезәк уллары, үзләре бакча башына үрмәләп чыгып, беренче тапкыр зур дөнья белән танышалар… Әле кемнең кем буласын да белгән юк, язмышлар да билгеле түгел, холык-фигыльләр дә ачыкланып бетмәгән… Яшел чирәм өстендә, бер-берлә- ренә башларын терәп, әйтерсең лә нәни Туран белән Түлгән ята…

— Без быел җәй Чиләбе далаларында казу эшләре алып барабыз,— диде Туран, туганының җилкәсенә кулын салып.—Әйдә безнең белән, Түлгән? Бер дөнья күреп кайтырсың… Солдаттан соң бераз ял да итеп алырсың, табигатьтә булырсың, бөтенләй башка дөнья, башка кешеләр күрерсең, ә?

Түлгән аптырабрак калды. Ул мондый тәкъдим ишетермен дип бөтенләй көтмәгән иде, ул әле Туранның нәрсә әйтергә теләгәнен дә аңлап бетмәде...

— Нәрсә казыйсыз соң сез анда, хәзинәме әллә? — дип сорады ул, шаярган булып. Тирәнгә кереп, Туран алдында үзен бөтенләй надан итеп күрсәтәсе килмәде.

Туран бөтен күңеле, җаны-тәне белән яктырып, кабынып китте.

— Хәзинә, әлбәттә, хәзинә, дөрес әйттең, туганым! — диде ул, малайлар кебек мавыгып.— Без анда моннан 4—5 мең еллар элек төзелгән шәһәрне казып таптык! Ышанасыңмы, Түлгән, таштан йортлар, төрбәләр, курганнар, хәтта йорт эчендәге учак урыннары, җиһазлар кичә генә ташлап чыккан кебек… Боларны бит безнең борынгы төрки бабаларыбыз төзеп калдырган, бу җирләрдә татар нәселе яшәгән… Исеме дә җыр кебек яңгырап тора бит — Аркаим…

— Әллә алтын да таптыгызмы? — дип сорады Түлгән, туганының милли хисләр ташкынын тизрәк туктатырга теләп. Аны армиядә бу төркилеге, кысык күзләре өчен күп кыйнадылар инде, ул хакта хәзер аның ишетәсе дә килми…

— Алтын? — Туран сөрлеккәндәй туктап калды.— Әйе, алтын әйберләре дә чыккалый, әмма алар күп түгел. Эш алтында түгел бит, Түлгән, ә алтынга тиң борынгы тарихта, төрки-татар тарихында! Биш мең ел элек шундый шәһәрләр төзегән халыкка хәзер беркем дә кыргый, варвар дип әйтә алмас! Без бөтендөньяга аның үзебезнеке икәнен исбатларбыз! Әйдә безнең белән! Оныт ул Чечняны, дөнья бит әле сугыштан һәм үтерештән генә тормый, аның бөтенләй башка яклары да бар…

Туран, үзе дә сизмәстән, Түлгәннең тагы авырткан җиренә, женене китереп басты. Шулай… Ул анда ил өчен кан коеп йөрде, ә бу студент кисәге, җир казып, әкият сөйләп гомер уздырган. Һәм шул яшәү рәвешен, дөрес дип, Түлгәнгә дә төртмәкче була… Кем кемне өйрәтә бит әле, имеш, дөнья

үтерешләрдән генә тормый… Үзен шунда китереп тыксалар, ничек улар иде икән бу тәти егет? Бу чүпчарлары башыннан тиз чыгып очар иде…

— Мин сине акыллырак дип уйлаган идем, брат! — диде ул, Туранга түбәнсетеп карап.— Өч ел селкенеп укып йөреп, шушы әкияттән кала әйбер белмәдеңме? Кемгә кирәк мондый заманда синең ул шәһәр калдыкларың? Кем әйтте аны сиңа татарныкы дип? Бу җирдә әнә күпме халык яши! Кара аны, артык милләтчеләнеп, монда да Чечня китереп чыгарасы булмагыз, үзем ботыгыздан Урал тавына асып куярмын, понял? Аркаимнарыгыз, чуртларыгыз белән…

Хәзер инде тантана итәргә, акыл өйрәтергә Түлгәнгә чират җиткән иде. Ул Туранның үзен дә, мавыгуларын да, уй-хыялларын да түбәнәйтергә, яраксызга чыгарып калдырырга тырышты. Әмма ул әйтә дип кенә, Туран да сайлаган юлыннан борыла торган кеше түгел иде.

Сөйләшү барып чыкмады. Барып чыга да алмый иде, чөнки алар күптән инде икесе ике төрле кеше булып, дөньяга карашлары, аны кабул итүләре дә капма-каршы иде. Туран туганын кызганды, ә Түлгән аны күралмады. Туран дөньяга милли хисләр белән, мең еллык тарих күзлегеннән карый башлаган иде, ә Түлгәннең дөньясы үч, ачу, сугыш һәм үтереш белән тулган… Һәркем үзен хаклы санады, һәркем үз күңеленә туры килгән тормыш юлын сайлады…

Туран аңлады: Түлгәнне инде үзгәртерлек түгел иде…

Туран шуны да аңлады: гаиләсен, хатыны Сәрмәния белән улы Әтилне бу кеше янында, аның кара тәэсирендә калдырырга ярамый иде…

Ата-анасын кызганды, әмма Туран хәзергә аларга ярдәм итә алырлык хәлдә түгел иде…

Ул улы белән хатынын ата-анасы йортыннан алып, чыгып китәргә булды. Әмма кая барырга? Әле ике ел укыйсы бар, үзе тулай торакта, стипендия акчасына торып интегә, эшкә керсә, укуга, фәнгә зыян килә… Читтән торып укырга күчсә, шунда ук армиягә алып китәчәкләр, ул вакытта укуны да, гаиләне дә бөтенләй ташларга туры киләчәк… Нишләргә, кая барырга?

Туран бу хакта әти-әнисе белән сөйләшеп карарга булды. Алар инде Түлгәннең холкы белән килешкәннәр кебек тоела, киресенчә, Чечнядан исән кайтуына сөенеп, эшкә һәм укуына керүенә куанып, шуннан ямь табып яшәргә тырышалар иде. Бигрәк тә әнисе Түлгән белән Туран арасында йомгак кебек тәгәрәп йөри, ул гел Түлгәннең җаеннан торырга тырыша, чөнки Туранны көйлисе юк, ул болай да тәртипле, ипле бала. Ә менә Түлгәннең Сәрмәнияне эзәрлекләвенә, кечкенә Әтилне кагуына Җанбикә карчык барыбер иялөнә алмады, аларның араларын төзәтерлек сүз тапмады. Шуңа күрә, бу хакта Туран үзе башлап сүз каткач, ул сөенде генә, чөнки, чыннан да, алга таба болай яшәп булмый иде…

Түлгән өйдә юк чакны туры китереп, бары да бергә җыелдылар. Барысы алдында бер генә сорау тора иде: алга таба ничек яшәргә? Түлгәнгә «чыгып кит» дип әйтеп булмый, аның чыгып китәргә исәбе дә юк, урыны да юк. Сизелеп тора, Җанбикә карчыкның аны чыгарып җибәрәсе дә килми. Холкы җайсыз, күңеле каты, бу Чечня сугышыннан бигрәк тә усалланып, бозылып кайтты, бу хәлдә кемгә кирәк ул? Мондый холык белән ул ата-анасы янына гына сыя. Әмма инде яхшы аңлашыла: Түлгән булган җирдә Сәрмәния белән Әтилгә урын юк. Әле өйләнеп тә җибәрсә, Сәрмәнияләрне моннан барыбер кысрыклап чыгарачак ул. Туран хатыны, яшь баласы белән кая барыр? Әмма Туранның холкы яхшы, акылы башында, ул кайда да сыя ала. Ананың уйлавынча, бик авыр булса да, бу өйдән хатыны һәм улы белән Туран чыгып китәргә тиеш иде. Әмма моны аның үзенә ничек әйтергә? Рәнҗемәсме? Хәтере калмасмы? «Кудылар» димәсме?

Әмма бу йортта соңгы сүзне ана да түгел, бала да түгел, ата кеше әйтергә тиеш иде. Авыр булса да, бу хакта сүзне Җиһангир карт башлады:

— Үзегез күреп торасыз, без Түлгәнне кулдан ычкындырдык,— дип башлап китте ул сүзен, шактыйерактан уратып.— Балачактан аңа ачкыч таба алмадык, киресенчә, өйдә тавыш чыкмасын дип, гел аңа юл куйдык, этлегенә күз йомдык… Безнең арада, безнең күз алдыбызда ул безгә дошман булып үсте, безгә караганда, шул пычрак урамны, андагы бозыклыкны күбрәк яратты, күңеле азды… Соңыннан без инде аны тыя алмадык — армиягә киткәнче, аракысын да эчте, наркотиклар да кабып карады, кеше дә кыйнады, милициядә дә утырып чыккалады… Армиядән бераз акыл кереп, кеше булып кайтмасмы, дидек… Кая ул… Ул аннан кеше үтерергә өйрәнеп кайтты… Үзе исән кайткач, шунысына да сөенгән булдык, бала бит… Кайтып эшкә керүенә, укый башлавына да куандык — элеккечә, наркоманланып, кеше кыйнап йөрсә, нишләр идең? Наркоманлык мәсьәләсендә шигем бар, әлбәттә, кайвакытта ул бөтенләй ни эшләгәнен белми, котырына… Әмма хәзер закон үз кулында… Әмма җанны иң нык борчыганы — Түлгәннең Сәрмәния белән Әтилгә мөнәсәбәте… Җәберли ул аларны… Без дә әйтеп карадык, юк, үтми… Бала белән килен бик кызганыч, алар бу хәлләрне күрергә тиеш түгел иде… Алга таба нидер уйларга кирәк инде, улым… Син каршы килмәсәң, миндә бер тәкъдим бар…

Ата кеше шулай диде дә авыр эш эшләргә җыенгандай туктап калды. Атасының күңел газапларын сизеп, Туран үзе ярдәмгә килергә ашыкты.

— Мин Сәрмәния белән Әтилне Ырынбурга алып китәрмен, ахры, эти,— диде ул, башка юл күрмичә.— Квартирага керербез, көндез укырмын, төнлә эшләрмен, гаилә тотарлык акча табармын, Алла боерса… Башка чара юк, алар монда кала алмый инде, мин моны Түлгәннең үзе белән сөйләшкәндә үк аңладым…

Әмма ата кешенең әйтер сүзе ул түгел иде, мәсьәлә алай хәл ителердәй булса, ул бу сүзне башлап та тормас иде.

— Юк, улым, Ырынбурга алып китмә киленне,— диде ул.—Атасалга кайтарып куй син аларны…

Бу көтелмәгән тәкъдимнән, барысы да аптырашып, сүзсез калдылар. Беренче булып Җанбикә карчык телгә килде:

— Атасалга? — дип кабатлап сорады ул.— Анда өй торырлык түгел бит инде, атасы.

— Әле күптән түгел генә мин анда кайтып килдем,— дип сүзен дәвам итте ата кеше.— Өй, чыннан да, бераз бирешкән иде, мин аны, авыл осталарына түләп, яшәрлек хәлгә китердем. Бик яхшы килеп чыкты: миче, мунчасы, бакчасы… Балага үсү өчен менә дигән урын инде… Табигате, таулары, чишмәләре, дисеңме… Үземнең дә шунда кайтып яшисем килеп китте… Дөньяныкын белмәссең тагы… Менә монда мәчет төзелеше тота, шул гына…

Барысы да, гаҗәпләнеп, бер-берләренә караштылар. Атасал — Җиһангир картның туган авылы, Урал тауларына ябышып диярлек утырган татар авылы. Җиһангир карт сөйләгән йорт — аның төп нигезе. Авылда башлангыч мәктәп бар, почтасы, медпункты эшләп тора… Тимер юлдан да ерак түгел, шәһәргә дә якын… Ырынбурга да әле моннан караганда, аннан якынрак…

— Мин киленгә эш тә белешеп кайттым,— дип дәвам итте Җиһангир карт.— Мәктәптә эш бар, аның читтән торып институтта укыганын белгәч сөенделәр генә, чөнки яшьләр барысы да шәһәргә йөреп эшли, ә мәктәптә махсус белемсез авыл хатыннары укытып йөри икән… Безнең халык әйбәт анда, күрше-күлән нык, рәхәтләнеп яшәргә була… Әтил үсә төшкәч, үзегез уйларсыз тагы… Хәзер соңгы сүз сездән, балалар, карарны сез кабул итәсез…

Туран — Сәрмәниягә, Сәрмәния Әтиленә карады. Туран аңлады: әтисе авылга кайтып, йортны төзәтеп йөргән икән, димәк, ул инде бу исәпкә күптән кергән булган. Атасалны бик яхшы белә Туран, бәләкәй чакта ата-аналары белән алар анда еш кайталар иде. Урыны, чыннан да, искиткеч матур, хәтта кыргый матур… Ул өстеңә ишелергә торган кыя-таулар, тау итәгендәге урман-болыннар, ул ургып аккан тау чишмәләре, тирән сулы Карагай елгасы… Атасалны беренче күргән кеше: «Дөньяның җәннәте шушы икән»,— дип уйлый… Шуларны исенә төшергәч, Туранның йөрәге кысылып куйды. «Сәрмәния генә риза булсын иде»,— дип уйлады ул эченнән. Чыннан да, Ырынбурга да аннан якынрак, ул бит хәтта ай саен авылга кайтып йөри ала. Ә бу җәйдә ул, гомумән, шунда була ала, чөнки алар казу эшләре алып бара торган Аркаим да Атасалдан ерак түгел, һәрхәлдә, Аксуга караганда, берничә тапкыр якынрак. Бу мәңгелек кара төтен арасында, үз туганыннан сүз ишетеп, җәбер күреп ятканчы, Атасалга китүең мең тапкыр яхшы, мең тапкыр хәерле…

Ул, уйларына яклау табарга теләгәндәй, тилмереп хатынына карады.

— Мин риза,— диде Сәрмәния, иренең сүзсез ялваруын аңлагандай.— Син кайда барсаң, мин шунда китәргә риза, Туран. Ырынбурга дисәң — Ырынбурга, Атасалга дисәң — Атасалга. Соңгы сүзне син әйтәсең…

Шулай итеп, алар Атасалга кайтып киттеләр. Атасал аларны шаулап торган тау урманнары, чәчәкле болыннары, мәрмәр кыя-ташлары белән юлларына чыгып каршы алды. Йә Хода, булса да булыр икән шундый матурлык, тетрәндерерлек, күзгә яшьләр китерерлек кыргый, саф матурлык! Ир кеше була торып, хәтта Туранның да күзләренә яшь бәреп чыкты. Нәни улын кулларына күтәреп, бик озак карап торды ул биек тауларга… Кыя ташлардан, кымшанмыйча да, тирә-юньне мәгърур тау бөркетләре күзәтә иде…

— Менә безнең туган ил шушы була инде, улым,— диде Туран, әллә кечкенә улына, әллә үз-үзенә сөйләгәндәй.— Ата-баба йорты — Атасал шушы була инде…

Сәрмәниянең бу авылны беренче күрүе иде әле. Ул да бу хәтле матурлыктан тынсыз калды. Ул үзе — дала кызы, аның туган якларында, Ырынбур далаларында мондый кыя-таулар да, шаулап утырган урманнар да юк… Авыл өстендә атом бомбасы сынагач, чишмә-күлләр дә кипте, сулар агуланды… Ә монда әле бөтенесе дә дөнья яратылган замандагы кебек… Әйтерсең лә ул чаклардан бирле миллион еллар үтмәгән, бу тирәләргә бөтенләй кеше аяк басмаган… Исеме дә бик гаҗәп бит — Атасал… Нәрсәне аңлата икән ул?

— Галимнәр төрлечә аңлата,— диде Туран, Әтилне яшел аланга җибәреп.— Кемдер «чал» ди, кемдер «таш» ди… Бүгенге көнгә хәтле аңлата алучы юк әле…

— Ә нигә, бик аңлашыла бит,— диде Сәрмәния, аңа гаҗәпләнеп карап.— Ата-сал… Ата сүзе — әти дигәнне аңлата, сал — сал инде, үзең дә беләсең… Элек зур елгаларда сал агызганнар… Бер-берләренә беркеткән агач бүрәнәләр шулай елганы тутырып акканнар. Аның өстендә кешеләр дә бара алган, ягъни сал агызучылар…

— Сал сүзен беләм мин, әтидән ишеткәнем бар,— диде Туран.— Элек, яшьрәк вакытта, алар Агыйделдә сал агызганнар… Әмма нигә безнең авыл шулай дип аталды икән соң? Тирә-якта башка андый исемдәге авыл юк бит… Ата салы… Ата көймәсе була инде, хәзергечә әйтсәк… Тукта, тукта, бу хакта Бәндәбикә әбинең сөйләгәнен хәтерлим әле мин! Дөньяны су басканда, бер төркем кешеләр аталары ясаган салга, ягъни бикле көймәгә утырып исән калганнар, дигән иде ул. Алар, имеш, шушы тирәләргә килеп урнашканнар һәм авылга да «Атасал» дип исем биргәннәр… «Безнең нәсел — Нух пәйгамбәр нәселеннән башланган, шуңа күрә Нухаевлар фамилиясен йөртәбез»,— дип әйтергә ярата иде Бәндәбикә әби. Син аны беләсең инде, әтинең апасы ул… Менә җәйгә кунакка алып килербез әле үзен, Атасалга кайтырга бик ярата ул, хәзер кеше булмаганга гына кайтмыйдыр… Менә ул кайткач, нәсел шәҗәрәсе, авыл тарихы белән ныклап шөгыльләнә башлыйм әле. Авыл халкының сөйләгәннәрен дә язып барырга кирәк, син дә булышырсың, укытучы апа…

Ул хатынын үзенә якынрак тартты. Гомер буе аерым үз почмаклары булмаган, кеше алдында бер-берләренә якын килергә дә оялган ир белән хатын, бер-берләренә сыенып, сүзсез калдылар… Хәзер бөтен Урал таулары, чишмә-болынлыклар, бар табигать аларның туган йорты иде… Алар бу илгә, бу йортка хуҗа булып кайтып киләләр иде…

Шулчак янәшәдә сәер ысылдау тавышы ишетелде. Ата белән ана, сискәнеп, шул якка борылып карадылар. Алардан шактый читтә, билдән үлән арасында, кечкенә Әтил басып тора, ә аның каршындагы зур ташта, башын ыргактай катырып, кап-кара елан ысылдап ята иде… Әтил, берни аңламыйча, кулларын сузып, үзенчә нидер сөйләнеп, еланга таба атлый, елан исә аның саен катырак ысылдый, агулы теле белән яный иде… Тагы бер адым — Әтил кара елан куенына авачак иде…

Ата белән ана аңга килеп өлгермәделәр, һаваны ярып, ачы сызгыру авазы ишетелде. Ул арада баш очларыннан кара күләгә очып үтте һәм, таш булып, аска томырылды. Икенче мизгелдә инде кара елан, майлаган каештай елкылдап, бөркет авызында бәргәләнә иде… Тау бөркете аны бугазыннан алып, кыя башындагы оясына алып менеп китте… Әтил исә әллә бөркет җиленнән, әллә куркуыннан лып итеп җиргә утырды һәм кычкырып елап та җибәрде…

Менә шушы бер мизгел аларга тормышның никадәр нечкә, никадәр аяусыз, шул ук вакытта никадәр мәрхәмәтле дә икәнен күрсәтте… Бу тормышта алар әле таш араларына качкан кара еланнарны да, зәңгәр күкләрдә очкан тау бөркетләрен дә күп очратачаклар иде…

Атасал илендә, ата нигезендә, Урал тауларында аларны әнә шундый тормыш көтеп тора иде…

* * *

Сәрмәния урам яктан ишетелгән азан тавышына уянып китте. Башта ул үзенең кайда икәнлеген аңлый алмый торды. Кайда соң ул — төне буе төшкә кереп йөдәткән Атасалдамы, Туранны эзләп килгән Тимертаудамы әллә һаман Аксуда яшәп ятамы? Әйе, ул Аксуда иде, әмма бу йортка беренче тапкыр аяк басканга да ундүрт ел вакыт үтеп киткән шул… Ул кайнанасы белән кайнатасы йортында, әмма биредә инде аның газиз ире Туран да юк, аларның тормышын җәһәннәмгә әйләндергән Түлгән дә юк… Бөтенләй башка заман, башка тормыш… Аның каравы әнә буйга җитеп килә торган улы — Әтиле бар, Аллага шөкер, Туранның ата-анасы исән, Сәрмәния өчен өзелеп торалар…

Сәрмәния кичә кичтән булган хәлләрне күз алдына китерде. Кайнанасы тәмам үлеп беткән иде бит инде! Мәрткә китү дә шулай куркыныч була икән! Туран турында да нидер әйтте бит ул. «Атаңны күрдем, улым»,— диде… Иплән кенә, бүген тагы сораштырасы булыр әле… Мәрткә киткән кешегә дөресен күрсәтәләр, диләр бит… Әнә хәзер кайнанасы, берни булмагандай, әкрен генә кыштыр-кыштыр намазга әзерләнеп йөри. Кайнатасы Җиһангир карт өй каршындагы агач мәчеттә иртәнге намазга азан әйтә, ул намазын да шунда укып чыгачак. Урамда әле караңгы, төн кебек, әмма бу инде төн дә түгел — таң белән төннең очрашкан вакыты… Офыкта инде таң яктысы беленеп килә, урамда шундый тыныч, хәтта өй каршындагы агачларның яфраклары лепердәгәне дә ишетелми… Әле кошлар да сайрамый, күршеләрнең әтәче генә, көндәлек үз эшен белеп, бөтен дөньяга сөрән салып кычкыра…

Сәрмәния юрган астыннан гына кайнанасының намаз укуын күзәтеп ята. Ул үзе һаман намазга баса алмый әле, нидер тота, нидер җибәрми… Теге вакытта Туран да бик ашкынып, дәртләнеп кереп киткән иде дингә, менә ахыры гына ничек килеп чыкты… Туран аның да намаз укуын бик теләде, аерым догаларын да өйрәтә башлаган иде, аннан инде намаз кайгысы калмады… Менә хәзер Сәрмәния үзен юллар чатында адашып калган ятим кебек хис итә, нәкъ балачагындагы кебек… Үскәндә әти-әнисе булмады, хәзер янында ире юк… Ә баланы үстерергә, аякка бастырырга кирәк. Кемгә, нәрсәгә таянып,

кемнәр ярдәмендә? Кайнанасы белән кайнатасы инде үзләре картлар, Җанбикә карчык әнә үлгәндә генә калды… Элеккеге кебек, кеме дә юк икән Сәрмәниянең… Үз өе дә юк, укыганы буенча эшли дә алмый… Ә кулында — бала, ир бала… Йа Алла, үзең ярдәмеңнән ташлама инде…

Ярдәм сорап, Аллаһка мөрәҗәгать иткәнен Сәрмәния үзе дә сизми калды. Юк, бу гадәти генә сорап кую түгел иде, нindидер бер мизгелдә, Сәрмәния, чыннан да, үзенә ярдәм итәрлек көчнең бары тик Аллаһ икәнен аңлаган кебек булды. Әллә кичәге хәлләрне күрү, үлем белән очрашу аңа нык тәэсир иткән идеме, әллә кичә генә үлеп яткан Җанбикә карчыкның ихластан намаз укуы шулай хисләндердеме — ул беренче тапкыр чын күңеленнән Аллаһтан ярдәм сорады һәм ярдәм буласына ышанды. Аның күңеле тынычланып китте, Җанбикә карчык артыннан ул да белгәннәрен укый, кабатлый башлады… Кичәге кич үлем белән башланса, бүгенге көнгә исән-сау килеш, дога белән керделәр… Бу — аларны көтеп торган могҗиза һәм зур сынауларның әле башлануы гына иде…

Җанбикә карчыкның бүген хәле яхшы күренә иде, шуңа күрә, онытып бетергәнче, Сәрмәния аннан иплəп кенә мәрткә киткәндә ниләр күрүен сорап карарга булды. Ул бит кичә Туран турында бик сәер сүзләр әйтте. «Шушы таулар арасында, җир астында»,— диде… Бу авыру карчыкның бер саташуы гына идеме, әллә, чыннан да, аның күзенә берәр нәрсә күренгәнме? Кичә ул, саташып, шактый нәрсәләр сөйләде, «Аксу астында җәһәннәм бар»,— диде, Әтил белән чиратлашып, нindидер сәер шигырь әйттеләр… Җанбикә карчык белән мавыгып, ул улы Әтил турында онытыбрак та җибәргән әле… Чыннан да, нинди шигырь сөйләде соң ул Әтил мәрткә китеп яткан әбисе янында? Каян белгән, өйрәнгән ул аны? Андый шигырьне Сәрмәния үзе дә белми, ул, шигырь дисәң, шигырь түгел, әллә нинди шомлы хәбәр, кисәтү кебек…

Иртәнге чәйне эчкәндә, ул иплəп кенә шул хакта сүз кузгатты. Туран турында соңыннан сорарга булды, чөнки аш янында карчыкның йөрәген җәрәхәтлисе килмәде. Ә менә парлап укыган теге сәер шигырь турында сорап карарга булды.

— Әнкәй, сез кичә Әтил белән чиратлашып нинди шигырь укыдыгыз ул? — дип сүз башлады ул сак кына.— Нәрсә иде ул, мин андый шигырьне беренче ишетәм?

— Шигырь түгел ул, кызым… — Җанбикә карчыкның йөрәгеннән тагы шомлы дулкыннар йөгереп үткән кебек булды.— Шигырь түгел — хәбәр… Миңа аны әйтеп тордылар… Һәм күрсәттеләр…

— Нәрсәне?

Килененең бу соравына каршы карчык дәшмәде. Әллә аңа бу хәлләрне искә төшерү авыр иде, әллә онытып җибәргән —ул дәшмәде… Аның каравы Әтил тиз генә җавап бирергә ашыкты:

— Дөньяны су басканны күрсәттеләр аңа… Әби шуны сөйләде…

— Ә син кайдан беләсең?

— Мин дә төшемдә шуны күрдем… Әллә ничә көн рәттән инде… Миңа да шушы ук сүзләрне сөйләделәр… Аннан күрсәттеләр…

Сәрмәниянең эченә курку төште. Ярый, Җанбикә карчык мәрткә китеп саташсын инде, ә бу балага кайдан килеп кергән бу төш? Төш кенә түгел, саташу бит бу, нindидер шигырь, хәбәр, ди, нәрсәнедер күрсәттеләр, ди… Соңгы вакытта гел ялгыз калып, әллә бу бала авырый башлаганмы соң, Ходаем?

Килененең куркып калуын күреп, Җиһангир карт сүзгә катнашырга ашыкты.

— Син хәвефләнмә, килен, андый төшләр була ул,— диде ул тыныч кына.— Төшләрнең Аллаһтан кергәне бар, шайтаннан килгәне бар… Бу төш — хикмәтле төш, хәбәр… Дөньяны су басу турында Коръәндә дә, башка дин китапларында да бар…

Әтил ашаган җиреннән туктап калды. Ничек инде — Коръәндә дә бар?

— Безнең тарих китабында ул су басу турында әкият дип язылган бит, бабай,— диде ул.— Син бит Коръәннең һәр хәрефе дөрес, дигән идең. Алайса, дөньяны су басу турында хәбәр дөрес буламыни, ул чыннан да булганмыни?

— Әйе, улым, бу хакта Коръәндә берничә урында хәбәр бар, дөньяны су басу чыннан да булган,— диде бабасы, икеләнергә урын калдырмыйча.— Тик бу хакта төш ничек сиңа килеп кергән менә, мәрттә вакытта әбиеңә күренгән — монысы бик гаҗәп хәл… Бер-бер хикмәте бар инде моның, әмма Аллаһтан вакыты җитмичә торып, без моны белә алмаячакбыз…

Өстәл янында сүзне шуннан артык куертмадылар. Җанбикә карчыкның да кәефе юк иде, ул әле кичәге хәлләрдән айнып, арынып та җитмәгән, аңа ял, тәрбия кирәк иде. Моны күреп, Сәрмәния берничә көнгә биредә калырга булды. «Бүген —җомга, алда ике көн ял,— дип уйлады ул.— Кешеләрне ашатасы юк… Әтил дә бераз ял итәр әби-бабасы янында… Карт-карчыкны да бераз карарга, тәрбияләргә кирәк, бигрәк ятим хәлендә калганнар бит икесе генә…»

Сәрмәниянең бу фикерен белеп, Җиһангир карт белән Җанбикә карчык бик сөенделәр. Өй эче тагы да нурланып, ямьләнеп киткән кебек булды. Җанбикә карчыкны, чәйләр эчертеп, чиста урынга яткырдылар. Сәрмәния, берәр камыр ризыгы пешерергә ниятләп, мич тирәсендә кайнаша башлады,

Җиһангир карт белән Әтил урамга ук чыгып киттеләр. Әтил, чыгу белән, бакча башына таба йөгерде, песи кебек тал башына үрмәләде. Җиһангир картка да аның артыннан бармыйча чара калмады.

— Бабай, бабай, кара әле, моннан бө-ө-өтен Аксу күренә! —дип кычкырды ул өстән.— Завод торбаларын саныйммы? Бер, ике, өч, дүрт, биш… ун… әй, бәк күп инде! Ә мәчет манарасы —бер генә. Аның каравы иң матуры, ие бит, бабай?!

Җиһангир карт тал төбендәге күләгәгә килеп утырды. Бүген иртәдән бирле кыздыра иде. Көннең шулай матур булуына да, оныгы белән менә шулай сөйләшеп утырырга җай чыкканына да бик сөенде ул. Югыйсә соңгы вакытларда гел авыр хәбәр дә кайгы-борчулар… Ике малайдан тиң хәбәр юк, карчыгы чак үлми калды… Имән кебек ир үзе дә гомерендә беренче тапкыр ару, талчыгу сизде… Бу — яшәп ару, авырлыклардан ару иде… Шушы мәчете, намазлары, азаннары булмаса, ул да карчыгы кебек күптән сыгылып төшкән булыр иде инде… Тормыш кисәк кенә басты да китте шул… Башта Түлгән бөтен гомерләрен бозды, аннан Туран белән менә шулай килеп чыкты… Хәзер менә янында икесе дә юк… Кайда икәнлекләрен белүче дә юк… Картлык көннәрендә шушы хәл… Җитмәсә, ничә тапкыр инде Җанбикә карчык котны алды… Мәрткә китә дә уянмый гына… Аннан әллә нинди кот чыгарлык нәрсәләр сөйли… «Шәһәр астында җәһәннәм бар, безнең Аксу гөрләп яначак»,— ди… Гел тыңлый торгач, ышандырып, куркытып та куя… Әле бу балаларның килеп чыгуы бик яхшы булды, гел кара кайгы белән яшәп булмый бит инде!

— Улым, безнең мәчет манарасы иң матурымы? — диде ул, үзе дә балаларча куанып. Чөнки ул — Җиһангир карт үзе төзеткән мәчет бит!

— Әйе, бабай! Әнә генә бит ул! Син шуннан кычкырасыңмы?

— Кычкырмыйм, улым, азан әйтәм… Теләсәң, сине дә өйрәтермен, яме?

Малай бабасы янына сикереп төшкәнен сизми дә калды.

— Манара башыннан кычкырырга да рөхсәт итәсеңме, бабай?

— Өйрәнсәң, рөхсәт тә итәрмен. Тик хәзер манара башына менеп йөрү юк бит инде ул, улым, техника заманы. Бабаң да мәчеттәге микрофонга азан әйтә, ә ул бөтен тирә-юньгә яңгырый…

Әтилгә күңелсез булып китте. Әй, манара башына менеп кычкырмагач аны!

— Мин өйрәнсәм, манара башына менеп кычкырам, яме, бабай! — диде ул.

Бабасы кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Ярар, балам, ярар, өйрән генә, мәчет түбәсенә менеп кычкырырсың,— диде ул, рәхәтләнеп.

Әтил бабасына сыеныбрак утырды. Рәхәт бик рәхәт иде аңа болай утыруы. Бабасыннан әтисе исе килә — таза, нык, сәламәт ир-ат исе… Җил исе, тимер исе, җир исе… Их, Әтилнең әтисе хәзер янында булса… Бөтен дөньяны, бөтен Урал тауларын әйләнеп чыгарлар иде алар хәзер… Әтил укырга керәсе елны да, солдаттан ялга кайткан арада, ул аңа күпме җирләр күрсәткән иде бит! Агыйделнең башланган урынында булдылар, ул тирәләрдә, палаткалар куеп, ничә көн яшәделәр… Аркаим дигән җирдә булдылар, әллә нинди борынгы шәһәр калдыкларын, курган һәм төрбәләрне күрделәр… Әтисе аны бик тә Урал тауларындагы иң борынгы мәгарәләргә алып барырга җыенган иде, өлгерә алмады — ялы бетеп китте… Аннан соң ул инде кайтмады, бөтенләй юкка чыкты…

Малай, нәрсәдәндер моңсуланып, бабасының култык астына борынын төртте. Бабасы да оныгының күңелендәниләр кайнаганын аңлады, ахры, аны үзенә ныграк кысты. Завод торбаларының ачы итеп кычкыртып җибәрүенә икесе дә сискәнеп киттеләр, тагы чын тормыш, бүгенге көннәре исләренә төште.

— Бабай, әби кичә мәрткә киткәндә, Аксу утта яначак, диде… Сез дә янарсыз микәнни? Бәлки сезгә моннан китәргә кирәктер, бабай?

Оныгының шулай гаять җитди итеп сорап куюына Җиһангир карт, бераз аптырап, җавапсыз калды. «Әбиеңнең саташуы гына ул»,— дип әйтсәң, бик үк дөрес булмас, чөнки мондый хәлне ул инде мәрткә киткән саен күрә… «Бу хәлләр бик булырга мөмкин»,— дисәң дә, баланың куркуы, гел хәвефләнеп яшәве бар…

— Барысы да Аллаһ кулында инде, улым,— дип җавап бирде ул, бик киңәймичә генә.— Нәрсә язса, шул булыр… Дөрес яшәргә кирәк, уттан шул гына коткарачак…

Бу турыда сөйләшә башлагач, Әтилнең инде болай гына туктыйсы килми иде.

— Бабай, бабай! — дип ялынды ул.— Дөньяны су басу турында сөйлә әле! Син бит бу хакта дини китапларда бар, дидең… Чынлап та, дөньяны су басканмыни?

Җиһангир карт, аякларын сузып, җайлабрак утырды. Ул Коръәннән, тәфсирләрдән, пәйгамбәрләр тарихыннан укыганнарын исенә төшерергә тырышты. Фикерен бераз туплагач, малайга да аңлашылырлык дәрәҗәдә сөйли башлады:

— Өйгә кергәч, мин сиңа Коръән тәфсирен, пәйгамбәрләр тарихын бирермен, алар татар телендә,— диде ул.— Анда дөньяны су басу тарихы бик ачык язылган… Ә хәзер дин буенча үзем белгәннәрне сөйлим, тыңла, алайса…

Әтил чирәмгә сузылып ятты да бабасына текәлде. Ул бабасының һәр сүзен, сөйләгәннәрен үзенең төше һәм белгәннәре белән чагыштырып барырга тырышты. Бабасының сөйләгәннәре аның өчен хак дөреслек иде, чөнки ул бик белеп, дин белән бәйләп сөйли бит!..

— Элек дөньяда бик зур гәүдәле кешеләр — алыплар яшәгән, улым,— дип дәвам итте Җиһангир карт, бик борынгы заманнарга китеп.— Пәйгамбәребез Мөхәммәт салаллаһу галәйһиссәламнең хәдисләреннән күренгәнчә, беренче кеше Адәм галәйһиссәламнең буе 60 терсәк озынлыкта булган, аркылысы — 7 терсәк… Ягъни аның буе 30 метр озынлыкта була, әнә безнең мәчет манарасы кадәр…

Малай авызын ачып калды. Бер бабасына, бер башын күккә чөеп утырган мәчет манарасына карады… Эссе рәшәдә мәчет манарасы селкенеп, аңа таба килә кебек тоелды.

— Җир йөзендәге беренче кешеләр әнә шундый куәтле булганнар, улым,— дип дәвам итте Җиһангир карт.— Алар башта Аллаһ кушкан тәртип буенча яшәргә тырышканнар, әмма араларына гел шайтан кереп, котыртып торган. Атабыз Адәм белән анабыз Һаваның Кабил исемле уллары энесе Һабилне үтерүдән дөньяда явызлык башланган… Бу эшкә аны явыз шайтан котырткан, көнчелектән шулай эшләгән…

Карт тынып калды… Күз алдына үз уллары — Туран белән Түлгән килеп басты… Бер дә борынгы заманнарга китәсе юк, күз алдында, үз балалары арасында, үз гаиләсендә шушы хәлләрне күрде ата кеше… Түлгәннең Туранга карата көнчелеге, явызлыгы, күрәлмавы бер дә борынгыларныкыннан ким түгел иде… Ул вакытта аларны бәла-казадан, фаҗигаләрдән Аллаһ үзе саклады, әмма икесен дә юкка чыгарды… Бәетләрдәге кошка әйләнгән Сак-Сок балалары кебек күздән юк булдылар…

— Шуннан дөньяны су басканмы, бабай?

Оныгының шушы беркатлы соравы картны тагы бу дөньяга кайтарды, ул, кайда туктап калганын исенә төшерергә тырышып, тагы сөйли башлады.

— Юк әле, улым, Адәм галәйһиссәламнең балалары, җирдә пәйгамбәрлек итеп, әле бераз яшәп карыйлар. Әмма заманнар үтү белән, Аллаһның әйткәннәре онытыла башлый, кешеләр ни теләсә, шуны кылана, аза башлыйлар… Алар үзләренең бу көч-куәтләрен дә, бөтен җир йөзенә хуҗа булып, рәхәтләнеп яшәүләрен дә Аллаһтан икәнлеген таныргa теләмиләр. Җирдә бозыклык, азгынлык арта, кешеләр, төрле сыннар ясап, Алла урынына шуларга табына башлыйлар, Аллаһны исә бөтенләй оныталар. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә аларга үз араларыннан бер яхшы кешене пәйгамбәр итеп җибәрә, бу — Нух пәйгамбәр була. Ул кавемен 950 ел буе иманга чакыра, бер Аллаһка табынырга өнди, сынымнардан, ялган иләһәләрдән баш тартырга чакыра… Әмма халкы аны тыңламый, Нух пәйгамбәрне ташлар атып, кыйный-кыйный араларыннан куалар… Берничә кеше генә, аңа ышанып, иманга килә… Нух пәйгамбәр, бу явыз кавем белән арасын өзүне сорап, Аллаһка дога кыла. Аллаһ бу изге кешенең догасын кабул итә. Ул аңа бер көймә ясарга боера. Кавеме аннан көлә: «Әле кичә генә син пәйгамбәр идең, бүген балта остасы булдыңмыни?» — дип… Алар һаман иманга килмиләр, залимлекләрен һәм бозыклыкларын дәвам итәләр… Шуннан соң Аллаһ аларга яңгырны туктата, елгалары кибә, болар суга тилмерә башлыйлар… Бу явыз кавемнең сулары гына түгел, нәселләре дә корый башлый —хатыннары бала таба алмый… Әмма бу аларга җибәрелгән җәзаларның әле башы гына була, бу явыз кавемне алда зур бәла-казалар, фаҗига көтә…

— Дөньяны су басамы? — дип сорады Әтил, бу хәлләрне күңеле белән сизенгәндәй.

— Әйе, улым, шушы хәлләрдән соң дөньяны су басу башлана… Аллаһ күкнең ишекләрен ача һәм җир өстенә көчле яңгыр ява башлый… Яңгыр шул хәтле көчле була, җир өстендә куәтле елгалар барлыкка килә… Нәтиҗәдә күк суы белән җир суы бергә кушыла, беркайда качып котылыр урын калмый. Аллаһ шул чагында Нух пәйгамбәргә һәм иман китергән кешеләргә көймәгә керергә әмер бирә, һәр хайваннан берәр пар алырга куша. Әмма бу көймәгә Нух пәйгамбәрнең бер улын һәм бер хатынын кертми, тегеләр иман китермәгән булалар, ягъни Аллаһка ышанмыйлар, Нух пәйгамбәрдән көлгән булалар… Алар туфан суында батып үлә… Бөтен кеше шул чагында батып үлә, Нух пәйгамбәрнең иман китергән нәселе һәм аларга ияргәннәр генә исән кала… Нух пәйгамбәр көймәсе иксез-чиксез су дәрьясында йөзеп йөри һәм Аллаһ теләге белән бер тауга килеп туктый… Шулай итеп, Аллаһ аларны мөбарәк булган урынга хәере белән индерә… Җирдә кешелек икенче тапкыр шул Нух пәйгамбәр нәселеннән тора…

— Без дәме?

— Без дә, улым… Бөтен кешелек шуннан тарала… Татарларның борынгы тарихында, нәсел шәҗәрәләрендә безне, ягъни төрки халыкларны, Нух пәйгамбәрнең улы Яфәс нәселе, дип язылган… Ягъни Яфәс улы Төрек, аның улы Алып, аның уллары Болгар һәм Бортас, алардан инде безнең

борынгы бабаларыбыз киткән… Болар хакында әтиең бик күп белә иде инде, миннән дә нәсел тарихы турында күпме сорашты, Уралдагы татар, нугай, типтәр, мишәр авыллары буйлап күпме йөрде, шәҗәрәләр, риваятьләр туплады… Армиядән кайткач, укуын аспирантурада дәвам итәсе иде бит атаң… Зур галим булыр иде хәзер, бу хәтле белеме белән… Менә сиңа сөйләр иде ул татар тарихын… Мин башка өлкәдә укыдым шул, улым. Техника, төзелеш эшләрен мин яхшы беләм, динне, тарихны үзлегемнән генә укыдым, анысын да бик соңлап… Шуңа күрә сиңа әллә нәрсә сөйли дә алмам… Өйдә әнә атаңнан калган кайбер китаплар саклана, анаң Тимертауга күчкәндә, монда китереп куйган иде. Шуларны актаргала бераз, аларда күп нәрсә булырга тиеш…

Сүз тагы, ихтыярсыздан, Туранга барып тоташты… Әгәр Әтил шыпырт кына әбисеннән сорап караса — мәрткә киткәндә, аны кайда күрде икән? Ул: «Атаң җир астында, шушы таулар арасында»,— диде бит. Нәрсә күрде икән әбисе? Әтил сорагач, бәлки исенә төшерер аны кайда күрүен… Шуны белсә, Әтил үзе барып алыр иде әтисен! Нигә бабасы белән әнисе Җанбикә әбидән шул хакта җентекләп сорашмыйлар икән? Әй, ышанмадылар бит алар аңа! Ә Әтил ышана менә, әбисенең һәр сүзенә ышана — дөньяны су басканны күрүенә дә, җир астында Әтилнең әтисен күрүенә дә, хәтта Аксу астында ут булуына да… Ул әбисеннән җентекләп кенә үзе сорашыр әле… Тик әнисе ашыктырып, Тимертауга гына алып кайтып китмәсен! Җәй буе анда бәрәңге әрчеп, чөгендер пешереп ятасы килми Әтилнең! Аның әби-бабасы янында яшисе, белмәгәннәрен беләсе, күрмәгәннәрен күрәсе, әтисеннән калган тарих китапларын укыйсы килә! Әллә бабасына ялынып карасынмы икән, Әтилне беразга монда калдырсын әле, дип?

— Бабай, минем әни белән Тимертауга кайтып китәсем килми… Сездә калыйм әле бераз?

Җиһангир картның үзенең дә оныгын яныннан җибәрәсе килми иде. Баланың иң нык кызыксына, эзләнә торган чагы, вакытында дөрес юнәлеш бирмәсәң адашуы, саташуы да бар… Түлгән белән Туран үскәндә, ул аларга азрак игътибар бирде, завод эше буенча командировкалардан, юлдан кайтып кермәде. Әниләре дә гел заводта булды… Вакытында яннарында булса, бәлки болай килеп тә чыкмаган булыр иде… Бигрәк тә Түлгән белән… Түлгән бераз мәрхәмәтлерәк булса, бүгенге көндә менә бу бала да алар янында үскән булыр иде, килен дә чит-ят җирдә әллә кемнәргә аш пешереп йөрмәс иде… Иң мөһиме, Туран яннарында булыр иде… Шушы кыска бер гомер эчендә барысы да буталып, асты-өскә килеп бетте шул… Ике баласы күз алдында суга төшкәндәй юк булды… Инде монысын —оныгын югалтырга һич ярамый… Хәзер инде Җиһангир карт үзе дә башка кеше, ул дөньяга бөтенләй башка күз белән карый, бөтенләй башка нәрсәләрдән мәгънә таба… Картайган көнендә ул дөньяны өр-яңадан ачты… Шушы белгәннәрен башкаларга, нәселенә дә биреп калдырырга кирәк. Калдырырлык бердәнбер кеше — менә шушы бала… Оныгын бу кара дөнья тырнагына бирмәс өчен, ул барысын да эшләячәк, иншаллаһ!

— Каласың, улым, каласың, Алла боерса! — диде карт, дәртләнеп.— Анаң белән үзем сөйләшермен. Теләсәң, җәй буе тора аласың, укырга барганчы. Барасы килгән җирләреңә барырбыз, иркенләп, укыйсы килгән китапларны укырсың… Азан әйтергә дә өйрәнербез, шулай бит!

Әтил шатлыгыннан бабасын кочаклап алды. Ул бабаларында җәй буе торачак! Ул бабасы белән әллә кайларга барачак! Ул әтисенең китапларын укыячак! Ул да әтисе, бабасы кебек галим кеше булачак!

Шул шатлыклы хәбәрне әйтергә дип, ул өйгә йөгерде. Бөтен бакчага, тирә-юньгә әнисе пешергән тәмле ризык исләре таралган иде… Бала кеше бу мизгелләрдә бик бәхетле иде… Балачакта бәхетле булу өчен янында яраткан кешеләрең һәм хыял белән яшәү дә җитә шул… Әтил, кочагын җәеп, хыяллары каршына йөгерде… Завод торбаларыннан ишетелгән ямьсез аваз аны бу юлы куып тота алмады — малай аны ишетмәде дә, чөнки ул бөтенләй башка дөнья, башка уйлар белән яши иде…

* * *

Килене аны йокларга дип җайлап яткырса да, Җанбикә карчыкның күзенә йокы кермәде. Ул мәрттә күргәннәреннән бик нык тетрәнгән иде. Карты белән килене күңеле булсынга гына алар белән сөйләшкән булды, ясап биргән чәйләрен эчте, ә үзе һаман өн белән төш арасындагы саташулы бер хәлдә иде… Әле аның өстенә, шаулап, су таулары ишелеп төшә, әле аяк астында дөрләп җир яна башлый… Шул су таулары, ут-ялкын эчендә — аның балалары, уллары… Берсе җир астында, үлем базында йөри, икенчесе диңгез артында, богауда ята… Мәрткә киткәндә, аңа Түлгәнне дә күрсәттеләр, ул бу хакта өйдәгеләргә әйтмәде генә… Чөнки Түлгән өчен биредә беркем сөенмәячәк тә, көенмәячәк тә… Шуңа күрә әйтеп тә тормады… Аның балакае, газизе, Түлгәне тимер богаулар белән богауланып, җиде диңгез артындагы утрауда, җиде ят арасында ята… Утрау тирәли ерткыч балыклар йөзеп йөри, беркая кача торган түгел… Адым саен — озын каланча, аларда, мылтык тотып, әллә нинди хәрбиләр басып тора… Аның Түлгәне ничек монда килеп эләккән соң? Кайда ул җир, нинди ябык утрау ул?

Җанбикә карчык ыңгырашып куйды. Килене Сәрмәния, эшеннән туктап, аның ягына карап алды. Карчык газаплы сулышын эчкә йотты да күзләрен йомды. Йоклый, дип белсен… Аларга боларны сөйләүдән ни мәгънә? Барыбер ышанмыйлар бит… Шул Әтил сабыйдан кала, беркем дә ышанмый аның күргәннәренә… Җанбикә карчык шул мәрткә киткән җиреннән инде мәңгегә ятып та калган булыр иде, дулкын тавы инде аны басып та калган булыр иде — шушы бала ярдәмгә килде… Үкереп өскә килгән кара давыл арасында ул шушы сабыйның тавышын ишетте, инде беттем, инде төпкә киттем дигәндә, аның җылы кулларына тотынды… Шушы ихлас бала аны теге дөньядан алып чыкты, алып кайтты… Бу бала аларның тормышына бәхет тә, бәхетсезлек тә алып килде…

Өйгә шушы бала килеп керү белән, алар тормышында шау-шу, ыгы-зыгы башланды. Түлгән башта ук аларның икесен дә яратмады: Сәрмәнияне дә, нәни Әтилне дә… Шулар аркасында туганы Туран белән дә арасы өзелде… Нигә шулкадәр күрәлмады ул аларны? Теге вакытта, Тураннар җыенып чыгып киткәч, Җанбикә аның белән ипләп кенә сөйләшеп тә карады.

— И әни, мин анда күргәннәрне күрсәң, син бу хакта сорамас идең,— дип кырт кисте Түлгән.

Ул төннәр буе уһылдап, аһылдап, ыңгырашып чыга иде. Әшәке итеп кычкырып, урысча сүгенеп саташып уянган чаклары да күп булды… Улының җаны да, тәне дә авыру иде — ана кеше моны сизмиме соң? Түлгәндә кеше кайгысы түгел иде, үзенең эчке тормышын да ул башкаларга күрсәтәсе килмәде… Ул Чечнядан кешеләрне күрәлмас хәлгә килеп кайтты… Ул шәһәргә хуҗа кебек, герой булып кайтып керсә дә, күп нәрсәләргә бәйле иде: үзен яллаган органнарга, бер мизгелгә дә исеннән чыкмаган канлы хатирәләргә, шуларны онытыр өчен яңадан капкалый башлаган ак төймәләргә, наркотикларга… Һәм шундый вакытта аяк астында — чит кешеләр… Туранның яшь, гүзәл хатыны, алма кебек тупырдап торган баласы… Түлгән беркайчан да күрә алмаячак шәхси бәхет…

Җанбикә карчык сизә иде: үлеп көнләште Түлгән туганының шәхси бәхетеннән… Тураннар чыгып киткәч, әнисе аны әллә өйләнерме, өйгә килен алып кайтырмы дип көткән иде. Юк, өйләнмәде Түлгән, киресенчә, үзенә йомылды, беркемне якын җибәрмәде… Кеше арасында, ниндидер чире бар икән, өйләнә алырлык түгел икән, дип тә сүз чыгардылар… Чеченнар тотып алып, шундый хәлгә китергәннәр икән, дип сөйләүчеләр дә булды… Эше буенча тагы берничә тапкыр Чечняга барып кайтты… Бәлки Чечняга да булмагандыр, чөнки Түлгән беркайчан, беркемгә берни сөйләми иде. Җыена һәм чыгып китә, мөгаен, кая җибәрсәләр, шунда китәдер, нәрсә эшләргә кушсалар, шуны эшлидер… Түлгәннең кеше кешесе булуын, кемнәрнеңдер яшерен эшләрен эшләп йөрүен ата белән ана күптән сизгәннәр иде инде. Әмма аңа тәэсир итәргә, тормышын башка якка үзгәртергә алар көчсез иде…

Һәм шул бер китүендә Түлгән бөтенләй юкка чыкты. Кавказ тауларында чеченнар үтереп ташладымы, артык күп белгәнгә үзенекеләр юк иттеме, яшерен йомыш белән тагы берәр җиргә китереп тыктыларммы — ата белән ана берни белмиләр иде… Һәм шул китүеннән ул инде менә биш ел юк… Исәнме ул, юкмы, кайларда йөри — алар белми… Җиһангир гына бер тапкыр урамнан ишетеп кайткан иде, имеш, Түлгәнне Чечняга мөселманнар өстеннән шымчылык итәргә җибәргәннәр икән, имеш, ул алар арасында мөселман булып йөреп, урысларга барысын да хәбәр итеп тора икән… Имеш, аны шулай, кысык күзле һәм каратут йөзле булуыннан файдаланып, мөселманнар арасына шымчы итеп, әле Таҗикстанга, әле Әфганстанга җибәргәләп торалар икән…     Кеше әллә ниләр белә, әллә ниләр сөйли… И Ходаем, ахыры ни белән бетәр моның, исән калырмы аның бу бәхетсез баласы? Юкка гына богауланган килеш күрмәде бит инде ул аны… Улы, Түлгәне исән, әмма бик бәхетсез, бик бәхетсез… Ана йөрәге ничек түзсен бу хәлләргә, нинди генә булса да, бала бит ул…

Җанбикә карчык, килене Сәрмәнияне чакыртып, су сорап алды, башын калкытып кына, йөрәк даруы эчеп җибәрде. Аның йөзе тагы агарып, сулып, мәет төсенә кереп бара иде.

— Әнкәй, әллә хәлең начараеп киттеме? — диде Сәрмәния, аның бу кыяфәтен күреп.— Әллә әткәйне чакыртып керимме? Бәлки врач чакыртырга кирәктер?

— Борчылма, килен,— диде Җанбикә карчык, пышылдап кына.— Үтә ул… Балалар искә төште… Шуңа йөрәгем өзелә… Мин анда Туран белән Түлгәннең икесен дә күрдем бит… Икесе дә богаулы… Уйламаска да тырышам инде… Намаз укый башлагач, бераз тынычланган идем… Мәрткә киткәч, тагы барысы да искә төште… барысын да яңадан күрдем, яңадан кичердем… Хәзер оныта алмыйм… Оныта алмам да инде…

— Әнкәй, бер яктан караганда, аларны мәрттә күрүең начар да түгел бит әле,— дип, аны юатырга тырышты Сәрмәния.—Күргәнсең, димәк исәннәр. Шунысына сөеник. Исән кеше барыбер бер кайта ул, менә күрерсең… Мин Туранның исән икәнлегенә бер минут та шикләнмәдем. Юкка чыккан көннән эзләтә башладым. Тимертауга күчүебез дә шуның өчен булды бит, авылда ятып, андый эшне ерып чыгып булмый, зур шәһәрдә барысы да кул астында — почтасы, телеграфы, военкоматлары,

милициясе, судлары… Мин ышанам, Туран барыбер табылырга тиеш, энкәй… Түлгән дә кайтыр, иншаллаһ!

Җанбикә карчык, ризалашып, баш кагып куйды. Әйе, аның балалары табылырга тиеш... Туран бигрәк тә… Аллаһы Тәгалә андый кешене күрәләтә юк итмәс… Аның бит гомерендә бер кешегә зыяны тигәне булмады, зыян түгел, хәтта усал итеп эндәшмәде дә ул кешегә… Ата-анасына изгеләргә караган кебек карый иде… Хатынын кулында гына йөртте. Солдаттан ялга кайткач, улының мәчеттә картлар белән бергә намаз укыганын да күрде Җанбикә карчык. Бөтен Аксу татарлары моны шау итеп сөйләде, әй сөенгән иде шул көннәрдә Җанбикә, әй куанган иде! Дагстанда хезмәт иткән җирендә, аңа озак вакытлар нугай, кумык авылларында яшәргә туры килгән… Штабта офицер булгач, аңа ул хәтле басым булмаган, Туран авыл халкы белән дә аралашып яшәгән. Бәйрәмнәрдә алар белән бергә мәчетләрендә намаз укыган, өйләрендә еш булган, аларны галим буларак та өйрәнгән… Бу — теге ике сугыш арасы, бераз тынычрак вакыт иде… Ә шул елны август аенда, Туран ялдан китүгә, анда икенче чечен сугышы башланды… Туран урнашкан часть, нугай авылы ике ут арасында калган… Һәм шуннан соң аның балакае суга төшкән кебек юк булды… Исәнме, тереме, әсир төшкәнме, төрмәдәме —әйтүче юк… Әтисе күпме эзләтеп карады, килен әнә күпме эзләтә икән… Түлгән монда булса, ул бәлки тиз табар иде, әмма ул үзе дә нәкъ шул чорда юкка чыкты… Бәлки ул да шул тирәләрдә булгандыр… Аның Урал тауларында тыныша алмаган балалары әллә кайдагы Каф таулары артында юкка чыктылар… Кешегә сөйләсәң, кеше ышанырлык хәл түгел…

Шул чакта өйгә, кояш нурына күмелеп, Әтил атылып килеп керде.

— Әни! Әни! Мин әбиләрдә калам! — дип кычкырды ул, керә-керешкә бөтен өй эчен яңгыратып.

Өй эче шунда ук шау-шу, яшәү дәрте, бала бәхете белән тулды. Җанбикә карчыкка да җан кереп китте, күзләренә нур инде, ирен кырыйларына күптән күренмәгән елмаю кунды.

— Әй балакаем, кала күр, кала күр! — дип пышылдады ул, Әтилдән дә ныграк куанып.— Тормышыбызга ямь кереп китәр, балакаем…

Ул арада ишектә Җиһангир карт та күренде.

— Нәрсә, хәбәр итеп өлгердемени инде бу егет? — диде ул, көлеп.— Килен, мин башта синең белән киңәшләшермен дигән идем. Калсын Әтил беразга бездә. Каникулы бит, торсын безнең янда. Үзеңә дә бераз ял итеп алырга буладыр. Ә?

Сәрмәния аптырап калды. Бер якта — бәхетеннән түшәмгә сикерергә әзер торган улы, Әтилнең калуына аңардан да ныграк сөенгән карт-карчык, икенче якта — Тимертауда —тау-тау эш… Әтилсез ул ике кулсыз булачак инде… Юк, калсын бала, аның бәхетенә каршы төшәргә ярамый, болай да әтисез үсә, ярты ятим…

— Ярар, әткәй, бераз калып торыр алайса,— диде ул, бер карарга килеп.— Үзем дә бу елларда монда булырмын әле… Аннары китмичә булмас, кешеләргә ышандырган бит, килешү төзелгән…

Шул карарга килеп, түгәрәкләнеп ашарга утырдылар. Җомга намазына хәтле әле вакыт бар иде, Сәрмәния пешергән тәмле ризыклар белән чәй эчеп алырга булдылар. Җанбикә карчык та күзгә күренеп терелде, хәтта чәйне дә, элеккечә, үзе ясап бирә башлады. Җиһангир карт, түбәтәен киеп, үзенең яраткан урынына — өстәл башына кереп утырды. Килен бәлеш кисә башлады. Бөтен тирә-юньгә татар ризыгы исе таралды… Ниләр генә юк иде бу өстәлдә — авызга тимәс борын эреп торган җимешле гөбәдияләр дә, кызарышып яткан кайнар өчпочмаклар да, һава кебек җиңел кош телләре, бавырсаклар — барысы да өстәлгә менеп кунаклаганнар иде… Бу —гадәти татар гаиләсенең гадәти татар тормышы билгеләре иде… Бөтен тирә-юньдә, Урал тауларында мондый ризыкларны бары тик татарлар гына пешерә һәм аларның да тарихы мең елларга барып тоташа иде…

Шулай тәмләп кенә ашап алгач, Җиһангир карт җомга намазына дип чыгып китте. Җанбикә карчык та намазга әзерләнеп, әкрен генә тәһарәтләр алып йөри башлады. Әбисен карап торырга, әбисенә ярдәмгә өйдә Әтилне калдырдылар, чөнки Сәрмәния ишегалдына чыгып китте, ул җомга намазы үткәч, кич керерлек итеп, мунча ягарга әзерләнә башлады. Ул арада, бөтен урамга яңгыратып, бабасы азан әйтте, намаз вакыты керде. Әбисе иелеп укудан курыкты, ахры, урындыкка утырып кына, өйлә намазын укып алды. Әтил гел аның янында басып, күзәтеп торды. Башы әйләнеп китеп, әбисе егыла күрмәсен тагы, чирли күрмәсен, яңадан мәрткә китмәсен…

Кичә әбисен бик кызганды Әтил, көче җитсә, ул аны кулларына күтәреп алган булыр иде… Бәләкәй чагында әбисе аны гел шулай күтәреп йөртә иде бит… Үскәч, Әтил аларны кулларыннан да төшермәс, гел үзендә генә тотар, беркемнән, беркайчан сүз әйттермәс…

Менә әбисе укып бетерде, Әтилнең кулларына таянып, әкрен генә урынына барып ятты. Әтил аның янына идәнгә тезләнде, башын әбисенең кулларына куйды. Шул хәлендә ул шактый утырды. Тынлыкны Җанбикә карчык үзе бозды.

— Аллаһ безнең икебезгә дә бик хикмәтле нәрсәләр күрсәтте, улым,— диде ул әкрен генә.— Без дөньяның башланганын да, беткәнен дә күрдек… Башкалар белмәгәнне белдек… Моны кешеләргә дә җиткерергә кирәк… Мин инде карт, сүземә ышанучы булмас… Боларны кешеләргә җиткерү сиңа кала, улым…

— Ышанмаслар, әби, көләрләр генә,— диде Әтил.— Саташкан, тилергән, төш сөйләп йөри, диярләр…

— Анысын үзең дә аңлыйсың икән,— диде Җанбикә карчык, оныгының башыннан сыйпап.— Атаң кебек акыллы шул син, балам… Кешеләр алар беркемгә дә, бернәрсәгә дә ышанмаганнар… Хәзер бигрәк тә… Шуңа күрә хикмәт белән аңлатырга кирәк, гыйлем белән… Укы, улым, атаң кебек, күп укы, дөнья гыйлемен өйрән… Бабаң кебек, динне яхшы бел… Шулар аша, кешеләргә хакыйкатьне ач, белгәннәреңне сөйлә… Бу хәтле нәрсәне син үзеңдә тота алмыйсың…

Әтил, ризалашкан кебек, башын иеп куйды… Ул бу хакта хәзер күп укыячак, өйрәнәчәк, бөтен җирдән шул хакта хәбәр җыячак… Әле бабасы әйткән китапларны укыйсы бар, әтисенең китапларын өйрәнәсе бар… Әтисе искә төшүгә, малай тагы боегып калды. Әбисеннән сораргамы икән, юкмы аның турында? Ул бит аны күргән… Бәлки тагы нидер хәтерләр, әтисенең кайда икәнен әйтә алыр?

— Әби, син әтине кайда күрдең? — дип сорады ул туп-туры итеп.

Җанбикә карчык тирән уйга калды. Әйтерсең ул кичәге газаплы хәлләрне яңадан күрә, өр-яңадан кичерә иде. Аннан, хәтереннән берәм-берәм үткәреп, ул күренешләрне кабатлый башлады.

— Мин аны җир астында күрдем, улым,— диде ул сагышлы тавыш белән.— Атаң ак киемнән иде, аяк-кулы богаулы, авыз-борыннары ак битлек белән капланган…

— Алайса син аны ничек таныдың соң, бите күренмәгәч? — дип соравын Әтил сизми дә калды…

— Күзләреннән… — диде Җанбикә карчык, ыңгырашып куйгандай.— Андый күзләр бары тик минем Туран улымда гына… Зур яшькелт-зәңгәр күзләр… Аларда иман нуры, мәрхәмәт мөлдерәп тора, акыл көче чагыла… Шушы күзләр аша мин аның җанын күрдем… Балакаемның саф җанын…

Карчык, сүзен дәвам итә алмыйча, сулкылдап куйды. Әтил тизрәк су алырга йөгерде. Әбисе, шуны эчеп куйгач кына, бераз тынычлана алды һәм сүзен дәвам итте.

— Атаңа ярдәм кирәк, улым,— диде ул, Әтилнең кулларыннан кысып тотып.— Бабаң инде карт, әниең — хатын-кыз… Атаңны эзләп табу, аңа ярдәм итү сиңа кала… Шуны онытма…

— Әби, син аны кайда күрдең соң? — дип, тагы сорарга мәҗбүр булды Әтил.

— Ул… җир астында иде… Тау араларында… Тау… Биек тау… Миңа бик тә таныш тау… Олы Тау… Җәмәле…

Карчык шактый вакыт дәшми торды. Аннан, Әтилгә иелә төшеп, сер әйткәндәй әйтеп куйды:

— Мин Түлгән абыеңны да күрдем бит, улым.

— Әти белән бергәме?

— Юк, балам, Түлгән абыең диңгез эчендәге утрауда иде… Аның да аяк-куллары богаулы… Алар анда күп, барысын да этләр белән саклыйлар…

Әтил аптырап куйды. Нинди җир икән соң ул — этләр белән сакларлык? Түлгән абыйсы үзе милициядә эшли иде бит, үзе теләгән кешесенә богау кидерә ала иде…

— Улым, сиңа әйтер сүзем бар,— дип дәвам итте Җанбикә карчык.— Дөньяда ни генә булса да, Түлгән абыеңны эзләп тап… Без инде карт, атаң юк, Түлгәнгә ярдәм итәрлек кеше юк… Син аның бу дөньядагы бердәнбер туганы… Туганлык хакына, ташлама Түлгән абыеңны… Сүз бирәсеңме?

— Ярар, әби,— диде Әтил, нәрсә турында сүз барганын үзе дә аңлап бетмәстән.

Әмма кайдан эзләп табар соң ул Түлгән абыйсын? Ул аннан курка да әле, әнисе дә курка аннан… Әмма әбисен борчымас өчен, Әтил ризалык бирде. Моны күреп, Җанбикә карчыкның өстеннән тау төшкән кебек булды. Ул, арып, күзләрен йомды һәм бераздан инде, тигез сулыш алып, йоклап та китте…

Әтил, әкрен генә басып, әтисенең бүлмәсенә юнәлде. Бабасы, аңа мәчеткә керер алдыннан, дин китаплары калдырган иде. Менә ул Коръән тәфсиреннән туфанга караган урыннарын билгеләп тә куйган. Монда әллә ничә җирдә дөньяны су басу турында бар икән бит!

Әтил йотлыгып укый башлады. Укыган саен, куркуы, тетрәнүе артты, күргән төшләренең рас килүен аңлады, дөнья аңа өр-яңадан ачылып киткән кебек булды… Менә бабасы билгеләп куйган «Һуд» сүрәсе. Бабасы ак кәгазь битенә язып та калдырган: «Мөхәммәт салаллаһу галәйһиссәлам, «Һуд» сүрәсе иңгәч, көлүне оныткан. Ягъни дөнья-да инде бервакытта да көлмәгән… Аның кайгыдан чәче агарган… «Нәрсә булды, нигә көлүеңне оныттың?» — дигән кешеләргә ул: «Сез мин белгәннәрне белсәгез, елар идегез, бер дә көлмәс идегез»,— дип җавап биргән… «Һуд» сүрәсе аша Аллаһы Тәгалә аңа кешелекнең тарихын аңлаткан, ни белән башланып, ни белән бетәсен күрсәткән… Нух пәйгамбәр тарихы да шунда, укы, улым»,— дип язып калдырган… Һәм Әтил татарчага тәрҗемә ителгән Коръән

тәфсиреннән «Һуд» сүрәсен, аның Нух пәйгамбәр тарихы турындагы урынын йотлыгып укый башлады: «Тәхкыйк, Без Нухны үз кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрдек: әлбәттә, мин сезне Аллаһ газабы белән ачык куркытучымын».

«Башка һичкемгә түгел, фәкать Аллаһуга гына гыйбадәт кылыгыз»,— дип хәбәр бирәмен, тәхкыйк мин куркамын сезгә каты газаплы көннең килүеннән.

Кавеменең кяфер булган олуглары әйтте: «Ий Нух, син безнең кеби адәмсең, бездән артык җирең юк, дәхи сиңа ияргән кешеләр дә арабызда иң түбән кешеләрдер һәм безгә караганда сездә дә бернинди артыклык күрмибез, бәлки без сезне ялганчылар дип уйлыйбыз».

Нух әйтте: «Ий каумем, беләсезме, әгәр сөйләнгән сүзләремнең хаклыгына Аллаһудан куәтле дәлилләрем булса, янә Аллаһ сезгә бирмәгән нигъмәт вә рәхмәтне миңа бирсә, инде сез хак динне мәкруһ күрә торып, мин аны сезгә көчләп кабул иттерергә кадир булырмынмы?

Ий каумем! Хак динне өйрәткәнем өчен мин сездән мал сорамыйм, сезгә исламны өйрәтүемнең әҗерен фәкать Аллаһу Тәгалә үзе бирәчәк, дәхи мин иман китереп, миңа ияргән кешеләрне ташлаучы түгелмен, ул мөэминнәр Раббыларына юлыгачакларын әлбәттә беләләр, ләкин мин сезне бик надан кавемнәр дип күрәмен ки, хак динне дә, Аллаһуга кайтачагыгызны да белмисез.

Ий каумем, әгәр мин фәкыйрьләрне янымнан кусам, ярдәм биреп, Аллаһ газабыннан мине кем коткарыр, шуны уйлап вәгазьләнмисезме?»

Мин сезгә әйтмимен: «Минем кулымда Аллаһ хәзинәләре бар вә яшертен эшләрне беләмен һәм мин фәрештәмен»,— дип. «Һәм сезнең күзегезгә яман күренгән фәкыйрьләргә Аллаһ рәхмәт кылмас, нигъмәт бирмәс»,— дип тә әйтмим, аларның күңелләрендәге иманны һәм мәгърифәтне Аллаһ белә, әгәр мин фәкыйрьләрне кимсетсәм, әлбәттә, залимнәрдән булырмын».

Кяферләр әйттеләр: «Ий Нух, тәхкыйк син безнең белән бәхәсләштең һәм безнең белән бәхәсләшүеңне бик күп кылдың, әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсаң, вәгъдә кылган газабыңны өстебезгә китер».

Нух әйтте: «Ул газапны әгәр теләсә, фәкать Аллаһ үзе китерер, газап килгәндә сез Аллаһуны гаҗиз кыла алмассыз.

Әгәр мин сезгә вәгазь кылырга теләсәм дә минем вәгазем сезгә һич файда бирми, әгәр Аллаһ сезне adдырырга теләсә — аздырыр, Ул сезнең Раббыгыз, ни теләсә, шуны эшләр, вә ахырда аңа кайтарылырсыз».

Яки алар бу сүзләрне Мөхәммәт Аллаһуга ифтира кылып ялган сөйли диләрме? Ә син аларга әйт: «Әгәр ифтира кылып ялган сөйләсәм, бит гөнаһы да үземә булыр, ләкин мин сез эшли торган гөнаһлы эшләрдән бизүчемен».

Дәхи Нухка вәхи булды: «Синең кавемеңнән иман китерәселәре иман китерде, инде калганнары иман китермәсләр, аларның кылган кабахәт эшләре өчен кайгырма!»

«Вә көймә яса, Безнең күз алдыбызда һәм Безнең өйрәтүебез белән, ләкин мөселман булмаган кешеләр өчен Безгә дога кылма аларны газаптан коткар дип, чөнки ул залимнәр туфан суына батып һәлак булачаклар».

Нух көймә ясый башлады, һәркайчан олуглары Нух яныннан үтеп китсәләр, пәйгамбәр балтачы булган дип, төрлечә көлеп, мәсхәрә кылып үтәләр иде. Нух әйтте: «Бүген сез безне мәсхәрә кылсагыз, иртәгә без сезне мәсхәрә кылырбыз, сез мәсхәрә кылган кеби.

Кемгә рисвай кылучы газап килгәнен тиздән белерсез һәм кемгә мәңгелек газап булачагын белерсез!»

Безнең газап белән әмеребез килеп, хәтта җирдән су кайнап чыга башлагач әйттек: «Ий Нух, һәр хайваннан ирле-хатынлы итеп берәр пар һәм иман китергән кешеләрне вә өй җәмәгатеңне көймәгә алып кер, мәгәр алар хакында Аллаһудан «алар кяферлек кылдылар» дигән сүз булган бер хатының илә бер углың көймәгә кермәсләр». Әмма Нухка бик аз кешеләр иман китерделәр.

Нух әйтте: «Көймәгә Бисмиллаһ әйтеп керегез, бу көймәнең йөреше һәм тuктавы Аллаһ теләге белән булыр, дип әйтегез! Тәхкыйк, минем Раббым мөэминнәрне ярлыкаучы вә рәхмәт итүче».

Ул, көймә аларны күтәреп, таулар кеби зур дулкыннар эчендә йөрер. Көймәгә кермичә бер читтә торучы углын чакырды: «Ий углым, безнең белән көймәгә кер, кяферләрдән булма»,— диде.

Углы әйтте: «Бу судан тау башына чыгып котылырмын». Нух әйтте: «Бүген Аллаһ газабыннан коткаручы юк, сине тау да коткара алмас, мәгәр Аллаһ рәхмәт кылган кешеләр генә көймәгә менеп котылырлар»,— дип. Соңра араларына дулкын төшеп аларны аерды вә карышкан углы суга батып һәлак булды.

Вә Аллаһ тарафыннан әйтелде: «Ий җир, суыңны киптер вә, ий күк, суыңны туктат»,— дип. Су кимеде, Аллаһы Тәгалә тарафыннан каргалган һәм ләгънәтләнгән һәлак буласы кешеләр тәмам һәлак

булып бетте вә көймә Җуди тавына барып туктады вә әйтелде: «Залим кешеләргә Аллаһуның рәхмәтеннән ераклыктыр»,— дип.

Нух нида кылып әйтте: «Ий Раббым! Углым минем җәмәгатемнән, җәмәгатеңне коткарырмын дигән хак вәгъдәң бар вә Син хәкимнәрнең дә хәкимерәгесең».

Аллаһу Тәгалә әйтте: «Ий Нух, углың синең җәмәгатеңнән түгел, тәхкыйк углыңны миннән соравың, ягъни аңа дога кылуың яхшы эш түгел, белмичә, дәлилсез миннән сорама, әлбәттә, мин сине наданнардан булмаска өндимен».

Нух әйтте: «Ий Раббым, Сиңа сыгынамын, мине сакла үзем белмәгән нәрсәне Синнән сораудан, әгәр Син мине ярлыкамасаң һәм рәхмәт кылмасаң, әлбәттә, мин һәлак булучылардан булырмын».

Әйтелде: «Ий Нух, безнең тарафтан имин булып көймәдән төш вә сиңа һәм синең белән булган мөэминнәргә күп бәрәкәт булган хәлдә көймәдән төшегез, дәхи сезнең нәселдән булган бер өммәтне дөньяда файдаландырырбыз, соңрак, азганнары өчен, аларга Бездән рәнҗеткүче газап ирешер».

Әтил сискәнеп туктап калды… Нәкъ ул төшендә күргән кебек… Түлгән абыйсы көймәгә утыра алмады, аны чоңгыл йотты… Көймә, бик озак йөзгәннән соң, бер тау каршына килеп туктады… Монда, Коръән тәфсирендә «Җуди» таулары диелгән, ә төшендә Туран таулары диделәр… Бәлки, алга таба бу хакта тагы нидер бардыр?

Моннан соң дөньяда алып кешеләр яши башлавы, аларның да, әкренләп, Аллаһны онытулары турында язылган иде. Бу кавем Гад кавеме дип аталган, аларга, Аллаһ барлыгын исләренә төшерү һәм шушы гыйбрәтле хәлләрне сөйләү өчен, Һуд исемле кеше пәйгамбәр итеп җибәреләӛ… Әмма кавеме аны тыңламый, төрле сыннарга табына башлый. Алар шул хәтле көчле кешеләр булалар ки, алар аяк басканда, җирләр тетрәп тора, аяклары туфракка батып керә… Шул көчләренә мактанып, моны үзләреннән дип белеп, алар Аллаһка каршы китәләр һәм һәлак булалар… Аллаһы Тәгалә алар өстенә каты җил-давыл, кара болыт җибәрә… Аллаһ Һуд пәйгамбәрне һәм аңа иман китергән берничә кешене генә коткарып кала. Гад кавеме һавада салам кебек очып йөри, алар ташларга тотынып, тау куышларына качып, исән калырга тырышалар, әмма көчле җил аларны кайдан да эзләп таба һәм, итләрен сөякләреннән аерып, җиргә бәрә… Җиде көн, җиде төн давыл котырып, барысын үтереп бетерә… Тугыз көн буе алар туфрак астында иңрәп, кычкырып яталар… Әмма аларны коткаручы булмый…

Әтил кулындагы китапларны бер читкә алып куйды. Аңа куркыныч, бик куркыныч булып китте. Димәк, Нух пәйгамбәр көймәсе дә, дөньяны туфан басу да, алып кешеләр дә — барысы да дөрес икән, әкият түгел икән?! Болар хакында бит әнә Коръәндә язылган, ә Коръән — Алла сүзе, ди бабасы. Нигә болар хакында мәктәптә берни дә сөйләмиләр икән соң? Китапларга да язмыйлар, телевизордан да күрсәтмиләр… Боларга бары тик әбиләр әкияте итеп кенә карыйлар… Әбиләр шундый нәрсәләрне уйлап чыгара аламы? Бу бит — кот чыгарлык хәлләр… Дөньяның башлануы һәм бетүе турында хәбәр… Нигә бу хакта кечкенәдән өйрәтеп, ничек яшәргә, ничек ялгышлардан сакланырга кирәген аңлатмыйлар икән?

Әтил бу сорауларына җавап таба алмады. Инде нинди көчле, алып кешеләрне дә Алла шулай җиргә алып сылагач, аларны җир йөзеннән юк иткәч, хәзерге заман кешеләренә ни кала? Хәзер бит пәйгамбәрләр дә юк, борынгы тарихны белүче дә юк, болардан гыйбрәт алучы да юк… Юк, Әтилнең атасы боларны белә иде, бабасы да белә, хәтта әбисе дә нидер аңлый… Бәлки әле әнисе дә нидер беләдер, әмма ул хәзер эшкә кереп баткан шул, болар турында уйларга, Әтилгә аңлатырга аның бөтенләй вакыты юк… Их, әтисе булса хәзер Әтилнең янында!.. Бөтенесен-бөтенесен аннан сорар иде ул… Бөтенесен ул әйткәнчә эшләр иде, аның кебек эшләр иде…

Малай хыялланып күзләрен йомды… Аның күз алдыннан тагы тау-тау дулкыннар үтеп киткәндәй булды, әллә кайдан серле көймә килеп чыкты… Алар барысы да шул көймәдә икән: әби-бабасы да, әтиәнисе дә, Әтил дә… Монда Түлгән абыйсы гына юк икән… Менә көймә, дулкыннар эчендә чайкалып йөзә-йөзә, күгәреп торган бер тау янына килеп туктый… Тау түбәсе ике өркәчле булып, багана кебек озын кыя-таш әллә кайлардан күренеп тора…

Әтилнең бабасы, кулларын күккә күтәреп, дога кыла… Аның артыннан барысы да шул сүзләрне кабатлыйлар, исән калганнары өчен, Аллаһка рәхмәтләрен әйтәләр… Менә алар әкрен генә җир өстенә төшәләр, дымлы туфракка тезләнеп, сәҗдәгә китәләр… Алар белән бергә кыя-таулар да, көймәдән чыккан кыргый хайваннар да, кош-кортлар да, туфаннан исән котылганнарына куанып, Аллаһка сәҗдә кылалар… Зур су күзгә күренеп чигенә, көймә тау башында, туктаган җирендә, күл эчендә утырып кала… Кыргый хайваннар, тау итәге буйлап йөгереп китәләр дә күздән югалалар… Кошлар да, кешеләрне калдырып, күккә күтәреләләр… Кешеләр тау башына беренче казыкны кагалар… Һәм алар монда яши башлыйлар…

Әтилнең әтисе аны кулларына күтәргән дә:

— Менә, улым, бу безнең яңа илебез инде — Туран иле,— ди.— Дөньяга кешелек менә шуннан таралачак…

Аста, җәелеп, иксез-чиксез диңгез ята… Һәм диңгез чигенгән саен, су астыннан тау сыртлары чыга бара… Төньяктан көньякка таба алар тоташ чылбыр булып сузылганнар… Әмма алар басып торган тау — арада иң зурысы, иң биеге һәм иң матуры икән… Тирә-юньдә салкын сулы чишмәләр челтерәп агып ята, түбәндәрәк яшел урманнар шаулап утыра, урман аланлыкларында шау чәчәкле болынлыклар… Тау итәкләре тулы кош-корт, җәнлек, җиләк-җимеш… Аяк асты тулы гәүһәр ташлар, җемелдәшеп яткан зөбәрҗәтләр, алтын-көмеш чәчмәләре… Җил-давылдан саклый торган мәрмәр кыялар, кышын — туңдырмый, җәен эсселәтми торган тау куышлары, мәгарәләр… Бу — Әтилнең туган иле иде, Ата салы, таралып яткан Туран иле — Татар иле иде… Һәм бу җирләрне аларга Аллаһ үзе биргән иде…

— Бу Туран иленә, Туран тауларына хәзер без хуҗа, улым,— диде аңа әтисе.— Аллаһ кушканча яшәсәк, мәңге шулай булачак… Юк икән, бу җирләргә явыз кавем киләчәк, шуны онытма, улым…

Шулай диде дә әтисе юкка чыкты… Әтил аннан иң кирәкләрен сорамыйча калды бит! Туран тауларының кайда икәнлеген, ничек дөрес яшәргә кирәклеген сорарга өлгермичә калды! Кая китте соң аның әтисе, Әтилне берүзен шушы тау башында калдырып?!

— Әти!!! Әтием!!! Әти!!!

Әтил тау түбәләрен яңгыратып кычкырып җибәрде. Әмма әтисе аңа җавап бирмәде… Каяндыр әнисе килеп чыкты.

— Кояш баер алдыннан йокларга ярамый, улым,— диде ул, Әтилне ипләп кенә уятып.— Соңгы вакытта бик саташа башладың әле син, бабаңнан өшкертергә кирәк…

Әтил, гаҗәпләнеп, күзләрен ачты. Кайда соң ул? Теге ике өркәчле биек тау кайда? Әле генә янында басып торган алып әтисе кайда? Аларны туфан суыннан коткарып калган тылсымлы көймә кайда?

— Кояш баеганчы, мунчага кереп чыгарсың, улым,— дип, әнисе аның аркасыннан сөеп.

Шул чагында гына Әтил үзенең Аксуда, бабасы йортында икәнен аңлады. Ул моңа сөенергә дә, сөенмәскә дә белмәде. Аның әтисеннән, көймә килеп туктаган серле таудан, гәүһәр ташларыннан, мәгарәләреннән аерыласы килми иде… Әмма алар барысы да тагы төш кенә булып чыктылар… Ә гел чын кебек иде бит, Әтил әле һаман су шаулауларына хәтле ишетә… Әтисенең тавышын ишетә…

— Менә, улым, бу безнең яңа җирләребез инде — Туран иле…

Әтил теләр-теләмәс кенә урыныннан торды. Бу ике дөнья арасында аерма шулхәтле зур иде, ул кайсында калырга белми интекте… Әмма тормыш үзенекен итте: ул бүген бу дөньяда, әби-бабасы өендә, әнисе янында яши иде… Алар белән ул бу дөньяда да бәхетле, һәм аңа бүгенге белән яшәргә кирәк иде…

* * *

Кичке якта, мунчалар кергәннән соң, Әтил бабасы белән мәчеткә китте. Көндезге якта йоклап алып, инде аның йокысы туйган иде, хәзер бабасы белән төне буе мәчеттә сөйләшеп утырырга да була. Төнге намазга әле шактый вакыт бар иде, алар идәнгә җәелгән йомшак келәм өстенә иркенләп утырдылар. Әтил бабасыннан тагы шул туфан басу, Нух пәйгамбәр көймәсе турында сораштыра башлады.

— Бабай, Нух пәйгамбәр көймәсе кайсы тауга туктаган соң? — дип башлады ул, бабасы идәнгә җайлап утыруга.

— Ә син мин биреп калдырган китапларны укыдыңмы соң? — дип, сорауга каршы сорау белән җавап бирде бабасы.

— Коръән тәфсиренме? Укыдым, әлбәттә…

— Йә, анда нәрсә дип язылган, кайсы тау, диелгән?

Әтил башта исенә төшерә алмыйча торды. Туран түгел инде, мәктәп китапларында язылганча, Арарат та түгел… Нәрсә иде соң?

Бабасы аңа үзе ярдәмгә килде:

— Анда: «Көймә Җүди тауларына килеп туктады»,— диелгән, улым…

— Ә кайда соң ул Җүди таулары?

— Эш шунда, улым,— дип җавап бирде бабасы,— гарәпчә «Җүди» — тау дигәнне аңлата… Моны «көймә тауга килеп туктады» дип тә аңларга була… Шуңа күрә ул тауларны, Нух пәйгамбәр көймәсен бөтен җирдән эзлиләр һәм һаман таба алмыйлар… Бу — Аллаһның бер хикмәте инде, улым…

— Ә безнең тарих дәреслегендә Арарат тавы, диелгән… Ул тау Төркиядә икән бит, мин картадан карадым,— диде Әтил.

— Христиан китапларында, Библиядә дә шулай диелгән, улым… Әмма ул китапларга кеше кулы кергән шул, ялган булырга да мөмкин… Дөрес булуы да бар… Аннан эзләп карадылар инде ул көймәне, таба алмадылар бит… Дөресен Аллаһ кына белә инде…

Шулай диде дә бабасы туктап калды. Әмма Әтилнең бу хакта сөйләшүдән туктыйсы килми иде әле. Аның әле төшендә күргән Туран таулары турында сорыйсы килә иде. Әмма тау турында сорыйсы урында, ул, үзе дә сизмәстән, этисе турында сорап куйды.

— Бабай, ник син этигә Туран дип исем куйдың? Нәрсәне аңлата ул? Ә Түлгән абыйның исеме нәрсәне аңлата — алар игезәкләр бит?

Җиһангир карт оныгыннан бу сорауны бөтенләй көтмәгән иде. Хәер, бу хакта элегрәк сораганнары бар иде аннан, кечерәк чакта балалар үзләре сорап йөдәтәләр иде, бигрәк тә Туран…

— Туран исеме безнең нәселдә булган, улым,— диде ул.— Безнең нәселдә әллә кемнәр булган: Туран да, Түлгән дә, Алып та, Әтил дә, хәтта Нух пәйгамбәр дә… Атасалда табылган борынгы шәҗәрәдә шулай язылган иде… Аны атаң Казан архивларына илтеп бирде, чөнки татар тарихының бер өлеше бит ул…

— Үзебездә калмадымыни? — диде Әтил, нәүмизләнеп.

Бабасы, көлеп, аның аркасыннан кагып куйды.

— Борчылма, Казан журналларында басылып чыкты ул,— диде бабасы.— Мин өйдән эзләп караган идем, нишләптер таба алмадым. Бәндәбикә әбиләреңдә булырга тиеш ул… Бәлки әле берәр көнне аның янына да барып кайтырбыз, Алла боерса… Ул бик күп белә инде болар хакында… Әтиеңә Туран исемен дә ул куштырды бит. Ә Түлгән абыеңа әбиең — Җанбикә карчык куштырды исемне… Нигә шул исемгә чат ябышкандыр…

— Ул исемнәр берәр нәрсәне аңлатамы икән соң, бабай?

— Борынгы төрки-татар дастаннарында бар ул исемнәр, улым… Туран батыр — бөтен тирә-юньгә билгеле каһарман булган, Урал тауларын явыз аждаһалардан арынырга ярдәм иткән, дөньяга тереклек суын бөркегән кеше… Ә Түлгән… Минем балага андый исем куштырасым килмәгән иде, Бәндәбикә әбиең дә бик каршы төшкән иде… Үз әбиең шушы исемнән кире кайтмады…

— Нигә, Түлгән начар исеммени?

— Начар дип тә әйтеп булмый аны, улым… Түлгән — Шүлгән исеменең нугай-типтәр варианты гына инде ул… Шүлгән исә, борынгы дастаннардан күренгәнчә, ата-анасын тыңламыйча, юлдан язган бала… Үз балаң турында алай әйтергә ярамый инде, улым, әмма Түлгән абыеңның исеме җисеменә туры килде… Үзең беләсең, шактый күрсәтте ул безгә…

Әйе, Әтил хәтерли ул кешене… Ул аннан әле дә курка… Әнисе дә курка иде аннан… Ә менә этисе курыкмый иде, солдаттан ялга кайткан елны Атасалда этисе аңа бик каты итеп әйткән иде… Алар хәтта сугышып китә яздылар, чак аерып алдылар үзләрен… Әтилнең хәтерендә ул милиция киемен кигән усал кеше булып кереп калды. Аның төсе-кыяфәте дә бөтенләй этисенә охшамаган иде — Әтилнең этисе зур гәүдәле, яшькелт-зәңгәр күзле, ак йөзле, коңгырт чәчле… Ә аның игезәк туганы Түлгән кыл кебек кап-кара чәчле, кысыграк күзле, каратут йөзле, буе да Әтилнең этисеннән күпкә кайтыш… Аларның бер җирләре дә охшамаган… Холыклары да бөтенләй икесенең ике төрле. Әтилнең этисе тыныч, йомшак күңелле, беркайчан ярсымый, ачуланмый, ә аның туганы Түлгән гел әллә нәрсә, котырган эт кебек… Бөтенесен рәттән талый: ата-анасын да, бердәнбер туганын да, Әтилне дә, аның әнисен дә, мөселманнарны да, татарларны да… Шуңа күрәдер дә, төшләрендә Түлгән абыйсы алар утырган көймәдә юк иде, аны дулкын тавы басып китте… Алар җәннәт урыннары булган Туран тауларына да ансыз гына төштеләр…

— Бабай, ә Туран таулары кайда ул? — дип, кисәк кенә сорап куйды Әтил.

— Туран таулары, дисеңме?.. Ай-һай, улым, мин дөньяда андый таулар барын белмим… Ә менә Туран иле булган, этиең ул турыда бик белеп сөйли иде… Тын океаннан Каф тауларына чаклы булган җирләр Туран иле дип аталган, аңа татарларның борынгы бабалары төркиләр хуҗа булган… Аларның үзәкләре шушы Идел — Урал арасында булган дип сөйли иде атаң…

Малай тагы уйга калды…

Туран иле…

Туран таулары…

Туран-Урал… Туран-Урал… Туран-Урал таулары…

Әтилнең йөрәге, күкрәгеннән чыгардай булып, шашып тибә башлады. Аның баш миен яшен яктысы телеп үткән кебек булды. Туран таулары — шушы Урал таулары була түгелме соң?! Димәк, Нух пәйгамбәр көймәсе дә шунда килеп туктаган?! Кавказда да түгел, Арарат тауларында да түгел, нәкъ менә Урал тауларында, Әтил яши торган җирләрдә, Атасалда туктаган Нух атаның сал-көймәсе! Ничек башта ук шуны белмәде соң Әтил?!

Ул, корт чаккандай, чәчрәп урынынnan сикереп торды. Бабасы, гаҗәпләнеп, аңа текәлде.

— Бабай, бабай! Белдем мин Туран тауларын, таптым! Ул — Урал таулары икән бит! Иле Туран булгач, аның тавы да Туран була бит инде! Яки тавы да Туран, иле, халкы да Туран! Шулай бит, бабай?!

Җиһангир карт, оныгындагы мантыйкка һәм акылга гаҗәпләнеп, баш чайкап куйды. Әйе, малай зиһенле, әнә кайларга барып чыкты бит башын эшләтеп… Әтисенә охшаган, әтисе юлыннан китәр дә, ахры… Бу балага ярдәм итәргә кирәк: эзләнсен, өйрәнсен, уй чаткысын сүндермәсен… Әмма саташып, әллә кайларга кереп китә күрмәсен, хәзер андыйлар да күп… Аның өчен ныклы гыйлем кирәк, иман кирәк…

— Булырга бик мөмкин, улым,— диде ул, оныгының күңелен төшермәскә тырышып.— Нигә булмасын икән — Урал таулары ул заманында төрле исемнәр йөрткән бит, атаң шулай дип әйтә торган иде… Аның, хәтерем ялгышмаса, Рифей... Айани, Нухрат... Һун, Субаш… Җүкәтау исемнәре дә булган булырга тиеш… Бәлки, төрле җирдә төрлечә атап йөрткәннәрдер… Озынлыгы 2 мең чакрымга сузылган бөек тау бит ул — Урал таулары… Аның бер башы — төньяктагы Кар диңгезенә, икенче башы көньякта казах чүлләренә барып тоташа… Ул тауларның аркылыга киңлеге, урыны-урыны белән 100—150 чакрымга җитә… Аларда — йөзләгән тау сыртлары, түбәләр, аларның меңләгән исем-атамалары… Бу тау буйларында төрле милләт һәм кавемнәр яшәгән, әмма борынгыдан төп халык төрки-татарлар булган, шуңа күрә бу исем-атамалар безгә барсы да аңлашыла… Урал тауларының кайчандыр Туран исемен йөрткән булуы да бик мөмкин, бик мөмкин…

— Ә мин төшемдә, дөньяны су баскан вакытта көймәнең Туран тауларына… Урал тауларына… килеп туктавын күрдем, миңа шулай дип әйттеләр,— диде малай әкрен генә. Әйтерсең ул бу мизгелләрдә дөньяның ниндидер бер бөек серен ачкан иде һәм бу ачышның зурлыгыннан, көтелмәгән булуыннан үзе дә куркып калган иде…

Бабасы да дәшмәде. Оныгының бу сүзләреннән, бу ачышыннан ул да аптырабрак калган иде… Туран һәм Урал таулары… Бу баланың сәер төшләре… Дөньяны су басу һәм Нух пәйгамбәр көймәсе… Оныгы хәзер әнә шул дөньяда яши икән бит… Һәм адашмас, саташмас өчен, ярдәм сорап, аңа мөрәҗәгать итә…

— Алай булуы да бик мөмкин, улым,— диде тагы карт, аның сүзләрен җөпләгәндәй.— Бу дөньяда әллә нәрсәләр булуы мөмкин… Күбрәк укы, гыйлем ал, улым, җавапны дин китапларыннан да эзлә… Бәлки Туран тауларын да эзләп табарсың…

— Һәм Нух пәйгамбәр көймәсен дә,— дип өстәде малай, бабасының хуплавына батыраеп китеп…

— Һәм Нух пәйгамбәр көймәсен дә,— дип, тагы аны җөпләде Җиһангир карт.— Дөрес гыйлемең, тырышлыгың булса, бар сорауларыңа да җавап табарсың, улым… Фән дә боларга күптән җавап тапкан булыр иде, әмма алар Коръәнне читләтеп үтәләр, андагы хәбәрләрне игътибарсыз калдыралар… Югыйсә анда кешелекнең бөтен сорауларына да җавап бар бит…

Шулай диде дә бабасы төнге намазга әзерләнә башлады. Менә ул бер читтә торган микрофон янына килеп басты, ниндидер төймәләрне боргалады һәм Аксу өстенә, Уралтау араларына моңлы азан тавышы яңгырады…

— Аллаһу-әкбәр! Аллаһу-әкбәр! Аллаһу-әкбәр! Аллаһу-әкбәр!

Әшһәдү әл-лә иләһә илләл-лаһ! Әшһәдү әл-лә иләһә илләл-лаһ!

Әтил дә, әле генә ясаган ачышына әсәрләнеп, бабасы артыннан кабатлап бара башлады. Ни гаҗәп: ул барлык сүзләрне дә дип әйтерлек дөрес әйтә белде! Ул арада мәчеткә тирә-юньнән берничә бабай да килеп җитте һәм Җиһангир карт артына намазга тезелешеп бастылар… Әтилнең дә алар янына барып басасы, алар эшләгәнне эшлисе килеп китте. Әмма ул намаз тәртибен дә, догаларны да белми иде шул… Аның икеләнеп торуын күреп, бабасы үзе оныгына ярдәмгә килергә ашыкты.

— Бас, улым, минем артка,— диде ул йомшак кына.— Мунчадан яңа чыктың, камил тәһарәтлесең… Без нәрсә эшләсәк, шуны эшлә… Бу — җәмәгать намазы, сезнең өчен мин укыйм, сез кабатлап кына барасыз…

Шулай итеп, үзе дә сизмәстән, гомерендә беренче тапкыр Әтил бабасы артына намазга басты. Ул әле берни белми иде, әмма аның белергә теләге көчле иде. Ул бабасы һәм башка картлар ни эшләсә, шуны эшләде. Малай үзен гаять мөһим эш башкарган кебек тойды, ул хәтта олыгаеп, үсеп киткәндәй булды. Башындагы юк-бар уйлары да каядыр югалды, бөтен аңын, тәнен, җанын бабасының көйләп Коръән укуы күмеп китте… Бу — малай тормышындагы өр-яңа гамәл, яңа халәт иде, аның күңеленә бик якын, якты, изге нәрсә… Бу — аның гомерендә беренче намазы иде…

Урамга чыккач та, алар өйгә керергә ашыкмадылар, озак кына сөйләшеп утырдылар… Бергәләп намаз укыганнан соң, малай бабасына тагы да якынаеп киткән кебек булды, әйтерсең лә бабасы — көймә борынын тотып барган Нух пәйгамбәр… Аның артыннан барса, аның янәшәсендә булса, Әтил

беркайчан да юкка чыкмас, адашмас кебек… Җиһангир картның да бик күңеле булганга охшый — оныгы аның белән бергә намаз укыды бит! Бу балада өмет бар, бар, аны тик дөрес юлга кертеп җибәрергә генә кирәк, урам кулына бирмәскә, адаштырмаска, саташтырмаска…

Әтил бабасының култык астына ук кереп утырды… Өйдә инде ут сүнгән, мөгаен, әнисе белән әбисе йоклыйлардыр инде… Аларның өйләре калкулыкта урнашкан һәм биредән бөтен Аксу, чокыр төбендәге кебек, ясалма утлары белән җемелдәп ята… Инде соң булса да, әле халык йокламый, күп тәрәзәләрдә ут бар… Завод торбаларыннан күккә аллы-гөлле кара төтен ургыла, тирә-юньдә газ факеллары дөрләп яна… Шул ялкын телләрен дә уздырырга тырышып, караңгы күккә җыр-музыка авазлары ашкына, барабан тавышлары дөбердәп тора… Нәкъ әбисе әйткән җәһәннәм инде — тагы бер мизгел, һәм чокыр эчендәге Аксуның үзенә дә ут кабар кебек… Әле ярый аларның өйләре бу мәхшәрдән читтәрәк, еракта урнашкан… Татарлар, аерым бер бистә булып, менә шушы шәрә калкулыкта яшәп яталар… Шәһәрне бөтен яктан да Урал таулары әйләндереп алган, алар әнә төн караңгылыгыннан шомлы калкып, караешып карап торалар… Урал таулары… Юк, Туран таулары… Аның йөзләгән сырты, түбәләре… Нух пәйгамбәр көймәсе шуларның кайсына килеп туктады икән?

— Бабай, син ничек уйлыйсың,— диде ул, бабасына сыеныбрак утырып.— Әйтик, менә бүген дөньяны су басты, ди… Без синең белән өйдәгеләрне дә алып, көймәгә утырып, йөзеп киттек, ди… Бөтен-бөтен дөнья, хәтта Урал таулары да су астында калган, кайбер биек тау түбәләре генә күренеп тора икән, ди… Син ничек уйлыйсың, безнең көймәбез кайсы тау түбәсенә туктар иде икән монда? Ягъни бу тирәдә иң биек тау — кайсы тау?

Җиһангир карт оныгының уйлары һаман шул тирәдә йөрүенә гаҗәпләнеп тә куйды. Димәк, баланың башына ныклап кергән икән бу уй! Әнә сорауны да ничек әйләндереп, кайлардан кайларга китереп чыгарып куя бит… «Юк белән мавыкма, улым!» — дип, кырт кисеп, баланың хыялын өзәргә дә ярамый… Хыялллансын, эзләнсен, дөньякүләм ачышларны да әллә кемнәр түгел, менә шундый тере, терекөмеш кебек кешеләр ача инде… Картның үзенә дә бу турыда сөйләшү кызык булып китте, ул әйтерсең лә яңадан хыялый балачагына кайтты…

— Бу тирәдәге иң биек тау сырты, дисеңме? — диде ул, үзе дә оныгы кебек мавыгып китеп.— Ямантау була ул, улым… Әйе, синең көймәң Ямантау түбәсенә килеп туктар иде… Чөнки ул бу тирәдә иң биек тау — аның биеклеге…1640 метр, чакрым ярым, ягъни… Ирәмәл дә биек, әмма ул Ямантаудан бераз калыша…

Ямантау?

Бу исемне ишеткәч, малай сискәнеп куйды. Ни өчен Ямантау? Яман — начар дигән сүз түгелме соң ул? Анасы еш кына, Әтил ризыгын ашап бетермәсә: «Яманнан ярты кашык кала, дип әйтәләр, улым, ашап бетер ризыгыңны»,—дия иде… Ямантау… Кайда икән соң ул тау, моннан еракмы икән?

— Бабай, ә моннан еракмы соң ул тау? — дип сорады ул.— Синең анда булганың бармы? Ә нигә шундый ямьсез исем белән атаганнар аны?

— Моннан әллә ни ерак түгел ул, улым,— диде бабасы.— Турыга бер илле чакрымнар булыр, әмма анда турыга юл юк хәзер… Урман да тау… Урап барсаң, артыграк та булыр… Халык телендә аны элек Нәрәле дип тә йөртәләр иде, безнең типтәрләр Ямәле, Җәмәле дип тә әйтәләр… Әмма рәсми исеме Ямантау инде аның хәзер…

— Ә нигә Ямантау?

— Аны, улым, төрлечә сөйлиләр инде,— диде бабасы,ниләрнедер исенә төшерергә тырышкан кебек.— Менә Бәндәбикә әбиең сөйләп бирер иде инде сиңа ул турыда… Аның янына бер барып кайтмыйча да булмас әле болай булса… Ә мин белгәннәр менә болай, улым… Безнең нугай-татарларның борынгы риваятьләреннән күренгәнчә, бу тирәне элек аждаһалар баскан булган… Бәлки алар да дөньяны су басканда шушы Урал тауларында, тау куышларында качып калган булганнардыр, кем белә… Шулай бөтен тирә-якта су була һәм анда җир һәм су асты патшасы аждаһа хакимлек итә… Туран батыр менә шушы явызны җиңә һәм шуның гәүдәсеннән Ямантау барлыкка килә, имеш… Шуңа күрә яман дигән исем бирелгән, диелгән борынгы дастаннарда… Ә Туран батырның үз гәүдәсеннән Урал таулары барлыкка килгән, диләр… Болар — дастаннар инде, әкият дисәң дә ярый… Дөреслек тә бар кебек… Аждаһа дип халык борынгы динозаврларны атаган булырга тиеш… Чөнки бу тирәдә чыннан да яшәгән алар, җир казыганда һаман сөякләре табыла тора…

— Ә эти нәрсә дип әйтә иде ул Ямантау турында? — дип сорап куйды малай кинәт кенә.

— Әтиең?

Карт шактый гына уйланып утырды. Балалар яшь чагында ул алар белән мондый нәрсәләр турында сөйләшмәде шул… Ә сөйләшергә, дөнья күрсәтергә бик кирәк булган югыйсә… Һаман шул эштән башы чыкмады, гаилә тәртибе белән түгел, завод режимы белән яшәде… Нәтиҗәдә Түлгәнне бөтенләй

югалтты, кулдан ычкындырды, Тураны, бәхетенә, туры юлны үзе эзләп тапты, атасына да, баласына да кыйбланы ул күрсәтеп калдырды…

— Әтиең дә кызыксына иде болар белән,— диде ул, улы белән булган соңгы сөйләшүләрне искә төшереп.— Ул Ямантауны Ямән дигән сүздән килеп чыкмадымы икән дип әйтә иде… Гарәбстанда шундый ил бар, Ямән дип атала… Безнең халык аны Җәмәл дип тә йөрткән… Ямәл булырга да мөмкин, чөнки Урал таулары башланган җирдә Ямал ярымутравы бар… Атаң боларның очына чыгып өлгерә алмады инде, улым… Менә кем уйлаган аны, син дә шул юлга килеп чыгарсың дип…

Әтилнең күз алдында хәзер бары тик Ямантау гына басып тора иде. Өнендә бер тапкыр күргәне булмаса да, ул аның нинди икәнен белә — ике өркәчле, зур биек сырты, кыя булып, әллә кайдан күренеп тора… Әтил ул тауны төшләрендә әллә ничә тапкыр күрде бит инде, ул әтисе белән аның түбәсендә, итәкләрендә йөрде.

— Менә безнең яңа җирләребез — Туран иле шушы була инде, улым,— дигән иде аңа әтисе…

Оныгының боегып калуын күреп, картның аны юатасы, аңа тагы да мавыктыргыч нәрсәләр сөйлисе, шатлык бүләк итәсе килде.

— Моннан ерак түгел бик борынгы тау куышы бар, улым,— диде ул, Әтилне моңсу уйларыннан арындырырга теләгәндәй.— Моннан 15 мең еллар элек анда борынгы кешеләр яшәгән… Алар ул мәгарәгә йонлач мамонтлар, мөгезборын, кыргый ат, хәтта озын кеше рәсемнәре дә ясап калдырганнар… Ул рәсемнәрне минем үземнең дә күргәнем бар…

Әтил урыныннан ук сикереп торды, бабасы каршына барып басты.

— Чынлапмы, бабай?! Үзең күрдеңме?

— Әйе, заманында без анда скважиналар бораулап, җирнең астын тикшереп йөрдек… Заводтан шулай җибәрәләр иде… Шунда теге борынгы тау куышын — Шүлгәнташны да күрдем… Гаҗәпләнерлек хәлләр бар анда, улым… Насыйп булса, сине дә алып барып кайтырмын әле… Бәндәбикә әбиләрең дә шунда бара торган юл өстендә калалар, аның да хәлен белеп чыгарбыз…

Малайның күңеле, җаны хыял белән тулды. Аждаһа гәүдәсеннән барлыкка килгән Ямантау, мамонт рәсемнәре төшерелгән борынгы мәгарә — Шүлгәнташ, шуларның барысы хакында да белгән Бәндәбикә әбисе… Һәм бабасы аны шунда алып барырга тели… Әтил өчен нинди зур бәхет, могҗиза бит бу!

— Бабай! Бабай! Ямантауга да барабызмы? — диде ул, хыялга батып.— Син аны да якын дип әйттең бит!

— Менә Ямантауга барып булмас, улым,— диде бабасы, кинәт кенә җитдиләнеп.

— Ә нигә барып булмас, бабай? Юл юкмыни?

Җиһангир карт оныгына ни дип җавап бирергә дә белмәде. Ничек дип аңлатасың бу балага — ул бит әле дөньяда үлемнең үзен яшереп ята торган яшерен урыннар барлыгын белми… Урал тауларында җир аслары тулы атом шәһәрләре барлыгын да белми бу бала… Ничек аңлатасың аңа бу турыда? Бераз аңлатмыйча да булмый, чөнки дөнья барыбер аңлатачак, үзенчә, бугазга басып аңлатачак… Бу хакта аның бабасыннан ишетә торуы хәерле…

— Анда кертмиләр бит, улым,— диде ул, тавышын әкренәйтә төшеп.— Чөнки Ямантау итәгендә, җир астында хәзер ябык атом шәһәре… Аны хәрбиләр бик нык саклый…

— Анда… атом бомбасы ясыйлармыни, бабай?

Әтилнең атом бомбасы турында ишеткәне бар иде. Әнисенең сөйләве буенча, 50 нче еллар уртасында аларның авылы өстендә атом бомбасы сынаганнар… Бөтен авыл халкы диярлек кырылып, үлеп беткән… Әтилнең әнисе ягыннан әби-бабалары да соңыннан кан рагыннан үлгәннәр, әнисенең бөтен туганнары нурланыштан үлгән… Әтилнең әнисе Ырынбурда балалар йортында тәрбияләнеп үскән… Әмма ул да хәзер еш авырый, борыныннан, колакларыннан тик торганда кан китә, хәлсезләнә, гел больница юлында йөри… Тимертауга күчүләренең дә бер сәбәбе шул булды бит: әнисе анда ниндидер авырудан хисапта тора, тик бу хакта Әтилгә әйтми… «Инде синдә генә булмасын бу авыру»,— ди… Ул вакытта Ырынбур далаларында сынаган атом бомбаларын шушы Ямантау астындагы яшерен шәһәрләрдә ясаганнармы икән?

— Анда нәрсә ясаганнарын беркем дә төгәл белми, улым,— диде Җиһангир карт, артык тирәнгә керәсе килмичә.

Дөресен әйткәндә, анда нәрсә ясаганнарын төгәл генә ул үзе дә белми… Картның уйлавынча, анда уран шахталары булырга тиеш… Ямантау итәгенә урнашкан ул шәһәрнең озак еллар исеме дә булмады, анда теләсә ничек кертмәделәр дә, чыгармадылар да… Бөтен Ямантау астын тутырып, җир астында да шәһәр бар, дип сөйлиләр иде элек… Имеш, Америка белән атом сугышы була калса, Мәскәүдән монда хөкүмәтне күчермәкчеләр икән, шуңа күрә шәһәр, бункер рәвешендә, җир астында төзелә икән… Анда атом бомбасы ясыйлар икән, дип сөйләүчеләр дә булды, кемдер анда дөньяда тиңе

булмаган атом ракеталары ясаганнарын ишеткән, имеш… Кемнәрнеңдер әйтүенчә, анда бөтен илнең атом калдыкларын җыеп, саклап яталар икән… Җир астыннан Урал тавының ике ягына да тимер юллар үтә, ди, бөтен пычракны, үлем коралларын шунда ташыйлар икән… Әгәр андагы атом калдыклары, корал шартлый калса, җир шарын бер минутта юкка чыгарасы икән, дип сөйлиләр… Бу үзгәртеп корулар башлангач, халык бераз шаулап алган иде, Ямантауның атом серләрен ачуларын таләп иткәннәр иде… Дөрес, шушы хәлләрдән соң шәһәрнең үзен бераз гына ачтылар, дөньяда барлыгын танып, аңа исем дә бирделәр, хәтта Таулы дип атадылар… Һәм шуның белән бетте… Анда хәзер дә паспорт режимы, иркенләп кереп-чыгып йөрү юк, ул бүген дә яшерен, ябык зона. Анда элеккечә керә дә алмыйсың, чыга да алмыйсың… Әмма алар турында бу балага ничек аңлатасың?

— Без синең белән Шүлгәнташка барырбыз, улым,— диде ул, аны юатырга теләп.— Анда да бик матур, бик гыйбрәтле нәрсәләр бар… Теләсәң, иртәгә үк чыгып китә алабыз. Әбиеңне карап торырга әниең монда, көннәр әйбәт, нигә барып кайтмаска? Шунда юл уңаенда Бәндәбикә әбиләреңә дә кереп чыгарбыз, ә, улым? Теләсәң — машинада, теләсәң, Агыйделдән сал белән төшәрбез, ә?

Әтил үз колакларына үзе ышанмады. Агыйдел буйлап — салда?! Алай да була микәнни? Хәзер дә, нәкъ борынгы заманнардагы кебек, салда йөзеп була микәнни?! Әй, күңелле булыр иде ул — Агыйдел буйлап салда төшүе… Бер яктан, бабасы ишкәк ишә, икенче яктан — Әтил… Аларның өстенә тау-тау дулкыннар килә, яшен яшьни, күк күкри, ә алар, бабасы белән барысын да җиңеп, һаман алга баралар… Менә аларның каеклары… бер тау янына килеп туктый… Тукта, ә Шүлгәнташ янында таулар бармы икән соң?

— Бабай, ә анда таулар бармы соң?

— Әй! Бар гынамы соң?! Анда гел таулар, улым… Шүлгәнташ үзе дә таудагы мәгарә бит, ул җир астыннан ике чакрымга сузыла…

— Ике чакрымга?! Шуның буеннан-буена хәтле җир астыннан барып буламы?

— Хәзер эчкә үк кертмиләр, ахры, җимерелү куркынычы бар, ди… Әмма анда кергән, күргән кадәресе дә уйланырга бик җитәрлек… Менә үзең дә күрерсең әле…

Шундый уй-ниятләр, шатлыклы хыяллар белән алар төнгә керделәр.

Әмма аларның Агыйдел буйлап сал белән төшү ниятләрен өйдәгеләр берсе дә кабул итмәде. Башта бу эшкә әнисе каршы төште, аннан әбисе дә курка калды. «Берегез — бабай, икенчегез — малай, барып җитә алмассыз»,— диделәр алар. Аларны борчымас өчен, бабасы Шүлгәнташка машина белән барып кайтырга булды. Яше җитмештән артса да, Җиһангир карт әкрен генә машинаны һаман үзе йөртә, шуңа күрә Шүлгәнташка барып кайту да алар өчен авыр эш түгел иде. Баргач-баргач, бәлки кунып та кайтырга туры килер дип, палаткалар алдылар, юл сумкаларына азык-төлек, кирәк-ярак тутырдылар. Кайтышлый, юл өстендә калган Каһарман авылына, Бәндәбикә әбиләргә дә кереп чыгарга уйладылар… Ниһаять, әзерлек эшләре бетте, бабасының иртәнге намазыннан соң утырып чәй эчтеләр дә юлга кузгалдылар. Алда аларны йонлач мамонтлары, мөгезборыннары белән Шүлгәнташ мәгарәсе көтеп тора иде…

* * *

Урал тауларында җәйге иртә…

Кояш тау сыртлары арасыннан тәгәрәп чыкты да зәп-зәңгәр күккә берүзе хуҗа булып калды. Әле ул бик нык кыздырмый, җылыта гына, ә тиздән пешерә үк башлар… Шуңа күрә Җиһангир карт көн кыздырганчы барып җитәргә ашыга. Алай да бу тирәләр турында онытып сөйләп, аңлатып каласы да килә… Ә бу якларда сөйләрлек, аңлатырлык нәрсәләр күп, бик күп. Алар белән ярышып, бер тарафка аккан Агыйделкәй суы, ике якка гаскәр кебек баскан мәгъруур Урал таулары гына да ни тора… Ә алар арасында, үзәнлекләрдә, борынгы татар-типтәр авыллары сибелеп ята… Аларның һәрберсе үзе зур тарих, үзе бер дөнья… Карт үзе дә шушы чал Уралтау араларында туып үсте бит, бөтен гомере шушы тирәләрдә үтте, шуңа күрә ул бирсдәге һәр тауны, һәр авылны, һәр чишмәне төнлә уятып сорасалар да күрсәтеп, сөйләп бирә ала… Аның өчен бу тирәләр — җирдәге җәннәтнең үзе, дөньядагы иң матур, иң серле, иң газиз урын… Заманында ул кайсыдыр бер урыс китабыннан укыган иде: «Идел елгасы башланган кыя-таулы урыннарда, ак таш диварлар артында — җәннәт җирләре, анда изгеләр яши»,— диелгән иде анда. Әлбәттә, урыслар бу сүзләрне Идел-Волга елгасын күздә тотып язып калдырганнардыр… Әмма алар күздә тоткан Идел елгасы кыя-тау араларында түгел, сазлыклы җирләрдә башлана, алга таба юлын да шул рәвешле дәвам итә… Ягъни Идел-Волга елгасы биек кыя-тау араларыннан башланмый да, акмый да… Җиһангир картның уйлавынча, бу борынгы урыс елъязмаларында сүз Агыйдел елгасы турында барган булырга тиеш… Чөнки элек барлык зур суларны да Идел яки дәрья дип атаганнар, халык телендә Агыйделне хәзер дә Идел дип йөртәләр… Ә бик борынгы заманнарда халык Иделне Әтил дип йөрткән… Бүген исә Агыйдел дип язалар, ягъни Ак Идел,

ак сулы елга… Ак бәлки изгелек, хикмәт мәгънәсен дә аңлатадыр, анысын ук Җиһангир карт белми инде, әмма бу урыннар аның өчен изге, бик изге…

— Бабай, бабай, бу Агыйдел елгасын бер тапкыр чыккан идек бит инде без,— дип, Әтил аның уйларын бүлдерде.—Ә анда, күпер башына, тагы «Белая — Агыйдел» дип язып куелган… Бу әллә башка Агыйделме?

— Юк, улым, бу шул ук Агыйдел инде,— диде бабасы, машинаны бераз акрынайта төшеп.— Әле без аны юлда тагы берничә тапкыр кичеп чыгарбыз, иншаллаһ! Ул безнең Аксудан ерак түгел башлана да Татарстанда Кама елгасына барып коя… Элек, киресенчә, Каманы Агыйделгә коя дип уйлаганнар…

— Татарстанга хәтле барып җитәме?! Ничә чакрым юл үтә соң ул, бабай?

— Мең чакрымга якын юл үтә ул, улым, мең чакрымга хәтле… Беләсеңдер инде, үзеңнең исемеңне йөрткән елга, яки, киресенчә, син ул елганың борынгы исемен йөртәсең, бик белеп тор…

Әтил бу хакта белә иде, аңа әтисенең сөйләгәне бар иде инде. Теге вакытта, әтисе солдаттан ялга кайткач, алар Агыйдел елгасы башланган урынга барганнар иде. Әмма Әтил ул чакта кечкенәрәк иде шул, күп әйберләрне хәтерләми дә, кайберләренә игътибар итмәгән… Хәзер булса, ул әтисеннән әллә нәрсәләр сорар иде. Беренче булып Ямантау турында сорар иде… Әтисе барыбер җавап табар иде, әле Әтилне анда алып та барыр иде…

Әйе, Агыйдел елгасының биек Ирәмәл тавында, кечкенә генә чишмәдән башланганын күрде ул… Әтисенең әйтүе буенча, элек ул бик зур су булган, аны тутырып, камыштан үргән көймәләр, каеклар, саллар йөзгән… Соңрак аларны пароходлар алыштырган… Кызык, ничек инде камыштан көймә үреп була икән ул? Бабасыннан сорап караса, ул белерме икән?

— Бабай, камыштан үргән көймә нинди була ул? Элек әни җырлый иде, «Агыйделне кичәр идем, камыштан көймә үреп», дип… Ул ничек батмады икән?

— Камыш — көймә үрү өчен иң җиңел, иң җайлы нәрсә инде ул, улым,— диде Җиһангир карт, яшь чакларын искә төшереп.— Без элек күп нәрсәне камыштан үрә идек: балык тота торган сөзгечләрне, чыпталарны, хәтта көймә-салларны да… Хәзер ул һөнәрләрне онытып бетерделәр инде, камышның үзен дә…

— Борынгы индеецлар да диңгезләрдә камыш көймәләрдә йөзгәннәр бит, безгә мәктәптә сөйләделәр… Бу хакта телевизордан да күрсәттеләр,— диде Әтил, шул хакта исенә төшереп.—Бабай, ә татар сүзе нәрсә дигәнне аңлата ул? — дип сорады Әтил кинәт кенә.

— Татар сүземе, улым? — Бабасы бераз уйлап барды.— Аны галимнәр төрлечә аңлата…

— Ә әти ничек дип әйтә иде?

— Әтиеңнең аның һәрнәрсәгә үз фикере бар иде… «Татар» сүзен ул «тау ирләре» дип аңлата иде… «Тат» сүзе — тау дигәнне белдерә икән, «ар» — ир дигәнне аңлата… Менә шуннан «тау ире» килеп чыга инде…

— Ә дөрес бит! — дип кычкырып җибәрде Әтил.— Тауда яшәгәч, тау ирләре була инде, шулай бит, бабай? Әти ничек дөрес уйлаган…

Шул чагында барыр юллары тараеп, караңгыланып киткән кебек булды. Аларның каршына саф-саф булып биек кыя-таулар чыгып баскан иде. Соклану һәм куркудан, Әтилнең тыны кысылды, алар әйтерсең лә тауның өстенә баралар иде… Ә таулар, бөтен дәһшәте белән, алар өстенә килә иде…

— Улым, уңга-сулга кара әле,— диде бабасы, аны юатырга тырышып.— Күрәсеңме, нинди биек таулар! Безнең Атасалда мондый ук таулар юк бит, без, ни әйтсәң дә, Урал аръягы дип аталып йөртеләбез… Ә монда — бөтенләй башка… Монда аларның оясы, таулар иле бу, чын мәгънәсендә, таулар иле… Болар хәтта Аксу тирәсендәге таулардан да биегрәк!

— Ямантаудан дамы?!

— Юк, улым, Ямантау — иң биеге, аңа җитүче юк… Аннан кала — Ирәмәл, ул Ямантаудан аз гына кайтыш, аның да биеклеге чакрым ярым… Агыйдел елгасы шуннан башлана бит инде, хәтерлисеңме, әтиең белән барган идегез теге вакытта? Менә бу таулар да биеклеккә бер чакрымнан артык, әнә бит күккә үк кереп, тиеп торалар… Үзәнлектән бармасаң, өстеңә ишелер кебек…

Чыннан да, юл, Агыйдел ярлары буенча, үзәнлектән бара иде. Дөресрәге, юлны Агыйдел салган, ул биек тауларны әйләнеп, кара урманнарны кисеп үткән, ә кешеләр аның артыннан гына ияреп барганнар… Агыйдел үткән юл буенча, киң үзәнлекләрдә авыллар, кирмәннәр, шәһәрләр, курганнар утырып калган… Әле алар теге вакытта әтисе белән Агыйдел башланган җирдән күп тә төшмәделәр, ә күпме нәрсәләр күрсәтте аңа әтисе! Атасалдагы кебек, язулы ташлар, «Алыплар каберлеге» дип атап йөрткән серле урыннар, борынгы курган-каберлекләр… Тирлән дигән җирдә хәтта мамонтның бүрәнәдәй борынын да тапканнар, алар аны шундагы музейга кереп караганнар иде. Күпме таш, чүлмәк ватыклары җыеп кайткан иде ул чагында Әтил! Музейдагы кебек борынгы ук очлары, иске акчалар да

табасы килгән иде аның, аларга очрамады шул… «Аның өчен махсус экспедицияләргә чыгарга кирәк, армиядән кайткач алып барырмын, улым»,— дигән иде әтисе… Барысы да хыялда гына калды…

— Бабай, без, әти белән Агыйдел башында йөргәндә, зур каберлекләр күргән идек. Аларны «Алыплар каберлеге» диделәр, анда бик зур гәүдәле кешеләр күмелгән икән… Син теге көнне сөйләгән зур кешеләр — шул алыплармы инде? Мин алар турында Коръән тәфсиреннән дә укыдым, Гад кавеме турында… Бу якларга алар шул туфаннан соң килгәнмени инде? Нух пәйгамбәр көймәсе белән?

— Әйе, улым, син күргән курган-каберлекләрдә дөньяның беренче кешеләре — алыплар ята, шуңа күрә ул шулай дип атала инде… Туфанга хәтле җирдә барлык кешеләр дә шундый зур гәүдәле булган, Адәм галәйһиссәлам кебек… Чөнки аның балалары бит инде алар… Җирдә беренче кешеләрнең алыплар булуы турында Коръәндә дә бар, бу хакта башка диннәрнең китапларында да язылган, хәзер фән дә бу хакта күп сөйли башлады… Кайдадыр алар титаннар дип, кайдадыр гигантлар дип, кайдадыр атлантлар, алыплар дип аталганнар… Библиядә исә аларны исполиннар дип язганнар, ягъни җир астында яшәүче галәмәт зур гәүдәле кешеләр… Бәлки алар тау куышларында яшәгәндер, кем белә… Әле беркөнне телевизордан сөйләп тордылар, шаккатып тыңладым, чит илдә эшләнгән тапшыру күрсәтteләр… Туфан вакытында 409 000 титан суга батып үлгән икән! Туфанга хәтле озон кыры нык булган, шуңа күрә тереклек тә көчле, гигант рәвештә булган, диләр… Ул вакытта хайваннар да гаҗәеп зур булган, әйтик, динозаврлар, мамонтлар, безнең татар әкиятләрендәге канатлы аждаһалар…

— Һәм шул аждаһалар, алыплар безнең якларда да яшәгәнме?

— Әлбәттә, яшәгән, улым, яшәмәсәләр, халык хәтерендә сакланмас иде, дастаннарга, шигырь-хикәятләргә күчмәс иде… Аннан — ул «Алыплар каберлекләре»н, мамонт, динозавр калдыкларын кая куясың? Булган инде алар монда, чөнки Урал таулары, Урал итәкләре алар яшәр өчен иң уңайлы урын бит… Үзең уйлап кара, бөтен нәрсә бар монда: кышларын, кар-бураннарда кереп яшеренергә зур тау куышлары, җәйләрен туклану өчен кара урманнар, яшел болынлыклар, саф сулы чишмәләр, кош-корт, җәнлек, җиләк-җимеш… Тауларыннан тимере, бакыры, алтыны чыга, мәрмәр ташлары аяк астында аунап ята… Тагы кайда шундый әзер байлык бар, улым? Тагы кайда шундый матурлык бар? Аллаһы Тәгалә җәннәттәй мондый җирләрне ничек буш яткырсын? Әлбәттә, бәлки, син әйткәнчә, туфаннан соңдыр монда алып гәүдәле кешеләр килгән… Әмма алар инде соңгы алыплар булгандыр, чөнки туфаннан соң җир йөзендә табигать бик нык үзгәрә, бөтен эре хайваннар үлеп бетә, эре агачлар да бетә, кешеләр дә күзгә күренеп кечерәя башлый… Әлбәттә, бу хәлләр бер-ике елда гына булмаган, моңа бәлки меңнәрчә еллар вакыт киткәндер… Әмма тора-бара кеше дә табигатькә җайлаша, менә бүгенге хәленә килә… Безнең татар халкында алыплар белән бәйле бик күп истәлекләр саклана, син аларны Бәндәбикә әбиеңнән сорарсың, яме, улым… Әнә хәзер без аларның авылы турыннан үтеп барабыз, кайтканда тукталырбыз, иншаллаһ!

Әтил бабасы күрсәткән якка карады. Юлның сул ягында, Агыйдел елгасы буенда, кыя-тауларга сыенып, бер авыл утыра иде… Еракtан ул Атасалга да охшаган, әмма Атасалдан зуррак, ныграк кебек… Менә кайда яши икән аның яраткан Бәндәбикә әбисе! Әтилнең аны күрмәгәненә дә инде 4—5 ел булыр… Тимертауга күчкәч, аларның Атасал белән дә, Бәндәбикә әби белән дә, хәтта Аксу белән дә аралары шактыйга өзелеп торды шул… Инде Бәндәбикә әбисе дә бик карттыр, аңа теге вакытларда ук 80 яшьләр иде бит инде… Һәм Әтил дә инде бәләкәй малай түгел, үсмер егет булып очраша аның белән, Алла боерса…

Каһарман авылы артта калды. Тау юллары тагы да кысылды, машина инде аклы-каралы кыяларга ышкылып диярлек бара иде. Әнә алар бер каршыга йөгереп чыгалар, бер читкә чигенәләр, артта басып калалар… Бабасының машинасы тау сыртларының берсенә менә, икенчесенә төшә, бишектә тибрәлгән кебек барасың… Башны борып, кайсы якка карасаң да —таулар, таулар, таулар… Кайсыларын түбәсенә хәтле агач баскан, өсләрендә урманнар шаулап утыра, кайсылары бер агачсыз, шәп-шәрә ташкыялар, аларның түбәләрендә җил генә уйнап тора… Тауларның кайсылары яртылаш агач, яртылаш таш… Мәңге яшел чыршы-карагайлар, хәтта Урал ташларына тамыр җибәреп, яшәргә, исән калырга тырышалар… Нәкъ безнең татар халкы кебек… Алар ауганда да шушы таулар белән бергә авачаклар…

— Уң якта — Баштау, сулда — Керәкәтау сыртлары, улым,— диде бабасы, Әтилгә сөйли барып.— Кара, нинди горурлар алар… Дөньяның нинди генә чорларын күрмәгән бит алар — туфанын да, бозлык чорларын да, корылыкларны да… Болар арасында, заманында, янартау булып, ут атып торганнары да булган…

— Ут атып торганнары да?! Вулканнар да булган инде монда, алайса, шулай бит, бабай… Ә бу тауларга ничә яшь икән соң, бабай, бер… йөз мең ел бармы икән?

Бабасы, бер мәһабәт тауларга, бер оныгы Әтилгә карап, көлемсерәп куйды.

— Таулар мең яшьлек кенә булмый, улым,— диде ул, чираттагы кискен борылышны җайлап кына үтеп.— Таулар… миллион еллык була алар… Безнең Урал таулары бигрәк тә… Ул бу тирәләрдә генә

түгел, бөтен дөньясында иң борынгы, иң карт тауларның берсе бит… Аңа, кимендә, 200—300 миллион яшь бар инде…

— 300 миллион ел!!!

Әтилнең тыны кысылды, ул, тәрәзәдән башын тыгып, кырыс тауларга карап, сүзсез калды… Ул бу хәтле чорны хәтта күз алдына да китерә алмый иде… Ул вакытта да бу тауларда шушындый ук агачлар үстеме икән? Юк, ул вакытта таулар да, агачлар да башка төрле булгандыр, элек бар нәрсә дә зур булган, ди бит бабасы. Бәлки әле Урал таулары үзләре дә башка төрлерәк, биегрәк булгандыр?

— Бәлки ул чакта Урал таулары тагы да биегрәк булгандыр, шулай бит, бабай?

Җиһангир карт оныгындагы акылга, фикер йөртү сәләтенә эченнән генә сокланып куйды. Бу баланың башы мантыйк, логика белән эшли, булган белеменнән чыгып, үзалдына кирәкле сорауны куя белә. Сорау куелган икән, ул инде аңа җавапны таба да таба… Әнә бит Ямантауга да әйләнә дә кайта, әйләнә дә килә… Шушы соравына гомер буе җавап эзләсә эзли, әмма тапмыйча туктамый инде ул аны… Дөньяны да менә шундый кешеләр алып бара инде, бөтен ачышларны алар ясый, зур сүзне алар әйтә… Кем белә, бәлки бу бала да моңа кадәр беркем ачмаган серләрне ачар? Әнә башына кереп утырган бит Нух пәйгамбәр көймәсе, шуны тапмыйча, ул бәлки туктамас та… Ә кемдер барыбер табачак бит инде аны, Алла насыйп итсә…

— Дөрес әйтәсең, улым,— диде Җиһангир карт, оныгын җөпләп.— Урал таулары борынгы заманнарда хәзергедән 2—3 чакрымга биегрәк булган. Ул шушы миллион ел заман эчендә инде берничә тапкыр иңеп, берничә тапкыр җир белән бергә яңадан калыккан… Күкрәге тулы байлык белән күтәрелгән… Бу — дөньяда иң бай тауларның берсе, балакаем! Ни генә юк анда — алтыны да, бакыры да, тимере дә, мәрмәре дә, нефте-газы да, гәүһәр ташлар, алмазлар — барысы да бар… Аллаһы Тәгалә монда байлыкны хисапсыз биргән, кешеләр рәхәтләнеп яшәсеннәр, кайгы күрмәсеннәр, дигән… Урманнарында нинди генә җәнлеге юк — бүресе, боланы, аюы, пошие, барсы, һаваларда — бөркете, карчыгасы, лачыны… Уралтау елгаларында нинди генә балыкларны очратмыйсың — чуртаны, алабугасы, кызылканаты, корбан балыгы, кызыл балык… Ә нинди тиңсез елгалар башлана Урал тауларыннан, улым, нинди елгалар агып чыга?! Санап бетергесез бит…

— Агыйдел, Карагай, Сакмар, Җаек! — дип, тиз-тиз санап китте Әтил һәм туктап калды. Ул башка елгаларны исенә төшерә алмый иде.

Бабасы аңа ярдәмгә килергә ашыкты:

— Әй улым, кечкенәләрен дә кушсаң, йөзләгән елга бәреп чыга Урал тауларыннан,— диде ул, машинасын Сөбханкул авылы ягына җай гына борып.— Безнең тирәдәгеләре — Агыйдел-Идел, Җаек, хәзер аны Урал елгасы, диләр, аннан тыш Нөгеш, Сакмар… Болар Ирәмәл, Әвәләк, Түгәрәктау тирәләреннән башлана… Син кызыксынган Ямантауның көнчыгышында, аңа терәлеп диярлек, Мәшәк дип аталган бик биек бер тау бар, әнә шуннан Йөрүзән елгасы агып чыга инде… Аның икенче ягында Күмердәк тавы кала… Ямантауны ике яктан урап, Олы һәм Кече Инзәр елгалары агып ята, берсе — Күмердәктән, икенчесе Нәрә тау сыртларыннан башлана… Моннан тыш безнең якларда Кече Катау, Олы Катау, Зур Әүнәр, Арша елгалары, бераз өстәрәк Ай һәм Уй елгалары агып ята… Тагы Сим, Дим, Ык, Нух, Аша елгалары бар… Саный китсәң, санап бетерерлек түгел, улым… Исемнәренә генә игътибар ит әле син аларның, исемнәренә генә — барысы да төрки-татарча бит… Әнә син эзләгән Нух елгасына кадәр бар…

— Ә тауларның, тау сыртларының исемнәре нинди матур, тыңла әле син, улым,— дип дәвам итте бабасы, машинасын таудан төшкәндә бераз әкренәйтеп.— Безнең Аксу тирәләрендәгеләрен генә санаек әле: Юша, Нәрәташ, Караташ, Сынташ, Җигүле, Күмердәк, Бәләгуш, Акбүләкарка таулары… Бу тирәдә ә-ә-нә — Мәчем, Шүлгән таулары, Олытау, Шарлык сыртлары, аның артында — Канчак, Кыбыз, Ямантау сыртлары…

— Ямантау?! — Әтил, аптырап, бабасына карады.— Ник монда да Ямантау бармыни?

— Ямантаулар да берничә, улым,— дип, сабыр гына җавап бирде бабасы.— Олы Ямантау янында әле Кече Ямантау бар, анысының биеклеге бер чакрымга җитеп бетми… Андый сыртлар әнә биредә дә бар… Биредә дә Ямантау бар… Әле Ырынбур өлкәсенең төньягында да шул исемдәге тау бар… Анысы инде әниеңнең туган яклары…

Бабасының шулхәтле күп белүенә Әтил гаҗәпкә калды. Ул аны намаз укып утыра торган түбәтәйле бер бабай дип уйлаган иде, ә ул, әнә бер нәрсәгә карамыйча, инде иртәдән бирле сөйли дә сөйли… Кайдан белә ул боларның барысын да?

— Бабай, син боларның барысын да кайдан беләсең? — дип сораганын Әтил үзе дә сизми калды.

— Мин боларны тормышның үзеннән беләм, улым,— дип җавап бирде бабасы җитди итеп.— Минем бөтен гомерем шушы тауларда, шушы елга буйларында үтте бит… Бу —минем туган илем, улым… Кечкенәдән — ялан тәпиләрем белән, олыгайгач — бөтен йөрәгем белән тойдым мин Урал

тауларының җылысын, рухын… Аннан, яшь чакта мин күп еллар буе геологик экспедицияләрдә катнаштым, бу тирәләрдә күп скважиналар бораууларга туры килде… Башта без йөри идек җир астында кайда нәрсә ятканын өйрәнеп, безнең арттан — кирәксә — төзүчеләр, нефтьчеләр, газчылар, атомчылар килә иде… Бу Урал тауларында яшерен заводларның күбесе шул елларда барлыкка килде инде, чөнки бу тирәләрдә хәтта уран ятмалары да булырга тиеш… Ә атом өчен нәкъ шул кирәк… Менә, шулай итеп, аларга барысын да табып бирдек тә, хәзер туган-үскән җирләребезгә рөхсәтсез керә дә алмыйбыз, улым… Болардан сез гыйбрәт алырга тиеш…

Ул арада асфальт юл бетеп, күтәртелгән коры ак ташлы юл башланды. Әле анысы да туры гына юл түгел — бер тауга менә, бер атылып аска төшә, уңга керә, сулга ташлана… Менә шунда Әтил чын тауның нәрсә икәнен аңлады инде — ул асфальт юлдан, машина тәрәзәсеннән генә карап барырга яхшы икән, менә хәзер, үрле-кырлы сикертә башлагач, бер дә алай матур күренми. Әллә кай арада машина эченә аксыл-соры таш тузаны кереп тулды, сулыш алулары авыраеп китте. Әтил тизрәк тәрәзәсен япты, тузан арасыннан, юлга карады. Әнә аста, бик аста киң тасма булып Агыйдел елгасы агып ята… Ул да Әтилләр белән шушы урынга хәтле килеп җитте, әле алга да китәчәк… Елга буена, тау итәкләренә, яшелрәк урыннарга берничә авыл кереп поскан… Алда — тау, тагы бер тау, тагы… Инде Әтил тәмам әлсерәп, башы әйләнеп, бабасына шуны әйтим дип торганда, тау башыннан җәелеп яткан киң үзәнлек күренде. Әллә кай тауларны урап үтеп, каршыларына зәңгәр сулы Агыйдел дә килеп туктаган иде… Аста ниндидер матур йортлар да күренә, юл читенә исә «Шүлгәнташ тыюлыгы» дип язып куелган…

* * *

— Килеп җиттек, улым, әнә каршыбызда — Шүлгәнташ,— диде аңа бабасы.

Шүлгәнташ?!

Моннан 15 мең ел элек борынгы кешеләр яшәгән Шүлгән мәгарәсе! Менә кайда икән ул! Әнә Агыйдел елгасы, әнә аның каршы якта ак кыялы текә яры, ә анда караеп тау тишекләре күренеп тора! Шүлгәнташ мәгарәсе шул микән? Елга аша аңа ничек кереп йөриләр икән соң?

Оныгының елга аръягындагы тау тишегенә текәлеп карап торганын күреп, Җиһангир карт ачыкларга ашыкты:

— Шүлгән мәгарәсе бераз арырак әле, улым,— диде ул.— Анда машина белән кертмиләр, бераз ял итеп, капкалап алгач, җәяү генә барырга чыгарбыз. Әйдә, хәзергә урнашыйк.

Алар машиналарын Агыйдел ярына ук китереп куйдылар. Яр бу яктан бик сөзәк, ямь-яшел чирәм белән капланган, суы да кул сузымында гына иде. Әтил, йөгерә-йөгерә, бабасына әйберләрне урнаштырырга, палатканы куярга булышты, ә үзенең күңелендә янәшәдә генә җемелдәп яткан көмештәй Агыйдел суы иде. Җитмәсә, машинадан урамга төшүгә, ул көннең бик эссе, хәтта кызу икәнлеген сизеп алды. Ул бер мизгелгә мәгарәне дә, хәтта ашау-эчүне дә онытып торды, аның тизрәк суга керәсе, суга сикерәсе килде. Бабасы аның хәлен тиз аңлап алды.

— Бар, бар, улым, юынып чык,— диде ул.— Тик бик эчкә кермә, чоңгыллы урыннары бар монда Агыйделнең, суырып ала күрмәсен.

Шулай диде дә ул оныгын су буена җибәрде, үзе исә, өйдән алып килгән ризыкларны чыгарып, табын әзерли башлады. Өйлә намазына да инде озак калмаган иде — кояш әнә нәкъ баш очында кыздыра. Әтил юынып чыкканчы, ул палаткага кереп, намазын да укып куйды. Бәлки бу борынгы җирләрдә кешеләр тарафыннан укылган беренче намаз, шөкерана итү булгандыр…

Әтил судан туңып, тешләре шыкырдап килеп чыкты. Көн эссе булса да, су суык иде. Агыйдел — тау елгасы шул, әле аңа таулардан чыккан боздай сулы күпме елга, чишмәләр килеп кушыла… Салкын күләгәле тау итәкләренә сыенып та күпме ага әле ул… Шуңа күрә ул җәй көне дә салкынча, саф, тәнгә һәм җанга рәхәт… Бу сиңа Атасал авылы янындагы Карагайлы елгасы гына түгел инде, әнә нинди чоңгыллы тирән урыннары бар! Тимертаудагы Урал елгасы да бик зур һәм тирән, әмма аның суы алар шәһәренә килеп җиткәндә, пычранып, каралып беткән була инде. Җәй көннәрендә аның өстендә корым элпәсе була — йөзләгән завод торбасыннан чыккан газ, төтен, корым шундый хәлгә китерә аны. Кышларын исә боз карала, кар, җиргә төшеп җиткәнче, кап-кара була… Монда исә кыш көне дә ап-ак буладыр, тирә-юньдә бер шәһәр, бер завод та юк бит… Монда шәһәр түгел, авыллар да бик сирәк әле, юл өстендә берничә генә калды. Ә теге бер-ике матур йорт монда килүче сәяхәтчеләргә ял итү өчен икән ул, бабасы шулай диде. Ә Әтилләрнең үз палаткалары бар — чын сәяхәтчеләрнеке кебек! Һәм алар бүген шунда куначаклар —бабасы шулай диде. Теге вакытта да алар, әтисе белән Агыйдел буйлап йөргәндә, палаткада кунган иделәр… Ничек күңелле булган иде Әтилгә! Аңа хәзер дә бик күңелле, чөнки ул хәзер бөтенләй башка дөньяда… Ул — таш мәгарәләр дөньясында, борынгы алып кешеләр җирендә бит! Һәм тиздән Әтил ул тау куышын үз күзләре белән күрәчәк! Бәлки берәр нәрсә дә табар әле шуннан…

Шундый татлы хыяллар белән малай яшел чирәм өстендәге табын янына килеп утырды. Ул шунда гына үзенең бик нык ашыйсы килүен аңлады. Әтил табын өстенә каплап куйган ак тастымалны ачып җибәрде. Әнекәем! Нәрсәләр генә юк иде анда. Әнисе аларга ашарганиләр генә салып җибәрмәгән — пешкән салкын ите, пешкән яңа бәрәңгесе, түтәлдән генә өзгән кыяр-помидоры, яшел суганы, тәгәрәшеп яткан авыл йомыркалары, кичәге бәлеш төпләре, камыр әйберләре… Ике термос кайнар чәй! Әйтерсең лә алар бер атнага чыгып киткәннәр… Биредә барысы да нәкъ өйдәге кебек. Тастымалларын, савыт-сабаларын да салырга онытмаган әнисе. Әтил юынып килешкә, бабасы аларны өстәлгә тезеп тә куйган. Алар барысы да Әтилне яраталар шул, Әтил үзе дә аларны бик ярата… Ашыйсы бик нык килсә дә, бабасы килеп утырмыйча, Әтил ризыкка үрелмәде, аны көтте.

Ул арада бабасы да, намазын укып, палаткадан килеп чыкты. Бисмилла әйтеп, табын янына утырдылар. Агыйдел буеннан искән җиләс җил аларга саф һава, су салкынын китереп торды, шуңа күрә кояшның кыздыруы да артык сизелмәде. Ашап-эчкәч, палаткага кереп, бераз ял итеп алдылар. «Көннең кызуы бераз сүрелсен, аннан соң барырбыз»,— диде бабасы. Агыйделнең салмак кына чупылдавын тыңлап, бабасы бераз черем итеп тә алды, Әтил исә ике күзенең берсен дә йома алмады. Аның тизрәк Шүлгәнташны күрәсе, тау тишегенә керәсе, йонлач мамонт рәсемнәрен үз күзләре белән күрәсе килде. Ул анда яшәгән борынгы кешеләрне күз алдына китерергә тырышып карады. Әмма хәзергә аның башында барысы да буталган иде: юлда бабасы сөйләгән серле алыплар, туфаннан соң Урал тауларына килеп урнашкан беренче кешеләр, Нух пәйгамбәр көймәсе, Ямантау, Шүлгәнташ, тагы дистәләгән тау, елга, авыл исемнәре һәм тарихлары… Ул бабасы кебек шуларның барысын да күрергә теләде, аның әтисе кебек бу борынгы тарихны өйрәнәсе килде, Урал тауларында аны әллә нинди зур ачышлар, могҗизалар, серләр көтеп торадыр кебек тоелды аңа… Бу, чыннан да, шулай иде, әмма ул ачышлар өчен үзенең күпме авырлыклар күрәсен үсмер малай әле аңлап бетерми иде… Һәм аңламавы белән бәхетле дә иде…

Бабасы уянуга, тиз генә җыендылар да Шүлгәнташка таба юнәлделәр. Капка төбендә билет сатучы егет аларга юлны күрсәтте. Вак таш сибелгән юл Агыйдел яры буенча куаклык-урман эченнән бара да, кинәт кенә көнбатышка таба борыла. Алга таба инде Агыйделгә түгел, Шүлгән суына юнәлеш тотып барасың. Ул су исә тау тишегеннән агып чыгып, мәгарә алдында күл булып җыелып ята икән. Күлдән агып чыккан инеш исә Агыйделгә таба ашыга…

Шулай бара-бара, шактый арыдылар. Җитмәсә, көн дә үзенең эсселеген сиздерә башлады, әллә кайдан килеп, чебен-черки сырып алды. Юл өстендә кыя-тау күргән саен, Әтилнең йөрәге кысылып-кысылып куйды. Шүлгәнташ шул микән? Ә тишеге кайда соң аның? Әмма болар берсе дә Шүлгәнташ булып чыкмады. Ара-тирә барган-кайткан кешеләр дә очрады, тыелган урында хәтта машиналар да күренде.

— Болар ерактан килгән зур кешеләрдер инде, тау тишегенә хәтле машина белән килеп туктаганнар,— диде бабасы.

Әтил шунда гына аңлады: алар Шүлгәнташ мәгарәсенә килеп җиткәннәр иде…

Мәгарә аларны упкындай кара авызы, өскә асылынып торган кыя-ташлары белән каршы алды. Аннан салкын һава бәреп тора иде. Мәгарә каршында кечкенә генә күл дә бар икән, әллә кыя шәүләсе төшеп, әллә үзе шундый — күл суы Әтилгә кара төстә кебек тоелды. Аннан, күләгәгә күзе бераз ияләнгәч кенә, ул күл төбендә төрле төстәге бик матур ташларны да күрде. Мәгарәдән чыккач, аларның берничәсен истәлеккә алырга уйлап, Әтил тау куышына таба ашыкты. Аның тизрәк эчкә йөгереп керәсе, ул борынгы мәгарәне тизрәк үз күзләре белән күрәсе килде. Әмма тау куышының авызына… тимер рәшәткә куелган булып чыкты. Рәшәткә-капка исә зур тимер йозак белән бикләп алынган иде. Аны күргәч, Әтилнең хәтеренә гарәп әкиятләре килеп төште, аның да: «Симсим, ач ишекне!» — дип кычкырасы килеп китте.

Ул арада, шушында эшләүче бер ирне ияртеп, Җиһангир карт та килеп җитте. Бу мәгарәгә болай гына керә торган түгел икән әле: муеныңа яктырткыч фонарь асасың, башыңа, таш төшмәсенгә, каска киясең, һәм яныңда озата баручы да булырга тиеш. Каратут йөзле бу типтәр агае монда шушы эшне башкарадыр, мөгаен…

Менә берзаман шалтырап тимер йозаклар, тимер капкалар ачылды. Алар сак кына мәгарә эченә атладылар. Өстә дә, аста да зур-зур кыя ташлар караеп ята иде, эчкәрәк үткән саен, бөтенләй караңгыланды, фонарь яндырмасаң, берни күренмәс хәлгә килде. Урамнан саркып кергән яктылык, ишек төбеннән ары узмыйча, караңгы ташларга сеңеп, юкка чыга бара иде. Әтил шунда ук игътибар итте: мәгарә эче салкынча иде, хәтта салкын дип тә әйтергә мөмкин. Моны алдан белгәндәй, бабасы кулындагы капчыгыннан Әтилгә җылы курткасын алып кидерде, үзе дә җилкәсенә нидер салды. Малай мәгарә эченә бераз ияләнә төште һәм фонарен арлы-бирле йөртеп, теге борынгы рәсемнәрне эзли башлады. Аның тизрәк йонлач мамонтларны, мөгезборыннарны, озын кеше рәсемнәрен күрәсе килә

иде. Алар бит моннан 15 мең ел элек ясалганнар! Мондый рәсемле тау куышларын дөньяда берничә генә диләр бит… Әмма күпме генә ялт-йолт килеп эзләнсә дә, Әтил берни дә таба алмады. «Белмәгән кеше бу караңгыда нәрсә таба алсын инде»,— дип уйлады ул, борчылып.

— Мин сезгә бераз бу мәгарәнең тарихын сөйләп үтим,—дип башлады озата йөрүче, малайның үзлегеннән эзләнеп йөрүен күреп.— Аннан рәсемнәрне дә күрсәтермен. Аның тәртибе шундый: эшне тарихтан башларга кирәк…

Үзенең артык кыбырсынуына, ашкынуына Әтил уңайсызланып та куйды. Әлбәттә, эш рәсемдә генә түгел бит, эш — бу якларның борынгы тарихында, ул рәсемнәрне кыя-ташларга төшереп калдырган кешеләр тарихында… Ул бит әле бу хакта берни дә белми, ә бу агай бирегә нәкъ шуны аңлату өчен куелган.

— Галимнәрнең әйтүе буенча,— дип дәвам итте озата йөрүче,— бу тау куышында моннан 14—15 мең еллар элек борынгы кешеләр яшәгән. Моны төрле дәрәҗәдәге анализ юллары белән расладылар инде… Бу тау куышы Шүлгән тавының эченә урнашкан. Шүлгән тавы бу тирәләр өчен бик биек тау, биеклеге бер чакрым тирәсе… Тауның төньяктан мәгарә авызына хәтле озынлыгы бер 12 чакрымнар булыр, озын тау ул… Менә шул тауның эче, ягъни бер өлеше — куыш. Бәлки тау эченнән аккан Шүлгән суы аны шул хәлгә китергәндер, бәлки кеше кулы да тигәндер, нәтиҗәдә бу мәгарә борынгы кешеләр җыелып яшәр өчен бик уңайлы урынга әйләнгән… Әзер таш йорт инде, дөресен әйткәндә… Менә бу тау куышының биеклеге, без басып торган урында, бер 30 метрлар булыр, киңлеккә исә ул бик киң, дистәләгән метрлы зур-зур заллардан тора… Әмма тау куышы бөтен төшендә дә болай биек түгел, тау эченә керә-керә, ул тәбәнәкләнә, хәтта үрмәләп кенә йөрерлек хәлгә килә… Мәгарә, шулай итеп, 3 катка күтәрелә, ягъни 3 яруслы, дибез инде без. Бу юллар тау эченә таба 3 чакрымга сузылган… Аның өченче катына, теге башына безнең әле үзебезнең дә барып җитә алганыбыз юк, тауның нәкъ үзәгендә тарих ниләр саклыйдыр — үзебез дә белмибез… Ә тау куышы бу тирәдә иң зурлардан санала. Заманында монда 400 атлы качак, аты-ние белән качып ятканын сөйлиләр. Менә шуннан аңларга була аның зурлыгын… Мәгарә үзе 12 зур залга бүленгән, алар, тармакланып, тауның үзәгенә хәтле китәләр…

— Ә рәсемнәр? — дип сорап куйды Әтил, түзә алмыйча. Аның тизрәк рәсемнәрне күрәсе килә иде, ә бу абый һаман алар турында сөйләми…

— Менә рәсемнәр янына да килеп җиттек,— диде озата баручы, шуны гына көткәндәй.— Фонареңны яктырт әле бу якка. Күрәсеңме, кызыл буяу белән ясаган рәсемнәрне?

— Күрәм, күрәм! — Малай тау куышын яңгыратып, кычкырып җибәрде. Өстә нидер шыбырдагандай, шыгырдап куйгандай булды, Әтил үзе дә курка калды.

— Күрәм, күрәм,— дип дәвам итте ул инде шыпырт кына.— Әнә мамонт, атлар… Анда озын аяклы кешеләр дә бар…

Барысы да, утларын яктыртып, шул якка текәлделәр. Монда тагы Әтил белмәгән әллә нинди кыргый хайваннар, серле билгеләр, таш тамгалар бар иде… Әмма Әтилне иң нык гаҗәпләндергәне — озын торыклы кеше булды. Аның гәүдәсе дә мамонт биеклегеннән ким түгел, ә аяклары — о-озын, ул, сөңгегә охшаган нәрсә тотып, кыргый хайваннар артыннан куа…

— Бөтен дөньяда мондый рәсемле мәгарәләр берничә генә,— дип дәвам итте озата баручы.— Франциядә, Испаниядә барлыгы билгеле, һәм менә бездә — Уралда…

— Монда ничек кешеләр яшәгән икән соң, кыш көне биредә суык буладыр бит? — диде Әтил, үзенең биредә җәй көне дә туңганын хәтерләп.

— Аның бөтен хикмәте дә шунда шул,— диде типтәр агай.— Биредә кыш көне дә, җәй көне дә уртача бер температура — 6—7 градус җылылык була. Кергәч тә, мәгарә авызында салкынрак була, әмма эчтә, югарыда кышын — җылы, җәен — салкынча… Менә нинди могҗиза бит ул — тау куышы, таш йорт… Нәрсә, урам белән ике арада аерманы сизмисеңмени? Анда, өстә, әнә 30 градус эссе, ә монда бөтенләй салкынча, җәй өчен хәтта салкын, әмма түзәрлек… Бабаң белеп җылы куртка кидерде сиңа, шуңа күрә аерманы сизмисеңдер…

Шулай сөйләшеп, алар борынгы рәсемнәр янында шактый басып тордылар. Малайның ул рәсемнәргә кагылып та карыйсы килде, әмма алар шактый биектә — идән белән түшәм арасындагы кыяга ясалганнар иде.

— Ә нәрсә белән ясаганнар соң алар аны, буявы һаман бетмәгән? — дип сорады малай, аяк очларына басып, үрелеп карый-карый.

— Галимнәрнең әйтүенчә, борынгы кешеләр бу рәсемнәрне күмер белән ясаганнар, аннан үсемлек һәм төрле ташларны төеп, буяу эшләгәннәр, аны хайванның туң мае белән катырганнар… Бәлки, тагы башка нәрсәләр дә катыштырганнардыр… Нәтиҗәдә мәңге бетми торган табигый буяу килеп чыккан…

Сөйләшә-сөйләшә, сак кына атлап, алар мәгарәнең тагы берничә зур залын карап чыктылар. Югары менгән саен, барган юллары тарайды, таш түшәм тәбәнәкләнде, мәгарә эче дөм караңгы булып калды. Яшен тармагыдай чатнап киткән юллар Шүлгән тавының үзәгенә — караңгылык дөньясына таба өстери иде… Монда инде үлем тынлыгы һәм кабер салкынлыгы, ә өстә урманнар шаулый, кошлар сайрый, кешеләр яшәп ята…

— Бу тауның тагы бер хикмәтле ягы бар әле, улым,— дип, Җиһангир карт та телгә килде.— Шүлгән тавының буеннан-буена, менә бу мәгарәнең астыннан, шаулап зур елга агып ята, шулай бит, туган?

Караңгыдан озата баручының тавышы ишетелде:

— Әйе, агай, Шүлгән суы, диләр аны… Ул Шүлгән тавының төньягында, моннан 12 чакрымнар ераклыкта башлана да, бу тау куышына 2 чакрым кала, шаулап җир астына кереп югала… Аннан 2 чакрым буе мәгарәнең астыннан, күзгә күренмичә, үз юлы белән агып бара да, мәгарә авызына җиткәндә, тагы шаулап дөньяга бәреп чыга… Монда кергәндә бер күл күрдегезме? Менә шул Шүлгән суыннан җыелган күл инде ул. Аннан күлдән инеш булып агып чыгып, Агыйделгә коя… Суы бик салкын, куырып ала, эчәргә тәмле, ниндидер шифасы да бар, диләр… Шулхәтле тау-таш арасыннан аккач, нидер бардыр инде…

Алар акрын гына, кармаланып диярлек, аска төшә башладылар. Төшкән саен, тау куышы иркенәеп, таш түшәмнәр биегәеп киткән кебек булды. Озата баручы аларны бер авыл мәйданын хәтерләткән тигез урынга алып килде.

— Менә биредән борынгы кешеләрнең торак урыны табылды,— диде ул, фонаре белән таш идәнне яктыртып.— Алар биредә үзләре бер авыл булып яшәп ятканнар… Галимнәр биредә чакматаштан ясалган эш кораллары, яшьмәдән һәм тау бәллүреннән ясалган әйберләр таптылар. Араларында сөяктән ясалган эш кораллары, яшел таш мәрҗәннәр дә бар иде… Балчыктан ясалган савытларда хәтта каткан буяу да сакланып калган, шуларның барысыннан чыгып, биредә 14—15 мең ел элек кешеләр яшәгәнлеген билгеләделәр… Менә монда янган күмер калдыклары, арырак мамонт борыны, мәгарәдә яшәүче аюларның сөякләре, төлке, куян, кеш калдыклары табылды… Аларның барысын да җыеп, Торатау музеена алып киттеләр. Теләсәгез, анда барып та карый аласыз…

Әтил бу урынга иелеп-иелеп карады. Аның йөзенә учак ялкыны бәргән кебек булды, ә учак янына, тезелешеп, борынгы кешеләр утырган… Алар бик зурлар, озыннар, аякка басканда, башлары чак кына түшәмгә тими кала… Әнә алар зур аюларны бугазларыннан гына буып алалар, кыргый атларны ялларыннан тотып туктаталар, хәтта мамонтларны бергәләшеп җиргә егалар… Бу тау куышы — аларның йортлары, Урал таулары аларның ил-җирләре була… Мәңгелек кар-бозларны ерып, ватып, кояш белән бергә алар да таулардан түбән төшә, дөньяга тарала… Туран тауларының — ике ягына да… Кар диңгезеннән — кайнар чүлләргәчә… Хәзергә алар, зур юлга чыгар алдыннан, учак янында ял итәләр, көч җыялар… Менә биредә аларның хәтта зур-зур аяк эзләренә кадәр ташка батып, уелып калган…

— Улым, чыгабыз,— дигән тавышка Әтил уянып киткән кебек булды. Учак урыны юкка чыкты, әле генә анда тезелешеп утырган алыплар каядыр таралдылар, мәгарә ташларында кызыл буяу белән ясалган рәсемнәре генә торып калды. Алар Әтилне, ул тау куышыннан чыкканчы, тезелешеп озата бардылар… Аннан караңгылык аларны йотты, алар мәңгелек туң илендә басып калдылар…

Урамда исә җәйге эссе зеңгелдәп тора иде…

Мәгарә авызына тотынып үскән куаклар, эсседән түзә алмыйча, кыя күләгәсенә сыенганнар… Аяк астында, шарлап, Шүлгән суы агып ята… Ул да таш кыяга сыенып бетеп, аның астына кереп китеп ага… Ул тирәдә күл тирән, ахры, суы да каралып тора…

Әтил тизрәк җылыга, ачык урынга йөгерде. Аның күл читеннән, су төбеннән теге төсле ташларны җыясы бар бит әле! Ул фонарен бабасына тоттырды да кулын суга тыкты. Су салкын иде, әмма ул ниндидер рәхәтлек бирә, бәрхеттәй йомшак… Әтил, үзе дә сизмәстән, битләрен дә юды, аның сулышлары киңәеп, күзләре ачылып киткән кебек булды. Мәгарә астыннан чакрымнар буе агып килгән Шүлгән суы бераз шомландырса да, малайның кызыксынуы көчле иде, ул су буеннан китә алмады. Әтил, күл читенә тездән кереп, ак, яшел, зәңгәр, кызыл, хәтта кап-кара ташларны җыя башлады, алар исә, «Мине ал, мине ал!» дигәндәй, аңа таба үзләре тәгәрәп киләләр иде… Малай Шүлгән күленнән бер уч таш җыйды, аларны ипләп кенә куртка кесәсенә салып куйды…

Шүлгәнташ мәгарәсе аларны кап-кара авызын яба алмыйча озатып калды. Анда — бөтенләй башка дөнья иде… Дөньяның беренче кешеләре иң авыр шартларда яшәргә мәҗбүр булган беренче таш куышлар… Кышын — салкын бураннарда, җәен көчле җил-давыл вакытларында алар шунда кереп сыенганнар, шунда тормыш иткәннәр… Дошман яулары килгәндә дә, бәлки алар шунда качып калганнардыр, явыз ерткычлардан да аларны шул таш мәгарәләр саклагандыр… Монда аларның балалары туган, монда алар гаилә, кавем, җәмгыять булып укмашып яшәгәннәр… Дөньялар тыныч һәм

матур вакытта алар тау куышларыннан тышка чыкканнар, тирә-якны өйрәнгәннәр, ризык тапканнар, дөнья буйлап таралганнар… Кем белә, бу таш мәгарәдә бәлки Әтилнең борынгы бабалары да яшәгәндер, салкын боз чорларында бәлки алар шунда качып исән калганнардыр…

Бу — тау эчендә, тарих төпкелендә барган бик борынгы вакыйгалар… Ә тау өстендә, әйләнә-тирәдә бүген бөтенләй башка вакыйгалар булып ята… Югыйсә Шүлгән дә шул, Агыйдел дә шул ук, әмма кешеләр башка, дөньясы башка… Табигать бу тирәләрдә генә менә шулай саф хәлендә сакланып калган, ә арырак китсәң — завод та завод, газ һәм төтен, атом һәм химик корал базлары… Бөтен Урал таулары шуның белән тулган, пәрәвездәй чорнап алынган… Бабасы әйтте, хәтта бу тау куышлары да барысы да хисапта икән, ә алар бу тирәдә генә дә 300 гә якын, ди… Хәрби сәнәгатьчеләрнең, тимер-бакыр заводларының, атомчыларның Шүлгәнташка килеп җитәселәре дә күп калмаган инде… Һәм беркөнне Шүлгәнташ та ябык зона булырга мөмкин… Ямантау кебек…

Алар, шул хакта сөйләшеп, бабасы белән Шүлгәнташ тирәсендәге урманлыкта шактый йөрделәр… Монда, адым саен, көтмәгәндә йә ялгыз кыя-таш, йә берәр тау калкып чыга… Һәм аларның күбесеннән тау тишекләре каралып күренеп тора… Агыйдел ярларының буеннан-буена да, яр карлыгачларының оялары кебек, зур-зур тау куышлары күренеп тора…

— Анда хәтле ничек менә алдылар икән, бабай? — диде Әтил, кулы белән ярдагы тишекләргә күрсәтеп.— Аста — су, өстә — биек кыя, кем бу тау куышларына керә алды икән?

— Менә синең алыпларың кергәндер дә инде,— диде бабасы, Әтилнең үзе кебек, мавыгып.— Шүлгәнташ мәгарәсендә күрдеңме син тирән-тирән аяк эзләрен? Берсе-берсе ярты метр бит аның, игътибар иттеңме?

— Әйе, бабай! — дип кычкырып җибәрде Әтил.— Мин дә күрдем аларны… Тик теге абый барында әйтмәдем генә, көлмәсен дип… Алыпларның эзе иде бит ул, әйеме?

— Шуларныкы… Ниндидер сәбәпләр белән, җирдәге таш җылынган һәм аларның эзләре уелып калган… Бәлки учак утыннан шулай таш кызгандыр, бәлки сугыш-мазарлар булгандыр, янгын чыккандыр… Хәзер белеп булмый инде, улым… Әмма гыйбрәт алырлык нәрсәләр күп монда, бик күп…

Бабасы өстәл әзерләгән арада, Әтил тагы Агыйделгә чумып чыкты. Агыйдел суы аны әле кочагына алып тибрәтте, әле агым белән бөтереп алып, ак кыяларга таба тартты… Анда хәтле йөзеп керергә Әтилнең батырчылыгы җитмәде. Янында әтисе булса, бәлки кергән дә булыр иде… Әтисе кайткач, Әтил монда аның белән дә киләчәк әле, һичшиксез киләчәк… Бәлки әле әнә ул ярдагы тау тишекләренә дә кереп карарлар… Анда нәрсәләр бар икән? Бәлки әле ул тау тишекләрендә әллә нинди ачылмаган серләр яшеренеп ятадыр?

Ул арада бабасы аны чәйгә чакырып алды. Әтил үзе дә туңа, арый башлаган иде инде — бабасының тавышын ишетүгә, судан чыгып йөгерде. Ул кайнар чәй эчкәч җылынып китте, табындагы тәмле-томлыны сыптыра башлады. Көне буе мәгарә карап йөреп, урман сукмагыннан арлы-бирле берничә чакрым җәяүләп үтеп, ул ачыккан, арыган иде. Су кереп, тәмләп ашап куйгач, тагы төне буе тау куышлары карап йөрерлек көч тойды ул үзендә. Әмма монда, тау арасында, караңгы тиз төшә икән, башта таулар каралып, төн пәрдәсе белән капланды, аннан Агыйдел өстенә дә караңгылык иңде…

— Әйдә, улым, бераз шәйләнгәндә, ризыкларны җыеп куйыйк та, бергәләп ястү намазын укып алыйк,— диде бабасы, табынны җыя-җыя.

Палаткаларына кереп, кыйблага карап бастылар. Бабасыннан көнгә әллә ничә тапкыр күреп, Әтил дә инде намаз тәртибен аңлый башлаган иде. Иң мөһиме, аның үзенең, бабасы кебек, ихластан намаз укыйсы, бу хәлләрдән гыйбрәт алуын Аллаһка белдерәсе килде… Көн, чыннан да, бик озын һәм гыйбрәтле булды, ул могҗизага тиң нәрсәләр күрде… Кайда-кайда, бу урыннарда, һичшиксез, намаз укырга, гыйбрәтләнергә, шөкерана итәргә кирәк… Бабасы гел шулай ди… Агыйдел суында юынып чыккач, Әтил тәнендә бетмәс көч, сафлык сизгәндәй булды, инде җанын, рухын да чистартырлык гыйбадәт кирәк иде…

Сәфәрдә булгач, бабасы намазны кыскартып укыды, тиз бетерде, әмма догасын озаклап кылды. Әтилнең исә догасы кыскарак булды, ул үзенә, әти-әнисенә, әби-бабасы өчен дога кылды, саулык, бәхетле тормыш теләде. Аннан бабасының ярым пышылдап кылган догасын тыңлап, күңеле белән аңа кушылып, теләктәшлек итеп утырды.

— Ий Раббым,— дип пышылдады бабасы,— безгә гыйбрәтләреңне күрсәттең, инде рәхмәтләреңнән дә аермасаң иде… Безгә җәннәткә тиң җирләр бирдең, инде шул ил-җирләргә яңадан үзебезгә хуҗа булып яшәргә насыйп итсәң иде… Ий Раббым, җирләргә-көннәргә иминлек бир, бәндәләргә иман бир, көтелмәгән бәла-казалардан, афәтләрдән сакла… Гаиләмә, нәселемә иминлек, иман бәхете бир, Раббым, милләтемә иманга кайтырга ярдәм ит… Милләтемә көч-кодрәт, акыл, саулык бир, хәерле нигъмәтләр белән нигъмәтләндер… Ий Раббым, безне явыз кавемнәр кулында калдырма, шушында

үзебезгә ил-җир корып, анда ислам тәртипләре урнаштырып, татар милләте булып яшәргә насыйп ит… Раббым, татар халкын рәхмәтләреңнән ташлама, аңа бәхет бир… Шушы җирләрдә бездән дога өмет итеп яткан, бу дөньядан мөселман булып киткән әрвахлар рухына да догаларыбызны ирештерсәң иде, Раббым Аллам! Алар белән җәннәтләрдә очрашу бәхетен бирсәң иде… Амин.

Әтил бабасының һәр сүзен кабатлап барды. Аны бигрәк тә бабасының татар халкы өчен шулай ихластан дога кылуы тетрәндерде… Ул бу доганың һәр сүзен хәтеренә, кан күзәнәкләренә язып барды… Инде ул үзе дә гомере буе шушы доганы кылачак, шулар өчен көрәшәчәк бер татар баласы иде…

Намазларын укып бетергәч, әкрен генә алдан әзерләп куйган урыннарга барып яттылар. Тышта җил күтәрелеп килә иде, ахры, ул Агыйдел буендагы тал-тирәкләрне шаулата, дулкыннарны чайкалдыра иде… Шул көйгә бабасы йокыга китте, ахры, аның тыныч кына сулыш алганы ишетелә башлады… Ярты көн машина рулендә килеп, ярты көн Әтил белән тау-таш арасында йөреп, карт кеше арыгандыр шул… Менә хәзер, бабасы белән озын юлга чыккач кына, Әтил үзенең ни дәрәҗәдә бәхетле икәнен аңлады. Аның бит дөнья бәясе бабасы бар! Үзе намаз укый, тәртипле, акыллы, тырыш, ормый-бәрми, кычкырмый, ә күпме белә?! Әтил өчен әнә кайларга чыгып китте… Әтил үзе дә бабасын беркайчан ташламаячак, алар — хәзер аның өчен дөньяда иң кадерле кешеләр…

Әтил бүген узып киткән озын көнне күз алдына китерде. Әле аның каршына юлда күргән биек-биек таулар чыгып басты, ул әле Агыйдел елгасы дулкыннарында тибрәнде, әле фонарь асып, Шүлгәнташ мәгарәсендә йөрде… Аның күз алдыннан таш-кыяга ясаган кыргый җанварлар үтеп киткән кебек булды, алар артыннан алып кешеләр куа бара иде… Бер көн эчендә күпме нәрсә белде Әтил, күпме нәрсә күрде! Әле ул үзе дә аңлап бетмәгән күпме нәрсә бар! Тимертауга кайткач, ул, иң беренче чиратта, тарих белән шөгыльләнә башлаячак. Юк, Аксуга, бабаларына кайтуга! Анда бит әтисеннән калган күпме китап саклана, Әтил аларның һәрберсен карап чыгарга, белергә тиеш. Аңлаганын аңлар, аңламаганын соңрак белер… Ул китапларны Әтил Тимертауга да алып китәр әле, анда да кыш буе өйрәнер… Аннан, мәктәпне тәмамлагач, ул әти-әнисе укыган Ырынбур институтына китәчәк, тарих буенча укыячак. Юк, Әтил Казан дәүләт университетына китәчәк! Анда татар тарихы буенча укыячак! Ул, һичшиксез, Урал тауларының ни өчен Туран таулары дип аталуын беләчәк, татарларның бирередә иң борынгы заманнардан — Нух пәйгамбәр чорыннан яшәвен исбатлаячак. Нух пәйгамбәр көймәсен табачак, иншаллаһ! Бабасы шулай дип әйтеп куярга куша, чөнки Алла теләсә генә теге яки бу эш булачак, ди…

Әтилнең уйлавынча, Нух пәйгамбәр көймәсе —Ямантау түбәсендә, бу яклардагы иң-иң биек тау башында… Һичшиксез бирередә ул... Әтил аны барыбер табачак, табачак, табачак…

Ул арада урамда, әллә җир астыннан, әллә тау түбәсеннән, бик саңгырау, әмма ап-ачык, көчле дөпелдәү авазы ишетелә башлады. Дөп-дөп… Дөп-дөп… Әйтерсең лә бер көтү фил, юк, бер көтү мамонт, шулай дөп-дөп басып, су эчәргә бара… Әтил, ярдәм көткәндәй, бабасына карады, әмма бабасы берни белми һәм ишетми йоклый иде… Әтил сулышын кысып, тынып калды, әллә үз йөрәгенең тавышы шулай ишетеләме икән, дип уйлады. Юк, аңа карап, дөпелдәү авазы бетмәде, киресенчә, көчәеп, инде алар яткан палатка тирәсендә үк яңгырый башлады. Әтил бабасын уятырга оялды, башын тыгып, башта палатка ишегеннән карарга уйлады. Һәм шул хәлдә катып, телсез калды… Чөнки ул күргәннәр дөньяда беркем ышанмаслык, дөньяда беркем күрмәгән хәлләр иде… Тулган ай нурына коенып, ап-актан киенеп, аңа таба алыплар атлый иде… Аларның дөп-дөп басып килгән аяк тавышларыннан Урал таулары селкенеп тора, Агыйдел сулары дулкынланып чайкала иде…

Тик, ни гаҗәп, бу хәлләрне Әтилдән кала күрүче дә, ишетүче дә юк, ахры, әнә бабасы да һаман тыныч кына йоклый бирә, мәгарә сакчысының эте дә өрми, алар кебек бирередә куна калган бер-ике палаткада да тынлык… Ниндидер тылсымлы көчкә буйсынгандай, үзендәге куркуны җиңеп, Әтил палаткадан тышка чыкты. Әтил аларны күрсә дә, алып кешеләр, әлбәттә, аны күрмиләр иде, ул алар өчен аяк астындагы кош баласы зурлыгында гына иде… Иң мөһиме — аларның аяк астында калып тапталмаска кирәк иде…

Әнә алар, эссе көндәге рәшә кебек, Агыйдел буеннан чайкалып бирегә таба киләләр… Башлары күккә тиеп тора, буйлары әнә шул кыя-тау биеклегендә, йөзләре тулган ай кебек якты, алардан әллә нинди көмеш нурлар сибелеп тора… Әллә соң болар күктән төшкән, чит планетадан килгән кешеләрме икән?

Менә алар, искән җилдәй тонык кына шаулап, Әтил янынннан үтеп киттеләр, эре-эре адымнар белән туп-туры Шүлгәнташка таба юнәлделәр. Алар үткәндә агачлар җиргә кадәр иелеп, шаулашып калдылар… Әтил, үзе дә сизмәстән, алып кешеләр артыннан ияреп китте, чөнки үз гомерендә беренче тапкыр күргән бу могҗизадан ул инде аерыла алмый иде…

Менә алып затлар Шүлгәнташ авызы янына килеп туктадылар. Алар килеп басуга, тимер капкалар шалтырап ачылып китте, алыплар, башларын бераз ия төшеп, тау куышына керделәр. Әтил дә алар артыннан ашыкты. Ни гаҗәп, алыплар керү белән таш мәгарә эче нурланып, яктырып китте. Әйтерсең лә бирегә ай, кояш нурлары кереп тулды! Менә алыплар авыл мәйданын хәтерләткән зур түгәрәккә тезелешеп утырдылар, Әтил исә бер читкәрәк, караңгырак урынга чүмәште, чөнки ул бу зур кешеләр күзенә күренергә курка иде…

— Ничә мең елга беренче тапкыр бу җирләрдә әрвахлар рухы өчен дога кылынды,— диде шулчак алыпларның берсе. Аның тавышы күк күкрәгән кебек гөрелдәп тора иде.

— Шул дога безне яңадан бу туфракка кайтырга ярдәм итте,— диде икенчесе.

— Әмма сез беләсез, бу җирләрдә беренче һәм соңгы дога бу… Тиздән казан кайный башлар һәм бу тау аралары ут белән тулыр…

— Дога ияләренә ярдәм кирәк,— диде тагы беренче алып.

— Бу эш — Аллаһ кулында, без сәбәпче генә,— диде икенчесе.

— Догага — дога белән җавап бирик… Дога ияләренә ярдәм сорап, Аллаһка ялварыйк… Без бу таш йортыбызга 15 мең елдан соң яңадан тик шуның өчен кайттык… Бүгенге дога ияләрен коткаруда сәбәпче булыр өчен…

Шулчак алыплар, башларын бер-берләренә терәп, киңәш-табыш итә башладылар. Әтилгә аларның сөйләшкәннәре өзек-өзек кенә ишетелә башлады. Ул сүзнең үзләре турында барганын күңеле белән сизенде, чөнки алар бүген әрвахлар рухына дога кылганнар иде… Нәрсәдән коткарырга телиләр аларны алыплар, нинди ут, казан турында сөйлиләр алар? Әтил аларга тагы да якынрак килергә курыкты, кисәк кузгалсалар, я таптарлар, дип уйлады. Әмма аның алыплар сөйләшкәнен бик тә ишетәсе килде, бәлки Ямантау, Нух пәйгамбәр көймәсе турында да нидер әйтерләр дип көтте ул. Тик алыпларның сөйләшүе нининдер серле, сәер хәлдә бара иде. Алар әллә шулай дога-гыйбадәт кылалар, әллә васыять әйтәләр, әллә бер мизгелгә генә кайтып килгән якты дөнья белән бәхилләшәләр иде… Шүлгәнташ мәгарәсен, җир астыннан килгән кебек, тонык гөрелте тутырды…

**…Бу җирләр тиздән кайнар ут булыр, тау аралары су белән тулыр…**
**Атом казаны тулып ташыр да, шушы хәл җитәр дөнья башына…**
**Утта янганы утта куырылыр, суга батканы судан тончыгыр…**
**Атабыз салын эзләр меңәрләр, табар берәүләр, мәгънә белгәннәр,**
**Раббым, дигәннәр…**
**Шулар котылыр яңа туфаннан, әмма җир инде яшәрлек булмас…**
**Ата салына кереп изгеләр күчәр бу йорттан икенче йортка…**
**Безнең тарафка — мәңгелек яшәү, мәңгелек бәхет, җәннәт иленә…**
**Шуны аңлатыйк без кешеләргә: эшләре аша, төшләре аша,**
**[illegible]**
**Барыбызның да аңа кайтуны…**
**Вакыт аз калды, янып килә ут, азларны гына булыр коткарып…**
**Ышанганнарны, яшәгәннәрне бары Раббыбыз Аллаһ кушканча…**

Алып затлар шулай диделәр дә, аякка басып, ак кулларын күккә күтәреп, тәкбир әйтә башладылар:

— Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

Ләә-иләһә-иллалаһу! Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

Әтил дә алар артыннан кабатлап барды, алып кешеләр белән бергә, яхшы кешеләрнең котылуын сорап, дога кылды…

Менә алыплар догаларын бетерделәр дә, тау тишеге буйлап, югарыга менә башладылар. Таш кыялар алар алдында икегә ярылып юл бирде, мәгарә киңәеп, офыкларгача ачылып китте… Менә алар, кыя-ташларны ярып, тау түбәсенә менделәр, менә җирдән аерылып, күккә күтерелә башладылар, күктәге ак болытларга әйләнеп, юкка да чыктылар… Югарыдан Әтилнең битенә яңгыр җиле килеп бәрелде, дөбердәп күк күкрәгән тавыш ишетелде… Әтил шул чагында гына үзенең тау куышында берьялгызы калганын аңлады. Дөм караңгыда, чыгарга юл таба алмыйча, ул мәгарәне яңгыратып, кычкырып җибәрде…

Әтил палатка эчен яңгыратып кычкырып җибәрде. Бу тавышка бабасы да уянды.

— Улым, улым, бисмилланы әйтеп ят әле, саташасың бит,— диде ул, караңгыда куллары белән капшанып, Әтилне эзләп.

Ә Әтил… палатканың ишек төбендә ята иде… Ничек монда килгән соң ул? Ә бабасы кайда? Бабасы палатканың эчендә үк — түрдә… Тукта… Ә теге алып кешеләр кайда? Әтил, башын күтәреп, палатка ишегеннән күккә карады. Анда бары тик куе ак болытлар гына йөзеп йөри иде… Кайдадыр, бик еракта,

дөбердәгән тавышлар ишетелә, төнге күкне телеп, яшен камчылары чагылып үтә… Алып кешеләр бер җирдә дә күренми…

— Нәрсә карыйсың анда, улым, нәрсә эзлисең?

Әтил әле генә менә монда алыпларны күрүен бабасына әйтергә оялды. Барыбер ышанмас, төш күргәнсең, саташкансың, дияр. Башка кеше сөйләсә, Әтил үзе дә ышанмас иде, әмма ул аларны үз күзләре белән күрде бит, тавышларын да үз колаклары белән ишетте…

Бабасын борчымас өчен, Әтил шыпырт кына урынына барып ятты. Юрган астында да аңа алыпларның тулган айдай ап-ак йөзләре күренгән кебек булды… Ул хәтта аларның дөп-дөп иткән аяк тавышларын да хәтерли әле, әнә нәкъ Агыйдел дулкыны ак кыяга бәргән кебек… Шушы җил, дулкын тавышларына изрәп, малай йокыга китә башлады. Әле таң атмаган, әле төн үтмәгән, әле фәрештәләрнең, җен-пәриләрнең иң уяу чаклары иде… Кинәт кенә урам якта мәгарә каравылчысының эте сузып-сузып улый башлады. Әтил малай тагы сискәнеп күзләрен ачты.

— Бабай, нигә шулай улый ул? — дип сорады ул, нигәдер пышылдап кына.

— Йокла, улым, йокла,— дип тынычландырды аны бабасы.— Күктә җен-пәриләрне, фәрештәләрне күрә — шуңа күрә улый ул эт… Ә син бисмилланы әйт тә йокла… Бисмиллалы кеше янына җен-пәри килмәс, аны бары тик фәрештәләр генә саклар…

Бабасының пышылдап дога укыган тавышына Әтил изрәп йокыга китте. Хәзер, чыннан да, аның тынычлыгын инде беркем бозарлык түгел иде, чөнки ул бабасының догалары белән саклана иде…

* * *

Әтил күктән шыбырдап яңгыр яуганга уянып китте. Палаткада бабасы инде юк, ул, ахрысы, машина тирәсендә кайнаша иде. Әтил башын палатка ишегеннән тыгып карады — бабасы, чыннан да, яңгыр үткәрми торган плащын киеп, машинаны карап йөри иде.

— Әйдә, улым, юынып, эшеңне бетереп ал да, чәй эчкәч, юлга кузгалырбыз,— диде ул.— Озакка килгән булырга охшый бу яңгыр… Урал тауларында шулай инде ул: әле генә кояш була, аннан коеп яңгыр ява башлый… Таулар тарта яңгыр болытларын, таулар…

Яңгыр күптән түгел генә башланган, ахры, аяк астын артык җепшетеп өлгермәгән. Әтил тиз генә бер урынга барып килде, бабасы әзерләп куйган су белән битен-күзен юды. Кире палаткага йөгергәндә, ул аяк астында ниндидер тирән-тирән эзләр күргән кебек булды. Алар Агыйделнең чирәмле ярына батып-батып кергәннәр иде, яңгыр исә алардан су чокырлары да әзерләп өлгергән… Шундый ук тирән-тирән зур эзләрне яр буендагы комлыкта да күрергә була иде…

«Алыплар! — дип уйлады Әтил, төнге хәлләрне исенә төшереп.— Димәк, бу төш кенә булмаган, димәк, алар чыннан да бу тирәдә йөргәннәр, Әтил дә аларны чынлап күргән…»

Ул, башын күтәреп, бер болытлы күк йөзенә, бер Агыйдел ярларындагы ак кыяларга карады. Аннан Шүлгәнташ мәгарәсе ягына борылды. Аның уйларына җавап биргәндәй, Шүлгән тавы өстендә күк күкрәп җибәрде, әйтерсең лә, дөп-дөп итеп басып, тау түбәсенә алыплар менеп килә иде…

— Яңгырга чыланып беткәнсең бит, улым, нишләп торасың анда? — дигән тавышка Әтил айнып киткәндәй булды. Тагы бер тапкыр Шүлгән тавы ягына карап куйды да палаткага таба йөгерде.

Бабасы аның юеш өс-башын салдырып, корыларын бирде — әнисе барысын да хәстәрләп салып җибәргән иде. Термостан агызып, кулына кайнар чәй тоттырды. Төнлә дә саташып яткач, ул оныгының чирләп китүеннән курка иде. Кичтән калган ризыкларны капкалап алдылар да юлга җыена башладылар. Яңгыр яумаса, бу тирәләрне тагы бераз карап йөрергә исәпләре бар иде, әмма яңгыр астында табигать карап йөрүнең мәгънәсе калмады.

— Шүлгәнташны кичә килеп карап калуыбыз яхшы булган әле, улым,— диде бабасы.— Төнлә мәгарәнең бер өлешендә тау ишелгән, түбәсенә хәтле зур ярык пәйда булган… Аннан хәтта күк йөзе күренеп тора, ди… Бер хәбәр инде бу, могҗиза… Хәзергә Шүлганташны япканнар, тәртипкә китермичә ачмаслар әле…

Әтил чәй эчкән җиреннән туктап калды. Тауның түбәсе ярылган? Әйе, Әтил үзе дә күрде: тау урталай ярылып китте һәм шул юлдан алыплар югарыга — түбәгә чыктылар… Аннан ак болытка әйләнеп, күздән югалдылар… Әмма кем ышансын мондый хәлгә? Моны бит хәтта бабасына да сөйләп булмый, авырып киткән, диячәк… Шуңа күрә Әтил хәзергә бу хакта беркемгә дә әйтмәскә булды.

— Кузгалыйк, булмаса, улым,— диде, ниһаять, Җиһангир карт.— Кайтышлый Каһарман авылына, Бәндәбикә әбиең янына да сугылып чыгасы бар… Аксуга кичке якта кайтып җитсәк, шул ярый…

Бәндәбикә әби!

Менә кем аңлар иде Әтилне! Алыплар турында да беренче булып Әтилгә ул сөйләгән иде бит. Малай аны бик яхшы хәтерли. Әтилләр Атасалга кайтып тора башлагач, ул аларга еш килә иде. Әй күп экиятләр белә дә соң инде Бәндәбикә әби! Уралтау буендагы төп нигезендә, Карагайлы елгасының

шаулап агуын тыңлый-тыңлый, ул Әтилгә төннәр буе әкият сөйли иде… Әллә нинди куркыныч та, могҗизалы да нәрсәләр сөйли иде ул… Бәндәбикә әбисе бер килсә, Атасалда атналар буе яшәп китә иде. Ул монда килгәч, үзе дә балага әйләнә, туган туфрагы, Карагайлы сулары аны яшьлегенә кайтара иде…

Яңгыр шәп кенә явып торса да, юл артык чыланмаган, Шүлгән тавының ком катыш ак ташлары барысын да сеңдерә генә барган… Менә алар машина белән аның биек сыртына да менеп җиттеләр, мәгарәләре, елга-күлләре белән саубуллашып, таудан түбән дә төшеп киттеләр… Аннан биек-биек Мәчем, Бәзәл тауларын кисеп үттеләр… Шулай итеп, килгән юлдан кайтырга чыктылар… Малай каерылып-каерылып Шүлгәнташ мәгарәсе калган якка карады. Яңгырдан соң үзәнлек җирләрдә, ап-ак булып, тау арасыннан күккә томан баганалары күтәрелеп килә, әйтерсең лә кичәге алып кешеләр Әтилне озата чыкканнар, озата киләләр… Юк, төнлә белән күрде аларны Әтил, үз күзләре белән күрде! Сүзләрен дә ишетте, хәзер төгәл итеп кабатлый гына алмый… Тимертауда күргән төшләрендәге кебек, болар да дөнья бетү турында сөйләделәр… Ата салы турында әйттеләр… Шул салга утырган яхшы кешеләр генә исән калачак, икенче йортка күчәчәк, диделәр… Әмма Ата салының кайда сакланганын әйтмәделәр…

— Нигә бик уйга калдың, улым? — дип сорады Җиһангир карт, оныгының моңаеп барганын күреп.— Ничек, ошадымы соң Шүлгәнташ? Гыйбрәт алырлык нәрсәләр бар анда, бар…

Әтил әллә бабасына дөресен әйтсенме икән? Барыбер аңа әйтмичә чыдый алмый инде ул.

— Бабай, мин төшемдә алыпларны күрдем,— диде Әтил, «өнемдә күрдем» дияргә уңайсызланып.— Алар Агыйдел буен тутырып киләләр иде… Үзләре шундый озыннар, әнә шул карагайлар тикле! Башлары зу-ур, ай кебек якты һәм түгәрәк… Йөзләреннән нур сирпелеп тора…

— Син төшеңдә фәрештәләрне күргәнгә охшаган,— диде бабасы, бик җитди тыңлап.— Алар шундый нурлы йөзле булалар, теләсә кем кыяфәтенә керә алалар…

— Алар дога кылдылар… Моннан 15 мең ел элек шушы мәгарәдә яшәгән алыплар өчен дә, безнең өчен дә…

Әтил туктап калды. Әллә бабасына дөресен әйтсенме? Төштә түгел, өндә күрде бит ул аларны. Алар белән әле яңадан мәгарәгә дә барды, ни сөйләшкәннәрен тыңлап торды… Әтил алыпларның, тау ярып, күккә ашканнарын да күрде…

— Син, чыннан да, төшеңдә фәрештәләрне күргәнсең, улым,— диде бабасы, уйланып.— Безнең якта аларны «Яхшылар» дип йөртәләр, изгеләр, димәк… Кайбер кешеләр, аларны өндә дә күрдек, дип сөйлиләр… Кем белә, Аллаһның кодрәте киң, теләгән кешесенә әллә нәрсәләр күрсәтә ала…

— Бабай, мин дә аларны чынлап күрдем бит! — дип кычкырып җибәрүен Әтил сизми дә калды.— Мин аларны өнемдә күрдем бит! Тавышларын, сүзләрен дә ишеттем! Алар артыннан әле Шүлгәнташка да бардым…

Әтил, тәртелеп, туктап калды. Ничек йоклаган җиреннән Шүлгәнташка барсын икән соң ул? Бабасы уятканда, ул бит палаткада йоклап ята иде… Әтил инде үзе дә буталып бетте: төшендә күрдеме ул алыпларны әллә өнендә күрдеме?

— Анысы, чыннан да, төш иде, ахры,— дип дәвам итте ул, aклaнгандай.— Хәзер инде үзем дә буталып беттем… Әмма алар да дөнья бетү турында сөйләделәр, бабай… Салга утырып, бик азлар гына котылып калыр, диделәр…

Җиһангир карт машинасын әкренәйтә төште. «Бу балага соңгы вакытта мондый хәвефле төшләр күп керә башлады»,— дип борчылып уйлады ул… Югыйсә аның бит әле берни турында уйламыйча, гамьсезләнеп уйнап йөрер чагы… Ә ул әнә нәрсәләр турында уйлана, бик тирәнгә, бик еракка карый… Иртә бит әле, бик иртә аңа үлем турында, дөньяның бетүе турында уйларга…

Бабасының дәшмәвен Әтил үзенчә юрады. Ышанып бетми иде, ахры, аңа бабасы, тагы саташкан, дип уйлыйдыр… Әтил үзе дә буталып бетте бит, кайда — төш, кайда — өн, үзе дә белми хәзер… Ә Шүлгәнтауның түбәсе барыбер ярылган…

— Ышанам, улым, нигә ышанмаска,— диде бабасы, аның уйларын аңлагандай.— Төштә дә булырга мөмкин, өндә дә булырга мөмкин… Дөньяның кайчан бетәсен бер Аллаһы Тәгалә генә белә, улым… Шуның өчен һәркөн бу дөньяга куанып, Аллаһка рәхмәтләр әйтеп, мәгънә белән яшәргә кирәк… Менә укы, дөнья гиз, динне өйрән, Аллаһ кушканча яшә — бик күп сорауларыңа үзең үк җавап табарсың… Миннән дә күп белерсең, иншаллаһ! Мәгънә белән яшәргә кирәк, улым, мәгънә белән…

— Әйе, бабай, алар да шулай диделәр:

**Атабыз салын эзләр меңәрләр, табар берәүләр, мәгънә белгәннәр,**
**Раббым, дигәннәр…**
**Шулар котылыр яңа туфаннан, әмма җир инде яшәрлек булмас…**
**Ата салына кереп изгеләр күчәр бу йорттан икенче йортка…**

**Безнең тарафка — мәңгелек яшәү, мәңгелек җәннәт, бәхет иленә…**

— Бу нинди шигырь, улым? — диде Җиһангир карт, сискәнеп китеп.

— Бу шигырь түгел, бабай, моны а л а р сөйләде… Әле аның башы да бар иде, ахыры да, бераз оныттым…

Җиһангир карт шунда гына оныгының саташмавын, бик җитди нәрсәләр турында сөйләвен аңлап алды. Юк, мондый сүзләрне, мондый нәрсәне бала акылы гына уйлап чыгара алмый. Ул бит бу әйберләр турында белми дә иде, кайдан белсен ул туфан булганын, дөньяны су басканын, Нух пәйгамбәр көймәсен… Һәм кайдан белсен ул кайчан да булса бер дөнья бетәсен? Заман ахырында изге җаннарның гына икенче йортка — җәннәткә күчәсен? Һәм шуны шигырь рәвешенә салып, җан тетрәндерерлек итеп, ничек сөйли белсен 13 яшьлек бала?! Димәк, төшләре аша булса да, ул хаклыкны белә, дөреслекне күрә?

— Тик син бу турыда әнигә дә, әбигә дә сөйләмә, яме, бабай? — диде Әтил.— Алар барыбер ышанмаслар, көләрләр генә…

— Ярар, улым, бу безнең ике арадагы сер булып калыр,—диде Җиһангир карт, сүзне бераз җиңеләйтәсе килеп.— Алай да, алыплар турында Бәндәбикә әбиеңнән сора әле син, ул бик күп белә андый хәлләрне.

Әйе шул, Бәндәбикә әбисе аңа теге вакытта Атасалда, Алып бабай чабатасын каккан урын, дип, ниндидер таулар, калкулыклар да күрсәтеп йөргән иде… Хәзер Әтил моны онытты инде, ул чагында кечкенәрәк булган бит, аңлап та бетмәгән… Бәндәбикә әбисе белә дә белә инде алыплар турында!

Юл тагы биек-биек таулар арасыннан, Агыйдел елгасы белән узышып, инде югарыга күтәрелә башлады… Әтил бик-бик борынгы заманнарны күз алдына китерергә тырышып карады. Менә бөтен-бөтен дөньяны су басты, ди… Бу Урал таулары барысы да су астына күмелеп калган… Би-ик еракта, күгәреп, ике өркәчле тау түбәсе күренеп тора… Ул, әлбәттә, Ямантау инде, Әтил төшләрендә күргән Ямантау… Ата салы да шунда туктады… Димәк, Нух пәйгамбәр көймәсе дә шунда…

— Бабай, бу Ямантау бигрәк сәер инде,— диде ул, бераз уйланып баргач.— Түбәсе ике өркәчле, нәкъ дөянеке кебек… Мин аны төшемдә гел шулай күрәм. Юк, өркәч тә түгел ул… үзе көймәгә охшаган — олы галош кебек…

Шулай диде дә Әтил көлеп җибәрде. Шундый дәһшәтле тау түбәсен галошка охшатуы үзенә дә кызык тоелды. Тик Җиһангир карт кына көлмәде, киресенчә, ул бу чагыштырудан сискәнеп куйды.

— Ә ул тау, чыннан да, зур галошка охшаган бит, улым,— диде ул, оныгының хак дөреслекне күрүенә тетрәнеп.— Мин бик яхшы хәтерлим ул тауны… Җанбикә әбиең дә бик яхшы белә…

— Ә әби кайдан белә?

Бу юлы инде Әтил гаҗәпләнде.

— Ник, мин сиңа әйтмәдеммени — әбиең шул Ямантаудан ерак булмаган Кушъелга авылыннан бит… Мин аны шул скважина бораулап йөргән җиремнән җитәкләп алып кайткан идем… Ул вакытта анда авыллар гына иде әле… Ахрысы, шул тирәдән уран табылды, безгә дә барысын да ачып бетермәделәр, менә шуннан соң анда кереп-чыгып йөрү бетте инде… Бикләп куйдылар да, меңәрләгән тоткын китертеп, шәһәр сала башладылар… Җир астында, җир өстендә — заводлары, атом реакторлары, тагы әллә нинди яшерен урыннар… Зонага әйләнде Кушъелга, зонага… Шул исәптән синең Ямантавың да…

Әтил телсез калып утыра иде. Аның Җанбикә әбисе — Ямантау яныннан?! Ямантауның үзеннән? Ничек Әтил бу хакта башта ук белмәде икән соң, кичә үк әбисеннән күпме нәрсә сораган булыр иде! Аксуга тизрәк кайтып җитсә, ул әбисеннән Ямантау турында җентекләп-җентекләп сораячак. Бәләкәй чагында аның ул тау башына менгәне булдымы икән? Анда нәрсәләр күрде икән? Ул Ямантау якыннан нинди икән? Анда тау куышлары бармы икән? Әбисе аларны күрдеме икән? Менә нәрсәләр сораячак ул әбисеннән!

— Бабай, ул авыл исәнме соң әле? — дип сорады Әтил, кызыксынуына түзә алмыйча.

— Әйткәнемчә, Кушъелгага кушып, атом шәһәре салдылар, улым,— диде Җиһангир карт.— Авылны бар дисәң дә ярый, юк дисәң дә ярый… Шәһәр белән кушылып беткән инде ул… Халкы да килгәннәр белән кушылып, аралашып беткән, татары-урысы бергә…

— Ә анда әбинең берәр кешесе калдымы соң?

— Әти-әнисе бик күптән үлде инде, без күмәргә дә керә алмадык… Атомның иң серле, иң яшерен заманы иде ул, аны дәүләт сере итеп саклыйлар иде… Ураны, атомы, бомбасы — бөтенесе бик яшерен иде, әле хәзер дә яшерен, анда чит кешеләрне кертмиләр… Туганнары бар да диярлек үлеп бетте шунда, Кушъелгага атом белән бергә үлем дә керде… Анда кеше тиз үлә, улым, ул чыннан да бик куркыныч, яман урынга әйләнде… Атом радиация белән бәйләнгән, ә радиация ракка китерә… Шуңа күрә, әбиеңнең туган җире булса да, бер аннан чыгып киткәч, без инде анда яңадан кермәдек… Ул

чагында ук сизенә идек инде анда куркыныч икәнен — 40—50 яшьлек кешеләр тәгәрәп үлгәч… Җанбикә әбиең бик сагына иде Кушъелганы, Ямантауны сагына иде… Сагынуына түзә алмыйча, берничә тапкыр кайтып, зонага керә алмыйча борылып та киттек… Анда хәрби тәртип, улым, автоматлар белән торалар… Шуннан соң әбиең башка, кайтыйк, дип әйтмәде инде… Кайтырга якыннары да калмады бит…

— Өе дә юкмы?

— Өйләре дә юк, аның урынында тоткыннар өчен төрмә, диделәр… Үлемгә хөкем ителгәннәрне шул атомда эшләтәләр бит… Шунда күмелеп кала да инде алар… Анысы да анысы, менә үлгәч үзен Кушъелга зиратына күмдерергә васыять итте бит әле әбиең… Әтиең белән Түлгән абыең монда булса, моны ерып чыгарга булыр иде, ә хәзер, ай-һай… Андый-мондый мин теге дөньяга әбиеңнән алдарак китеп барсам, сез моны белеп торырга тиеш, улым… Әйтеп калдырырга башка кеше юк, үзең беләсең…

Әтилгә, никтер, бик моңсу булып китте… Туган авылы капкасына килеп, керә алмыйча борылып киткән әбисен өзелеп кызганды ул, атом базына әйләнгән Ямантауны уйлап кайгырды, нәни йөрәген моңа кадәр булмаган олы сагыш басып китте… «Нигә алай соң? — дип уйлады ул.— Нигә кеше хәтта үз авылына да керә алмый? Нигә табигатьнең иң матур җирләрен үлем базына әйләндерәләр? Нигә ул авылларга, тауларга, елгаларга Җанбикә әбиләре, Җиһангир бабалары хуҗа түгел, бу бит аларның туган җирләре… Нигә?»

Каршыда, күгәреп, гаҗәеп зур тау күренде. Ул бу тирәдәге тауларның иң биеге иде, ахрысы, түбәсе болытлар арасына ук кереп киткән… Әтил гаҗәпләнеп як-ягына каранды. Бу тирә, гомумән, биек-биек таулар, таш кыялар, берсе бетеп, икенчесе башланган тау сыртлары белән әйләндереп алынган иде. Һәм шулар арасында, тар гына үзәнлек табып, Агыйдел елгасы агып ята… Биек тауларга сыенып, үзен чорнап алган урманнарны кысрыклап, Агыйдел елгасы буенда бер авыл утыра… Тукта, алар бу авылны үтеп киткәннәр иде бит инде! Бәндәбикә әбисе яшәгән Каһарман авылы бит бу!

— Менә Каһарман авылына да җиттек,— диде бабасы, аның уйларын җөпләгәндәй.— Бәндәбикә әбиең янына кереп, хәл белеп чыгыйк…

Яңгыр шактый чылаткан юл буйлап авылга керә башладылар. Бу авыл шактый таркау кебек тоелды Әтилгә. Атасалдагы кебек, тигез, рәт-рәт тезелеп киткән урамнар да күренми, монда өйләр дә башка төрле урнашканнар… Үзенә күрә бер түгәрәк ясап, оя-оя, күч-күч булып утырганнар… Хәер, Атасалда да андый оялы очлар бар иде, авылның борынгы өлеше шулай түгәрәкләп төзелгән иде… Ә яңалары инде гомум тәртип буенча, авыл советы кушканча төзелгән… Мондый түгәрәк йортларны Әтил әле Аркаимда да күрде, әмма анда агач түгел, таш, борынгы кирпеч йортлар иде…

Бабасы кайда барганын белеп бара, ахры, тар тыкрыкларның әле берсенә, әле икенчесенә чума, аннан тагы алга ыргыла…

— Бу — чын типтәр авылы, улым,— дип аңлата барды ул гаҗәпләнеп утырган Әтилгә.— Монда йортлар шулай, бер-берләренә терәп, оя-оя салына… Атасалда бит анда мишәре, типтәре — бөтен татар бергә… Анда бераз башкачарак — мишәр тәртибе белән яшиләр… Бәндәбикә әбиең, бирегә килен булып төшкәч, тиз генә ияләнеп тә китә алмады… Әмма үз өенә барыбер татар-мишәр тәртибен кертте… Менә күрерсең әле…

Бабасы машинасы белән чираттагы тар тыкрыкны йөзеп чыкты да алдына ак таш җәелгән зур агач йорт янына килеп туктады. Йортның капка-коймалары бизәкләп эшләнгән, төрле төсләргә буялган, ялт итеп тора иде. Ә өе, өе инде! Әкиятләрдәге тылсымлы тирмә диярсең: сап-сары нарат бүрәнәләр, бизәкләп, челтәрләп эшләнгән тәрәзә рамнары, икенче катта — челтәрле чардак, өй түбәсендә чит-читләре бизәкләп киселгән кызыл калай… Дөрестән дә, Бәндәбикә әбиләрнең өе тирә-юньдәге бөтен өйләрдән үзенең матурлыгы, татарлыгы, рухы белән аерылып тора иде… Әтилнең ерак әбисе Бәндәбикә карчык, әкиятче әби, патшабикәдәй затлы татар хатыны нәкъ менә шундый йортта, нәкъ менә шулай яшәргә тиеш иде…

Машинаны капка төбендә калдырып, йортка — ишегалдына керделәр… Монда килеп кергәч, Әтил тагы бер тапкыр аптырашта калды. Бу — ул күреп өйрәнгән авыл ишегалды түгел иде… Монда мал абзарлары да, мал-туар эзе дә күренми, киресенчә, ишегалды җимеш бакчасына, аллы-гөлле чәчәкләргә күмелгән иде… Капкадан өйгә хәтле әнә шул җәннәт бакчасыннан барасың… Ишегалдында эт-мазар да, хәтта тавык-чебеш тә күренми…

— Алар барысы да өйнең артында — бәрәңге бакчасы ягында,— дип аңлатты бу хәлне Җиһангир карт.— Мал-туар башка юлдан, башка капкадан йөри монда, абзар-кура да йорттан читтә… Элек Атасалда безнең дә шулайрак иде, соңыннан абзар-кура, мал-туар бөтенләй калмады…

Ул арада болдыр ишеге ачылып китте һәм анда әкияттәге ак әби кебек Бәндәбикә карчык күренде. Әтилнең аны инде әллә ничә ел күргәне юк иде, шуңа күрә башта бераз ятсынгандай басып торды. Әмма Бәндәбикә карчык аны бик тиз танып алды, кояштай балкып, үзе Әтил каршына ашыкты.

— Әтил улым түгелме соң бу? — диде ул, гөлдерәп торган күкрәк тавышы белән.— Менә бит нинди кадерле кунак килгән безгә! Ай, рәхмәт, Җиһангир канәт, кемне алып килгәнсең бит! Әйдәгез, әйдәгез, узыгыз…

Бәндәбикә карчык Әтилне кочагына алды, ул арада Җиһангир карт белән дә күрешергә өлгерде. Шулай гөр килеп, өйгә керделәр. Өйнең тышы гына түгел, эче дә бөтенләй башка төрле, авыл өйләренә охшамаган иде. Әтил карап, санап барды — өйнең үзенә кереп җиткәнче дә алар әллә ничә болдыр, әллә ничә бүлмә үттеләр, аларны ишек арты саен яңа ишек көтеп тора иде… Бәндәбикә әбисе биредә төпчек улы һәм килене белән яши икән, инде алар да пенсия яшенә җитеп киләләр, әбинең үзе белән бергә картаеп баралар… Калган балалар, оныклар исә кайсы-кая таралып беткәннәр, тау арасындагы бер ялгыз авылда кем калсын хәзер? Шул карт-коры инде…

— Синекеләр кайда соң әле, күренмиләр? — дип сорады Җиһангир карт, Бәндәбикә карчыкның улы белән киленен күздә тотып.

— Сөбханкулга киткәннәр иде, матай белән генә… Пенсия документларын әзерләп йөриләр бит… Больницага да, балалар янына да кереп чыгасы бар, диделәр… Районга баргач, эш бетәмени инде ул… Болай булса әле кичсез кайтмаслар да…

Чәчәкле пәрдә эленгән бер ишек артында кыштырдаган тавыш ишетелгәндәй булды, идән тактасы шыгырдап куйды.

— Оныклар мондамы әллә? — дип сорады Җиһангир карт, ишек ягына ымлап.

— Юк, Сөнгатулла ул, ялга кайткан иде,— диде Бәндәбикә карчык, никтер борчылган кыяфәттә.— Авырып тора шул бераз…

Ул арада ишектә Сөнгатулла үзе дә күренде. Ул, чыннан да, сулган ап-ак йөзле, күз төпләре шешмәкләнеп, күгәреп тора, озын гәүдәсе җайсыз сыгылып килгән кебек иде… Җиһангир карт шунда ук аның каршына үзе ашыкты.

— И Сөнгатулла энекәш, сине күрмәгәнгә дә ничә еллар бит инде! — дип, ул Сөнгатулланың ябык гәүдәсен кочып алды.— Ялга кайттыңмы?

Сөнгатулла, зурлап, аларның икесе белән дә ике куллап күрешеп чыкты. Бәндәбикә карчык чәй әзерләргә китте, ирләр үзара сөйләшеп калдылар.

Сөнгатулла Бәндәбикә карчыкның төпчек улы, төп йортта яшәүче Рәхмәтулланың игезәк туганы иде. Әтилнең аны бер генә тапкыр күргәне булды — ул Бәндәбикә карчыкны алырга Атасалга килгән иде. Ул вакытта әле ул бөтенләй башка төрле иде, чәчләре дә болай агарып, коелып бетмәгән, гәүдәсе дә төз, туры, гайрәтле иде… Нәрсә булган соң аңа — шулхәтле бетеренерлек?

Җиһангир картның да Сөнгатулланы бу кыяфәттә беренче тапкыр күрүе иде. Дөрес, алар күрешүен дә сирәк күрешәләр хәзер. Сөнгатулла ябык атом шәһәрендә — Таулыда яши, шунда эшли, гаиләсе, тормышы шунда… Соңгы елларда Җиһангир картның үз кайгысы кайгы булды: башта Туран армиядә юкка чыкты, аннан Түлгән суга салган кебек юк булды… Карчыгы Җанбикә шушы хәлләрдән соң еш кына авырый башлады… Туганнар белән аралашырга, хәл белешергә вакыт та калмады… Элек Атасал белән Каһарман арасында атка утырып та бер-берләренә йөрешергә вакыт табалар иде, хәзер, кулда машина була торып та, сирәк күрешәләр… Дөрес, ул апасы Бәндәбикә янына килгәләп йөри, ә менә Сөнгатулланы шактыйдан күргәне юк икән инде… Ә ул әнә ниндидер зәхмәттән бөгелгән дә төшкән… Яман чир генә була күрмәсен, Ямантау тирәсендә яшәүчеләрнең күбесендә шул бит…

— Отпускадамы соң, болай гына кайттыңмы? — дип сорады Җиһангир карт, энесенең авыруы турында төпченергә уңайсызланып.— Әле пенсиягә чыкмагансыңдыр, берничә елың бар кебек хәтердә калган?

— Инвалидность бирделәр миңа, абый,— диде Сөнгатулла, читкә-чатка кереп тормыйча.— 2 нче группа гарип мин хәзер…

— Нәрсә, шулай җитдимени? — дип сорады Җиһангир, сагая төшеп.

Сөнгатула кухня ягына карап куйды. Ул әнисенең бу сөйләшүне ишетүен теләми иде. Абыйсы сорагач, ир кешедән яшерә дә алмады.

— Нурланыш авыруы миндә, абый,— диде ул, тавышын әкренәйтә төшеп.— Шул радиация нәтиҗәсе, атом зәхмәте инде… Әни карчыкка моны әйтеп борчыйсы килми, эчкән дарулардан нидер сизенә бугай инде… Анда, Таулыда, атом арасында үлем көтеп ятып та булмый… Менә кайттым әле… Үз аягымда вакытта, җәен әни карчык янында бераз торып китим, дидем… Монда кайткач әле, бераз терелеп киткән кебек тә булдым… Тау һавасы, Агыйдел сулары килеште, ахры… Әни карчык та йөз төрле үлән, йөз төрле чишмә суы эчертә… Терек суын гына эчеп карыйсы калды инде…

Ул хәлсез генә көлеп куйган кебек булды. Әмма аның көлүе дә ютәлләгән тавышка охшаган иде, йөзендә газаплы, гаепле елмаю катып калды. Мондый хәлне күреп, Әтилнең коты чыкты. Ул, Сөнгатулла абыйсын кызганудан елап җибәрмәс өчен, тизрәк әбисе янына чыгып китте. Ирләр, башларын иеп, үзләре генә утырып калдылар.

— Гаиләң ничек соң, хатының ни ди? — дип сорады Җиһангир карт, бугазына утырган яшьле төерне әкрен генә эчкә йотып.— Ярдәмнәре бармы бераз?

— И абый, минем гаиләне беләсең бит инде,— диде Сөнгатулла, хәлсез генә кулын селтәп.— Хатын, атом казанында янып үлсә дә, шул Таулыга ябышкан инде ул, кубарып алып булмый… Үзең беләсең, мин солдат хезмәтеннән шунда калдым бит… Башта яшьлек белән аңланмаган — нинди җәһәннәмдә яшәвебезне… Аны бит элек бик әйтмиләр дә иде, нәтиҗәсе нинди буласын… Квартира, акча белән кызыктырдылар… Халыкның чебен урынына кырыла башлавын күргәч, аңлый башладык эшнең нәрсәдә икәнен, анда инде гаилә, балалар ишәйгән иде… Кая барасың?.. Алай да мин хатынга гел әйтә килдем, әйдә, исән чакта китик моннан, бер авылга булса да кайтып урнашыйк, ятмыйк монда радиация арасында үлем көтеп, дидем… Ризалашмады… Анда, үзең беләсең, акча күп, квартира яхшы, эш бар… Хатын шуларның тәмен белеп алды, шул байлыгыннан аерылмас өчен, тәмугта яшәргә дә риза… Тик менә мин беттем инде, бетеп киләм, абый…

Әйе, яхшы хәтерли Җиһангир карт Сөнгатулланың хатынын. Авызаннан ут чәчеп торган бу керәшен хатынын җиңә алмады Сөнгатулла. Балаларын да үзенчә ертлач итеп тәрбияләде ул хатын, алар тормыштан умырып алу өчен генә яшиләр иде. Нәтиҗәдә, кызы урыска кияүгә чыкты, малае йортка марҗа җитәкләп кайтты. Аларга инде үлем җиле кагылган Сөнгатулла татар нигә кирәк тә, аның мәшәкате нәрсәгә? Дөрес, аларның да яшерен борчулары бар — берсенең дә балалары юк. Һәм беркайчан булмаячак та, дигәннәр врачлар. Радиация, атом афәте ул шулай бөтен нәселеңне, милләтеңне, илеңне корыта… Әле моны аңлап кына бетермиләр кешеләр… Хәер, мондый нәселнең, бәлки, булганнан булмавы хәерлерәктер…

Һәм менә Сөнгатулла, ике метрлы көрәшче ир, чирнең нәрсә икәнен дә белмәгән гайрәтле пәһлеван, кибеп-корып, үләргә дип, туган туфрагына кайтып егылган… Торган йорт та калган, керәшен хатын, марҗа килен-кияүләр дә, манкорт балалар да шул атом шәһәрендә утырып калган… Ул, татар ире, бер ялгызы туган тауларына кайтып егылган, ауса да, алар кочагына аварга уйлаган…

— Монда… ничек соң… килен кырын карамыймы? — дип сорады Җиһангир карт, Рәхмәтулланың хатынын күздә тотып.

— Юк, абый, монда әни хуҗа бит,— диде Сөнгатулла, елмаерга тырышып.— Аның сүзеннән монда беркем чыкмый. Рәхмәтулла белән Рәхимә үзләре дә бик әйбәтләр, әни кулдан ычкындырмаган аларны… Әле ярый алар бар, абый… Туганнарның кирәген олыгайган көндә, менә шундый хәлгә калгач кына беләсең икән аны…

Шушы сүзләрне сөйләгән арада да Сөнгатулла тәмам арып, тирләп чыкты. Ул гыж-гыж сулый башлады, тыны кысылды, хәле бетте. Җиһангир карт кухня ягына чыгып, тиз генә су алып килде, аны бер-ике тапкыр йотып куйгач, Сөнгатуллага хәл кереп киткән кебек булды. Ул, үз бүлмәсенә кереп, даруларын эчеп куйды, аннан әкрен генә урынына барып ятты. Җиһангир карт та аның янына кереп утырды, бу хәлендә ул аны ташлап чыгып китәргә яхшысынмады.

— Бабай, чәй әзер, әби чәй эчәргә чакыра! — дип, залга йөгереп кергән Әтил аларны анда очратмады, колагына күрше бүлмәдән әкрен генә сөйләшкән сүзләр ишетелде. Бу сүзләрдән ул идәнгә кадаклап куйган кебек катып калды. Сөнгатулла абыйсы… Әтилнең әтисе турында сөйли иде! Ирексездән Әтил аларның сөйләшкәннәренә шаһит булды.

— Шактыйдан үзем белән йөртә торган бер шигем бар — Туран турында,— дип башлады ул сүзен.— Ышансаң, ышанмасаң, сөйләп каласым килә… Үзең беләсең, без, атомчылар, җир астында эшлибез, безнең бөтен тормыш шунда… Авыз-борын капланган, баш капланган, ие… өстә — ак халат, аякта — махсус чүәкләр… Анда безнең белән заключенныйлар да эшли иде, токтыннар… Алар тагы да куркыныч урында, иң пычрак, радиацияле участокта… Кыскасы, аларны күрәләтә үлемгә керткәннәр инде, үзең беләсең… Без әле төнлә җир өстенә — өйләребезгә чыгабыз, ә алар гел шунда… Танытмас өченме, рәвешенә туры китерепме, аларга да махсус битлекләр кидергән булганнар, күзләреннән кала, бөтен җирләре капланган, ие… Менә шул токтыннар арасында килеш-кыяфәте белән безнең Туранга охшаган бер кешене очраттым мин, абый… Үзең беләсең, анда сөйләшергә ярамый, алар рәт булып үз участокларына үтеп китә, без үз урыннарыбызга барып басабыз… Бу безнең турыдан үтеп киткәндә, төбәлеп, гел миңа карый, мин дә, нигәдер, аңа карыйм, нәрсәдер тарта, ие… Башта мин моның гәүдәсенә игътибар иттем — безнең нәселдә генә булган зур, ике метрлы буй, алыптай төз сын моның… Шуны күргәч, әллә нишләп киттем, икенче көнне тагы да сынабрак күзләренә карадым. Ышанасыңмы, Җиһангир абый, ак битлек астыннан миңа томырылып Туранның күзләре карап тора

иде… Зур яшькелт-зәңгәр күзләр… Бу бит — безнең нәселнең күзләре — әнидә шундый, синдә шундый, миндә шундый яшькелт-зәңгәр күзләр… Моны күргәч, үземне ток туткандай, яшен суккандай булды… Икенче көнне тагы карыйм моңа — шул инде, безнең нәсел күзләре — карчыгадай үткен, диңгездәй тирән күзләр, алыптай зур гәүдә… Битлек астыннан әле нәрсәдер пышылдаган да кебек булды… Аннан аларны әллә башка урынга күчерделәр — башка күрмәдем мин аны… Аннан үзем дә кисәк кенә авырып киттем, җир астына бүтән төшмәдем… Әмма бүгенге көнгә хәтле хәтеремдә аның күзләре… Туран күзләре…

Әтил, кычкырып җибәрмәс өчен, йодрыгын авызына тыкты. Ул хәтта тын алырга да курыкты, тын алса да, сулкылдап елап җибәрер кебек тоелды. Аның этисе — җир астында?! Ямантау астындагы атом шәһәрендә?.. Бу хакта Җанбикә әбисе дә сөйләгән иде бит мәрттән уянгач, атаң таулар арасында, җир астында, аяк-куллары богауда, дигән иде… Димәк, ул дөрес әйткән…

— Анда… нинди тоткыннар эшли соң? Бераз сораштырдыңмы? — дип сорады Җиһангир карт, бу хәлләргә ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

— Сораштырдым, абый, сораштырдым… Гомер буе эшләгәч, анда белгән кешеләр күп бит инде минем… Чечнядан китерелгән тоткыннар, диделәр… Араларында төрле милләт кешеләре бар икән, татарлар да бар, диделәр… Аларны бит анда да гел аерым тоталар, номерлап кына йөртәләр, алар безнең халык белән бөтенләй аралашмый… Сакчылары да үзләре арасыннан — җиңелрәккә хөкем ителгәннәр… Аннан авырып киттем дә ул тирәдә бүтән йөрмәдем… Бәлки әле ул да булмагандыр, миңа гына шулай тоелгандыр… Әмма бу хакта сиңа сөйләп калдырыйм, дидем…

Җиһангир картның йөрәге чәнчеп куйды. Чечнядан кайтарылганнар! Туран да шунда юкка чыкты бит… Кайтырына ничә ай калгач, юкка чыкты… Алар Туранны бөтен дөнья буйлап эзләтәләр, әллә чеченнарда әсирлектә ятамы икән, дип тә уйладылар, ә ул Аксудан ерак түгел, җир астындагы атом шәһәрендә тоткын булып ята микәнни? Була торган хәлме бу?! Мөмкин эшме? Бу Сөнгатулланың авырып саташуы гына түгелме, көчле даруларның тәэсире аркасында түгелме икән?

Карт ни диярга дә белмәде, әмма Сөнгатулланың сөйләгәннәре бәгыренә уелып калды. Ул үзе белгән юллар аша, бу хәбәрне тикшертеп карарга булды. Чөнки бу илдән, бу кешеләрдән, бу хакимияттән бөтенесен көтәргә була иде…

Кухня яктан Бәндәбикә карчыкның патшабикәдәй көчле тавышы ишетелде:

— Әйтеп-әйтеп тә, нигә чәйгә чыкмыйсыз анда?! — дип гөрелдәде ул, өйне тутырып.

Барысы да аның әмеренә буйсынып, чәй янына чыктылар. Бәндәбикә карчык ике әйтергә яратмый, бу йортта аның сүзен ишетү белән үтәргә кирәк иде. Сиксәннән үтеп китсә дә, карчык ялт итеп өстәл әзерләп ташлаган, суыткычыннан, чоланыннан бөтен тәмле-томлысын чыгарып куйган, ашын җылыткан, чәен кайнатып чыгарган иде. Ирләр, тыңлаучан малайлар кебек, өстәл янына тезелешеп утырдылар. Карчык аларны үз куллары белән сыйлый башлады.

— Балалардан берәр хәбәр бармы соң, Җиһангир? — дип сорап куйды ул сүз арасында.

Барысы да тынып калдылар. Бигрәк тә Әтилгә авыр иде, ул, елап җибәрмәс өчен, башын тизрәк чәй тәлинкәсе өстенә иде. Ерак әбисе моны шунда ук сизде, зур, кытыршы куллары белән Әтилнең чәчләреннән сыйпап куйды.

— Бер хәбәр дә юк шул, дәү апа,— диде Җиһангир карт, Сөнгатулланың сөйләгәннәрен Бәндәбикә карчыкка әйтеп тормыйча.— Эзләтәбез инде, исән булсалар, табылыр дип өмет итәбез… Дөньясы бик болганчык бит хәзер, кеше юкка да чыга, табылып та тора… Безнекеләр дә табылыр, иншаллаһ!

— Шулай, энем, шулай,— диде Бәндәбикә карчык, аларга чәй ясый-ясый.— Бер дә өметне өзәргә ярамый… Егермешәр, утызар ел юкка чыгып торган кешеләр дә табыла, безнекеләр дә табылыр, иншаллаһ! Бу Аллаһтан бер сынау инде, моңа сабыр итәргә кирәк һәм бары тик Аллаһтан сорарга, ярдәм көтәргә инде…

Ул арада капка төбенә мотоцикл кайтып туктаган тавыш ишетелде.

— Кичкә кайтасы кешеләр өйләгә үк кайтып җиттеләрме әллә? — дип, Бәндәбикә карчык ишеккә карады.

Аннан, чыннан да, пәһлевандай зур гәүдәле Рәхмәтулла һәм аның кәтүк хәтле генә хатыны Рәхимә кереп киләләр иде. Өй эче шунда ук шау-шу белән, исәнләшү сүзләреннән тулды, әйтерсең лә, җил һәм яңгыр исләрен таратып, өйгә тормыш үзе томырылып килеп керде. Авыру Сөнгатулла янында игезәк туганы Рәхмәтулла каһарман булып күренә иде, алтмышка җитеп килсә дә, ул әле егетләр кебек нык һәм гайрәтле иде…

— Тиз тоттыгыз сез,— диде Бәндәбикә карчык, алар өстәл янына урнашып беткәч.— Хәер, кайтуыгыз бик яхшы булды әле, менә Җиһангир абыегызны, Әтилне күреп өлгердегез. Бу кечкенә Туранны ничә ел күргән юк иде инде, ә? Бу инде хәзер этисен дә узып бара, урамда күрсәң, танымассың да үзен. Егет, безнең нәсел каһарманы!

Туганнары да, яратып, якын итеп, аның аркасыннан кактылар, башыннан сыйпадылар. Әтилгә бу эчкерсез, гади, көчле кешеләр арасында тыныч, рәхәт булып китте… Ул ялгыз түгел иде… Әтил бу дөньяда үзе өчен өзелеп торган туганнары барлыгын белде, алар аңа үз әтисен хәтерләттеләр, бер мизгелгә аны алыштыргандай булдылар… Ул, беразга булса да, үз кайгысын, әтисе хәсрәтен онытып торган кебек булды. Бабасы да, әнә инде бераз тынычланып, онытылып, чәй эчә, тик чынаяк тоткан кулы гына бераз калтырый, чәе чайпалып-чайпалып китә иде…

Чәй эчеп бетергәч, Сөнгатулла белән Әтилдән кала барысы да өйлә намазына әзерләнә башладылар. Әтил юынып чыкач кына намаз укый, шуңа күрә бу тәне белән олылар янына барып басуны дөрес дип тапмады. Аның күңеле дә тынычсыз иде, шуңа күрә ул тизрәк Сөнгатулла абыйсы артыннан ишегалдына чыгып китте. Сөнгатула абыйсының тәрәзә каршындагы кечкенә бакчада үзенең урыны бар икән, астына җылы киез салып, ул инде шунда чыгып утырган. Яңгыр инде туктаган, ялт итеп кояш чыккан, көнне тагы кыздыра башлаган иде. Әтил дә аның янына килеп утырды. Сөнгатулла абыйсы арык куллары белән аны үзенә якынрак тартты.

— Сөнгатулла абый, мин синең әти турында бабайга сөйләгәннәреңне ишеттем бит,— диде Әтил шыпырт кына.— Чынлап та әти булдымы икән соң ул? Әти булса, нигә бер сүз дә әйтмәде икән?

Сөнгатулла бу хакта бала кешенең белүен теләми иде —нигә аның яшь йөрәген яраларга? Әле ул үзе дә төгәл генә белми бит: әллә Туран булды ул, әллә юк… Шуңа күрә ул малайны тынычландырырга ашыкты.

— Үзем дә бик икеле-микеле шул, энем, һич өздереп әйтә алмыйм,— диде ул, төгәл җаваптан читкәрәк качып.— Атаң булса, чыннан да, бер-бер хәбәр бирер иде ул… Юк, Туран булмагандыр ул… Анда бит бөтен кеше бертөсле, һичкемне аера торган түгел… Мин инде ул вакытта авырый да башлаган идем, башым әйләнеп, күзгә күренүе дә бар… Анда әллә нәрсәләр күзгә күренә, үлем базы бит ул… Син борчылма, энем, әтиең исәндер синең, шул Кавказ тирәсендә булырга тиеш ул… Сугыш вакыты бит, әсирлектә ятуы да бар… Туран болай гына юкка чыга торган егет түгел ул, бөтен нәселебезнең йөзе, горурлыгы иде атаң… Андый кеше мәгънәсез үлемгә бирешми ул, энем…

Әтилнең күңеле әтисе өчен горурлык хисләре белән тулды. Әйе шул, аның әтисе бөтен тирә-якта иң көчле, иң акыллы, иң әйбәт кеше иде… Сөнгатулла абыйсы дөрес әйтә: андый кеше болай гына юкка чыга алмый ул. Һәм Әтил аны барыбер үзе эзләп табачак: Кавказда булса — Кавказдан, Урал тауларында булса — Уралдан, җир астында икән — җир астыннан! Әтисе әйткәндәй, «атасының малае» әле ул, Туран улы Әтил Нухаев! Аңа хәзер җебеп төшәргә дә, елап утырырга да, бирешергә дә ярамый… Әтисе турында кайда нинди мәгълүмат бар — шуны җыярга, Мәскәүгә, Чечняга хатлар язарга, хәрбиләр белән элемтәгә керергә кирәк. Әнисе белән бабасы эшли алмаганны Әтил эшләргә тиеш, һәм ул аны эшләр дә, Алла кушса!

Ул арада намазын тәмамлап, Бәндәбикә карчык ишегалдына чыкты. Чыга-чыгышка Сөнгатуллага әмерләрен бирә дә башлады:

— Улым, Рәхимә киленгә әйт, мунчага газны тоташтырып җибәрсен, Җиһангир абыйларың мунча кереп китәрләр,— диде ул, капчыгына буш шешәләр тутыра-тутыра.— Без Әтил улым белән су буйларын әйләнеп менәбез… Син Коткар чишмәсенең суын эчеп куй, улым, шифасы бар аның, өшкереп тә куйдым әле мин аны…

Карчык, шулай сөйләнә-сөйләнә, капчыгына үзенә кирәк нәрсәләрне тутырды. Ул, гадәттә, су буйларына бер чыгып китсә, аннан шифалы үләннәрен, төрле чишмә суларын, тагы үзе генә белгән әллә нәрсәләр җыеп кайта. Бүген әнә Әтилне дә алып барырга булган бу сәяхәтенә. Әтил өчен моннан да зур бәхет була аламы соң инде? Ул, йөгереп килеп, Бәндәбикә әбисен җитәкләп алды. Нигәдер, бу йортта Бәндәбикә әбисеннән барысы да бераз шүрли, аның сүзе өйдәгеләр өчен генә түгел, тирә-күрше, туганнар өчен дә канун кебек. Чөнки Бәндәбикә карчык әйтсә — хак әйтә, эшләсә — тиешлесен эшли, барысын да гадел хөкем итә. Ә менә Әтилгә карата ул һәрчак йомшак булды. Әтил хәтерли: Бәндәбикә әбисе Атасалда бөтенләй башка төрле иде. Ул үзе дә йомшарып, күңеле белән гел балачакларына китә иде. Әтилгә дә шул заманнар турында күп нәрсәләр сөйли иде… Ә күпме әкиятләр, дөньяда булган куркыныч хәлләр турында сөйләде ул Әтилгә! Бу тирәдәге һәр тауның, һәр чишмәнең, һәр авылның, һәр нәселнең тарихын ул көннәр буе сөйли ала иде. Әтилнең әнисе шуңа күрә, Бәндәбикә әбиең ул — аяклы тарих, дип әйтә торган иде…

Хәзер Бәндәбикә әбисе шактый картайган инде, йөрешләре дә, тын алулары да авырайган, әмма фикере бик йөгерек әле, зиһене ачык, теле чартлап тора.

— Үзем дә бик сагынган идем инде, улым, сине,— диде ул, Әтилнең кулын кысып.— Әниең шул Тимертауга алып китте дә, югалдыгыз… Атасалга кайткалаганыгыз бармы соң?

— Юк, күптән кайткан юк инде,— диде Әтил.— Әни анда кунарга курка хәзер, төрле кеше бар, ди…

— Булмаганны! — Бәндәбикә карчык самавырдай кайнап алды.— Булмаганны! Туган авылда, туган нигездә ни булсын ди?! Атасалда куркырлык кеше бармыни? Анда гомер бакый тыныч булды, ул тау арасына кирәксезгә кош та очып керә алмый бит…

Әтилнең тизрәк әбисенә үзе белгән яңалыкларны җиткерәсе килде.

— Анда хәзер Атасал янынnан алтын эзлиләр бит, әби! — диде ул, зур яңалык әйткәндәй.— Имеш, бик борынгы заманнарда Атасал нәселенең хәзинәсе күмелгән булган ди анда… Бөтен бәрәңге бакчаларын актарып бетергәннәр инде, безнекенә дә кергәннәр, диде әни… Анда хәзер әллә кемнәр йөри, ди, читтән килгәннәр… Имеш, ул тирәдә җир астында бик күп алтын-көмеш бар, ди…

Бәндәбикә карчык аны бүлдермәде, сабыр гына тыңлап бетерде.

— Берсе дә тапмаячак,— диде ул, Әтил сөйләп бетергәч.— Атасал үз серен үз нәселенә генә ачачак… Атаң булса, бәлки тапкан булыр иде… Ә болай — тапмый торулары хәерле…

Шулай сөйләшә-сөйләшә барып, алар шаулап агып яткан тау елгасы янына килеп туктадылар. Күренеп тора, бу елга тыныч, киң Агыйдел түгел, ярсып, ургып агуыннан ук аның башка тау елгасы икәне күренеп тора иде…

— Коткар бу,— диде Бәндәбикә әбисе, яр буена ауган карт өянке янына килеп утырып.— Күрәсеңме, ничек котырынып, котны алып ага ул? Ә-ә-нә күрәсеңме каршыдагы иң биек тауны? Шул Баштаудан башлана бу елга… Алар анда бишәү, авылга җитәрәк бергә кушылалар да Агыйделгә килеп коялар… Иркенрәк килсәң, Рәхмәтулла абыең башланган җиренә дә алып барыр иде… Галәмәт елга ул — кыяның өстеннән баштүбән сикереп ага, барыбер үзенә кирәк юлны таба… Мин бирегә килен булып төшкәч, бабаң белән еш менә идек Баштау башына… Хәзер менә бабаң да юк инде, мин дә анда менә алмыйм… Картайды әбиең, улым, картайды…

Әтил ерак әбисен кызганып куйды. Ул өйдә әби патша кебек кырыс күренсә дә, монда, елга буенда, Әтил каршында картайган, йөзен җыерчык сарган бер карчык утыра иде… Әтил, күңеле нечкәреп, әбисенең тезләренә башын салды. Атасалда шулай Бәндәбикә әбисенең тезләрендә еш йокыга китә иде ул… «Әби, экият сөйлә әле!» — дип, теңкәсенә тия иде дә, әбисе сөйли башлагач, мышкылдап йокыга китә торган иде… Әтил шулчакларны исенә төшерде дә, кечкенә баласыман иркәләнеп: «Әби, экият сөйлә әле!» — диде һәм үз сүзеннән үзе үк көлеп җибәрде. Әтилнең шулай шук тай кебек шаяруы Бәндәбикә карчыкны да үзгәртеп җибәрде, аның да хәтеренә Атасал, Атасалда үткән балачаклары, яшьлеге килеп төште. Әле кайчан гына шушы бала белән җитәкләшеп, Карагайлы буйларында йөрүләрен хәтерләде…

— Мин сөйлисе экиятләрне син күптән беләсеңдер инде, балакаем,— диде ул.— Нәрсә ишетәсең килә — сора, сорап кал, улым, югыйсә без белгәннәр безнең белән китәр инде алар…

«Нәрсә сорыйм икән? — дип уйлап алды Әтил тиз генә.— Алыпларнымы, Туран таулары турындамы әллә Нух пәйгамбәр көймәсенме? Алыплар турында, Нух пәйгамбәр тарихы турында ул инде үзе дә бераз белә, ә менә Туран таулары хакында берни белми… Шуны сорап карасын әле ул ерак әбисеннән…»

— Әби, син Туран таулары турында берәр нәрсә беләсеңме? — дип сорады ул, Бәндәбикә әбисенең күзләренә туп-туры карап.

Мишәр әбисенең яшькелт күзләреннән хатирәләр дулкыны үтеп киткәндәй булды, алар бик тирәннән — күңел чоңгылларыннан ук күтәреләләр иде кебек… Туран, Туран… Аларның Атасал нәселе башында торган Алып-баһадир… Аның хакында истәлек-риваятьләр, телдән телгә күчеп, ничә мең еллар үтеп, Бәндәбикәләр чорына да килеп җитә алды… Үзенең нәсел шәҗәрәсен дә, аның тарихын да бик яхшы белә Бәндәбикә карчык. Ул аны Әтилнең атасы Туранга да язып, күчереп биргән иде. Туран аны Казанда, кайсыдыр журналда бастырып чыгарып, Бәндәбикә карчыкка да җибәргән иде әле… Бу бала, Тимертауда урыс телендә укыгач, боларны белмидер шул инде. Ә белергә, белеп калырга тиеш бит… Әмма янында боларны сөйләрлек атасы юк… Бәндәбикә карчыкның үз оныклары болар белән кызыксынмый, кайсы — урыс, кайсы — керәшен, кайсы тагы әллә кемнәргә әйләнде… Аларга татар тарихы кирәкми инде… Ә бу балада өмет бар, күзләре якты, этисе Туран кебек, гел эзләнә, сораша…

— Туран таулары турында беләм мин, улым,— дип башлап китте ул, ерактагы кыяларга карап.— Миңа ул хакта Нугайбәк бабаң сөйләде, аңа Җанбирде бабай сөйләгән, җиде буыннан гына түгел, кырык, хәтта йөз буын аша шушы риваять безнең көннәргә хәтле килеп җиткән… Аны белергә тиешле кеше белә, белмәскә тиешлесе экият итеп кенә карый… Ә бу — экият түгел, безнең токымның, безнең ыруның тарихы, туфаннан соң дәвам иткән кешелекнең тарихы… Алайса тыңла, улым…

Бик-бик борынгы заманнарда була бу хәл, улым… Туфаннан соң бөтен дөнья су астында калган… Ата салына утырып, бик азлар гына котыла алган туфаннан… Бер кечкенә генә коры җирдә безнең токым башы булган бер нәсел яшәп киткән… Картның исеме — Җанбирде, карчыкныкы Җанбикә

булган… Боларның Туран һәм Түлгән исемле ике уллары булган, ди… Карт белән карчык сунарчылык белән көн күргәннәр, малайлары әле кечерәк булган… Ул вакытта дөньяда зур кешеләр яшәгәннәр, урманнарда иләмсез зур хайваннар, тауларда, суларда аждаһалар мыжлап торган, ди… Алып кешеләр, зур, көчле булгач, алардан курыкмаганнар, үлемнең нәрсә икәнен белмәгәннәр, йөзәр, хәтта меңәр ел яшәгәннәр, ди, болар…

Туран белән Түлгәннең әти-әнисе, йола буенча, өйдә үзләре үтергән хайваннарның канын тотканнар, әмма аны кабып караудан балаларын кискен рәвештә тыйганнар… Түлгән исемле уллары аларны тыңламаган, әтиләре юкта каннан авыз итеп караган һәм рухы белән ерткыч җанварга әйләнгән… Туран исә ата-ана сүзеннән чыкмаган, тәртипле, баһадир егет булып үсеп җиткән… Ул җиңә алмаган берни калмаган, шулхәтле көчле булган ул… Әмма Туран дөньяда үлем барлыгын белгән, аннан кешеләрнең зур зыян күргәнен ишеткән һәм, атасының булат кылычын алып, Акбүз атка атланып, үлемнең үзен үтерергә эзләп чыгып киткән… Үзенә күрә, халыкны бәхетле яшәтәсе килгән инде аның, кавемен үлемсез итәсе килгән… Туран батырга каршы бөтен дөньяның дию-пәриләре, аждаһалар, бөтен явыз көчләр берләшеп күтәрелгән, ди, үз туганы Түлгән дә алар белән бергә булган, ягъни Туранга каршы сугышкан… Алпамыш Туран аларның барысын да җиңгән, халыкны ул явызлардан коткарган… Туран батыр җир асты һәм су асты патшасы Аждаһаның үзен дә үтергән, аның яман гәүдәсеннән Ямантау калкып чыккан, ди… Шулхәтле зур булган ул Аждаһа!

— Аксу янындагы Ямантаумы, әби? — дип, Әтил сорамыйча түзә алмады.

— Юк, улым, сүз бу тирәдәге Ямантау турында барырга тиеш, чөнки әтиең шулай дип әйтә торган иде… Шул сез барган Шүлгәнташтан ерак түгел инде ул, алар барысы бер тирәдә… Түлгән кереп качкан Шүлгән күле дә, аның янында Туран батыр эзләп тапкан терек чишмәсе дә, Ямантау да — бер тирәдә… Шул… Кайда калдым әле мин, улым?

— Туран батыр Аждаһаны үтерә…

— Әйе, Туран батыр Аждаһа патшасын үтерә, дию пәриләре яклы булган туганы Түлгән белән дә алыша, Түлгән соңыннан шул Шүлгән күленә батып үлә… Туран батыр явыз Катилне һәм еланнар патшасы Каһкаһәне дә үтерә… Инде соңгы җен-пәриләрне дә бетерим, дип, алар кереп качкан күл суын эчә, диюләр шулчак аның эченә кереп тулалар да аның үпкә-бавырларын талый-тураклый башлыйлар… Туран батырны газаплы үлеменнән тере су гына коткарырга мөмкин була… Ул мәңгелек суы булган Җанчишмәне эзләп китә… Таба ул бу суны, авызына да каба, әмма йотмый — дөнья өстенә бөркеп җибәрә… Чөнки күрә Туран батыр: бөтен тирә-як инде үлем көтеп, кибеп-корып ята… Шулай итеп, тере су ярдәме белән, дөнья яңадан яшәп китә, ә Туран батыр егылып үлә… Аның изге гәүдәсеннән Туран таулары барлыкка килгән, ди халык… Уралтау сыртын үзең беләсең инде — б-и-ик озын сырт ул —аның бер башы — Аксу тирәсендә, икенче башы Атасалга барып җитә… Халыкта менә шуны Туран батырның гәүдәсе, диләр инде, аннан чыккан алтын-көмешне, гәүһәр ташларны Туран батырның изге сөякләре, диләр… Шулай итеп, улым, Туран батыр төрки бу җирләргә үлемсезлек китерә. Әнә шул тере су бөркелгәнгә, бу тирәдәге матурлык бөтен дөньясында юк… Безнең татар халкы бу хакта мең еллар буе сөйләгән, җырлар чыгарган, дастаннар язган, телдән телгә тапшырган… Без кечкенә чакта бабайлар менә ничек дип җыру әйтәләр иде, тыңла, улым…

Бәндәбикә карчык, кыя-тауларга карап, моңлы күкрәк тавышы белән борынгы дастан әйтә башлады… Ул дастан әйткәндә, Коткар елгасы да дуламыйча, шыпырт кына ага башлады, елга буендагы тал-тирәкләр дә лепердәшүләреннән туктап калдылар… Кыя-таулар, Коткар-Агыйдел буйлары, бар тирә-як, таң калып, туксанга җитеп килә торган татар карчыгының милли мөнәҗәтен тыңлыйлар иде…

Әй Идел-Йорт, Идел-Йорт!
Идел буе имин Йорт!
Атам кияү булган Йорт —
Иелеп тәгъзим кылган Йорт,
Анам килен булган Йорт —
Иелеп сәлам биргән Йорт,
Кендегемне кискән Йорт,
Керем-коңым юган Йорт,
Бия сауган сөтле Йорт,
Кымыз эчкән котлы Йорт,
Идел — Җаек арасы
Елкы белән тулган Йорт,
Казан — Болгар арасы
Кала белән тулган Йорт…
Әй Идел-Йорт, Йдел-Йорт!

Әтил йотылып Бәндәбикә әбисен тыңлады… Аның мондый җыруны, мондый сүзләрне әле беркайчан да ишеткәне юк иде… Аның күз алдына иксез-чиксез киңлекләрдә — бөтен Идел — Урал арасында җәелеп яткан Татар иле килде… Аларның аралары зур-зур шәһәр-калалар белән тулган, җәйләүләрдә маллар утлап йөри, Идел-Йорт тыныч, имин, аңа әле бернәрсә дә янамый…

Әмма бу хәтле бай, гүзәл Йортны тынычлыкта калдыралармы соң? Әтилнең күз алдына Идел-Йортка һөҗүм иткән Аждаһа явы, авыр вакытта милләтен саткан хыянәтче Шүлгәннәр, аларга каршы чыккан һәм илен коткарган Туран- батыр килеп басты… Ул, үзе үлеп ятканда да, тере суны иле өстенә бөрки, милләте турында уйлый… Тере суы… Бүген дә бармы икән ул? Әй Әтил шуны тапса, иң беренче үлем базына әйләнеп барган Ямантау өстенә бөркер иде, атом казанына әйләнгән Урал тауларын коткарыр иде, әнисенең туган яклары булган Ырынбур далаларына сибәр иде ул тере суны Әтил! Әбисе туктаган арада, Әтил аннан сорап куйды:

— Әби, тере су хәзер дә бармы соң ул?

Бәндәбикә карчык шактый гына җавап бирми торды. Әллә ул үзе дә белми иде, әллә белеп тә әйтәсе килми иде — Әтил аңламады. «Мөгаен, Бәндәбикә әби үзе дә белмидер,— дип уйлады ул.— Белсә, шул су ярдәмендә Сөнгатулла абыйны терелтер иде… Безгә дә әйтеп калдырыр иде…»

— Ул тере суны күп кешеләр эзләп караган, улым,— диде Бәндәбикә карчык, аның уйларын бүлдереп.— Бабайлар сүли иде Атасалда — әле бик-бик борынгы заманнарда, әле Нух пәйгамбәр исән вакытта ук, ерак Урук иленнән Гилгәмеш-Алпамша исемле баһадир бу якларга мәңгелек суын эзләп килгән, ди… Нух пәйгамбәр ул вакытта салкын боз илендә, Мәшәк таулары артында яши… Ул яши торган икенче дөньяга юл тау куышы аша үтәргә тиеш була… Ул тау куышында 12 бүлмә була… Нух пәйгамбәр янына тере суны алырга аның көймәсендә «үлеләр елгасын» үтеп кенә барып булган… Алпамша бу юлны үтә, бик батыр егет була ул. Кайбер картлар, аны Туран батыр үзе булган, дип тә әйтәләр… Шулай итеп, бу батыр тере суны таба, аны чәчәктән эшләнгән савытка салып, кайтырга дип юлга чыга… Әмма юлында очраган явыз елан тере суны чәчәге-ние белән кабып йота… Шулай итеп, елан мәңгелек булып кала, кеше исә үлә торганга әйләнә…

— Тере су да монда булганмыни, әби?

— Бабайлар шулай дип сөйли торган иде шул, тере су Урал тауларында ул, диләр иде… Искәндәр Зөлкарнәйне дә шул мәңгелек суын эзләп дөнья гизгән, диләр бит… Чыңгыз хан да шуны эзләгән, тере суны тапкан кешегә ярты патшалыгын бүлеп бирергә вәгъдә иткән, имеш… Кешеләр гомер буе эзләгәннәр ул Җанчишмәне, улым, әмма таба алмаганнар… Ачса да, Аллаһы Тәгалә иманлы, гадел, көчле кешеләргә генә ачачак ул серне… Бәлки Җанчишмәне мәңге табучы да булмас…

Шулай диде дә әбисе Коткар елгасыннан үзе белән алып килгән буш шешәләргә су тутыра башлады.

— Әбекәй, син нигә аласың ул суны? — дип сорады Әтил, гаҗәпләнеп.— Сезнең өегезгә су кертелгән бит.

— Бу су башка, улым,— диде әбисе, серле генә итеп.— Коткар суы белән юынгач, Сөнгатулла абыеңның сызлаулары бетеп тора. Авыл халкы электән дә белә иде аның шифасын, әле башланган җиренә үк барып алалар иде, чишмәсеннән… Сөнгатулла абыеңа да эчәргә Рәхмәтулла абыең шуннан алып кайта… Коткар суы күп авырулардан коткарды халыкны, улым, күп ярдәм итте.

Шул чакта Әтилнең зиһенен яшен уты яктыртып киткән кебек булды. «Бәлки мәңгелек су — шушындадыр? — дип уйлады ул, шаулап аккан тере суга карап.— Әнә бит Бәндәбикә әбисе дә туксанга җитеп килә, авылда йөз яшьлек кешеләрне дә байтак, диләр… Әмма барысы да барыбер үлә бит, мәңгелек түгел…»

— Әби, Коткар елгасының исеме дә «коткар» дигән сүздән алынмадымы икән ул? Коткар ярдәм ит дигәнне аңлата бит…

— Кот ул, улым, элек-электән бик тирән мәгънәле сүз… Ул бәхет дигәнне дә, җан, тереклек дигәнне дә аңлата… Элек «бәхетле булсын» дигәнне дә «котлы булсын» дип әйтәләр иде… Кот койдыру да бар иде элек халыкта, мин үзем дә элегрәк шөгыльләнә идем моның белән… Каты курыккан, авырган кешегә кот койдыралар иде безнең якларда. Хәзер моны белүче юк инде, мин үзем дә дога, өшкерү белән дәвалыйм хәзер…

Шешәләрне, тутырып, капчыкка салдылар. Аннан соң әбисе Әтилгә, кечкенә кайчы биреп, су буенда куе булып үсеп утырган бөтнек үләннәрен җыярга кушты. Алардан баш әйләндергеч хуш ис бөркелә иде… Аннан әбисе, үзе күрсәтеп торып, үги ана яфракларын өздерде, Әтил бөтенләй белмәгән тагы берничә төрле үлән-чәчкәне җыйдырды.

— Коткар чишмәсенең суын болай гына да эчерәм, шушы үләннәр белән төнәтмә ясап та бирәм Сөнгатулла абыеңа,— диде ул, үзалдына сөйләнеп.— Мунчада, шушыларны салып, зур ләгәндә

юындыра да үзен Рәхмәтулла абыең… Шулардан соң терелеп киткән кебек була балакаем… Әмма авыруы каты тоткан шул, җибәрми… Хәзер барысы да Аллаһ кулында инде…

Суларны һәм үләннәрне алып, кайтырга чыктылар. Капчыкны Әтил үзе күтәрде. Коткар елгасы аларны авыл башына хәтле озата барды да, кинәт кенә борылып, Агыйделгә таба йөгерде. Әтил, башын күтәреп, каршыда каралып торган Бештәк тауларына таба карады. Аларның очлы түбәләре томан арасында йөзеп барган корабларның җилкәннәрен хәтерләтә иде… Көндезге рәшәдә салмак кына тибрәлеп, алар Әтилгә таба киләләр кебек… Шушы тауларның түбәсеннән Коткар елгасы башлана… Шушы тирәләрдә Туран батыр мәңгелек суны — Җанчишмәне эзләп йөргән… Шушы тирәдә әбисе сөйләгән дастаннардагы Шүлгән күле, Әтил үзе барып күргән Шүлгәнташ… Ямантау сыртлары…

Менә алар гаҗәеп зур бер таш янына килеп туктадылар, шуның янында бераз ял итеп алырга булдылар. Бәндәбикә карчык үзе әйтмәсә дә, аңа хәзер, балалар кебек, адым саен ял кирәк иде. Моны сизенеп алган Әтил, бераз барган саен, утырып ял итәргә җай эзли башлады. Зур ташның күләгәсенә сыенып, алар бераз хәл җыеп алдылар.

— Улым, таш өстендә зур-зур тирән эзләр күрәсеңме? —дип сорады аннан әбисе, яулык кырые белән маңгай тирләрен сөртеп.— Каһарман бабайның аяк эзләре, дип сөйлиләр аны монда. Бар, менеп кара әле…

Әтил, мәче җитезлегендә, түше белән шуышып, таш өстенә менеп тә китте. Чыннан да, таш өстендә, аермачык булып, зур-зур аяк эзләре ярылып ята иде… Нәкъ теге алып кешеләрнең аяк эзләре кебек, алар ташка батып кергән- нәр…

— Әби, кайдан килгән соң монда бу эзләр? — дип кычкырды Әтил биек таш өстеннән.

— Аның тарихы болай, улым,— диде Бәндәбикә карчык, ташка куллары белән таянып.— Аллаһ Мәһди дип аталган бер каһарман кешене нининдидер гаепләре өчен җиргә сөргән, дип сөйлиләр… Төшүгә Мәһди шушы таш өстендә тәһарәт алган һәм намаз укыган, диләр… Бик елаган инде ул җәннәттән сөрелгәненә… Аның күз яшьләреннән хәтта таштан да чишмә бәреп чыккан… Күрәсеңме, анда ермакка охшаган ярыклар бар, элек анда чишмә аккан, дип сөйлиләр иде… Каһарман бабайның намаз укыганда тезләнгән, маңгай куйган урыннарын да шәйләргә була иде элек, хәзер беткәндер инде… Әле анда комган куйган урын, таяк урыны да бар иде, дип сөйлиләр иде картлар, мин үзем аларын күрмәдем инде…

Әтил, шаккатып, әбисен тыңлады, һәм, чыннан да, комган урынын да, намаз укыганда тезләнгән, маңгай куйган урыннарны да күргән кебек булды… Әмма аны иң тетрәндергәне — Каһарман Мәһди бабайның аяк эзләре иде… Алар җылы таш өстендә ап-ачык булып җәелеп ята, биш бармак эзенә чаклы күрергә була иде…

Әтилнең Мәһди ташы яныннан китәсе килмәде, әмма аларны өйдә көтәләр иде. Ул бу авылга тагы килергә, бу тирәләрне җентекләп өйрәнергә булды. Әбисеннән, башка карт-карчыклардан авыл тарихы, нәсел тарихлары белән бәйле бөтен нәрсәне сорашып, язып калырга кирәк… Әтисе дә шулай эшли иде бит…

Инде авылга да керделәр, әмма аларның өенә шактый ерак иде әле. Тагы бер тапкыр утырып, ял итеп алырга булдылар. Әтилнең дә сулы шешәләр салган капчык тоткан куллары шактый арган иде. Авыр-авыр тын ала башлаган Бәндәбикә карчык та чираттагы ялга бик теләп риза булды.

— Әби, син Аксу янындагы Ямантау турында берәр нәрсә беләсеңме? — дип сорап куйды Әтил, үзенең серен әбисе белән дә бүлешәсе килеп.— Ул бит Урал тауларының иң биек урыны икән…

— Ямантау… Ямантау… Олы Тау… — дип, нәрсәнедер исенә төшерергә теләгәндәй, Бәндәбикә карчык бераз хәтерен җыеп торды.— Беләм мин аны, бик яхшы беләм, гомер онытырлык түгел… Электән халык арасында аның башка исемнәре дә бар иде, улым… Аны Нәрәле дип тә йөртәләр иде, Җәмәле дип тә… Әле аның халыкта җыры да бар бит:

Җәмәлекәй тауның, һай, башына,
Исемемне яздым ташына,—

дип җырлыйлар иде элек Ямантау турында, улым… Би-ик хикмәтле, хәвефле тау ул, балам… Нигә ул турыда сорадың соң әле син?

Әтил әйтергәме-әйтмәскәме дип бераз уйланып торды… Бәндәбикә әбисенә дә әйтмәсә, кемгә әйтер тагы ул бу серен? Дөрес, Әтил бу хакта бабасына сөйләде инде, әмма бабасы аңа бик үк ышанып бетмәде, ахры, саташулы бер төш, әкият кебегрәк итеп карады… Әтилнең үзенә бу хакта әйтмәде ул, әмма малай сизде: бабасы өчен болар чын нәрсә түгел иде… Ә Бәндәбикә әбисе башкарак, ул үзе дә әнә әллә нәрсәләр белә, әллә нәрсәләрне ышанып сөйли… Димәк, Әтил дә аңа ышанып эч серен ача ала?

— Мин әллә ничә тапкыр бер төш күрәм, әби,— дип башлап китте Әтил.— Дөньяны су баса икән… Без барыбыз да зур көймәгә төяләбез һәм дәрья буйлап йөзеп китәбез… Безнең көймәбез Туран

таулары дип аталган тауга килеп туктый… Без шунда яшәп китәбез… Әти миңа шунда әйтә: «Менә бу безнең яңа җирләребез инде, улым, Туран иле»,— ди…

— Әйе, заманында бу яклар Туран иле дип аталган, безгә бабайлар шулай сөйли иде шул… Таулары да Туран таулары дип аталган булырга тиеш, Нугайбәк бабай шулай ди иде… Ул хакта бер бәет тә әйтә иде ул… Тукта, хәтеремә генә төшерим дә… Әйе, менә болай:

Туран таудай тау булмас,
Туран аша су булмас.
Хәзинә син, югалмыйсың,
Сине су ала алмаган…
Юк кешеләр арасында
Тураннан файдаланмаган…

Әтил шатлыгыннан кычкырып җибәрде:

— Әйе, әби, әйе, нәкъ шулай — аны су ала алмаган! Ягъни туфан вакытында су Урал тауларына хәтле күтәрелә алмаган! Әби, кара син: бары да туры килә бит! Урал таулары — дөньяда иң борынгы таулар, заманында иң биек таулар… Урал тауларының иң биек түбәсе — Ямантау, көймә, туктаса, шунда гына туктый ала… Әмма Ямантау турында беркайда берни язылмаган... Хәзер анда кереп тә булмый икән…

— Шулай, улым, хәзер анда кертмиләр шул инде,— дип, уйчан гына әйтеп куйды Бәндәбикә карчык.— Хәзер анда атом бомбасы ясыйлар, диләр, Сөнгатулла абыең да шунда бетеп кайтты бит… Бик яхшы хәтерлим мин ул тауны… Элек ул тирәдә берничә татар авылы бар иде… Шуларның берсендә, Ямантау итәгендә, безнең ерак туганнар яши иде, Атасал нәселе… Балачакта этинең шунда алып барганын һаман хәтерлим әле мин…

— Җиһангир бабай да бардымы ул чакта? — дип сораганын Әтил сизми дә калды.

— Юк,— дип дәвам итте Бәндәбикә карчык.— Ул чакта Җиһангир бабаң дөньяга тумаган иде әле…

Бәндәбикә карчыкның күз алдына моннан 75 еллар элек булган хәлләр килеп басты… Ерак, бик ерак хатирәләр иде ул аның өчен… Әмма ул әле һаман да яман зур тауны, шул тау тирәсендәге вак-вак авылларны, андагы елга-күлләрне хәтерли… Ул тауның түбәсе гел куе соры томан эчендә булып, бик сирәк, аяз көннәрдә генә ачылып ала иде… Балалар түгел, хәтта олылар да ул таудан шүрлиләр, анда менәргә куркалар иде… Анда менгән кеше кире төшә алмый, дип сөйлиләр иде… Авыл малайлары белән бәхәсләшеп, үсмер Бәндәбикә ул тауның яртысына хәтле менгән иде… Соңыннан, аңын җуйган хәлдә, аны туганнары эзләп таптылар… Шактый озак авырды бу хәлләрдән соң Бәндәбикә, анда күргәннәре исенә төшсә, әле дә калтырап китә…

— Мин сиңа боларны өйгә кайткач сөйләрмен, улым, бик гыйбрәтле тарих ул,— диде Бәндәбикә әбисе, авырлык белән генә урыныннан кузгалып.— Кайтып чәй эчмичә, сөйләп булмас, телем аңкавыма ябышты инде.

Әтилгә уңайсыз булып китте. Бәндәбикә әбисен ул бит инде кайчаннан бирле сөйләтә дә сөйләтә, әлбәттә, бу эсседә ул инде арып беткәндер. Әмма, Атасалдагы кебек, иң кызык җирендә генә туктады да калды әбисе… Аның Ямантауга менгәнен белсә, Әтил килгәннән бирле бары тик шуны гына сөйләткән булыр иде… Өйгә кайтуга бабасы, әйдә киттек, дисә? Ямантау турында сөйләгәнне тыңламыйча китәме хәзер Әтил?

Алар әлсерәшеп кайтып кергәндә, мунча өлгергән, тавык суелган, инде аш пешеп ята, Рәхимә килен исә чажылдатып коймак пешереп йөри иде. Ул Бәндәбикә карчык белән Әтилне шунда ук чәй янына утыртты, Сөбханкулдан алып кайткан тәмле-томлыны да өстәлгә куеп, аларны чәй белән сыйлый башлады.

— Сагынышкансыз сез, ә? — диде ул, көлеп.— Әнкәйгә күптән иптәш юк иде, сөйләшеп рәхәтләндегезме?

Бәндәбикә карчык, яңадан әби патша рәвешенә кереп, түргә — үз урынына менеп утырды. Авызы бик кипкән иде, каршы сүз әйтмәде, иркенләп, чәй эчә башлады.

— Бабай кайда соң? — дип сорады Әтил, як-ягына каранып.

— Сөнгатулла абыеңны мунчага алып кереп китте, үзем юындырам энекәшне, дип… Аңа эссе мунча ярамый бит, кеше керә башлаганчы кереп чыксыннар, дидем.

Әтил җиңел сулап куйды. Бабасы әле мунчадан чыгуга ук, кайтыйк, димәс, димәк, Әтил әле Бәндәбикә әбисеннән Ямантау турында сөйләтеп кала ала.

Әмма Бәндәбикә әбисе чәен бик иркенләп, озаклап эчте. Әтилнең кыбырсынып утыруын күргәч, аңа балалар бүлмәсенә керә торырга кушты, чәен эчеп бетергәч, үзенең дә анда керәсен әйтте. Әтил әбисе күрсәткән бүлмәгә кереп китте. Әмма аның башында гел Ямантау турында уйлар кайнаша иде. Ул әбисенең шулай озаклап чәй эчүенә аптырады, «Бер-ике чынаяк чәйне ничек шулай сузарга мөмкин

икән?» —дип уйлады ул. Әбисе кергәнче, ул пыяла шкафтагы китапларны карый торырга булды. Аларны кулга алу белән, Әтилнең тәнен ток токкандай булды — бу китап-журналларда әтисе кулы белән язып калдырган хәбәрләр бар иде. Әтил инде бөтен дөньясын онытты, әтисеннән калган кадерле китапларны кочагына төяп, караватка җайлап барып утырды. Шул чагында, тамак кыра-кыра, бүлмәгә Бәндәбикә карчык та кереп җитте.

— Атаңның китапларын карыйсыңмы, улым? — диде ул керә-керешкә.— Миңа Казаннан да, Ырынбурдан да җибәреп бара иде ул татарча китаплар… Кайсыдыр бер Казан журналында безнең нәсел тарихы да басылып чыккан иде, аны да карасың әле...

Әбисен күргәч, Әтил китапларны тиз генә бер читкә алып куйды. Юк, бу китапларны ул кайчан да укый ала, ә менә әбисен ул әле кайчан күрә? Аның Ямантау турында сөйләп калуы яхшырак хәзер Әтил өчен.

— Әби, син миңа Ямантау турында сөйлә әле, мин бу китапларны соңрак карармын,— диде Әтил, әбисенең аяк очына җайлап утырып.

Әбисе дә аркасын зур мендәрләргә терәп, җайлап утырды, терсәк астына исә кечерәк мендәрләрне куйды. Бу мизгелләрдә ул, чыннан да, хан арбасына чыгып утырган патшабикәне хәтерләтә иде.

— Алайса тыңла,— дип башлап китте ул, инде көр, ныклы тавыш белән.— Ул чакта синең яшьләрдә идем мин, улым, бәлки аз гына кайтыш булганмындыр… Синең төсле бик кызыксынучан ут борчасы кебек бала идем… Менмәгән тавым, эчмәгән суым калмады үз тирәбездә… Инзәр авылына баргач та, беренче эш итеп шул Ямантау буена йөгердем… Менәсем килде шул Ямантау башына — и бетте-китте! Ә авыл балалары ул тауга якын килергә дә куркалар, чыннан да әллә нинди хәвефле, шомлы булып караеп утыра ул… Мине дә куркытып куйдылар: имеш, аның башында аждаһа яши, дип… Имеш, ул тау башында бер күл бар икән, имеш, аждаһа шул күлдә яши икән, шул яшен болытына әйләнә икән дә тауга менгән кешене кире төшерми икән, адаштырып үтерә икән, дип сөйлиләр авыл балалары… Мин ышанмыйм инде боларга, әтәчләнәм, чөнки Атасал тауларын аркылыга-буйга йөргән кеше бит мин, беркайда да аждаһа күргәнем булмады… Җәйнең эссе бер көнендә бәхәсләштем дә чытырдап менеп тә киттем Ямантауга… Авыл малайлары, авызларын ачып, аста карап калдылар… Менәм-менәм, башта кызык кына булды. Атасалдагы кебек, шундый ук тау: чыршы, каен, төрле куаклар үсеп утыра, аяк астында соры ташлар ауный, араларында ямь-яшел үлән, чәчкәләр җилферди… Бернинди куркыныч нәрсә юк, күктә кояш көлә, җиләс җил исә, үләннәр кыштырдый, вак ташлар шыбырдашып коела… Менәм шулай, менәм, менә бер заман каен агачлары күренми башлады, чыршылар сирәгәйде, аяк асты гел кара-соры таш…

Кисәк кенә көн дә караңгыланып киткән кебек булды, салкынайтып җибәрде… Агачлар да әллә нинди кәкре-бөкре, ямьсез булып тоела башлады миңа, үзләре тәбәнәкләр, үзләрен җонлач мүк баскан, ташлы җиргә ябышып диярлек утыралар… Мин өстемә җылырак кофта алмаганыма үкенә башладым, чөнки тау өстендә искән салкын җил инде үзәккә үтә башлады… Ә сер бирәсе килми авыл малайлары алдында, мишәр үҗәтлеге көчле, барыбер менеп җитәм, дим, үзем, өметләнеп, өскә карыйм… Ә анда!!! Анда әле юлның тагы шуның хәтлесе бар… Куркып, аска карадым: тау итәгендәге балалар кеп-кечкенә булып, кырмыскалардай гына күренәләр иде…

Инде нишләргә? Өскә менү мөмкин түгел — туңудан мин инде дер-дер киләм, тәнем салкыннан күгәреп үк чыкты… Менә алмыйча, аска төшәргә дә оят — Атасал атаманы, мишәр Бәндәбикә башың белән, ничек хурланмыйча ярты юлдан борыласың? Ни булса да булыр, дип, соңгы көчемне җыеп, үҗәтләнеп Ямантауга үрмәләдем. Зур-зур ташлар ышыгында бераз җылынып торган кебек булам да тагы өскә үрмәлим… Һәр адымым газапка әйләнде, күз алдымда күк, тау, агачлар, ташлар җыелышып сикереште, йөрәк тибешем бер катыланды, бер әкренәйде… Ә Ямантау түбәсе бик ерак иде әле…

Бәндәбикә карчык туктап калды. Әтил, түземсензләнеп, аңа текәлде. Менә ул шулай, Атасалда да гел шулай итә иде — иң кызык җирендә туктап кала да ахырын башка вакытта сөйләп бетерә. Бу юлы бит башка вакыт юк, бабасы әйдә диюгә, Аксуга кайтып китәчәкләр! Ә Бәндәбикә әбисе һаман мамык мендәрләргә кырын ятып, уйланып утыра…

— Менеп җитә алдыңмы соң син анда? — дип, Әтил үзе Бәндәбикә әбисенә ярдәмгә ашыкты.

— Юк, улым, менеп җитә алмадым мин Ямантау башына, Алла саклап калды,— дип дәвам итте Бәндәбикә карчык.— Менеп җиткән булсам, кире төшә алмаган булыр идем, туңып, салкын тиеп, шунда үлгән булыр идем… Мин бит аны соңыннан гына белдем: анда иң эссе җәй көнендә дә көндезге җылылык 10 градустан артмый икән, ә төнлә, гомумән, су катырлык туңдыра… Бетәсе булганмын мин анда, Алла саклап калды инде… Шул… Сөйләп бетерим инде ахырын… Менәм бит инде үҗәтләнеп, менәм, ярты юлны үткәч, аякларым җиргә бата башлаган кебек тоелды… Атлыйм — җир тибрәлеп тора, ул мүк шулай баскан саен селкенә икән… Каршыга карыйм — анда дуга-дуга тау сыртлары — Атасалга хәтле тезелеп киткән… Бер заман күз алдымда тау әйләнә башлады — аста инде балалар да

күренми, авыллар да күренми, тау сыртлары да күренми — күз алдында тоташ божра… Шул божраның кырыена тотынам дип талпындым да җиргә аудым… Аннан мин инде яңадан тормадым… Авылдан өлкәннәр килеп, эзләп тапканда, мин инде ярты үлек булганмын… Менә шулай итеп, Ямантауга менәргә азапландым мин, улым, әмма менеп җитә алмадым… Ул тау беркемне дә үзенә якын җибәрми икән… Яман урын булып чыкты ул… Алай дисәң, анда бик хикмәтле нәрсәләр дә белдем мин, бик хикмәтле нәрсәләр күрдем…

Бәндәбикә карчык, сөйләргәме-юкмы дигәндәй, Әтилгә карап алды. Бу хәлләрне аның әле үз гомерендә беркемгә дә сөйләгәне юк, сөйләсә дә ышанмаслар иде… Ул хәзер гомеренең ахырына җитеп килә, чик якынлаша, кемгә булса да сөйләмәсә, бу сере үзе белән китәчәк иде… Ә бу бала, беркем мәҗбүр итмичә, нәкъ шул нәрсәләр белән кызыксына, җаны шул тирәдә эзләнә… Димәк, шулай язган, Аллаһы Тәгалә бу хикмәтле серне ачуны шушы балага насыйп иткән…

Әтилнең мөлдерәп көтеп утыруын күреп, Бәндәбикә карчык сүзенең ахырын сөйләмичә булдыра алмады.

— Болар кеше ышана торган хәлләр түгел, улым, әмма мин аларны бик яхшы хәтерлим,— дип дәвам итте ул.— Шулай әллә арып, әллә аңымны җуеп егылдым… Әмма бер җирем авыртмый үземнең, хәтта туңмыйм да икән… Тәнем шул мүкле артышлар арасында ята, ә җаным инде, чыгып китеп, шуны өстән карап тора… Ягъни мин Ямантау башыннан аска — үз-үземә карап торам… Менә бер заман минем җирдә яткан гәүдәм янына зур-зур гәүдәле, баштанаяк актан киенгән кешеләр җыела башлады… Алар шундый озыннар — аяклары минем гәүдәм янында, башлары Ямантау түбәсенә тия язган… Үзләре алар кеше дә кебек, әмма кеше дә түгел иде, чөнки аркаларында, бөркет кошларныкы кебек, зур-зур канатлары бар… Хәтта дүртәр, унар канат… Шул ук вакытта мин аларның сөйләшүләрен дә ишетеп, аңлап ятам икән…

— Иртәрәк килгән әле монда бу бала,— диләр.— Моңа әле Раббыбыздан вакыт җитмәгән, аңа үз дөньясына кайтырга ярдәм итәргә кирәк…

Мин өстән күреп торам: болар минем гәүдәмне җирдән сак кына күтәреп алдылар да тау башына менә башладылар… Ә анда бер күл бар икән, анысын мин дә күрәм… Болар минем гәүдәмне шул күлдән алган су белән юалар да, баш очымда нидер укып, озаклап дога кылалар… Сүзләрен аңламыйм —безнеңчә түгел… Хәзер бик белдем: Коръән укыганнар алар миңа, әмма ул вакытта аңлап бетми идем әле…

Укып бетергәч, гәүдәмне кулларына алдылар да таудан түбән төшә башладылар. Минем җаным да аларга иярде…

— Озак яшәр, йөзгә хәтле,— диде аларның берсе.

— Дөрес яшәр, безнең дога белән,— диде икенчесе.

— Әмма нәселе тагы монда киләчәк,— диде өченчесе.

Алар, минем гәүдәмне йомшак мүк өстендә, артыш арасында калдырып, китеп бардылар, юкка чыктылар. Алар китүгә, мин, ягъни минем өстә эленеп торган җаным, атылып гәүдәм өстенә төштем… Астан, шаулашып, кешеләрнең менеп килүе ишетелә иде… Аларны күреп, җаным гәүдәм өстенә капланды, мин аңа сеңеп беттем һәм җилдәй сулыш булып, суырылып тәнемә кердем…

…Соңыннан, бер тәүлек үткәч, мин дога тавышына аңыма килгәнмен… Әмма бу тауда алып фәрештәләр укыган дога түгел, авыл өендә, сәке башында мулла бабай миңа шулай ясин чыгып утыра икән… Мине тәүлек буе уганнар, җылытканнар, өшкергәннәр, аннан, үлүе шушы икән, ахры, дип, ясин чыга башлаганнар… Менә шул тавышка мин аңыма килдем һәм аякка бастым… Менә шундый хәлләр дә була дөньяда, улым… Аннан соң да шактый вакыт авырдым әле мин… Күршедәге Кушъелга авылыннан кот коючы әбине алып килгәннәрен хәтерлим… Ул мине шапы-шопы суккалап, мунчага алып кереп, башыма кара тавык бастырып кычкыртты — куркуым шулай чыксын, диптер инде… Аннан, бу балага пәри ияләшмәгәе, дип, үзе белгән «Каһәрнамә» догасын укыды, мин аны ятлап та калдым әле шул чакта, чөнки бик кызык тоелды ул миңа… Әле дә хәтерлим әле мин аны…

Бәндәбикә карчык, күзен йомып, бераз селкенә төшеп, татарларның борынгы кот догасын күңелдән көйләп укый башлады:

Бисмиллаһи р-рахмани р-рахим.
Газимәт галәйкем.
Йад йүфриләр,
Ак атлыглар,
Алла бер,— гаһлыклар,
Алтын садаклылар,
Көмеш көрсилекләр,
Нәргис күзлекләр,
Кяфур җаҗлыклар,

Каләм кашлыглар,
Сәлдүс түшәклегләр,
Йәшел фаршин тунлыглар,
Гыйбер-гыбрәтлегләр,
Даштан куышлыклар,
Төрлег-төрлег тунлыглар,
Бүрек алтынлыглар,
Йылан камчылыглар,
Болыт менгәнләр,
Көлгә очканлар,
Тагълар ашканлар,
Дәрьйа кичкәнләр,
Күлдә сулаганлар.
Җәмәнләрдә төшкәнләр,
Үгүз йиләрдә ултырганлар.

«Чәч-чишмәлекләрдә бу Адәм углы вә кызының йите ин матдә урын тотучы. Афәт оргучылар агыза йөкләдем Сөбхане газыйм ярлыкы берлән сезләрне күргәле вә күчүргәле, вә китергәле киләдем. Әй мәлгуньнәр, итләре вә үтләре, тәнләре, өч йөз алтмыш тамырлары, түрт йөз кырык сүйәкләре арасындин бу зәхмәт тигүргәнләр күчгил вә киткел. Әй мәлгуньнәр, битараф шәркыйа угыр… Вә ля куәте Аллаһу әл-гадюме әл-газыйм. Әй туар котлуг фәриләр вә әй сансыз җариклар, бу адәм углы-кызыга белмәйен килеп, сезләр аңламайын төшеп, сезләр дийүмүсезләр Бихак хакы хөрмәте, Сөбхан хакы хөрмәте, йөз ун түрт сүрәлек «Коръән» хакы хөрмәте вә Җәбраил, вә Микаил, вә Исрафил, вә Газраил хакы кирү бәйан».

Шуларны әйтеп-сөйләп бетерде дә, өстеннән авыр йөк төшкәндәй, Бәндәбикә карчык туктап калды. Аның гомерендә беркемгә дә сөйләмәгән бер сере бар иде, менә аны да тиешле кешесенә тапшырды… Бу бала — киләчәк кешесе, үткәннәрдән бу хәбәрләр анда сакланырга тиеш…

Әтил әбисенең сөйләгәннәреннән бик нык тетрәнгән, тәэсирләнгән иде… Әйтерсең лә ул үзе дә Бәндәбикә әбисе белән Ямантауда йөрде, арып һәм авырып егылды, алып кыяфәтенә кергән фәрештәләр белән очрашты… Әйтерсең лә алар Бәндәбикә әбисе белән бер гомерне яшәп яталар иде… Әбисе сөйләгәннәрдән аны тагы «Каһәрнамә» догасы бик гаҗәпләндерде. Аның кайбер сүзләрен Әтил аңлап бетермәсә дә, борынгы догадагы «Таштан куышлыклар… Таулар ашканнар… Дәрья кичкәннәр… Җәмәннәрдә төшкәннәр…» дигән сүзләр Әтилне тетрәндерде. Нинди Җәмән турында сүз бара соң ул догада?

— Әби, синең ул соңгы доганда нинди Җәмән турында сүз бара икән ул? — дип сорады ул Бәндәбикә әбисеннән.

— Аны Җәмән — Ямән иле дип тә, Җәмән — Ямантау дип тә аңларга була, улым… Чөнки югарыда тауда, таш куышлыкларда яшәгән, соңыннан таудан төшкән, дәрья кичкәннәр турында сүз бара бит… Биредә сүз Ямантаудан төшкән изгеләр турында барадыр, мөгаен… Хәзер аны кемнән сорыйсың инде…

— Мин дә бу хәлләрне төшемдә күрдем бит, әби,— диде Әтил, уйга калып.— Син менгән Ямантауны да күрдем, дөньяны су басканын да күрдем, Нух пәйгамбәр көймәсен дә… Без барыбыз да шул көймәдә идек, анда Түлгән абый гына юк иде…

Бәндәбикә әби дәшми торды. Аннан, авыр сулап:

— Бу — заман ахырыдыр инде, балам,— дип әйтеп куйды.— Аллаһы Тәгалә изге бәндәләренә дөньяда ни буласын күрсәтә, алар аша кисәтә… Дөньяның башын ахыры белән бәйли, бауны бәйләгән кебек итеп кенә… Түлгәнгә ул көймәдә урын булмас шул, күп начарлык эшләде бу дөньяда…

Бәндәбикә карчыкның шулай әйтергә хакы бар иде, чөнки ул барысын да белеп тора иде… Түлгәннең туганы Туран белән Сәрмәнияне Аксудан кысрыклап чыгарганын да, Атасалга кайтып, аларга бәйләнеп йөрүләрен дә, кемгә хезмәт иткәнен дә, кемнәргә каршы сугышып-көрәшеп йөрүен дә — барысын да белә туксанга җитеп килә торган Бәндәбикә карчык… Иблискә җанын сатты Түлгән, замана аждаһаларының колы, кулларында коралы булды… Ата-анасы бу хакта дәшмәсәләр дә, ил авызына яулык каплап булмый — Түлгәннең кемгә хезмәт иткәнен бу тирәләрдә яхшы беләләр… Яхшы ата-анадан туган начар бала ул… Менә хәзер үзенең кайда икәнлеген дә белүче юк… Үз хуҗалары да юк иткән булырга мөмкин, алар этлекне эшләткәндә эшләтәләр дә аннан юк та итеп ташлыйлар… Туран балакай да юк, әмма аның илдә яхшы исеме, яхшы улы калды… Ә Түлгәннән нәрсә кала?

— Ярар, улым, бабаң мунчадан чыкканчы, бераз ял итеп ал, мин дә таянып торыйм,— дип, Бәндәбикә карчык үз бүлмәсенә кереп китте.

Әтил караватка барып ятты һәм әбисе сөйләгәннәрне күңеле аша уздыра башлады… Ул гомердә ишетмәгән, гомер буе белмәгән нәрсәләрен бүген ишетте, бүген белде… Әбисе әллә нәрсәләр сөйләде аңа — Туран белән Түлгән турындагы халык дастанын да, тере суы турында да, Туран-Урал таулары турында да, Мәһди ташы турында да… Әмма Әтилне иң тетрәндергәне — әбисенең Ямантау турында сөйләгәне булды… Бәндәбикә әбисе ул тауда булган, аны күргән бит! Әтил үзе дә Ямантауны нәкъ шундый итеп күз алдына китергән иде. Дәһшәтле, серле һәм… хикмәтле… Әбисе бу сөйләгәннәре белән аның уйларын раслап кына куйды. Барысы да Әтил уйлаганга туры килә иде — дөньяны су басканда, бер нәселнең, көймәгә утырып, исән калуы да, көймәнең бу тирәдә иң биек тау түбәсе булган Ямантауга килеп туктавы да, шул нәселдән кешелекнең дәвам итүе дә… Туран белән Түлгәненә хәтле туры килеп тора… Әйтерсең лә аларга исемнәрне дә тәкъдир кушкан, язмышларына карап шулай билгеләгән… Тукта, Әтил монда әтисенең китапларын да карап куйган иде бит, Бәндәбикә әби кергәч, аларны калдырып торган иде… Вакыты булганда, тизрәк карап чыксын әле ул аларны. Аларда әтисе язып калдырган хәбәрләр дә бар бит!

Менә бит ул журнал! Ул Казан шәһәрендә чыккан һәм «Мирас» дип атала икән. Аның һәр битендә диярлек әтисе кулы белән ни дә булса язып куелган. Ә менә «Татар шәҗәрәсе, Нугай урдасы һәм Атасал нәселе» дип аталган зур мәкалә. Журнал битенең кырыйларына әтисе эре хәрефләр белән: «Бу язма безнең турыда»,— дип язып калдырган… Әтил, аякларын караватка җайлап сузып, әбисе кебек аркасын мендәргә терәп, бу мәкаләне укый башлады. Кемнәр генә юк монда, нинди генә нәселләр тупланмаган! Кирәет нәселе, Гәрәй кабиләсе, Катай, Уран, Уйшин Майка би шәҗәрәләре, угызлар, бүләрләр, тагы әллә кемнәр… Аерым бик зур бүлекне Кара би шәҗәрәсе алып тора… Һәм менә нугай татарларының борынгы шәҗәрәсе… Әмма Әтилне иң нык кызыксындырганы — Атасал нәселенең башы булып торган Җанбирде карт шәҗәрәсе булды. Әтисе бу урынга аерым билге дә куйган, «Бу — безнең токым турында»,— дип язып калдырган. Әтил, дөньяда бар нәрсәне онытып, журнал өстенә капланды… Әйтерсең лә ул бу мизгелләрдә әтисе белән генә түгел, шушы нәселгә нигез салган иң борынгы кешеләр белән дә аралаша, сөйләшә иде…

Нәсел башы, нәкъ Әтил көткәнчә, Нух галәйһиссәламнән башлана иде… Биредә ул, нигәдер, «Әхнух» дип бирелгән. Нухтан соң Яфәс китә, аннан — Төрек, аннан — Алып, аннан — Җанбирде, аннан — Туран… Кара инде, нәкъ Җиһангир бабасы әйткәнчә икән бит! Туфаннан соң менә кемнәрдән башланган икән бит татар-төрек нәселе! Моннан соң инде бөтен дөньяга билгеле пәйгамбәрләр, патшалар, солтаннар, изгеләр буыннары китә… Боларны укыганда, башлар әйләнә, бу хәтле мәгълүмат акылга сыймый, хәтта ышанып та бетеп булмый… Әмма, акка кара белән, туфаннан соң булган тарихның көне-көнгә язып барылган, заман башының бу хәбәрләре татарларның кан күзәнәкләренә, Урал ташларында, курганнарда, кабер ташларында, тиреләрдә, ак кәгазь битләрендә язып калдырылган… Һәм менә шул рәвешле сакланып, Әтилгә хәтле килеп җиткән… Биредә йөзәрләгән генә түгел, меңәрләгән буыннарның тарихы, шәҗәрәсе… Менә алтмыш дүртенче буын — Солтан Баба Төкләс. Шәҗәрәдән күренгәнчә, ул хәтта Кәгъбәтулланың үзендә падишаһ булып торган, аның Тирмә атлы бер улы, кан тартуы буенча, яңадан Идел буйларына кайткан, көн күрә башлаган… Тирмә ханнан — Кырынчы би, аннан — Ислам Кыйа солтан — Кадер Кыйа солтан — Котлы Кыйа солтан… Котлы Кыйа солтанны урыс хан шәһит кылдырган. Аннан җитмешенче буын — Идик би нәселе дәвам итә, аннан — Чалбак хан. Ул шушы Нугай Йортының билгеле татар ханы була…

Шәҗәрәдән күренгәнчә, бөтен дөньяга таралган Нух пәйгамбәр токымы, аның төрек-татар кавеме төп нигездә — Идел — Урал арасында яшәп кала һәм зур дәүләтләр, илләр, җирләр тотып яши…

Менә бит бу хакта әтисе дә кулдан гына нәрсә язып калдырган. «Биредә әле моннан 4 мең еллар элек иксез-чиксез Туран иле җәелеп яткан,— дип язып куйган ул журнал читенә.—Бу Туран илендә туранлы төрки-татарлар яшәгән, хуҗа булган. Башка халыклар аларны һуннар, гуннар яки скифлар дип йөрткәннәр. Яңа эраның өченче, дүртенче йөзләрендә Һун биләмәләре Җаектан Днепрга хәтле сузылган, төньяктан — Камага, көньяктан Хәзәр (Каспий) диңгезенә, Кавказга хәтле барып җиткән. Соңрак бу Бөек Туран иле җирләрендә Болгар, Алтын Урда, Нугай Урдасы, Себер һәм Казан ханлыклары, Кырым һәм Әстерхан ханлыклары барлыкка килә… Аларның барысы белән дә төрки-татарлар идарә итә, бу дәүләтләрнең төп халкы татарлар була». Моның нәкъ шулай икәнлеге шәҗәрәдән дә күренеп тора, рәт-рәт булып, Идел Болгары ханнары, Алтын Урда ханнары, Казан ханнары, Нугай Урдасы ханнары, Себер һәм Кырым ханнары, Әстерхан һәм Касыйм ханнарының исемнәре тезелеп киткән… Һәм алар барысы да татарлар…

Әтилне шушы Идел-Урал арасында хакимлек итеп яткан татар ханлыгы — Нугай Урдасы да бик кызыксындырды. Чөнки бу хакта Әтилгә мәктәптә дә берни сөйләгәннәре булмады, китаплардан да укырлык нәрсә тапмады. Шушы җирләрдә моннан дүрт йөз еллар элек кенә зур дәүләтләр тотып яшәп яткан нугай татарлары турында бу якларда хәзер берни язмыйлар да, сөйләмиләр дә иде… Ә менә бу

Казанда чыккан татарча журналда Нугай Урдасының тарихы да, хәтта картасы да бирелгән. Әтил, үз күзләренә үзе ышанмыйча, шул картага карап торды, соң, бу Татар иле Россиянең генә түгел, элеккеге СССРның да күпме өлешен алып торган икән бит! Менә бирегә әтисе үз кулы белән язып та куйган: «Безнең Нугай Урдасының җирләре көньякта Бохарадан алып, төньякта — Пермь тирәләренә, көнчыгышта — Иртыш буйларыннан, көнбатышта Идел буйларына хәтле җитеп, аннан Днепргача барып җитә»,— дип язып калдырган әтисе. Һәм шушы җирләрнең барысы белән дә татарлар идарә иткән! Бу хәлләр әле кайчан гына булган…

Нугай Урдасы белән янәшәдә Казан ханлыгы картасы да бирелгән — ул да бөтен Идел — Урал арасын тутырып, аның чикләре төньякта — Кар иленәчә, көньякта Самара, Сарытау далаларына хәтле җәелеп ята… Шул ук татар ханлыгы булган Касыйм ханлыгы Мәскәүнең борын төбендә үк, ил-җир тотып, үзенчә яшәп яткан… Кырым татарларының ханлыгы исә бөтен Кубань буйларына, Кавказ тауларына, хәзерге Мордовия, Украина җирләренә хуҗа була… Ә менә монда татарларның Себер ханлыгы биләмәләре, алар исә Тын океандагы Татар бугазыннан Урал тауларына хәтле җирләрдә җәелеп яшәгәннәр… Ә борынгы Һун биләмәләре, Скифия яки Туран иле чикләре, бу карталардан күренгәнчә, хәтта Европага хәтле барып җиткән, һун татарлары хәтта хәзерге немецлар яши торган җирләргә дә хуҗа булган… Шуңа күрә фәндә кайвакытта «Скифия-Германия» дип тә языла икән…

Ә нинди генә кала-шәһәрләр булмаган Татар илендә! Рус китапларында мыскыллап язылганча, татарлар тире киеп, чи ит ашап, тирмәләрдә яшәп ятмаганнар, ә бөтен дөньяда кодрәтле дәүләтләр тотып, зур-зур шәһәрләр төзеп калдырганнар. Аларның кайберләре турында Әтилнең хәтта ишеткәне дә юк иде… Менә бу татар журналында ул борынгы татар шәһәрләренең урыннары, исемнәре, тарихлары да бирелгән… Аркаим, Лүнчән, Дайлин, Ханбалык, Каракорым, Сәмәндәр, Әтил, Самар, Болгар, Бүләр, Сувар, Җүкәтау, Казан, Кашан, Сарай, Хаҗитархан, Үкәк, Мохша, Маджар, Аккирмән, Ханкирмән, Чаллы, Алабуга, Урмат, Калатау, Арча, Тора-Тау, Имән-Кала, Искер, Чимки-Тура, Бичек-Тура, Кашлык, Яулы-Тура, Кызыл-Тура, Тон-Тур, Касыйм-Тура һәм тагы әллә нинди шәһәрләр… Журналда басылган борынгы тарихи чыганаклардан күренгәнчә, болар барысы да татар шәһәрләре булганнар… Бер Казан ханлыгында гына да 120 шәһәр булганлыгы билгеле…

Әмма Әтилне иң тетрәндергәне тагы шул булды: Атасал нәселе шушы ил һәм шәһәрләрнең барысы белән дә диярлек элемтәдә торган, алай гына да түгел, күпчелек очракта алар белән идарә иткән… Бу шәҗәрәдә дә бик ачык чагылыш тапкан. Шулчак Әтилнең күзе шәҗәрәнең ахырына төште, һәм ул сискәнеп китте: Атасал токымы Әтил белән тәмамлана иде… Ул ашыгып күзләрен уды, шәҗәрәгә тагы бер тапкыр игътибар белән карады: әйе, шәҗәрәнең иң ахырында Әтил исеме тора, ә аннан өстә — әтисе Туран, аннан да өстә — бабасы Җиһангир… Димәк, бу нәселне дә, шәҗәрәне дә, хәтта бу зур татар тарихын да дәвам итүче Әтил булып чыга?.. Шуңа күрә якыннары аңа барысын да аңлатып калырга тырышалар, кулларыннан җитәкләп, Татар иле тарихы буйлап йөртәләр…

Әтил, арып һәм уйга батып, журналдан башын күтәрде. Аның күз алдына ярты дөньяны биләп алган татар илләре, татар җирләре килеп басты. Таралып яткан Татар иле… Әтил аның авыр итеп сулыш алганын, хәтта ыңгырашып куйганын ишеткән кебек булды. Хәзер кайда соң ул илләр, ул җирләр, ул бөек тарих? Һәрберсенә кем дә булса хуҗа яки хуҗа булырга омтыла… Моның шулай икәнлеген моннан биш ел элек Әтил үз күзләре белән Аркаимда күреп кайткан иде. Әле дә хәтерли Әтил: әтисе солдаттан ялга кайткан җәйне аны Аркаимга — төрки-татарларның иң борынгы шәһәренә дип алып китте… Әмма аларны анда бөтенләй икенче дөнья, икенче хуҗалар, татарга капма-каршы булган сәясәт каршы алды… Әтисенең анда эшләүче галимнәр белән ничек кызып бәхәсләшүен хәзер дә хәтерли Әтил…

Ә менә бу Казан журналында Аркаим турында нәкъ аның әтисе сөйләгән кебек язганнар — «Борынгы төрки цивилизация үрнәге» дигәннәр… Аркаимның югарыдан — самолеттан төшергән фоторәсемен дә биргәннәр… Түгәрәк, боҗра рәвешендәге борынгы шәһәр урыны, эчтә — тагы аерым түгәрәкләр, күч-күч булып утырган өйләр… Нәкъ Каһарман авылы кебек, Атасалның иске очы төсле… Әтил, үзенә таныш урыннарны эзләп, рәсем өстенә иелде… Күз алдында Аркаимның борынгы курганнары, елга-таулары, түгәрәк өйләре яңарган, җанланган кебек булды… Шул хатирәләр эзе буйлап, Әтил яңадан казах далаларына терәлеп утырган төрки Аркаимга китеп барды…

* * *

Әйе, Әтилнең әтисе солдат хезмәтеннән ялга кайткан җәйне алар бергәләп Аркаимга бардылар. Әтисе моңа кадәр дә, институтта укыганда, анда казу эшләрендә катнашкан булган, шуңа күрә Әтилне дә анда алып барып күрсәтәсе килде. Аркаим — Урал тавының арьягында, Атасалдан 100—150 чакрымнарда, Чиләбе өлкәсенең Казахстан чигенә якын далаларында табылган бик борынгы шәһәр урыны ул. Әтисе әйтүенчә, борынгы курганнар иле, чөнки анда Туран халкыннан курган һәм каберлекләр генә сакланып калган. Һәм җимерек шәһәр урыннары… Алар Чиләбе шәһәре белән ике арада, көньякка таба

350—400 чакрым җирләргә таралып ятканнар… Әтисенең әйтүенчә, курган «кораган» дигән сүздән алынган икән, ә ул сүз үлгән, корыган дигәнне аңлата, ди… Курган — корган, татарча — корып, өеп куйган дигәнне дә аңлатырга мөмкин икән… «Ни генә булса да, бу курганнарның исеме дә, җисеме дә — татарныкы, барлык төрки, Туран халкыныкы»,— дигән иде аңа этисе, кылганнар үсеп утырган зур яланга аяк басуга.

— Әти, ә нәрсә дигәнне аңлата соң ул — Аркаим? — дип сораган иде ул вакытта аннан Әтил.

— Бу тирәдә Аркаим исемле елгачык агып ята, улым, аның янындагы әнә теге калкулык та Аркаим дип атала,— дип җавап бирде аңа этисе.— Татарда «ар» тамырлы сүзләр күп бит, улым,— аръяк, ягъни аргы як, арка, артыш, арпа сүзләре… Күп инде алар… Татарстанда Арча авылы да бар бит, шагыйрь Тукай бабаң туган як… Төректә «аркадаш» сүзе бар — дус, иптәш дигәнне аңлата. Бу Аркаим сүзе дә аръякта яшәүче бер кавем аркадашлар мәгънәсен аңлатырга мөмкин…

Менә алар, шулай сөйләшеп, борынгы Аркаим үзәнлегенә килеп керделәр…

Үзәнлекне урап, Караган елгасы агып ята, аңа әллә кайдан, курганнар артыннан гына Үтәгән елгасы килеп кушыла… Су буенда, дымлы урыннарда гына агачлар шаулап утыра, ә калган җирләрдә — кылганлы дала… Үзе биеклеге кылганнар арасыннан йөгергән Әтил, сөрлеккәндәй, кинәт туктап калды һәм үзәнне яңгыратып кычкырып җибәрде:

— Әти! Әти! Кил әле тизрәк! Монда бер таш кеше басып тора!

Әтисе ашыгып аның янына килде. Ул кылганнар арасыннан кырыс кына аларга карап торган таш сынның башыннан сыйпап куйды. Әтил шунда гына игътибар итте: бу таш кеше яртылаш кына иде, ягъни аның аяклары юк, гәүдәсенең өске өлеше генә җирдән калкып тора…

— Төрки таш балбал ул, улым,— диде этисе, аның янына чүгәләп.— Аны әле теге елларда без, студентлар, Караган суы буеннан казып чыгарган идек. Дөньяның төрки халыклар яшәгән бөтен җирләрендә дә бар алар — Саян тауларында — Тувада да, монгол чүлләрендә дә, Кытай җирләрендә дә, казах-кыргыз далаларында да, Идел — Урал арасында да, хәтта Богырысланда — Ырынбур якларында да…

— Әти, кем соң ул, нәрсә тоткан ул кулына?

— Анысы — касә, ягъни ант савыты… Шуннан ак сөт эчеп, борынгы төркиләр Күк Тәңресе каршында ант итә торган булганнар. Алар ул вакытта ук бер Аллага — Күк Тәңресенә табынганнар. Шул хакта менә ташларга да уеп калдырганнар… Безнең борынгы бабаларыбыз менә шундый булган…

Әтил бу таш кешегә тагы да текәлеп карады. Чыннан да, аның йөзе Атасалдагы авыл картларына охшаган иде — бергә кушылып үскән куе кашлар, озын, туры борын, куе мыеклар, таза, әмма бик үк җәелеп китмәгән кырыс йөз, нык ияк, арка белән тоташкан гайрәтле муен, киң күкрәкләр… Аның Җиһангир бабасы да менә шундыйрак бит, ул Әтилнең этисенә дә охшаган бераз…

Таш балбалга борылып карый-карый, Әтил Аркаим үзәнлеге буйлап атлады. Менә алар җир астына кертеп салынган бер алачык янына килеп җиттеләр. Юк, бу — өстенә балчык өелгән кабер-курган икән, кешеләргә карарга җайлы булсын өчен, аның авызын ачып, алачык рәвешенә китергәннәр, ишегенә тимер рәшәткә куйганнар. Әтил рәшәткә аша эчкә карады һәм сискәнеп китте: каберлектә, чын кешеләр кебек киенеп, ике сын ята иде… Үзләре озыннар, берсе — ир-ат, икенчесе — хатын-кыз, ахры, өс-башлары нәкъ Атасалда олылар кунакка кия торган кием кебек… Хатын-кызында — олылап, маңгайга төшереп бәйләгән зур кызыл яулык, изү-итәкләре кара һәм сары ефәк белән чигелгән озын кызыл күлмәк… Аның өстеннән озын каракучкыл җилән кидергәннәр, җиләннең изү һәм җиң очлары алтын белән чигелгән, ул әллә кайдан ялтырап, күренеп тора… Хатын-кызның аягында күннән тегелгән үкчәсез көрән читекләр, янында — ук салынган садак-савыт… Ир-ат сакал-мыектан, ул бераз җирән төстә дә кебек… Аның чәчләре озын, җилкәләренә тиеп тора… Чәчләре кара да түгел, сары да түгел — көрәнсу-җирән төстә… Алар маңгайдагы кызыл тасма белән бәйләп куелган… Ир-атның өстендә — чия төсендәге билдән тун, җиңел тунның изүләренә, итәк очларына ак җәнлек тиресе тотылган… Ул озын ыштаннан, аякларында — күн читек, читек кырыйларына тиредән кайма тотылган… Ир-атның кырыенда — үзе озынлыгы тимер башлы сөңге… Икесенең дә аяк очларында балчык чүлмәк куелган… Әйтерсең лә алар авыр сугыштан соң хәл алырга ятканнар һәм… мәңгегә ятып калганнар…

— Әти, кемнәр соң алар? — дип сорады Әтил, нишләптер пышылдап кына.

— Бу — «Курган Тимер» дип атала, улым, ул фәнгә шулай кергән инде… Ә безнеңчә, татарча — Тимер курганы була… Яңа эрага хәтле VI—V гасырларда яшәгән кешеләр күмелгән монда, ягъни моннан 2500 ел элек яшәгән төркиләр… Күрәсеңме өс-башларын — нәкъ безнең халыктагы кебек…

— Чынмы соң ул әйберләр? — дип сорап куйды Әтил, ышанырга да, ышанмаска да белмичә.

— Аларның өс-башлары да, сөңге-уклары да, хәтта чәч, сакал-мыек төкләре дә бередәге курган-каберлекләрдән табылды, улым,— диде этисе, аңа җентекләп аңлатып.— Алар өйрәнелеп, яңадан

торгызылды… Ягъни шул борынгы әйберләрнең төгәл күчермәсе эшләнде… Гәүдәләре дә каберлекләрдәге гәүдә рәвешендә эшләнде: озынлыклары, йөз төзелешләре, аяк-куллары — барысы да төгәл торгызылды… Аның үз галимнәре бар инде, улым, алар еллар буе берәмтекләп җыялар андый әйберләрне. Һәм нәтиҗәдә, тарихның үзен терелтеп, яңадан кешеләргә күрсәтәләр…

Янәшәдә генә тагы шул курганга, төрбә-шалашка да охшаган бер алачык бар иде — әтисе Әтилне шунда таба алып китте. Анысының эченә дә керергә ярый икән — чыпта ишекне читкә этеп, алар җир идәнгә аяк бастылар. Бу — бик борынгы, таш гасырларда ук яшәгән кешеләрнең өе икән, алар биредә моннан 5—6 мең ел элек үк яшәгәннәр. Өйнең төзелеше тыштан да, эчтән дә бик сәер, бераз гына казахларның тирмәсен дә хәтерләтә кебек… Тыштан караганда, ул балчыктан эшләнгән кебек, әмма эчкә кергәч, түгәрәк өйнең агач бүрәнәләрдән гөмбәз кебек өелгәнлеген күрәсең. Һәм шуның өстенә, җирдән кисеп алып, кәс түшәлгән. Уртада, нәкъ түбә турында, тишек бар, ул төтен чыгу өчен эшләнгән, бәлки якты да шуннан төшкәндер… Җир өйгә өсте ябык лапас аша узасың…

— Менә монда, урта бер җирдә, учак булган, улым,— дип сөйләвен дәвам итте әтисе.— Кырый-кырыйда — йоклау өчен сәкеләр, көндез бәлки шунда утырып ашаганнардыр да… Биредә шулай ук таштан корал да ясаганнар, тире, сөяк эшкәрткәннәр…

Бу салкын җир өй Әтилдә сәер тәэсир калдырды. Әллә нинди шыксыз, җансыз, хәтта мескен булып күренде ул аңа. Монда ничек яшәргә мөмкин? Борынгы халыклар барысы да шундый җир өйләрдә яшәгәнме? Әтисе еш кына: «Без дәүләтләр, илләр тоткан халык, безнең шәһәрләребез, ханнарыбыз, күп санлы гаскәрләребез булган»,— дип сөйли иде… Нәрсә, ханнар да шундый өйдә торганмы?

— И-и әти, бигрәк хәерче бит бу өй! — диде ул турыдан-туры.— Безнең бөтен бабайлар да шулай яшәгәнме? Син бит биредә Калалар иле булган дигән идең?..

Алар җир өйдән яктыга, урамга чыктылар. Кылган башларын чайкалдырып, казах далаларыннан кыйбла җиле исә, үлән арасында мең төрле бөҗәк-корт яшәп ята иде… Каршыда берничә курган-тау, калкулыклар гына, барысыннан да аерылып, җир өстеннән калкып күренеп тора иде…

— Ә-ә-нә анда, Чиләбегә таба 400 чакрым арада, йөзләгән борынгы шәһәр урыны табылды, улым,— диде әтисе, кулы белән төньякка күрсәтеп.— Кайберләрен казуда студент чакта мин үзем дә катнаштым. Бу урыннар тарих фәнендә, хаклы рәвештә, Калалар иле дип атап йөртелә… Без әле генә кереп чыккан җир өй — ул бер модель генә, бу тирәдә яшәгән берәр кавемнең кайсыдыр чорда яшәп киткән куышы… Ә безнең бабайлар, нигездә, түгәрәк таш шәһәрләрдә яшәгәннәр… Хәзер мин сине шул борынгы шәһәрлек урынына алып барам…

Әтисе аны бер читтәрәк казу эшләре алып барган кешеләр янына алып китте. Алар биредә эшләүче студентлар һәм галимнәр булып чыкты, араларында Әтилнең әтисен танучылар да бар икән. Алар белән күрешеп хәл белешкәннән соң, Әтилләр казылган рәтләр буйлап киттеләр. Шул чакта гына Әтил бу рәтләрнең кат-кат боҗра ясап урнашуларын аңлап алды. Әйе, бу — түгәрәк шәһәр иде, йортлар да оя-оя булып, түгәрәкләнеп, шушы боҗра эченә урнашканнар…

— Фәнни анализларның күрсәтүе буенча, бу калада моннан 4 мең ел элек кешеләр яшәгән,— дигән иде аңа әтисе.— Бу шәһәр биеклеге 4 метрдан да ким булмаган ике кат стена белән уратып алынган булган. Эчтәге йортлар да түгәрәк ясап, күч-күч булып урнашкан, һәм барысы да үзәк мәйданга чыккан… Түгәрәк өйләрнең түбәләреннән яңгыр да шушы мәйданга аккан… Кирәк вакытта, бигрәк тә сугыш-яу вакытларында, халык өй түбәләреннән торып сугышкан… Бишәр метрлы калын кирпеч стеналар, су тулы канаулар аша дошман берничек тә шәһәргә керә алмаган, ә эчтәге халыкка Аркаим-нан тышка чыгып тору кирәк булмаган…

— Ә ашарга, эчәргә кайдан алганнар? — дип сораган иде Әтил шул чакта.

— Һәр торак йортның эчендә коелар, азык базлары булган. Шунысы гаҗәп: ул коелар мич белән тоташкан булганнар… Һәр өйдә үз заманы өчен канализация дә булган, кирәкмәс сулар тирән каналлар аша шәһәр стенасының тышына чыгарылган. Әлбәттә, алар гел шәһәр эченә генә бикләнеп яшәмәгән-нәр, бу сугыш вакытында гына шулай булган. Яу булмаганда, Аркаим халкы шәһәр тышында көтүлекләр дә, иген кырлары да тоткан. Алар азыкны эшкәртеп, шәһәр эчендәге тирән базларда саклаганнар… Без биредә аларны да күп таптык…

— Ә биредә күп кеше яшәгәнме соң?

— Менә күрәсеңме — йорт-оялар урыны? Шуның һәрберсендә 30—50 кеше яшәгән булырга тиеш, ягъни зур бер гаилә… Биредә менә шундый алтмышлап йорт урыны ачыкланды, әле казылмаганы күпме… Кара исәп белән генә дә, биредә 3 меңләп кеше яшәгән булып чыга… Ул заманнар өчен бик күп инде бу… Әйткәнемчә, мондый шәһәрлекләр бу тирәдә йөздән артык… Шуннан биредә күпме кеше яшәгәнен чамаларга була инде — Урал тавының менә бу ягында гына да ярты миллионга якын кеше яшәгән… Шунысы гаҗәп: алар ул чакта ук тимер кою серен белгәннәр, бакыр эреткәннәр, Урал

тауларының таш-тимереннән эш һәм сугыш кораллары ясаганнар… Алар көчле, бик көчле халык булган, улым…

— Ул чагында нигә моннан киттеләр икән соң алар? Аларны кем җиңгән икән? — дип сорады Әтил.

Әтисе шактый вакыт дәшми торды. Аннан җирдә яткан чүлмәк кисәкләрен кулына алып, озак кына уйланып торды.

— Боларга хәзергә тарихта җавап юк, улым,— диде ул.— Чөнки бу хәлләр бик борынгы заманнарда — фиргавеннәр чорында ук булган бит… Галимнәрнең әйтүенчә, биредә нindидер табигать бәла-казасы булган булырга мөмкин… Ә-ә-әнә теге соры тауны күрәсеңме?

Әтил ул күрсәткән якка борылып карады. Анда сөзәк, әмма бу тирәләр өчен шактый биек, түгәрәк башлы бер тау калкып тора иде. Анда таба кешеләр төркеме сузылган, алар тау түбәсендә дә нидер эшлиләр иде…

— Әнә шул тауны җир астыннан вулкан атканнан соң барлыкка килгән, дип сөйлиләр… Бәлки, кешеләр шул бәла буласын сизеп, йорт-җирләрен ташлап, бу урыннардан китеп барганнардыр? Бәлки, берәр яман чир аларны бу урыннардан кугандыр… Зур сугышлар нәтиҗәсендә халыкның моннан качуы бар… Әле монда күп нәрсәләр өйрәнелмәгән, ачыкланмаган, улым… Монда әле эш сезнең буынга да кала…

— Әти, ул кешеләр нишләп бөтенесе шул тауга таба баралар, әйдә, без дә меник әле? — дип сорады Әтил, соры тауга күрсәтеп.

— Алар һич кирәкмәгәнне эшләп йөриләр, улым,— диде әтисе, ул якка карап.— Кемдер, кайчандыр хәбәр тараткан, имеш, шул Шаман тавы башыннан җиһанга чыгып була икән… Күңелең белән инде… Имеш, шушы тау түбәсендә җирнең үзәге икән… Менә кешеләр хәзер шул тау башына менеп, җиде тапкыр әйләнеп, үзләренә кирәк нәрсәне сорап йөриләр… Барысы да нindидер могҗиза көтә… Тилелек инде бу, әлбәттә… Могҗиза ул — тарих өчен сакланып калган менә шушы шәһәр урыннары инде, болардан гыйбрәт алырга кирәк тә… Әйдә, тауның гаебе юк, без дә менеп төшик, аннан бу үзәнлек, тирә-юнь бик матур күренә…

Әтил тауга таба әтисеннән дә алда торып йөгерде. Аннан арыды. Аннан тагы йөгерде. Тауның яртысына җитәрәк, бөтенләй арып, туктап ук калды, бер зур таш өстенә килеп утырды… Аның яныннан, төркем-төркем булып, кешеләр аска-өскә менеп-төшеп тордылар… Әтисе килеп җиткәч, Әтил аның кулларына тотынды. Шулай җитәкләшеп, тау башына менеп җиттеләр…

Шаман тавы такыр гына түбәле бер тау икән… Анда җир тигез, агач та үсми, чокыр-чакыр да юк… Тау түбәсендә вак ак ташлардан җиде кат божра ясаганнар… Һәм кешеләр бик җитди кыяфәттә шуның тирәсендә әйләнеп йөриләр… Тирә-якта аунап яткан ташларга әллә нинди кызыллы-яшелле чүпрәкләр бәйләп куйганнар… Кемдер, кулларын күккә күтәреп, нидер пышылдый, сорый, кайсылары аяк астына карап кына йөри…

— Улым, кил, аска кара,— дип чакырып алды аны әтисе.— Күрәсеңме анда нинди матурлык? Менә кайда ул могҗиза, үзең тезгән ташлар тирәсендә әйләнеп йөрүдә түгел…

Әтил, әтисе янына йөгереп килеп, аска карады. Ә анда, ерак офыкларга барып терәлгәнче, иксез-чиксез дала җәелеп ята иде… Ул даланың бер читеннән Карагай елгасы телеп үтә… Аста, кечкенә генә булып, Курган Тимер, борынгы кешеләрнең җир алачыклары күренеп тора, рәт-рәт казылган шәһәрлек стеналары буенда кешеләр кыймылдый… Ә теге таш балбал бөтенләй күренми дә, ул кылганнар арасында күмелеп үк калган…

Әтилнең шушы тау түбәсеннән, кош кебек очып, аска төшәсе килде, күргәннәреннән шулхәтле хисләнгән, дәртләнгән иде ул… Аның да җиде кат җир астына төшеп, җиде кат күккә менеп, әллә нәрсәләр беләсе килеп китте.

— Әти, әйдә без дә тау түбәсендә әйләник әле, минем дә әллә нәрсәләр беләсем килә,— диде ул, әтисен түгәрәк янына тартып.— Мин дә анда теләк теләр идем…

— Ярамый, улым,— диде әтисе, кырт кисеп.— Теләгәнеңне Аллаһтан сорарсың, кайтышлый Субай мәчетенә керербез…

Аннан, бераз йомшарып, Әтилгә иплəп кенә аңлата башлады:

— Бу рәвешле җиде тапкыр әйләнеп, теләк теләү Кәгъбәтулла янында гына рөхсәт ителгән, улым,— диде ул, башкалар да ишетерлек итеп.— Калган җирләрдә болай эшләү гөнаһ санала, Аллага тиңдәшлек китерү булып исәпләнә… Кеше, тәртибе белән намаз укып, Аллаһтан сорыйсы урында, шушы тауларга, чишмәләргә килеп, әллә нинди «ияләрдән», «хуҗалардан» ярдәм көтеп йөри… Бу тауларны, бу чишмәләрне, бу дөньяның үзен дә Аллаһ барлыкка китергән бит, алар Ул яшәтсә генә яши алалар… Димәк, ярдәмне дә Аллаһтан гына сорарга кирәк, теләкне дә Аның ризалыгы өчен теләргә… Югыйсә Аллаһның зур җәзалар бирүе бар…

Ташлар тирәли әйләнеп йөргән кешеләрнең кайберләре, сәерсенеп, аларга карап алды, кайберләре куркып, туктап калды, сихерле боҗрадан тизрәк чыгарга ашыкты… Күпчелек исә исерекләр кебек әйләнүләрен дәвам итте… Алар, үз аяклары белән, үзләренә әзерләнгән утлы җәһәннәмгә таба баралар иде…

Аска төшкәч, этисе аны музейга алып кереп китте. Менә шунда аның биредә эшләүчеләр белән бәхәсе, бәрелеше килеп чыкты инде...

Сүз дә юк, музей бик кызыклы эшләнгән иде. Биредәге балчыктан ясалган, кое белән тоташкан өч авызлы мичләрне күреп, Әтил шаккатты... Аларның кайсы мич авызы икәнлеген ул барыбер аңлый алмады… Киштәләргә — кечкенәрәк, идәннәргә зур-зур балчык чүлмәкләр куелган, аларның кайберләренә хәтта Әтил дә кереп утырырлык… Шунда ук тимер сөңге башлары, сөяктән кырып ясалган эш кораллары, төрле ташлардан эшләнгән бизәнү әйберләре, сәйләннәр тезелеп ята… Бер почмактан ниндидер хайванның галәмәт зур мөгезләре карап тора… Әмма Әтилне иң гаҗәпләндергәне һәм куркытканы бөгәрләнеп яткан кеше сөякләре — скелеты булды… Ул яны белән яткан, баш сөяге сап-сары, шоп-шома, авызында бөтен тешләре сакланган… Умыртка баганасы, кабыргалары, кул-аяк сөякләре — барысы да ап-ак булып сакланган… Бу озын кеше аягүрә торып басар да, сөякләрен шалтыратып, Аркаим буйлап йөреп китәр кебек… Үзенең өй-оясын, кавемен, якыннарын эзләп…

Ул арада музей кешеләр белән тулды. Тау башындагылар да бирегә төшеп, авызларын ачып, бу шыр сөякләрне карап йөрергә керештеләр. Музейда эшләүче рус хатыны, аларның һәрберсе янына килеп, таягын болгый-болгый озаклап аңлата башлады.

— Биредә моннан 4—5 мең еллар элек борынгы индоевропалы индоиран халкы, ягъни ариецлар яшәгән,— дип сөйли башлады ул, эчке бер горурлык белән.— Бу хакта индоиран язмаларында, аларның «Авеста» дип аталган дастаннарында хәбәр ителгән… Моңа кадәр аларның борынгы илләре кайда икәнлекләрен белмиләр иде, менә хәзер, Аркаимны казып ачкач, барысы да аңлашылды инде — алар биредә яшәгәннәр икән бит, бу җирләр — фарсы, һинд телле индоевропеец, индоиран халкы җирләре булган… Алар биредә дәүләтләр тотканнар, зур калалар салып яшәгәннәр…

Шул чакта бер читтән, күк күкрәгән кебек, көчле, дәһшәтле аваз яңгырады:

— Ә төрки халыкларны кая куясыз? Биредә мәңгелектән яшәгән татарларны кая куясыз?

Бу — Әтилнең этисе иде, төркем каршына чыгып басып, ул үзенең 2 метрлы биеклегеннән шул сорауны бирде. Музейда эшләүче хатын моны көтмәгән иде, ул башта югалып, куркыбрак калды, аннан тиз генә үзен кулга алып, кабаланып сөйли башлады.

— Төркиләр бирегә соңрак килеп урнашканнар, татарлар исә иң соңыннан килгән… Алар яки бу җирләрне басып алганнар, яки мал йөртергә урын эзләп килеп урнашканнар… Сез борчылмагыз, монда төрки халыклар почмагы да бар… Менә, рәхим итегез — татарларның чиккән сөлгесе, сукыр лампасы, юкәдән үргән чабаталар… Без боларны бу тирәдәге татар авылларыннан үзебез җыйдык…

Әмма Әтилнең этисен моның белән генә алдап булмый иде.

— Гафу итегез, мин югары белемле тарихчы,— диде ул, барысы да аңларлык саф рус телендә.— Һәм мин борынгы татарлардан чиккән сөлге белән чабата гына калмаганлыгын бик яхшы беләм… Бу җирләрнең борынгы төрки, һун, скиф бабаларыбыз җирләре — Татар иле булганлыгын да бик яхшы беләм мин… Борынгы Аркаим шәһәренең дә саф төрки-татар цивилизациясе ядкаре икәнлеген мин беләм, чөнки бу шәһәрне җир астыннан казып чыгаруда мин үзем дә катнаштым, андагы һәр табылдыкка төрки тамга сугылган иде…

Эш болайга киткәч, марҗа хатын аны тизрәк бүлдерергә ашыкты:

— Әмма Аркаимның индоиран мәдәнияте икәнлеге бөтен дөньяга исбатланды бит инде,— дип, чәчрәп каршы чыкты ул.— Без бу темага халыкара конференцияләр, экспедицияләр үткәрдек, бу хакта йөзләгән фәнни хезмәт, китаплар басылып чыкты. Сез, тарихчы башыгыз белән, ничек шуларны инкарь итә аласыз?! Шаккатырлык хәл!

— Ул чагында, сез исбатларга тырышканча, бу тирәдә йөзләгән шундый шәһәр тоткан индоиран халкы кая киткән соң? — дип, Әтилнең этисе гап-гади сораулар бирә башлады.— Ник бу якларда бүген беркем фарсы телендә дә, һинд телендә дә сөйләшми? Шәһәрләр тотарлык шулхәтле күп санлы халыктан барыбер кемнәрдер монда калырга тиеш иде бит инде? Моңа җавабыгыз юк инде сезнең, әлбәттә… Ә менә безнең җавабыбыз бар. Чөнки бу җирләрдә фарсы телле индоевропалылар түгел, ә Нух пәйгамбәр заманыннан бирле төрки халыклар, шул исәптән татарлар яшәгән… Бәлки сезгә аларның нәкъ менә шушы туфракта тоткан дәүләтләрен дә санап китәргәдер, болар инде тарихта исбатланган нәрсәләр… Рәхим итегез — Бөек Һун каганаты, Бөек Төрки каганаты, Уйгур каганаты, Кимак каганаты, Туран иле, Болгар, Алтын Урда, Нугай Урдасы, Себер, Казан ханлыклары… Аларның барысының да башында төрки-татарлар булган бит, шулаймы? Шулай, ул татарлар монда ил тотканнар, бүген дә биредә яшәп яталар… Биредә инде аларның ил-дәүләтләре булмаса да, алар барыбер монда

авыл-авыл булып, шәһәрләргә урнашып, нәсел-нәсел булып яшәп яталар… Әнә капкагыздан аяк атлап кергәч тә, сезне төрки таш балбал каршы ала, аны мин үзем Карагай суы буеннан казып чыгардым — аны кая куясыз? Бу тирәдә мәңгелектән сакланып калган төрки-татар атамаларын кая куясыз, Карагай һәм Үтәмеш елгаларын, төрки исемдәге Аркаим сүзен, төрки атама йөрткән тауларны кая куясыз? Бирегә килеп җиткәнче юл буе озата барган төрки-татар атамаларын — Яңа Ил, Караболак, Сембер, Ерлыгач, Кондыр, Исмәгыйль авылларын, Ильяс, Кызыл елга исемнәрен кая куясыз? Кайда соң монда фарсылык, кайда соң монда индуслык? Сез бит җирле халыкның тарихын күзгә карап таптыйсыз, талыйсыз, аны читек-чабатага гына кайтарып калдырасыз. Безнең бабаларыбызның сөякләре өстендә шайтан туе ясап ятасыз… Курган башларына менеп, шаманлык кыласыз… Ә анда атлы-арбалары белән күмелгән төрки тарих сыкрап ята бит…

Җыелган халык аны тын да алмыйча тыңлады. Марҗа хатын да чәтелдәвеннән туктады, чөнки аның бу тарихчы татарга каршы әйтерлек бер генә дәлиле дә юк иде.

— Әйдә, улым, чыгабыз,— диде этисе, үз сүзен әйтеп бетергәч.— Безгә үз тарихыбызны торгызырга, үз тарихыбызны күрсәтергә кирәк. Һәм без аны, Алла теләсә, күрсәтербез дә…

Алар, кызу-кызу атлап, Аркаим үзәнлегеннән чыгып киттеләр. Көн бозылып, вак яңгыр сибәли башлаган иде… Яңгыр тамчылары таш балбалның йөзеннән агып төшә дә, күз яшьләре булып, аның касәсенә җыела… Күкрәгеннән кара җиргә баткан таш балбал… Әйтерсең лә чабып өзелгән татар тарихы… Кулына күз яшьле касә тотып, ул дала уртасында бер ялгызы басып калды…

* * *

Журналда Аркаим рәсемен, Атасал шәҗәрәсен күргәч, Әтил менә шул тетрәндергеч вакыйгаларны исенә төшерде… Аркаимдагы таш балбал кебек, ул үзен дә бу дөнья каршында япа-ялгыз итеп хис итте…

Ул арада зал яктан аяк тавышлары, сөйләшкән авазлар ишетелде. Әтил, китап-журналларын бер читкә алып куеп, шунда чыкты. Бабасы белән Сөнгатулла абый икән — кызарышып мунчадан чыгып киләләр. Хәтта Сөнгатулла абыйга да бераз төс кереп киткән, битләре алсуланып тора.

— Әни миңа Коткар елгасыннан махсус су тота бит,— диде ул. Әтилнең аптырап үзенә карап торуын күреп.— Баштау түбәсеннән әле эчәргә дә алып кайталар… Әни карчык могҗизаларга ышана инде ул безнең…

— Дөрес эшли Бәндәбикә апа,— диде Җиһангир карт.— Табигать ярдәм итә икән, дарулар белән бик мавыкмаска кирәк… Иң мөһиме: өметне өзмәскә, энекәш, өметне өзмәскә кирәк, Аллаһтан сорарга…

Өйгә, орчыктай бөтерелеп, Рәхимә килен килеп керде. Ул мунчаны карап йөргән, ахры, битләре кызарып чыккан, маңгаендагы тирләре дә кибеп өлгермәгән иде.

— Бар, Әтил энем, юынып чык,— диде ул керә-керешкә.— Менә оныкларның чиста күлмәк-ыштаннары, өстеңдәгене барысын да алыштыр, чистаны ки… Бар, рәхәтләнеп юын, чабын, сезгә шәһәрдә бик эләкмидер мондый мунчалар… Ярдәм кирәк булса, Рәхмәтулла абыеңны кертермен. Кертимме?

— Юк, кирәк түгел,— диде Әтил, уңайсызланып.— Мин үзем генә юынам…

Рәхимә апасы әзерләп биргән чиста күлмәк-ыштаннарны алып, Әтил бакча башындагы мунчага йөгерде. Аның тәненә дә, җанына да бераз ял, бу туктаусыз уйланулардан арынып тору кирәк иде… Яңадан балалыгына, малайлыгына кайту кирәк иде… Җылы җир буенча яланаяклап тар сукмактан йөгергәндә, ул инде яңадан Әтил-малайга әйләнеп калган иде… Аңа бәрәңге бакчасы өстендә гөжләп очып йөргән бал кортлары да, юлын аркылы сикереп үткән бака балалары да, тал башында каркылдап утырган кара каргалар да гаҗәеп кызыклы булып тоелды… Авыл, бигрәк тә аның табигате бөтенләй үзгә бер дөнья булып яшәп ята иде… Бер мизгелгә булса да, Әтил шушы табигать, тал-тирәкләр, бал кортлары, бака малайлары белән кушылып киткән кебек булды… Алдан-арттан кисәтеп торган зур дөнья беразга чигенеп торды, Әтил-малайга балачагында яшәп калырга рөхсәт итте…

Бәндәбикә карчык кунарга кыстаса да, мунча чыгып, чәйләр эчкәч, тавык шулпасын ашап куйгач, Җиһангир карт кайтырга булды. Бирeдән Аксуга күп булса 50—60 чакрым булыр, җәйге көн озын, әле караңгы төшкәнче кайтып җитәргә дә була иде. Биргән күчтәнәчләрен алып, кочаклашып саубуллашканнан соң, юлга кузгалдылар… Бәндәбикә карчык аларны тагы килергә кат-кат кыстап калды. Карт белән малай вәгъдә бирделәр. Әмма Әтил үзенең бирегә башка беркайчан да килмәячәген, ә Җиһангир картның нәкъ бер тәүлектән яңадан монда буласын белмиләр иде әле алар…

Алар юлга чыкканда, көн эссесе инде тәмам сүрелгән, кояш та, Баштау артына кереп, качам-качам дип тора иде… Әтил, борыла-борыла, инде җанга якын булып өлгергән Каһарман авылына карады. Оя-оя булып, кочаклашып утырган өйләр инде аңа сәер тоелмады, ул аларда Аркаимнардан башланган татар тарихының дәвамын күрде. Урал аръягы булган Аркаимда һәм Атасалда да нәкъ шундый өйләр

иде, Баштау буйларында да шундый ук күренеш… Әнә юлларына Коткар елгасы сикереп чыкты… Ул Каһарман авылы башында Агыйдел кочагына ташланып, үзенең шифалы сулары белән аны да терелтергә, тергезергә омтылыр, әмма ярты дөньяның керен үзенә җыйган Агыйдел инде яңадан ак суга әйләнә алмас… Тау араларындагы үзәнлекләргә кысыла-кысыла, үзенең ярларына салынган зур шәһәрләрнең бөтен пычрагын төяп, атом заводларының агулы радиациясен үзенә алып, Агыйдел суы ага торыр. Менә Әтилләр дә аны берничә тапкыр кисеп чыктылар инде, ә ул, алардан аерылырга теләмәгәндәй, һаман каршыларына килә дә чыга, килә дә чыга… Әтисе белән теге вакытларда Агыйдел буйларында йөргәндә, ул Әтилгә гел бер шигырь юллары укый иде, ул моннан мең ел элек язылган булган икән.

Әтил суы ака торур,
Кыя төбен кака торур…

«Идел суы ага торыр, кыя төбен кага торыр…» Мең ел элек тә Идел-Агыйдел шулай агып яткан, бүген дә шулай… Моннан биш ел элек әтисе Әтилгә шушыларны күрсәтеп, сөйләп йөргән иде бит… Менә бүген Идел бар, Әтил бар, ә әтисе — юк… Әллә бабасыннан сорап карасынмы икән — Сөнгатулла абый сөйләгәннәр дөресме? Бу хакта бабасы ни уйлый икән?

Әтил бабасына карап алды. Бабасы нигәдер сөйләшми, арыган, ахры… Әллә һаман авыру Сөнгатулла абый турында уйлыймы икән, әллә аның җир астында, атом базында күргәннәрен исенә төшерәме? Әтил дә оныта алмый аның сөйләгәннәрен… Бәлки ул, чыннан да, җир астында Әтилнең әтисен күргәндер? Җанбикә әбисе дә, мәрткә киткәч, аны шушы тау араларында күргән иде бит… Ике кешенең бер үк нәрсәне күрүләре мөмкинме, әгәр ул чынлап та шулай булмаса? Әллә Әтил тәвәккәлләп, бабасыннан сорап карасынмы икән?

— Бабай, Сөнгатулла абый, чыннан да, Ямантау астында әтине күрдеме икән ул?

Җиһангир карт оныгының бу сөйләшүне ишеткәнен белми иде, шуңа күрә, дәшмичә, шактый озак барды. Чөнки ул аңа нәрсә дип җавап бирергә дә белми иде. Тикшертеп кенә карар идең — Таулыга, Ямантауга якын бара торган түгел… Түлгән монда булса, бәлки бик тиз эзенә төшәр иде, мондыйны тикшертергә аның үз юллары бар иде… Кая барып карарга кирәк хәзер бу хәбәр артыннан — милициягәме, военкоматкамы, прокуратурагамы? «Минем улым атом шәһәрендә тоткыннар арасында түгелме?» — дип, кемнән барып сорыйсың? Кем җавап бирсен моңа, ул бит яшерен сер, атом белән бәйле бөтен нәрсә — сер… Җитмәсә, анда чечен тоткыннары, мөселманнар, ди… Аларны анда череп үләргә кerткәннәр инде, аннан исән чыгу мөмкин түгел… Бу сабыйга ничек шуны әйтәсең? Ә ул әнә мөлдерәп җавап көтә…

— Белеп булмый, улым, һич тә белеп булмый,— диде ул, урталыкны сайлап.— Сөнгатулла абыең аның йөзен күрмәгән бит, ә күз буенча гына әйтүе авыр… Тавышын да ишетмәгән… Ул булмаска да мөмкин, шул ук вакытта ул булуы да бар, тормыш бит бу… Хәзер безнең өчен иң мөһиме, улым, атаңның исән булуы, ни әйтсәң дә, бу әле үлде дигән хәбәр түгел… Бәлки әле тикшертеп тә карарбыз, бер юлы табылыр әле…

— Әни белән әбигә әйтәбезме соң, бабай?

— Юк, улым, аларга әйтми торыйк… Хатын-кыз нечкә күңелле бит ул, йөрәкләренә авыр булыр… Бераз белешик әле, бер-бер очы килеп чыкмасмы? Ул тирәдәге бөтен иске танышларны барларга кирәк хәзер, бәлки әле Аксуда да ярдәм итәрдәй кешеләр табылыр… Өметне өзмик әле, улым…

Ләкин алар өйдә үзләрен нәрсә көткәнен, иртәгә үк җыенып Ямантауга чыгып китәргә туры киләсен белмиләр иде әле… Ул арада Аксу юлына борылдылар, олы юл булганлыктан, монда инде машиналар күп иде. Кояш та ул арада Козгын таулары артына кереп югалды… Урал таулары арасына кызыл шәфәкъ таралды… Алда, ясалма утлары, кара төтен чыгарып утырган завод торбалары белән, Аксу шәһәре күренде… Бу шәһәрдә аларны зур кайгы көтеп тора иде…

* * *

Алар Аксуга кайтып кергәндә, Җанбикә карчыкның җаны юк иде инде… Янында ак халат кигән табиб хатын, милиция хезмәткәре басып тора, аяк очында Әтилнең әнисе бөкрәеп утырган. Җиһангир карт кайтып керүгә, алар барысы да җиңел сулап куйдылар, чөнки мәет белән хәл итәсе нәрсәләр шактый иде…

Җиһангир карт керә-керешкә эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алды, өстәл өстендәге көзгегә юнәлде. Карчыкның чынлап үлгәнен белсәләр дә, аңа беркем бернәрсә әйтмәде, картның үзенең инануын көттеләр. Җиһангир карт, элеккечә, түгәрәк көзгене карчыгының борын астына куеп карады, могҗиза көткәндәй, аның парланып чыгуын көтте. Әмма көзге өсте парланмады… Җиһангир карт, иелеп, карчыгының йөрәк тибешен тыңлап карады — йөрәк тибеше ишетелмәде. Аның тез буыннары

йомшарып китте, аягының хәле бетте, ул, лапылдап, карчыгының аяк очына килеп утырды. Шунда килене Сәмәрия дә телгә килде:

— Бүген өйлә намазыннан соң хәле бетеп, ятып торган иде,— диде ул.— Инде икенде намазына да тормагач, борчылып, уята башладым. Уянмады. Тагы мәрткә киткәндер, дип, мин дә күзге куеп карадым. Аннан, куркып, врач чакырттым… Ул, үлгән, диде…

— Әйе, әби үлгән,— диде табиб хатын, аның сүзләрен җөпләп.— Йөрәге авыру булганга охшый, берәр чир белән хисапта тора идеме?

Җиһангир карт баш кына кагып куйды, сүз дәшә алмады. Әйтерсең лә Урал таулары, җимерелеп, өстенә төште… Ул ап-ак булып үлеп яткан карчыгының йөзеннән күзен ала алмады. Бу мизгелләрдә аның күз алдыннан бөтен тормышы үтеп киткән кебек булды — олаеп кына Кушъелганың тыйнак типтәр кызына өйләнүе, беренче балаларының туган бере үлә баруы, ниһаять, инде баласыз калабыз икән, дип торганда, игезәк улларының тууы… Туран белән Түлгәннең капма-каршы тормышы һәм язмышы, алар кайгысыннан карчыгының соңгы вакытта еш авырулары, мәрткә китүләре… Ул менә хәзер генә үзенең ни дәрәҗәдә ятим калганлыгын, ялгызлыгын аңлады… Күзләрен — яшь, күңелен сары сагыш каплады…

— Яру-ярмауны үзегез хәл итәрсез, мин үлгәнлегенә акт төзим,— диде милиционер егет, картны ачы хәсрәт утларыннан өстерәп чыгарып.

Әйе, Җанбикә карчыкны соңгы юлга озату тулысынча Җиһангир карт өстендә иде. Аның хәзер хәсрәтләнеп, йомшарып утырырга вакыты да, хакы да юк.

— Яру турында сүз дә була алмый — без мөселманнар,— диде ул, кырыс итеп.— Ул йөрәк авыруы белән больницада хисапта тора иде, бу хакта анда беләләр…

— Бабай, алайса, күмү өчен иртәгә шулардан белешмә алырсыз,— диде табиб хатын.— Әби хисапта торган булса, алар аны ярып азапланмаслар… Калганын үзегез хәл итәрсез…

Язасы кәгазьләрен язып, алар чыгып киттеләр…

Җанбикә карчыкның мәете инде соңгы төнен чыгарга үз өендә ятып калды…

Җиһангир карт кече якка кереп, ахшам намазын укып алды. Аннан килене һәм оныгы ярдәмендә, карчыкны кыйбла якка борып куйдылар, өстенә юка пәрдә яптылар. Сәмәрия тәрәзәләрне ачып җибәрде, кайнанасының үлемтекләрен барлый башлады. Әтил, нишләргә белмичә, озак кына әбисе янында утырды. Ул әбисенең үлгәненә әле һаман ышанып бетми иде, менә теге вакыттагы кебек уяныр да мәрттә күргәннәрен сөйли башлар кебек тоелды ул аңа… Шул вакытта тагы Әтилнең ярдәме кирәк булса? Ул ак җәймә астына кулын тыгып, әбисенең кулын эзләп тапты. Кул салкын һәм җансыз иде, Әтилнең кысып-кысып каравына кыймылдамады да, җавап та бирмәде…

Җиһангир карт мәчеткә кереп, мәет юуучыларны белешергә, күмү өчен кирәк-ярагын хәстәрләп куярга булды. Әмма бу эшләр алдыннан аның килене һәм оныгы белән киңәшеп алыр нәрсәсе бар иде. Ул — Җанбикә карчыкны кайда күмү мәсьәләсе. Җанбикә карчыкның әйтеп калдырган васыяте буенча, аны туган авылы Кушъелгага алып кайтып күмәргә кирәк. Әмма анда кереп булмый, ул — ябык атом зонасы. Аксуда исә татар зираты бөтенләй юк, урысын-татарын бергә күмәләр… Күп кеше, мөселман зираты эзләп, тирә-күрше татар авылларына китә. Җанбикә карчык мәете белән нишләргә?

— Килен, күмү мәсьәләсен нишләтербез икән соң? — диде ул, алар белән дә киңәшергә уйлап.— Җанбикә мәрхүмә үзе исән вакытта Кушъелгага алып кайтып күмәргә васыять иткән иде. Ә анда, үзегез беләсез, кертмиләр… Монда татар зираты юк…

Сәмәрия дә уйга калды. Мөселман тәртибе буенча, иртәгә мәетне күмәргә кирәк. Бу эсседә аны өйдә яткырып, урын эзләп йөреп булмый. Ә күмәргә урын юк… Хәер, аны Атасалга да, Каһарманга да алып кайтып күмеп булыр иде, әмма кайнанасының васыяте бар бит — ул үзен туган авылы зиратына күмәргә кушкан…

— Әткәй, әллә иртәгә Аксуда бераз артыннан йөреп карыйсыңмы? — диде ул.— Туган авылына алып кайтып күмәргә бәлки рөхсәт бирерләр? Мәет бит инде ул, аннан атом каласы өчен бернинди дә куркыныч юк…

— Шулаен ул шулай да, килен…

Җиһангир карт тагы уйга калды. «Әйе, иртәнге якта йөреп карарга кирәк,— дип уйлады ул.— Бу бит инде шундый очрак… Органнарда да бөтенләй имансыз кешеләр утырмыйдыр… Бер дә булмаса, Атасалга алып кайтып китәр…»

— Ярар, килен, шулай итеп карарбыз,— диде карт, катгый бер карарга килеп.— Иртәгә иртәнге якта йөреп карармын, булмаса, Атасалга алып кайтып китәрбез…

Шулай диде дә, ул мәчеткә кереп китте. Бераздан өйгә тирә-яктан күрше хатыннары җыела башлады. Биредә гадәт шундый: берәрсе үлсә, төне буе аның янында утырып, зекер әйтеп чыгалар… Апалар шыпырт кына мәет тирәли тезелеп утырдылар, авыл өенә моңлы һәм бераз шомлы зекер һәм

тәхлил авазлары таралды. Бу хәл исә фаҗигане тагы да көчәйтеп, үлем ачысын тагы да зурайтып, бәгырьләрне тагы да нечкәртеп, чарасыз итеп калдырды… Җанбикә карчык үз өендә, якыннары, күрше-тирәсе белән берлектә, соңгы төнен үткәрә иде…

Әтил башын түбән иеп, әтисе бүлмәсенә кереп китте. Бу аның үз гомерендә беренче үлем күрүе иде. Ул нишләргә дә белмәде, аның әбисе өчен, теге апалар кебек, дога кыласы килде, әмма ул берни дә белми иде. Ул үзенең моңа кадәр ваемсыз йөрүенә, әби-бабасыннан бер дога да өйрәнмәвенә үкенде. Әтил дә менә хәзер, теге яктагы әбиләр кебек, дога кылып, күңелен тынычландырыр иде… Әбисенең рухы да шатланыр иде…

Юк, Әтил күңеле белән барыбер әбисенең үлеменә ышанмады. Ниндидер бер могҗиза булыр да, әбисе күзләрен ачыр кебек тоелды аңа… Аның бит инде әллә ничә тапкыр шулай булган — үлеп беткәч, яңадан терелгән… Әтил чын күңеленнән ышана: бу юлы да әбисе тереләчәк, бөтенесен шаккатырып, яңадан сөйли башлаячак әле… Бу юлы әбисе мәрткә киткәндә ни күрер икән? Әлбәттә, аның әтисен күрәчәк! Ничек итеп әбисенә тизрәк уянырга ярдәм итәргә соң? Әлбәттә, дога белән, бары тик дога белән! Әмма кайдан алырга ул доганы? Тукта, Әтил бит аны яттан белмәсә, китаптан да укый ала…

Ул тиз-тиз генә өстәлдә өелеп яткан китапларны актара башлады. Шул чакта, могҗиза булып, аның күзенә кечкенә генә бер китап чалынды. Китап «Кыска догалар» дип атала һәм бүгенге хәрефләр белән, татар телендә язылган иде! Әтил аны ашыгып актара башлады. Әбисен үлем йокысыннан уятырлык догалар кайда икән соң? Монда барысы да бар кебек: кеше тугач һәм үлгәч укый торган догалар, кайгы яки шатлык вакытында, авырганда, авыр хәлдә калганда укый торган догалар, рәхмәт догалары, ризык һәм су өчен, биргән гомер өчен шөкерана догалары… Әмма ул мәрткә киткән кешене уятыр өчен дога эзләп таба алмады… Эзләп-эзләп тә кирәген таба алмагач, Әтил беренче очраган доганы көйләп, пышылдап укый башлады…

«И Раббым, бу гомерне бирүче дә, алучы да — Син! Безне бәхетле итүче дә, гамәлебезгә күрә, бәхетсезлекләр бирүче дә — Син! Теләсәң — ризыкландырасың, теләсәң — ач тотасың, теләсәң — саулык һәм байлык бирәсең, теләсәң — барысын да бер мизгелдә кире ала аласың… И Раббым, Син безгә файдалану өчен иксез-чиксез җирләр, киң ризыклар бирдең, камил тән һәм җан бирдең, акыл бирдең, инде иманыбызны да ныгытырга ярдәм ит! Бу дөньяда Син өйрәткәнчә дөрес итеп яшәргә, ахирәт көнендә каршыңа да мөэмин-мөселман булып барып басарга насыйп ит! И Раббым, безне кабер газапларыннан сакла, безгә җәннәт бәхетләре насыйп ит!»

Һәм шушы теләкләрдән соң, менә бу дога укыла икән:

«Раббәнә әтинә фид-дүнйә хәсәнәтәү вә фил-әхирати хәсәнәтәү вә кыйнә гәзәбән-нәр».

Мәгънәсе дә язылган:

«Әй Раббыбыз, безгә дөньяда да, ахирәттә дә изге нигъмәтләр бир. Вә безне җәһәннәм газабыннан сакла».

Әтил, җентекләп, хәрефләп, шушы доганың гарәпчәсен укый, ятлый башлады. Шушыны өйрәнсә, аңа әбисе яңадан терелер кебек тоелды. Әгәр терелми икән, аның җаны барыбер бу доганы ишетергә тиеш… Ул бит хәзер бу йортта әбисенең нәселен, динен дәвам итәрлек бердәнбер кеше… Ул хәзер әбисе өчен дә, әтисе өчен дә, үзе өчен дә дога кылырга тиеш… «Раббәнә» догасын ятлау аңа авыр да тоелмады, чөнки ул бабасының, һәр намаздан соң, кычкырып шуны укып куюын исенә төшерде. Әйе, бу аңа таныш сүзләр иде… Һәм, төн чыкканчы, Әтил аны һичшиксез ятлап бетерергә тиеш… Әтил могҗизага ышана иде: ул бу доганы укыгач, я аның әбисе, элеккеге кебек, күзләрен ача, я аның җаны башка нәрсә турында хәбәр бирә…

Бу көннәрдә берсе өстенә икенчесе өелеп килгән вакыйгалар, хәбәрләр, тетрәнүләр Әтилнең җанын һәм тәнен басты, дога сүзләре дә күз алдында бер таралдылар, бер җыелдылар, авырайган күз кабаклары бер ачылдылар, бер ябылдылар… Каршында кинәт кенә кабынып киткән көчле яктылыкка түзә алмыйча, ул чытырдатып күзләрен йомды. Аннан яктылык акрынлап тарала барды һәм бүлмәгә искиткеч хуш ис таралды… Әтил, гаҗәпләнеп, тирә-якка карады: өй эче әллә нинди сәер затлар белән тулган иде… Аларның йөзләре кояш кебек балкып тора, кул-канатларында дөньяда тиңе булмаган хуш исле ап-ак кәфенлек икән… Алар күктән туп-туры Җанбикә карчык яткан бүлмәгә иңәләр… Менә алар хуш исле кәфенлекне Җанбикә карчыкның өстенә җәеп җибәрделәр, аның нурга әйләнгән җанын шуңа төреп, яңадан күккә атылдылар… Бу җан тирә-якка көмеш нурлар чәчә һәм хуш исләр тарата икән… Юлда очраган сакчы фәрештәләр:

— Шулхәтле нурлы һәм хуш исле — бу нинди изге җан? — дип сорыйлар икән…

Җанны күккә алып менүче фәрештәләр аларга:

— Бу — Ибраһим кызы Җанбикәнең җаны,— дип җавап бирәләр…

Фәрештәләр Ибраһим кызы Җанбикә рухына дан җырлыйлар…

Менә алар, бөтен дөньяга көмеш нурлар һәм хуш исләр таратып, күкнең беренче катына килеп җитәләр… Кемнең җаны килгәнен белгәч, сакчы фәрештәләр, аңа сөенеп, күк капкаларын ачалар һәм аларны икенче катка хәтле озата баралар… Шулай итеп, бернинди каршылыксыз, үзләре турында яхшы хәбәр бирә-бирә, алар җиденче кат күккә хәтле килеп җитәләр… Шул вакытта Аллаһның тавышы ишетелә:

— Минем колым турында хәбәрне тәкъдир китабына теркәп куегыз,— ди Ул.

Фәрештәләр шунда ук бу әмерне башкаралар…

— Хәзер аны яңадан җиргә кайтарыгыз, чөнки мин аларны җирдән чыгардым, яңадан җиргә кайтарырмын, дигән вәгъдәм бар һәм алар җирдән кубарылачаклар,— ди Аллаһы Тәгалә.

Фәрештәләр, Җанбикә карчыкның җанын алып, яңадан җиргә кайталар һәм аны, тәне белән бергә, кабердә калдыралар… Кабер казучыларның аяк тавышлары да тынып өлгерми, җан янына сорау алучы фәрештәләр килеп баса…

— Раббың кем? — диләр алар, кырыс тавыш белән.

— Минем Раббым — Аллаһ,— дип җавап бирә җан.

— Динең нинди?

— Минем динем — ислам дине.

— Сезгә кем җибәрелгән иде?

— Ул — Аллаһның илчесе иде, аңа Аллаһның рәхмәтләре һәм сәламнәре булсын.

— Син нишләдең?

— Мин Аллаһның китабын укыдым, аңа ышандым һәм тугры булып калдым.

Һәм күктән тавыш ишетелә:

— Минем колым дөрес әйтә. Аның өчен җәннәтне әзерләгез, аңа җәннәт киемнәре кидерегез, аның каршында җәннәт ишекләрен ачыгыз.

Һәм бу изге җанга җәннәт нигъмәтләре китерәләр, аның кабере күз карашы җитәрлек ераклыкка киңәеп китә, нур һәм хуш ис белән тула… Изге җан каршында җәннәтне күрә һәм аның кабере җәннәтнең бер почмагына әйләнә…

— Раббым, тизрәк кыямәт көнен җиткер, шушы җәннәттә гаиләм белән очраштыр,— ди изге җан.

Һәм аңа:

— Тыныч бул! — дип җавап бирәләр…

Һәм Әтил дә әллә кайдан күреп тора: әбисенең кабере —ул кабер түгел икән, ә җәннәтнең бер почмагы… Анда аллы-гөлле, Әтил гомерендә дә күрмәгән чәчәкләр үсеп утыра, былбыл кошлар очып йөри, аяк астыннан, челтерәп, кәүсәр сулары агып ята… Һәм бөтен дөньяга әллә нинди тылсымлы моң тарала… Бу моң Әтилне әле бишеккә салып тибрәтә, әле очар кош кебек, канат куеп, күкләргә күтәрә… Инде җиде кат күккә җиттем дип уйлаганда, өйдәге моңлы авазга Әтил уянып китте… Ул, кулына догалар китабы тотып, атасы караватында ята иде… Инде төн үтеп киткән, урамда яктырып беткән, ә зал яктан Коръән укыган моңлы аваз ишетелә иде…

Әтил шул чагында гына чынлыкта нәрсә булганын аңлады: күрше бүлмәдә әбисенең мәете ята иде… Бу юлы могҗиза булмаган, әбисе терелмәгән, аны хәзер күмәргә алып китәргә тиешләр иде…

Ул арада бүлмәгә әнисе килеп керде.

— Бар, улым, юынып кер, аннан әбиеңне озатырбыз,— диде ул.— Мунчага кереп, бер кат чайканып чыксаң да ярар, мәет янында тәһарәтле булырсың…

Әтил әнисе әйткәнчә эшләде: мунчада чайканып алды да күрше әбиләрдә тиз генә чәй эчеп чыкты. Аннан, бисмилласын әйтеп, әбисе янына керде. Әбисен инде юып, кәфенләп куйганнар, ул, кыйблага карап, ак биләүгә төргән сабый бала кебек, тып-тын ята иде… Әтил ишектә күренүгә, «Балам, кил монда, әбиең белән саубуллаш»,— диделәр.

Ул әбисе янына килеп басты. Күңеленнән нindидер җылы сүзләр әйтәсе килде, һәм теленә, могҗиза булып, кичтән ятлаган догасы иңде: «Раббәнә әтинә фид-дүнйә хәсәнәтәү вә фил-әхирати хәсәнәтәү вә кинә газәбән-нәр».

Шуны кычкырып укып бетерде дә, олылар кебек итеп, кулларын күтәреп, малай дога кылып куйды:

— Урының җәннәттә булсын, әбием, кабер эчләрең нурлы булсын, кабер туфракларың җиңел булсын,— диде ул, бик җитди итеп.

Бала кешенең бу саф, ихлас күңелдән ышанып укылган эчкерсез догасы өйдәгеләрне дә тетрәндерде. Кемнәрдер аны этисе Туранга, кемнәрдер бабасы Җиһангирга охшаттылар, Сәмәрия исә улының бөтенләй үзгәреп, олыгаеп китүен күрде. Бу инде бөтенләй икенче кеше, тормыш арбасына үзе җигелергә әзер торган җитди ир бала иде…

— Әни, әбине кайда күмәбез соң? — диде ул, әнисе белән киңәшкәндәй.

— Менә бабаңны көтәбез инде, улым,— диде әнисе.— Ул, нинди хәбәр белән кайта, шулай булыр. Бер дә булмаса, Атасалга алып кайтырбыз…

Җанбикә карчыкны соңгы юлга озатырга бөтен күрше-күлән, шәһәрдәге мөселман-татарлар җыелды… Мәет әзер, әмма әле кабер казылмаган, күмеләсе зираты билгеле түгел иде… Соңгы сүзне Җанбикә карчыкның гомер иткән ире Җиһангир карт әйтергә тиеш иде…

Ә Җиһангир карт иртәдән бирле ут урынына чаба… Больницадан «Үз үлеме белән үлде» дигән белешмәне алуы алай озак булмады, карчык йөрәк белән хисапта торгач, аның шулай кисәк кенә үлеп китүе табигый хәл иде. Бары тик врачларның, әвәләнеп, эшкә килеп җитүләрен көтеп торуы гына озак кебек тоелды аңа. Чөнки кояш инде шактый күтәрелде, көн кыздыра ук башлады, ә өйдә мәет ята… Кабере казылмаган, зираты билгеле түгел… Кулыңда шушы белешмә булмый торып, мәетне күмә дә алмыйсың… «Ничек ял көннәргә туры килмәде әле,— дип уйлады Җиһангир карт.— Җәйге көндә нишләр идең бу хөкүмәт йортларының эшли башлаганын көтеп…»

Иртәнге тугызларда кирәкле белешмә картның кулында иде инде. Хәзер күмәргә рөхсәт бар, әмма зират мәсьәләсе хәл ителмәгән… Дөрес, Аксуның урыс зиратына хәзер алып барып күмәргә була, кабер казучылар да әзер тора, әмма Җанбикә карчыкның, Кушъелгага күмегез, дигән васыяте бар бит әле… Аксу зиратына үзенең дә аягы тартмый картның, чөнки анда нинди кыргыйлык хөкем сөргәнен белә ул: аракысы да шунда, фәхеш эшләре дә… Мәетне Кушъелгага алып кайтып китәргә машинасын да белешеп куйды Җиһангир карт, мөселманнар булыштылар, тик анда ничек керәсең? Анда керү өчен, кем янына барып карыйсың?

Һәм Җиһангир карт, тәвәккәлләп, Түлгән эшләгән урынга— шәһәрнең милиция бүлегенә китте. Нәрсә әйтсәң дә, органнар бит, закон үз кулларында, бер-бер киңәш бирми калмаслар, бәлки әле ярдәм дә итәрләр… Үз хезмәткәрләренең әнисе бит…

Милиция бүлегендә күбесе яңа, яшь кешеләр иде, алар Җиһангир картны танымадылар да. Әмма, аның бәхетенә, электән эшләп килгән олы як та бар икән, алар картны танып алдылар, хәлен сораштылар. Милиция начальнигы да Түлгән белән бергә эшләгән олы яшьтәге урыс кешесе булып чыкты. Ни гаҗәп, Түлгән турында ул берни дә сорашмады, әйтерсең лә ул аның турында барысын да белә… Ә менә Түлгәннең әнисе үлеп китүенә чын күңелдән кайгы уртаклашты, берәр ярдәм кирәкмиме, дип сорады хәтта.

— Ул үзен туган авылы Кушъелгага алып кайтып күмәргә васыять иткән иде,— диде Җиһангир карт, тәвәккәлләп.—Ә анда, үзегез беләсез, ябык зона бит, болай гына кертмиләр… Мәетне шунда көнендә генә күмеп чыгарга рөхсәт итмәсләрме икән, дип, сезгә килеп карадым…

Милиция начальнигы уйга калды. Кушъелга шушы Аксу районы территориясенә кереп, аларга буйсынса да, ул — ябык зона, аның үз тәртипләре бар. Әле алдан йөри башлап, гаризасын язып, Мәскәү ФСБсы аша тикшерү үткәннән соң кертергә дә мөмкиннәр… Әмма мондый эшне көнендә генә эшләп булмый бит…

— Нигә бирегә — Аксуга гына күммисез соң? — диде ул, картның хәленә керергә тырышып.— Мондый челләдә тау арасында мәет өстерәп йөрү дөрес булырмы — бирердә зират була торып?

— Бирердә мөселман зираты юк шул,— диде Җиһангир карт, нигәдер аклангандай.— Безнең динебез аерым күмәргә куша… Мәрхүмәнең үзенең дә васыяте бар иде — туган авылына алып кайтып күмәргә дигән…

«Һәркемнең үз дине шул,— дип уйлады карт урыс.— Исән чакта да — аерым, үлгәч зиратлар да аерым…» Теге елларда бу картлар татар зираты өчен урын сорап йөреп карадылар, әмма йөреп бетерә алмадылар… Аннан җирләрне сатып кына бирә башладылар, карт-корының аңа акчасы җитмәде, ә яшьләргә кайда күмсәләр дә барыбер иде…

Бу тыныч, сабыр татар карты аңа кызганыч булып тоелды. Улы да кайчандыр бирердә эшләп киткәч, аңа ярдәм итәргә кирәк иде, әлбәттә. Әмма ничек итеп? Милиция начальнигы белә иде: Түлгән яшерен оешмаларга да хезмәт итте, әгәр ФСБга мөрәҗәгать итсәң, алар үз хезмәткәрләре өчен нәрсә дә булса эшли алырлар иде… Ачылмас өчен, ярдәм итмәскә дә мөмкиннәр… Һәм милиция начальгы, тәвәккәлләп, шул оешмага шалтыратып карарга булды. Әмма аның белән бу хакта телефоннан сөйләшергә теләмәделәр — янәшәдәге соры бинага кереп чыгарга куштылар. Ниндидер могҗизага өмет итеп, Җиһангир карт аны көтеп калды…

Озак, бик озак көткән кебек тоелды Җиһангир картка. Гадәттә, алар мәетне өйлә намазыннан соң җеназа укып күмәләр. Һәрхәлдә, ислам дине буенча, мәет кояш баеганчы күмелергә тиеш… Әле ярый җәйге көннәр озын, кояш соң байый, барасы җиргә барып җитәргә мөмкин… Әмма көне бик эссе бит, көне… Ә өйдә, җиргә тапшыруларын көтеп, мәет ята…

Ул инде Җанбикә карчыкның мәетен Атасалга гына алып кайтып китмәвенә дә үкенеп куйды. Әмма… васыять бар бит, васыять! Җанбикә карчык соңгы елларда гел шул Кушъелга белән генә

яшәде, аның белән саташты… Балачакта Әнзәр елгасында су керүләре турында, Ямантау һәм Нәрәле итәкләрендәге урман-яланнарда җиләк җыюлары хакында, Ямантауның дәһшәтле матурлыгы турында соңгы вакытта бик еш сөйли иде ул… Әмма теге вакытта атом шәһәренең капка төбеннән туган авылына керә алмыйча борылып киткәч, Кушъелгага кайту турында башка кузгатмады… Тик васыятен барыбер үзгәртмәде, бәлки, мәетләр өчен аерым закон бар дип уйлагандыр…

Бер караганда, карчыгын анда да алып кайтып күмәсе килми Җиһангир картның… Җанбикәнең туган авылы Кушъелга үзе дә атом шәһәре белән кушылып беткәндер инде ул, урыс белән тулгандыр… Кушъелганың астында атом базлары, бөтен дөньяның атом калдыклары саклана… Дөньяның иң пычрак һәм иң куркыныч урыны бит ул хәзер — Кушъелга… Ә кая алып барасың мәетне? Атасал дип әйтте әйтүен Җиһангир карт, әмма хәзер анда да тыныч түгел бит… Анда алтын бар, дигән хәбәрдән соң, читтән килеп, бөтен бәрәңге бакчаларын, хәтта зиратларга хәтле актарып бетергәннәр… Шуннан һун чоры хәзинәсен эзлиләр икән… Карагай буенда зираттан чыккан баш сөякләренең аунап ятканын күргәннәр… Тимертаудан, Чиләбедән кайтып, төнлә актаралар икән каберләрне… Аннан, Атасал бик ерак та әле ул Аксудан… Ул турыга гына якын кебек тоела, әмма хәзер тау араларыннан кем йөрсен, юлы да юк аның хәзер… Башта — йөз чакрымлап Тимертауга, аннан тагы шуның хәтле — Субайга, аннан Атасалга кайтырга кирәк… Хәзер кузгалсаң да, ахшамга кайтып кына җитәсең… Нишләргә? Хәзер инде барысы да милиция начальнигының нәрсә дип килеп әйтүеннән тора иде…

Ни гаҗәп, милиция начальнигы, була, дип килеп әйтте! Ул ФСБда бөтенесен килешкән, мәет белән бергә, берничә генә сәгатькә картның үзенә генә кереп, күмеп чыгарга рөхсәт иткәннәр. Оешма хәтта үз машинасын, үз шоферын да бирергә булган…

— Менә кирәкле белешмәләр, пропусклар, машина ишек төбендә көтеп тора,— диде милиция начальнигы, бу хәлләргә үзе дә ышанып бетмичә.— Алып кайтыгыз карчыгыгызны, күмегез, кабер туфрагы йомшак булсын…

Чит милләт кешесе әйткән шушы җылы сүзләрдән дә Җиһангир картның күңеле йомшарды. Туганыдай якын күреп, кушучлап, ул аның кулларын кысты, чиксез рәхмәтләрен әйтте. Ул инде хәзер бер җылы сүз, бер белешмә кәгазе, хәтта өч аршын җир биргәннәре өчен дә барысына да рәхмәтле иде…

Үзен сабыр гына урамда көтеп торган автобус шоферы белән ул өйләренә кайтты. Рәхмәт яугыры, шофер егет тә татар кешесе булып чыкты, ярдәм итәргә дип, бөтерелеп йөри башлады.

— Ничек хәл иттегез, эткәй? — диде Сәрмәния, кайнатасы машина белән кайтып кергәч.

— Кушъелгага алып кайтабыз, килен, ярдәм иттеләр,— диде Җиһангир карт, кәгазьләрен күрсәтеп.— Тик рөхсәт минем үземә генә, сез монда каласыз инде.

— Ә мин?

Әтил, тилмереп, бабасына карады. Әбисен Ямантауга күмәргә алып кайталар, ә Әтилне алмыйлар! Бу эштән Әтил ничек читтә калсын инде, ничек үз әбисен күмүдә катнашмасын, ничек Ямантауны күрми калсын?!

— Бабай, мин ничек бармыйм ди инде анда, мин бит хәзер эти урынына калган кеше! — диде ул, барысын да аптырашка калдырып.

— Рөхсәт бер генә кешегә бит, улым,— диде Җиһангир карт, ни әйтергә дә белмичә.— Әйтергә башым җитмәгән, рөхсәтне ике кешегә язызыгыз, дип... Хәзер соң инде, улым, сабыр итәргә кирәк…

— Бабай, алайса, утырып кына барыйм, шәһәр эченә кермәм,— дип ялынуын дәвам итте Әтил.— Сез чыкканны капка төбендә көтеп торырмын, алып бар инде, бабай?

Малайның күзләреннән мөлдерәп яшь тамарга торганны күреп, шофер егетнең күңеле йомшарды.

— Барсын, бабай, ул бит әле паспорт яшендә түгел,— диде ул, җаваплылыкны үз өстенә алгандай.— Кертмәсәләр, шунда көтеп торыр, кертсәләр, әбисен күмешер… Үзем дә сөйләшеп карармын, проходнойда белгән егетләр бар минем анда…

Моны ишеткәч, Әтил тиз-тиз җыена башлады. Әнисе күрмәгәндә, пакет-капчыгына тиз генә кечәге җылы курткасын алып салды, бер шешә су белән өстәлдә яткан ипине төреп тыгып куйды. Ни өчен шулай эшләвен ул әле үзе дә аңлап бетерми иде, юлда ни булмас, дип, үз-үзен алдарга тырышты… Әбисенең мәете, Кушъелга, Ямантау, атом шәһәре, шундагы җир астында үлем көтеп яткан этисе — малай башында барысы берьюлы буталды… Төгәл генә ни эшләргә җыенуын ул әле үзе дә белми иде… Иң мөһиме: ул Ямантауга бара…

Җанбикә карчыкны, аяклары белән ишеккә таба борып, алып чыга башладылар. Ишегалдына чыккач, башы белән алга таба бордылар һәм, югары күтәреп, карчыкны, миләш-баланнары белән бәхилләштертеп, урамга алып чыгып киттеләр. Урамда кеше күп җыелган иде, бөтен тирә-як халкы, дога кылып, Җанбикә карчыкны соңгы юлга озатып калды… Автобуска кергәч, Җиһангир карт белән

Әтил мәет салынган кабыкның баш очына утырдылар, аны икесе ике яктан тотып бардылар… Шулай итеп, Җанбикә карчык кабык бишегендә туган авылы Кушъелгага кайтып китте…

Башта шактый гына олы юлдан бардылар, аннан машина кинәт кенә уңга борылды да куе урман эченә кереп чумды. Биредә урман бик зур һәм калын, агачлар карт иде, асфальт юл булмаса, бу кара урманның кайда да булса бетүенә ышанып та булмый… Ә юл бар икән, ул инде кайда да булса алып барып чыгарга тиеш… Кайда да булса түгел — Ямантауга, Ямантауга, Ямантауга бара ул юл… Әтилнең йөрәге дә бу мизгелләрдә «Ямантау, Ямантау, Ямантау» дип тибә иде… Бераз баргач, як-якта биек-биек таулар күренә башлады, аларның һәрберсе Әтилгә Ямантау булып тоелды. Ләкин бу хакта ул бабасыннан сорарга уңайсызланды, бабасы мәет янында уйга талып, дога кылып бара иде…

Малайның боргаланып, тирә-юньне карап баруын күреп, шофер егет ярдәмгә килде.

— Бу тирәдәге иң биек таулар бу, энекәш,— диде ул.— Сулда — әнә Нәрәле таулары, уңда — Юша белән Бәләтур, каршыда — Караташ таулары…

— Ә Ямантау кайда? — дип сорамыйча түзә алмады Әтил.

— Ә син Ямантауны кайдан беләсең? — дип сорады шофер егет, игътибарсыз гына кыяфәттә.

— Ник… Ник… Мәктәптә үттек,— диде Әтил, күзләрен челт-челт йомып.— Ул биредә иң биек тау икән бит, китапта шулай язылган иде…

— Шулай,— диде шофер егет.— Ямантау — бу тирәдәге иң биек тау ул, энекәш, дөрес әйтәсең… Менә шунда барабыз инде без синең белән, үзең дә күрерсең шулай икәнлеген…

Кайсыдыр борылышны узуга, каршыга төрле күрсәткеч такталар очрый башлады. Һәм алга таба баруны тыя торган билгеләр пәйда булды. Бер тактага русча-татарча «Стой! Запретная зона» һәм «Тукта! Ябык зона» дип язып куелган иде. Янәшәдә генә халык телендә «кирпеч» дип аталган тыю билгесе ясап куелган. Аның астына: «Таулы шәһәре номеры булган машиналарга гына алга таба барырга рөхсәт ителә»,— дип язылган иде…

Әтил, моны күргәч, шикләнеп шоферга карады, ә ул бик тыныч, баруын белә, бу тирәләрдә судагы балык кебек йөзә иде…

Көтмәгәндә каршыларына, зәңгәр рәшә арасыннан тибрәлеп, биек тау сырты калкып чыкты… Әйтерсең лә яшел урман диңгезе астыннан гаять зур су көймәсе йөзеп чыгып килә иде… Әтил, телдән язып, бу күренешкә карап торды… Тау сырты шулхәтле зур һәм дәһшәтле күренә — ул җирдәге кара урманнардан да, күктәге ак болытлардан да югары күтәрелгән, хәтта кояшның үзенә хәтле барып җитә язган кебек тоелды аңа… Тау сырты ике өркәчле булып, бер сырты бигрәк тә биек һәм серле күренә… Бу — Әтил-малай төшләрендә күргән тау, бу Ямантау иде…

Ул арада юл кайсыдыр тау сыртыннан тагы аска төшеп китте — Ямантау күздән югалып торды… Өскә чыктылар — Ямантау тагы да якынайды, тагы да зур һәм куркыныч булып күренә башлады, ул, ниндидер тылсымы белән, Әтилне үзенә тартып китерә, суырып ала кебек иде…

Урман эчендәге тимер каланчалардан беренче тикшерүчеләр килеп чыкты. Алар шофер егетнең документларын тикшерделәр, эчкә кереп, мәеткә күз төшерделәр, Җиһангир карт кулындагы кәгазьләрне җентекләп карадылар һәм аларны алга таба үткәреп җибәрделәр… Нигәдер, бу юлы Әтилгә сүз әйтмәделәр, әмма аларны алда тагы берничә шундый тикшерү көтеп тора иде әле…

Менә алар биек коймалар каршына килеп туктадылар. Коймалар шулхәтле биек иде, хәтта аларны стена дип тә, крепость дип тә атарга мөмкин иде… Әмма бу әле беренче кат таш-бетон койма гына булып чыкты, алда аларны биек тимер капкалары белән тимер койма көтеп тора иде… Машинаны шул ике капка арасындагы тар читлеккә кертеп туктаттылар да барысына да чыгарга куштылар, икенче ишеккә таба җибәрделәр. Автобус эченә кораллы хәрбиләр тикшерергә кереп калды…

Инде бу ишекне дә үтеп, кечкенә генә бүлмәгә килеп чыктылар. Алда — үтеп китү өчен, тимер читлеккә охшаган, проходной дип аталган тар гына урын булып, анда компьютер каршында хәрби кием кигән кеше утыра иде. Ул Җиһангир карт белән шофер егетнең документларын җыеп алды һәм аларны компьютердагы мәгълүматлар белән чагыштыра башлады. Мәсьәлә бик югары дәрәҗәдә хәл ителгән иде, ахрысы, аның артык сораулары булмады, бүген кичкә зонадан кире чыгарга тиешлекләрен әйтеп, документларын кире бирде.

Әтилнең йөрәге бугазына менеп тибә башлады. Аның бит бернинди дә документы юк, аны хәзер нишләтерләр икән инде? Шул чагында компьютер каршында утыручы хәрби дә аны күреп алды, аптырап, бер малайга, бер бабайга карады.

— Ә бу малай кая бара, аның документлары кайда? — диде ул, коры тавыш белән.

— Ул да әбисен күмәргә бара, аның паспорты юк бит әле, унөч тә тулмаган аңа,— дип, бабасы ашыгып җавап бирә башлады.

— Паспорт яшендә түгел икән, өлкәннәрнең рөхсәт кәгазенә кертергә кирәк иде,— диде хәрби, тимер тавыш белән.— Документсыз керергә рөхсәт юк.

— Монда кайда калдырыйм инде мин аны урман эчендә, берүзен? — диде бабасы, нәрсә әйтергә белмичә.

Шунда шофер егет тә сүзгә кушылды.

— Безнең системада эшләүченең улы ул,— диде ул, күзгә карап ялганлап.— Әтисе заданиедә анын, анын әнисен күмәргә менә улы бара.

Һәм ул, иелеп, компьютер артындагы хәрбигә тиз-тиз генә нидер әйтте, кесәсеннән чыгарып, ниндидер документ күрсәтте. Хәрби кеше тагы бер — малайга, бер бабайга карап куйды. Ул арада аның янына хезмәттәшләре килеп керде, алар шофер егет белән исәнләшеп, хәл белешеп алдылар.

— Җаваплылыкны тулысынча үз өстемә алам: күмәбез дә бүген үк кире дә чыгабыз,— диде шофер егет, танышларын күргәч, ышаныч белән.

— Ярар, алайса,— дип килеште сакчы хәрби.— Әмма малайны синең рөхсәт кәгазеңә язабыз, компьютерга да шулай дип кертәбез… Чыкканда да синнән сораячакбыз.

Проходнойның тимер кыскычлары як-якка ачылып китте, бөтен гәүдәләрен экран аша тикшертеп, алар эчкә үттеләр. Чыгып автобусларына утырмыйча, монда керүенә Әтил әле үзе дә ышанып җитмәде. Гел теге хәрби кеше артларыннан йөгереп чыгар да келәшчәдәй куллары белән Әтилне эләктереп алыр кебек тоелды аңа. Ул хәтта бер мизгелгә Ямантау турында да онытып җибәрде. Әмма әтисе турындагы уйлар бер генә мизгелгә дә башыннан чыкмады. Сөнгатулла абыйсы әйткәнчә, Әтилнең әтисе шушында җир астында икән, ул аны моннан эзләргә, эзләтергә тиеш… Ничек итеп — анысын әле Әтил үзе дә белми, әмма моның өчен Ямантауга керергә кирәклеген ул белә… Аксуда ятып та, Тимертауда бәрәңге әрчеп ятып та, ул әтисе турында берни белмәячәк… Ә монда ул барыбер нәрсә дә булса беләчәк, Әтилгә күңеле шулай дип әйтә…

Автобус кузгалып китеп, шәһәр эченә керә башлагач, ул, сәерсенеп, як-ягына карады. Кайда соң монда әбисенең авылы? Кайда теге яшерен атом базлары, җир асты шәһәре? Аның каршында Аксудан, Тимертаудан берние белән дә аерылмый торган таш шәһәр җәелеп ята иде… Шундый ук биек тимербетон йортлар, алар артында биек-биек торбалар, ул торбалардан күтәрелгән кара-шәмәхә төтен болыты… Һәм шуларның барысын да каплап китәргә теләгәндәй, Ямантау калкып тора… Якыннан ул бигрәк тә зур һәм иләмсез булып күренә икән… Моңа кадәр Әтил күргән биек, төз таулар кебек түгел икән Ямантау, ул җәенке биек икән… Һәм ул ярты дөньяны каплап тора… Шәһәр дә аның кара күләгәсе астында җиргә сеңеп, кеп-кечкенә булып күренә…

— Кайсы якка барабыз, абзый? — диде шофер егет, Җиһангир карт ягына борылып.

Җиһангир карт, аптырап, үзе дә як-ягына каранды. Аның биредә инде бик күптәннән булганы юк иде, ул чагында бу биек таш йортларның берсе дә юк иде әле, монда, агач өйләре белән, Кушъелга авылы җәелеп ята иде… Ул әле дә хәтерли: авылдан бераз читтә, урман булып, борынгы зират шаулап утыра иде… Кайда соң Кушъелга, кайда аның зираты? Кайсы якка карасаң да, урман кебек биек таш йортлар тырпаеп тора…

Картның йөрәге аяк астына төшеп киткәндәй булды — үз урынында Кушъелга юк иде… Зираты да күренми…

Биек йортлар арасында бераз буталып йөргәч, шофер егет тә эшне аңлый башлады, туктап, кешеләрдән зират турында сорап карарга булды. Кибет янында җиләк-җимеш сатып утыручы хатыннар аңа шунда ук зиратка юлны күрсәттеләр.

— Шәһәрне чыгып, бераз баруга зират икән, анда күрсәткечләр куелган булырга тиеш,— диде ул, автобуска кереп утыру белән.

Хатыннар күрсәткән якка карап, кузгалып киттеләр. Чыннан да, шәһәрне чыгуга, зиратка таба күрсәткеч билге куелган иде. Җилдә лепердәп утырган яшь агачлары белән, тиздән каршыда ул үзе дә күренде. Зиратка якынайган саен, Җиһангир картның эченә шом керә барды. Кушъелга зиратына охшамаган иде бу, аның агачлары инде карт, урман кебек иде, ә бу — яңа зират, агачлары да яшь күренә… Татарлар яңа зират ачкан булсалар гына инде…

Зиратка якынайган саен, Әтилнең дә йөрәге әсәрләнә төште… Чөнки зират юлы Ямантауга таба бара иде… Әтилгә исә, киресенчә, Ямантау үзе бирегә таба килә кебек тоелды… Һәм нәрсәседер белән Әтилне үзенә таба тарта, тарта, тарта… Ямантау зиратка терәлеп үк тора диярлек, аның итәгендә куе урман шаулый, түбәсе болытлар арасына кереп киткән, озынлыкка бер башыннан икенчесе күренми иде…

Машинадан төшеп, зират ягына күз салуга, Җиһангир картның аяк астында җир чайкалып куйды. Зират эченнән аңа, чекрәешеп, зур-зур тәреләр карап тора иде… Ул шунда ук аңлап алды, бу урыс зираты иде… Шушы 30 градуслы эсседә, яныпешеп, мәет өстерәп, алар урыс зиратын эзләп йөргәннәр икән…

Гаҗиз булып, ул шофер егеткә карады. Шофер егет үзе дә хәлне аңлап алган иде инде, ул, зират коймасына тотынып, эчкә күз ташлады. Аннан кош тоткандай шатланып кычкырып җибәрде.

— Агай, монда татарлар да күмелгән бит! Әнә айлы кабер ташлары күренә, анда гарәпчә язылган… Так что, безгә дөрес әйткәннәр, дөрес килгәнбез…

Аның мәетне тизрәк җиргә тапшырып, кайтып китәсе килә иде. Әнә инде кояш та төшлектән авышып бара…

— Юк, энем, бу — урыс зираты,— диде Җиһангир карт, тимер тәреләр ягына күрсәтеп.— Мондый катнаш зират Аксуда да бар иде ул, мөселман кешесен анда күмеп булмый.

Алар сөйләшкән тавышка зират башындагы алачык-өйдән берничә ир-ат чыгып, болар ягына таба килә башлады.

— Нәрсә кирәк, мужиклар? — диде берсе урыс телендә.— Кабер казыргамы, мәет күмәргәме — мигом эшләп ташлыйбыз. Документларыгыз һәм баксаларыгыз гына тәртиптә булсын.

— Без ялгыш килгәнбез, ахры, улым,— диде Җиһангир карт бу салмыш урыс егетенә.— Безгә татар зираты кирәк, безнең мәетебез — мөселман кешесе.

— А какая разница? — диде урыс егете, бер дә исе китмичә.— Без мөселманнарны да күмәбез. Әнә күрәсезме — күпме айлы каберләр? Җир астында барысы да тигез — тәресе дә, ае да… Монда башка зират юк…

Җиһангир картның җиргә чүгеп, үкереп елыйсы килде. Могҗиза белән биргә керергә рөхсәт алды, авырлык белән булса да, атом шәһәренә үтеп керделәр, зиратны эзләп таптылар… Ә ул урысныкы булып чыкты… Ничек итеп ул намаз иясе булган карчыгын шушы тимер тәреләр арасында калдырып кайтсын? Ничек шушы исерек урыслардан кабер казытсын, кемнәр белән җеназа укысын?

Картның җан газапларын күреп, зиратта эшләүчеләрнең берсе аңа татарча эндәшеп куйды:

— Син алай ук борчылма, абзый кеше,— диде ул.— Каберне үзем казырмын… Әнә тегендә, бер читтәрәк, анда урыслар күмелмәгән, гел татар каберләре…

Үз телендә әйткән кешечә сүзгә карт кайгысыннан айнып киткәндәй булды, соңгы саламга ябышкандай сорап куйды:

— Кушъелга зираты кайда соң, энем? Бар иде бит монда татар зираты?

— Ул зона эчендә калды,— диде татар ире, артык сөйләшергә теләмичә.

Зона эчендә, димәк, атом казанында, атом пычраклары, радиация арасында…

— Ә авыл үзе кайда? — диде Җиһангир карт, тетрәнеп.

— Авыл урынында — әнә шәһәр… Бер өлеше — зонада…

Сүз шунда бетте. Җиһангир карт үзенең бер чарасыз калганын аңлады. Кояш инде төшлекне узды, чамасыз кыздыра… Ә машинада, ак кәфеннәргә уранып, Җанбикә карчык ята… Туфракка иңдерүне көтеп ята ул… Шофер егет тә ашыктыра, аның тизрәк күмеп, кайтып китәсе килә… Кулында үз машинасы булса, Җиһангир карт хәзер борылып чыгып, туп-туры Атасалга алып кайтып китәр иде карчыгының мәетен… Бүген өлгермәсә, иртәгә күмәр иде, кеше кебек, пакь җиргә җеназалар укып күмәр иде… Бу егет аны алай йөртмәячәк инде, кире Аксуга кайтарачак та куячак… Мәетне яңадан өйгә алып керергәме? Нишләтергә? Кайда куярга?

Муенына үлем элмәге салынган мал кебек, ул өстерәлеп зират эченә кереп китте. Башкалар аңа иярделәр. Агачтан һәм тимердән эшләнгән зур-зур тәреләр аның чабуына ябышып, эләктереп калырга тырыштылар… Кояштан төсләре уңган кәгазь чәчкәләр картның аяк астына сибелделәр… Кабер араларында буш шешәләр, ризык калдыклары аунап ята иде… Көтмәгәндә каршында калкып чыккан тимер кешене күреп, карт авып китә язды. Зират эче утырган, баскан тимер һәм, таш кешеләрнең сын-һәйкәлләре белән тулган иде… Бу хәлләрне күрмәс өчен, ул тизрәк татар почмагына борылды һәм айлы каберләр арасында аунап яткан исерек парны күреп, баскан урынында катып калды. Мәетләр өсте фәхешханәгә әйләнгән иде… Һәм ул шушында иң кадерле кешесен — балаларының анасын калдырып китсенме?! Монда калдырганчы, алып чыгып, кара урманда күмә ул аны, тау башында, Агыйдел ярында күмә — тик монда түгел!!! Ул бит монда дога кылырга да керә алмаячак… Һәм ул монда карчыгын калдырмаячак. Юк, мәңге калдырмаячак!

Җиһангир картның, кырт борылып, зираттан чыгып китүен күреп, шофер егет барысын да аңлады. Әмма Аксуда да шушы ук хәл бит: урыс-татар катнаш зираты, тимер сыннар, кабер аралары тулы шешә һәм исерекләр… Кая барырга уйлый бу карт хәзер?

— Әйдә, энем, борылыйк,— диде Җиһангир карт, аның уйларын сизгәндәй.— Үзең күреп торасың — монда мөселман кешесен калдырып булмый.

— Аксуга кайтабызмыни? — диде шофер егет, бераз гаҗәпләнеп.

— Юк,— диде Җиһангир карт, өздереп.— Олы юлдан бер илле чакрымда Каһарман авылы бар, шунда алып кайтабыз мәетне… Анда безнең туганнар яши, кешечә күмәргә булышырлар, иншаллаһ!

Картның өздереп әйткән бу сүзләренә каршы шофер егет бер сүз дә әйтмәде. Каһарманга икән — Каһарманга, чөнки ул авыл биредән алай ерак түгел, кире кайтканда, Аксуга да якын… Татар кешесенең татар авылына күмелүе яхшырак, әлбәттә, моны ул үзе дә аңлый…

Шушы ният-уй белән, алар машиналары янына килделәр һәм шул чагында гына яннарында Әтилнең юклыгын күрделәр. Ул автобус эчендә дә юк иде. Җиһангир карт яңадан зират эченә карады — Әтил анда да юк иде… Карт аның исемен әйтеп, кычкырып-кычкырып та карады, аңа җавап бирүче булмады… Әтил җир астына төшеп баткандай юкка чыккан иде…

Картның эченә шом керде. Кайда булыр бу бала? Әбисен күмгәнче вакыт бар, дип, әллә якын-тирәләрне карарга киткәнме? Бу арада гел Ямантау турында сорашты, әллә, Ходаем, Ямантауга ук китеп барганмы? Әллә урманга кереп адашып, чыга алмыйча йөриме?

Шул чагында, нидер сизенеп, картның йөрәгә жу итеп китте. Ул ашыгып автобуска керде, Әтилнең Аксудан алган пакетын эзләде — капчык урынында юк иде… Тирә-юньне карарга кеше капчык күтәреп китәме? Нәрсә булды икән соң аның ул капчыгында? Юлда ул шуннан су алып эчкән иде, Җиһангир карт шунда оныгының җылы курткасын күреп, бераз гаҗәпләнде… «30 градуслы эсседә нигә кирәк булды аңа бу кием?» — дип уйлаган иде… Уйлады да онытты, чөнки аның башында мәет кайгысы, аны күмү мәшәкате генә иде… Әллә соң бу бала…

Карт ашыгып урамга чыкты. Кабер казучы ирләр таралмаганнар иде, ул йөгереп диярлек алар янына килде. Кабер казучылар, бу карт кире уйлады, ахры, дип, аңа таба борылдылар.

— Малай юкка чыкты бит әле, сез күрмәдегезме? — диде карт, аларга өмет белән карап.

Шунда теге татар ире телгә килде:

— Капчыгын күтәреп, урманга кереп бара иде ул,— диде ул.— Мин аны җиләк-мазар эзлидер дип уйладым, бала-чага бит… Һәрхәлдә, мондагы җиләкне ашарга ярамаса да…

Карт тәмам пошаманга төште. Әле аның оныгы бу тирәдә генә йөридер дигән өмете бар иде, ә бу татар аның урманга кереп баруын күргән… Ямантау итәгендәге кара урманга… Капчыгын да үзе белән алган…

Җиһангир карт, хәле бетеп, зират коймасы буена килеп утырды. Ул тәмам арыган, хәлсезләнгән, йончыган иде…

— Энем, бераз көтик,— диде ул, шофер егеткә ялварып.— Бала кеше бит, Ямантауны карыйсы килгәндер… Кире кайтырга юлны таба алмыйча йөридер… Бераз көтик…

— Мин кичкә хәтле дә көтә алам, абзый,— диде шофер егет, канәгатьсез тавыш белән.— Анда мәет көтеп ята бит… Хәзер кузгалсак, берәр сәгатьтән кайтып та җитәр идек…

— Бераз көтик, бер ярты сәгать көтеп карыйк,— диде Җиһангир карт, ни әйтергә дә белмичә.

Ул, соңгарак калып булса да, көйгән җиргә тезләнеп, өйлә намазын укып алды. Әле икендегә хәтле шактый вакыт бар, әле көннең ахшамы җитмәгән… Аллаһтан сорасын, бу эшләрнең ахыры хәерле бетсен, Раббым! Карчыгының кинәт үлеме, оныгының юкка чыгуы, Туран турында ишеткән борчулы хәбәре — болар барысы да Җиһангир карт өчен Аллаһтан сынау иде, сынау! Менә шундый вакытта сабырлык кирәк, иман ныклыгы, акыл кирәк инде… Һәм эшләреңне Аллаһка тапшырырга кирәк…

Әмма Әтил ярты сәгатьтән дә килмәде, бер сәгатьтән соң да күренмәде… Кояш, күзгә күренеп, Нәрәле тауга таба түбән тәгәри иде… Карт башкача көтәргә ярамаганын аңлады: мәетне җирләргә кирәк иде… Һәм бүген кичкә ул бу шәһәрдән чыгарга тиеш, чөнки рөхсәт бүгенгә генә бирелгән…

Җиһангир карт, бер карарга килеп, урыннан торды.

— Китәбез, энем,— диде ул.— Малай мөгаен адашып калгандыр… Хәзер бернишли алмыйбыз инде, мәетне күмәргә кирәк… Иртәгә эзләтә башларбыз, аңынчы үзе табылып куймаса… Аллага тапшырдык, кузгалыйк.

Шофер егет тә аның белән килеште.

— Проходнойда гына бәйләнмәсеннәр,— диде ул, машинасын шәһәр ягына борып.— Сорасалар, урманда адашып калды, диярбез… Компьютерга кергәч, аны барыбер эзләтәчәкләр инде… Хотя бала кешедән нинди куркыныч инде… Үзенә генә авыр булыр малайның… Хотя егет кешегә нәрсә инде ул бер төн табигатьтә куну? Без малай чакта әле атналар буе кырда, урманда кунып йөри идек…

Шулай сөйләшеп, бер-берләрен юата-юата, шәһәр капкасына килеп җиттеләр. Аларның бәхетенә, тимер капкада шофер егетнең белгән кешесе утыра иде. Кораллы сакчылар машина эченә кереп тикшергән арада, компьютердагы сакчыга хәлне аңлатып бирделәр. «Малай урманда адашып калды, монда килеп чыкса, безгә хәбәр бирерсез»,— дип, Аксуның телефоннарын бирделәр. Шулай итеп, җәһәннәм капкасын исән-имин чыгып китә алдылар…

Атом зонасыннан чыккач та, карт каерылып-каерылып Ямантау ягына карады. Тоташ таш стена буйлап, бу үлем базыннан чыгарга урын таба алмыйча, оныгы йөгереп киләдер кебек тоелды аңа… Әмма Әтил бер җирдә дә күренмәде… Шәһәр тәмам артта калды, Ямантау да күздән югалды…

— Борчылма, абзый,— диде шофер егет, картның кайгырганын күреп.— Иртәгә минем бирегә киләсем бар, үзем эзләтермен оныгыңны… Шул Ямантау тирәсендә буталып йөридер, бик сорашып барган иде бит…

Көннең кызуы бераз сүрелә төште. Ике яктан да ачык тәрәзәләрдән үтәли җил йөри… Сабый бала кебек ак биләүгә биләнгән Җанбикә карчык, туган авылы белән мәңгегә бәхилләшеп, Ямантау буйларыннан китеп бара… Агач яфраклары, тәрәзәгә үрелеп, аңа соңгы сәламнәрен тапшыралар, тау җилләре аның ак кәфенлеген сыйпап үтә, кара урман соңгы борылышка кадәр озата бара…

Әнә алда инде Каһарман авылы…

Агыйдел буенда, Баштау итәгендә, борынгы татар авылында Җанбикә карчыкны мәңгелек өе көтә… Биредә аны сандугачлар сайрап, тау елгалары шаулап, бөдрә таллар сәҗдә кылып каршы ала… Таулар, киңәеп, аның җәннәткә тиң кабер-өенә урын бирәләр, җир аслары һәм җир өсләре илаһи бер нурга, моңга күмелә… Җанбикә карчыкның ак җаны ахирәт көненә китә…

* * *

Әтил зират кырыеннан ук башланып киткән нарат урманына таба ашыкты. Тырпаешкан, кипкән ботаклар аның күлмәк чабуыннан эләктереп калырга тырыштылар, кулындагы капчыгы да әллә ничә урыннан тишелеп, ертылып чыкты. Әтилнең күңелендә капма-каршы уйлар бәргәләнде, ниндидер гаепле эш эшләгәндәй, җаны елады… Үлгән әбисен, карт бабасын шушы хәлдә калдырып китүенә ул газапланды, нишләргә белмәде… Әмма аның күз алдында һаман шушы шәһәр астында богаулап ташланган газиз әтисе торды… Ул әтисе турында нәрсә дә булса белергә, ишетергә тиеш иде! Ул тагы монда яңадан ничек керсен, әтисе турында тагы ничек белә алсын? Ул бүген Ямантауда куныр, шуңа күрә җылы курткасын да алды, иртәгә шәһәргә төшәр, кешеләрдән сорашыр… Бала кешедән берсе дә шикләнмәс, бабасы эзләтмәсә, аны эзләмәячәкләр дә әле… Монда хәтле могҗиза белән кереп җиткәч, ул барыбер нидер белеп чыгар… Ямантауны да күрер, әтисе турында да нидер белер — Әтил моңа чын күңеленнән ышана иде… Ә бабасыннан ул, тезләнеп, гафу сораячак — шундый вакытта борчыганы өчен, сүзеннән чыкканы, үз юлы белән китеп барганы өчен… Бабасы аны аңлаячак, Әтил урынында булса, ул үзе дә нәкъ шулай эшләр иде..

Әйе, бабасы аңлар, иң мөһиме: Әтилне тотып, кире бормасыннар. Шуңа күрә ул тизрәк урман эченә кереп югалырга ашыга, бик саклык белән, як-ягына карап кына бара. Ул нарат урманының бетмәвен, тауга хәтле дәвам итүен теле. Һәм Ямантауга ничек тә буш яланлыктан түгел, агачлар арасыннан күтәрелергә кирәк. Шәһәр ягыннан түгел, икенче яктан — кешеләр күрмәслек тирәдән менәргә кирәк… Әгәр очрасалар, ул: «Җиләк җыям, дару үләннәре җыям,— дияр,— шушы шәһәрдә яшим»,— дип әйтер. Хәер, башка җирдә яшәгән кеше монда керә дә алмый бит инде, гел шуны онытa Әтил…

Шул чагында Әтил кешеләр сөйләшкән тавыш ишетте һәм куркып, агачлар артына качты. Уйга бирелеп китеп, ул ачык урынга килеп чыга язган икән бит! Алда зур ялан иде, ә аланлыкта озын ак кием кигән, ак битлекле кешеләр нидер эшләп йөриләр… Яннарында гына бөркәүле йөк машинасы да тора. Алар аннан шундый ук ак киемле, әмма битлексез кешеләрне… Шундый ук кешеләрне…

Әтил, коты чыгып, фикерен туплый алмыйча торды… Әллә ялгыш күрәмме, дип, күзен йодрыклары белән уды… Юк, ул ялгышмый иде, каршыдагы аланда — зур зират, ә ак киемле кешеләр мәет күмеп йөриләр иде… Янәшәдәге йөк машинасы шыкыраеп каткан мәетләр белән тулган…

Куркыныч, сәер зират иде бу! Анда ник бер агач үссен, ник бер чардуган булсын! Шәп-шәрә җир һәм рәт-рәт каберләр… Кабер өсләрендә саннар язылган кечкенә такталар… «Нәкъ концлагерьлардагы кебек…» дигән уй сызылып үтте Әтил башыннан. Аның телевизордан, кинолардан күргәне бар: Сталин лагерьларында, фашист төрмәләрендә үлгән тоткыннарны номерлап кына күмгәннәр… Аларның барысын бер чокырга тутырганнар… Монда да нәкъ шулай бит: әнә инде әллә ничә мәетне бер чокырга ыргыттылар, берәүләр ташлый тора, икенчеләре шунда ук күмә бара… Болар өстендә җеназа укучы да юк, каберләренә тәре яки ай куючы да юк… Кемнәр бу мәетләр: татарлармы, руслармы, мөселманнармы, христианнармы — беркем белми… Алар ничек киенгән, шулай күмелә… Әйтерсең лә болар да төрмә тоткыннары…

Шулчак Әтилнең хәтеренә келт итеп Каһарман авылында Сөнгатулла абыйсы сөйләгәннәр килеп төште. Ул атом шәһәре астында тоткыннар эшләве, аларның рактан, нурланыш авыруыннан чебен урынына кырылулары турында сөйләгән иде бит! «Аларны шунда, шәһәр читендә, этне күмгән кебек, уртак чокырга күмәләр,— дигән иде.— Аларның исем-фамилияләре дә юк, исән вакытта да номерлап кына йөртәләр, үлгәч тә номер сугып күмәләр… Кайберләре әле үлеп тә бетмәгән була, дип сөйлиләр…» Димәк, Сөнгатулла абый барысын да дөрес әйткән, ул бу турыда яхшы белгән, монда тоткыннар каберлеге барлыгын да белгән…

Димәк, монда тоткыннар күмелә…

Шәһәрдән читтә, Ямантау итәгендә, урман эчендәге яланда, уртак чокырда исемсез тоткыннар күмелә… Сөнгатулла абый сөйләгәннәр барысы да дөрескә чыкса, көннәрдән бер көнне Әтилнең әтисе дә биредә булырга мөмкин… Бу куркыныч уйдан Әтил тораташ булып катты, тын ала алмыйча, җиргә ауды… Ул эссе көндә өши, туңуданмы, куркуданмы калтырый башлады… Шулай хәле бетеп ятканда, аның колагына мәет күмүчеләрнең сөйләшкәннәре килеп ишетелде.

— Кичке якта, тәмам караңгы төшкәнче, әле тагы берничә партия алып килә алабыз,— диде берсе, читкә китә төшеп.

Аның янына башкалар да җыелды, ахрысы, ял итеп алырга уйладылар. Алар авыз-борыннарын каплаган ак битлекләрен салып аттылар, урман читенә чүгәләп, тәмәке көйрәтә башладылар. Мәет күмүчеләр шулхәтле якын утырганнар иде, Әтил, тәмәке төтененнән йөткермәс өчен, авыз-борынын каплады.

— Алып килмичә, кая барасың, әле төнлә дә күмәргә туры килер,— дип җавап кайтарды аңа икенчесе.— Бу авария бөтен цехлары белән кырып салды бит… Әле ярый зеклар эшләгән участок булды, безнең халык алай зыян күрмәде…

— Зыяны барыбызга да тиде инде аның,— диде тагы берсе.— Аерма шунда гына: кем иртәрәк, кем соңрак китә… Анда газапланганчы, бу тюремщикларның монда ятуы хәерле инде… Радиациядән исән калган кеше юк әле… Ә монда кругом радиация…

Алар шактый сөйләшми утырдылар. Аннан битлекләрен киеп, яңадан мәет тулы чокырлар янына киттеләр. Чокырларны тиз-тиз күмеп бетереп, өсләренә саннар язылган агач такталар утырттылар да, машинага төялеп, аланлыктан чыгып та киттеләр. Әтил дә бу тирәдән тизрәк китәргә ашыкты. Ул яңа гына күмелгән мәетләр янында, тоткыннар зираты кырыенда калырга курыкты… Бу кешеләрнең, теләсә кайсы вакытта әйләнеп килеп, Әтилне күреп алулары мөмкин иде. Бу шомлы урынга соңгы тапкыр күз салып алды да ул, урман эчләтеп, Ямантауга таба йөгерде…

Кайчан да булса әтисенең дә шушы тоткыннар зиратында, исемсез уртак чокырда ятуын Әтил күз алдына да китерә алмады. Юк, юк, бу мөмкин хәл түгел иде! Аның әтисе, көчле, кодрәтле, акыллы, матур әтисе эт хәлендә шушы чокырда ятырмы?! Юк, юк, бу мөмкин хәл түгел! Әтил җир актарыр, тау ярыр, үзе тәгәрәп үләр, әмма әтисен монда яткырмас, монда китермәс… Ул инде хәзер бала түгел. Ул инде хәзер барысын да аңлый… Нинди илдә, кемнәр арасында яшәгәнлеген дә аңлый… Кемнәрдән куркыныч көтәргә кирәклеген дә белә… Исән калу өчен көрәшергә кирәклеген дә белә… Һәм ул әтисенең гомере өчен барыбер көрәшәчәк, нәрсә эшли ала, шуны эшләячәк…

Юлында адым саен очрап торган тимерчыбыклы коймаларны әйләнеп уза-уза, ул гел Ямантауның аргы ягына чыгарга тырышты. Шулай әйләнеп йөри торгач, ул инде барган юлыннан да адашты, чама белән генә бара башлады… Аның өчен төп маяк Ямантауның баганадай очлы түбәсе иде… Бер урында туктап, капчыгыннан алып ипиен ашады, суын эчеп куйды. Нарат урманы бетеп, инде катнаш урман киткән иде. Аяк астында, кызарышып, эре-эре җиләкләр тәгәрәп ята, уч-уч бөрлегәннәр явып утыра… Әтил аларны бик өзеп кабарга теләсә дә, куркуы җиңде, аларга кагылмады. Әнә бит мәет күмүчеләр: «Монда кругом радиация...» — диләр… Әтил ишетеп белә: атом калдыклары күмелгән җирләрдә, радиацияле урыннарда җиләк, гөмбә ише нәрсәләр зур булып, котырып үсәләр икән… Әмма аларны ашасаң, шул үтергеч радиация сиңа үтеп кереп, кешене тиз арада черетеп үтерәчәк… Әтил әле хәтерли: узган ел аларны Чиләбегә, радиация корбаннары музеена алып барганнар иде. Аны экологлар, табигатьне саклаучылар оештырганнар… Анда коточкыч нәрсәләр күреп кайтты Әтил. Спиртлы банкаларга салып куйган ике башлы балаларның мәетләре, койрыклы балаларның яралгылары, башлары корсактан үсеп чыккан, өч күзле, куркыныч гарип кешеләрнең фоторәсемнәре… Кыштым тирәсендәге кара янган үле җирләр, шушы тирәдә беренче атом бомбасын ясаган һәм хәзер дә атом белән эш итеп яткан «Маяк» комбинаты, атом шартлавы астында калып, череп яткан татар авыллары, шунда атом тәҗрибәсе өчен махсус калдырылган мөселман-татарлар, авыл башларында урман булып җәелгән тугызар, унар татар зиратлары… Әтил Чиләбедән шуларны кайтып сөйләгәч, әнисе Ырынбур өлкәсендә үз авылларының да нәкъ шул фаҗигале хәлдә калганлыгын әйткән иде… «Уралтауның бу ягы да тоташы белән атом каберлеге, улым»,— дигән иде… Ул чагында Әтил аңлап бетермәгән икән, аңа бабалары яшәгән Аксу да, үзләре яшәгән Тимертау да атом афәтеннән ерак тора кебек тоелган иде. Ә ул афәт әнә бөтен Урал тауларына, тау араларына, җир асларына таралган икән… Ул атом бомбаларын да шушында ясаганнар, әнисенең туган авылы өстендә — Ырынбур далаларында сынаганнар… Әнисенең сөйләве буенча, алар авылында инде бөтен кеше кан рагыннан үлеп беткән, шул исәптән Әтилнең әнисе ягыннан әби-бабасы да… Әтил аларны хәтта күрмәде дә, әнисенең фотолары аша гына белә… Әнисенең Ибрай авылында инде беркеме дә калмаган, барысы да яман шештән үлеп беткән… Әнисенең Әтилне анда бер тапкыр да алып кайтканы булмады. «Ул җирләр Чер-

нобль кебек, улым, анда яшәргә ярамый»,— дия иде… Ә шунда барыбер татарлар яшәп ята бит… Әле үлеп бетмәгәннәре…

Әтисе ягыннан әбисенең туган авылы өстендә, Кушъелгада — атом шәһәре, астында — атом базлары, радиацияле яшерен заводлар… Әбисен күмәргә хәтта татар зираты да калмаган, ул тирәләрдә хәзер — атом зонасы… Бәлки Әтил дә хәзер шул зона эчендә йөридер, әнә бит бөтен тирә-якка күгәргән тимерчыбык тарттырылган, әйтерсең лә пәрәвез оясы… Юк, үрмәкүч оясы гына түгел шул бу, ә аждаһа оясы, мең башлы гыйфрит оясы… Атом аждаһасы өне… Ул Әтилнең әби-бабалары җиренә үзенең агулы капшавычларын сузган, әтисен суырып алган, хәзер Әтилнең тормышына яный… Әгәр бу ябык шәһәр булмаса, әгәр монда җир астында, бөтен дөньядан яшеренеп, үлем кораллары ясап ятмасалар, әбисенең туган авылы Кушъелга да бетмәс иде, Әтил анда җәйләрен ялга кайтыр иде, ул әтисе, бабасы белән Ямантау башына менәр иде… Болай, карак кебек, үз илендә, үз туфрагында кача-поса йөрмәс иде… Юк, йөрмәс иде…

Каршында көтмәгәндә әллә кайдан килеп чыккан елганы күреп, Әтил аптырап калды. Елганың суы саф, ул шарлап ага, хәтта төбендәге зур-зур ташларга хәтле ап-ачык булып күренеп тора… Су очраганнан файдаланып, Әтил тирләгән бит-кулларын юып алырга уйлады һәм елга өстенә иелде. Әмма анда күргән нәрсәләр аның котын алды, ул, имәнеп, читкә тайпылды. Әтил зур таш дип уйлаган нәрсәләр — сәер, гарип балыклар булып чыкты. Алар дөм-сукыр, күзләре бөтенләй юк, ә тәннәре тишелеп, үлекләп беткән, уч-уч йолкынып, кубып чыккан иде… Арада хәтта кечкенә бүрәнә зурлыкларына хәтле бар… Аларны биредә тотучы да, ашаучы да юктыр, мөгаен. Шуңа күрә алар котырып үскәннәр дә үскәннәр… «Бәлки аларга да радиация тәэсир иткәндер, бәлки бу балыклар да, Чиләбе музеендагы экспонатлар кебек, мутантларга әйләнгәннәрдер?» — дип уйлады Әтил. Димәк, бу җирләрдә туфрак һәм һава гына түгел, су да агулы, радиацияле булып чыга? Әтил әле шунда бит-кулларын юарга уйлаган иде… Монда, әкияттәге кебек, адым саен куркыныч, адым саен бер бәла сагалып кына тора икән…

Елга артык зур булмаса да, Әтил аны ерып чыгарга батырчылык итмәде. Күрә торып радиацияле суга керәсе, бу мутант балыкларга кагыласы килмәде аның. Елганың тирәнлеген дә төгәл генә белеп булмый бит, бәлки аның уртасында муеннан урыннары да бардыр, белер-белмәс барып керсәң…

Ул елганың башланган урынын эзләп китәргә булды. Мондый елгалар, гадәттә, таулардан башлана, шушы су юлы буйлап барса, ул, һичшиксез, Ямантауга барып чыгачак иде… Юлында кешеләр генә очрамасын да, көтелмәгән хәлләр генә килеп чыкмасын…

Ул арада урман да сирәкләнә төште, шәһәр бөтенләй күздән югалды. Су юлы, ахры, тауның төньягына таба борылды — көн кинәт кенә караңгыланып, салкынаеп киткән кебек булды. Аяк асты да юешләнеп китте, баскан саен лычкылдап су чыкты… Әтил аяк киемен салып, тубыгыннан су ерып, елга яры буенча өскә таба менүен дәвам итте. «Инде бабай Җанбикә әбине күмеп кайтып та киткәндер,— дип уйлады ул, аларны да, үзен дә кызганып.— Бабасы Әтил өчен кайгырадыр инде, ачуланадыр… Бәлки болай, үз белдеге белән аерылып китеп, Әтил бик үк дөрес тә эшләмәгәндер… Әмма аның башка чарасы юк иде шул… Ул гомер буе бабасы чабуына ябышып йөри алмый бит инде, гел әкият кенә тыңлап яши алмый… Әтилнең әтисен табасы бар… Һәм ул аны дөньяның бөтен җиреннән эзләячәк: Урал тауларыннан да, Чечнядан да, җир астыннан да, җир өстеннән дә… Тиешсез урында тотсалар да, Әтилне беркем дә утыртып куймас, чөнки әле ул бала өммәтендә. Аның нинди зур эшләр белән йөргәненә ышанмаслар да, җәза да бирмәсләр…»

Әтил шулай дип уйлап бетерергә өлгермәде, аяклары, суырылып, салкын ләмгә кереп батты. Ул аларның әле берсен, әле икенчесен тартып алырга тырышты, әмма аяклары аңа буйсынмады, киресенчә, тарткан саен, ләмгә бата гына бардылар… Әтил башта берни аңламады, баткан җиреннән чыгар өчен чәбәләнде, чәбәләнгән саен, тирәнрәк батты. Менә ул инде тездән сазда басып тора, менә сасы исле салкын су аның бот төбенә җитте… Әтил шул чакта гына үзенең сазга кереп батуын аңлады. Ул, коты чыгып, як-ягына карады. Тирә-якта сирәк урман, түмгәкле салкын сазлык һәм елга гына агып ята иде…

Әтил тиз генә аркасына аскан аяк киемнәрен капчыгына алып салды һәм капчыгын болгап, агачлар арасына — корырак күренгән җиргә ташлады. Һәм кыймылдамыйча да уйлый башлады. Нишләргә? Кычкырыргамы, ярдәм сораргамы? Кычкырып, бу урман эчендә аны кем ишетсен, ишетеп, ни эшләсен? Тотып алып, ябып куярлар, бабалары эзләп тапканчы… Әтил шул хурлыкны күрер өчен монда калдымы? Кычкырмаса, шунда батып үләргәме? Ә нигә үләргә? Бәлки әле бу урын батып үләрлек тә түгелдер, ләм хәзер алай аска тартмый кебек, тик бик туңдыра, чиркандыра гына… Әтилгә хәзер ничек тә я коры җиргә чыгарга, я елгага керергә кирәк. Һәрхәлдә, елга төбендә, таш арасында сазлык булмас…

Әмма сазлык аны нык тоткан, аякларыннан келәшчә кебек эләктереп алган иде. Әтил хәзер генә үзенең ни дәрәҗәдә ялгышуын аңлады… Олылар белән киңәшмичә, беркемгә бер сүз әйтмичә,

бабасын, анасын, якыннарын кара кайгыга салып, чит, ябык шәһәрдә шулай юкка чыгарга тиеш идемени ул?! Әбисенең мәете күмелмәгән килеш калды, аның баш очында дога да кылмыйча, ул шулай качып китәргә тиеш идемени? Бәлки аңа хәзер әби-бабасының рәнҗеше төшкәндер, бәлки ул Аллаһның ачуын китергәндер, шушылай кылынганы өчен… Менә хәзер аның янында ярдәм итәрлек беркеме дә юк: әтисе дә, әнисе дә, бабасы да янында түгел, якын-тирәдә ярдәм итәрлек чит кешеләр дә юк хәтта… Инде ни булса да булыр, дип, Әтил хәлсез генә тавыш белән кычкырып та карады, әмма аның тавышын урман шаулавы һәм елга шарлавы басып китте… Ә салкын, лайлалы ләм һаман аска суыра, ул кыймылдаган саен тирәнрәк бата бара иде…

Әтил, башын күтәреп, күккә карады… Күк йөзен авыр болытлар каплап киткән, кояш шулар артына кереп качкан иде… Әмма күктә, бик-бик еракта, аны күзәтеп торган бер Зат барлыгын белә Әтил… Аңа бары Ул гына ярдәм итә ала иде… Инде билдән су эчендә торган хәлдә, Әтил елый-елый ерак күктәге Аллага ялвара башлады. Ул үзенең шулай качып китүе өчен чын күңелдән үкенүен әйтте, якыннарына башка мондый борчу китермәскә вәгъдә итте, Аллаһтан үзен бу бәладән коткаруын ялварды… Теленә, күңеленә үзеннән-үзе кичә кичтән өйрәнгән догасы килде, аны белгәненә сөенеп, ярдәм итәсенә чын күңелдән ышанып, ул кулларын күтәреп дога кыла башлады…

«Раббәнә әтинә фид-дүнйә хәсәнәтәү вә фил-әхирати хәсәнәтәү вә кыйнә гәзәбән-нәр»…

Берничә тапкыр шулай кабатлап, ахырында такмаклый-такмаклый татарча да ялынгач, Әтил, куллары арып, аларны түбән төшерде. Куллары инде су эчендә иде… Әтил, зур игътибар белән, тагы тирә-ягын карый башлады… Ниндидер өмет белән, ул артына да әйләнеп карады һәм үзеннән ерак булмаган зур, очлы ташка күзе төште… Таш малайдан ерак түгел елга ярында калкып күренеп тора иде… Артындарак булганга ул аңа игътибар итмәгән, ә бит ул шушы зур ташны файдалана ала! Малай, бөтен гәүдәсе белән ыргылып, җан ачысы белән, таш өстенә ташланды, аның очлы башын куллары белән чытырдатып кочып та алды. Таш селкенмәде дә, ахры, аның зур өлеше җир астында ята иде… Малайның гәүдәсе — суда, аяклары әле һаман салкын ләмдә иде, ә куллары инде очлы ташны ычкындырмаска эләктереп алган… Шулай бәргәләнә, тартыша торгач, саз ләме ташка биреште, теләр-теләмәс кенә малайны үзенең тырнагыннан ычкындыра башлады… Малай ташка битен куеп, соңгы җан көче белән тартылды һәм аякларының ләм пычрагыннан суырылып чыгуын сизде… Ул бөтен гәүдәсе белән сузылып, таш өстенә менеп ятты… Ул сазлыктан котылган иде… Аллаһ аңа ярдәмгә шушы җансыз ташны сәбәпче иткән иде…

Бераз шулай ятып хәл алгач, таш өстендә утырган килеш, малай җентекләп тирә-юньне өйрәнә башлады. Сазлыктан котылса да, ул әле тулысынча иркле түгел иде. Коры җиргә ныклап аяк басмый торып, Әтил үзен хәвефсез итеп хис итмәде. Хәзер нишләргә, кайсы якка китәргә? Алда, быкырдап, үзе әле генә котылган сазлык ята… Ул зур да түгел кебек, әнә аннан берничә адымда гына коры җир башлана, агачлар шаулап үсеп утыра, үләннәр күренә… Шул үләннәр арасында агарып, Әтилнең капчыгы күренеп ята… Уң кул якта — шарлап аккан билгесез елга, аның яр буйлары да, төбе дә зур-зур ташлар белән тулган… Менә бит, менә котылу кайда — Әтил шул ташларга басып, моннан чыгачак! Әнә ич алар ничек күп, әйтерсең Әтил өчен су төбенә, яр буйларына таштан юл түшәп куйганнар!

Ул тиз генә янәшәдәге ташка сикереп карады — таш селкенмәде дә… Аннан елга төбендәге башка ташларга күчә-күчә, Әтил алга таба китте. Яр буендагы корырак урыннан чыгып, ул капчыгын да барып алды, аннан тагы елгага кереп, таштан-ташка басып, аргы ярга чыкты… Чөнки монда куе чыршылар белән капланган тау итәге иде… Һәм шушы урыннан Ямантау башланып китә…

Малай тиз генә куе урман эченә чумды. Эчкәрәк кергәч, җылы курткасын астына җәеп, бераз ял итеп алырга уйлады. Аңа хәзер ныклы бер карарга килергә кирәк иде. Алга таба нишләргә? Шушы төпсез сазлыклар, радиацияле елгалар, куркыныч зиратлар аша үтеп, кичкә каршы яңадан шәһәргә кайтып егылыргамы әллә бу төнне инде Ямантауда гына үткәрергәме? Шәһәргә кире кайтса да, ул анда барыбер бабасын тапмаячак инде… Әле ул анда тиз генә кире кайта да алмаячак… Шәһәрдән зиратка кадәр генә дә алар машина белән күпме килде бит, ә Әтил — җәяүле… Ул, кире борылса да, инде барыбер төнгә калачак, караңгыда я адашачак, шул зират тирәсеннән уза алмаячак… «Иң яхшысы: төнне шушы тауда үткәрергә инде,— дип уйлады Әтил.— Иртәгә яктыргач, таудан төшәр, шәһәргә керер… Ә әтисе турында ничек, кемнәрдән белешер соң Әтил? Әллә туп-туры милициянең үзенә барып карасынмы? Алар әйтми инде аны, әлбәттә, әмма шундый кешене эзләгәннәрен белерләр иде…»

Бу уй-гамәлләренең барысын да Әтил иртәгәгә калдырырга булды. Әлбәттә, болайрак килеп чыгуына ул үзе дә бераз үкенә, алга таба үзбелдекләнеп йөрмәскә ул сүз бирде, әмма аның хәзер шушы тауда калудан башка чарасы юк… Ул бит инде Ямантау итәгендә, әнә каршыдагы очлы тауларга таба кояш тәгәрәп төшеп килә… Димәк, кич җитә, аннан Урал тауларына төн килер… Караңгы тәмам

төшкәнче, Әтил әле Ямантауның түбәсенә хәтле күтәрелә ала… Түбәсенә хәтле үк менмәсә, яртысына хәтле менәр… Шулай интегеп, монда хәтле килеп җиткәч, тау итәгендә качып ята алмый бит инде ул!

Әтил капчыгыннан чыгарып, тагы ипи белән суын ашап куйды. Аягына оекбашларын һәм кроссовкаларын киде. Аларның коры булуына Әтил сөенеп бетә алмады, юеш аяк киеме белән нишләр иде бу таш арасында! Курткасын кире капчыгына салып куйды, чөнки көн сүрәнләнсә дә, әле барыбер җылы иде, көне буе кызып яткан ташлардан җылы бәреп тора…

Уйларын һәм үзен тәртипкә китергәч, Әтил урман буйлап тауга күтәрелә башлады. Кояш тәмам баеп, караңгы төшкәнче, аның тизрәк тауга менеп каласы килә иде. Караңгыда күтәрелергә куркыныч буласын ул белә иде: тау бит бу, ялгыш бассаң да, өстенә таш төшүе бар, я үзең таш булып түбәнгә очасың… Сазлыкка батып бер бәлагә очрагач, тауда тагы авыр хәлдә каласы килми иде Әтилнең. Һәм ул мөмкин кадәр сак, уйлап эш итәргә тырышты.

Ямантауның итәгендә чыршы һәм карагайлар, каен агачлары шаулап утырса, югарырак менгән саен, Әтил табигатьнең кырыслана баруына игътибар итте. Агачлар күзгә күренеп сирәкләнде, каен агачлары тәбәнәкләнде, аларның кәүсәләрен әллә нинди җонлач мүк басып киткән… Тау биегәйгән саен, агачларның тәбәнәкләнә баруына игътибар итте Әтил. Әнә чыршылар да җиргә ябышып диярлек үскәннәр, аларның итәкләренә артыш куаклары тотынган, араларыннан хәтта үтеп тә булмый… Әйтерсең лә тиешсезгә тауга менүчеләр каршына калкан булып басканнар… Әтил әле хәтерли: Бәндәбикә әбисе Атасалда артыш ботакларын өйгә чир-зәхмәт кермәсен, дип җыеп кайта иде, аны ишек өсләренә, матчаларга кыстырып куя иде… Чебен-черки якын да килми иде ул вакытта аларга… Атасал тауларында Әтилнең ул артыш җимешләрен ашап та карганы бар — алардан төтен сыман әче тәм килә иде… Күгәреп, күзгә карап торган бу җимешләрне хәзер Әтил өзеп кабарга курыкты — алар радиациянең үзәгендә үсеп утыралар бит…

Ямантауга күтәрелгән саен, Әтил үзенең кайгы-борчуларын бераз оныта барды… Балалык, малайлык барыбер үзенекен итте — яшьлеккә озак кайгыру, өметсезләнеп утыру хас түгел бит… Аның тәненә көч керде, акылы ачык эшли башлады, авыр, кара уйлар каядыр качты, бу таудан аңа бар дөнья матур һәм якты булып күренде… Әнә бөтен җирне кантар-кантар ташлар басып киткән… Аларның коточкыч иләмсезләре дә, Әтил зурлыкларындагылары да, кечерәкләре дә бар… Алар биредә гаҗәеп күп һәм гаҗәеп матурлар… Һәрхәлдә, Әтилгә шулай күренә… Ямантауда ничек ямьсез таш була алсын инде, ул бит үзе дә гади генә тау түгел — Нух пәйгамбәр көймәсе килеп туктаган тау… Ул турыда уйлагач, Әтилнең күңелендә тагы күргән төшләре яңарды, дөньяны су басу, туфан турында укыганнары исенә төште… Ул төшләрендә, әтисе белән, шушы тау башында басып торды бит, әтисе, аны кулларына алып: «Менә, улым, безнең яңа җирләр шушы була инде — Туран иле…» — дигән иде… Их, хәзер дә бер могҗиза булсын иде дә, әтисе белән шушы тау буйларында йөгереп йөрсен иде Әтил… Бәхет өчен аңа шушы да җитәр иде… Ул бит Алладан күп тә сорамый — шушында әтисе белән очраштыруны тели… Ямантауның һәр ташына, һәр үләненә аяк баскан саен, ялварып сорый, бөтен бәгыре белән өзгәләнеп сорый… Әмма бу теләге тормышка ашканчы аңа әле шактый сынаулар үтәргә туры киләсен ул белми иде…

Әтилгә кинәт салкынча булып китте… Ул тиз генә капчыгыннан җылы курткасын алып киде. Капчыгы бушап калды: ипи инде ашалып беткән, су шешәсе дә буш иде… Алай да Әтил капчыгын ыргытмады, төреп, кесәсенә салды. Бушап калган су шешәсен да ташламады ул, кирәге чыгар, дип, икенче кесәсенә тыгып куйды. Инде куллары да бушап, иркенәеп калды. Ә кулларның буш булуы бик кирәк иде, чөнки кайбер урыннардан мүкәләп диярлек, дүртаяклап үтәргә туры килә… Артыш куакларының тамырларына ябыша-ябыша, үзе дә шулар кебек җиргә сеңеп бетеп, Әтил югарыга үрмәләвен дәвам итте. Ул күпме юл үткәнен дә, тауның кай тирәсенә җиткәнен дә ачык кына чамалый алмый иде…

Караңгы тәмам төшкәнче, Әтил тауга менәргә булды. Аннан берәр ышык җирдә туктар да төн үткәрер. Саклана торган шәһәр булгач, көн яктысында аңа иркенләп тауда йөрергә ирек бирмәсләр, шуңа күрә шушы эңгер-меңгер чакта күтәрелеп карап калырга кирәк… Ә иртәгә нәрсә булыр — Әтил әле үзе дә белми… Ул әле төнлә нәрсә буласын да белми, бераз курка, хәвефләнә дә… Әмма үз-үзен җиңәргә тырыша… Чөнки ул үзе шулай теләде бит… Артка инде юл юк, аста урман да сазлык, атом шәһәре, атом базлары һәм бөтен тирә-якта тоташ каберлекләр… Тауның үзендә, Ямантауның башында ниләр бар — Әтил белми… Бәндәбикә әбисе сөйләгән фәрештәләрме, тау түбәсендәге тылсымлы күлне саклап ятучы аждаһалармы, әллә инде шул тирәгә яшерелгән Нух пәйгамбәр көймәсеме… Бәлки анда яшерен атом объектлары, уран базлары бардыр… Алай дисәң, бу тау битләре сакчылар белән тулган булыр иде, ә алар монда бөтенләй күренми…

Шактый менгәч, Әтил тагы туктап ял итеп алды, озак кына як-ягына карап торды… Тирә-яктагы матурлыктан аның тыны кысылды, күзләренә яшь бәреп чыкты… Әнә кояш, кып-кызыл утлы шар

булып, ерактагы таулар артына тәгәрәп төшеп бара… Алда да, артта да, алсу офыкларга барып җиткәнче, дулкын-дулкын булып биек тау сыртлары сузылып киткән… Әйтерсең лә яшел урман диңгезендә йөзеп баручы кораблар… Аста, шактый еракта, урманнар шаулый, Ямантауның ике ягыннан ике елга агып ята… Куш елга… Җанбикә әбисенең авылына да шуннан чыгып исем куелгандыр… Әбисенең авыл урыны, мөгаен, тауның теге ягында калгандыр, чөнки бу яктан шәһәр бөтенләй күренми… Аның күренмәве Әтил өчен бигрәк тә яхшы, димәк, аны да күрмиләр…

Әтил тагы шунысына игътибар итте: монда чебен-черки бөтенләй юк иде. Астарак алар аның теңкәсенә шактый тиделәр, талап бетерә яздылар. Ә монда әйтерсең лә җан иясе бөтенләй юк… Һава шулхәтле саф, салкынча, әйтерсең лә бөтенләй башка дөнья… Ә җил гел дуылдап, шаулап исеп тора, бер генә мизгелгә дә тукталмый… Ул әле шапылдап, кыя-ташларга килеп бәрелә, әле артыш араларына ятып сызгыра…

Әтил тирә-яктагы агачларга да игътибар итте: алар бөтенләй тәбәнәк, кәкре-бөкре, күбесен мүк басып киткән иде… Әтил бу тирәләрдә корыган чыршыларның шактый булуына да игътибар итте, корымаганнарының да ботаклары бер яклап кына үскән… Каеннар да биредә нииндидер гарип һәм тәбәнәк иде… Аяк астында бәрхеттәй йомшак мүк ул баскан саен тибрәнеп, селкенеп куя… Әйтерсең лә Әтил Ямантауда түгел, әллә кайдагы тундрада йөри, биредәге табигать бөтенләе белән шул туң җирләргә охшап калган иде…

Әтил, башын күтәреп, өскә карады… Ямантауның каккан казык кебек очлы түбәсе куе болытлар арасына кереп югалган… Ә ул болытлар шәфәкъ алсулыгына манчылган… Әле анда хәтле шактый ерак күренә… Алда зур-зур таш кыяларны, тирән-тирән чокырлыкларны үтәсе бар… Алда — караңгы билгесезлек… Алда — чын Ямантау үзе басып тора…

Шунда Әтил кичә Бәндәбикә әбисенең Ямантау турында сөйләгәннәрен исенә төшерде. Авыл балалары белән бәхәсләшеп, ул да шулай Ямантауга менгән булган бит. Әмма ул ярты юлда арып егылган, алыптай фәрештәләр ярдәме белән генә исән калган… «Ямантауга менсәң, кайтыр юл юк инде,— дип сөйләгән иде аңа әбисе.— Тауның башында бер таш багана бар, дип сөйли иде борынгылар. Имеш, шул багана янында кечкенә генә күл бар икән… Имеш, шул күлдән аждаһа чыгып, яшен болытына әйләнеп, бөтен тирә-якның котын алып йөри икән… Шуңа күрә халык ул тауга менәргә курка икән… Шуңа күрә Ямантауга менсәң, кайтыр юл юк, дип әйтәләр икән…»

Әтил әллә куркып, әллә туңудан калтырап куйды. Бүгенге көндә елан-аждаһалар булуына бик үк ышанып бетмәсә дә, әллә нигә шомландыра… Бу Ямантауны Туран батыр үтергән Әзрәкәнең гәүдәсе дип тә сөйлиләр бит әле… Анысы да әкияткә охшаган, әле кайсы Ямантау турында сүз барганын да белеп булмый, алар берничә бит… Бәлки ул Шүлгәнташ тирәсендәге Ямантаудыр, бәлки алар бирегә килгәндә юл өстендә калган Кече Ямантаудыр… Бәлки Ырынбур далаларының төньягына урнашкан ялгыз Ямантаудыр әле… Ә бу Ямантауны Әтилнең һич кенә дә яман исем белән бәйлисе килми, чөнки аның өчен ул — төшләрендә Нух пәйгамбәр көймәсе килеп туктаган тау… Төшләрендә ул аны нәкъ шундый итеп күргән иде бит: өркәчләнеп, икегә аерылып торган биек түбә, туфанга калкан булып каршы баскан кыя ташлар, урманнары шаулап утырган тау аланлыклары, алып бабаларга туган йорт булган тирән тау куышлары… Әтил аларны төшләрендә ничәмә-ничә тапкыр күрде бит инде… Ул бу тауларда, бу тирәләрдә төшләрендә һәм хыялында күпме йөрде… Шуңа күрә дә Әтил алай ук курыкмый, Ямантау аңа күптән инде үз өе кебек якын… Бәлки, чыннан да, үз өедер, чөнки Әтилнең үз өе юк бит әле бу дөньяда…

Шундый уйлар белән дәртләнеп һәм җылынып, Әтил тагы өскә үрмәли башлады. Бу тирәләрдә җил тагы да усалланды, бит-кулларны өшетеп, яндырып исә. Тау җиле, ярсып, кыя-ташлар тирәсендә бөтерелә, артыш куакларының башларыннан йолкып үтә… Әйтерсең лә ул — шушы кыя-тауларның сакчысы, бирегә беркемне дә якын җибәрмәс өчен, мәңгелек каравылда тора… Аяк асты да инде тоташ мүккә әйләнде, ул, йомшак мендәр кебек, баскан саен батып, тибрәлеп тора… Кинәт кенә, әллә кайдан килеп чыгып, бөтен җиргә куе томан төште… Көчле җил, тау башындагы болытларның үзеннән умырып алып, биткә яңгыр тамчыларын бәрә башлады… Юк, аның һич кенә дә Әтилне тау түбәсенә менгерәсе килми, ул аны бөтен көче белән аска куа, этеп-этеп җибәрә, куртка якасыннан тотып селки… Әтилнең туңуының инде чиге-чамасы юк, ул күзләре белән ышык, куыш кебек җир эзли, шунда тукталып, төн уздырырга уйлый… Каршыда ике зур таш арасында каралып торган тау тишеген күреп, Әтил шул якка таба ашыкты. Шүлгәнташ авызына охшаган бу зур, коры мәгарә аны тын һәм җылы куышы белән каршы алды. Төн чыгарга җайлы урын табылганга куанып, Әтил эчкәрәк атлады һәм аяк астында җирнең читкә шуганын сизеп алды. Тиз генә артка чигенәм дигәндә, ул инде үзенең караңгы бушлыкка очуын аңлады… Мәгарә эчендәге тирән чокырдан ул аска — тауның үзәгенә таба оча иде…

* * *

Тәненең чатнап-чатнап авыртуына Әтил аңына килде. Аның башы гөжләп шаулый, һәм ул берни аңларлык хәлдә түгел иде. Кайда ята соң ул, нинди урын бу? Аксуда бабаларында, дияр иде, бу бит өйгә бөтенләй охшамаган… Тирә-якта зур-зур кыя-ташлар… Әллә ул Агыйдел буендагы Шүлгәнташта ятамы соң? Юк, Әтил бабасы белән беркөнне үк аннан кайтып китте бит инде… Алайса, кайда соң ул, бу нинди җир? Нигә ул җылы курткадан, кесәсендә буш шешә, буш пакет?

Кулы шушыларга килеп тигәч кенә, Әтилнең аңы ачылып китте. Ул бу шешәгә тутырып, су алган иде бит! Алар бабасы белән Аксудан атом шәһәренә килделәр, әбисен күмәргә… Әтил зират яныннан Ямантауга менеп китте… Юк, башта әле ул урманда адашып йөрде, аннан әллә нинди куркыныч зиратка килеп чыкты, аннан сазга батты, аннан тауга менде һәм, төн кунарга дип, тау куышына керде… Калганын Әтил хәтерләми, караңгы бушлыкка очканы гына исендә калган… Күпме шулай очкан ул, кайда килеп төшкән, бирегә күпме гомер яткан — Әтил берсен дә белми иде…

Әтил, авыр ыңгырашып, яткан җиреннән торып утырды. Димәк, ул Ямантауда, тау куышында, тау эчендә… Бәлки ул инде исән дә түгелдер, ә бәлки бу чираттагы бер төше генәдер, саташудыр… Әтил ул Ямантау белән бәйле төшләрне бик күп күрде бит инде соңгы вакытта, аларның берсе дә чын булмый иде, төш кенә булып чыга иде… Бәлки әле монысы да төш кенәдер, Әтил уянып китәр дә тагы саташуын аңлар…

Авырлык белән генә муенын борып, ул як-ягына каранды. Әлбәттә, төш бу, чөнки дөньяда мондый зур тау куышы буламыни? Моның бит бер башыннан икенче башы күренми, чакрымнарга сузылган таш бушлык… Җитмәсә, каршыдагы таш стеналар һаман киңәя, ачыла баралар, анда Әтил бөтенләй белмәгән тормыш кайнап тора… Әллә шәүләләр, әллә кешеләр, әллә җен-пәриләр, әллә инде фәрештәләр арлы-бирле үтеп йөриләр, таш стеналар чигенеп, аларга юл бирә… Зур, озын гәүдәле бу затлар үтеп киткәч, таш диварлар тагы ябыла… Нәрсә соң бу, ничек алар ташны тишеп, тау эченә кереп китәләр һәм тагы шуннан таш ярып килеп чыгалар? Кемнәр алар?

Кайдандыр салкын җил исеп киткәндәй тоелды, һәм Әтил гаҗәпләнеп өскә карады. Өстә, нәкъ аның турында, тау ярылып икегә ачылган, һәм күктән, тәгәрәп төшәрдәй булып, тулган ай карап тора иде… Күк йөзе бик караңгы да кебек түгел, аннан әллә нинди көмеш нурлар сибелә, салават күпередәй, аҗаган уйнап тора… Һәм шулхәтле моңлы, үзәкләрне өзеп елатырлык бер көй ишетелә… Ул бабасы укый торган азан тавышына да охшаган, башка аһәңнәр дә бар кебек… Аннан челтерәп аккан чишмә тавышлары, сандугачларның өздереп сайраулары, агач яфракларының лепердәшүләре ишетелә кебек… Һәм ул күктә канатлы фәрештәләр очып йөри… Көмеш нур да айдан түгел, алардан түгелә икән… Бабасы, фәрештәләр шундый икешәр, өчәр, дүртәр, хәтта унар канатлы була, ди торган иде… Ямантау өстен дә фәрештәләр саклый булып чыга инде, алайса… Бәлки алар Ата салын —Нух пәйгамбәр көймәсен шулай саклыйлардыр? Ә бәлки әле Әтилнең үзен саклыйлардыр?

Әтил күреп тора: Ямантау турындагы күк җиде кат икән, җиденче каты күз камаштыргыч тоташ нурдан тора… Анда дөньяда булмаган матурлык, җан рәхәте икән — Әтилнең дә тизрәк шунда барасы, мәңгегә шунда каласы килә… Өнә асларыннан татлы чишмәләр агып торган яшел бакчалар, ул бакчаларда Әтил гомерендә дә күрмәгән агачлар һәм җимешләр… Ул агачларда җәннәт кошлары сайрап тора… Анда яшь, көчле алып кешеләр яши икән… Аларның да йөзләреннән көмеш нур бөркелеп тора… Алар авыруны, кайгы-хәсрәтне, картаюны, хәтта үлемнең дә нәрсә икәнен белмиләр… Алар барысы да Адәм галәйһиссәлам озынлыгында — буйга алтмыш аршын, барысы да гел 33 яшьтә икән… Аларга дөньяда иң тәмле ризыкларны, иң татлы суларны, җәннәт җимешләрен китереп торалар… Җәннәт ияләренең өсләрендә озын яшел ефәк киемнәр, алар бер дә тузмый икән, гел төсләрен үзгәртеп торалар… Җәннәт ияләренә хур кызлары һәм егетләре хезмәт күрсәтә… Алар бу бәхет өчен Аллаһка рәхмәтләрен әйтеп, мәңге җәннәттә калалар икән…

«Менә җәннәт нинди була икән!» — дип уйлады Әтил, исе китеп. Аның да шул җәннәт кешеләре янына керәсе, шул изге, нурлы йортта мәңге каласы килде… Әмма моның өчен бу дөньяда бик күп сынаулар үтәргә тиеш икәнлеген дә белә иде ул…

Әтил, әле генә күргәннәреннән хисләнеп, аска карады. Һәм, коты чыгып, тизрәк таш стенага сыенды. Җир астында, кайнап, үкереп, җәһәннәм уты яна иде! Ул шулхәтле көч белән үкереп яна, аның ухылдаган тавышы хәтта тау куышына хәтле килеп җитә… Җәһәннәм уты, кара елан кебек, бөҗра-бөҗра булып уралып, җиде катлы булып яна… Анда утын урынына кешеләр һәм ташлар яна… Дөньядагы ут белән чагыштырганда, җәһәннәм уты җитмеш мәртәбә көчлерәк икән…

Җәһәннәм уты, мең ел шулай кыздырылып, башта ак төскә кергән, мең ел кыздырылганнан соң кара төс алган… Аллаһы Тәгалә җәһәннәмне өч мең ел буена шулай кыздырган, аның ут-ялкыны инде мәңге сүнмәячәк икән… Әгәр ул җәһәннәмнән инә очы хәтле генә бер тишек дөньяга ачылса, бөтен дөнья янып бетәчәк икән… Анда тирән коелар бар, ул коеларда еланнар һәм чаяннар мыжгып ята, алар

җәһәннәмгә эләккән кешеләрне тешләп газаплыйлар, бер тешләгәннең авыртуы кырык елга сузыла икән…

Шулчак Әтил тимер чылбырлар белән богауланган кешеләрне күргән кебек булды. Алар үкереп торган ут өстенә асып куелганнар… Бу кешеләрнең тәннәрендә тиреләре яна да, аның урынына тагы яңасы үсеп чыга икән… Шулай итеп, болар гел газапта, мәңгелек газапта… Аларның янып чыккан өске иреннәре башларын каплаган, аскы иреннәре аякларына хәтле асылынып төшкән… Алар тырнаклары белән күкрәкләрен канатканчы тырныйлар, бик нык кычкыралар, әмма аларга ярдәм итүче юк… Тимер тырнаклы җәһәннәм сакчылары аларны гел кыйнап, җәзалап торалар һәм:

— Сезгә җәһәннәм хакында хәбәр бирүче илчеләр килмәгән идемени?! — дип сорыйлар…

Җәһәннәм әһелләре:

— Килделәр, әйттеләр, әмма без аларга ышанмадык, алар ялганчылар, дидек, үзебезчә бозык яшәвебезне дәвам иттек,— диләр.

Һәм мәңгелек җәһәннәмдә акыра-бакыра януларын дәвам итәләр…

Әтил, куркып, бу коточкыч күренештән башын читкә борды. Бу бит — Җанбикә әбисе сөйләгән җәһәннәм! Ул бит, мәрткә китеп уянгач: «Аксу астында җәһәннәм бар, бөтен җир асты гөрләп яна»,— дигән иде… Димәк, әле генә Әтил җәһәннәмне күрде, һәм ул да шушында — Ямантау астында иде…

Әтил, утырган урыныннан сикереп торып, мәгарә буйлап йөреп китте. Бу хәлләрне күргәннән соң, аның хәтта үз авыртулары да юкка чыккандай булды, чөнки, җәһәннәм газабы белән чагыштырганда, ул бик кечкенә нәрсә иде…

«Нинди җир соң бу — җәннәтне дә, җәһәннәмне дә берьюлы күрсәтә алырлык? — дип уйлады ул.— Җиде кат күккә, җиде кат җир астына үтеп керерлек? Ямантаумы соң бу, әллә Әтил бөтенләй башка урынга килеп чыктымы? Менә бу таш стена артында ниләр бар?» Әтил, салкын ташка колагын куеп, теге якта ниләр булганын ишетергә теләде. Таш кыяның акрын гына селкенә, ачыла башлавын күреп, ул, куркып, читкә тайпылды. Тауның ишекләре ачылып китте, һәм Әтил үз каршында утлы төтеннәр чыгарып утыручы төнге шәһәрне күрде… Ни гаҗәп, ул биек-биек йортларны гына түгел, ул йортлар эчендә ни булганын да күреп өлгерде… Кайдадыр котырып, шашып бииләр, кайдадыр егылганчы эчәләр, өелеп сугышалар, кайсыдыр йортларда күзләре калайланган наркоманнар идәннәрдә тәгәрәшеп яталар, кайдадыр — зина, көчләү, үтерү, алдау… Тау араларындагы һәр шәһәрдә, һәр йортта шул хәл… Үзләре үк куйган тимер ишекләр, тимер рәшәткәле тәрәзәләр артында кешеләр хайван тормышы алып баралар, хәтта хайваннан да түбән, җирәнгеч нәрсәләр эшлиләр… Бу халыкта инде әдәп тә, әхлак та калмаган, алар динне белми, белергә дә теләми, монда инде намаз укучылар юк, Аллаһ онытылган иде…

Бу хәлләрне күрмәс өчен, Әтил башын читкә борды. Карашы шунда ук тирәндә булган җир асты шахталарына төште… Тукта, бу бит шахта гына түгел, бу — бөтен җир астын, тау араларын тутырып, җәелеп яткан яшерен шәһәр… Аның бер башы Ямантауга хәтле килеп җиткән, икенче башы Урал тауларының аргы ягына ук чыгып китә… Биредә очсыз-кырыйсыз завод цехлары, катлы-катлы зур биналар, зур-зур тимер чаннар, кайнап торган утлы мичкәләр, тирән-тирән шахталар, аларда яшерелгән атом реакторлары, ракеталар, җир асты тулы яшерен складлар, аларда атом-төш, химик, бактереологик үлем кораллары… Шулар арасында әрвахлар кебек өстерәлеп йөрүче токтыннар, үлем көтеп йөрүче эшчеләр… Җир асты шәһәреннән бераз читтә — бөтен дөньяның атом калдыкларын саклый торган җир асты күлләре, зур-зур резервуарлар, бөтен тирә-якны каплап киткән атом каберлекләре… Алар бөтен дөньяга зәңгәрсу үлем нуры — радиация таратып яталар…

Әле хәтта биредә дә кешеләр эшләп азаплана! Аяк-куллары озын чылбыр белән богауланган ак киемле кешеләр шушы чаннарга нидер ташыйлар, даими рәвештә нидер бушаталар… Кайберләре ярты юлда ук егылып, авып кала… Аларны башкалары тиз-тиз генә бер читкә өя баралар… Атлап барган җиреннән, тимер чылбырларын шалтыратып, әнә тагы берәү ауды, зур гәүдәсе белән агулы күл буена сузылып ятты… Аның янына тиз генә ак киемле берничә кеше килеп, тыңлап, капшап карадылар… Ахрысы, үлгәнлегенә ышангач, йөзендәге битлеген салдырып, ул кешене мәетләр әрдәнәсенә китереп ташладылар… Мәет, ап-ак йөзе белән, бу якка карап ята иде… Бу кеше Әтилнең әтисе иде…

Әтил, ачыргаланып кычкырып, аңа таба ташланды һәм маңгае белән таш стенага килеп бәрелде… Таш дивар ябылды, һәм аның тирә-ягында үзе яткан тау куышы гына торып калды…

Әтил, коты чыгып, башын селкеп куйды. Нәрсә соң бу?! Ул әле генә, ап-ачык итеп, әтисен күрде бит! Әтил аны миллион кеше арасыннан да бер күрүдә таныр иде… Әмма нигә аның әтисе мәетләр арасында ята? Әтисенә нәрсә булган? Ул, чыннан да, Сөнгатулла абыйсы әйткәнчә, шушы Ямантау астында, атом шәһәрендә микәнни? Җанбикә әбисе дә аны җир астында, Урал таулары арасында дигән иде бит! Әтил үз күзләре белән күрде: аның әтисен мәетләр арасына китереп ташладылар, аның зур яшькелт күзләре, Әтилгә томырылып карап, мәңгегә тынып калган иде…

Әтил, таш идәнгә бөгәрләнеп ятып, үксеп-үксеп елый башлады… Аңа хәзер үзе белән нәрсә булса да — барыбер иде… Чөнки аның әтисе үлгән, аның газиз әтисе юк иде инде… Таш стена аша, үткән замандагы туфан чорлары аша, хәтта киләчәк аша, томырылып, ул Әтилгә карап ята иде… Тукта, әтисенең яшькелт күзләрендә Әтил үзен дә күрде бит, аларда Ямантау түбәсе, борынгы Ата салы тибрәлә иде… Әтил үз күзләренә үзе ышанмыйча сикереп торды… Юк, Әтилнең әтисе үлмәгән, үлеп бетмәгән, ул бары тик Әтилне генә көтеп ята, аның ярдәменә мохтаҗ иде…

Әтил урыныннан сикереп торды. Ул, тау-ташларны ярып булса да, әтисен эзләп табарга тиеш иде! Ул бит җир астына алып төшә торган яшерен баскычларны да күреп өлгерде, атом калдыклары күмелә торган күлләрне дә күрде, әтисенең кай тирәдә ятканлыгын да белә… Ул алардан ялынып-ялварып, әтисенең гәүдәсен сорар, Урал тауларыннан тере суны табып булса да, әтисен терелтер, аякка бастырыр… Әтисе мәңгелеккә генә күзен йома күрмәсен, Әтилне генә көтеп ала алсын...

Шундый катгый карар белән Әтил алга таба атлады. Һәм, аптырап, кая барырга белмичә, як-ягына каранды. Аның дүрт ягында да таш стена иде… Аяк асты — таш, баш өстендә — таш, уңда — стена, сулда — таш кыя… Алай да баш очында ниндидер ярык шәйләнә, Әтил, мөгаен, шуннан аска егылып төшкәндер. Әмма анда болай гына менә торган түгел шул, ул шактый биек күренә. Ничек чыгарга соң моннан, ничек котылырга бу таш капчыктан? Әтил, гаҗизләнеп, мәгарәнең бер башыннан икенче башына йөренә башлады… Әле генә иксез-чиксез зур булып тоелган тау куышы тар төрмәгә әйләнде дә калды… Бу, чыннан да, Әтил өчен чын төрмә иде… Ашарына юк, эчәренә юк, кычкырса, мәңге ишетерлек кеше юк — Ямантау башында кем йөрсен? Һәм моннан чыгар юл да юк… Шулчак Әтил аяк астында аунап яткан таш кисәкләренә игътибар итте. Тукта, шушыларны җыеп, аларга басып күтәрелсә? Ул ашыгып-ашыгып тау куышы уртасына төрле зурлыктагы ташларны җыя башлады, аларны түбәдәге тишек турысына туры китереп тезәргә тырышты. Бераз җыйгач, өсләренә басып, түшәмгә үрелеп карады… Әмма түбәдәге тишеккә хәтле, ай-һай, бик ерак иде әле… Ул арада Әтилнең өйгән ташлары дөбердәп, ишелеп төштеләр, һәм Әтил үзе дә, шул ташлар белән бергә, бер читкә тәгәрәде… Әтил, чарасыз булып, таш идәнгә капланды…

Шулай капланып, шактый озак ятты ул… Һәм менә хәзер генә үзенең гаять авыр, яман, хәтта куркыныч хәлдә калганлыгын аңлап алды… Бу инде көн яктысында сазлыкка бату гына түгел, бу дөм-караңгы тау тишегендә бикләнеп калу, ачтан, сусыз кибеп үлү иде… Әтил, җан ачысы белән, соңгы көчен, акылын, өметен сакларга тырышты, чөнки өзгәләнә, бәргәләнә башласа, ул бик тиз бетәчәк иде… Аның соңгы өмете: «Мине барыбер эзләп табачаклар» дигән уй иде… Бабасы аны барыбер эзләтәчәк, ул аны нәкъ менә биредә, Ямантаудан эзләтәчәк, әмма тапмый туктамаячак… Шуңынчы ничек тә түзәргә, көчне сакларга, үлмәскә кирәк… Үзе белгән бердәнбер доганы укып, Аллаһның Әтилне коткарырга кешеләр җибәргәнен көтәргә кирәк… Аллаһ Әтилне барыбер коткарачак, барыбер коткарачак, барыбер коткарачак…

Шушы дога сүзләрен кабатлап, күпме ятты икән Әтил — ул белми… Бәлки берничә минут кына яткандыр, бәлки — берничә сәгать, бәлки — берничә көн… Бөтен дөньяны тетрәтеп килгән аяк тавышларына ул сискәнеп уянып китте… Дөпе-дөпе, дөпе-дөпе… Бу аяк тавышларыннан тау куышы селкенеп, Ямантау дерелдәп тора иде… Бу тавышлар җир астыннан киләме әллә тау түбәсеннәнме — Әтил аңлый алмады. Ул, коты чыгып, таш стенага елышты… Әмма Әтил якын килгән саен, таш кыялар артка чигенәләр, ачыла баралар иде… Тау куышы яңадан очсыз-кырыйсыз чикләргә хәтле киңәйде, шул бушлык уртасында Әтил берүзе утырып калды… «Инде ни булыр икән?» — дип, ул күзен аяк тавышлары яңгыраган якка төбәде… Ни булса да булсын, кем килсә дә килсен, бары тик Әтилне бу таш капчыктан алып кына чыксыннар, котылырга ярдәм итсеннәр…

Менә тау ишекләре ике якка ачылып китте һәм аннан галәмәт зур гәүдәле алыплар чыга башлады… Аларның өстендә җиргә хәтле тиеп торган озын ак күлмәк, башларында маңгайларын урап торган яшел кашбау иде… Аларның йөзләреннән шулхәтле көчле нур агыла ки, хәтта таш мәгарә эче дә кинәт кенә яктырып китте… Әтил аларны Шүлгәнташта күргән алыпларга да охшатты, әмма боларның куллары урынына ике яклап тезелеп киткән ап-ак канатлар иде… Әтил санап өлгерде: бишәр, хәтта унар канатлы алыплар да бар иде алар арасында… «Кемнәр булыр икән болар? — дип уйлады Әтил, бер читкә чигенә-чигенә.— Кешеләрме, җеннәрме, фәрештәләрме? Шүлгәнташта күргән алыпларның мондый канатлары юк иде бит, димәк, болар кешеләр түгел… Җеннәр булса, канатлары булмас иде… Димәк, болар — фәрештәләр… Канатлы фәрештәләр…»

Алар җир тетрәтеп якынлашкан саен, аяк асларында калып тапталмас өчен, Әтил читкәрәк чигенә барды. Менә бөтен тау куышына, Ямантау өстенә, бар дөньяга көчле, хәтта куркыныч тавыш яңгырады. Кайдан килә иде ул тавыш — күктәнме, җир астыннанмы — аңларлык түгел иде… Бу тавыштан тау куышында шыбырдашып ташлар коелды, җир селкенеп куйган кебек булды… Һәм бар дөньяга инде Әтилгә таныш булган сүзләр яңгырады…

**Бу җирләр тиздән кайнар ут булыр, тау аралары су белән тулыр…**
**Атом казаны тулып ташыр да, шушы хәл җитәр дөнья башына…**
**Утта янганнар уттан куырылыр, суга батканнар суга тончыгыр…**
**Атабыз салын эзләр меңәрләр, табар берәүләр, мәгънә белгәннәр,**
**Раббым, дигәннәр…**
**Шулар котылыр яңа туфаннан, әмма җир инде яшәрлек булмас…**
**Ата салына кереп изгеләр күчәр бу йорттан икенче йортка…**
**Безнең тарафка — мәңгелек яшәү, мәңгелек бәхет, җәннәт иленә…**
**Шуны аңлатыйк без кешеләргә : эшләре аша, төшләре аша,**
**[illegible]…**
**Барыбызның да Аңа кайтуны…**
**Вакыт аз калды, янып килә ут, азларны гына булыр коткарып…**
**Ышанганнарны, яшәгәннәрне бары Раббыбыз Аллаһ кушканча…**

Күкрәп торган тавыш тынып калды… Алып фәрештәләр, ак кул-канатларын күккә күтәреп, тәкбир әйтә башладылар…

Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

Ләә-иләһә-иллалаһу!

Аллаһу әкбәр! Аллаһу әкбәр!

Менә алар тигез сафларга тезелделәр, шаулатып азан әйттеләр һәм намаз укый башладылар… Әтил дә тиз генә аларның аяк араларына килеп басты. Аның бабасы белән намаз укыганы бар иде, шуңа күрә хәзер дә, алыплар нәрсә эшләсәләр, шуны эшләде. Әмма Әтил күңеленә, теленә ургылып дога сүзләре килгәнен сизде, ул моңа кадәр белмәгән Коръән аятьләре, аның мең еллык кан күзәнәкләрендә уянып, телгә килгәннәр иде… Әтил барысын да белә иде. ул белгәнәрен исенә генә төшерде… Ул фәрештәләр артыннан чын күңеленнән Коръән сүрәләрен кабатлады, ярдәм сорап, елый-елый бер Аллаһтан сорады… Ул җир астында үлеп яткан әтисен коткаруны сорап, күз яшьләре белән теләк теләде, үзен бу таш капчыктан тизрәк коткаруны ялварды, әнисенә, бабасына, барлык туганнарына, якыннарына, татар милләтенә иман бәхете теләде… Әтил тау куышында тынлык урнашуын да, үзенең бер ялгыз кычкырып-кычкырып теләк теләп утыруын да сизми калды. Шулчак кемдер аны сак кына тотты да югарыга күтәрде… Әтил, куркып, күзләрен йомды. Күзләрен ачканда, ул, кош баласыдай куркып, фәрештә канатында сыенып утыра иде…

— Хәсрәтең нәрсә, и нәни кеше? — дип сорады алып-фәрештә, пышылдап кына.

Аның пышылдап әйткән сүзләреннән дә мәгарә эчендә көчле җил кузгалып алды, түбәдән ташлар коелды, Әтилнең колак яфраклары ярыла язды… Бу фәрештәнең сулышыннан очып китмәс өчен, ул аның канат арасына кереп качты. Ул үзе курка, шул ук вакытта бу алып-фәрештәләрнең аңа начарлык эшләмәячәкләрен дә белә иде… Алар бит намаз укый торган фәрештәләр, ә намаз укучы башкаларга начарлык эшләми… Әтисе дә, бабасы да шулай дип әйтәләр иде…

Әтисе турында уйлауга, Әтил канат арасыннан башын чыгарды. Бу бәләкәй кеше тәгәрәп төшеп китмәсен өчен, фәрештә аны киң күкрәгенә таба кысты… Аның ак күлмәгеннән җәннәт исләре килеп тора иде… Мондый исне, мондый рәвешле затларны Әтилгә күрсәткәннәр иде инде… Шунлыктан бу фәрештә дә Әтилгә үз әти-әниседәй, бабасы кебек якын, кадерле булып китте… Һәм Әтил аларга үзенең серен ачарга булды.

— Анда, җир астында, минем әтием үлеп ята,— диде ул, бөтен көченә кычкырып.— Ул инде үлекләр арасында, әмма үлмәгән ул, үлмәгән… Ярдәм итегез, изге фәрештәләр?!

Алып-фәрештәләр бер-берләренә карашып алдылар.

— Без Аллаһ рөхсәт иткән очракта гына кешеләргә булыша алабыз,— диде Әтилне канат очларында тотканы.

— Әмма сез үзегез әле генә: «Ышанганнарны коткарырга кирәк»,— дидегез бит! Ә минем әти Аллага ышана, намаз да укый иде, мин дә ышанам бит, әни дә, бабай да ышана… Ярдәм итегез безгә…

Алып-фәрештә Әтилне әкрен генә җиргә төшерде дә зур таш өстенә утыртты. Барлык канатлы затлар да аның тирәсенә җыелдылар.

— Борчылма, кечкенә кеше,— диделәр алар.— Сезнең нәселне коткарырга Аллаһтан рөхсәт бар, без шул изге бурычны үтәү өчен биредә… Әмма син әтиеңне үзең коткарырга тиешсең.

— Мин?! — Әтил бөтен көченә кычкырып җибәрде.— Мин ничек коткарыйм соң аны — ул яшерен шәһәргә кереп тә булмый бит…

— Аллаһның рөхсәте белән, без сине өйрәтербез,— ди алып затлар.— Әмма син, биредән киткәнче, кайдан килгәнеңне белергә тиешсең… Бөтен сорауларыңа җавап табап китәргә тиешсең…

— Ә кайда китәм соң мин? — дип сорап өлгерде Әтил, әллә үлеме шушымы икән, дип уйлап.

— Кайдан килдең, шунда китәсең.

Җавап әнә шулай кыска һәм кискен булды. Әтил алардан яңадан нидер сорарга батырчылык итмәде…

Шунда Әтил каршында торган таш диварлар әкрен генә ачыла башладылар, һәм ул анда үзенең бөтен үткән гомерен күрде…

— Кара, бу — Гамәл көзгесе,— диде фәрештәләрнең берсе, Әтил өстенә иелеп.— Монда бөтен кешелекнең гомере чагыла… Кыямәт көнендә Раббыбыз һәркемгә бу дөньяда кылган эшләрен менә шул рәвешле күрсәтәчәк… Бу хәлдән беркем качып котыла алмаячак… Күп гөнаһлы кешеләр, бу хурлыктан качу өчен, хайванга әйләнергә теләрләр, әмма бу да мөмкин булмас… Үз тәннәреннән аккан сасы тиргә тездән, билдән, муеннан батып, кешеләр җир йөзендә үзләре эшләп киткән кабәхәт эшләрне менә шушы гамәл көзгесендә караячаклар… Бу хәл 50 мең ел барачак… Бу көндә бөтен сорауларга да җавап табылачак…

Һәм Әтил өстенә, чиксез таш экранны җимерерлек булып, тау-тау дулкыннар ишелеп килә башлады… Өстә, күзләрне ярып, яшен яшьни, колакларны ярып, күк күкри, аста, улап, җир яна, кешеләр су белән ут арасында бәргәләнә… Әнә Әтил әтисенең кулына чыпырдатып ябышкан, алар, билдән су ерып, качар урын эзлиләр… Менә әтисе аны кулларына күтәреп ала да яр кырыенда торган көймәгә таба алып китә… Бу сәер салга аларның бөтен гаиләләре кереп тулган, тик анда Түлгән абыйсы гына юк икән… Ул, исән калу өчен тәкәбберләнеп, биек тауларга таба йөгерә, әмма юлына таудай дулкын каршы төшеп, аны үз астында калдыра… Аны кара чоңгыл йота…

Югарыдан:

— Бу кеше, сезнең нәселдән булса да, сезнең өммәттән булмады, иман китермәде, шуңа күрә бу көндә аңа котылу юк,— дигән тавыш яңгырый…

Әтил, башын күтәреп, өскә карады. Алып-фәрештә аңа шулай хәлне аңлата икән…

— Ә Түлгән абый кайда соң хәзер? — дип сорарга батырчылык итте Әтил. Чөнки Җанбикә әбисе аннан Түлгән абыйсына ярдәм итәргә вәгъдә алды бит, бәлки ул да хәзер аның ярдәменә мохтаҗдыр…

— Ул үз юлын үзе сайлады һәм харап булды,— диде алыпфәрештәләр, тонык күкрәк тавышы белән.— Ул ислам дошманнарына ярдәмгә алынды, мөселманнар өстеннән шымчылык итте, кушкан буенча гына алар арасына кереп, монафикъ булып йөрде, дингә зур зыян салды… Кара!

Алар таш диварның икенче ягын көчле нур белән яктырттылар, һәм Әтил анда Түлгән абыйсын күрде… Менә ул Аксуда, Әтилне һәм аның әти-әнисен өйдән куып чыгара… Менә ул, Атасалга кайтып, аның әтисенә нидер яный, әнисенә бәйләнә… Менә ул Чечняда, милиция киемендә мөселманнарны үтереп йөри… Менә ул тагы шунда, әмма инде билдән сакал үстереп, мөселман кыяфәтенә кереп, чеченнар арасында йөри… Менә ул мөселманнар турында хәбәрне урысларга җиткереп тора, аларны тотарга һәм юк итәргә ярдәм итә… Менә ул бертуганы Туран хезмәт иткән Дагстан авылына үтеп керә, үзе кебек хыянәтче-монафикълар белән бергә, солдатларны, халыкны кыра… Авылга урыс армиясе бәреп кергәч, алар ягына чыга, аларга туганы Туранны тотып бирә, аны ваххабитларга атмауда гаепли… Менә Түлгәнне, шул ук мөселман кыяфәтендә, башта — Таҗикстанга, аннан Әфганстанга шымчы итеп кертәләр… Ул даими рәвештә Мәскәүгә хак мөселманнар турында хәбәр биреп бара һәм бу мөселманнарны төрмәләргә утыртып бетерәләр… Шулай итеп, мөселман кыяфәтендәге хыянәтче-шымчы булып, ул Әфганстанга ук барып җитә… Әмма утны-суны кичкән талиблар аңа ышанмыйлар һәм, шымчылыкта гаепләп, төрмәгә үк утыртып куялар… Инде тырнагын кимереп, үлем көтеп ятканда, Америка гаскәре Түлгәнне талиб төрмәсеннән коткара… Әмма, ул көткәнчә, Россиягә кайтарып җибәрми, ә океан артына — Кубадагы бер ялгыз утрауга озата… Аяк-куллары богауланган хәлдә, озак ята ул анда, хуҗаларының үзен килеп коткаруларын көтеп… Әмма Мәскәүдәге хуҗалар ачылырга ашыкмыйлар… Алар рөхсәтеннән башка, ул үзе дә ачыла алмый… Әмма утрау тоткыннары әкренләп бу бәндәнең кем икәнен чамалый башлыйлар… Аны тәүбә итәргә чакыралар… Әмма ул, тәкәбберләнеп, иманга килүне кире кага… Аның белән беркем сөйләшми, аралашмый башлый… Ялгыз утрауда бер ялгызы калган Урал татары, хуҗалары килеп коткарудан өметен өзеп, үз-үзенә кул сала… Бер атнадан Россия тоткыннарын илләренә кайтаралар, әмма Түлгән мәңгелеккә шул утрауда ятып кала… Аның илгә кайтуыннан мөселманнарга тагы да зуррак зыян буласын белеп, Аллаһ шулай хәл итә… Бу бәндә кеше булып дөньяга килә, монафикъ, икейөзле булып яши һәм мөртәт булып дөньядан китә… Һәм болар барысы да Гамәл китабына язылып куела, кыямәт көнендә дөньяга чыгарыла…

Әтил барысын да күрде, барысын да аңлады… Бу хәлләрне күреп, ул нык курыкты, тетрәнде, Аллаһтан бернәрсәне дә яшереп калып булмаганлыгын аңлады… Барысы-барысы да язылып, теркәп барыла икән һәм бу хәлләр кыямәт көнендә бөтен дөньяга күрсәтеләчәк… Зират буенда бабасын ташлап, качып киткәне өчен ул чын күңеленнән үкенде, чөнки бабасына китергән зур борчу өчен ул да җавап бирәчәк иде…

— Инде бу якка кара! — дигән тавышка, Әтил башын каршыдагы диварга таба борды…

Анда, төн караңгылыгында, иксез-чиксез су дәрьясы эчендә ялгыз көймә чайкала иде… Бу — Әтилләр утырган сал икән… Алар, бата-чума, һаман йөзәләр дә йөзәләр… Бөтен тирә якта су, су, бары тик су гына… Күпме шулай тоташ су диңгезендә йөзеп йөрделәр алар, Әтил белми… Менә көймә су эченнән төз багана кебек очлаеп күренеп торган бер кыя-тау каршына килеп туктый… Коры җир күренгәнгә барысы да шатланышып, көймәдән төшә башлыйлар… Туфаннан исән калганнарына сөенеп, дымлы туфракка тезләнеп, барысы да сәҗдәгә егыла… Алар белән бергә, кыя-таулар да, көймәдән чыккан кыргый хайваннар да, кош-кортлар да Аллаһка сәҗдә итәләр… Зур су күзгә күренеп чигенә, алар алдында мәһабәт тау калкып чыга… Ата салы, туктаган җирендә, тау башында утырып кала…

Кыргый хайваннар тау итәге буйлап чабып китәләр һәм күздән югалалар…

Кошлар да, аларны калдырып, күккә күтәреләә…

Кешеләр шул тауда яшәп калалар…

Алар арасында Әтил дә бар икән…

Әтилнең әтисе аны кулларына күтәргән дә:

— Менә, улым, бу безнең яңа җирләр инде,— ди.— Алыплар иле, Туран иле… Дөньяга кешелек яңадан менә шуннан таралачак…

Аста, тау итәгендә, иксез-чиксез диңгез җәелеп ята… Су чигенгән саен, тау сыртлары чыга бара… Төньяктан көньяккача алар тоташ чылбыр булып сузылганнар… Диңгез астыннан, зур кораб кебек, Урал таулары күтәрелеп килә… Алар басып торган тау исә дөньяның иң зуры, иң матуры, иң [illegible] икән…

Аларны кайда төшерергә кирәклеген Аллаһ Үзе хәл иткән…

Тирә-юньдә салкын сулы саф чишмәләр агып ята, тау битендә урман-болынлыклар шаулап утыра, кош-кортлар, киек җәнлекләр мыжлап тора… Аяк асты тулы гәүһәр ташлар, җемелдәшеп яткан зөбәрҗәтләр, алтын-көмеш чәчмәләре… Кешеләр алар өстеннән таптап йөриләр… Шунда ук — җил-давылдан саклый торган мәрмәр кыялар, кышын — туңдырмый, җәен эсселәтми торган таш мәгарәләр… Аларның беренче йортлары…

Бу — Әтилнең туган иле икән…

Атасалы, Туран иле икән…

Һәм бу җирләрне аларга Аллаһ үзе биргән…

Әтил, күзләрен ала алмый, галәм хәтеренә язылып барган кешелек тарихын карый, үз тарихын укый… Аның төшләрендә шушы галәм хәтере чагылган икән… Аларда да нәкъ шушы тау, нәкъ шушы гүзәл табигать, шушы тау куышлары иде бит…

Әнә ул кешеләр өстенә, яңа сынаулар булып, кар-боз афәтләре килә… Менә бу тау куышлары озак елларга алар өчен бердәнбер тору урынына әйләнә… Менә, Аллаһның рәхмәте белән, боз афәте чигенә, дөнья эри, җылына башлый… Кар белән бергә, алып кешеләр дә таудан төшәләр, су юллары буйлап, бөтен дөньяга таралалар… Туран-Урал тауларының башланган җирләреннән — Төньяк котыптагы Кар диңгезеннән алып, көньякка — Мөхит Адәм галәйһиссәламгәчә, ягъни Һинд океанынача аралар борынгы алыплар — төрки кавемнәр белән тула… Туран-Урал тауларының кояш чыгышы тарафына — Саба ирләренең Себер җирләре буйлап Америка кыйтгаларына кадәр Алып балалары — төрки халыклар таралып китә… Туран-Урал тауларының көнбатыш тарафына таба — алып-Альп, Балканнаргача, Садум-Скандинавия җирләренә, Атлантлар — алыплар океанын кичеп, янә Америка кыйтгаларынача, җир тетрәтеп, алып-төркиләр барып җитә… Алар җирдә зур дәүләтләр, көчле империяләр, тиңе булмаган шәһәрләр, зиннәтле курган-пирамидалар төзеп калдыралар… Бөтен җиһанга таралган бу төрки цивилизация Туран мәдәнияте дип атала…

Әтилләр нәселе шушы Туран таулары буенда — Идел —Җаек арасында яшәп кала, Себер киңлекләренә күчә, Алтай —Саян араларына, Архун — Анасу буйларына, чин сахраларына тарала, Идел буйлап Хәзәр диңгезенә хәтле төшеп утыра… Алар биредә татарларның бөек империяләрен, каганатларын, дәүләтләрен төзиләр, үзләрен «Күк уллары» дип атыйлар… Кайбер урыннарда исә аларны һуннар-сөннәр-гуннар дип йөртәләр, кайбер халыклар бу «Күк уллары»н тураннар, түркләр, скифлар, аргипейлар, кыпчаклар, хәзәрләр, болгарлар, суварлар дип атыйлар… Таш хәтер шуны күрсәтә: алар барысы да тере суы эчкән татарлар була… Алар моннан күп мең еллар элек, Туран тауларыннан тимер табып, корыч кою серләренә өйрәнәләр, бакыр коялар, алардан эш һәм сугыш кораллары ясыйлар, шулар ярдәмендә үзләренең данлыклы дәүләтләрен һәм шәһәрләрен саклыйлар… Әнә ул татарларның борынгы ил-дәүләтләре океаннан океангача, кыйтгадан кыйтгаларга сузылган… Әнә таш экраннан татарларның кодрәтле хан-каганнары карап тора: Кытайдан Рим империясенә хәтле җирләр тоткан Атилла патша, әнә Бумын каган, Истеми, Кара-Чура каганнар, данлыклы таш язмалар калдырган Күл-Тәгин, Билге каганнар… Әнә аларның ташка чокып язган васыять-кисәтүләре:

Төркинең бәкләре, халкы, сүземне тыңлагыз!

Кабиләләрне ничек берләштерергә кирәклеген әйтеп,
Мин монда ташка чокып яздым.
Ялгышу нәтиҗәсендә таркалачагыгызны әйтеп тә
Мин монда чокып яздым…

Әнә таш экранда тоташ тимердән киенгән, көчле атларга атланган, ярты җиһанны тетрәтеп торткан татар ирләре… Кубрат хан, Аспарух хан, Алмаз хан, Чыңгыз хан, Җуҗи хан, Бату хан, Нугай мирза, Үзбәк хан, Туктамыш хан, Идегәй мирза, Олуг Мөхәммәт хан, Хәлил хан, Ибраһим хан, Сәхип Гәрәй хан, Сафа Гәрәй хан, Сөембикә ханбикә… Таш экраннан алар тоткан ил-җирләр, дөньяда тиңе булмаган гүзәл шәһәрләр йөзеп үтә… Чин сахраларындагы кодрәтле Ханбалык һәм Каракорымнары белән, Идел буендагы гүзәл Болгар-Казан-Сарайлары белән, Урал тауларындагы кирмән-калалары — Аркаимнары, Торатаулары, Атасаллары белән, алар таш хәтергә мәңгегә уелып калалар… Бу ил-җирләргә туктаусыз һөҗүм итеп торалар, төрки-татарларны бер яктан кытай кавеме кысрыкласа, икенче яктан урыс халкы, ябырылып, өсләренә килә… Таш экранда да туктаусыз сугышлар, сугышлар, сугышлар… Төрки-татар дәүләтләренең берсе җимерелә, аның урынында икенчесе барлыкка килә, чөнки бетәргә язмаган барыбер бетми, тартыша, көрәшә…

Таш хәтер шуны күрсәтә: шушы мең еллык чорлар эчендә татарлар зур язма мәдәният тудыралар, дөньяга тиңе булмаган әдәби ядкарьләр калдыралар, милләтне бер дин һәм бер тел тирәсендә берләштерә алалар… Әмма, явыз күршеләр һәм эчке таркаулык нәтиҗәсендә, җир йөзендә татар дәүләтләре әкренләп юкка чыга… Тик тарихи хәтер барыбер сакланып кала… Мең еллар буе бер Аллага табынган Алып татар нәселе бу җирләрдә барыбер бетми, юкка чыкмый, илсез, дәүләтсез хәлдә дә исән калу юлларын эзли, көрәшә… Әнә дин, ирек өчен канга батырылган, очлы казыкларга утыртылган, телләре, борыннары кисеп алынган татарлар, әнә шул халыкны кяферләргә каршы яуга күтәргән Батырша хәзрәт, әнә Себер төрмәләрендә черегән, атып, асып үтерелгән татар муллалары, әнә Чечняда дин өчен шәһит киткән яшь татар-мөселманнар, әнә Ямантау асты тоткын татарлары…

Әтил, әсәрләнеп, таш экранга якынрак килде. Ул инде үз каршында бүгенге Урал тауларын, тау араларындагы хәерче, пычрак хәрби шәһәрләрне, эчеп азган халыкны, үлем коралы ясап ята торган яшерен хәрби заводларны күрде… Әнә сөргенгә сөрелгән татарларның сөякләре өстенә салынган Тимертау шәһәре… Әнә астында да, өстендә дә җәһәннәм тормышы кайнаган Аксу… Менә Ямантау астындагы яшерен атом шәһәре, уран шахталары, ракета базлары, атом каберлекләре… Әнә Урал тауларының аръягына урнашкан хәрби заводлар, атом бомбасы ясап яткан «Маяк» комбинаты, шул агудан череп, үлеп ятучы татар авыллары, дөньяда булмаган ахырзаман гарипләре, мутантлар… Туфаннан соң тормыш башланып киткән җәннәттәй җирләрне имансыз кешеләр җәһәннәмгә әйләндергән… Бу тирәгә тупланган атом калдыклары, үлем кораллары бөтен җир шарын бер мизгелдә юк итәргә җитә — таш хәтер шул хакта да кисәтә…

— Бу изге җирләр сезгә мәңгелеккә бирелгән иде,— дип сүзгә кушылды алып затлар.— Әмма сез бу җирләрне тота алмадыгыз, хәзер инде аңа имансыз кавем хуҗа… Хәзер инде бу җирләрдән бәрәкәт качты, иминлек бетте… Сез инде бу явыз кавемне җиңәрлек хәлдә түгел… Сез инде үзегез дә шундыйга әйләнеп барасыз, алар белән кан катнаштырасыз, гаилә корасыз, Туран нәселен бетерәсез… Аллаһның рәхмәте белән, сезнең иманлыларыгыз бу җирләрдән алыныр, шулай сакланып калырсыз… Чөнки бу җирләрне зур тетрәнүләр көтә…

Әтил әле генә таш экранда күргәннәреннән айный алмый утырды. Нинди бөек үткәннәр, нинди шанлы һәм данлы татар тормышы! Һәм нинди бәхетсез бетү… Әтил шуны аңлады: җире юкның — иле юк, иле юкның — дәүләте юк, дәүләте юкның милләте дә юк икән шул… Милләттә аерым татарлар бар алар әнә, гомер буе дин, дәүләт, тел өчен көрәшкән, шуның өчен газап күргән… Әмма инде бу югалган дәүләтне, җирләрне, данны һәм малны яңадан кайтарып алырлык татар милләте калмаган…

— Ә нигә без шундый хәлдә калдык икән соң? — дип сорады Әтил әллә үз-үзеннән, әллә сакчы фәрештәләрдән.

— Аллаһ бу җирләрне сезгә биргән иде,— дип кабатлады алар.— Сез әле ул вакытта иманда, берлектә идегез… Сезгә бу байлыклар, бу дан мәңге бетмәс кебек тоелды… Динегезне, илегезне ныклап сакламый башладыгыз… Үзара ызгыш-талашлар, сугышлар китте, күпләр, Аллаһны онытып, малга табына башлады… Моннан күршедәге явыз кавемнәр файдаланды — башта җирләрегезгә, аннан үзегезгә хуҗа булдылар… Сез күптән инде аларда коллыкта, әмма сез моны коллык дип белмисез… Диннән китү аркасында сез илне һәм үзегезне югалттыгыз… Әмма Аллаһның рәхмәте киң: ул сездән динне алмады, сезне бу тирәләргә имам милләт итте… Бу тирәдә дин бары тик сездә генә калды… Сезнең бу көнегез — Аллаһтан зур сынау ул, әмма бетү түгел… Һәм сез биредән вакытлыча гына китәсез…

— Ә… Кайда китәбез соң без? — дип сорады Әтил, ишеткәннәреннән тетрәнеп.

— Килгән җирегезгә китәсез,— диделәр алар.— Сез үз илегезгә — Ямән җиренә, Саба иленә, алыплар ватанына кире кайтасыз… Сезнең су төбенә киткән Атлантидагыз шунда… Менә, кара, кечкенә кеше… Сез әнә шунда барасыз…

Таш экран тагы хәрәкәткә, җанга килде… Анда башта бик сәер кыяфәттәге бер көймә пәйда булды. Ул Ямантау түбәсендәге күл төбеннән әкрен генә килеп чыкты да туктап калды… Тукта, бу бит — теге вакытта туфаннан соң, Урал тауларына килеп туктаган көймә, Ата салы! Ул үзе каек кебек, салга да охшаган, өсте тоташ каплаулы, димәк, ул су астында да йөзә ала… Әнә бит аның янында Әтил үзе дә басып тора, нәкъ бүгенге киеменнән… Һәм әтисе! Аның белән ак киемле тагы берничә кеше бар… Алар барысы да тиз-тиз генә шул көймәгә кереп утыралар… Меңәр еллар буе Ямантау түбәсендә, күл төбендә яткан көймә су өстендә бераз тибрәлеп тора да әкрен генә күмелә башлый… Менә ул күл өстеннән бөтенләй юкка чыга, җир астындагы су юллары буйлап кыйбла якка таба йөзеп китә… Җир асты дәрьялары буйлап алар озак йөзәләр, меңәрләгән чакрым юл үтеп, җирнең икенче ягына килеп чыгалар… Бу — яшеллеккә күмелгән бер утрау икән… Һәм аларның борынгы ватаны Атлантлар иленнән калган бердәнбер коры җир кисәге… Каршыда — Гаден култыгы аша — аларның төп йортлары булган Ямән иле, борынгы Саба җирләре җәйрәп ята… Утрау да, Ямән иле дә ямь-яшел җәннәт бакчасын хәтерләтә… Кайчандыр биредә алыплар яшәгәнен искә төшереп, җир-су атамалары сөйләп тора: Гад култыгы, Гаден шәһәре… Биредә хәзер бар халык ислам динендә икән, дөньяга кешелекне тудырган һәм туфаннан да исән калган халык, бер Аллага табынып, Ул кушканча яшәп ята һәм тарихи хәтерне саклап тора… Әтил хәзер шул борынгы иленә кайткан, һиҗрәт кылган икән…

Әйе, инде Әтилнең кан күзәнәкләренә дә тарихи хәтер салынды… Ул хәзер кешелек тарихын да, шуның бер өлеше булып торган татар тарихын да хакыйкый белү белән белә… Әйе, бу җирләрнең, бу зур тарихның күпчелегенә инде башка халыклар хуҗа… Әтил белә: кайчандыр бер Аллага табынган, соңыннан мең фиркагә, төркемгә бүленгән, үзара теткәләнеп, талашып беткән төрки-татар халкына бу да Аллаһның бер сынавы, җәзасы булып тора… Әтил белә: төрки-татар халкы кайчан тагы бер Аллага табына башлый, кайчан бер милләт булып берләшә, шул чагында тагы бу илләргә, җирләргә, зур тарихка хуҗа булачак… Әмма аңа хәтле әле бу халыкны, дөньяны зур тетрәнүләр, бәла-казалар, зур сынаулар көтә… Инде бу сынау аша бары тик иманлылар гына үтә алачак, исән калачак… Һәм таш экранда асты-өскә килгән шәһәр һәм авыллар, актарылып ташланган тау өемнәре, кара көеккә әйләнгән җирләр, сасып, бозылып яткан елгалар, шәмәхә төтен белән тулган агулы һава пәйда була…

Таш экран әкрен генә сүнде… Әтил озак кына аңына килә алмыйча утырды… Аның күз алдыннан һаман соңгы күренешләр китмәде… Аңа җирнең җәннәттәй чагын да, җәһәннәмгә әйләнгән вакытын да күрсәттеләр… Бер мизгел эчендә Әтилнең күз алдыннан бөтен кешелек тарихы үтеп китте…

— Менә син хәзер барысын да беләсең инде,— дигән тавышка Әтил уянып киткәндәй булды… Ул һаман тау куышында, алып-фәрештәләр арасында утыра иде.

Аның башыннан: «Ә этине ничек коткарырга?» дигән уй сызылып үтте. Болар бит бу турыда берни дә әйтмәделәр. Ә ул анда, җир астында, үлеп ята, үлекләр арасында ята…

— Сез этине ничек коткарырга кирәген әйтмәдегез бит, ә ул үлеп ята,— диде Әтил, яңадан үз дөньясына кайтып.

— Син әтиең турында барысын да беләсең, үзең күрдең,— диде алып-фәрештә.— Әтиең хәзер яшәү белән үлем арасында… Аңа син үзең ярдәм итәргә тиешсең…

— Сез миңа җир асты шәһәренә керергә ярдәм итәсезме?!

— Сиңа анда керергә кирәкми, бәләкәй кеше,— диде алып-фәрештә.— Хәзер игътибар белән безне тыңла һәм без әйткәнчә эшлә… Әтиеңне бүген төнлә җир өстенә күмәргә алып чыгалар… Син бүген ул зират яныннан үтеп киттең, хәтерлдәме?

— Әйе,— диде Әтил, уртак чокырга әрдәнәләп күмелгән мәетләрне исенә төшереп. Аның этисен дә шунда алып киләләр микәнни?!

— Аллаһ әмере белән, без ул мәет күмүчеләрнең күзләренә йокы салырбыз,— дип дәвам итте фәрештәләр.— Син этиеңә без өшкереп биргән тере суын бөркерсең — этиең терелер… Аннан монда кайтырсыз… Без биргән Ата салына утырып, җир асты суы буйлап җирнең теге ягына чыгарсыз… Шулай исән калырсыз…

Әтил үз колакларына үзе ышанмады! Алып затлар аңа тере су бирергә вәгъдә итәләр! Шуның белән этисен терелтергә өйрәтәләр! Нух пәйгамбәр көймәсенә утыртырга җыеналар! Дөньяда мондый могҗиза була аламы? Әллә соң Әтил һаман төш кенә күреп ятамы, бернинди Ямантау да, алыплар да, Нух пәйгамбәр көймәсе дә юкмы? Бу саташулардан айнып өчен, Әтил маңгаен таш стенага бәреп карады — маңгае шундук шешеп, күбеп чыкты… Юк, бу төш түгел иде, Әтил, чыннан да, әле һаман Ямантау мәгарәсендә ята, ә аның як-ягында алып-фәрештәләр тезелеп утырган иде…

— Ә нигә җирнең теге ягына чыгарга кирәк соң безгә? — диде ул, бу хәлләрнең чын икәнен аңлап.— Өйдә бит әни калды, бабай көтәдер… Без эти белән өйгә кайтырга тиеш бит…

— Сезгә монда калырга ярамый,— дип аны бүлдерде алыплар.— Бу җирләргә динсезләр хуҗа, сезгә монда авыр булачак… Аллаһның әмере белән мөселманнар чиста җирләргә күчәргә тиешләр… Бу җирләрдә зур бәла-казалар көтелә…

— Ә әни белән бабай нишли? — дип чәчрәп каршы чыкты Әтил, бу куркыныч хәбәрләрне ишеткәч.

— Сез барып урнашкач, алар сезнең янга үзләре киләчәк… Бу хәл бик тиздән булачак… Аллаһ ул яхшы бәндәләрен ярдәменнән ташламас, иншаллаһ!

Шул сүзләрне әйтте дә алып зат тауга кулы белән сукты, тау ярылып, аннан челтерәп чишмә ага башлады. Алыплар учларына шул суны җыеп, Әтилнең бит-кулларын юдылар, өстенә бөркеделәр… Әтил үзендә моңа кадәр булмаган көч-кодрәт сизде, курку-шикләнүләре юкка чыкты, ул үзен шул алыплар зурлыгында итеп хис итте. Аннан кесәсеннән тиз генә буш шешәсен чыгарды да тау ярыгыннан челтерәп аккан көмеш суны шунда тутырды…

— Ә нигә сез бу тере су белән Урал тауларын, үлем көтеп яткан дөньяны терелтмисез соң, монда күп бит әле ул? — дип сорарга батырчылык итте Әтил.

— Кешеләрнең башта күңелләрен терелтергә кирәк, балакай,— диде күк фәрештәләре.— Калебе бозык кешегә, бу черек тормышка тере су сибүдән мәгънә юк, алар барыбер тагы шундый хәлгә киләчәкләр… Кеше үзен Аллаһ барлыкка китергәнне һәм кабат Аллаһ каршына кайтасын онытты… Бу дөньяның бөтен бәлаләре шуннан… Адәм баласы Аллаһ кушканча яшәгәндә генә бәхетле булачак, шуны онытмагыз!

— Хәзер бар, аска төш,— диделәр алып затлар.— Барысын да без әйткәнчә эшлә… Тик таң атканчы бирегә кайтып җитегез…. Бисмиллаһи тәвәккәл Аллаһ!

Ул арада тау түбәсе икегә ачылып китте, һәм алып затлар, шул юл белән, күккә аштылар… Алардан иңгән көмеш нур ай нурлары белән катнашып, эреп таралды, күк йөзендә канат җилпегән авазлар гына ишетелеп калды, аннан ул да юкка чыкты… Мәгарә эче караңгыланып, тараеп китте. Шул чагында гына Әтил тау куышында бер ялгызы калганлыгын аңлады… Тукта, ә ул моннан ничек чыга соң? Ул бит үзе бу таш капчыктан чыга алмый!

Ул, ярдәм сорап, тау куышын яңгыратып кычкырып җибәрде… Һәм үз тавышына үзе сискәнеп уянып китте…

Әтил кичә кергән тау куышында, кичтән ничек ятса, шулай бөгәрләнеп йоклап ята иде… Һәм үз тавышына сискәнеп, ул уянып китте… Әнә бирердән тау итәге дә күренеп тора, көчле җил агач ботакларын, кыя ташларын шапылдатканы ишетелә… Өстә-аста бернинди тишек-ярык та юк, таш экран да күренми, алыпларның исә эзләре дә юк иде…

«Эх, тагы төш кенә булган икән! — дип уйлады Әтил, нәүмизләнеп.— Ә мин чын-чынлап ышанган идем бит… Әтине коткарам, Ата салында Ямән иленә китәбез дип хыялланган идем… Ә болар барысы да тагы төш кенә булып чыкты…»

Һәм нинди төш! Әтилнең әле гомерендә дә мондый ачык һәм хикмәтле төш күргәне юк иде! Алып затлар аңа Гамәл көзгесен күрсәттеләр… Анда бөтен кешелек тарихы язып барылган иде… Әтилгә Нух пәйгамбәр көймәсен дә, борынгы алып кешеләр тормышын да, борынгы татар дәүләтләрен һәм шәһәрләрен дә, Урал тауларындагы бүгенге хәлләрне дә, җир астында һәм җир өстендәниләр барлыгын да җентекләп күрсәттеләр… Мондый төш буламыни? Әтил аларны чын-чынлап күрде бит: аңа кешелекнең үткәнен дә, киләчәген дә күрсәттеләр… Юк, мондый төгәл төш була алмый, болар барысы да чын иде, бик җитди нәрсәләр иде һәм аңа кисәтү, юл күрсәтү булып яңгырады… Алай дисәң, мондый төшләрне Әтил элек тә күрә иде, алар барысы да төш кенә булып чыга иде шул…

Әтилнең бик нык авызы кибеп, эчәсе килеп китте. Шешә төбендә бераз су калмадымы икән, дип, ул кесәсенә тыгылды. Шешә су белән тулы иде… Әтил шашынып калды. Ул бит кичә суын төбенә хәтле эчеп бетерде, кирәге чыгуы бар, дип кенә, буш шешәне атмады, кесәсенә тыгып куйды… Ул беркайда да яңадан су алмады, кичтән шушы тау куышына керде дә йокларга егылды… Димәк…

Малай, әсәрләнеп, шешәсенә текәлде… Шешә су белән тулы һәм аннан көмешсыман нур сирпелеп тора иде… Әтил бу суның тамчысын гына эчеп карарга булды. Йотуга аның сулыш юллары киңәеп, тәннәре җиңеләеп китте, ашыйсы-эчәсе килүе дә онытылды, ул үзендә моңа кадәр булмаган көч-кодрәт сизде. Һәм ул аңлады: аның кулында тере су иде… Аны Әтилгә алып кешеләр бирде, ул шушы су ярдәмендә этисен коткарырга тиеш иде… Кояш чыкканчы, алар Ямантау түбәсендәге күлдән, Нух пәйгамбәр көймәсенә утырып, бирердән китәргә тиешләр… Аларны төрки-татарларның борынгы ватаны, Атлантидасы — Ямән иле көтеп тора иде…

Шулар искә төшүгә, Әтил урыныннан чәчрәп сикереп торды. Димәк, болар барысы да чын, димәк, ул бирердә төш күреп ятмаган, ә алып-фәрештәләр белән очрашкан! Ә алар Әтилне ничек итеп этисен

коткарырга өйрәттеләр… Кат-кат итеп: «Аны син коткарырга тиеш»,— диделәр… Хәзер Әтилгә бер генә минутны да әрәм итәргә ярамый. Кояш чыкканчы, аңа барысын да фәрештәләр кушканча эшләп өлгерергә кирәк…

Ул шешәсен кесесенә тыкты һәм йөгереп урамга чыкты. Урамда әле төн иде… Әнә күк йөзеннән түм-түгәрәк ай карап тора, ул алып фәрештәләрнең нурлы йөзенә охшаган. Көнчыгыштагы Мәшәк таулары әле хәзергә шул ай нурында коенып утыралар, әмма тиздән аларның түбәләрен шәфәкъ кызыллыгы күмәр… Аннан Урал тауларында таң атар… Әтил кояш чыкканчы фәрештәләр кушканны эшләп өлгерергә тиеш… Һәм ул, бөтен көче белән, таудан аска томырылды… Әллә тере суның ярдәме тиде, әллә этисен коткару теләге шулхәтле көчле иде: Әтил үзендә алыплар көче һәм егәре сизде, әйтерсең лә ул атлап түгел, очып бара… Төн булса да, бернидән курыкмый Әтил, чөнки аның беркем алдында да куркырлык гаебе юк, аның теләге изге — этисен коткару… Милләтне коткару… Кешелекне коткару… Әтил аның юлларын белә, чөнки ул үткәндәге ялгышларны белә, нәрсәләр ярамаганын белә…

Кичә менгән таныш юл буйлап, Әтил очып диярлек түбәнгә төшеп җитте, аннан елга ярлары буйлап югарыга йөгерде… Тулган ай, ул кая гына барса да, аның артыннан ияреп, юлын яктыртып барды… Борылышка җиткәч, бер-ике сикерүдә Әтил елганы ерып чыкты, аннан кара урман эченнән таныш каберлекне эзләп китте… Кесәсендәге шешәсен ул чытырдатып кысып тотты, аның өчен хәзер иң мөһиме: этисенең шул зиратта булуы иде…

Шомлы һәм куркыныч зират Әтилнең каршына үзе атылып килеп чыкты кебек… Үзенең исемсез каберләре, күмәк күмелгән чокырлары белән, ул урман аланында караеп ята иде… Анда кичәге машиналар да, кешеләр дә күренми… Бер кырыйда казылган тирән чокыр ыржаеп тора һәм аның янында әле күмелеп өлгермәгән мәетләр өелеп ята…

Әтилгә нәкъ шушы кирәк иде… Фәрештәләр хак әйткән: мәет күмүчеләр бу тирәдә күренми, алар, йокылары килүгә түзә алмыйча, эшләрен ташлап киткәннәр иде… Төн уртасы булса да, мәетләр янына барса да, Әтил курыкмады, Аллага тәвәккәлләп, зират буйлап йөгерде. Ул тау куышында күргән фәрештәләргә чын күңеленнән ышана һәм этисенең шушы мәетләр арасында ятуын белә иде… Әмма ул үлмәгән, фәрештәләр әйткәнчә, яшәү белән үлем арасында тартыша, ә аны инде монда китереп ташлаганнар… Тереләй күмәргә җыеналар… Әмма Аллаһның моңа рөхсәте юк, һәм Ул Әтилне этисен коткарырга сәбәпче итте…

Менә Әтил мәетләр янына килеп җитте. Алар кара җиргә әрдәнәләп өелгән һәм үзләреннән ак нур — үлем радиациясе таратып яталар иде… Моны күреп, Әтил чак кына читкә сикермәде, әмма шушы мәетләр арасында аның этисе дә булырга тиеш бит! Һәм Әтил аны коткарырга тиеш, нинди генә атом куркынычы булса да!

Әтил аны шунда ук күреп алды, этисе, яшькелт күзләрен зур итеп ачып, күккә карап ята иде… Әйтерсең лә ул үлмәгән, ә күктән ниндидер могҗиза, хәбәр көтеп ята… Аның ак йөзе тагы да агарып киткән, ак чәчләре белән төнге җил уйный… Аның өстендә дә, башкаларда да ак кием, алардан исә бөтен тирә-якка ак үлем — радиация таралып ята…

Әтил бераз калтыранган куллары белән кесәсеннән шешәсен чыгарды. Фәрештәләр өйрәткәнчә, бисмилла әйтеп, тере суны өч тапкыр этисенең өстенә бөркеде… Әмма этисендә бернинди хәрәкәт тә, җан әсәре дә сизелмәде… Авызына су алып, Әтил аны тагы аның өстенә бөркеде — этисе уянмады… Моны күреп, Әтил шашынып калды: ул этисенә ярдәм итә алмый иде, терелтә алмый иде!

Әтил ашыгып уйлана башлады… Кайда ялгышты, дөрес эшләмәде соң ул? Тукта, терелү өчен, тере суны эчәргә кирәктер бит?! Әтил шешәнең авызын иплән кенә этисенң иреннәренә тидерде… Этисенең бераз ачык калган иреннәре аша ул берничә йотым су тамызды… Этисендә хәрәкәт сизелмәде… Әтил, ачыргаланып, күккә карады… Күк читендә, Мәшәк таулары артында, сызылып таң яктысы беленеп килә иде… Моны күреп, аның тез буыннары йомшарып китте. Ул мәетләр янына җиргә утырды, шешәдәге су өстенә иелеп, Коръән аятьләре белән өч тапкыр өшкерде һәм, соңгы өмет белән, ул суны этисе өстенә бөркеде…

Шул чагында этисенең озын керфекләре тетрәнеп куйды, йөзенә таң алсулыгы иңгән кебек булды, шул алсулык белән бергә, әйтерсең лә аңа күктән тагы җан иңде… Ул, күзләрен зур итеп ачып, могҗиза күргәндәй, Әтилгә карады, үрелеп аның кулларыннан алды. «Улым…» — дип пышылдады…

Әтил аның күкрәгенә капланды… Ничек озак көтте бит ул бу мизгелне, ничек озак көтте ул этисен, бердәнберен, газизен!.. Ул үз куллары белән этисен торгызып утыртты, аның өс-башларын рәтләде… Башка вакыт булса, Әтил аны озаклап кочар иде, яныннан китмәс иде, барысын да сөйләр иде… Әмма хәзер Әтилнең бер минут та артык вакыты юк, әнә күк йөзе инде яктырып килә, кояш чыкканчы, әле аларга Ямантауга менеп җитәргә кирәк…

— Әти, безгә хәзер үк моннан китәргә кирәк,— диде ул, аны аякка бастырып.— Мин сиңа барысын да соңыннан сөйләрмен… Син бара аласыңмы?

Әтисе башта чайкалып куйгандай булды, ул тизрәк улы Әтилгә таянды. Аннан аның аякларына, гәүдәсенә көч кер-де, ахры, ул атлап ук китте. Әмма әтисенең әле шактый хәлсезлеген күреп, Әтил аңа шешәдәге калган тере суны сузды.

— Әти, менә бу суны эчеп бетер әле, бөтенләй терелерсең, чөнки бу — фәрештәләр биргән тере су,— диде ул.

Әтисе, гаҗәпләнеп, шешә төбендәге суга карады… Шешәдән көмешсыман нур сирпелеп тора иде… Әтисе, ышаныр-ышанмас, шешәне кулына алды, авызына китерде һәм, эчмичә, кулын кире төшерде… Аның карашы җирдә аунап яткан мәетләргә текәлгән иде…

— Терелтүче дә, үтерүче дә — Аллаһ, улым,— диде ул.— Башка нәрсәләр барысы да сәбәпче генә… Бу шифалы суны да сиңа фәрештәләре аша Аллаһ җибәргән… Аның миңа файдасы тигәч, башкаларга да файдасы тиюе бар… Биредә бу тере суга мохтаҗ һәм лаек кешеләр бар, улым…

Шулай диде дә ул җирдә аунаган мәетләр янына килеп чүгәләде… Ул аларның берничәсен аерып алды, башлары белән кыйблага каратып, сузып салды…

— Менә бу кешеләр — минем кебек үк мөселманнар, улым,— диде ул, алар өстенә карап.— Монда татарлар да, чеченнар да бар… Безнең барыбызны да шуннан кайтарып, менә бу атом шәһәре астына яптылар, үтерер өчен, радиация арасына ташладылар… Әмма Аллаһ бар! Аның тәкъдире һәм рәхмәте бар… Бу тере су башка мөселманнар өчен дә булырга тиеш, улым…

Шулай диде дә әтисе шешәдәге соңгы тере суны җирдә яткан мәетләр өстенә бөркеп җибәрде… Коръән аятьләре укый-укый, күккә карап, теләк тели-тели сипте ул бу суны… Соңгы тамчы тере суны исә, тезләнеп, һәрберсенең иреннәренә тидереп чыкты… Күккә — таң яктысы, кешеләргә җан иңде, алар, ахирәт көнендәге әрвахлар кебек, әкрен генә торып утырдылар… Аларның бер якларында үзләре өчен казылган кабер караеп ята иде, икенче якларында Туран кардәшләре басып тора иде… Аның янындагы ир бала, бер күккә, бер аларга карап, нидер сөйли…

— Әти, безгә ашыгырга кирәк,— ди ул, өзгәләнеп.— Кояш чыкканчы, безгә Ямантауга менеп җитәргә кирәк… Югыйсә барыбызны да тотып алулары бар…

Инде артык сүз сөйләргә, аңлатырга кирәкми иде… Алар барысы да кайда икәнлекләрен беләләр һәм монда бер минутка да калырга ярамаганын яхшы аңладылар. Иң яхшысы, менә бу бала әйткәнчә, тауга качу иде… Чөнки бу тирәдә калу турыдан-туры сакчылар кулына килеп керү дигәнне аңлата. Анда, тауда, әле төн җиткәнче берәр куышта качып ятарга була, аннан күз күрер… Аларны хәзергә беркем эзләмәячәк, чөнки алар барысы да мәет исәпләнә… Ә биредә мәетләрнең саны юк… Аннан, төн җиткәч, исәпләшерләр, уйлашырлар: кайсы якка китәргә, зонадан ничек чыгарга? Алар шулай уйладылар, әмма биек тау башында үзләрен нәрсә көтеп торганын алар күз алдына да китерә алмыйлар иде…

Менә алар Әтил артыннан кара урманга кереп югалдылар… Аннан, агач араларыннан кача-поса, Ямантауга күтәрелү башланды… Алар урманнан бик чыкмаска, кыя-ташларга сыеныбрак барырга тырыштылар, чөнки аларның ак киемнәре әллә кайдан күренеп тора иде… Күк йөзе яктырганнан-яктыра барды, әмма әле кояш чыкмаган иде… Кояш чыкканчы, тәмам яктырып беткәнче, аларга тау башына менеп җитәргә, күздән югалырга кирәк иде…

Югарырак күтәрелгән саен, һава суыта барды. Әллә кайдан көчле җил килеп чыгып, кешеләрне йолыккалый башлады… Аннан, аларны танып алгандай, кинәт кенә тынычланып, кыя-ташлар артына кереп посты… Монда һавалар иркен, дөнья искиткеч гүзәл, табигать тетрәндергеч иде… Әле генә үлеп яткан, үлемнән калган, мәңгелек әсирлектән котылган кешеләр өчен бу дөнья җәннәт булып күренде… Алар туңуны да, арыганлыкны да, ачлыкны да сизмәделәр, чөнки алар иректә иде! Алар исән иде! Алар шуның белән бәхетле иде…

Тагы бер-ике адым, һәм Ямантауның түбәсе — бу дөньяда алар качар, сыенып өчен хәзергә бердәнбер урын… Әнә ул түбә, багана кебек кыя-ташын болытлар арасыннан калкытып, көтмәгәндә каршыга үзе килеп чыкты… Әйтерсең лә ул шушы күк йөзеннән, болытлар арасыннан йөзеп килә иде… Кыя төбендә түгәрәк күл дә бар икән… Һәм шул күлдә алар моңа кадәр гомерләрендә дә күрмәгән бер каек тибрәлеп тора… Бу нинди могҗиза, кем әзерләгән бу көймәне монда алар өчен, аның белән бу тау башыннан кая барырга мөмкин? Алар, телсез калып, шул көймәгә текәлделәр… Ә көн инде бөтенләй яктырып, Мәшәк тавы артыннан менә-менә кояш килеп чыгарга тиеш иде…

— Әти, без тизрәк шушы көймәгә керергә тиеш,— диде Әтил, әтисен күлгә таба тартып.— Кояш чыкканчы, без моннан китәргә тиеш…

Аннан беркем дә: «Нигә алай?» — дип сорамады. Кайда китсә дә китсен бу каек, әмма биредән генә китсен, атом зонасыннан чыксын… Күккә ашамы, җир астына төшеп китәме — алар өчен барыбер, тик

кяфер коллыгыннан котылырга гына ярдәм итсен… Бу көймәнең өсте тоташ ябык, үзе гаять зур — йөзләгән кешене сыйдырырлык, һәм бер генә тишек-ярык та күренми… «Мөгаен, су астында да йөзә аладыр бу могҗиза»,— дип уйладылар алар һәм бу эшне Аллаһ рәхмәте итеп кабул иттеләр…

— Аллага тапшырып керәбез, улым,— диде Туран, көймәгә таба ашыгып.— Әйдәгез, кардәшләр, Аллаһ ярдәмчебез булсын…

Ирләр, тәкбир әйтеп, Ата салына утыра башладылар… Туран белән Әтил, бәхилләшкәндәй, соңгы тапкыр Урал тауларына, туган якларына, шаулап утырган яшел урманнарга күз ташладылар… Кая карама, дулкынланып яткан тау сыртлары, тау сыртлары… Аларның түбәләре иртәнге томан арасына кереп югалган… Тиздән бу якларда кояш чыгар, ул мәңгелек томаннарны куып таратыр, Урал күкрәгенә күктән тагы җылы агылыр, нур агылыр… Әнә Ямантау өстеннән ялгыз бөркет очып узды, әйтерсең лә ул алар белән бәхилләшер өчен генә шушы биеклекләргә күтәрелгән, әйләнеп, баш очларында очып йөри…

Хуш, Уралтау бөркете, хуш, Уралтау өстендәге зәңгәр күк, хушыгыз, чал Урал таулары… Без сезгә кайтыр өчен китәбез… Бәлки йөз еллар, бәлки мең еллар үтәр, әмма без монда барыбер кайтырбыз, үз Уралыбызга үзебез хуҗа булыр өчен кайтырбыз, кыя-ташларны кочаклап елар өчен кайтырбыз, изге җирендә җан бирү өчен булса да кайтырбыз… Без кайту өчен китәбез… Тарихи хәтерне үзебез белән алып китәбез…

Ата белән ул, соңгы кешеләр булып, көймәгә кереп утырдылар. Ишекләр тавышсыз гына ябылды, Аллаһның рәхмәте белән, көймә хәрәкәткә килде һәм суга күмелә башлады… Көймә башта чирек өлешен батты, аннан — яртылаш, аннан инде түбәсе дә су төбенә китеп, юкка чыкты… Мәшәк тавы артыннан атылып килеп чыккан кояшның беренче нурлары, Ата салы белән хушлашып калырга теләгәндәй, күл өстендә бераз җемелдәп торды да, бу хәбәрне җиһанга җиткерү өчен таралды… Ә дөнья әле йоклый иде, ул, Ата салының хәрәкәткә килүен дә, яңа туфан кубарга бик аз вакыт калуын да белмичә, дөнья үлек йокысы белән йоклый иде…

* * *

…Ямантау итәгеннән, этләр тотып, хәрбиләр йөгергәне күренде… Алар арасында кичәге шофер егет тә бар… Өйрәтелгән этләр, Әтилнең аяк эзләре буйлап, туп-туры тау куышына таба чабалар… Хәрбиләр аларны, кулдан ычкындыр-мыйча, чак тыеп торалар, ычкындырсаң, алар малайны шундук өзгәләп ташлаячак… Ахыр чиктә алар этләрне барыбер җибәрәчәкләр, чөнки мондый зур таудан кешене башкача эзләп табу мөмкин түгел… Ямантау зонасына яшерен керергә теләгән һәркемнең язмышы әнә шулай тәмамлана…

Менә этләр, ыргылып, тау куышына ябырылдылар, әмма яман чинап, ток тоткандай, шунда ук артка ташландылар… Ни хикмәт, этләрне берничек тә тау куышына кертеп булмый иде, әйтерсең бу мәгарәне ниндидер кодрәтле көчләр саклап тора…

Этләр кермәгәч, хәрбиләр үзләре тау куышын әйләндереп алдылар һәм аның эчен көчле фонарьлар белән яктырттылар… Куыш эче буш иде, бары тик бер пакет кына, тыштан кергән җил белән, бер баштан икенче башка очып йөри… Шофер егет шунда ук бу капчыкны танып алды. «Кичә аның кулында шушы пакет иде, димәк, ул монда булган»,— дип, үз фикерен әйтте… Әмма кая киткән соң ул малай? Этләр шушында килеп туктадылар, ә куыш эче буш… Хәрбиләр тагы бер тапкыр кереп, тау куышын яхшылап тикшереп карарга булдылар, үзләре белән өйрәтелгән этләрен дә өстерәделәр… Этләр исә чиный-чиный каршы торды, тырнаштылар, аяк терәделәр һәм ахырда күккә карап улый ук башладылар… Куркыныч, дәһшәтле күренеш иде бу, хәрбиләр тормышында моңа кадәр күрелмәгән хәл иде… Аларның үзләрен дә курку басты, әмма эшне ахырга кадәр башкарырга, тау куышын җентекләп карап чыгарга кирәк иде…

Берничә кешене этләр белән тышкы якта калдырып, алар эчкә атлады...

Кинәт мәгарә эче көчле нур белән тулды, астан җирнең гүләп күтәрелгәне ишетелде, аяк астында тау селкенә башлады… Хәрбиләр, котлары чыгып, куыш авызына ташландылар, әмма соң иде инде… Алар басып торган таш, убылып, аска очты, аннан исә ут-ялкын бәреп чыкты… Эчтәгеләрнең тереләй януын күреп, тыштагылар таудан аска ташландылар… Әмма аларның да юлларын Ямантаудан атылып төшкән зур-зур ташлар, кыялар бүлде, алар астында сытылып, барысы бергә таудан тәгәрәде…

Мең-миллион еллар дәшми торган Ямантау, Аллаһ кодрәте белән, телгә килгән иде…

Үзенә хуҗа булырга теләгән оятсыз бәндәләрне ул бер мизгел эчендә җир белән тигезләде…

Өсләренә ут яңгыры яудырды…

Азган шәһәрләрен әйләндереп каплады…

Җәннәттәй җирләрен җәһәннәмгә әйләндергән өчен, Ямантау барысыннан да үч алды…

Ул аларның җирдәге тормышларын җәһәннәмгә әйләндерде…

Бу фаҗигадән бик азлар гына котыла алды…
Аллаһ теләгәннәр генә исән калды…

* * *

Яңгырлы көзге көн…

Торатау шәһәре буйлап, таякка таянып, бер карт килә… Ул инде бик карт, аңа йөз яшьме, меңме әллә аннан да күбрәкме — беркем белми… Аның ап-ак чәчләрен көзге җил тузгыта, зур яшькелт күзләрендә ерактагы Урал таулары чагыла…

Көн инде кичкә авышып бара, әмма кояш әле батмаган… Картка, кояш баеганчы, кичкә кадәр бер йортка барып җитәргә кирәк. Шуның өчен ул, ярты дөньяны гизеп, монда кайтты… Биредәге шәһәр музеенда бик борынгы заманнардан — туфан чорыннан калган бер таш барлыгын белә ул. Аның шул хакта әйтеп калдырасы сүзе бар… Ул инде гомеренең ахырына җитеп килүен сизә, һәм бу дөньяда бары ул гына белгән хәбәрнең үзе белән китүен теләми… Шуңа күрә, кояш баеганчы, ул йорт ябылганчы, аңа өлгерергә кирәк…

Кичке як булса да, йортта кеше шактый булып чыкты. Могҗиза күргәндәй, барысы да шул таш тирәсенә җыелганнар… Ташның буеннан-буена, чокып-чокып, нидер язылган, әмма аны дөньяда беркем дә укый белми… Менә хәзер дә ул Язулы ташны кинога төшерәләр, рәсемен алалар, таш билгеләрне күчереп язып карыйлар, әмма беркем дә мәгънәсен аңлый, аңлата алмый…

Чал карт та Язулы таш каршына килеп туктады. Ул аны шунда ук таныды, бу аның туган авылындагы кыя-таш иде… Бу — Атасал ташы, шуның хәбәре иде…

Карт таш каршына барып басты һәм әкрен генә анда язылганнарны укый башлады:

**Тетрәде җирләр, ярылды күкләр, ике арада җилләр улады…**
**Астан ут бәрде, өстән су акты, беркайда качар урын калмады…**

Музейдагы кешеләр, ашыгып, карт янына җыела башладылар… Нәрсә сөйли бу сәер карт, нәрсә укый ул? Әллә соң Язулы ташның серен ачканмы? Тик нинди телдә сөйли соң ул, кем аңлый? Кем бар аңларлык, тизрәк килегез, аңлатыгыз?!

Карт, аларның аптырап гөжләшүләренә карамастан, таш билгеләрне укуын дәвам итте:

**Ата — баланы, бала ананы күрер булмады, белер булмады…**
**Бер-берләренең басып башына исән калырга алар тырышты…**
**Әмма бу көндә качу юк иде, туфан суында бар да тончыкты…**

Карт тирән итеп тын алды да як-ягына карады. Кешеләр, тыгыз бөҗра булып, картны әйләндереп алганнар иде. Алар авызларын ачып, аңа текәлгәннәр, кемдер аның әйткәннәрен язып, кемдер яздырып барырга тырыша… Күпләрнең күзләрендә гаҗәпләнү һәм сорау иде.

Карт, шомлы һәм моңлы тавыш белән, Язулы ташны укуын дәвам итте:

**Тик сездән кала — сезгә Аллаһның рәхмәте иңде —**
**Ышанган өчен, буйсынган өчен сезгә бирелде тылсымлы көймә…**
**Утта да янмый, суда да батмый, буйсынып бары Аллаһ иркенә…**
**Тылсымлы көймә килеп туктады күгәреп торган тауның читенә…**
**Сезнең өегез шушы тау булды, су белән бергә таудан төштегез…**
**Җирдә кешелек икенче тапкыр сездән таралды —**
**Шуны белегез!..**

Карт тагы туктап калды. Кешеләр дә, инде берни дәшмичә, тып-тын басып торалар иде… Алар картның укып бетерүен көттеләр… Карт дәвам итте:

**Туран тавының ике ягында, карлы илдә дә, кайнар чүлдә дә,**
**Аллаһ гыйлемен сез тараттыгыз, хаклыкны җирдә сез**
**аңлаттыгыз…**
**Шуның өчен бит җирдә калдыгыз, туфан суыннан исән**
**калдыгыз —**
**Аллаһ нәкъ сезне сайлаган өчен…**
**...Бу юлдан әгәр читкә чыксагыз — әгәр Аллаһны сез онытсагыз —**
**Тетрәнер җирләр, ярылыр күкләр, ике арада җилләр уларлар…**
**Астан ут бәрер, өстән су агар, беркайда качар урын тапмассыз…**
**Ата — баланы, бала — ананы бар дип тә белмәс, газабын күрмәс...**
**Бер-берләренең басып башына, исән калырга алар тырышыр…**

**Әмма бу көндә котылу булмас, туфан суында бар да тончыгыр…**

Карт укып бетерде дә өстеннән тау төшкәндәй туктап калды. Шушы сүзләрне әйтер өчен, кешеләргә шушы борынгы таш язманы укып бирер өчен, дөньяны яңа бәла-казалардан кисәтер өчен, ул җиде диңгезләр кичеп, бирегә кайтты… Ул соңгы сүзләрен әйтергә иленә кайтып өлгерде…

Әмма тирә-яктагылар тып-тын басып торуларын дәвам иттеләр… Чөнки бу илдә, бу җирдә бу сәер картның телен аңларлык бер кеше дә калмаган иде…

Әтил карт моны үзе дә аңлады… Бу илдә аның инде теле дә, дине дә, нәселе дә калмаган иде… Бу илнең инде үзенең дә көннәре санаулы гына калып бара иде…

Ул әкрен генә борылды да музей йортыннан чыгып китте… Бирәдәге халык, авыру дип белеп, аны кызганып калды…

Ә ул аларны кызганды…

Чөнки ул бик борынгыдан бер зур хәбәр белән килгән иде…

Чит кавем аны аңламады… Борынгыдан килгән Язулы таш алар өчен бары тик җиһаз гына иде… Ә үз телендә нидер сөйләгән сәер карт — бу шәһәр аша узып баручы бер юлаучы дәрвиш кенә…

Ерактан, күзгә эңгер арасыннан, Урал тауның биек сыртлары күренеп тора…

Аны бирегә әнә шулар тартып кайтарды…

Картның борынгы телен бары тик алар гына аңлый, бу дөньяда Әтил картны бары тик алар гына таный иде…

Һәм бары тик алар гына аның илгә кайтуына шат иде…

# БӘХЕТ АЧКЫЧЫ

«Җир вә күкләр хәзинәсенең
ачкычлары Аллаһ кулында».

*(Коръән. «Зүмәра» сүрәсе, 63 аять.)*

## ЮЛГА ЧЫГАР АЛДЫННАН

Безне чорнап алган бу дөнья серләр һәм могҗизалар белән тулы. Башны күтәреп күккә карасаң, меңләгән якты йолдыз, җем-җем килеп, җиһаннан безгә хәбәр итә, үз телендә нидер сөйли… Күккә менеп, ул йолдызларга якыная алсак та, без әле һаман аларның серен белеп бетерә алмыйбыз. Кем, нәрсә тотып тора аларны бу чиксез күк күкрәгендә, нинди бөек тәртипкә буйсынып, алар үз юллары буенча хәрәкәт итәләр, яшәп яталар? Кемнең нинди бөек кодрәтенә буйсынып, бу кояш һәр таңда дөньяны нур белән тутыра, җир йөзен җылыта, иркәли, яшәтә? Кем әмере белән һәр якты көннән соң караңгы төн килә, кояшка алмашка ай туа?

Башны иеп җиргә карасаң, анда мең төрле җан иясе кайнаша, кырмыскадан алып очар кошларга кадәр нәсел калдыру, җан саклау өчен тырыша, менә инде мең вә миллион еллар буе һәрберсе үз тормышы белән яшәп ята… Кемнең бөек әмеренә буйсынып, елан миллион елдан соң да елан булып, бөркет миллион елдан соң да бөркет булып дөньяга килә, ягъни еланнан — елан, бөркеттән бөркет туа? Энә очы кадәр генә нәни орлыктан йөзьяшәр агачларны кем үстерә, күктән — яңгырын, җирдән ризыгын кем биреп тора? Кем кара җир куенына саф суларны салып калдырган, кем бу елга-диңгезләрне, иксез-чиксез су дәрьяларын барлыкка китергән? Кем җир өстенә кыя-тауларны утыртып чыккан, кем аларның эчләрен бихисап байлык, алтын-көмеш, затлы ташлар белән тутырган?

Инде кешенең үз төзелешенә карасаң, сорауларың, гаҗәпләнүләрең тагын да артыр, җир белән күкләрне тоташтырып торучы адәми зат тән төзелеше белән дә, акылы, күңел дөньясы белән дә сине таң калдырыр… Боларны күреп, кеше кайда да кеше булып туа икән, диярсең. Әйе, кайнар ком чүлләрендә дә, мәңгелек боз таулары арасында да, зур калаларда да, сахра-далаларда да кеше кеше булып туа — бер калыпта һәм бер рәвештә дөньяга килә. Кайда да кешегә күрер өчен — күзләр, ишетер өчен — колаклар, йөрер өчен — аяк-куллар, уйлар өчен баш бирелә. Беркем дә үз теләге яки ата-аналары ихтыяры белән өч күзле яки ике йөрәкле булып туа алмый. Яки борынны — күрү өчен, күзләрне ашау өчен үзгәртеп файдалана алмый, чөнки аларга башка бурычлар йөкләнгән. Шул ук вакытта адәм баласына иң камил организм, иң төгәл эчке әгъзалар, могҗизага тиң акыл, иң серле күңел дөньясы бирелгән. Кеше үз теләге белән боларның берсен дә булдыра, тудыра алмый икән, кем аны дөньяга *шундый* итеп яраткан, нинди максат белән яраткан? Яшәр һәм үләр өчен генәме? Ә үлгәч

нәрсә? Барысы да шушы дөньяда бетәме, әллә кеше кадәр кеше үзенең яшәвен инде мәңгелектә дә дәвам итәме?

Гомумән, ничек бәхетле булырга?

Бу дөньяда адашмыйча-саташмыйча, ялгыш юлларга кереп китмичә, кадерсезлекләргә төшмичә, санап кына бирелгән шушы гомерне ничек мәгънәле, файдалы, бәхетле итеп уздырырга? Иминлекнең, кадер-хөрмәтнең, бәрәкәтнең ачкычы кемнең кулында? Бозыклыкның, явызлыкның, гаделсезлекнең сәбәпләре нәрсәдә? Исән килеш үк тере мәеткә әйләнмәс өчен, нәрсәләр эшләргә, дөрес, тәртипле итеп яшәр өчен, кемнәрдән, нәрсәдән өйрәнергә соң?

…Кешелек дөньясы барлыкка килгәннән бирле менә шушы мәңгелек сорауларга җавап эзләгән. Борынгы адәмнәрдән башлап бүгенге заман кешесенә хәтле һаман шушы сорауларга җавап эзли, җир һәм күкләрнең, үз күңел дөньясының серләренә ачкыч табарга тырыша. Ә дөнья һәркемгә дә ачылырга ашыкмый… Адәм баласы бу дөньяның серләрен ачарга фәнне дә, акылын да, күңел сизгерлеген дә файдаланып карый, әмма бик күп сорауларга барыбер җавап таба алмый… Кемнәрдер: «Бу дөнья үзеннән-үзе барлыкка килгән, бернинди илаһи көч юк, яшибез дә бетәбез»,— дип, үзе дә бик нык ялгыша һәм башкаларны да адаштыра. Кемнәрдер исә бу дөньяның төзелешендә, җир һәм күкләрнең, адәм баласының бар булуында бөек хакыйкать күрә, аларның барысын да бер илаһи зат — Аллаһ барлыкка китерүен һәм тотып торуын, үлгәннән соң да яшәү барлыгын аңлый. Болар инде хакыйкать юлына чыккан кешеләр, болар кулында — галәм гыйлеме, болар кулында — җир һәм җиһан серләренең ачкычы. Болар кулында — бәхет ачкычы…

Бәхет ачкычы…

Йолдыз серләрен, җир могҗизаларын, күңел дөньясын ачып керерлек хикмәтле ачкыч…

Кешегә галәм гыйлемен һәм җирдә яшәү серләрен өйрәткән, үз күңел дөньясын һәм тормышын тәртипкә салу юлларын күрсәткән *бәхет ачкычы…* Кайлардан табарга, ничек кулга төшерергә соң сине? Безне чолгап алган бу билгесез дөньяны ачып керү өчен, аның серләрен һәм могҗизаларын белү өчен, ничек файдаланырга ул ачкычны? Бер эзләп тапкач, ничек, югалтмыйча-җуймыйча, гомер буена саклап калырга аны, ничек итеп бу могҗизалы хакыйкать ачкычын башкаларга, балаларыңа, нәселеңә дә тапшырырга? Әйдәгез, бүген шул хакта ныклап уйланыйк әле, бу мәңгелек сорауларга җавапны бергәләп эзләп карыйк, бәлки шушы эзләнүләр юлында хакыйкатьне — бәхет ачкычыбызны да табарбыз? Әмма башта ук шуны әйтәсем килә: бу ачкыч бары тик ихлас, эчкерсез, саф күңелле кешеләргә генә табылачак. Мәкерле, көнче, явыз кешеләр беркайчан да бу ачкычны таба алмаячаклар. Дөнья үзенең серләрен бары тик яхшы кешеләр өчен генә ачачак. Менә хәзер без, балалар, саф, ихлас күңел белән, изге теләкләр белән, хакыйкать эзләргә юлга чыгабыз. Алдыбызда — мең төрле сорау, мең төрле сынау, билгесезлек һәм… ымсындырып торган *бәхет ачкычы…* Мин ышанам: кемнәрдер, һичшиксез, ул ачкычны табачак, шушы ачкыч ярдәмендә кешелек өчен бөек ачышлар ясаячак, кешене һәм дөньяны саклап калырга ярдәм итәчәк… Без ул хакыйкать ачкычын җирдән дә, тау-ташлар арасыннан да, диңгезләрдән дә, җиһаннан — йолдызлар арасыннан да, кешенең үзеннән дә эзләп карарбыз. Иншаллаһ, барыбер табарбыз, барыбер килер буыннарга тапшырып калдырырбыз… Аллага тапшырдык, балалар, хакыйкать эзләп — олы юлга…

## ҖИР СЕРЛӘРЕН АЧКАНДА…

Бу җир — синең туган йортың…

Син — аның хуҗасы. Бу — урман-кырлар, кара туфрак, саф сулар, чиста һава, үсемлекләр һәм тереклек ияләре — барысы да синең өчен барлыкка китерелгән. Бушка килгән бу байлык сиңа кадәр дә булган, аннан син дә рәхәтләнеп файдаланасың, әгәр дә дөрес яшәсәң, бу нигъмәтләр әле синең балаларыңа, нәселеңә, милләтеңә дә калачак…

Синең уйлап караганың бармы, балам, кем бирә икән безгә бу иксез-чиксез байлыкны-бәрәкәтне: саф чишмә суларын, чиста һаваны, шул һаваларны тутырып очкан кошларны, шаулап утырган урманнарны, шул урманнарны иңләп йөргән җанварларны, киң кырларны, шул кырларда туктаусыз үсеп утырган хисапсыз ризыкларны, балыклары мыжлап торган диңгез-дәрьяларны — кем биргән икән боларның барысын безгә? Син инде уйлый беләсең, болар үзеннән-үзе барлыкка килгән дигән сүзләргә күңелең ышанып бетми. Чөнки бу кадәр байлыкның, бу кадәр гүзәллекнең, бу кадәр камиллекнең үзеннән-үзе барлыкка килә алмавын инде син дә аңлыйсың. Ул чагында, кем барлыкка китергән соң бу дөньяны, кем тотып тора, кем үз тәртибенә буйсындырып, һаман яшәтеп килә? Син укыган дәреслекләрдә моңа төгәл җавап юк, ә синең җаның, акылың инде ул китапларга гына сыймый һәм, бу мәңгелек сорауларга җавап эзләп, син үзең юлга чыктың.

Башыңны күтәреп күккә карасаң, син күктә дә шундый ук кырыс тәртипне, бер көч-куәткә буйсынып хәрәкәт итүче галәмне, әле син аңлап та бетермәгән серле системаны, закончалыкларны күрерсең. Һәм тагын үзеңә сорау бирерсең: кем хәрәкәткә китерә, кем тотып тора, кем яшәтә соң бу күкләрне? Син укыган дәреслекләрдә моңа да төгәл җавап юк әле. Җир һәм күкләрнең бөек хакыйкате әле синнән ерак яшерелгән шул, әмма бу хакыйкать ачкычын син барыбер табарга тиешсең, чөнки, шул сорауларга җавап тапмый торып, син үз күңелеңә, үз бәхетеңә дә ачкыч ярата алмаячаксың…

Дөньяны танып-белү бик гади сораудан башлана кебек: бу дөнья ничек барлыкка килгән? Күп кенә галимнәр әйтүенчә, дөнья үзеннән-үзе генә барлыкка килгәнме, әллә, акыл ияләре, иманлы кешеләр кисәтүенчә, дөньяны илаһи көч — Аллаһы Тәгалә барлыкка китергәнме? Бу сорауларга җавап табу гаять мөһим, чөнки шуннан башка хакыйкать тә, хаклык та юк. Безнең гыйлем дөньясына сәяхәтебез дә шушы сорауга дөрес җавап табу өчен булачак. Шуңа күрә без фикерләрнең дә төрлесен тыңлап, тикшереп карарбыз. Әгәр без: «Дөнья үзеннән-үзе барлыкка килгән, аның белән беркем идарә итми»,— дип барабыз икән, ул чагында җирдә һәм күктә, адәм баласының, тереклек ияләренең тән төзелешләрендә булган закончалыкларны, миллиард еллар буе барган буйсынулы тәртипне, идарә ителү системасын кая куярбыз? «Дөнья белән идарә итү системасы бар»,— дип әйтәбез икән, «Кем идарә итә?» дигән сорау килеп туачак. Әлбәттә инде, кеше идарә итү турында сүз бара алмый, адәм баласы әле ай-йолдызлар белән түгел, үзенең эчке әгъзалары, үз күңеле белән дә идарә итәргә өйрәнмәгән. Алайса, кем бу җиһан белән, ай-йолдызлар, кояш, җир-су белән, кеше һәм бар тереклек дөньясы белән идарә итә соң? Ничек караңгы төн артыннан якты көн килә, салкын кышлардан соң ямьле яз айлары башлана, туң туфраклар эреп, дөнья тагын чәчәк ата, бөтен әгъзалары, тәне-җаны камил хәлдә, дөньяга тагын бер адәм баласы аваз сала? Мең ел элек тә шулай булган, бүген дә шулай, шушы бөек идарә туктап калмаса, иншаллаһ, мең елдан соң да шушылай булачак… Кем соң ул, безнең өчен шушы бөек дөньяны яратты, безгә җир кадәр җирне бүләк итте, алдыбызга исәпсез-хисапсыз байлыкларны китереп куйды, безне шушы нигъмәтләрнең хуҗасы итеп билгеләде? Кем ул күктәге йолдызлардан башлап тәнебездәге һәр күзәнәкне барлыкка китерүче, хәрәкәтләндерүче, яшәтүче һәм теләгән вакытта туктата да алучы?

Әйе, әлбәттә, андый илаһи көч бар, газиз балалар. Ул көч — Аллаһы Тәгалә. Дөньяны барлыкка китерүче дә — Аллаһы Тәгалә, аны яшәтүче, тотып торучы да — Аллаһы Тәгалә. Безнең үзебезне бу дөньяга яратучы, яшәтүче дә — Аллаһы Тәгалә. Безнең тормышыбызда, җаныбызда һәм уйларыбызда нәрсә барганын белеп торучы да — Аллаһы Тәгалә. Үлгәннән соң безнең барыбызны да яңадан терелтеп, каршына сорау алыр өчен бастырачак зат та Аллаһы Тәгалә булачак…

Күрәсез, бу дөнья уен өчен генә, тиктомалдан төзелмәгән икән. Бу дөньяда җирдән шуышучы бөҗәктән башлап күк йөзен яктыртучы йолдызларга хәтле үз вазифасын, үз бурычын үти икән. Ә кеше хәтле кешене Аллаһы Тәгалә нинди максатлар белән дөньяга яратты икән, аның алдына нинди максатлар куйды, нәрсәләрдән тыелырга, нәрсәгә омтылырга кушты? Әгәр без дөньяны һәм үзебезне Аллаһы Тәгалә барлыкка китерүен таныйбыз икән, без Аның үзебезгә ниләр кушуын, нинди тәртиптә яшәргә өйрәтүен дә белергә тиешбез бит инде. Ә беләбезме соң?

Менә син компьютер каршына килеп утырдың. Сине берәрсе компьютерда эшләргә өйрәтмичә яки үзең бик ныклап бу техниканың инструкциясен өйрәнмичә торып, син аны эшләтеп җибәрә алмаячаксың. Тиешсез урыннарына баскалап, бөтенләй ватып куюың да бар. Барлык техника белән дә шулай: башта син аның эшләү тәртибен өйрәнәсең. Аллаһы Тәгалә дөньяга кеше хәтле кешене барлыкка китергән икән, Ул аңа дөньяда яшәү тәртибен дә өйрәтергә, бирергә тиеш иде! Һәм бу нәкъ шулай була да — кеше белән бергә аның яшәү кагыйдәләре дә туа. Аллаһы Тәгалә беренче кешеләргә үк яхшы белән яманны аера белү гыйлемен бирә, нәрсәләрдән тыелырга кирәклеген, ә нәрсәләрне эшләргә яравын аларның аң-җаннарына салып калдыра. Гасырлар һәм чорлар дәвамында Ул кешелеккә бу хакта гел искәртеп, кисәтеп тора, җиһаннан җиргә үзенең хәбәрләрен җибәрүен дәвам итә. Аллаһның шушы өйрәтүләрен һәм кисәтүләрен кешеләр *дин* дип, Аның хәбәрләрен алган һәм дөньяга тараткан кешеләрен *илче-пәйгамбәрләр* дип атаганнар. Аллаһның сүзләреннән, әмерләреннән тупланган китаплар төрле вакытта төрлечә аталган, соңгысы — Мөхәммәт пәйгамбәр аша кешеләргә килеп җиткәне, ул — Коръән. Моннан 1400 еллар элек җиһаннан килгән бу хәбәрләр — Аллаһның кешеләргә юллаган соңгы китабы, өйрәтүе, кисәтүе һәм әмерләре. Кешелек өчен күктән иңгән соңгы яшәү тәртибе, соңгы кагыйдәләр, соңгы инструкция. Әмма кешелек дөньяда шушы илаһи тәртип, шушы күрсәтмә буенча яшиме соң? Яки җир йөзендә һәркем үзенчә тәртип урнаштырырга, үзенчә җимерергә тырышамы? Адәм баласы дөньяны Аллаһ өйрәткәнчә алып барамы яки, Аллаһны танымыйча, тәкәбберләнеп, дөньяга үз кагыйдәләрен тагарга омтыламы? Гомумән, бүгенге көндә кеше үзен һәм дөньяны барлыкка китергән илаһи көчне — Аллаһны таныймы? Ул кушканча яшиме яки барысын да киресенчә эшлиме? Бу хакта һәрберебез үз-үзеннән сорый ала…

Димәк, без бу дөньяда ялгыз түгел икән. Безнең җиребез —җиһан дәрьясында бер ком бөртеге генә, үзебез дә бу дәрьяда нәни тамчы гына икәнбез бит… Тәнебез дә, җаныбыз да, акылыбыз да, гомеребез дә үзебезне барлыкка китерүче Аллаһ кулында икән. Ул гына да түгел, шушы җир дөньясында яшәгән һәр мизгелебез, эшләгән һәр эшебез, әйткән һәр сүзебез, уйлаган һәр уебыз өчен без әле, Аның каршына басып, ахирәт дөньясында җавап та тотасы икәнбез бит… Менә шушыларның барысын да белгәннән-аңлаганнан соң, кеше дөньяга яңадан туган кебек була, аның күңел күзләре ачылып китә. Һәм ул дөньяга Аллаһның гыйлеме аша карый башлый. Аңа очар кошлар теле дә, судагы балыклар сере дә, агач вә яфракларның гөжләшеп сөйләшүләре дә аңлашыла башлый. Ул, бар дөньяның: тау-ташларның, агач-яфракларның, кош-кортларның, искән җилләрнең, аккан суларның — һәммәсенең дә Аллаһка үзләренчә гыйбадәт кылуларын, сәҗдә итүләрен күреп, тетрәнү кичерә. Әйе, кешедән кала бар табигать Аллаһны таный, Аңа буйсына, Аңа сәҗдә кыла, бары тик адәм баласы гына шушы тәртипкә буйсынмаска тырыша һәм кешелекне һәлакәткә алып бара…

Ни өчен адәм баласы инде күренеп торган, каршына килгән бөек хакыйкатьне күрергә, танырга теләми соң? Галәмгә очарга, диңгез төпләренә төшәргә, электр уты, компьютер, роботлар уйлап табарга җиткән акылы нигә Аллаһны танырга җитми? Тәкәбберлекме бу, наданлыкмы, әллә инде белә торып та яшерүме, әйтмичә калумы? Хәзергә кеше, барысын да үзем беләм, үзем уйлап табам, дөнья белән дә үзем идарә итәм, дип бара бит. Ә инде Аллаһның барлыгын таныгач, ул инде: «Аллаһ рөхсәт иткәнне генә беләм, Аллаһ биргән акыл ярдәмендә генә уйлап таба алам, Аллаһ идарә иткән дөньяда яшим»,— дип әйтергә мәҗбүр булачак. Әле күп кенә галимнәргә, иҗат әһелләренә үзләре гомер буе табынган, алга сөргән адаштыргыч идея-фикерләреннән баш тартырга да туры киләчәк. Кем үз теләге белән шушыңа бара ала? Бөтен фәннәрне өр-яңадан карап, аларның өйрәтүләрен Аллаһның бөек тәгълиматына буйсындырырга туры киләчәк. Дөньяның яратылышыннан алып тәнебездәге күзәнәкләрнең хәрәкәтенә хәтле Аллаһы Тәгалә тәкъдирендә булуын инде фәнни юл белән дә аңлатырга туры киләчәк. Кем моңа әзер? Менә шуңа күрә дә инде дөнья галимнәре дәшми, ул гына да түгел, кешене Аллаһтан, хакыйкатьтән ерагайта торган идеяләр, программалар, чаралар уйлап табып торалар. Дөньяның бер өлеше канкойгыч сугышларга, җинаятькә кереп батса, икенче өлеше массакүләм миңгерәйтүләргә: тоташ күңел ачуларга, җыр-биюгә, зинага, наркоманиягә, эчкечелеккә чумды. Галимнәр боларның барысын да күрә, әмма бу вәхшилекне туктатырга көчләре дә, теләкләре дә юк, ахрысы. Ә Аллаһ ярдәменә мөрәҗәгать итәргә күпләргә наданлыклары һәм тәкәбберлекләре комачаулый.

Әмма сез чын хакыйкатьне белергә тиешсез, балалар! Сезгә бу дөреслекне нәкъ менә бүген әйтергә кирәк, чөнки иртәгә инде күпләрегез өчен бик соң булырга мөмкин. Бер тапкыр наркоманлык энәсенә утыргач, үз теләге белән аракы шешәсенә үрелгәч, зина, хәрам кочагына аугач, кешенең аңы һәм җаны инде кара сөрем белән каплана башлый. Әгәр кешегә вакытында ярдәм итмәсәң, шушы тыелган нәрсәләр инде аның яшәү рәвешенә әйләнеп китә, ул хакыйкатьтән, сафлыктан, бәхеттән ерагайганнан-ерагая барачак һәм аны һәлакәт көтә. Без сөйләячәк дөреслек — каннары һәм җаннары агуланып өлгермәгәннәр өчен. Без сөйләячәк бөек хакыйкать сезнең өчен, кадерле балалар!

*«Бисмиллаһир-рахмәнир-рахим.*

*Әлхәмдулилләһи раббил галәмин!»*

Аллаһуның китабы Коръән менә шул сүзләр белән башлана.

«Галәмнәр Раббысы Аллаһка дан!»

Галәмнәр Раббысы… Галәмнәр Хуҗасы… Ул безгә кадәр дә булган, бездән соң да булачак… Ул безгә мохтаҗ түгел, без Аңа мохтаҗ. Без Аны өйрәтә алмыйбыз, Ул безне өйрәтә, күрсәтмәләр бирә, дөрес юлны күрсәтә. Аллаһы Тәгаләнең нигъмәте, могҗизалары, хикмәте бөтен дөньяга сибелгән. Әмма Аның безгә биргән иң зур могҗизасы, байлыгы — Коръән. Коръәндә бар нәрсәгә дә җавап бар. Дөньяның яратылышыннан башлап бетүенә кадәр нәрсә булган һәм булачак — Аллаһ Тәгалә Коръән аша безгә барысын да әйтеп биргән. Әмма боларны күрү, аңлау һәм кабул итү өчен дә ихлас күңел күзе кирәк шул, үзеңне барлыкка китергән Аллаһка рәхмәтле була белү кирәк.

Аллаһы Тәгалә Коръәннең «Әнгам» сүрәсендә *(67 аять)* безгә мөрәҗәгать итеп, болай ди: *«Коръәндә хәбәр бирелгән һәр нәрсәнең урыны һәм вакыты бар, Коръәндә әйтелгән сүзләрнең хак икәнлеген тиздән белерсез».* Менә шул хәбәрләрнең ачылу вакыты инде җитеп килә, моннан 1400 ел элек Коръәндә әйтелгән күп кенә хәбәрләрнең раслыгын инде фән дә исбатлады. Әйтик, Аллаһы Тәгалә Коръәндә: *«Җир белән күкләр бергә кушылган иделәр, Без аларны аердык вә һәр-*
*төрле терек иясен судан чыгардык»,*— ди *(«Әнбия» сүрәсе, 30 аять).* Инде бүген галимнәр дә җир белән күкнең кайчандыр кушылган булуын, дөньяда бар тереклекнең судан барлыкка килүен исбатладылар. Бүгенге фән дөнья яратылган вакытта күкнең тоташ төтен-газдан гына торуын исбат итә. Әмма нигәдер бер генә галим дә: «Бу хакта инде 1400 ел элек Коръәндә язылган иде»,— димәде. Әйе, Коръәннең «Фуссиләт» сүрәсендә, 11 аятьтә: *«Ул вакытта күк төтен иде»,*— диелә. Ягъни дөнья

яратылганда, күк төтен-газдан гына тора. Аллаһы Тәгалә күкне җирдән аерып, һәрберсен үз урынына урнаштыра, күк белән җир Аллаһка буйсынып яшәргә ант бирәләр. Коръәндә шулай ук күкләрнең җиде катлы булуы турында да хәбәр бар. Бүгенге көндә галимнәр дә күкнең җиде кат ярусллы булуын, күк белән җирнең бер көчкә, бер системага, бер закончалыкка буйсынып хәрәкәт итүен әйтәләр. Әмма бу илаһи көчнең Аллаһы Тәгалә икәнен, бу кырыс системаның Аллаһ системасы икәнлеген, бу закончалыкның Аллаһ законы икәнен әйтеп бетерми шул галимнәребез! Аллаһның дәлилләре күз алларында, кулларында була торып та, ул хакта дәшми калуны артыграк күрәләр. Күк җисемнәре хакында Коръән хәбәрләренә без, иншаллаһ, алдагы бүлекләрдә иркенләбрәк тукталырбыз. Ә хәзер сүзебез, вәгъдә ителгәнчә, җир, андагы хикмәт һәм могҗизалар турында Коръәндә ни әйтелә, шул хакта.

Җирнең түгәрәк икәнен бүген инде мәктәп балалары да белә. Ә заманында бу мәсьәлә зур бәхәсләр тудырган бит. Кемдер җирне үгез мөгезендә эленеп тора дип исәпләгән, кемдер зур балык, ташбака өстендә урнашкан дип күз алдына китергән. Җирнең чиге бар, дип әйтүчеләр дә булган. Урта гасырларда хәтта җирнең шар сыман булуы турында һәм кояш тирәсендә әйләнүен әйткән өчен кайбер галимнәрне яндырып үтерүләрен дә беләбез. Югыйсә Аллаһы Тәгалә җирнең рәвеше турында да Коръәндә ундүрт гасыр элек хәбәр биргән иде бит!

Аллаһ Коръәндә җирне йомырка (дәхәә) рәвешендә түшәп бетерүен хәбәр итә *(«Нәзигат» сүрәсе, 30 аять).* Бүген исә галимнәр дә җирнең эллипс, ягъни йомырка рәвешендә булуын исбатладылар. Бу хакта сезнең астрономия дәреслекләрендә дә язылган. Әмма җирнең йомырка сыман рәвештә булуы турында Коръәндә аять-хәбәр барлыгы турында бу дәреслекләрдә әйтелмәгән.

Ислам диненә каршы бәхәсләшүчеләр еш кына: «Коръәнне кеше язган»,— дип әйтергә яраталар, ягъни Аны Мөхәммәт пәйгамбәр үзе уйлап чыгарган, диләр. Мөхәммәт пәйгамбәр — укый-яза белми торган чүл гарәбе булган, аның астрономия, анатомия, физика, тарих, психология, география фәннәре буенча бөтенләй гыйлеме булмаган. Ә Коръән шушы өлкәләр буенча тиңе булмаган мәгълүмат, хәбәрләр бирә бит! Ул — чын мәгънәсендә, бөтен асылы белән — Аллаһ сүзе, Мөхәммәт пәйгамбәр аны 23 ел буе Җәбраил фәрештә аша кабул итеп, халыкка җиткерүче булган. Һәм үзе исән чагында ук Аллаһның хөкемнәрен кешеләр арасында урнаштырып калучы. Коръәннең һәр сүзе — хакыйкать, һәр сүзе — бөек могҗиза һәм һәр сүзе — мәңгелек… Без дөньяны өйрәнә башлауны да иң беренче булып Аллаһ сүзеннән — Коръәннән башларга тиешбез. Хакыйкатьне дә шырпы сызып түгел, мәңге сүнмәс илаһи нур тотып эзләргә кирәк.

Җир йөзе буенча сәяхәтебезне дәвам итик. Менә каршыбызга биек-биек таулар очрый, кайберләренең түбәләре мәңгелек кар катламы белән капланган, итәкләрендә исә кара урманнар шаулап утыра… Тау куеннары алтын-көмеш, алмаз-якутлар белән шыплап тулган, бөтен дөнья бу таулардан тимерен, күмерен, мәрмәрен алуны дәвам итә. Сезнең уйлап караганыгыз бармы икән: тауларның төп бурычы нәрсәдә соң? Ягъни рас алар бар икән, нинди олы максат белән барлыкка китерелгәннәр? Алтын-көмеш, зөбәрҗәт ташлар өчен генә түгел бит инде? Ниһаять, соңгы вакытта галимнәр моңа да җавап таптылар: таулар җирне селкенүдән саклап торалар икән бит, ягъни җиргә ныклык бирәләр, үзләренә күрә терәү булып торалар. Дәреслекләр буенча хәтерләсәгез, җир бит туктаусыз хәрәкәттә, ул бер күтәрелә, бер төшә, кысыла һәм киңәя, әйтерсең лә тере җан кебек сулыш ала, кайнап, ухылдап яшәп ята. Җир артык тынычсызланып киткәндә, янар таулар —вулканнар ата башлый, җирнең үзәгеннән утлы сыекча бәреп чыга. Җир вакыты-вакыты белән тетрәп тә ала, ярылып китеп, юлындагы бар нәрсәне үзенә йота. Менә шундый вакытта җир дәһшәтенә каршы таулар баса инде, гранит таш-кыялар бу тетрәүләрне үзләренә кабул итәләр, аларның ургылып килгән көчләрен бәреп сындыралар, җирне тәмам тетрәп-теткәләнеп бетүдән саклап торалар. Алар Аллаһ кушканны үтиләр. Моның нәкъ шулай икәнлеген Аллаһы Тәгалә безгә Коръәндә ап-ачык итеп әйтә:

*«Ул тетрәмәсен өчен җир өстенә мәхкәм тауларны ыргытты»,—* ди Аллаһ Коръәннең «Нәхел» сүрәсендә *(15 аять).* Димәк, таулар бер дә максатсыз гына барлыкка китерелмәгән, алар җирне артык селкенүләрдән терәү-терәк булып тотып торалар икән. *«Әйә җирне аларга торырга яраклы кылмадыммы? Дәхи селкенмәсен өчен тауларны җиргә кадак кылмадыммы?» («Нәба» сүрәсе, 6—7 аятьләр.)* Таулар темасы Коръәннең буеннан-буена бара: пәйгамбәребез Мөхәммәт салаллаһу галәйһиссәлам дә Аллаһның беренче әмерләрен, Коръәннең беренче аять-хәбәрләрен тау куышында ишетә. Муса галәйһиссәлам дә Аллаһ сүзен мәһабәт Тува тавында ишетә, Раббының нурын шунда күрә. Димәк, Аллаһтан пәйгамбәрләргә хәбәрләр килү дә, нигездә, таулар белән бәйләнгән. Коръәндә «Тау тишеге» — «Каһәф» дип аталган тулы бер сүрә дә бар. Имансызлыктан качкан мөселман егетләре тау тишегенә кереп яшеренергә мәҗбүр булалар. Алар анда 300 ел буе йоклап — мәрткә китеп торалар. Вакыты җиткәч, Аллаһ аларны уята, кешеләргә күрсәтә, һәм бу егетләр, мөселман булган хәлләрендә, инде мәңгегә күзләрен йомалар. *«Каты йокыларыннан уятканыбыз кеби шул вакыттагы патшага һәм кавеменә ул егетләрнең хәлен күрсәттек, ачык бәян кылдык, аларның хәле белән танышкан кешеләр,*

*Аллаһуның кыямәт белән кылган вәгъдәсе хак икәнен вә кыямәтнең булачагында һич шик юк икәнен белсеннәр өчен» («Каһәф» сүрәсе, 21 аять).*

Аллаһ диненең ныклыгы, иман кыя-таулар белән чагыштырыла, бәрабәр итеп күрсәтелә. Иманы нык кеше ул дөнья тетрәнүләре алдында кыя-тау кебек басып тора, әхлаксызлык уты йотудан ул үзен дә, башкаларны да саклап калырга сәләтле. Әйе, җир тетрәмәсен өчен, таулар кирәк булса, җан тетрәмәсен өчен, иман, ныклы иман кирәк шул…

Күрәсез, бу дөньяда бер генә нәрсә дә кирәксезгә, мәгънәсезгә барлыкка китерелмәгән. Туфрактан алып тауларга кадәр, җирдәге нәни орлыктан алып күктәге ай-йолдызларга кадәр — барысының да максаты һәм бурычы бар, алар барысы да Аллаһы Тәгалә кушкан эшне башкара, барысы да Аңа буйсынып хәрәкәт итә. Бары тик кеше генә һаман ни өчен дөньяга килүен дә, ни өчен яшәвен дә, ничек яшәргә тиешлеген дә аңлап бетми, шул сәбәпле үзенә дә, тирә-юньгә дә зур зыян сала, дөньяны һәлакәткә таба алып бара. Аллаһы Тәгалә җир йөзенә таралып барган әхлаксызлыкны, гаделсезлекне безнең үз кулларыбыз белән юк итүебезне тели, үзебезнең яхшы якка үзгәрүебезне, Аның гыйлеме белән кораллануыбызны, бары тик Аңа гына буйсынып, Ул кушканча гына яши башлавыбызны тели. Шуңа күрә безгә әледән-әле гыйбрәтләрен биреп тора, могҗизаларын күрсәтә, шәфәгатеннән ташламый, бәла-казалары белән кисәтә… Бу могҗизаларны бары тик күрә һәм аңлый белергә, бәла-казалардан гыйбрәт алып, мәрхәмәтенә рәхмәтле була белергә генә кирәк шул…

Таулар юлы буйлап сәяхәтебезне дәвам итәбез. Әнә тау түбәләре ап-ак кар-боз белән капланган, алардан аска таба челтерәп чишмәләр агып төшә, чишмәләр — елгаларга, елгалар диңгез-океаннарга барып тоташа. Аллаһы Тәгаләнең иң зур нигъмәтләренең берсе булган су безнең бөтен тирә-юнебездә: җирдә, күктә, ашаган ризыкларыбызда, тәнебездә һәм каныбызда яшәп ята… Җир шарының 3/4 өлеше судан тора, кеше организмының күпчелек өлешендә — су, хәтта каныбызның да 80 проценты судан гыйбарәт. Кеше үзе дә бер тамчы судан барлыкка килә, ана карынында да, диңгездәге балык кебек, су эчендә бөгәрләнеп ята, соңгы юлга да аны су белән пакьләп, юып озаталар… Аллаһы Тәгаләнең: *«Бар тереклек иясен судан барлыкка китердем»,*— дигәненә тагы бер дәлил түгелмени бу?

Әлбәттә, су булмаса, җирдә тереклек булмас иде…

Ә су үзе кайдан, нәрсәдән барлыкка килгән соң?

Бик борынгы галимнәр дә, хәтта Аристотель, Платон кебек философлар да җир йөзендә суның килеп чыгышы турында ялгыш фикердә торганнар. Алар фикеренчә, караңгы җир куенында, тау куышлыкларында яшеренеп яткан су, җир асты юллары буйлап даими рәвештә океан-диңгезләргә чыгып, аларны тутырып торган. Бу галимнәр чишмәләрне дә шул яшерен запастан килеп тора дип уйлаганнар. Җир астында бу сулар кайдан барлыкка килгән — ул хакта галимнәр әйтә алмаганнар. Суның килеп чыгышы турында бүгенге галимнәрнең фикерләре бераз үзгәрәк, әмма алар да әле бу сорауга тулы җавап биреп бетерә алмыйлар. Бүгенге фән раслаганча, дәрья сулары кояш нурлары тәэсире астында парга әйләнәләр, ул парлар, күккә күтәрелеп, болытларга әвереләләр, аннан яңгыр булып җиргә явалар, күктән иңгән яңгыр суы җиргә сеңә, төрле юллар белән яңадан океан-дәрьяларга кайта, биредә яңадан парга әйләнеп, тагын күккә күтәрелә, яңгыр булып тагын җиргә кайта… Бу система «Бөтендөнья су әйләнеше» (Мировой круговорот воды) теориясе дип атала, һәм мәктәп дәреслекләрендә сез аны шушы рәвештә өйрәнәсез. Бу теория хакыйкатькә шактый якын. Әмма күңелдә бер сорау кала, ә дәрья-океанга су каян килгән? Менә бөтен хикмәт шунда да шул: барысы да дөрес кебек, әмма әйтеп бетермәү яки дөреслекне буташтырып әйтү бар. Галимнәр һаман башта тавык барлыкка килгәнме әллә йомыркамы дигән сорауга җавап бирә алмаган кебек, биредә дә шундыйрак хәл. Су җирдә барлыкка киләме, күктәме? Безнең фикеребезчә, монда хәрәкәт-процессның урыннарын үзгәртергә, ягъни су барлыкка килүне *күктән* башларга кирәк. Аллаһы Тәгалә бу хакта Коръәндә болай ди:

*«Аллаһ күктән суны иңдерде, һәм тармакланды, һәм акты ул су көчле агымнар булып билгеле бер үлчәү белән» («Рәгыд» сүрәсе, 17 аять).*

*«Әйә күрәсеңме, Аллаһ күктән су иңдерде, соңра ул суны чишмәләргә, елгаларга кушты, соңра ул су белән төрле төстәге игеннәр, җимешләр вә үләннәр үстерде, күзге якта барын да саргайган күрерсең, соңра ул игеннәрне вә үләннәрне сулган, вакланган кылыр, Аллаһуның бу эшендә гакыл ияләре өчен, әлбәттә, вәгазь вә гыйбрәтләр бардыр» («Зүмәра» сүрәсе, 21 аять).*

Аллаһ күктән су иңдерде…

Димәк ки, суның беренчел урыны — күктә? Һәм күрәсезме, нинди камил, төгәл, туктаусыз хәрәкәт-процесс! Үзеннән-үзе генә яңгыр сулары күк белән җир арасында шулай мәңге әйләнеп йөри аламы? Бер урында да, бер чорда да, бер мизгелгә дә өзеклек, буталчыклык, хаос юк бит?! Кем идарә итә соң бу мәңгелек хәрәкәт белән, җир-сулар белән? Әлбәттә, бөтен галәмнәрнең хуҗасы Аллаһы Тәгалә!

*«Ул — Аллаһ, яңгырдан алда җил җибәрер, рәхмәте белән шатландырмак өчен, хәтта ки ул җил яңгырлы авыр болытны алып килсә, сөрербез ул болытны үлгән-үләнсез шәһәр өстенә, ул шәһәргә яңгырны яудырырбыз вә ул яңгыр белән төрле җимешләрне чыгарырбыз, әнә шулай мәетләрне чыгарырбыз, шаять, вәгазьләнерсез» («Әгъраф» сүрәсе, 57 аять).*

Күрәсез, яңгырдан алда әле җил килә икән. Яңгыр нигъмәт булса, җил хәбәр икән. Күктән иңгән су афәт билгесе дә булырга мөмкин, туфан басу вакыйгасы дөньяның бетүенә китерә язып кала. Димәк, бәрәкәт тә, бәла дә, рәхмәт тә, ләгънәт тә күктән килә, күктән иңә, һәм моның кем өчен —шатлык, кем өчен кайгы икәнен бары Аллаһы Тәгалә генә белә… Ул гына билгели…

Күпләрнең күңелендә: «Ә яңгыр болытлары ничек барлыкка килә соң?» дигән сорау туарга мөмкин. Коръәндә моңа да җавап бар:

*«Әйә күрмәдеңме, Аллаһ болытларны куар, соңра аларны бер-берсенә кушар, соңра аларны берсе өстенә икенчесен кылыр, һәм күрерсең, аларның араларыннан яңгыр чыгар, вә Аллаһ шул болытлардан тау күплегендә боз иңдерер, ул боз белән теләгән кешесен һәлак итәр вә теләгән кешесен коткарыр, вә шул болыт яшененең яктылыгы күзләрнең нурын бетерергә якын булыр» («Нур» сүрәсе, 43 аять).*

*«Аллаһ җилләрне җибәрер вә алар белән болытларны күтәрер, вә ул болытларны үзе теләгәнчә бер-берләренә кушып туплар, вә кисәкләргә бүләр, күрерсең, яңгырны болытлар арасыннан чыгарыр, әгәр ул болытларны үзе теләгән бәндәләренә ирештереп яңгыр яудырса, шул вакытта алар шатланырлар» («Рум» сүрәсе, 48 аять).*

Күрәсез, Коръәндә ачыктан-ачык әйтелгән: Аллаһы Тәгалә җилләрне җибәреп, вак болытларны куа һәм, бер-берләренә кушып, яңгыр болытлары барлыкка китерә икән. Бүгенге фән дә яңгыр болытларының җилләр ярдәмендә аерым вак болытлардан бергә кушылып ясалуын исбат итте. Галимнәр әйтүенчә, бер-берләре өстенә өелгән болытлар эчендә һава агымы барлыкка килә икән, ул исә, үз чиратында, болытның аскы өлешендәге су парларын кузгата, бер тирәгә туплый-куалый. Су парлары, үз чиратында, һава агымының тагын да көчәюенә, шулай итеп, болытларның кабаруына китерә. Һава агымы һәм су парлары бергә кушылып һәм болганып, даими кысылып һәм киңәеп, су фонтаннары барлыкка китерә, бу су исә, болыт араларыннан ярык табып, яңгыр булып җиргә томырыла. Бүгенге фән нәкъ Коръән әйткәннәрне кабатлый түгелме соң? *«Әйә күрмәдеңме, Аллаһ болытларны куар, соңра аларны бер-берсенә кушар, соңра аларны берсе өстенә икенчесен кылыр, һәм күрерсең, аларның араларыннан яңгыр чыгар…»*

Әйе, Аллаһның рәхмәте белән җил һәм болытлар ярдәмендә күктә барлыкка килгән бу су җиргә иңәр, бер өлеше җир астына китәр, бер өлеше җир өстендә калыр, дәрья сулары өстеннән пар булып күккә күтәрелер, аннан тагын җиргә кайтыр… Бу бөек могҗиза бары тик Аллаһның рәхмәте белән генә булып торыр, адәм балалары, барысы бергә җыелып, гомер буе баш ватсалар да, бер тамчы су уйлап таба алмаслар, аны бер күккә күтәреп, бер җиргә төшереп тора алмаячаклар… Бушка килгән бу бәрәкәтнең кадерен белеп, шөкраналар итеп, Аллаһның бу нигъмәтләрен саклап яшәргә кирәк, балалар.

Коръәндә су турында хикмәтле хәбәрләр күп. Әйтик, Аллаһы Тәгалә «Рахман» сүрәсенең 19—20 аятьләрендә болай дип хәбәр итә:

*«Аллаһ берсе татлы, берсе тозлы ике диңгезне (суны) янәшә агызды. Аларның арасында Аллаһның кодрәт пәрдәсе бардыр, сулары кушылмас».*

Биредә сүз бер диңгездә янәшә аккан төче һәм тозлы сулар турында бара. Елга-чишмәләрдән диңгезгә койган төче су агымнары тозлы су белән кушылып, аралашып бетми икән, алар арасында чик кала. Моның шулай икәнен бүгенге көндә галимнәр космостан төшерелгән сурәтләр аша исбат иттеләр. Коръәндә әйтелгәнчә, дәрьяларда төче һәм тозлы сулар янәшә аксалар да кушылмыйлар, араларында Аллаһның чик-пәрдәсе кала икән… Ком чүлендә яшәгән, гомерендә диңгез күрмәгән Мөхәммәт галәйһиссәлам мондый хәбәрне үзе уйлап чыгара алыр идеме? Юк, әлбәттә. Бу хәбәр — һичшиксез, Аллаһтан, Мөхәммәт пәйгамбәр ул сүзләрне халыкка җиткерүче генә. Һәм кешеләр, Аллаһ биргән акыл ярдәмендә, 1400 елдан соң Коръәннең бу хәбәре дә чын хакыйкать икәнлеген ачтылар…

Игътибар итсәгез, су җиргә күктән иңә… Коръән дә күктән иңә… Ана карынындагы балага җан да күктән иңә. Болар барысы да — Аллаһның зур нигъмәтләре. Тәнебез судан башка яши алмаган кебек, җаныбыз да иманнан башка үлә, мәеткә әйләнә. Димәк, җаныбызны күгәртмәс, корытмас өчен, без аны даими рәвештә Аллаһ гыйлеме белән сугарып торырга тиеш булабыз икән. Яңгыр сулары җирне сугарган кебек… Шул ук вакытта эчкән суларыбызның нинди булуы безнең холкы-бызга, сәламәтлегебезгә тәэсир итүен дә онытмаска кирәк. Бөтен җирдә, хәтта таш эчендә, кан составында да су барлыгын әйткән идек инде. Димәк, эчкән суың нинди, каның да шундый, каның нинди, холкың, сәламәтлегең дә шундый, дигән сүз. Кеше организмының 2/3 өлешен су алып тора. Күзәнәкләрдә матдә алышуы бары тик су эретмәсендә генә бара ала. Кан, нигездә, плазмадан тора, ә плазма составының 90 проценты судан гыйбарәт… Яңгыр суы җир белән күк арасында әйләнеп йөргән кебек, кан да йөрәк

белән баш мие арасында туктаусыз әйләнеп, хәрәкәт итеп тора. Җир тамырлары буенча да, кан тамырларыбыз буенча да Аллаһның иң зур могҗизаларының берсе — көмеш су йөгерә, көмеш су чаба…

Күктән иңгән суның җирдәге тереклек дөньясы өчен ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген күрдек. Әмма бу күренеш, кайбер мәҗүси халыклардагы кебек, суны изгеләштерә башлап, аңа табынуга китермәсен иде. Шуны беркайчан да онытмыйк: су үзе дә Аллаһы Тәгалә кодрәте белән барлыкка килгән бит! Җирне җылытучы кояш, ай, йолдызлар турында да шуны ук әйтергә була. Әгәр без шушы хакыйкатьне онытсак, Аллаһ үзенең нигъмәтләрен ничек бирсә, шулай туктатырга да мөмкин. Мәҗүсилектә чиктән узган халыкны җәзалау өчен шушы ук ут-суны, алар табынган башка нәрсәләрне дә файдаланырга мөмкин. Моның мисаллары тарихта күп булды бит инде, Нух пәйгамбәр заманындагы туфан фаҗигасен генә искә төшерегез! Һәм беркайчан да Аллаһы Тәгалә билгеләгән чикләрдән үтмәгез, Ул барлыкка китергән нәрсәләргә изгеләштереп табынмагыз, ә бары тик Аллаһка рәхмәт әйтеп, байлыкларыннан тиешенчә файдаланыгыз гына. Чөнки җир йөзендәге бөтен нәрсә кеше өчен, аңа файдалы, яхшы булсын өчен барлыкка китерелгән.

*«Ул — Аллаһ сезгә күрсәтәдер һәм сөйләп белдерәдер һәм дөньяның бөтен хәле белән Үзенең бер генә икәнлеген исбат итәдер, һәм сезгә ризык булсын өчен күктән яңгыр яудырадыр, Аллаһуның бу эшләреннән һич дәрес, гыйбрәт, вәгазь алучы булмас, мәгәр инсаф һәм иман китергән вә инабәт илә Аллаһуга кайткан гакыллы кешеләр генә вәгазьләнерләр» («Мөэмин» сүрәсе, 13 аять).*

Әйе, җирдәге бар байлык кеше үз тормышы өчен файдалансын, ачлыктан, ялангачлыктан интекмәсен, авырлык-газаплар күрмәсен өчен барлыкка китерелде. Әмма әле бу җир йөзендәге бөтен тереклекне үз нәфесе өчен кырып бетерергә адәм баласына рөхсәт бирелде дигән сүз түгел. Аллаһның безгә бушка биргән барлык нигъмәтләре дә кирәге кадәр генә, чама белән файдаланырга тиешле, ягъни ачтан үлмәс һәм ялангач йөрмәс өчен генә. Чөнки безне чорнап алган, суларда йөзгән, күкләрдә очкан барлык тереклек ияләренең дә җаны бар, алар барысы да, безнең кебек үк, яшәү өчен, җан саклау, нәсел калдыру өчен тырыша. Бу дөньядагы барлык үсемлекләр дә, кош-кортлар, җәнлекләр дә, судагы балыклар да — бар тереклек дөньясы Аллаһка буйсынып яшиләр, Аңа сәҗдә кылалар, үзләренчә гыйбадәт кылалар. Бар тереклек дөньясының Аллаһка буйсынып яшәве шунда күренә: һәр төр үз нәселен дәвам итәр өчен көрәшә. Ягъни җирдә тормыш барлыкка килгәндә ничек итеп яратылган, заманча әйтсәк, ничек программалаштырылган, һәр төр күзәнәкләрендә шул әмерне йөртә, миллион еллардан соң да шул рәвешле яшәвен дәвам итә. Бу дөньяда һәр үсемлекнең, һәр бөҗәкнең, һәр тереклек иясенең үз роле, үз бурычы, үз урыны бар. Берсенең яшәве өчен икенчесе кирәк, безнең яшәвебез өчен исә аларның барысы да кирәк. Без кайвакытта теге яки бу тереклек иясенең ни өчен барлыкка китерелүен белеп тә бетермәскә мөмкинбез, әмма бу җан иясе дөньяда бар икән, димәк, ул кирәк булган. Хәер, хәзер инде галимнәр дә табигатьтә тереклек дөньясының бер-берсе белән бик тыгыз бәйле булуын, әгәр бер төр тәмам юкка чыкса, икенчесенә дә һәлакәт янавын исбат иттеләр бит инде. Әйтик, бүре — кырлар санитары, ул чирле тычкан-күселәрне, зәгыйфь, чирле куяннарны юк итеп бара, ирек куйсаң, сарыкларыңны да ашап чыгып китә. Әмма йортка бүре килгәнен хәбәр итү өчен эт бар… Кырда кайнашкан күсе-тычканнар, беренче карашка, гел зыянлы кебек күренсәләр дә, алардан да файда бар: алар җирне йомшартып, көпшәкләндереп торалар. Еланнар, нигездә, күсе-тычкан белән туклана, әмма кеше йортына якыная башлаган еланнарны буып ташларга гап-гади мәче дә җитәргә мөмкин. Шул ук вакытта кош-кортларның, төрле бөҗәкләрнең үсемлекләрне серкәләндерүдә, орлыкларын дөнья буйлап таратуда бу тереклек ияләренең әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Бал кортлары һәм күбәләкләр булмаса, күпме гөлләр чәчәк ата алмас иде, серкәләнә алмыйча, нәселләре корыр иде. Күрәсез, һәркем үз эшен эшли, шул ук вакытта башкалар өчен дә эшли, үзе дә яши, башкаларга да юл ача. Шул ук вакытта, җан саклау өчен, башкаларны корбан итәргә дә мөмкин. Әмма бу да билгеле бер күләмдә — ачка үлмәс өчен генә эшләнә. Ерткыч хайваннар ачка үлмәс өчен бер-беренә һөҗүм итә. Аларда, кешеләрдән аермалы буларак, тик торганда, бер мәгънәсезгә бер-берләрен үтерү юк. Алар бу очракта да Аллаһның чиген үтмиләр. Шул ук вакытта тереклек дөньясында башка төрләр белән кушылу, буталу да юк. Елан бөркет белән якынлык кылмый һәм миллиард еллар буе бары тик еланнар гына тудырып ята… Бер үк йортта торсалар да, эт мәчегә якын килми, сыер аттан бозау тапмый яки колынламый… Алмагачта кыяр үсми, иген башагында җиләк пешми… Бу очракта да тереклек дөньясы тулысынча Аллаһның әмеренә буйсына: һәркем бары тик үз нәселе өчен генә җавап бирә, үз нәселен дәвам итә… Күрәсез, без акылсыз дип уйлаган кош-кортлар да, киек-җәнлекләр дә, телсез-өнсез үсемлекләр дөньясы да эчке бер тәртиптә, тышкы бер әмергә буйсынып яшиләр икән бит! Адәм баласы гына бу мәңгелек тәртипне бозарга, барысын да үзенә буйсындырырга тырыша. Аның теләге — рәхмәт әйтеп, файдалану түгел, буйсындыру. Җиһанның, җирнең мәңгелек тәртибен үзгәртү

һәм кеше нәфесенә хезмәт иттерү! Әлбәттә, бар галәмнәрнең хуҗасы Аллаһы Тәгалә мондый комсызлыкка һәм явызлыкка ирек куймаячак. Бу хакта Ул безгә инде күптән кисәтеп куйды:

*«Сезнең кулыгызда булган нәрсәләр һәммәсе бетәчәк, әмма Аллаһ кулында булган нәрсәләр мәңгегә каладыр» («Нәхел» сүрәсе, 96 аять).*

Әйе, барысы да бәндә әйткәнчә түгел, Аллаһ әйткәнчә булачак. Һәм бар дөнья белән дә бары тик Аллаһы Тәгалә генә идарә итәчәк. Хаклык акрын ачыла шул, әмма барыбер ачыла бара. Нәкъ Аллаһы Тәгалә әйткәнчә:

*«Ул — Аллаһ җирне вә күкләрне төзүче, вә сезнең өчен үзегездән хатыннар кылды, вә һәрбер хайванны (тереклекне) аталы-аналы итеп яратты, шул тәртип белән сезне дә, хайваннарны да күбәйтте, Аллаһуга охшаган һичнәрсә юктыр, вә Ул һәр тавышны ишетүче вә һәрнәрсәне күрүчедер» («Шура» сүрәсе, 11 аять).*

Коръәндә Аллаһ бар хайваннарны, үсемлекләрне, ягъни тереклек дөньясын парлы итеп яратуын хәбәр итә. Бу хакта «Та һа» сүрәсенең 53 аятендә, шулай ук «Рәгыд» сүрәсенең 3 аятендә дә хәбәр бар:

*«Ул — Аллаһ барлыкка китерде җирне вә анда зур таулар һәм дәрьялар бар итте, һәм дә һәр җимешләрдән ике төрлене яратты».* Монда да сүз үсемлекләрнең, тереклекнең ирле-хатынлы, ягъни парлы-парлы булуы турында бара. Сез укый торган биология дәреслекләрендә дә нәкъ шулай дип язылган, әмма бу хакта Коръәндә дә хәбәр ителгәнлек турында әйтелмәгән. Алай гына да түгел, дәреслекләрдә язылганча, бу үсемлекләр, имештер, эволюция юлы белән әкренләп, үзләреннән-үзләре барлыкка килгән икән. Шулкадәр камил табигать, безне туендырып тора торган игеннәр, җиләк-җимешләр үзләреннән-үзләре барлыкка килгән дә, җиләге — җиләк булып, хөрмәсе — хөрмә булып, карбызы карбыз булып үскән дә киткән икән! Алай була алмый ул, балалар! Әгәр үсемлек дөньясы алай җиңел генә барлыкка килә һәм яши торган булса, бүген кешеләр үз ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен әллә нинди җиләк-җимешләр, файдалы үсемлекләр уйлап тапкан булырлар иде. Әмма һаман шул булганнары — Аллаһ биргәннәре белән тәҗрибәләр үткәреп яталар: бер-берләренә кушып, ялгап карыйлар, шулай иттереп нараттан — алма, каеннан чикләвек үстереп җыймакчы булалар. Әмма каен — һаман каен булып, чикләвек куагы һаман чикләвек булып кала бирә... Кушып караган җиләк-җимешләрендә дә тәм юк, ләззәт юк, табигый файда-дәва юк. Алар безгә һаман Аллаһ биргән рәвештә кирәк, Аллаһ биргән рәвештә кадерле һәм файдалы.

Кайберәүләр без әле генә сөйләгән үсемлекләр дөньясы турында «табигать бүләге», «табигать могҗизасы» дип кенә күрсәтергә тырышалар. Табигать — шушы тауларның, диңгезләрнең, тереклек дөньясының бер символик исеме, җыелмасы гына бит ул. Без йортлар төзеп, аларның җыелмасын авыл яки шәһәр дип атаганыбыз кебек. Үсемлекләр, тереклек дөньясында барган хикмәт һәм могҗизаларны берни аңлатмый торган, тудыру һәм юк итү сәләтеннән мәхрүм булган табигатькә «сылтап» калдыру ул — я хакыйкатьне белмәү, я белеп тә аннан качу, яшерү. Ә хакыйкать шул: Аллаһы Тәгаләнең кодрәтеннән башка җиргә бер тамчы су төшмәс, кояш нурлары үтмәс, җирдә бер бөртек үлән үсмәс, тереклек, кешелек булмас. Аллаһы Тәгалә шулай яратмаган булса, меңләгән һәм миллионлаган төр үсемлекләр мең вә миллион еллар буе һәрберсе үз төрен саклап, нәсел дәвам итә алмаслар иде. Әгәр «үзеннән-үзе» дигән тәртипсезлеккә юл куелса, бар дөнья бик тиз буталып, ботарланып, асты-өскә килеп бетәр иде! Шуны беркайчан онытырга ярамый: бөтен тереклек дөньясы бары тик Аллаһы Тәгалә теләге белән генә барлыкка китерелгән, Ул төзеп биргән тәртип буенча яши, Аның теләге белән генә юкка чыгачак…

Инде тагын үсемлекләр дөньясына кайтыйк. Алар безне бөтен җирдә чорнап алганнар: аяк астыбызда, җирдә әллә нинди үсемлекләр, чәчәкләр, үләннәр үсеп ята. Дөньяда чәчәкле үсемлекләрнең генә дә 250 мең төре барлыгы билгеле. Моннан тыш әле ылыслы үсемлекләр, сүүсемнәр дә бар. Шунысын онытмыйк: җирдә бер генә тереклек иясе дә, шул исәптән кеше дә, үсемлексез яши алмас иде. Яшел үсемлекләр безгә сулау өчен кислород бүлеп чыгаралар, алар табигатьтәге органик булмаган матдәләрдән органик матдәләр ясыйлар, ягъни табигатьтә булган суны, газны, минераль матдәләрне эшкәртеп, аксымга, майга, углеводка (шикәргә, крахмалга) әйләндерәләр. Шул ук вакытта үсемлекләр кешеләр һәм хайваннар өчен ризык ролен дә башкаралар — без турыдан-туры үсемлекләр белән тукланабыз, хайваннар ризыгы аша ит, сөт, май рәвешендә дә кабул итәбез. Күрәсез, Аллаһы Тәгалә әйткәнчә, җир йөзендәге бөтен байлык: үсемлеге дә, хайваннары да адәм баласы файдалансын өчен барлыкка китерелгән икән. Хәтта аяк астындагы чүп үләне дә үзеннән-үзе, тик-томалга үсеп утырмый, аның да бу дөньяда үз бурычы бар икән. Ягъни чүп үләнен хайваннар ашый, ә ул хайваннарның ите-сөте, тәмле ризык булып, безнең табыннарыбызны бизи. Шул ук чүп үләннәренең дә туктаусыз кислород бүлеп чыгарып, һаваны чистартып торуларын искә төшерсәк, бу дөньяда бернәрсәнең дә артык түгел икәненә ышанырсың. Ә үсемлекләр дөньясының үз эчендә нинди катлаулы, шул ук вакытта нинди төгәл, тәртипле тормыш барганлыгын күрсәгез, сез тагын бер тапкыр Аллаһның барлыгына һәм Аның кодрәтенә ышанырсыз. Бары тик бу дөньяга — аяк астындагы үлән бөртегеннән

алып күктәге йолдызларга кадәр — күңел күзе белән карарга кирәк. Алар үзләре үк безгә Аллаһның барлыгына һәм берлегенә шаһәдәт китерерләр, сөйләп бирерләр, Аңа сәҗдә кылырлар…

## ҮЛӘН НИЛӘР СӨЙЛИ

«Мин — җирдәге үләннең тере бер күзәнәге — туам, сулыйм, тукланам, тудырам һәм вакыты җиткәч үләм… Мин — тере, мин гел хәрәкәттә, гел эштә… Минем белән бергә, меңләгән күзәнәк хәрәкәт итә, яши, һәрберсенең үз эше бар, үз бурычы билгеләнгән. Тамырдагы туганнарыбыз үсемлекне туктаусыз су һәм туклыклы матдәләр белән тәэмин итеп торалар. Шул ук вакытта ул күзәнәкләр дә туктаусыз бүленүдә һәм үсүдә. Тамырлар әле туфракка берегеп, тотынып тору ролен дә үтиләр. Тамырлар бик төгәл өлешләргә бүленгән. Анда үсү һәм суыру зоналары, гел бүленеп тору өлешләре бар. Мондагы күзәнәкләр һәрберсе үз эшен, үз функциясен генә башкара. Әйтик, бүленү зонасында яңа күзәнәкләр җитлегеп тора, үсү зонасында төп көч үсемлекнең үсүенә һәм зураюына китә, суыру зонасы исә тамырдагы нәни төкчәләр аша туфрактагы суны һәм файдалы матдәләрне суырып алып, сабак буйлап куып тора. Тамыр төкчәләре әле үзләреннән махсус лайла да бүлеп чыгара, бу лайла туфрактагы матдәләрне, тозларны эретеп, үсемлек өчен яраралык хәлгә китерә. Бу тамыр төкчәләре, нәни насослар кебек, туктаусыз эшләп торалар, искеләре урынына яңалары үсеп чыга, болар булмаса, үсемлек корый, үлә. Хәер, үсемлекнең һәр күзәнәге, һәр өлеше бары тик яшәү, яшәү өчен көрәшә.

Боларны нәрсә өчен сөйлим? Безне барлыкка китергән Бөек затның кодрәтен, акылын һәм осталыгын күрсәтү өчен. Безнең һәрберебез Аның тарафыннан яшәү һәм нәсел калдыру өчен барлыкка китерелгән, программалаштырылган. Мондагы хикмәт һәм могҗизаны әйтеп, сөйләп бетерерлек түгел. Сезгә без аяк астындагы гади үлән генә булып күренәбез. Ә шул үләннең үзәгендә кеше күзе күрмәгән хәлләр, химик һәм биологик үзгәрешләр барып ятканын кешеләр белми дә. Менә сез тамырның суыру зонасындагы күзәнәкләргә генә күз салыгыз. Бу төзелештә бер генә артык яки җитешмәгән нәрсә юк, барысы да, бер системага буйсынып, яшәү өчен эшләп тора. Тамырның үзәгенә үткәргеч тукымалар урнашкан, алар буйлап тамырның кәүсәсеннән су һәм файдалы матдәләр үтеп тора. Моның өчен махсус үткәргеч каналлар-көпшәләр барлыкка китерелгән. Тамырның үзәгендә гаять мөһим бурыч үти торган тагын бер тукыма бар, ул юкәр дип атала. Бу тукыма, киресенчә, җир өстеннән җир астына — тамырларга органик матдәләр: аксым, май, углевод күчерә. Юкәр белән үзагач тамырның суыру зонасына чиратлашып, йолдыз рәвешендә урнашканнар. Бу бөек төзелештә ник бер ялгыш, ник бер җитешмәү, ник бер гариплек булсын… Ә югыйсә җирдәге үлән генә бит…

Тамыр күзнәкләренең, су, һава һәм матдәләр үткәрү кебек тышкы функцияләреннән тыш, үзара да бик төгәл билгеләнгән бурыч-эшләре бар. Без туктаусыз бүленеп, үрчеп торабыз. Шулай ук үзебездә запас матдәләрне: шикәр, май, аксымны туплап торырга сәләтлебез. Хәтта үлгән күзәнәкләрнең дә үз бурычлары бар — алар тамырны кибүдән, артык җылынудан, авырулардан саклап торалар, ягъни алар үлгәннән соң да яшәү-яшәтү өчен көйләнгән… Я Раббым, Синең көч-кодрәтең чиксез, мәрхәмәтең бөтен дөньяны чорнап алган бит! Хәтта үлән тамырындагы үлгән күзәнәкләрне дә онытмыйсың, яшәү өчен эшләргә көйләгәнсең!

Менә шулай тамырдан — бәбәк, ягъни сабак күтәрелә, үсемлек җир астыннан җир өстенә чыга, яфраклана һәм бөреләнә, чәчәк ата, орлык бирә, нәсел калдыра… Биредә дә бернинди очраклылык юк, барысы да төгәл бер тәртипкә салынган. Үсемлекнең җир өсте өлешендә дә һәр орган, һәр күзәнәк гомум принципка — яшәү принцибына буйсынган. Бәбәкнең, ягъни сабак һәм яфракларның төп функциясе —һавадан туклану, ягъни углекислый газ һәм судан, кояш энергиясе тәэсирендә, органик матдәләр барлыкка китерү. Шуңа күрә үсемлекләргә кояш җылысы, кояш нуры бик кирәк, шуңа күрә яфраклар һәрвакыт кояш нуры ягына таба борылалар, даими рәвештә күзгә күренмәгән хәрәкәттә, әйләнештә булалар.

Үсемлек бәбәгендәге яфраклар тамырларга һавадан туклану өчен кирәк булса, бәбәкнең бөресе исә, нигездә, нәсел калдыру, яфракларга тормыш бирү өчен хезмәт итә. Ягъни бөресез — яфрак, яфраксыз бөре шытып чыга алмас иде. Бөреләр үтә салкын һәм үтә эссе һавага бик сизгер, алар мондый вакытта ачылмыйлар гына, чөнки һәлакәттән саклану сигналы безнең һәр күзәнәгебезгә салып калдырылган. Шушы кечкенә генә бөре дә, әле ачылмас борын, үзендә булачак үсемлекнең рәвешен-копиясен йөртә. Бөрене ачып карап, аннан нинди яфрак чыгасын, яфрагына карап, нинди агач яки үлән үсәсен әйтергә була. Бөре, үз вакыты җиткәнче, махсус кабырчык эчендә бөгәрләнеп ята, бу кабырчык исә бөренең үсүдән иртә туктаган үз яфраклары… Я Раббым, монда да үлгән яфраклар яңа тормышны дәвам итү өчен эшлиләр, яшиләр бит! Кем өйрәткән аларны шушы изгелеккә, шушы фидакарьлеккә?! Аллаһ, әлбәттә, Аллаһ! Барыбызның да Хуҗасы һәм барлыкка китерүчесе бөек Аллаһның мәрхәмәте бит бу…

Менә шушы бөгәрләнеп яткан бөре эчендә дә тулы тормыш бара — биредә булачак яфраклар яки чәчкәләр формалаша. Бер заман күзәнәкләр шулкадәр тиз бүленә һәм үсә башлыйлар ки, бөре күзгә күренеп бүртә, зурая һәм беркөнне кабырчыклар ярылып китә һәм аннан яңа тормыш, яңа яфрак яки яңа чәчәк йомарланып дөньяга атыла, дөньяга ачыла. Әйтерсең лә күктә яңа йолдыз кабына, дөньяга яңа кеше туа, җиһанда яңа планета ачыла…

*«Җирдә вә күкләрдә булган барча мәхлуклар кайберләре ихтыярый вә кайберләре ихтыярсыз Аллаһуга сәҗдә кылырлар вә иртәләрдә һәм кичләрдә үзләре сәҗдә кылганда күләгәләре дә сәҗдә кылыр» («Рәгыд» сүрәсе, 15 аять).*

Әйе, без барыбыз да Аллаһка буйсынабыз, Аңа сәҗдә кылабыз, Ул билгеләгән бурычны ахыргача үтибез… Минем менә бу нәни яфрагым да дөньяга үз бурычын үтәү өчен яралды. Аның төп эше — һавадан азык алу, туклану. Безнең яфрактагы күзәнәкләребез сулыйлар, үзләре дә туеналар, тамырларга да аксым, май, крахмал куып торалар. Без — тере, гел хәрәкәттә, суга туенганда, күзәнәкләребез ачыла, су бетә башласа йомылабыз, үзебездә булган су парларын шулай запаста тотабыз, шулай итеп, кибеп бетүдән сакланабыз. Без яшәү өчен ахыргача көрәшәбез, безгә шундый әмер салынган. Безгә үз-үзебезне тирә-юньнең һөҗүменнән саклау инстинкты да салып калдырылган — безнең кайбер күзәнәкләребез тәмсез исле яки агулы матдәләр бүлеп чыгарырга сәләтле. Шулай ук безнең арада суның парга әйләнүен киметә торган күзәнәкләр дә бар — алар корылык вакытында хәрәкәткә киләләр һәм үсемлекне саклап калалар. Шулай ук бу нәни яфракта шикәр эремәсен үсемлекнең барлык башка органнарына куа-тарата торган күзәнәкләр дә бар. Моның өчен яфракка иләк сыман көпшәләр урнаштырылган, шикәр шунда бер күзәнәктән икенчесенә күчеп йөри. Боларны безнең өчен шундый уңайлы һәм камил итеп син уйлап таптыңмы, кешем? Юк, син безнең өстән таптап йөргәндә яисә бер сәбәпсезгә өзеп ыргытканда, менә бу яфрак, үләннәрдә шундый тулы һәм кызыклы тормыш барадыр дип, башыңа да китереп карамыйсың бит! Кая инде сиңа мондый гаҗәеп дөньяны барлыкка китерү?! Безне дә, синең үзеңне дә бөек Аллаһ шушындый итеп дөньяга яратты, без моны онытмыйбыз, син дә беркайчан да бу хакта онытырга тиеш түгелсең, адәм баласы!

Әйе, яшәү өчен көрәш барганда, безнең барыбызга да эш җитәрлек: кайсыбыз үз күзәнәкләрендә су йөртә, кайсыбыз —һава, кайсыбыз — тоз, кайсыбыз — шикәр, аксым… Күктән җылы, нур, һава алабыз да җиргә тапшырабыз, җирдән дым, азык алабыз да тирә-юньгә таратабыз… Үзебезне дә яшәтәбез, Аллаһның ризалыгы белән, сезне дә тукландырабыз, хайваннарга да азык булып торабыз. Әйе, без җирдә тормышны тотып торабыз. Үлән генә диеп, таптап китмәгез — бу үлән дә җирдә тереклекне дәвам итүдә катнаша. Үлән генә димәгез — ул да җир белән күкләр арасында үткәргеч ролен үти, сез яшәсен өчен яши. Без хәтта үлгәннән соң да сезнең өчен яшибез —ташкүмер, ягулык булып, йортларыгызны җылытабыз, тормышыгызны хәрәкәткә китерәбез.

Без, үсемлекнең тере күзәнәкләре, нәселебезне калдыру өчен дә җавап бирәбез. Бу гаять җаваплы эш, нигездә, чәчәкләр һәм орлык-җимешләр аша бара. Бар тереклек дөньясындагы кебек, нәсел калдыру өчен безгә ике җенестәге күзәнәкнең бергә кушылуы кирәк. Чөнки Аллаһ безне шулай яраткан:

*«…һәм үстерер һәрбер үсемлектән ирле-хатынлы яхшы үсемлекләрне» («Хаҗ» сүрәсе, 22 аять).*

*«Шиксез, Аллаһу Тәгалә вак орлыкларны һәм җимеш төшләрен яручы, ягъни җиргә салган һәр орлыкны үстерүче» («Әнгам» сүрәсе, 95 аять).*

Әйе, без дә парлашып нәсел дәвам итәбез. Парлашу өчен серкәләр безнең үзебездә дә өлгерергә мөмкин, җил, бөҗәкләр ярдәмендә, без аны читтән дә ала алабыз. Бөҗәкләрне үзебезгә кызыктырып тартып китерү өчен, безгә баллы ширбәт бүлеп чыгару сәләте бирелгән. Балга һәм хуш искә кызыгып килгән бөҗәкләр тәпиләре белән безнең серкәләребезне дә алып очалар, аны башка чәчәкләргә дә тараталар, шулай итеп, безгә нәсел калдырырга ярдәм итәләр. Бу да — безне барлыкка китергән Раббының бер могҗизасы, рәхмәте бит…

Шулай итеп без чәчәктәге җимешлек авызына эләгәбез. Монда безгә шыту һәм үсү өчен бик яхшы шартлар булдырылган — без дымлы һәм яшерен яралгы капчыгында урнашкан күкәй күзәнәкләр белән кушылып, яңа тормыш тудырабыз. Ягъни серкә белән бергә ата күзәнәк килә, җимшәндә исә ана күзәнәк үз вакытын көтеп ята… Без бергә кушылабыз да тагын бүленә, үрчи, үсә башлыйбыз. Безнең шушындый максатчан эшебез нәтиҗәсендә, орлык яралгысы барлыкка килә һәм җимшән эчендә җимеш үсә башлый. Бу җимеш һәм орлыкларның төп бурычы — яңа тормышка нигез булу, нәселне дәвам итү… Безне дөнья буйлап җилләр, сулар да тарата, бу бөек күченеш-хәрәкәттә кешеләр, кошлар, хайваннар, бөҗәкләр дә ярдәм итә. Шулар ярдәмендә, дәрья уртасындагы утрауларда да, биек тау башларында, салкын тундраларда, хәтта кайнар ком чүлләрендә дә без яшәвебезне дәвам итәбез. Без тирә-юньгә җайлашабыз, көрәшәбез, әмма барыбер бөтенләй юкка чыкмыйбыз. Безне бу дөньяда Аллаһның чиксез рәхмәте тота. Без бетсәк, җирдә тереклек тә бетәчәк. Шуңа күрә үлән генә димәгез, өстебезгә каты басмагыз, кирәксезгә өзмәгез, гомеребезне кыймагыз — без бит Аллаһның яратканы,

Аның колы… Безнең һәр күзәнәгебез Аллаһ кушкан эшне башкара, Аңа буйсына, Аңа сәҗдә кыла. Бу мәңгелек гыйбадәтне сез күрмисез, әмма Аллаһ күрә… Шуңа күрә безне саклый. Сиңа бу сүзләрне, бу хакыйкатьне аяк астындагы гап-гади үлән сөйли, бер иелеп кара әле, кеше туганым…»

*«Үләннәр һәм агачлар Аллаһуга сәҗдә кылалар» («Рахман» сүрәсе, 6 аять).*

Әйе, иел дә җиргә кара әле, адәм баласы! Әгәр күңел күзе белән карасаң, син шушы гап-гади үләннең дә нинди катлаулы һәм төгәл төзелеш белән барлыкка китерелүен һәм яшәп ятуын күрер идең. Син — кеше, бөек, әмма шушы гап-гади үләнне дә барлыкка китерә алмыйсың, җир белән күк арасында су, һава, җылылык үткәргеч булып торучы шундый төгәл механизмлы тере организм уйлап чыгара алмыйсың. Кая ул — тулы организм, җан иясе, хәтта мондый камил бер тере күзәнәк тә ясый алмыйсың син! Бик тырышып, нидер уйлап тапсаң да, син аңа җилләрне, суны, туфракны, кояш нурларын буйсындыра, хезмәт иттерә алмаячаксың, ягъни табышыңны барыбер һәлакәткә дучар итәчәксең. Юк, бу синең көчсезлегеңне күрсәтми, бу — Аллаһның барыбыз каршында да бөек кодрәтен, көчен күрсәтә. Син шушы илаһи көчне танырга һәм Аның алдында баш ияргә тиеш…

Тирә-ягыңа кара — бөтен җирдә Аллаһның могҗизалары, дәлилләре, хикмәте. Әйе, *«Ул — Аллаһ сезгә күрсәтәдер һәм сөйләп бирәдер, һәм дөньяның бөтен хәле белән Үзенең бер генә икәнлеген исбат итәдер...»* Әйе, балалар, менә сез Аллаһның сүзе булган Коръәнне укыгыз һәм Аллаһ барлыкка китергән дөньяга карагыз! Чагыштырып, күңел күзе белән карагыз!

*«Яшерен нәрсәләрнең ачкычлары Аллаһ кулында, аларны Аллаһудан башка белүче булмас, вә Ул корыда һәм суда булган нәрсәләрне белә, янә агачтан бер яфрак төшсә, аны Ул белә, дәхи туфрак астында кечкенә бер орлык булса һәм җирнең өстендә я эчендә аз гына юешлек я корылык булса, әлбәттә, Аллаһ аларны алдан ук белеп, Ләүхүл-мәхфүздә язып куймыштыр» («Әнгам» сүрәсе, 59 аять).*

Ләүхүл-мәхфүз — язмыш китабы, ягъни һәр кешенең, бөтен тереклек иясенең, хәтта ки бөтен дөньяның язмышы язылган төп китап. Бөтен тереклек иясенең программасы салынган Гамәл китабы… Һәм боларның барысын да барлыкка китерүче, бер камил системага, программага салучы — галәмнәр хуҗасы Аллаһы Тәгалә… Ул агачтан яфракның да кайчан өзелеп төшәсен белә, чөнки нәкъ шул матдәләре беткәч, яфракны картаеп үлә торган итеп Аллаһы Тәгалә Үзе барлыкка китергән бит. Менә сез игътибар итегез: бер караганда, гади яфрак кына бит инде, саргая да өзелеп төшә кебек. Ә юк, бу өзелеп төшүнең дә үз тәртибе, үз механизмы, үз закончалыклары бар икән бит! Билгеле бер вакыт җиткәч, яфракның күзәнәкләре картая башлый, аңа су, һава, файдалы матдәләр инде аз микъдарда гына килә, күзәнәкләр матдәләр ясаудан бигрәк, таркалуга, хәтта үз зарарларына эшли башлыйлар… Кирәкле матдәләр җитмәгәннән, яфраклар саргая яки кызара. Аннан яфракның сабакка тоташкан урынында бөке кебек каты катлам барлыкка килә. Бу каты катлам яфрак белән сабак арасындагы бөтен элемтәне туктата. Шулай итеп, яфрак сабактан аерыла… Яфрак үлә…

Яфрак үлә, әмма тормыш дәвам итә. Әгәр безнеке кебек салкын шартларда агачлар яфракларын коймасалар, һаман да суны парга әйләндерүне дәвам итсәләр, ягъни эшләп торсалар, бу бөтен агачның һәлак булуына китерер иде. Чөнки туң яфрак су да, файдалы матдәләр дә бирә алмый, шуңа күрә кыш көнендә күп агачлар ярым йокы хәлендә булалар, тулы тормыш белән яшәү өчен көчләрен әрәм итмиләр. Димәк, яфракларның картаеп коелулары, үлүләре ул агачның, үсемлекнең яшәве өчен кирәк икән! Ягъни агачтан яфрак аерылу хәлен Аллаһы Тәгалә максат белән эшләгән. Менә шуңа күрә Аллаһы Тәгалә агачтан яфракның кайчан һәм ничек төшәсен дә, җир астындагы нәни орлыкның ничек үсәсен дә, туфракта нинди шартларда су яки корылык буласын да — барысын да алдан белеп тора. Бөтен тереклек дөньясы шушы бөек хакыйкатьне танып, Раббысына буйсынып яши, бары тик адәм баласы гына күз алдында булып яткан шушы могҗизаларны күрми яки күрмәмешкә салыша!

Сезнең күзәткәнегез бармы икән — әле кояш чыкмаган, әмма офыкта инде таң яктысы беленә башлаган бер вакыт була. Бу — иртәнге намаз вакыты. Шушы вакытның бер мизгелендә җил дә исүеннән туктап, бөтен әйләнә-тирәнең, агач-яфракларның тынып-оеп калганын күрәсең… Әйтерсең лә бар табигать Аллаһы Тәгалә каршында тынып, намазга оеган, сәҗдәгә киткән… Бу хакта бит Коръәндә дә әйтелгән: «*Үләннәр һәм агачлар Аллаһуга сәҗдә кылалар»,*— диелгән *(«Рахман» сүрәсе, 6 аять).* Без инде күрдек: безне чорнап алган менә бу дөнья — урман-болынлыклар, үсемлекләр дөньясы — ул бит тере дөнья, алар да безнең кебек туа, яши, үлә… Аларның теле дә, җаны да бар, әмма без аларны аңлап кына бетермибез. Шуңа күрә һәр агачка, һәр чәчкәгә, һәр яфракка карата сак һәм мәрхәмәтле булыйк, газиз балалар! Кирәкмәскә таптамыйк, өзмик, рәнҗетмик үзләрен! Безнең яшәвебез тулысынча аларга бәйләнгән бит. Аллаһы Тәгалә аларны безнең өчен барлыкка китергән, әмма бу байлыкны урынсызга, кирәксезгә, мәгънәсезгә сарыф итүдән катгый рәвештә тыйган! Тик торганда агач ботагын сындырырга кул сузасың икән, син үзең кебек үк тере җан иясен рәнҗеттең, анда кайнап торган тормышны өздең, туктаттың дигән сүз. Син агачның кулын сындырдың, һәм,

әлбәттә, моның өчен Аллаһы Тәгалә каршында һичшиксез җавап бирәчәксең. Үлән-гөлләр белән, таланган, тапталган урман-әрәмәләр белән дә шул ук хәл. Ботак сындырудан тотынган кеше инде ярты табигатьне корытуга барып җитте. Кеше җәннәт кебек җирне үз теләге белән җәһәннәмгә әйләндерә, бу вәхшилеге өчен аны үлгәч тә җәһәннәм көтәсен ул әле аңлап бетерми… Үзе бер күзәнәк тә барлыкка китерә алмаган кеше Аллаһ биргән шушы байлыкларның кадерен белми, сакламый, фикерләп карамый. Табигатькә карата сез дә шундый миһербансыз булмасагыз иде, балалар! Яфрак-үләннәрнең телен аңларга өйрәнсәгез иде, сез дөньяда нинди гүзәл тормыш барганын күрер идегез! Шушы изге эштә сезгә Коръән гыйлеме бәхет ачкычы булып торсын иде… Амин.

## ТЕРЕКЛЕК ДӨНЬЯСЫ ТУРЫНДА

Безнең тирә-юнебездә тагы бер терек дөнья — хайваннар дөньясы яшәп ята. Судагы балыклар, һавадагы кошлар, җирдәге бөҗәкләр, урман-кырлардагы киек җәнлекләр, йорт хайваннары үзләре бер могҗизалы дөнья булып, туу һәм үлемнәре белән кырыс бер тәртипкә буйсынып, үзләренчә яшәп яталар алар. Хайваннар дөньясы гаҗәеп күптөрле һәм күп санлы — галимнәр тарафыннан өйрәнелгән бер миллионнан артык төр хайван бар, әле өйрәнелмәгәне шуның кадәр ике-өч өлеш. Үзебезне әйләндереп алган шушы тере дөньяның, аяк астыбыздагы кырмыскаларның, баш очыбыздагы бал кортларының могҗизалы тормышларын аерым-аерым алып тикшерә башлаганчы, галимнәребезнең, дәреслекләребезнең бу тереклек дөньясы турында ни әйтүләрен карап үтик әле.

Биология дәреслеге беренче битеннән үк: «Биология — терек табигать һәм аны идарә итүче закончалыклар турындагы фән ул»,— дип башланып китә. Сөбханалла! Галимнәребез үз телләре белән үк: «Терек табигать идарә ителә»,— диләр түгелме соң? Сорау бирик әле: кем тарафыннан идарә ителә соң ул терек табигать? Табигать, үсемлекләр, хайваннар дөньясы өчен закончалыклар, системалы тәртип бар икән, ул кануннарны, тәртипне барлыкка китерүче зат та булырга тиеш бит инде?! Әллә бакалар, еланнар, кошлар һәм балыклар үзләреннән-үзләре генә система төзеп, закончалык тудырып, үз-үзләре белән идарә итеп яталармы икән? Юк, әлбәттә, аларның барысын да барлыкка китерүче дә, системалы максатка эшләтүче дә, билгеле бер кысаларда тотып яшәтүче һәм юкка чыгаручы да — бары тик Аллаһы Тәгалә. Җирдә һәм күкләрдә башка бер генә затның да бу кадәр кодрәткә, бу кадәр гыйлемгә, бу кадәр камиллеккә көче җитәрлек түгел. Шул ук мәктәп дәреслекләре үзләре үк: «Һәрбер организм бербөтен булып үзара килешеп эшләүгә көйләнгән структуралар җыелмасыннан гыйбарәт, ягъни ул бер система булып тора»,— дип яза. Кем шулай «үзара килештерә» соң мескен хайвандагы «структуралар җыелмасын», кем хайванга туу, яшәү, нәсел калдыру серләрен *системага* салып программалаштырган, өйрәткән? Үзеннән-үзе генә шундый катлаулы тере организм барлыкка килгәнме, оешып яшәп ятамы? Галимнәребез бу дәреслекләрдә: «Организмның теләсә нинди составы өлешенең үз вазифасы бар, ул билгеле функцияләрне башкара»,— дип язалар. Кем кушуы, өйрәтүе буенча башкаралар соң бу мәхлуклар ул вазифа-функцияләрне? Кем билгеләп куйган аларга бу кырыс тәртипне, шул тәртипкә буйсынуны? Хайваннар үзләреме? Юк, әлбәттә, тереклек дөньясына бу бөек тәртипне билгеләүче, һәр әгъзага үз вазифасын тапшыручы да — бары тик Аллаһы Тәгалә генә. Аллаһ ярдәме белән, хайваннар да, үсемлекләр кебек үк, тирә-юньнән энергия алалар, аны эшкәртә һәм файдалана беләләр. Үсемлекләр кебек үк, хайваннар дөньясы да тышкы тирәлеккә җайлаша ала, моның өчен судагы балыкларга һәм һавадагы кошларга карау да җитә. Үсемлекләр кебек, хайваннар дөньясы да ике җенесле, ягъни аталы һәм аналы, алар үз ишләре белән тормыш кора, нәсел калдыра, ягъни үрчү сәләтенә ия. Каян килгән соң җирдән шуышучы бөҗәкләргә нәсел калдыру, нәсел саклау гыйлеме? Нәкъ үз ишенә, үз төренә тартылу белеме, башка төрләр белән тән дә, кан да бутамау, бары тик *үзеңнекен* саклап калу гыйлеме? Әлбәттә, алар өчен нәкъ менә шушылай яшәү тәртибе Аллаһтан, бары тик Аллаһтан гына була ала! Бар тереклек дөньясы, шул исәптән хайваннар да, шушы бөек тәртипкә буйсынып яшиләр, шуңа күрә әлегә дөнья исән, дөнья бара…

*«Ул — Аллаһ җирне вә күкләрне төзүче, вә сезнең өчен үзегездән хатыннар кылды, вә һәрбер хайванны ата-аналы итеп яратты, шул тәртип белән сезне дә, хайваннарны да күбәйтте, Аллаһуга охшаган һичнәрсә юктыр, вә Ул һәр тавышны ишетүче вә һәрнәрсәне күрүчедер» («Шура» сүрәсе, 11 аять).*

Әйе, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте чиксез… Хайваннарны парлы-парлы итеп яратучы да — Ул, аларның күзәнәкләренә нәселдәнлек мәгълүматларын салучы да — Ул, бар тереклек дөньясына гаҗәеп камил организм бирүче дә — Ул, Аллаһ бит! Хайван гына димәссең, бөҗәк-тараканнар гына димәссең — боларның да организмнарында гаять катлаулы химик процесслар, матдә алышынулар, өзлексез операцияләр булып ята бит! Монда да үсемлекләр дөньясындагы кебек — һәр операция өчен махсус бер матдә җаваплы. Әйтик, хайванның физиологик процессын, ягъни яшәешен көйләүче гормоннар

гөрләп эшләп яталар, бу матдәләр хайванның махсус күзәнәкләрендә ясалып тора. Аларның кайберләре организмда су күләмен көйли, кайберләре җенси җитлегүгә җавап бирә һәм үрчүдә катнаша. Хайваннарда да, кешеләрдәге кебек, борчылса, каннарында шикәр арта, алар ярсый башлыйлар. Куркыныч туганда махсус гормоннар бүлеп чыгаручы кош-кортлар, бөҗәкләр дә бар. Авыруларга каршы хайван организмында исә махсус саклагыч матдәләр — антитәнчекләр эшләнә. Алар көне-төне организм сагында торалар, әгәр хайван организмына чит-ят матдә үтеп керсә, шунда ук һөҗүмгә ташланалар һәм аны юк итәләр. Абзарда яткан хайванга яки җирдә шуышучы бөҗәкләргә каян килгән мондый иң югары сизгерлек, тиз генә оеша алу, тәннең, канның иң яшерен күзәнәкләре белән идарә итә алу сәләте? Уйлагыз әле, балалар, уйлагыз, хайван үз акылы белән бу тикле катлаулы химик, биологик, физиологик процесслар белән идарә итә аламы? Юк, әлбәттә, ул күп очракта үз организмында мондый хәлләр булып ятканны белми дә, хайван түгел, хәтта кеше дә әле үз организмында нинди процесслар барганын белеп бетерми. Алайса, бу тереклек дөньясы ничек шулай бөек бер система булып, тәртип белән яшәп ята соң? Ничек үзен-үзе җимереп, юкка чыгарып бетерми? Чөнки тереклек дөньясы Аллаһ тарафыннан шулай итеп яратылган, аларның организмнары төгәл бер системага салынган һәм бер тәртипкә буйсындырылган. Бу бөек тәртипнең исеме — Аллаһ тәртибе, бу камил системаның исеме — Аллаһ төзегән система, бу күзгә күренмәгән идарә законнары — Аллаһ билгеләгән законнар. Менә шушыларны нык аңлау белән аңласагыз, Аллаһны менә шушы хикмәтләре аша тетрәнеп танысагыз, сез бөтен җиһанның серләренә төшенә башларсыз, балалар… Сезгә Аллаһның гыйлеме, нуры, бәхет капкалары ачылыр. Карагыз бу дөньяга, карагыз һәм уйланыгыз, уйланыгыз һәм тетрәнегез: сезнең алда Аллаһның хикмәт һәм могҗизалары таралып ята…

*«Җирдәге төрле хайваннар һәм ике канатлары белән оча торган кошлар сезнең кебек җәмәгать булудан башка нәрсә түгелләр» («Әнгам» сүрәсе, 33 аять).*

*«Әйә ул гафил кешеләр һавадагы кошларга карап гыйбрәт алмыйлармы? Ул кошлар күктә һава эчендә Аллаһ әмере белән очалар, аларны һавада күтәрүче юк, мәгәр аларны Аллаһ күтәрә. Аллаһның бу эшендә дә гыйбрәтләр бар иман китергән кешеләр өчен» («Нәхел» сүрәсе, 79 аять).*

*«Аллаһ җир йөзендә булган барча җан иясен судан бар итте, ул хайваннарның кайберләре корсагы өстендә йөрер, вә кайберләре ике аяк өстендә йөрерләр, вә кайберләре дүрт аяк өстендә йөрерләр, Аллаһ үзе теләгән мәхлукларны бар итәр, бит Аллаһның һәрнәрсәгә көче җитә» («Нур» сүрәсе, 45 аять).*

Әйе, Аллаһның һәрнәрсәгә көче җитә. Үлән тамырларындагы тере күзәнәктән алып кояш һәм ай-йолдызлардагы нурга кадәр — Аллаһ барлыкка китергән, Аллаһ биргән байлык. Аның гыйбрәтләре, могҗизалары җирдә, күктә, суда, үсемлекләрдә, бал кортларында, бар тереклек дөньясында, ниһаять, кешенең үзендә… Сүзебез хайваннар дөньясы турында барганлыктан, хезмәтебезнең бу бүлегендә күбрәк тереклек ияләре, бөҗәкләр һәм кош-кортлар, судагы балыклар турында гыйбрәтле хәлләр сөйләрбез. Башта сезгә бал кортлары турында бер хикәят-кыйсса сөйлисебез килә…

Коръәндә әйтелгән: *«Раббың бал кортларына вәхи кылды (хәбәр бирде): «Ий бал кортлары, тауларда, агачларда вә кешеләр тора торган җайларда үзегезгә оя ясагыз! Соңра һәр җимеш чәчәкләреннән бал ашагыз һәм җыегыз вә итагать итеп, мин әмер кылган юлга керегез!» — дип. Бал кортлары кешеләр өчен эчләреннән төрле төстәге балларын чыгарып бирәләр, ул балларда ашар өчен тәме дә һәм кешеләр өчен шифасы да бар. Фикерли белгән кешеләр өчен бал кортларының эшендә зур гыйбрәт вә дөреслек бардыр» («Нәхел» сүрәсе, 68—69 аятьләр).*

Бу аятьләрдә Аллаһы Тәгаләнең турыдан-туры бал кортларына биргән әмере хәбәр ителә. Ягъни Аллаһы Тәгалә бал кортларына шундый программа-инстинкт сала ки, өсләренә шундый бурыч йөкли, бал кортлары заман ахырына кадәр тауларда, агачларда, кешеләр төзегән урыннарда яшәргә, чәчәкләрдән бал җыярга һәм Аллаһ кушкан юлдан гына йөрергә һәм тормыш алып барырга тиеш булалар. Болар барысы да кешеләргә файда булсын өчен һәм кешеләр бал кортларының тормышларына карап, гыйбрәт алсыннар өчен эшләнә.

Инде хәзер тирә-юнегезгә карагыз: бал кортлары гаҗәеп катлаулы, кырыс тәртипкә буйсынып, күмәк тормыш белән яшәп яталар бит! Беренчедән, алар чыннан да нәкъ менә Аллаһы Тәгалә кушкан урыннарда — тауларда, агачларда һәм кеше җайлаган урыннарда — умарталарда оя коралар. Балыклар кебек, диңгез суында да, диңгез астында да түгел, бөҗәкләр кебек, туфракта яки җир астында да түгел, нәкъ менә Коръәндә әйтелгәнчә, тауларда, агачларда һәм кеше торган җайларда оя ясый бал кортлары! Бу хәл дөнья яратылганнан бирле шул рәвешле дәвам итә, Аллаһның «шунда яшәгез!» дигән әмерен үзгәртергә бал кортларын берни дә мәҗбүр итә алмый!

Икенчедән, бу күмәк тормышта һәрбер бал кортының үзенең башкара торган эше бик ачык билгеләнгән. Бер ояда, гадәттә, ике буын кортлар — ана һәм бала буын бергәләп яшиләр. Монда үзара функцияләр шундый итеп бүленгән ки, бер-берләреннән башка бал кортлары бөтенләй яши алмаслар

иде. Әйтик, бер ояда бер буыннан булган өч төрле корт төркеме яши — ана корт, соры кортлар һәм эшче кортлар. Ана кортлар бары тик үрчем өчен генә җаваплы, ягъни бары тик күкәй салу белән генә мәшгульләр. Сорыкортлар (ата кортлар) исә бары тик ана кортларны аталандыру өчен генә кирәк. Ә эшче кортлар бөтен ояны карап, ашатып торалар, болар бал җыялар, кәрәз ясыйлар, ояларын саклыйлар, кәрәзләрдәге күкәйләрне карап торалар…

Күреп торасыз, бал кортлары бер-берләре белән мәңгелеккә бәйләнгәннәр, берсеннән башка икенчесе юк. Монда максатсыз, эшсез, бурычсыз бер генә төркем дә каралмаган. Монда тәртип бик кырыс, хәтта усал, дип әйтергә мөмкин. Әйтик, аталандыру вазифасын башкарган соры кортларны яңадан ояга якын җибәрмиләр, чөнки алар күзәнәкләрдәге бала кортларга дигән азыкны ашап кына ятачаклар. Шуңа күрә соры кортларның күбесе үз эшен башкаргач юкка чыга яки үлә.

Корт анасы исә — бөтен күчнең патшабикәсе. Ул берүзе, йөз меңгә якын күкәй салып, зур бер нәсел калдыра, дөньяга яңа эшче кортлар әзерли. Корт анасы бөтен күч өчен җавап бирә. Кортлар күч аерганда, ягъни аерылып чыкканда, яңадан ояга кертү өчен башта корт анасын тотарга кирәк, аннан күч үзе аның артыннан ияреп барачак. Шуңа күрә татар халык мәкале: «Башта кортның анасын тот, күче ту бала үзе керер», — ди.

Эшче кортларның тормышы исә — үзе бер могҗиза. Эшче кортлар алар — үрчем бирми торган ана кортлар. Аларга Раббылары тарафыннан нәсел калдыру вазифасы салынмаган. Аның каравы, эшче кортлар — искиткеч төзүчеләр, очучылар, үсемлекләрдән татлы ширбәт җыючылар, шул ширбәттән бал ясаучылар… Сез алар ясаган балавыз кәрәзгә генә карагыз! Дөньяда төзелеш өчен әле моннан да камил, моннан да файдалы форманың уйлап табылганы юк! Бу кәрәзнең һәр күзәнәге алты кырдан һәм алты почмактан тора. Никадәр төгәллек, никадәр гүзәллек, никадәр симметрия аларда! Бер генә кәкрәйгән-бөкрәйгән, чыгып торган яки ясалып бетмәгән урын юк! Алты кырлы кәрәз рәвешенең дөньяда иң камил төзелеш формасы икәнлеген әйткән идек инде. Чөнки бу геометрик фигураны кулланып эшләгәндә, төзелеш мәйданында бер генә буш урын да калмый икән! Һәм бу мәйданга иң күп санлы (меңләгән!) кәрәзләрне бары тик алты кырлы итеп ясаганда гына урнаштырырга мөмкин икән! Каян килгән бал кортларына шулкадәрле гыйлем, математика, инженерлык сәләте? Моны без аңсыз-җансыз дип исәпләгән бөҗәкләр эшли бит!

Аннан шушы кәрәзләргә корт анасы тәгәрәтеп күкәйләр салып чыга. Эшче кортлар исә бу яралгыларга чәчәкләрдән татлы азык ташыйлар, аларны саклап һәм ашатып торалар. Әгәр оя авызында чакырылмаган кунаклар — шөпшә яки сорыкортлар пәйда булса, сакчы кортлар аларны пырхылдатып куып чыгаралар. Әйе, әйе, эшче кортлар әле сакчы ролен дә үти, әйткәнемчә, ояда бөтен вазифалар да бик төгәл бүленгән. Хәллерәк, яшьрәк кортлар ерак-еракларга бал эзләп очса, олыгая башлаганнарына исә ояда да эш җитәрлек. Дөм караңгы ояда да шундый пөхтәлек һәм тәртип саклау өчен, чыннан да, зур булдыклылык һәм могҗизаи сәләт булу кирәктер шул. Ә ул сәләт нәп-нәни бал кортларына, әлбәттә, Аллаһтан бирелгән… Адәм баласы бу бәрәкәттән файдалана һәм фикерләп гыйбрәтләнә алсын өчен. Ә без, корт кына, дибез. Баксаң, шушы кечкенә генә корт та Аллаһ кодрәте белән гаҗәп хикмәтле эшләр башкара ала икән.

Ә сез беләсезме, бал кортлары беркайчан да үз ояларында, ризык арасында «пес» итмиләр икән бит? Моның өчен алар оядан читкә чыгып очалар. Балның гәрәбәдәй чиста һәм сары булырга тиеш икәнлеген каян белә икән соң бу бал кортлары? Әлбәттә, чисталык гыйлеме дә аларга Аллаһтан бирелгән. Бал кортлары бер ояда яшәсәләр дә, беркайчан да бер күч икенчесе белән буталмый, чөнки — ни могҗиза! — һәр күчнең үз исе бар икән! Ягъни һәр нәселнең үз исе бар! Шушы ис буенча алар бер-берләрен табалар, бер гаилә булып укмашалар, бер-берләрен саклыйлар икән! Кем бу бал кортларын нәсел исен саклый торган бизләр белән барлыкка китергән? Аллаһ, әлбәттә, Аллаһ!

Ә инде бал кортларының кешеләргә китергән файдасы турында сөйләп тә, язып та бетерерлек түгел! Нәп-нәни бал кортлары җитештергән бу балда кеше организмына кирәкле бөтен нәрсәләр дә бар. Ул йөрәк һәм кан авыруларыннан да дәва, ашказаны, бавыр, бөер, эчәкләр өчен дә шифа, тын алу юлларына, баш мие эшчәнлегенә дә умарта балының тәэсире көчле. Бары тик аны чама белән һәм белеп кулланырга кирәк. Хәтта умарта кортының чагуы да, ягъни корт агуы да, билгеле бер микъдарда кеше сәламәтлеге өчен файдалы. Бүгенге көндә медицинада бал үзе дә, корт агуы да, балавыз да бик нык кулланыла. Галимнәр умарта балының файдасы турында яңадан-яңа ачышлар ясап торалар. Әмма алар да бу хикмәтләрдән халыкны гыйбрәтләнергә чакырмыйлар. Бал кортларының Аллаһ әмере белән барлыкка китерелүләрен һәм яшәүләрен, Аллаһ әмерен үтәп кешеләргә хезмәт итүләрен искә алмыйлар. Ә бу хакта онытырга ярамый бит, бу безнең Аллаһка карата рәхмәтсезлегебез булыр иде. Аллаһ бит бу нигъмәтләрне ничек биргән, шулай кире ала да ала. Ул моңа безнең үзебезне үк сәбәпче итәчәк. Әйләнә-тирәнең гаять пычрануы аркасында бүген канатсыз бал кортлары туа икән, кешеләрдәге җан гариплеге инде табигатькә дә күчкән, дигән сүз бит бу! Уйлап кына карагыз әле, экологик пычранулар аркасында, канатсыз бал кортлары туа! Зур фаҗиганең, афәтнең башы түгелме

соң бу! Без кадерен белдекме икән шушы кадәр бушка килгән байлыкның: урман-кырларның, гөлчәчәкләрнең, менә бу бал кортларының, судагы хисапсыз балыкларның? Кеше аларны соң чиккәчә агулап, кортларын — канатсызга, балыкларын санаксызга әйләндереп бара түгелме соң? Ә шушы бал кортларыннан, урман-кырлардан, чишмә-сулардан башка ничек яшәрбез соң без?! Уйла әле, кеше туганым, гыйбрәт ал әле бу дөньяга карап, безнең гаеп белән юкка чыккан һәр үлән, һәр бөҗәк өчен без Аллаһы Тәгалә каршына басып җавап бирәчәкбез бит! Һичшиксез соралачакбыз һәрберебез, һәрнәрсә өчен!!!

*«Аллаһу Тәгалә чебенне вә чебеннән өстенрәк үрмәкүчне мисал итүдә әлбәттә оялмас. Коръәнгә ышанучылар бу мисалны, әлбәттә, Раббыларыннан дип беләләр. Әмма кяферләр, шундый хәшәрәтләрне мисал итеп китерүдә Аллаһуның максаты нәрсә, диләр. Аллаһ шундый мисаллар белән күп кешеләрне адаштырыр һәм күп кешеләрне туры юлга күндерер. Ләкин хак юлдан фасыйкларны гына адаштырыр» («Бәкара» сүрәсе, 26 аять).*

Әйе, Аллаһы Тәгалә Коръәндә бал кортларын да, чебенне дә, үрмәкүчне, кырмыскаларны да безгә мисал итеп күрсәтә. Ягъни җир йөзендә ниләр бар — Коръәндә алар бар. Коръәндә ниләр бар — алар барысы да безнең тормышыбызда бар… Бу тормышта дөрес итеп яшәү өчен, ялгышмас һәм хәсрәткә төшмәс өчен Аллаһы Тәгалә безгә юлларын күрсәтә. Хәтта шушы җан ияләрен мисалга китереп, безне гыйбрәтләндерергә тели, фикер йөртергә чакыра. Бу дөньяда бар нәрсәне Ул Үзе барлыкка китерүен, Үзе яшәтүен, Ул Үзе юкка да чыгара аласын кисәтә. Шул исәптән безнең үзебезне дә… Коръәндә китерелгән һәр мисал — могҗиза, һәр мисал — кисәтү, һәр мисал — Аллаһны тануга өндәү. Бу дөньядагы һәр тамчы, һәр үлән, һәр бөҗәк, һәр кызәнәк Аллаһы Тәгаләнең барлыгын һәм берлеген раслый, шул хакта үзләренчә кычкырып сөйләп торалар, ә без ишетәбезме, күрәбезме, аңлыйбызмы соң?!

Менә үрмәкүчләргә генә карыйк. Коръәндә бу җан ияләре исемендә тулы бер сүрә бар, әмма 69 аять-хәбәрдән торган бу сүрәнең нибары берсе генә турыдан-туры үрмәкүчләр хакында кебек. Калганнары — Коръән белән гамәл кылмаган төрле сыннарга, нәфескә һәм башка нәрсәләргә табынучылар турында. Алар барысы да үрмәкүч белән чагыштырыла, мондый кешеләрнең диннәре дә, үзләре дә, тормышлары да тотрыксыз булуын Аллаһы Тәгалә бик мәгънәле итеп аңлата:

*«Аллаһудан башка сынымнарны дус тоткан мөшрикләрнең мисалы — үрмәкүч кеби ул үзенә өй ясады, әлбәттә, өйләрнең зәгыйфьрәге үрмәкүч өедер, салкыннан, яңгырдан файда бирмидер, шуның кеби сынымнарны дус тоткан мөшрикләр дә алардан һич файда күрмәсләр, әгәр шуны белсәләр» («Гәнкәбут» сүрәсе, 41 аять).*

Әйе, үрмәкүчләрнең өе — ябышкак пәрәвез, ул никадәр оста үрелсә дә, җил-яңгырлардан, салкыннан, кар-бураннардан сакламый. Шуның кебек, Коръән белән гамәл кылмыйча, тормышларын өстән-өстән генә үргән кешеләр дә кайгы-хәсрәткә, тормыш авырлыкларына тиз бирешә. Аларны эчкечелек, наркомания бик тиз үзенә буйсындыра, лайлалы пәрәвез кебек, үзенә ябыштырып калдыра. Мондый кешеләрнең тормышлары күп очракта фаҗига белән тәмамлана. Мөшрик ул — Аллага түгел, башкага буйсынучы һәм табынучы — үз нәфесе теләкләренә, төрле идеяләргә, кешеләргә, малга, байлыкка кол булучы… Һәм Аллаһы Тәгалә, бу аятьне дәвам итеп, мондый мөшрикләрне бик нык кисәтә.

*«Аллаһ шиксез беләдер аларның Аллаһудан башка нәрсәгә гыйбадәт кылганнарын, җәзасыз калдырмас, Ул — җиңүче һәм хикмәт иясе. Коръәндә бу кеби мисалларны кешеләргә бәян итәбез аңларга җиңел булсын өчен, ләкин ул мисалларны галимнәрдән башкалар аңламас» («Гәнкәбут» сүрәсе, 42—43 аятьләр).*

Тормышны аңларга җиңелрәк булсын өчен, Аллаһы Тәгалә безгә тормышның үзеннән менә шундый мисаллар китерә. *«Ләкин ул мисалларны галимнәрдән башкалар аңламас»,*—ди. Галимнәр, ягъни уйлый, фикерли белә торган кешеләр, эзләнүчән җаннар, бөек хакыйкатькә барып җиткән кешеләр… Алар Аллаһны таныйлар һәм бары тик Аңа гына буйсынып яшиләр. Без барыбыз да шушы гыйлем ияләре сафында булсак иде…

Инде карыйк: үрмәкүчнең җәтмәсенә кемнәр эләгә соң? Саксыз чебеннәр, җилбәзәк күбәләкләр, тәҗрибәсез бөҗәк-кортлар… Үрмәкүч — ерткыч бөҗәк, ул башка җан ияләрен ашау хисабына яши, оя-җәтмәсе дә аңа ау коралы булып хезмәт итә. Җәтмәне үрмәкүч үзе үрә, ә төзелеш материалы булган сыекча исә үрмәкүчнең эчендә ясала, бу сыекча тышкы якка чыккач катып китә, һәм ябышкак пәрәвез җепләре барлыкка килә. Сез карагыз, ничек тырышып ясый үзенең тозагын үрмәкүч — башта ул ябышмый торган пәрәвезеннән күппочмаклы рам кебек нәрсә ясый. Бары тик шуннан соң гына лайлалы җепләреннән бөҗра ясый башлый, аларны бер ноктадан — үзәктән рамга тоташтыра. Ау вакытында үрмәкүч үзе читтә качып утыра, әмма җәтмәнең үзәгеннән сузылган җеп аңа ни булса да хәбәр биреп тора. Ягъни җәтмәгә берәр бөҗәк килеп эләксә, сигнал җебе тартыла, үрмәкүч тизрәк качкан урыныннан атылып чыга да корбанын ябышкак пәрәвезе белән уратып ташлый. Аннан әле

җаны да чыгып өлгермәгән корбанына агу җибәрә. Бу сыекча-агуның шундый көче бар ки, ул җәтмәдәге бөҗәкне үтереп кенә калмый, аның бөтен эчке әгъзаларын кабыгында килеш эретеп кайната, ягъни үрмәкүч өчен әзер шулпага әйләндерә. Үрмәкүчкә исә шушы әзер шулпаны чәйнәп тә тормыйча суырып йотарга гына кала…

Аллаһы Тәгалә безгә бу үрмәкүч мисалын ни өчен күрсәтеп биргән соң? Игътибар белән тирә-юнегезгә карагыз әле: бу тормышта кешене адаштыру, сataштыру, һәлак итү өчен атлаган саен җәтмәләр корылган… Алар читтән бик матур һәм нәфис булып күренәләр, зеңгелдәп, үзләренә чакырып торалар… Челтәрләп үрелгән бу сәнгать әсәрләрендә башка җан ияләрен үлем көтеп торадыр дип уйлыйсы да килми. Ә хәзер шушы пәрәвез тозагын кешеләр тормышына күчереп, чагыштырып карагыз. Күзләрне камаштыргыч төнге концерт заллары, асылташларга күмелгән ярымшәрә хатын-кызлар, затлы шешәләрдәге шәраблар, алдавыч ләззәт вәгъдә иткән наркотиклар, дус-ишләр, ыгы-зыгы… Яшьләр, төнге күбәләкләр кебек, шушы ясалма матурлыкка тартыла, наркотиклар, алдавыч дөнья пәрәвезенә ябышып кала, һәм инде шушы азгынлык, хәрам җәтмәсеннән күпләр мәңге чыга алмый… Бу ясалма тормыш әкренләп аның җанын, хәлен, ахыр килеп, гомерен дә суырып йота… Кеше дигән заттан бары тик буш кабык кына торып кала…

*«Һәр өммәткә (халыкка) үзләренең кылган гамәлләрен зиннәтле итеп күрсәттек, соңра аларның кайтачак урыны Аллаһугадыр, Аллаһ кылган эшләреннән хәбәр бирер…» («Әнгам» сүрәсе, 108 аять).*

Ә яшьләрнең аңнарын аулау өчен төзелгән төрле секталар — шушы ук үрмәкүч җәтмәсе түгелмени? Ничек оста итеп коралар бит ул миссионерлар үзләренең ябышкак җәтмәләрен — имеш, алар космос белән сөйләшә, имеш, алар «өченче күз»не ача, имеш, тәнне җаннан аера ала… Һәм яшьләр, чебен кебек, шушы шарлатаннарга сырыша, аларның агулы җәтмәсенә каба… Нәтиҗәдә бернинди күзе дә ачылмый, күккә дә аша алмый, ә җирдә иң газизләреннән — ата-анасыннан, гаиләсеннән, туганнарыннан аерыла, миңгерәүләнә, зомбига, шушы үрмәкүч-миссионерларның колына әйләнә… Чөнки инде үрмәкүч корбанының тәненә һәм җанына үзенең агуын җибәреп өлгергән була…

Әмма шуңа да игътибар итегез: бер саф, көчле җилнең исүе җитә — үрмәкүч өенең асты-өскә килә. Шуңа күрә үрмәкүч үзенең җәтмәсен аулаграк урынга корырга тырыша, аңа яшерен, ышык урын кирәк. Әмма үрмәкүч күпме генә яшерергә тырышмасын, һәр искән көчле җил, давыл, яңгыр, салкын кар-бураннар иң элек аның өен җимереп ташлый. Нәкъ Коръәндә әйтелгәнчә: *«Өйләрнең зәгыйфьрәге үрмәкүч өедер, салкыннан, яңгырдан файда бирмидер…»* Бу мәхлуклар җир белән күк арасындагы җәтмәләрендә җилфердәргә мәҗбүрләр. Бу инде сиңа умарта кортларының кәрәзле йортлары да, кыя карлыгачларының таш оялары да, җирне тишеп ясалган йомран өннәре дә түгел. Кайсыбызның үрмәкүчнеке кебек үтә күренмәле җилбәзәк йортта яшисе килер иде икән?! Гыйбрәтләнәм дисәң, Аллаһның гыйбрәтләре атлаган саен, әмма без аларны күңел күзе белән күрә, чагыштыра, гыйбрәтләнә белмибез шул…

Инде башыбызны җирдән күтәреп, күккә карыйк әле, балалар! Сез анда төрле-төрле кошларның уйнаклап очуын күрерсез. Кечкенә генә соры чыпчык та теләсә кайсы вакытта күккә күтәрелә ала, күгәрченнәр дә күкне үз йортлары кебек итеп хис итәләр, каргалар да, зур хуҗа булып, күкне аркылыга-буйга гизәләр. Ә без астан кызыгып карап торабыз. Безнең зәңгәр күккә күтәрелергә чыпчык кадәр дә канатыбыз, күгәрчен кадәр дә көчебез юк. Җилкенеп кенә очып китәр идек, Аллаһ безне оча торган итеп яратмаган. Очу бәхетен Ул башка мәхлукларына бүләк иткән…

*«Әйә алар күрмиләрме, гыйбрәт күзе белән карамыйлармы өсләрендә очып йөргән кошларга, канатларын җәярләр һәм кабыргаларын кысарлар. Ул кошларны һавада тотучы юк, мәгәр Аллаһ Үзе генә тотадыр. Ул Аллаһ һәр нәрсәне күрүчедер» («Мөлек» сүрәсе, 19 аять).*

*«Әйә ул гафил кешеләр һавадагы кошларга карап гыйбрәт алмыйлармы? Ул кошлар күктә һава эчендә Аллаһ әмере белән очалар, аларны һавада күтәрүче юк, мәгәр аларны Аллаһ күтәрә. Аллаһуның бу эшендә дә гыйбрәтләр бар иман китергән кешеләр өчен» («Нәхел» сүрәсе, 79 аять).*

Бу аятьләрдә бик ачык итеп әйтелә: кошларны һавага күтәрүче дә, аларны анда тотып торучы да — Аллаһ Үзе икән. Аллаһы Тәгалә кошларны дөньяга барлыкка китергәндә үк аларны һавада очарга яраклы итеп яраткан. Ягъни кошларның тән төзелешенә кешеләрдә юк нәрсәне куеп калдырган. Кайберәүләр, бу — канатлар, диярләр. Әйе, канатлар кошларга һавада очу өчен гаять мөһим роль уйный. Аллаһның ярдәме белән, кош канатларына каурыйлар очарга яраклы итеп — җиңел һәм сыгылмалы яратылган. Бу каурыйлар рәт-рәт булып кош канатына урнаштырылган һәм күзгә күренми торган ыргакчыклар белән үзара тоташтырылган. Шулай итеп, каурыйлар бер-берләренә керешеп, тиеп торалар, бу тигезлек исә үз чиратында һава каршылыгын киметә, очуны җиңеләйтә, җылы саклый һәм су үткәрми. Очар кошның койрыгы да үзенә күрә мөһим бурыч башкара — ул очуны көйли, руль хезмәтен үти. Әмма Аллаһының кошларга биргән нигъмәте монда гына бетми әле, Аллаһ очар кошларны аерым бер хикмәт белән бүләкләгән. Кошларның тәненә, үпкәләрдән тыш, һава тоту өчен

капчыклар да куеп калдырган. Шушы һава капчыклары кошка очарга, күктә иркен итеп сулыш алырга, еш сулаудан янып үлмәскә ярдәм итә. Бу һава капчыклары үпкә белән тоташкан, очкан вакытта һава капчыклары кысыла һәм киңәя, алардагы һава үпкә аша үтә. Әйтерсең лә кош күккә махсус өреп кабартылган һава шары ярдәмендә күтәрелә! Кош шушы «ярдәмче капчыклар» булышлыгында һавага туена, шулар ярдәмендә тәнендәге температураны көйли… Йодрык хәтле кошка кайдан килгән шулхәтле гыйлем, осталык? Җавап бер генә: ул Аллаһ тарафыннан шулай яратылган, бу могҗизалы һава капчыкларын да, мамык кебек каурыйларын да кош үзе барлыкка китермәгән, ясамаган. Бу нигъмәтләр аңа Аллаһ тарафыннан дөнья яратылганда ук бүлеп бирелгән, бүләк ителгән. Кошлар бөтен тормышлары белән шушы тәртипкә — Аллаһ төзеп биргән яшәү тәртибенә буйсыналар. Алар үз белдекләре белән бу һава капчыкларын булдыра да, юкка да чыгара алмыйлар. Кулыннан килсә, кеше дә тәнендә шушындый һава капчыклары барлыкка китереп кенә күккә күтәрелер иде — булдыра алмый. Чөнки Аллаһ тарафыннан кеше очар өчен яратылмаган шул. Шушындыйрак механизм дөньяда тагы бер төрле мәхлукларда — балыкларда бар. Үзегез беләсез: балыклар судан авыррак һәм алар суда батарга тиеш кебек. Әмма — батмыйлар, кошлар һавада уйнаклап очкан кебек, балыклар да суда уйнаклап йөзеп йөри. Чөнки, кошлардагы кебек, балыкларда да һава капчыклары бар. Балык чистартканда үзегезнең дә күргәнегез бардыр, балык эченнән газ белән тулы үтә күренмәле капчыклар чыга. Аларны кыссаң шартлыйлар, эчләрендәге һава да бик тиз чыгып бетә. Балык маймычы тугач та, су өстенә чыгып, шушы йөзү капчыгын һава белән тутырырга тиеш була, шулай эшләмәсә, ул үлә. Кошлардагы һава капчыгы, хәрәкәтләнүенә карап, киңәеп һәм кысылып торган кебек, балыкларда да, суның тирәнлегенә карап, йөзү капчыгы кечерәя яки зурая. Ягъни балык тирәнгәрәк төшсә, куык кечерәя, артык газ капиллярлар аша канга күчә. Бу балыкның тизрәк чумуына ярдәм итә. Ә инде балык өскә күтәрелгәндә, куык та зурая, балык та җиңеләя төшә. Кайбер балыкларда йөзү куыгы нечкә генә көпшә аша эчәк белән дә бәйле була. Мондый очракта артык газ авыз һәм саңаклар аша суга тарала…

Күрәсез, һәр тереклек төре билгеле бер тәртип белән барлыкка китерелгән һәм һәр мәхлук шушы тәртипкә буйсынып яши икән. Коръәндә әйтелгәнчә: *«Аллаһу Тәгаләгә җирдә вә күкләрдә булган мәхлукатлар тәсбих әйтерләр, канатларын һавада җәйгәннәре хәлдә, кошлар да тәсбих әйтерләр. Тәсбих әйтүчеләрнең барчасы үз гыйбадәтләрен белер булдылар. Аллаһу Тәгалә ул мәхлукатларның ни эшләгәннәрен белүче» («Нур» сүрәсе, 41 аять).* Ягъни бар тереклек иясе Раббыны таный, Аңа буйсына, Аңа үзенчә сәҗдә итә, гыйбадәт кыла, дигән сүз. Бу буйсынуның иң зур дәлиле — тереклек иясенең Аллаһ билгеләгән нәсел калдыру, нәсел саклау әмерен үтәүләре. Сез карагыз, кайбер балыклар, нәсел калдырыр, уылдык чәчәр өчен агым суларга каршы йөзеп меңәләр, шарлавыкларга каршы күтәреләләр, әмма билгеләнгән урынга, билгеләнгән вакытта уылдык чәчәләр, нәсел калдыралар һәм үләләр. Әйе, кайбер тереклек ияләре, балыклар, бөҗәкләр, нәсел калдырганнан соң, шунда ук үлә торган итеп каралган. Җан ияләре моңа да бара, чөнки бу очракта нәсел калдыру максаты, программасы яшәүнекенә караганда да ныграк һәм көчлерәк салынган булып чыга. Һәм тереклек иясе бу әмергә буйсына… Карагыз сез үзләре ачлы-туклы килеш икешәр ел буе балаларын имезеп яткан ак аюларга, карагыз үз авызыннан өзеп, йоткан ризыгын бугазыннан кире чыгарып балаларын ашаткан бөркетләргә! Карагыз балалары артыннан утка сикергән мәчеләргә, балалары өчен корабларга ташланган кит балыкларына, колынын эзләп меңәр чакрым юл үтә алган атларга! Каян килгән аларга нәселне саклау кирәклеге белеме? Әлбәттә, Аллаһтан, бу мәхлукатлар барысы да Аның әмерен үтиләр — һәрберсе үз нәселен, үз төрен дәвам итә. Хайван булып хайван шуны аңлый, шушы билгеләнгән тәртипкә буйсына, нәселен саклый, ә кеше? Кеше кадерен беләме соң бу тормышның, үзенә бирелгән бу нигъмәтләрнең, гыйлемнең кадерен беләме адәм баласы? Гыйбрәт аламы ул шушы могҗизалардан, дөрес аңлыймы ул бу дөньяны һәм дөрес яшиме? Аллаһы Тәгалә билгеләгән тәртипкә буйсынып яшиме? Әллә туганнан бирле үз тәртибен урнаштырырга тырышамы? Хайваннар дөньясына карап, кеше тормышы турында тагы бер кат уйланыйк әле… Һәм тагы бер кат үз тормышыбызга күз салыйк: кеше дигән дөньяда ниләр булып ята икән?

## «КЕШЕЛӘРНЕҢ ЯРАТЫЛЫШЫ АЛЛАҺ ЭШЕ

*«Безнең кодрәтебезгә вә берлегебезгә дәләләт иткән ачык вә көчле галәмәтләребезне, бөтен галәм төзелешенең хәлләреннән кешеләргә күрсәтербез, вә кешеләрнең яратылышы Аллаһ эше икәнлеген үзләренең төзелешләреннән күрсәтербез, хәтта ачыкланганга чаклы Аллаһу Тәгаләнең хаклыгы һәм бер генә икәнлеге вә Коръән Аллаһ китабы вә Мөхәммәт г-м Аллаһуның рәсүле икәнлеге ачыкланганга чаклы. Әйә, һәрнәрсәгә шаһит булырга синең Раббың җитмиме?» («Фуссиләт» сүрәсе, 53 аять.)*

Нинди ачык һәм тетрәндергеч хәбәр — *«...кешеләрнең яратылышы Аллаһ эше икәнлеген үзләренең төзелешләреннән күрсәтербез...»* Ягъни кешеләрнең тән төзелеше, бөтен әгъзалары бу бөек һәм камил яратылышның Аллаһтан икәнлеген *үзләре үк* сөйләп торалар икән! Кешене дөньяга Аллаһ барлыкка китергән, Ул яраткан! Һәр әгъзага, һәр күзәнәккә үз бурычын, үз эшен йөкләгән. Һәм кешенең һәр әгъзасы, һәр күзәнәге шушы әмергә буйсынган. Ягъни күзләр — күрер өчен, колаклар — ишетер өчен, үпкәләр — сулау өчен, йөрәк кан йөртер өчен көйләнгән. Күзләр — колакны, үпкәләр йөрәк эшен алыштыра алмаганнар, кешелек яратылганнан бирле, һәрберсе үз урынында, үз эшен башкарган. Кеше күп очракта үз организмында нинди катлаулы химик, физик һәм психологик процесслар булып ятканын үзе дә аңлап, белеп бетерми әле. Һәм күп очракта бу катлаулы процессны көйләп, аның белән идарә дә итә алмый. Чөнки безнең бөтен әгъзаларыбыз һәм күзәнәкләребез үзләрен барлыкка китерүче Аллаһка буйсыналар, кеше нәфесенә, кеше теләгенә түгел. Һәм органнарыбыз алга таба да дөрес, тәртипле эшләп торсыннар өчен, сәламәт, төзек булсыннар өчен, безнең үзебезгә дә иң беренче чиратта Аллаһ сүзен тыңларга, Аның киңәшләрен тотарга кирәк. Аллаһ шулхәтле камил механизм — кеше затын барлыкка китергән икән, аның әгъзаларын, күзәнәкләрен зур мәгънә һәм төгәллек белән төзегән икән, Ул алар белән дөрес эш итү тәртибен дә күрсәткән бит инде, ягъни инструкциясен дә биргән! Сез нинди генә камил техника сатып алсагыз да: компьютермы, аудио-видеоаппаратурамы, эшләтеп җибәргәнче, иң беренче чиратта аның инструкциясен өйрәнәсез. Шулай булмаган очракта, техникагыз бик тиз янып, ватылып чыгачак яки сез аны тулы көчкә эшләтеп кенә җибәрә алмаячаксыз. Кешенең үзе белән дә нәкъ шулай. Бу катлаулы, кайнап торган дөньяда дөрес, тәртипле яшәү өчен, адашмау, саташмау, вакытсыз җимерелмәс өчен, кешегә Аллаһ тарафыннан тәртип кагыйдәсе бирелгән. Ул — әлбәттә, Коръән. *«Кеше өчен кирәк нәрсәләрнең барчасын ачык бәян итүче Коръән белән ант итеп әйтәмен»,* — ди Аллаһы Тәгалә «Духан« сүрәсенең 2 аятендә. Әйе, *Коръәндә кеше өчен кирәк нәрсәләрнең барчасы да ачык аңлатылган*. Шул исәптән тән һәм җан өчен кирәк булган нәрсәләр дә…

Аллаһы Тәгалә дөньяга бик күп нәрсәләр барлыкка китергән, һәм кешеләргә боларның кайсыларын файдаланырга ярый, кайсыларын ярамый — Коръәндә бик ачык әйтелгән, һәр нәрсәгә чик күрсәтелгән. Әмма күпчелек кешеләр бу нәрсәләргә бик җиңел карыйлар, тыелганнардан тыелмыйлар, кушканны үтәмиләр. Нәтиҗәдә, кешенең дөрес яшәмәве аркасында, дөнья да бозыла, кеше үзе дә аягүрә таркалып, череп юкка чыгып бара. Бу дөньяда килеп чыккан күп төрле авыруларга, бозыклыкларга, фаҗигаләргә күп очракта кеше үзе сәбәпче булып тора. Кеше Аллаһ кушканча түгел, нәфесе, күңеле кушканча яши, Аллаһ кушканнарга түгел, үз хис-теләкләре котырткanга буйсына, шул хис-теләкләрнең колына әйләнеп китә. Шулай итеп, Аллаһка буйсынырга яраклы итеп барлыкка китерелгән бөтен әгъзаларын, организмын да хәвеф астына куя, харап итә…

Кеше тәннән, җаннан һәм аңнан тора. Тән үзенең төзелеше белән Аллаһка буйсына, җан — Аллаһтан бирелгән яшәү нуры, ә менә аң белән эшләр катлаулырак тора. Аңга уйлау һәм фикерләү сәләте, сайлап алу хокукы бирелгән. Кеше менә шушы сайлап алу процессында зур сынау үтә дә инде… Я ул үз теләге белән Аллаһ күрсәткән юлга чыга, я бу юлдан читкә китеп, адашып, харап була. Үзенең бәхетенә дә, бәхетсезлегенә дә кеше үзе — сәбәпче. Кеше үз язмышын үзе яза. Аллаһы Тәгалә кешене җирнең хуҗасы итеп билгеләде, аны җирдә үзенең ярдәмчесе итте. Хәтта фәрештәләргә кешегә хезмәт итәргә боерды. Бу дөньядагы нигъмәтләрне кешегә файдасы, ярдәме тисен өчен барлыкка китерде. Күрәсезме, Аллаһы Тәгалә кешене ничек олылый, ничек кадерли, ничек сакларга тырыша? Ә кеше нишли? Таныймы ул үзенең Барлыкка китерүчесен? Буйсынамы ул Аңа, рәхмәтлеме, шөкрана итәме? Әллә тәкәбберләнеп, наданланып, үзен Раббысыннан да өстен куеп йөргән буламы? Үзенең гомерен дә, Аллаһ биргән тиңсез нигъмәтләрне дә юкка сарыф итәме? Шушы мәгънәсезгә, зыянга үткән һәр көне өчен, начар һәр гамәле, буш һәр сүзе өчен Аллаһ каршына басып җавап тотасын онытамы?

*«Аллаһ беренче атагыз — Адәм галәйһиссәламнең тәнен балчыктан бар итте, соңра һәрберебезгә гомер билгеләде вә һәрберебезгә билгеләнгән әҗәл аның хозурында. Шуннан соң да Аллаһ эшләренә шик тотасыз» («Әнгам« сүрәсе, 2 аять).*

Әйе, һәр әгъза кыямәт көнендә Аллаһ каршында җавап тотачак, шаһәдәтлек бирәчәк. Ягъни кеше аны тиешле урында Аллаһ билгеләгән эшкә файдаландымы әллә бу әгъзаларны үз нәфесенә хезмәт итәргә мәҗбүриләдеме? Күзләрен Аллаһ тыйган хәрамнан тыйдымы әллә бозыклыкны, азгынлыкны комсызланып аңына, җанына сеңдердеме? Телен Аллаһ тыярга кушкан гайбәттән, әшәке сүзләрдән, ялганнан, буш сүздән тыйдымы, әллә теленә ни килсә, шуны сөйләп йөрдеме? Авызын Аллаһ тыярга кушкан хәрам ризыктан тыйдымы әллә аракысын да, дуңгыз итен дә, башка тыелган нәрсәләрне дә нәфесе күпме тели, шуның кадәр кулландымы? Аякларын Аллаһ тыйган бозык урыннарга йөрүдән туктаттымы әллә аларны азгынлык, җинаять юлында йөрергә мәҗбүр иттеме? Аллаһ кадерләп биргән сау-таза йөрәген, иң төгәл компьютерлардан да камил баш миен, берни белән дә алыштырып булмый

торган башка әгъзаларын тиешенчә саклый белдеме, әллә теләсә нәрсә эшләп, теләсә нәрсә ашап, үз-үзенә зыян китердеме? Һәр әгъза менә шулай соралачак, кеше дөрес яшәмәгән икән, һәр әгъзасы аңа каршы шаһәдәтлек бирәчәк…

*«Ул — Аллаһ сине хак кылды да әгъзаларыңны төзәтте вә һәр әгъзаңны үлчәп төзеде. Сине нинди сурәттә кылырга теләсә, шул сурәттә кылды» («Инфәтар» сүрәсе, 7—8 аятьләр).*

Безнең һәр әгъзабыз — Аллаһ төзегән механизмның бер кисәге, детале ул. Һавадагы очкычның кечкенә генә бер шөребе тотмаса да, ул җиргә егылып төшәргә мөмкин. Кеше дә шулай ук — аның организмында нәни генә бер күзәнәге, бер бизе эшләмәсә дә, кешене үлем көтәргә мөмкин. Чөнки кеше дигән тере механизмда бер генә артык деталь дә, кирәксез нәрсә дә юк, барлык әгъзалар, күзәнәкләр, бизләр үзара бик тыгыз бәйләнгән һәм бер-берләреннән башка яши алмыйлар. Кеше организмы — ул үзе бер дөнья, ул тулы бер системаны тәшкил итә. Әмма бу — кеше үзе барлыкка китергән система түгел, бу бербөтен дөнья аңа инде әзер килеш тапшырылган. Әйе, әйе, аңа бу тән һәм җан инде әзер, формалашкан килеш, әманәт итеп тапшырылган һәм гомеренең ахырына кадәр ул Аллаһның шушы бүләген кадерләп сакларга тиеш. Моның өчен, әлбәттә, гыйлем кирәк, үз тәнеңә һәм җаныңа ачкыч таба белү кирәк, үз организмыңны, әгъзаларыңны тыңлый, ишетә белергә кирәк. Ә алар безнең өчен көне-төне эшләп тора, Аллаһ гыйлемен сөйләп тора, үзләрен кем дөньяга яралтканны төзелешләре белән аңлатып, күрсәтеп тора бит… Аларны бары тик аңлый, күрә, тыңлый белергә генә кирәк.

*«Кешеләрнең яратылышы Аллаһ эше икәнлеген үзләренең төзелешләреннән күрсәтербез...» («Фуссиләт» сүрәсе, 53 аять).*

## ЙӨРӘК СЕРЕ

«Мин — зур түгел, йодрык кадәр генә, әмма миңа Раббыбыз тарафыннан бик зур эшләр йөкләтелгән. Мин канны бөтен гәүдә буйлап куып, эшләтеп торам. Баш миенә дә, кул-аякларга да, үпкә-бавырларга да кан бары тик минем ярдәмем белән генә барып җитә ала. Шулай итеп, минем аша кан белән бөтен тукымаларга, күзәнәкләргә һава һәм файдалы матдәләр үтеп тора, таркалып кирәксезгә чыкканнары кире китеп тора… Мин эшләмәсәм, боларның барысы да туктала, тән буйлап кан әйләнүе дә туктала һәм кеше үлә. Ә мин кешене яшәтү өчен барлыкка китерелгән. Шуңа күрә мин Аллаһтан туктарга вакыт җитми торып туктамыйм: көне-төне эшлим, кеше йоклаганда да эшлим, эшләгәндә дә эшлим, минем барлыгымны белсә дә эшлим, белмәсә дә эшлим… Тыңлап карагыз әле, мин ничек туктаусыз тибеп, хәрәкәтләнеп торам. Кешенең үзеннән аермалы буларак, минем ялкаулыкка, мәгънәсез, буш эшләргә, туктап калырга хакым юк. Мин башкалар эшләгәнгә дә дәгъва кылмыйм, безнең һәрберебезнең үз бурычы, шул ук вакытта без бер-беребездән башка яши дә алмыйбыз. Шуңа күрә без бер-беребезгә карата бик сизгер, беребез зәгыйфьләнә башласа, икенчебез күбрәк эшләргә тиеш була, беребез чирләсә, икенчебез үз күзәнәкләрендә аңа дәва-шифа әзерли. Кеше күп очракта үз организмында нинди хәлләр булып ятканын аңлап та бетерми. Без күп очракта кешенең саксызлыгы, дөрес яшәмәве, дөрес тукланмавы аркасында нык зарар күрәбез, зәгыйфьләнәбез, бөтенләй сүнәбез…

Мин менә хәзер эшләп торам… Тәүлегенә мин йөз мең тапкыр кыскарып, тибеп алам. Шушы вакытта үзем аша ун тоннага якын кан үткәрәм. Бу — аена өч йөз тонна, дигән сүз… Гомер буена бу авырлык миллион, миллиард тонналарга җитәр иде. Мин шушы авырлыкны күтәрергә, үткәрергә һәм эшкәртеп торырга көйләнгән. Кеше организмында 5 литр чамасы кан бар, мин шуны 20 секунд эчендә бөтен тән буйлап таратырга сәләтле. Ә үпкә-бавырларга исә мин бу канны биш тапкыр тизрәк куып кертәм. Мин үзем йөрәк карындыгы эчендә нык утырам, бу карындык мине кысылу-бәрелүләрдән генә саклап калмый, ә ышкылуны киметә торган сыекча да бүлеп чыгара. Бу исә, үз чиратында, мине вакытсыз тузудан, таушалудан саклап кала…

Минем эчем куыш итеп яратылган. Анда дүрт бүлемтек булып, бу бүлемтекләр бары тик кан кабул итү һәм канны кире чыгару өчен генә көйләнгән. Канның миңа билгеле бер чама белән кереп-чыгып торуын капкачлар (клапаннар) көйли. Алар миңа сеңер белән нык итеп беркетелгәннәр, өске бүлемтекләрем кысылганда, капкачлар ачыла да, кан аскы бүлемтекләргә агып төшә. Бу аскы бүлемтекләр кыскарганда исә, капкачлар ябылалар, һәм кан яңадан өске бүлемтеккә үтә алмый. Ул инде хәзер кан тамырларына кысып чыгарылырга тиеш була…

Бөтен кан юллары да миннән башлана һәм яңадан миңа әйләнеп кайта. Кан тамырларының бик калыннарыннан башлап бик вак, нечкәләренә кадәр бар. Менә шул нечкә кан тамырларым — капиллярлар бик зур функция үтиләр: алар канда эрегән матдәләрне күзәнәкләргә чыгару һәм күзәнәктән канга кирәкле матдәләрне алу, сеңдерү эшен башкаралар. Бу вак кан тамырчыклары кеше тәнендә 150 миллиардка якын, һәм аларның барысын да бер рәткә тезсәң, җир шарын ике тапкыр уратып узарга җитәр иде…

Кан минем аша ике түгәрәк ясап әйләнә. Кан махсус юллар буйлап миннән үпкәгә кертелә, аннан кислородка баеп чыга, үзендәге углекислый газны үпкә аша һавага чыгара, ягъни чистарта. Шушы чиста кан миңа кайтарыла һәм мин инде аны бөтен тән буйлап йөртә башлыйм. Бу әйләнештә инде кан үзендә булган кислородны һәм туклыклы матдәләрне тәннең барлык тукымаларына күчерә, өләшеп йөри. Шул ук вакытта вак кан тамырчыкларына күзәнәкләрдәге углекислый газ күчә. Шулай итеп, кан тагы ярлыланып, көчсезләнеп, миңа килеп егыла, мин исә аны, чистарту өчен, тагы тизрәк үпкәләргә куам. Үпкәдә кан тагы саф кислород белән тула, кирәксез агулы газлардан арына… Минем йөрәгемдә чиста кан һәм начар кан беркайчан да бергә буталмый, дүрт бүлемем дә менә шуның өчен инде ул. Миннән үпкәгә чыга торган юлда да, кан тәнгә тарала торган урында да сакчы капкалар тора. Начар кан килгәндә — тәнгә китү юлы, чиста кан килгәндә үпкәгә керү юллары шартлатып ябылып куела. Бу — кеше өчен мәңге шулай көйләнгән, барлыкка китерелгән. Мине һәм бөтен организмыңны шушындый хикмәт белән эшли торган итеп син үзең ясадыңмы, кеше туганым? Юк, бу синең хезмәтең түгел, мактау һәм дан бөтен галәмнәрне һәм синең үзеңне дә барлыкка китергән Аллаһка булырга тиеш! Без барыбыз да бер Аңа буйсынабыз, Ул билгеләгән тәртип буенча шулай төгәл эшлибез. Безгә Аллаһ тарафыннан шундый әмер бирелгән: без мәңге кешегә хезмәт итәргә тиешбез. Һәм без шушы эшебез өчен Аллаһ каршында җавап бирәчәкбез…

Аллаһның хикмәтләре һәм могҗизалары безнең барыбызда да ачык чагыла, әмма кеше аны аңлап кына бетерми. Менә минем аша тәүлегенә тонналап узган канны гына карагыз. Бу канның 90 проценты судан тора, калган өлеше — аксымнар, майлар, шикәр, тозлар һәм башка матдәләр. Кан исә үзе күзәнәкләрдән тора. Мондагы хикмәтләрне дә сөйләп-аңлатып бетерерлек түгел. Бу кан күзәнәкләре күзгә күренмәгән сакчы гаскәр кебек. Аларның кайберләре (эритроцитлар) кислородны сулыш органнарыннан тәннең бөтен күзәнәкләренә күчерү һәм углекислый газны тукымадан чыгару өчен кирәк. Канның бу кызыл күзәнәкләре гаять вак була, әйтик, 1 куб мм канда 5 миллион эритроцит бар. Бу күзәнәкләр кан ясаучы органда — сөякнең кызыл җелегендә ясалып торалар, талакта тупланалар һәм даими рәвештә, кирәк кадәрле микъдарда, канга чыгарылып торалар. Канның мондый кызыл күзәнәкләре дүрт ай чамасы яши һәм соңыннан, үз эшләрен тәмам итеп, юкка чыгалар, алар урынына яңалары туа тора. Канда бу күзәнәкләр җитмәсә, кеше авырый башлый, вакытында дәваланмасаң, бу авыру үлемгә дә китерергә мөмкин. Саф һава, дөрес, хәләл туклану, тәртипле яшәү мондый авырулар килеп чыкмаска ярдәм итә. Кеше бәлки үз канында мондый зур эш, яшәү өчен туктаусыз көрәш барганын белеп тә бетермидер. Хәер, ул бит үзе бу кан күзәнәкләренең берсен генә дә барлыкка китерә алмый. Ул аларга комачау гына итмәскә тиеш. Әгәр кеше үзе зыян китермәсә, бу күзәнәкләр ахыргача кеше гомере өчен көрәшәчәкләр, чөнки аларга Аллаһның әмере шундый.

Канда әле тагы башка төрле күзәнәкләр дә бар — лейкоцитлар. Боларның төсе юк, шуңа күрә аларны канның ак күзәнәкләре дип тә атарга була. Кызыл күзәнәкләр төзелешләре буенча төшсез булса, ак күзәнәкләр барысы да төшле. Бу ак күзәнәкләр үзләренең төзелешләре һәм функцияләре белән бер-берләреннән аерылалар. Кызыл күзәнәкләрдән аермалы буларак, ак күзәнәкләр организмда берничә көннән берничә елга кадәр яши алалар. Лейкоцитлар да кан ясаучы органнарда — сөяктәге кызыл җелектә, талакта, лимфатик төеннәрдә өзлексез ясалып торалар һәм бик хәрәкәтчәннәр.

Бу ак күзәнәкләрнең роле искиткеч мөһим: алар — сакчы күзәнәкләр. Алар организмга килеп кергән чит җисемнәрне, авыру тудыручы микробларны, төрле агулы матдәләрне сагалап кына торалар. Һәм шунда ук аларга һөҗүм итәләр. Организмга куркыныч янаган очракта, алар хәтта кан тамыры стеналары аша да үтеп чыгып, авыру, агулы микробны йотып, кайнатып, юкка чыгарып ташларга сәләтле. Организмга чит-ят, зарарлы җисемнәр күбрәк кергән саен, аларга ак күзәнәкләрнең һөҗүме, ябырылуы да көчәя төшә. Авыру белән көрәшә-көрәшә, ак күзәнәкләр үзләре дә күпләп үләләр, әмма алар урынына яңалары туа тора. Гадәттә, еш кына, авыру белән организм үзе көрәшә, диләр. Авыру белән күзгә күренми торган көчле күзәнәкләр көрәшә, аларга нәкъ менә шушы бурыч — кеше организмын чит-ят җисемнәрдән саклау бурычы йөкләтелгән. Аларга кеше өчен зарарлы булган матдәләрне танып алып юк итү гыйлеме бирелгән. Һәм алар Раббыларының шушы бөек әмеренә буйсынып, мәңге шушы бурычны үтәячәкләр, кеше гомере сагында торачаклар…

Кеше организмында авыру һәм агуларга каршы көрәшә торган тагы бер көчле корал яшерелгән, ул — үзенә бер төрле аксымнар, ягъни антитәнчекләр. Бу эштә дә ак күзәнәкләр (лейкоцитлар) катнаша, һәм яңа төр һөҗүмчән күзәнәкләр (лимфоцитлар) барлыкка килә. Аларның кайберләре бер төрле авыруны гына сагалап торырга һәм юк итеп ташларга сәләтле, кайберләре исә берьюлы берничә авыруга каршы көрәшә ала. Канда менә шушы һөҗүмчән һәм саклагыч күзәнәкләр ясалу үзләре бер *система* тәшкил итәләр. Бу — кешене авырулардан саклый торган механизм, ягъни *иммунитет* дип атала. Кеше туганда ук канында менә шушындый кораллы гаскәр белән туа. Әмма дөрес яшәмәве аркасында ул Аллаһ биргән шушы ярдәмчеләрен гомер барышында югалтып та бетерергә мөмкин. Бу

исә — үлем, дигән сүз, шушы күзәнәкләр булмаса, организм теләсә нинди чиргә бик тиз бирешәчәк, көрәшә алмаячак һәм сыначак.

Кеше безгә — үзенең йөрәгенә дә, башка органнарына да зур авырлыклар китерә. Без тәртипле яшәү өчен көйләнгән. Әмма кеше үзенең тәртипсезлеге белән безнең эчке эшләребезгә катнашып, үзенең әгъзаларына зур зыян ясый. Тыелган ризыклар аша безнең тәнебезгә, каныбызга бик күп ярамаган, зарарлы нәрсәләр үтеп керә. Хайван каны белән безгә хайванның хайванлыгы күчә, тыелган дуңгыз ите аша безгә йөзләгән куркыныч чирләр үтеп керә, аракы, хәмер бездәге иң көчле күзәнәкләрне дә үтерергә, җимерергә сәләтле. Югыйсә бу ризыклар барысы да Аллаһ тарафыннан тыелган бит, кеше аларны кулланырга тиеш түгел. Ә кеше туганнан алып үлгәнгә хәтле шушы хәрам ризыкны куллана, авырулардан башы чыкмый, нәселенә, балаларына үзеннән соң куркыныч чирләр калдыра. Һәм беркөнне без — йөрәк, кан күзәнәкләре, башка әгъзалар — кешенең үзенә, читтән кергән хәрамга каршы тору көчебезне югалтабыз. Шуны гына көтеп торган кебек, кешегә коточкыч чирләр ташлана һәм аны бик тиз арада кабергә китереп кертә… Күреп торасыз, Аллаһ тыйганнардан тыелмавы белән, дөрес яшәмәве белән кеше үз-үзенә кабер казый. Һәм Аллаһ биргән шушы кадәр камил, гүзәл организмын да үз куллары белән сүтеп, җимереп ташлый…

*«Исертә торган эчемлекләр һәммәсе дә хәрамдыр» («Маидә» сүрәсе, 90 аять).*

*«Үлгән хайван, бугазлаганда аккан кан, дуңгыз ите һәм бугазлаганда Аллаһ исемен әйтмичә бугазланган хайван ите — хәрам» («Әнгам» сүрәсе, 145 аять).*

Күреп торасыз, мөселман кеше өчен Аллаһ тарафыннан тыелган ризыклар күп тә түгел. Болар — һәртөрле хәмер һәм миңгерәйткечләр (наркотиклар да шуңа керә), дуңгыз ите, хайван каны, үлгән хайван (үтерелгән — ит комбинатларында ток белән), суйганда Аллаһ исемен әйтеп суймаган һәм каны агызып бетерелмәгән хайван. Боларның барысын куллануны да Аллаһ Коръән белән тыя: «Куллансагыз, зарары үзегезгә булыр»,— ди. Әмма кеше тыеламы соң? Дөнья тулы ризык, берсеннән-берсе татлы җимеш сулары, соклар, ә кеше исерткеч, миңгерәйткеч хәмер, сасы аракы эчә. Һәм бездәге — тәндәге һәм кандагы иң саф, иң көчле күзәнәкләрне яндырып үтерә, үз-үзен җимерә. Дөнья тулы нигъмәт мөселманча суйган яхшы итләр, сөт, балык, яшелчә ризыклары, икмәк, камыр ашлары, ә кеше хәрамның да хәрамы булган дуңгыз итенә үрелә! Тыелганын белә торып, никадәр зарарлы икәнен ишетә торып, дуңгыз итеннән әзерләнгән колбасасын, башкасын ашый. Инде дөнья галимнәре дә дуңгызда 440 төрле куркыныч, йогышлы авырулар барлыгын ачтылар бит, күп илләрдә бу шакшыны өстәлгә якын да җибәрмиләр, ә Россиядә дуңгыз ите төп ризык булып тора. Үзләрен мөселман дип санаган күп кенә татарлар да авыз тутырып шушы хәрам ризыкны ашыйлар. Сез аталарыгыз барган ялгыш юлдан китә күрмәгез, балалар, Аллаһ тыйганнардан үз нәфесегезне тыярга өйрәнегез — файдасы үзегезгә булыр. Тыелмыйча, бу эшләрне җиңелгә, уенга санап йөрисез икән — зарары да үзегезгә булыр…

Ышаныгыз, бу сүзләрне сезгә күпне күргән кешенең йөрәге сөйли… Мин бит кешегә тугры хезмәт итү өчен яратылган. Минем миллион елларга сузылган үз көем, үз тәртибем бар. Бу тәртипне минем өчен мәңгелеккә дип Аллаһ урнаштырды. Мине кирәкмәгән начар уйлар, явыз ниятләр, яманлыклар белән каралтмасаң иде, адәм баласы! Мине гел хәсрәткә, борчуга төшереп тормасаң иде! Тормышыңда авырлыклар килсә, адашуларга һәм саташуларга юлыксаң, мине тыңла! Мин үземнең мәңгелек тибешем аша сиңа Раббыбызның бөек хакыйкатен җиткереп торырмын, тынычлыкка һәм сабырлыкка өндәрмен, сиңа яшәргә рух, көч биреп торырмын. Чөнки мин шундый бурыч белән барлыкка китерелгән бит. Мин сине сакларга тиеш, кеше туганым, ә син — мине, бу —безгә Аллаһның әмере. Мин мизгел саен: «Аллаһ!», «Аллаһ!», «Аллаһ!» дип тибәм. Тыңлап кара әле үз-үзеңне, кеше! Һәм пәйгамбәребезнең әйткән сүзләрен исеңә төшер. Ул: «Тәндә бер ит кисәге бар, ул сау-сәламәт, саф булса, кешенең калган бөтен әгъзалары сау була, ул бозык булса, бөтен җире чирле, начар була»,— дигән. Аннан: «Ул нинди урын соң?» — дип сорагач, пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам: «Ул урын —кальб-йөрәк»,— дигән. Кальб ул — иманның урыны.

Мине — йөрәгеңне саф хәлендә сакла, адәм баласы! Үзең өчен сакла!»

*«Җирдә дә ышанучы кешеләр өчен галәмәтләр бардыр. Дәхи үзегезнең төзелешегездә дә галәмәтләр бардыр, әйә шуларны күрмисезме?» («Зарият» сүрәсе, 20—21 аятьләр.)*

*«Аллаһ сезне аналарыгыз карынында Үзе теләгәнчә сурәтләр» («Гыймран» сүрәсе, 3 аять).*

## МИ НИ СӨЙЛИ

«Мин — баш мие. Кеше организмындагы барлык процессларны: йөрәк эшчәнлеген, хәрәкәтләнүне, сулауны, ашкайнатуны, күрү, сизү, ишетүне, сөйләмне — барысын-барысын да көйләү миңа тапшырылган. Шул ук вакытта мин кеше хәтеренең компьютеры да — мин кеше өчен кирәкле булган

барлык мәгълүматны да үземдә саклыйм. Минем ярдәмемдә кеше уйларга, фикерләргә, үзе белән идарә итәргә өйрәнә. Минем ярдәмемдә кеше дөньяны таный, дөньяда яши. Минем бер генә күзәнәгем эшләүдән туктаса да, кеше телсез, күзсез, кул-аяксыз, хәрәкәтсез калырга мөмкин. Мин бер генә мизгелгә эшләүдән туктасам да, кеше үлә. Кеше үзе миңа зарар китермәсә, мин, баш мие, беркайчан да кеше зарарына эшләмим. Киресенчә, миңа Аллаһ тарафыннан кыямәт көненә тикле кешегә тугры хезмәт итәргә йөкләтелгән. Мин гомер буена кешене сакларга һәм аңа яшәргә ярдәм итәргә тиеш. Мин шушы бөек әмергә буйсынып эш итәм һәм кешелек яратылганнан бирле адәм баласын саклап, җитәкләп алып барам. Һәм кыямәт көнендә, кеше белән бергә, Аллаһ каршында мин дә җавап тотачакмын, бу дөньяда ничек яшәвем турында шаһәдәтлек бирәчәкмен…

Мин зур түгел — кеше тәненең кечкенә бер өлешен тәшкил итәм. Миңа шушылай кечкенә булып кеше башында урнашырга миемдәге сырлар һәм буразналар ярдәм итә. Миндә 14 миллиардка якын күзәнәк (нейрон) урнашкан. Бу күзәнәкләрнең һәрберсе кеше өчен гаять мөһим булган берәр эшкә җавап бирә. Шушы күзәнәкләремне даими эшләтеп тору өчен миңа кеше тәнендәге канның 1/5 өлеше кирәк. Бу кан белән миңа тәннән кислород һәм туклыклы матдәләр килеп тора. Баш миенә аз гына вакытка булса да кан килү туктап торса, минем күзәнәкләрем сүнә һәм кеше үлә. Шуңа күрә без даими рәвештә йөрәк эшчәнлеген көйләп торабыз, йөрәк исә бертуктамый мидәге күзәнәкләрне чиста кан белән тәэмин итеп тора. Без бер-беребездән башка яши алмыйбыз. Минем миллиардлаган күзәнәкләрем кеше тәнендәге һәр күзәнәк, һәр орган белән даими рәвештә элемтәдә тора, без тән белән дә бер-беребездән башка яши алмыйбыз. Без — даими, көне-төне эшләп торган тулы бер система, Раббыбыз барлыкка китергән иң төгәл, иң камил һәм иң гүзәл механизм, без — кеше затының тере күзәнәкләре…

Тышкы тирәлектән зыян булмасын өчен, Раббым мине зур саклык белән баш сөягенә эченә утырткан, ул сөяк исә, үз чиратында, калын тире белән тарттырылган. Ми үзе дә соры кабык белән капланган, шулай итеп минем күзәнәкләрем өч кат саклагыч артына яшерелгән. Миемнең тирән-тирән буразналар, сырлар белән бүлгәләнүен әйткән идем инде. Мондый төзелешнең дә үзенә күрә бер хикмәте һәм сере бар. Шушы махсус җыерчыклар булмаса, баш миенең күләме гәүдәгә караганда 20—25 тапкыр зуррак булыр иде. Сырлар ярдәмендә шушы зур күләм дә кечерәеп, кечкенә генә баш тартмасына кереп утырган. Минең эче исә ак һәм соры төстәге матдә белән тулган. Ак матдә эчендә баш миен арка мие белән тоташтыручы махсус үткәргечләр бар, шундый ук үткәргечләр минең башка бүлекләрен дә тоташтырып тора. Бөтен организмга, үзәк нерв системасына сигнал-хәбәрләр шушы үткәргечләр аша җибәрелә, һәр күзәнәк, һәр әгъза шуннан соң гына хәрәкәткә килә. Моннан тыш, минем төп кәүсәмә 12 пар нерв җебе тоташтырылган. Болар баш миен сизү органнары, мускуллар, бизләр эшен көйли торган күзәнәкләр белән тоташтырып торалар. Ә бер пар нерв җебе исә турыдан-туры эчке органнар белән тоташтыручы ролен үти. Минең маңгай өлеше — уйлау һәм хәтер өчен, түбә өлеше — барлык хәрәкәтләр һәм сизү-тоемлау өчен, чигә — ишетү, арткы өлеше күрү өчен хезмәт итә. Я, менә хәзер әйтегез инде, дөньяда тагы кем, нинди зат шушындый төгәл, могҗизага тиң нәрсә уйлап таба ала? Кем кеше тәнендәге миллиардлаган күзәнәкне бер-берләре белән бәйләп, бер-берләренең эшенә көйләп һәм керештереп, бер-берләре белән тоташтырып, шуларның барысын бер системага буйсындырып яшәтә һәм эшләтә ала?! Бу бөек могҗизаны — баш миен ясауда кешенең үзенең бернинди катнашы юк бит, бала барлыкка килгәндә ата-аналарыгыз да мине төзүдә катнашмадылар, алар баланы инде шушылай әзер, төзелеп беткән хәлдә кабул иттеләр. Кеше үзенең миендә, канында, йөрәгендә, башка органнарында мондый бөек хезмәт — һәр мизгелдә яшәү өчен нинди зур көрәш барганлыгын белеп-аңлап та бетерми бит! Һәр күзәнәге менә шушылай Аллаһка буйсынып хәрәкәт иткән кеше үзе Раббысына буйсынамы соң? Кеше Аллаһның үзенә биргән шушы кадәр зур бүләгенә рәхмәтлеме, аны тиешенчә саклыймы, әллә һаман, наданлыгында калып, үз зарарына яшәп ятамы?

Аллаһы Тәгалә Коръәндә кат-кат тыйса да, ярамый, дип әйтсә дә, кеше һаман комсызланып хәмергә — аракыга, исерткеч, миңгерәйткеч нәрсәләргә үрелә. Аракы турыдан-туры миңа — баш миенең эшчәнлеген җимерүгә каршы юнәлтелгән. Аракы парлары минем гөрләп эшләп яткан күзәнәкләремне киптерә, корыта, үтерә. Һәр үлгән күзәнәк белән кешенең бер әгъзасына зыян килә: йөрәге, бавыры, бөере, ашказаны, бизләре начар эшли башлый һәм беркөнне бөтенләй туктап кала. Аракы нәселдәнлек күзәнәкләренең яшәү кодын җимереп ташлый, нәтиҗәдә, гарип, тиле балалар туарга мөмкин, яки кеше бөтенләй нәселсез кала. Аракы кешенең акылын ала, миен томалый, җүләрләндерә, шаштыра. Һәм боларның барысын да кеше үзе теләп эшли! Нәфесе аңа шушы эшне рәхәт, яхшы итеп күрсәтә. Нәтиҗәдә, кеше бөтен бәхетсезлегенә үзе сәбәпче була. Наркотиклар, төрле миңгерәйткеч нәрсәләр дә кеше организмына үтергеч тәэсир ясый. Япь-яшь кеше үз теләге, үз кулы белән үзен-үзе җимерә, юкка чыгара башлый. Күрәсез, бер тере күзәнәк ясый алмаган кеше дөньяда тиңе булмаган тулы бер системаны — кеше кадәр кешене, үз-үзен юк итә дә ташлый!»

Әйе: *«Аллаһу Тәгаләнең дәгъваты хак, ягъни Аның файдалы дигәне хак файдалыдыр, вә Аның зарарлы дигәне хак зарарлыдыр» («Рәгыд» сүрәсе, 14 аять).*

*«Ул — Аллаһ барча нәрсәне бар итте, һәр нәрсәне кагыйдәгә туры китереп төзеп тәмам итте. Вә Ул һәр нәрсәгә тәкъдир төзеде вә һәрнәрсәне юлга салды» («Әгъла» сүрәсе, 2—3 аятьләр).*

Әйе, кеше организмы — бик нечкә һәм бик сизгер нәрсә. Ул яшәү өчен, үз-үзен саклау өчен бөтен көчен җыеп, соң чиккәчә җитеп көрәшә. Һәр күзәнәк, һәр орган үз бурычын ахыргача үти, кеше гомере өчен ахыргача көрәшә. Монда һәрберсе үз эшен белә, соңгы сулышка хәтле шул эшне башкара. Әйтик, үпкәләр бертуктамый кешене кислород белән тәэмин итеп торалар, канны чистарту эшен башкаралар, организмнан кирәкмәгән зарарлы газларны чыгарып ташлыйлар. Кеше шулай кушканга тырышып эшлиләрме алар? Юк, үпкәләр дә, Аллаһның әмерен үтәп, кешегә хезмәт итәләр. Ашказаны һәм ашказаны бизләре кергән ризыкны химик яктан эшкәртә, кайната, организм буйлап хәрәкәт итәрлек хәлгә китерә. Әйтик, ашказаны бизләре, махсус сыекча бүлеп чыгарып, ризык белән кергән углеводларны, аксымны, майларны эретә, тарката, бары тик шуннан соң гына майлы ризык организм тарафыннан үзләштерелә ала. Бөерләргә исә организмда булган зарарлы матдәләрне, артык тозны һәм суны бүлеп чыгару бурычы йөкләтелгән. Эчке секреция бизләре бүлеп чыгара торган гормоннар исә, гомумән, могҗизага тиң — алар организмның бөтен тереклек эшчәнлегенә тәэсир итәләр. Бу күзгә күренмәгән гормоннар шулхәтле үзара килешеп эшлиләр ки, организмда берсе көчәеп киткәндә, икенчесе сүлпәнәебрәк тора. Әйтик, организмда шикәр артса, аны азайта торган механизм хәрәкәткә килә, кан басымы түбәнәйсә, икенче бер сакчы гормоннар аны күтәрү һәм тигезләтү өчен эшкә керешәләр. Без моны җиңел генә: «Организм авыру белән үзе көрәшә»,— дибез. Организмга бу «үзе көрәшә алу» сәләте каян килгән соң? Әйе, Раббыбыз Аллаһ кешене барлыкка китергәндә, аның организмына авыруларны төзәтә торган механизмын да куеп калдырган. Кешенең үз организмында килеп чыккан җитешсезлекләрне төзәтеп, зыянлы үзгәрешләрне уңай якка көйләп торучы күзгә күренмәс күзәнәкләр, гормоннар, бизләр, тагы әллә нинди көчләр бар. Әгәр тышкы яктан зыян бик зур булмаса, кеше картайганчы авырмыйча яшәргә дә мөмкин, моның мисаллары тормышта шактый. Шулай ук тышкы тирәлектә дә кешенең барлык авыруларына да дәва бар, кеше бары тик аларны белеп кенә бетерми әле. Аллаһы Тәгалә кешене җирдә бәла-казалары белән ялгыз калдырырга теләмәгән, кешенең үз эчендә һәм тышта һәр авыруга дәвасын да әзерләп куйган. Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам: «Картлыктан кала, барлык авыруларга да дәва бар»,— дип әйтеп калдырган. Ягъни менә бу безне чорнап алган үсемлекләрдә, ризыкларда, җәнлекләрдә, җирдә һәм суда — бөтен тирәюньдә безнең барлык авыруларыбызга да дәва бар. Аларны бары тик өйрәнеп, белеп файдаланырга гына кирәк. Әмма, ни кызганыч, кеше үзен чорнап алган табигатьнең мондый яшерен серләрен бик аз белә шул. Ул гына да түгел, кеше табигатьнең бушка бирелгән бу биниһая байлыгын бөтенләй санламый, кадерен белми! Кеше көне-төне табигатьне бетерә, табигатьне агулый, шулай итеп, үзе сулыйсы һаваны, эчәр суларын, ашар ризыгын агулый, ягъни үз-үзен, үз тормышын агулый. Кешенең күп кенә авырулары — үзенең башсызлыгы, акылсызлыгы, имансызлыгы аркасында килеп чыккан авырулар алар. Кеше акылы атом һәм водород бомбаларын уйлап тапты, бөтен дөньяга радиация таратып, кешене аягүрә черетә торган кораллар булдырды, бөтен дөньяның башына җитәрлек химик һәм бактериологик кораллар уйлап тапты! Нигә, ни өчен! Болар барысы да кешегә каршы юнәлтелгән бит! Аллаһның иң гүзәл, иң кадерле затына —адәм баласына каршы юнәлтелгән! Сәгать механизмы кебек эшләп яткан күзәнәкләр, безне бәхетле итү өчен көне-төне типкән йөрәгебез, кешелек галәменең төп компьютеры булган баш миебез һәм, ниһаять, без үзебез кеше үзе үк уйлап тапкан шушы коточкыч кораллар ярдәмендә бер мизгел эчендә эреп, кайнап, янып юкка чыгарга мөмкинбез! Ни өчен?! Бер тере күзәнәк уйлап чыгарырга башы җитмәгән адәм баласы, әнә шулай итеп, бөтен кешелекнең башына җитәргә мөмкин! Уйлагыз, балалар! Сез бу кешеләр кебек булмагыз! Сүз сезнең гомер, сезнең тормыш, сезнең киләчәк, җир язмышы турында бара бит! Дөньяда нәрсә генә уйлап табылса да, ул кешегә, табигатькә каршы юнәлдерелгән булырга тиеш түгел. Аллаһы Тәгалә безгә бу акылны, тәнебезне һәм җаныбызны җимерү өчен түгел, дөньяны яшәтү өчен әманәт итеп биргән. Һәм шуны беркайчан да онытмагыз: кеше беркайчан да үзен барлыкка китергән Аллаһы Тәгаләгә каршы китәргә тиеш түгел!

*«Юк, Без кеше өчен никадәрле мәрхәмәтле һәм юмарт булсак та, кеше без куйган чиктән үтәдер, аннары азып адашадыр. Үзен Аллаһуга мохтаҗ түгел дип белеп» («Галәк» сүрәсе, 6—7 аятьләр).*

Кеше төзелеше турында сүзебезне тәмамлаганда, бер шактый четерекле мәсьәләгә дә кагылмый үтеп булмый. Ул — кешенең килеп чыгышы, тагы да төгәлрәк әйтсәк, ана карынындагы баланың яралуы турындагы мәсьәлә. Беренче кеше — Адәм галәйһиссәлам турында без әле алдагы бүлекләрдә киңрәк тукталырбыз. Хәзергә шуны әйтеп үтәбез: беренче кеше Адәм галәйһиссәламне Аллаһы Тәгалә Үзе барлыкка китергән, аның тәнен төзегендә, туфракта булган матдәләрне кулланган, кешегә җан һәм

аң биргән. Адәм галләйһиссәлам башта җәннәттә (күктә) яшәгән, аннан Һава анабыз белән бергә җиргә төшерелгән…

Монысы — беренче кешеләр турында Коръәннән мәгълүматлар. Сүзебез бераз башкарак нәрсә — адәм балаларының ничек нәсел калдыруы турында иде. Тагы да төгәлрәк әйтсәк, баланың ана карынындагы хәле-халәте турында иде. Балалар өчен хезмәттә бу хакта бик җентекләп язып та булмый, әмма анатомия дәресләрендә баланың яралуы турында укытылганга күрә, без дә бу темага бераз кагылып үтәргә булдык. Чөнки Коръәндә баланың яралуы, ана карынындагы хәле турында бик төгәл мәгълүматлар бар, мәктәп укучылары ул хакта да белергә тиешләр дип уйлыйм.

Коръәндә кешенең туфрактан яратылуы турында әйтелгән, шул ук вакытта бар тереклек иясенең судан чыгарылуы турында хәбәрләр дә бар. «Болар бер-берсенә каршы килмиме соң?» — дип тә сорарсыз. Юк, балалар, киресенчә, бу мәгълүматлар бер-берләрен тулыландыралар гына. Чөнки соңыннан ит һәм сөяк кунасы кеше яралгысы башта сыекча хәлендә була, ягъни бар тереклек иясе, шул исәптән кеше дә, сыекча (сперма) ярдәмендә үрчи (орлыклана). Икенчедән, ана карынындагы бала, чыннан да, махсус сыекча — су эчендә ята. Өченчедән, кеше үзе дә 80 процент судан тора. Шуңа күрә кешенең судан (сыекчадан) чыгуы безне гаҗәпләндерергә тиеш түгел. Хәзер бу хакта Коръәндә ниләр әйтелгәнен карыйк:

*«Ий кешеләр, әгәр каберләрдән терелеп кубарылудан шикләнсәгез, фикерләп карагыз: төп атагыз Адәмне балчыктан бар иттек, соңра нәселегезне үрчетер өчен мәни суыннан, соңра ул суны оешкан кан кылдык, соңра ул канны ит кисәге кылдык, кирәк — ул сурәтләнгән булсын, кирәк — сурәтләнмәгән булсын, шул эшебез белән сезгә кодрәтебезне белдерер өчен. Вә аналар карынында үзебез теләгәнчә билгеле вакыт тотабыз, соңра бала булганыгыз хәлдә чыгарабыз, соңра камил гакылга вә куәткә ирештерәбез» («Хаҗ» сүрәсе, 5 аять).*

*«Без Адәмне саф балчыктан яраттык. Соңра Адәмнең нәселен ана карынында мәни кылдык. Соңра мәнине каты кан итеп яраттык, соңра ул каты канны чәйнәлгән ит кеби кылдык, соңра ул итне сөяк иттек, соңра ул сөяккә ит кидердек, соңра аны икенче төрле иттек, ягъни аңа җан бирдек, барлыкка китерүче Аллаһ олуг» («Мөэминнәр» сүрәсе, 12—14 аятьләр).*

*«Әйә кеше белмиме, Безнең аны бер тамчы судан бар иткәнебезне, шуның соңында ул зәгыйфь кеше Безнең белән каты каршылашамы, үтергәнебездән соң аны яңадан тергезергә кадир икәнлегебезне инкяр итәме?» («Йәсин» сүрәсе, 77 аять.)*

Күрәсез, кешенең ничек яралуы турында Коръәндә бик ачык итеп әйтелгән, бу яралгының нинди периодта нинди хәлдә булуы да җентекләп тасвирланган. Укый-яза белмәгән Мөхәммәт галәйһиссәлам үзлегеннән шушы хәтле тулы медицина мәгълүматы бирә алыр идеме? Юк, әлбәттә юк! Бу хәбәрләр аңа барысы да Аллаһтан килә. Ул чактагы кешеләр, хәтта борынгы антик галимнәр дә бала яралгысы турында бөтенләй хәбәрсез булалар. Бары тик XVII гасырда гына, микроскоп уйлап тапкач кына, ана карынындагы бала яралгысы, аның барлыкка килүендә сперманың роле турында беренче мәгълүматлар алалар. Әмма әле алар да тулы булмый, чөнки монда әле сүз бары тик ир-атның күзәнәкләре турында гына бара. Һәм бары тик 1973 елда гына О'Рахилли исемле галим эмбрионнар турындагы барлык мәгълүматларны тулы системага сала һәм аларның Коръәндә язылганнар белән тәңгәл килүе күренә. Әлбәттә, бу — могҗиза, без гыйбрәт алырга тиешле хәбәр. Дөнья галимнәрен, бигрәк тә медикларны, эмбрионнар турында Коръәндәге хәбәрләр нык тетрәндерә, һәм алар бу хакта зур фәнни хезмәтләр язалар, кайберләре хәтта ислам динен дә кабул итә. Бу хакта без сезгә француз галиме Морис Букельнең «Коран и современная наука» (Казан, 1993), К.Мур, А.М.Зиндани, М.Ахметның «Коран и современная наука. Сравнительное исследование» (Москва, 1994) дигән хезмәтләрен укырга тәкъдим итәр идек. Аларда кеше яралгысының ана карынындагы үсеше, хәле бик җентекле язылган, бүгенге фәнни мәгълүматлар Коръән аятьләре белән чагыштырып өйрәнелгән. Бу мәгълүматлар Коръән аятьләренең хаклыгын тулысынча раслый, кире каккысыз дәлилләр белән дәлилли.

Коръәндә бала яралгысы, аның ана карынында урнашуы турында тагы бер тетрәндергеч хәбәр бар, ул — туачак баланың өч кат караңгылык — пәрдә артында ятуы турында хәбәр. Бүгенге фән дә туачак баланың өч кат чолганышта, капланышта ятуын раслады. Беренче кат — ананың корсак тиресе, икенче кат пәрдә — аналык, өченчесе — бала яткан соңгылык урыны. Менә хәзер бу хакта Коръәннән хәбәр тыңлагыз:

*«Ул сезне бер Адәмнән яратты, соңра Адәмнең хатыны Һаваны бар итте вә сезне аналарыгыз корсагында бертөрле сурәттә яратканнан соң, икенче сурәткә кертәдер, башта су идегез, кан булдыгыз, соңра ит кисәге булдыгыз, соңра кеше сурәтенә кердегез. Анагызның эчендә өч кат караңгылыкта бар ителәсез: баланың пәрдәсе, бала ятак урын һәм ананың корсагыдыр. Әнә шулай һәрнәрсәне халикъ итүче Аллаһ сезнең Раббыгыздыр, һәрнәрсәгә патшалык Аның кулындадыр, Алла-*

*һудан башка Илаһә юк, мәгәр Аллаһ Үзе генәдер, Аллаһуга гыйбадәт кылмыйча кемгә гыйбадәт кылырсыз?» («Зүмәра» сүрәсе, 6 аять.)*

Инде шушы хәтле ачык могҗиза-хәбәрләрдән соң да, Аллаһка гыйбадәт кылмыйча, кемгә гыйбадәт кылырга?! Аллаһка, бары тик Аллаһка гына!

## ҖАН АВАЗЫ

Кеше аңнан, тәннән һәм җаннан тора, дидек. Тәнебез җирдән бар ителгән, аның җирдәге ризыклар хисабына яшәгәнен күрдек. Аңыбыз — акылыбыз һәм хәтеребез, алган белемнәребез һәм тормыш тәҗрибәбез икәнен белдек. Ә җан нәрсә соң? Аның матди, ягъни җисми түгел икәнен беләбез, аны тән кебек тотып карап та, капшап та, күреп тә булмый. Шуңа карамастан без барыбер җан дигән серле нәрсә барына ышанабыз. Ана карынындагы балага, хәрәкәтләнә башлауга: «Җан керде»,— дип сөйлибез. Кеше үлгәч, җаны чыкты, дибез. «Җаным әрни», «җаны тыныч түгел» яки «җаным тыныч» дип тә әйтәбез. Нәрсә соң ул — җан? Күзгә күренмәгән, әмма авырта, хәсрәтләнә, борчыла яки сөенә-тынычлана алган нинди орган соң ул кеше тәнендә? Кай җиребездә урнашкан икән ул безнең, нинди тәртип һәм кануннарга буйсынып яши икән ул? Нинди син, нәрсә син, кайда син, кеше җаны?..

Кешенең тәне җирдән килгән, җаны исә күктән иңгән…

Тән — туфрактан, җан нурдан тора…

Кеше җанында Аллаһның нуры бар…

Кешегә җан Аллаһтан иңгән…

Әйе, кешегә җан Аллаһтан иңгән! Әле кеше дөньяга килгәнче үк, аның булачак җаны Аллаһ алдында ант бирә. Бу хакта Коръәндә хәбәр бар. Әле тәнгә кергәнче үк, җан бары бер Аллаһка гына буйсынырга ант бирә. Һәм Аллаһы Тәгалә, безгә бу хакта искә төшереп, менә нәрсә ди:

*«Аллаһуның сезгә биргән нигъмәтләрен хәтерләгез! Һәм дөньяга килмәс борын Аллаһуга биргән гаһедегезне (антыгызны) да хәтерләгез! Аллаһ рухларны (җаннарны) бар иткәч: «Сезне юктан бар кылып тәрбияләүче мин түгелме?» — дигәч, «Әлбәттә, Син! Сүзеңне ишеттек, үзеңә буйсындык»,— дидегез, шуны белегез! Аллаһудан куркыгыз, Аңа гасый булудан сакланыгыз! Күкрәкләрдә булган нәрсәне Аллаһ, әлбәттә, белүче» («Маидә» сүрәсе, 7 аять).*

Димәк, кешенең җаны тәненә караганда алданрак барлыкка килгән, ул күктән иңеп, ана карынындагы әзер тән формасына кергән. Кеше үлгәч тә, аның җаны юкка чыкмый — ул яңадан күккә аша һәм кыямәт көненә хәтле үз тәненә яңадан керүне көтеп тора. Аллаһ алдында да беренче булып үлгәч җан җавап тота. Әйткәнебезчә, кешегә җан ана карынындагы бала яралгысы 4,5 ай вакытта керә. Бүгенге фәннән билгеле булганча, бу вакытта баланың йөрәге тибә башлый һәм ул ана карынында беренче хәрәкәтләрен ясый. Димәк, җан төшенчәсе йөрәк белән, аның эшләп китүе белән дә бәйләнгән икән. Диннән белгәнебезчә, балага җанны күзгә күренмәгән фәрештәләр алып килә, ягъни ана карынындагы баланың йөрәге күктән килгән затлар ярдәмендә генә эшләп китә ала. Димәк, бары тик Аллаһның әмере белән генә ана карынындагы кеше яши башлый: җан иңү белән, кан әйләнеше хәрәкәткә килә, үпкә-бавырлар эшли башлый, баш мие үз эшенә керешә, бизләр, күзәнәкләр, гормоннар һәрберсе үз функциясен башкарырга тотына. Ягъни шушы мизгелдән кеше яши башлый. Күктән иңгән фәрештәләр, җан белән бергә, кешегә аның язмышы язылган программаны да тапшыралар, яшәү кодын билгелиләр. Ягъни кешенең холкы, нинди авыруларга һәм бәхетсезлекләргә дучар буласы, кыласы гамәлләре, җыясы ризыклары, кайда һәм кайчан, нилектән үләсе — барысы да шушы тәкъдир программасына салынган була. Бу хакта пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәламнең әйтеп калдырган хәдисе дә бар. Бүгенге фән дә моның шулай икәнлеген раслады: кеше геннарында нәселдәнлек программасы да, нәсел буенча күчүче авырулар турында мәгълүмат та, кешенең холкы-фигыле турында хәбәр дә, шушы холкы һәм нәсел чирләре аркасында нинди хәлләргә калырга мөмкинлеге турында кисәтү-информация дә — барысы да бар икән. Менә бу урында да дин белән фән очраштылар, дөресрәге, Ислам дине моннан 1400 ел элек әйткәннәрне бүгенге фән дә расларга мәҗбүр булды. Хәер, моңа гаҗәпләнергә дә кирәкми, бүгенге галимнәргә дә акылны, гыйлемне Аллаһы Тәгалә бирә бит, Аның ирегe булмаса, бу ачышлар ясалыр идеме? Болар бит барысы да без гыйбрәтләнсен, иманга килсен өчен эшләнгән эшләр…

Тагы җан турында сөйләүгә кайтыйк әле. Дөрес, Коръәндә җан, рух турында хәбәрләр шактый аз, чөнки бу бик нечкә һәм яшерен нәрсә. Хакыйкый гыйлемең булмаган килеш җан турында уйлана, эзләнә башласаң, бик тиз адашырга, саташырга да мөмкин. Шуңа күрә без дә Аллаһ күрсәткән чикләрдән узмыйча, дин буенча үзебез белгәннәрне укучыларга җиткерергә булдык. Әйе, җан ул күзгә күренми, әмма сизелә. Ул кеше белән идарә итә. Материя-тән телсез, ул җан телгә китерсә генә хәбәр

бирә. Җан элементы кайвакытта үзен төштә нык сиздерә. Игътибар итегез: күз күрми, йомык, әмма кеше төшендә үз-үзен читтән күрә. Бу — күңел күзе, җан шулай хәбәр бирә. Кайвакытта алда булачак хәлләрне төштә күрүчеләр дә бар. Вакыт пәрдәсен ертып, кем киләчәкне төсмерләде? Аллаһ ярдәме белән, моны җан эшләде. Йокы вакытында җанны чыгып тора дигән фаразлар да бар, әмма бу вакытта да җанның тән белән элемтәсе өзелми, чөнки йөрәк эшләп тора. Клиник үлем, ягъни кисәк үлем вакытында йөрәк туктый, кешенең җаны үз-үзен читтән күрә, әмма Аллаһтан үләргә вакыт җитмәгән икән, җан тәнгә кире керә. Клиник үлем вакытында кешеләр югарыдан үз гәүдәләрен үзләре күрә, бу — җанның күзәтүләре, карашы… Ходаның хикмәтләре әйтеп-аңлатып бетергесез шул…

Җан — Аллаһтан бирелгән илаһи энергия, әйткәнебезчә, кеше шушы көч ярдәмендә яши башлый, ул беткәч, яшәүдән туктый. Җанның кайда урнашуын без әйтә алмыйбыз, кешегә андый гыйлем бирелмәгән. Әмма җанның йөрәк-кальб белән бәйле булуын әйтергә мөмкин. Электр тогын беркем тотып карый алмаган кебек, җанны да тотып карап булмый, ягъни ул җисми түгел. Җанның газ, һава хәлендә яки нур кебек булуы ихтимал. Әмма шул ук вакытта аны хис, уйлар дөньясы белән дә бутарга ярамый, болары *күңел* дигән төшенчәгә керә. Күңел дөньясы белән кеше үзе идарә итә, җан исә, күргәнебезчә, үзе кеше гомере белән идарә итә икән. Ул инде *бар булуы* белән кешене яшәтә, электр чыбыгыннан чапкан ут кебек, кешенең йөрәген типтереп, канын хәрәкәтләндереп, бөтен органнарын эшләтеп, тотып тора. Җан булганда кеше яши, һәм көннәрдән бер көнне Аллаһтан бирелгән бу җанны яңадан Аллаһка кайтарыр вакыт җитә. Тәкъдирдә күрсәтелгән сәгатьтә күктән җан алу фәрештәләре иңә…

*«Ул — Аллаһ коллары өстеннән кадир вә сезгә сакчы фәрештәләрен күндерер, алар сезнең гамәлегезне язарлар. Инде берегезгә үлем килсә, без күндергән фәрештәләр аның рухын алырга килгәч, һич миһләт бирелмәс, күз йомып ачарга вакыт калмас» («Әнгам» сүрәсе, 61 аять).*

*«Әгәр үлемгә хәзерләнгән кешенең җаны бугазына җитсә, сез шул вакытта аңа карап сорарсыз. Ул кешенең хәлен белү өчен сезгә караганда Без белем вә кодрәтебез белән аңа якынракбыз, ләкин ул кешегә килгән хәлне сез белмисез һәм күрмисез» («Вакыйга» сүрәсе, 83, 84, 85 аятьләр).*

Әйе, без кешенең җаны ничек чыкканын белмибез. Моны үлеп яткан кеше үзе генә белә ала, әмма үлгәннән соң ул инде моны аңлата алмый, соңгы мизгелдәге бар кичерешләре үзе белән китә. Аллаһы Тәгалә Коръәндә: *«Ул кешегә килгән хәлне сез белмисез һәм күрмисез»,*— ди. Ягъни үлемнең читтән карап торучыларга күренмәслек булып килүенә ишарә ясый. Бередә сүз кеше күзенә күренми торган затлар —фәрештәләр турында бара. Кешенең җанын алу Газраил фәрештәгә йөкләнгән. Аңа башка фәрештәләр дә булыша. Бу җан-энергия бөтен гәүдәдән суырылып килеп, аяк очыннан югарыга таба чыгуга бара. Җан ташлап чыккан урында тән инде суына, сүнә бара. Аллаһка буйсынып яшәгән кешенең җанын ярдәмче фәрештәләр бик иплә п, кызганып, авырттырмыйча гына алырга тырышырлар, ә динсез, имансыз кеше бу мизгелдә зур газаплар кичерер. Мөэминнең җаны савыттан аккан су кебек чыгар, кяфернең җаны чәнечке кебек суырылып чыгарылыр. Кеше, үлем белән күзгә-күз очрашкач, барысын да аңлар, җан алырга килгән фәрештәләрне дә үз күзләре белән күрер, менә шунда инде Аллаһның барлыгына да ышаныр, Аллаһка буйсынмыйча яшәп, үзенең ни дәрәҗәдә ялгышканлыгын аңлар, әмма дөньяга кире кайтып, Аллаһ кушканча яшәргә инде соң булыр. Үлемне күргәч кенә тәүбәгә килү кабул ителмәс… Начар кешенең җаны күктә дә үзенә тынгылык тапмас, җиргә дә яңадан кайта алмас, ул тетрәп кыямәт көнен — Аллаһ каршында җавап бирү көнен көтәр… Ул көнне бөтен дөнья башка үлчәнешкә, башка яшәешкә күчәр: берәүләр, бу дөньяда Аллаһ кушканча яшәүчеләр, мәңгелек бәхеткә — җәннәткә юл алыр. Икенчеләр, бу дөньяда Аллаһны онытып, нәфес колы булучылар, утлы җәһәннәмгә куылырлар… Бу нәкъ шулай булачак! Чөнки моны бөтен галәмнәрне барлыкка китерүче Аллаһы Тәгалә вәгъдә итә:

*«Әлбәттә, бу хәлдән икенче хәлгә күчәрсез! Ягъни үләрсез, аннары терелерсез, аннан хөкем ителеп тиешле җәзаны алырсыз» («Инфәтар» сүрәсе, 19 аять).*

*«Иман китереп изге гамәлләр кылган кешеләр, әлбәттә, җәннәттә төрле нигъмәтләр эчендәдер. Вә Аллаһуга итагать итмәгән азгыннар, әлбәттә, җәһәннәмдәләр» («Инфәтар» сүрәсе, 13—14 аятьләр).*

Димәк, үлдем дә котылдым гына түгел икән. Җир йөзендә яшәгән һәр көнебезгә, эшләгән һәр эшебезгә, әйткән һәр сүзебезгә, уйлаган һәр уебызга без Аллаһ каршына басып җавап бирәчәкбез. Безнең һәр әгъзабыз — миебез, йөрәгебез, телебез, күзләребез, колакларыбыз, аяк-кулларыбыз — барысы-барысы да аерым-аерым җавап тотачаклар. Хәер, кешенең бу дөньяда эшләгән барлык эшләре дә җиһан компьютерында язылып баруын без беләбез бит инде. Кеше күк эфирына бу хәбәрләрне үзе җибәреп тора, ягъни аның ике ягындагы ике фәрештәсе, җир белән күк арасындагы үткәргеч-антенналар кебек, кешенең бөтен кылган гамәлләрен язып һәм күккә тапшырып баралар. Көне-төне, гомер буе, һәр минутта, һәр сәгатьтә… Менә шушыны беркайчан да онытырга ярамый, балалар! Без

Аллаһның мәңгелек күзәтүе астында. Җавап та кылган гамәлләребезгә карата булачак. Соңыннан гына берни арттырып яки берни киметеп булмаячак. Шуңа күрә яхшылыкны исән чакта, бүген күбрәк эшлик, начарлыктан исән чакта, бүген тыелыйк…

Кеше җир йөзендә йөргәндә, болар турында уйлап бетерми шул. Мондый хәлләрнең була аласына, бөтенләй икенче төрле халәткә, галәм үлчәнешенә, икенче төрле тормыш яссылыгына күчә алуына ышанып бетми. Ә нәкъ шулай булачак бит!

*«Әлбәттә, бу хәлдән икенче хәлгә күчәрсез!»*

Моны безгә Аллаһы Тәгалә вәгъдә итә. Ә бу хәлләргә ышанмаска, үзең теләгәнчә яшәргә кешене нәфес-шайтаны котырта…

Җан турында сөйләвебезне шушы урында туктатып торып, без кешенең күңел дөньясы, хис-эмоцияләре, нәфес-теләкләре турында да бераз сөйләп китәрбез. Болар да — күзгә күренми торган, тотып карап булмый торган, әмма вакыты-вакыты белән кешенең акылын үзенә буйсындыра торган нәрсәләр. Менә шушы чуар, четерекле, тетрәп-тибрәлеп торган дөньяны — күңел дөньясын ничек тәртиптә тотарга соң? Коръән бу хакта нәрсәләр әйтә? Үз күңелен тыя алмаган кешеләрне тормышта ниләр көтеп тора? Хәзер, әйдәгез, бергәләп шулар хакында сөйләшик…

## КҮҢЕЛ ДӨНЬЯҢДА НИЛӘР БАР?

Безнең халыкта: «Кеше күңеле — кара урман» дигән әйтем бар. Адаштыргыч калын кара урманда нәрсәләр яшеренгәнен белеп булмаган кебек, кеше күңелендә ниләр барын да белеп бетереп булмый. Хис-давыллардан, сагыш-әрнүләрдән, шатлык-бәхетләрдән торган ул дөнья чоңгыл кебек төпсез дә, күкләр кебек биек тә, дәрья кебек киң дә булырга мөмкин… Менә шушы күзгә күренми торган, үтә яшерен, үтә серле, бернигә буйсынырга теләмәгән дөньяны ничек тәртиптә тотарга соң? Чөнки күңелдә тәртип юк икән, кешенең тормышында да тәртип юк, күңел азгын икән, кеше үзе дә бозык юлда йөри, күңеле каты, рәхимсез икән, кеше җинаятькә, явызлыкка да барырга мөмкин. Димәк, кеше үз-үзен, тәнен, тормышын тәртиптә тотар өчен, иң башлап күңелен төзәтергә, тәртипкә салырга, аның белән идарә итәргә өйрәнергә тиеш икән. Кеше күңеле турында изге китабыбыз Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә ни әйтә соң?

*«Без кешегә аның нәфесе (күңеле) нәрсә вәсвәсә кылганын (котыртканын) яхшы беләбез, Без кешегә аның муен тамырыннан якынрак торабыз» («Каф» сүрәсе, 16 аять).*

*«Күңелләрегездә булган теләкләрегезне кирәк — яшерегез, кирәк — белдерегез, Аллаһ аны беләдер һәм җир, күкләрдә булган нәрсәләрне дә белә. Аллаһ һәрнәрсәгә кадир» («Гыйmран» сүрәсе, 29 аять).*

*«Күңелләрегездәге яман уйларыгызны яшерсәгез дә, яшермәсәгез дә, уйларыгыз белән Аллаһ сезне хөкем итәр» («Бәкара» сүрәсе, 284 аять).*

Ягъни яман уйларны әле кешеләрдән яшерергә мөмкин, кеше үз-үзен алдап, начарны яхшы дип ышандырып йөри ала, әмма Аллаһы Тәгаләне алдап та, Аннан берни яшереп тә булмый. Ул безнең күңел дөньябызны ничек бар, шулай итеп күрә һәм хөкеме дә күңелләребезгә карата булачак. Кеше тән дигән кабыгында нинди генә яшерен уйлар, азгын теләкләр белән янса да, күңеленнән нинди генә бозыклыкларга кереп батса да, Аллаһ аларны күреп тора һәм кисәтә:

*«Нәфес явызлыкка өнди. Нәфес өндәгән явыз эшләрдән котылыр Аллаһ рәхмәт кылган кешеләр генә» («Йосыф» сүрәсе, 53 аять).*

*«Коръән хөкеменә ияреrгә теләмәгән җаһил кешеләрнең нәфес һаваларына (күңелләренә), аларның ялган гамәлләренә иярмә! Аллаһ иңдергән хөкемнәрнең кайберләреннән сине дүндерүләреннән, адаштыруларыннан саклан!» («Маидә» сүрәсе, 49 аять.)*

Аллаһы Тәгаләгә бик нык ышанган кеше һәрвакыт Аның күзәтүе астында булуын яхшы аңлый. Начар уйлары өчен Аллаһтан курку һәм оялу кешене үз-үзен һәрвакыт контрольдә тотарга, күңелен кирәкмәс уйлардан һәм теләкләрдән тыеп-йөгәнләп тотарга өйрәтә. Әлбәттә, күңелеңне тәртиптә тоту өчен беренче шарт — Аллаһ хөкемнәренә буйсыну, Аллаһ кушканча яшәү яки шуңа омтылу. Күңелеңне дә үз теләкләреңә түгел, Аллаһның әмерләренә буйсындыру. Кеше күңеле нинди булырга тиеш соң? Коръәндә кеше күңеле, күңел ярдәмендә формалашкан холык-фигыль, кешедәге начар һәм яхшы сыйфатлар турында аятьләр бик күп, адәм баласының хәсрәткә төшү яки иминлеккә ирешү юллары да ачык күрсәтелгән. Коръән ул — яхшы белән начарны *аерып* күрсәтә торган китап, анда Аллаһы Тәгаләнең тыйганнары һәм кушкан әмерләре тупланган. Болар барысы да кеше өчен билгеләнгән. Кеше үз күңелен тәртипкә салуны да яхшы белән начарны аерудан башларга тиеш. Ул Аллаһы Тәгаләнең кеше өчен нәрсәләрне тыюын, ә нәрсәләрне эшләүне мәҗбүри шарт итеп куюын аңларга тиеш. Кешене Аллаһы Тәгалә барлыкка китерүен таныйбыз икән, без Аның үзебез өчен билгеләгән яшәү тәртибен дә танырга, аны кабул итәргә һәм шуңа буйсынырга тиешбез. Бу безнең

үзебез өчен кирәк. Аллаһка буйсынган кеше үзенең аңына, тәненә һәм җанына, күңеленә зыян китерерлек бернәрсә дә эшләргә тиеш түгел. Аллаһка буйсынган кеше башкаларга да зыян салырга тиеш түгел. Аллаһка буйсынган кеше үзенә дә, башкаларга да бары тик яхшылык кына тели, үзен дә, башкаларны да саклап калу өчен тырыша. Ул теле белән дә, кулы белән дә, эш-гамәлләре белән дә кешегә зыян салмый. Үзеңә һәм башкаларга, тереклек дөньясына зыян салу ул — зур начарлык, Аллаһ билгеләгән тәртипкә буйсынмау. Ә мондый буйсынмау өчен адәм баласына Аллаһ тарафыннан каты җәза каралган. Кеше моны беркайчан да хәтереннән чыгарырга тиеш түгел.

Алдагы сәхифәләребездә без дөньяны Аллаһы Тәгалә барлыкка китерүе турында сөйләгән идек инде. Бар дөньяның, шул исәптән кешенең дә Аллаһка буйсынып яшәргә көйләнгән булуы турында мисаллар белән аңлаткан идек, кешенең үз тән төзелеше аша күрсәтеп тасвирлаган идек. Әмма тәне һәм җаны Аллаһка буйсындырылып яратылган кеше күп очракта күңеле белән башка нәрсәләргә табына, башка нәрсәләргә буйсына, алардан курка, алардан ярдәм өмет итә. Менә шуннан инде бар буталу, саташу, тәртипсезлекләр һәм бәхетсезлек китә. Кеше күп очракта үзе кебек үк адашканнар уйлап тапкан узгынчы һәм саташтыргыч идеяләрнең колы була, бәндәгә, елга-тауларга, кояш-йолдызларга табына башлый, Алладан түгел, шул мәхлуклардан ярдәм көтә. Ул үзе үк «тудырган», уйлап тапкан шушы ясалма дөньяда яши башлый, гомерен һаман нидер эзләп, тынычсызланып уздыра. Ул бу дөньяда нәрсә өчен яшәвенә дөрес җавап таба алмый, яшәвенең, тормышының максатын ачыклый алмый. Шуннан күңелендә үз тормышыннан канәгатьсезлек килеп туа, кеше бу дөньяда алданганлыгын сизенә башлый, шул караңгы бушлыкны тутыру өчен аракыга, наркотикларга үрелә, явызлана, дөньяга начарлык, бозыклык тарата башлый, үзе артыннан упкынга башкаларны да өстери. Нәтиҗәдә, кеше адаша һәм харап була.

*«Алар, Аллаһ биргән белемне хак юлга кулланмыйча, һәлак булдылар» («Ганкәбут» сүрәсе, 38 аять).*

*«Ий мөэминнәр, сезгә ирешкән бәла-казалар вә кайгылар — үзегез кәсеп иткән гөнаһларыгыз сәбәпледер, шулай булса да Аллаһ гөнаһларыгызның күбрәген гафу итәдер» («Шура» сүрәсе, 30 аять).*

Без барыбыз да бәхетле булырга телибез. Барыбызның да байлыкта, саулыкта, кадер-хөрмәттә яшисе килә. Әмма күпләребез тормышын кайгы-хәсрәттә, бәхетсезлектә, җан тынычсызлыгында үткәрә. Кеше үз бәхетсезлегенә үзе төшә, үзе сәбәпче була, дидек. Бәхетле булу өчен нишләргә соң? Әлбәттә, үз күңелебезне, үз холкыбызны тәртипкә китерүдән башларга кирәк. Күңеле тәртипленең тормышы да тәртипле булачак, үз тормышы төзек кеше ил тормышын төзекләндерү өчен дә тырышачак. Күңелебезне тәртипкә салуны нидән башлыйк соң? Үзебездәге нинди начар сыйфатлардан арынырга тырышыйк, нинди яхшы якларыбызны үстерик, көчәйтик? Әйдәгез, бергәләп шул хакта уйлыйк әле…

Кешене кеше иткән, хөрмәт ияләренең берсенә әйләндергән сыйфат, ул — әлбәттә, иман. Гаделлек — иманның билгесе. Тугры, дөрес сүзле, дөрес гамәлле, гадел кешене хөрмәт итәләр, аның белән киңәш тоталар, сүзенә колак салалар. Дөрес, гадел кешеләр өчен дә авыр булган заманнар бар, чөнки залим патшаларга, тираннарга, азгын-бозык адәмнәргә беркайчан да дөреслекне әйтүчеләр кирәк булмаган. Ләкин дөреслекне әйтүчеләр, гаделлек өчен көрәшүчеләр халыкка кирәк, хаклык өчен кирәк! Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам әйтеп калдырганча, залим патшаларга каршы әйтелгән хак сүз ул —Аллаһ юлында көрәш, гаделлек урнаштыру өчен алып барган көрәш. Пәйгамбәребезнең: «Әгәр бер халыкта начарлыктан тыючылар бетсә, Аллаһ ул халыкны мәрхәмәтеннән кисәчәк»,— дип әйтеп калдырган сүзләре дә бар. Ягъни әгәр бер милләттә дөреслекне әйтүчеләр бетә икән, милләт бозыклыкка, ялганга, җинаятьләргә кереп батарга мөмкин. Аллаһ мондый халыкны инде коткармаячак. Ягъни мондый бозык халыкның бетүе хәерле икән. Шуңа күрә гаделлек, гадел булу, үзең дә дөрес яшәп, башкаларны да шуңа өндәү кеше булып, милләт булып яшәүнең нигезендә ятарга тиеш. Әгәр бүген татар татарны рәнҗетеп, татар татарны алдап, бер кеше икенчесе хисабына яшәргә тырыша икән — бу зур гаделсезлек. Аллаһ мондый эшне яратмый һәм кисәтә:

*«Ий мөэминнәр! Гаһедләрегезне (антларыгызны) Аллаһ ризалыгы өчен үтәгәнегез хәлдә, һәрвакыт гаделлектә булыгыз, бу гаделлек гәрчә үзегезнең, ата-анагызның һәм якын кардәшләрегезнең зарарына булса да, дөрес шаһәдәт бирегез! Сез шаһәдәт биргән кешеләр кирәк — бай, кирәк ярлы булсыннар, дөрес шаһәдәт бирегез, байга да, ярлыга да сезгә караганда Аллаһ артыктыр. Хактан үтеп китмәк өчен нәфескә иярмәгез! Әгәр шаһитлар яки вәкилләр, булган хәлне үзгәртеп шаһәдәт бирсәләр яисә шаһәдәт бирүдән баш тартсалар, Аллаһ, әлбәттә, кылган эшләрегездән хәбәрдар булды, эшегез буенча хөкем итәр» («Ниса» сүрәсе, 135 аять).*

Күрәсез, Аллаһы Тәгалә каршында хакыйкать, дөреслек, гаделлек бар нәрсәгә караганда да өстен икән. Хәтта иң якыннарың хакына да ялганга, башкаларга яла ягуга, гаделсезлеккә барырга ярамый. Чөнки бер ялган икенчесен тудыра, кеше үзен һәм якыннарын аклау өчен гаепсез кешене гаепләргә барырга мөмкин. Бу — Аллаһ тарафыннан тыела. Кеше кечкенәдән туры, гадел яшәргә өйрәнергә

тиеш. Аллаһы Тәгалә каршында иң яратмаган, начар сыйфатларның берсе — ялган сөйләүче гаделсез кеше. Әгәр дөреслекне әйтергә мөмкинлек юк икән, яки бу дөреслектән тормышыңа зур куркыныч яный икән, ул чагында, башкаларны гаепләп ялган сөйләүгә караганда, дәшми калуың хәерлерәк. Һәм мөмкинлек чыгу белән, хакыйкатьне кешеләргә җиткерергә кирәк. Чөнки кемнәрнеңдер ялганы, нахак сүзе аркасында газап күрүчеләр, рәнҗетелүчеләр, хәтта ирекләреннән мәхрүм ителүчеләр барлыгын да онытырга ярамый.

Гаделлек ул кеше өлешенә кермәүне дә аңлата. Безнең халыкта хәйләкәрлек, «төп башына утырту», ягъни башкалар хисабына шәп итеп яшәргә тырышу шактый күзәтелә. Хәлле хәлсезне төрткәли, бай ярлыны этә, хезмәт кешесе эшләп-эшләп тә эшләгәненең әҗерен күрми. Башкалар хисабына, хәтта башкаларны кычкыртып талап, рәнҗетеп яшәүчеләр дә бар. Бу — Аллаһ каршында зур гаделсезлек. Ил белән, милләт белән идарә итүчеләр моңа юл куярга тиеш түгелләр. Җитәкчеләр үзләре дә, алардан күрмәкче гади халык та бер-берләрен алдап, рәнҗетеп яшәргә тиеш түгелләр. Алдауга, гаделсезлеккә кереп баткан милләт беркайчан да бәхетле була алмаячак, чөнки Аллаһы Тәгалә: *«Эшегез буенча хөкем итәрмен»,*— ди. Без үз-үзебезне, бер-беребезне алдый алсак та, Аллаһны беркайчан да алдый алмыйбыз, Ул безнең уйларыбызны, эшләребезне дә һәрвакыт күреп тора һәм, шулардан чыгып, җәзасын да бирә. Шушы бөек хакыйкатьне беркайчан да онытмагыз, балалар! Гадел, туры яшәсәк, күңелебез дә тыныч булыр, тормышыбыз да тәртипкә керер, иншаллаһ!

Гаделсезлек ул — золым. Иң зур гаделсезлек ул Аллаһы Тәгаләгә ширек кылу, ягъни тиңдәшлек ясау, Аллаһ барлыкка китергән нәрсәләрне «алла» итеп тоту. Локман Хәким дигән акыл иясе Коръәндә үзенең улына: *«Аллаһка ширек кылма, ширек — иң зур золымлык, гаделсезлек»,*— ди.

Аллаһның кешеләрдә тагы бер яраткан сыйфаты бар, ул — *ихласлык.* Әйе, Аллаһ ихлас кешеләрне ярата. Ягъни эчкерсез, саф күңелле кешеләр Аллаһ рәхмәтенә якынрак торалар. Ихлас кеше, нәрсә эшләсә дә, чын күңелдән бирелеп, эчкерсез башкара. Ул кешеләргә күренү өчен, мактану-кәпрәю өчен дип түгел, барлык эшләрен дә Аллаһ риза булсын дип эшли. Менә шундый саф күңелле, сабый җанлы, беркатлы кешеләрне Аллаһ Үзе яклый, Үзе саклый:

*«Күңеле саф, иманы көчле һәм дине дөрес булган мөселман гына Аллаһ газабыннан имин булачак»,*— диелгән Коръәндә *(«Әнгам» сүрәсе, 83 аять).*

Әлбәттә, ихласлык ул — Аллаһ бүләге, ул, нигездә, синең белән бергә туа торган сыйфат. Аны ясалма рәвештә барлыкка китереп булмый. Әмма шул ук вакытта, үз холкың өстендә эшләп, ихлассызлыкны киметеп яки туктатып торып була. Ихлассызлык ул — ясалмалык, эшләгән эшләреңә рия кертү, кылану, икейөзлеләнү, кеше күрсен өчен генә эшләү. Бу — бик яман сыйфатлар, адәм баласы, ясалма рәвештә үз-үзен күтәрү өчен шулай кыланса да, кешеләр каршында барыбер вак һәм түбән булып күренә. Мактанган яки гел мактатып торган, кәпрәйгән, гел үз-үзен күрсәтергә тырышкан кешене кайсыбыз ярата соң? Бер заман андый кеше һәммәбезне туйдыра, гайрәтебезне чигерә башлый. Шуңа күрә безнең халыкта: «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык белер, халык белмәсә, балык белер» дигән әйтем дә бар. Ягъни эшләгән яхшылыгың белән гел мактанып йөрмә, кайвакытта балык кебек телсез дә була бел, кирәк икән, халык үзе бер гадел бәясен бирер дигән сүз бит бу! Ихлас кеше башкаларга яхшылыгын чын күңелдән эшли дә бу хакта оныта, исенә төшереп йөрми. Ихлассыз кеше, бер-бер яхшылык эшләсә дә, аны гел искә төшереп торып, ул яхшылыгы өчен үзе дә кешедән нидер өмет итеп яшәргә мөмкин. Димәк, аның кылган яхшылыгы да кеше өчен түгел, бары үз файдасына, үзен күздә тотып кына эшләнгән булып чыга. Мондый яхшылыкның Аллаһ каршында савабы юк, ә рия белән эшләнгәнгә, гөнаһ булып гамәл дәфтәренә язылырга мөмкин… Димәк, балалар, яхшылык әҗәткә эшләнми, ул бары тик эчкерсез күңелдән, кешегә яхшы булсын өчен эшләнә. Үз-үзеңә карата яхшылыкны нинди дә хәйләкәр максат белән эшләп булмаган кебек, кешегә дә изгелекне берничә яшерен максатсыз, сөенә-сөенә эшләргә кирәк. Ягъни үзеңә нәрсә телисең, кешегә дә шуны телә! Һәм нәрсә генә эшләсәң дә, чын күңелдән, Аллаһ риза булсын бу эшемнән дип эшлә. Шул вакытта күңелең тыныч булыр, баш очыңнан Аллаһның рәхмәт фәрештәләре өзелмәс, һәм син дөньяның иң бәхетле кешесе булырсың. Әйе, балам, бәхетле буласың килсә, кешегә яхшылык эшлә. Аллаһы Тәгалә сиңа да яхшылык эшләр… Безне Аллаһы Тәгалә Аны таныр өчен яратты. Димәк, безнең барлык тормышыбыз гыйбадәт икән. Гыйбадәт — ихластан Аллаһ ризалыгын алганда гына гыйбадәт булачак.

Аллаһ тагын нинди кешеләрне ярата? Аллаһ мәрхәмәтле кешеләрне ярата. Чөнки Ул Үзе дә — чиксез мәрхәмәтле, рәхимле, шәфкать иясе. Ул кешеләрнең дә бер-берләренә карата миһербанлы, йомшак күңелле, ярдәмчел булуларын тели. Шәфкатьсез, явыз, каты бәгырьле кешеләр Аллаһның рәхмәтеннән бик ерак торалар. Кешеләр дә мондый явызлар белән бәйләнмәскә, эш йөртмәскә тырышалар. Шунысын да онытмыйк: кешегә карата эшләнгән явызлык яңадан үзеңә, нәселеңә дә әйләнеп кайтырга мөмкин. Чөнки «кеше рәнҗеше» дигән гаҗәеп үткен һәм гаҗәеп зур көчкә ия корал бар. Кешене урынсызга, хаксызга бик нык рәнҗетәсең икән, бу рәнҗеш рәнҗетүчегә килеп бәреләчәк.

һәм бу кешенең бөтен тормышы хәсрәткә, бәхетсезлеккә батырга мөмкин. Шуңа күрә усал, явыз булмагыз, кешене тел белән дә, кул белән дә рәнҗетмәгез, кыерсытмагыз. Ялгыш катырак кагылгансыз икән, тизрәк кичерү сорагыз һәм инде беркайчан да бу начарлыкны яңадан эшләмәгез. Явыз, усал кешенең күңеле каты була, андыйларны яратмыйлар, алардан читләшәләр. Үзеңне мондый бәхетсезлеккә, ялгызлыкка дучар итмәс өчен, күңелеңне ярдәмчел, мәрхәмәтле булырга өйрәтергә кирәк. Кешеләргә яхшылык эшли алмыйсың икән, һич югы начарлык та эшләмә. Барысы да үзеңә кире кайтачак бит. Аллаһы Тәгалә сине дә, мине дә, барыбызны да күреп тора һәм гамәлебезгә карата җәзасын да бирәчәк.

*«Кешеләрнең кылган фәхеш, хәрам эшләре сәбәпле җир өсте вә диңгезләр өсте бозылды, Аллаһудан җәза йөзеннән каты ачлык, йогышлы каты чирләр заһир булды, кылган бозык эшләренең бәгъзе гөнаһларына дөньяда ук газапны татытмаклыгыбыз өчен, шаять, бозыклыктан яхшылыкка кайтырлар, иман китереп һәм тәүбә итеп, төзәлеп мөселман булырлар» («Рум» сүрәсе, 41 аять).*

Ислам диненең төп максаты — яхшы кеше тәрбияләү. Гаделлек, эчкерсезлек, ихласлык, ярдәмчәнлек, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатларның кешене никадәр бизәвен, Аллаһка никадәр якынайтуы хакында без инде язып үттек. Сабырлык та менә шундый гүзәл сыйфатлар рәтенә керә. Аллаһ сабырларны ярата… Ягъни дөньяда нинди генә авырлыклар килсә дә, аңа түзә белгән, үз-үзен ашап, дөньяны каргап йөрмәгән, кичерә белгән, фикерле белгән һәм гел бер Аллаһтан өмет итеп яшәгән кешеләр Аның рәхмәтенә дә ирешәчәкләр. Әйе, тәкъдирнең, язмышның яхшысы да, начары да — Аллаһтан. Яхшысы — эшләгән яхшылыкларыбыз өчен Аллаһның бүләге, авырлыкларыбыз — үзебез үк ясаган хаталарның нәтиҗәсе, Аллаһның безгә кисәтүе яки җәзасы. Кешеләр тормышлары яхшы чакта Аллаһны бик үк искә төшермиләр,ирешкән бөтен уңышларын үзләреннән дип уйлыйлар, ягъни акыллы, көч-гайрәтле, бай булуларыннан дигән нәтиҗәгә киләләр. Ә Аллаһ алар әле генә мактанган бу нәрсәләрне, ничек биргән булса, шулай кире дә ала ала бит! Байлыкны да, саулыкны да, дан-дәрәҗәне дә… Менә шундый вакытта кешеләр, Аллаһны искә төшереп, язмышны каргый башлыйлар инде. Имеш, нигә аларга гына шундый авырлыклар килгән, кайгы-хәсрәтләр, бәхетсезлекләр нигә аларны гына эзәрлекли? Әйе, кайвакытта бөтенесе дә бер кеше өстенә өелеп килә кебек. Бу — Аллаһтан сынау да, кисәтү дә, җәза да булырга мөмкин. Димәк, кайдадыр ялгыш киткән яки рәхмәтсезлек бар, нәселеңдә кемдер Аллаһка йә Аллаһ коллары кешеләргә карата гаделсезлек күрсәткән, кемнәрнеңдер рәнҗеше, күз яше шулай тыныч тормышыгызның ишеген кага… Димәк, тормышыбызда гөнаһ бар… Монда бик нык уйланырга, фикерләргә, үз ялгышларыңны табып, аларны тизрәк төзәтергә, тәүбә итәргә кирәк, Аллаһы Тәгалә кушканча эшләргә кирәк…

*«Берәү Аллаһка гөнаһлы булудан сакланса, ул кешегә Аллаһ дөньяда һәм ахирәттә хәсрәтле булудан котылу юлын ачар» («Талак» сүрәсе, 2 аять).*

Димәк, хәсрәттән хәсрәткә төшкәнче сакланырга кирәк. Аллаһ тыйган нәрсәләрне эшләү — барысы да гөнаһ. Аллаһ кешегә һәм үзеңә зыян салуны тыя, исерткеч эчемлекләрне, хәрам ризыкны, сәламәтлеккә зарарлы миңгерәйткечләрне (наркотиклар), зинаны, урынсызга кеше үтерүне һәм җәберләүләрне, гайбәт сөйләүне, ялганны, нахак сүзне, гомерне бушка уздыруны рөхсәт итми. Болардан зыян кешенең үзенә булуын кат-кат искәртә. Инде шушылардан кисәтү өчен Аллаһы Тәгалә кешегә бәла-каза җибәргән икән, моңа сабыр итә белергә кирәк. Аллаһның бу сынавыннан сынып түгел, киресенчә, фикер йөртергә өйрәнеп, үз-үзебезгә һәм дөньяга дөрес бәя биреп, иманыбыз ныгып чыгыйк. Шуны беркайчан да онытмыйк: бәндәсе өчен нәрсә хәерле икәнен Аллаһы Тәгалә Үзе белә. Заманында үзенә шактый борчулар китергән вакыйгаларга да кеше еллар үткәч башка төрле күзлектән карый башлый, шулай булып чыгуы яхшырак булган икән дигән нәтиҗәгә килә. Әйтик, каядыр эшкә урнаша яки укырга керә алмавы, кем беләндер тормыш кора алмавы соңыннан аның үзе өчен яхшырак булуы ачыклана. Шуңа күрә вакытлыча авырлыкларга, каршылыкларга бик бирешергә ярамый, бу нәрсәләргә дөнья бетү кебек итеп тә карарга ярамый — барысы да үтеп китә, шушы вакытларда сабыр итә, түзә белергә өйрәнергә кирәк. Шуңа күрә, тормышта нинди генә хәлләр булса да, башны югалтырга ярамый. «Ахыры хәерле булсын»,— дип әйтергә дә Аллага тапшырырга кирәк. Чын күңелдән, саф йөрәктән бары бер Аллаһтан ярдәм сорарга кирәк. Аның рәхмәтеннән беркайчан да өмет өзәргә ярамый. Сабырлык ул — Аллаһ кушканнарга сабыр булу. Сабырлык ул — Аллаһ тыйганнарга сабыр булу. Сабырлык ул — Аллаһ биргән сынауларга сабыр булу…

*«Әгәр бер бәндәм миннән сорар булса, Мин, әлбәттә, аңа һәрвакыт якынмын, Миннән сораса, сораганын бирермен. Әмма сораучылар үземә һәм сүземә ныклап ышансыннар һәм Миңа буйсынып, Коръән белән гамәл кылсыннар! Әгәр Мин әйткәнчә эш кылсалар, шаять, туры юлны табарлар» («Бәкара» сүрәсе, 186 аять).*

*«Сабыр кыл, чыдамлы бул Аллаһ юлында сабит булу өчен, әлбәттә, чыдамлык кирәк һәм изгелек кыл! Аллаһ изгелек кылучыларның савапларын һич җуймас» («Һуд» сүрәсе, 115 аять).*

Әйе, Аллаһ изгелек кылучыларны, юмартларны ярата… Чөнки Ул Үзе дә биниһая юмарт, биргән нигъмәтләренең иге-чиге юк. Һәм Үзе биргән шушы байлыкларны Ул башкалар белән дә бүлешүебезне тели. Тапкан малның кырыктан берен мохтаҗларга өләшү ислам диненең төп шарты булып тора. Чөнки кешеләр бик төрле бит, бар аларның җир җимереп эшләп йөри алганнары, бар гарип-горабалары, авыру-зәгыйфьләре… Бүген син сәламәт, иртәгә чирләп китәргә мөмкинсең, бүген бай, иртәгә барысы да янып юкка чыгарга мөмкин. Шуңа күрә сәламәт вакытта — авыруларга, бай вакытта ярлыларга ярдәм итәргә кирәк. Моны Аллаһы Тәгалә шулай куша:

*«Гөнаһларыгыз өчен Аллаһудан гафу сорагыз, соңра тәүбә итеп Аллаһуга кайтыгыз! Шулай булсагыз, Аллаһ сезне дөньяда күркәм файдаландыру белән файдаландырыр, билгеле әҗәлегезгә чаклы, һәм яхшылыкта юмартлык кылганнарга Аллаһ нигъмәтләре белән юмартлык кылыр» («Һуд» сүрәсе, 3 аять).*

Юмартлык кешенең күңелен нечкәртә, йомшарта, мохтаҗларның шатлыгы аның үзен дә чиксез сөендерә. Кешегә бирә алу, ярдәм итү — бик зур бәхет бит ул, аны башка берни белән дә чагыштырып булмый. Юмарт кешедә көнчелек сыйфатлары булмый, ул кешенекенә кызыгып карамый, киресенчә, үзе аңа бирә алу бәхетенә сөенә. Әмма иң соңгысын башкаларга таратып бетерү дә хупланмый, чөнки мондый кеше үзе дә бик тиз мохтаҗлар хәленә калырга мөмкин бит. Шуңа күрә һәрнәрсәдә чама кирәк. Соңгы күлмәгеңне башкаларга салып биреп, үзеңә шәрә калу ярамый. Аллаһ сиңа малны күп итеп биргән икән, аны башкалар белән дә бүлешү кирәк.

*«Юк, кешенең Аллаһ каршында хөрмәте дөнья байлыгы белән түгел, бәлки чын иман, хак дин һәм изге гамәлләр беләндер. Хур булуы да ярлылык белән түгел, бәлки имансыз, динсез булу белән һәм нәфескә ияреп азгынлык кылу беләндер. Бәлки сез ятимнәрне хөрмәтләмисез» («Фәлак» сүрәсе, 17 аять).*

Юмартлыкның киресе — саранлык. Саранны беркем дә яратмый. Саран, комсыз кеше беркайчан да байлыктан туймый, күпме мал җыйса да, аңа һаман аз булып күренә. Аллаһ биргән бу нигъмәттән ул фәкыйрьләргә өлеш чыгармый, үз-үзеннән, хәтта якыннарыннан булган байлыгын кызгана. Ул үзеннән байрак кешеләргә һаман көнләшеп карый, аны мал җыюда куып җитү максаты куя. Кеше бер машина алса, ул икене ала, кеше ике катлы йорт салса, ул өч катлыны җиткереп чыга, өй эчен кыйммәтле җиһаз, алтын-көмеш белән тутыра… Ул шушы байлыгын югалтмас өчен гомер буе дер калтырап яши, бөтен көчен, акылын шуны саклауга, малын тагы да арттыруга сарыф итә. Байлыкка табынган кеше тынычлыгын югалта, әкренләп якын дусларын, туганнарын югалта, комсызлыгы аркасында, үзенә карата ихтирамны югалта… Иң куркынычы: Аллаһның рәхмәтен, ярдәмен югалтырга мөмкин. Әйе, бай кешегә дә бәла килә, бай кешегә дә каты авырулар, үлем килә… Кеше китә… Кулында күпме байлыгы була торып, аны Аллаһ юлында сарыф итмичә, Аллаһ кушканча яшәмичә, Аллаһ биргән бу байлыкны мохтаҗлар белән бүлешмичә, әмма үлгәндә *барысын* да дөньяда калдырып, Аллаһ каршына барырга җыена. Малының һәр бөртегеннән соралачак бит бу бәндәдән: ничек тапкан һәм нәрсәгә сарыф иткән? Ягъни хәләл юл белән тапканмы ул бу байлыкны, кешеләрне рәнҗетеп, алдап, талап җыймаганмы? Булган байлыгының бер өлешен булса да Аллаһ юлында сарыф иткәнме, ятимнәр, фәкыйрьләр белән бүлешкәнме, мәчет-мәдрәсәләр тотуга, дини һәм милли китаплар бастыруга биргәнме? Милләтенә ярдәм иткәнме? Нәрсә дип җавап бирер бу кеше — гамьсез, комсыз, саран кеше?

*«…Бар шундый кешеләр — алтын вә көмеш җыеп асрарлар, Аллаһ юлына һич тә бирмәсләр, аларга рәнҗетүче газап булачагы белән хәбәр бир. Җыйган ул алтын-көмешләре кыямәт көнендә җәһәннәм утында кыздырылып, маңгайларына вә кабыргаларына, вә аркаларына басылыр һәм әйтелер: болар дөньяда вакытта үзегез өчен асраган алтын вә көмешләрегез. Инде саранлык белән җыеп саклаган малыгызның газабын татыгыз» («Тәүбә» сүрәсе, 35—36 аятьләр).*

Аллаһы Тәгалә канәгатьләрне ярата… Ягъни булганына канәгать булып, шөкрана итеп, зарланмыйча, офтанмыйча, кешенекенә кызыкмыйча яшәүчеләр Аллаһның рәхмәтенә якынрак торалар. Тормышыңнан һаман риза булмау, гел зарланып, сукранып йөрү ул Аллаһның биргәннәренә риза түгел икәнне аңлата. Ә бу — ярамый торган эш, гөнаһ, чөнки Аллаһы Тәгалә кемгә, кайчан, нәрсә бирергә кирәген Үзе белә.

*«Сезләрне җиргә хәлифә итүче Аллаһ дәрәҗәләрдә бәгъзеләрегезне бәгъзеләрегездән югары күтәрде, сезгә биргән нигъмәтләре хакында барыгызны да сынамак өчен. Дөреслектә, синең Раббың итагать итмәгәннәрдән ашыгып үч алучыдыр, вә әлбәттә, Ул итагать итеп төзәлгәннәрне ярлыкаучы, рәхимле» («Әнгам» сүрәсе, 165 аять).*

Бу дөньяда кешеләр бертигез түгел: бар бик байлар, бар бик ярлылар, бар синнән яхшырак яшәүчеләр, шул ук вакытта синнән начар яшәүчеләр дә бар… Бар акыл ияләре, галимнәр, бар укый-яза белмәүчеләр, наданнар… Аллаһы Тәгалә менә шулай итеп безнең беребезне икенчеләребез белән сыный. Үзеңдә булганына канәгатьлек хисе тәрбияләү өчен, тормышыңны тегеләре белән дә, болары

белән дә чагыштырып карарга өйрән, балам! Татар халык мәкале дә: «Күккә карап фикер йөрт, җиргә карап шөкер ит»,— ди бит. Үзеңнән бай яшәүчеләр тормышына кызыкканда, синнән дә авыр хәлдә яшәүчеләр барын онытма. Ягъни үзеңдә булганына шөкер ит, кешенекенә күпсенмә, көнләшмә, аңа карап, ул барыбер синеке булмый, үз җаныңны гына юкка ашыйсың. Артык мескенләнмә дә, чөнки әле синнән мескен хәлдәге кешеләр дә бар. Бу дөньяда иң бәхетле кешеләр — булганына сөенеп яши белгән кешеләр. Аларның җаннары тыныч, алар һәр якты көнгә сөенеп, һәр капкан ризыкка шөкрана итеп, бүген сәламәт булган һәр әгъзасы өчен куанып, Аллаһка рәхмәт әйтеп яшиләр. Аллаһ мондый кешеләргә һич көтмәгән җирдән зур нигъмәтләр бирергә мөмкин, ә шөкрана итә белмәгәннәр булганыннан да колак кагарга мөмкиннәр… Нигъмәтләрнең иң зурысы булган җәннәт ишекләре шөкрана итә белүчеләр өчен ачык булачак…

*«Җирдәге һәр җан иясенең ризыгы Аллаһ кулында» («Һуд» сүрәсе, 6 аять).*

*«Бәла-казага чыдап изге гамәлләр кылучыларга Аллаһуның ярлыкавы вә олуг җәннәт нигъмәтләре булачак» («Һуд» сүрәсе, 11 аять).*

Дөньяда иң бәхетсез кешеләр — көнче, хөсетле кешеләр. Башка кешедәге байлык, дан-дәрәҗә аның җанын ашый, ул кеше бәхетеннән көнләшә, аңа карата хөсет-мәкер белән яши башлый. Көнчелектән, гади кызыгудан башланган нәрсә кешене җинаятькә хәтле китереп җиткерергә мөмкин. Имеш: «Нигә анда бар да, нигә миндә юк? Миндә юк икән, ничек булдырырга? Булдырып булмый икән, ничек теге кешенекен дә юк итәргә? Нигә әле анда булырга тиеш?» Күп җинаятьләр менә шушындый башка сыймый торган фикерләү нигезендә эшләнә. Көнче, кара эчле кеше үзенә дә, әйләнә-тирәдәгеләргә дә зур зыян салырга мөмкин. Ул гомер буе кеше артыннан куачак, әмма барыбер куып җитмәскә мөмкин, чөнки башка кеше дә тик тормый бит. Теләгенә ирешмәсә, көнче, хөсетле кешенең күңелендә зур ризасызлык, ачу туа, ул барыбер үзенекен итәр өчен төрле юлларын эзли башлый.

Көнчелек — башкаларда булган нәрсәнең үзеңә күчүен яисә башкаларда юкка чыгуын теләү. Көнчелек — гаделсезлеккә этәрүче сәбәп. Көнче кеше үзенең яхшы гамәлләрен утта янган утын кебек яндырып бетерә. Гыйлемле кешедән, миндә дә шундый гыйлем булсын иде, дип, яисә, малым булып, шул малны бай кеше кебек Аллаһ юлында таратыр идем, дип көнләшү рөхсәт ителә. Көнче кешенең төп коралы —мәкер. Ул үзенең көндәшен болай гына җиңә алмагач, мәкер юлына аяк баса. Ягъни астыртын эш йөртеп, гайбәт сөйләп, нахак ялалар тагып, көндәшен юк итү өчен тырыша. Мондый кеше үз өстенә күпме гөнаһ, күпме рәнҗеш ала, күпме кешеләрнең нәфрәтенә дучар була! Ул үзе дә яшәми, кешеләргә дә яшәргә ирек бирми. Көнче, мәкерле, хөсетле кешеләр Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән бик ерак, алар мәңгелек күңел караңгылыгында, мәңгелек адашуда. Үзегездә шушындый яман сыйфатларны сизә башлауга, аларны юк итәргә, бастырырга тырышыгыз, балалар! Моның өчен кеше бәхетенә сөенә белергә өйрәнергә кирәк, юмарт булыгыз, башкаларга карата ярдәмчел, мәрхәмәтле булыгыз, бу яхшылыкларның барысын да Аллаһ риза булсын өчен эшләгез һәм көнчелек хисе үзе сезне ташлап чыгып качар. Чөнки ул вакытта сезгә Аллаһы Тәгалә ярдәмгә килер:

*«Аларның күңелләреннән көнчелек, кинә, ачу вә кайгы кебек начар нәрсәләрне чыгарырбыз» («Хиҗер» сүрәсе, 47 аять).*

*«Без аларның күңелләрендә булган хөсетне суырып алдык» («Әгъраф» сүрәсе, 43 аять).*

Күрәсез, балалар, Аллаһ ярдәме белән күңел дөньяңны тәртипкә салырга, андагы узгынчы уйлардан һәм яман гадәтләрдән арынырга була икән. Яшь кеше, бигрәк тә балалар, нәрсәнең яхшы, ә нәрсәнең начар булып бетәсен аңлап та бетермәскә мөмкиннәр. Бу мәсьәләдә дин тотучыларның, әти-әниләрнең, укытучыларның, галимнәрнең дөрес киңәшләрен тыңларга кирәк. Үзегез ислам тәрбиясе буенча китаплар укып гыйлем ала алсагыз, бигрәк тә яхшы. Шушы зур, изге эшләргә тотынып алдыннан, башта барыбер күңел дөньяңны чистартырга, тәртипкә китерергә туры киләчәк. Күрәсез, әйләнәбез дә тагы шул күңел дөньясына кайтып төшәбез. Әйе, кеше күңеле аны яхшылыкка да тартырга, начарлыкка да котыртырга мөмкин. Кеше күңелендә вакыты-вакыты белән тыелгысыз хис-тойгылар котырынырга мөмкин, алар күп вакытта кешене үз рәхәте өчен генә яшәргә, әдәп-әхлак кагыйдәләренә буйсынмаска чакыралар. Эшкә һәм гыйлемгә ялкаулык, тән һәм җан азгынлыгы, оят качу, дан-дәрәҗә, мал, кием, төрле тиле идеяләр колы булу, гомерне, малны һәм вакытны юкка сарыф итү, туктаусыз хәрамга — тыелганга тартылу, рәхимсезлек, явызлык, урлашу, эчкечелек, наркомания, кеше сөйләү, кеше тикшерү, ялган, көнчелек, саранлык, мәкер, куркаклык, мескенлек, куштанлык, тәкәбберлек, кеше күрсенгә кылану, икейөзлелек, түземсезлек — менә күрәсезме күпме начар сыйфатлар сагалап көтеп тора адәм баласын! Боларның берсенә генә бирешсәң дә, тормышыңда бәхетсезлекләр башланасын көт тә тор! Мондыйларны беркем дә яратмый. Шуңа күрә, балалар, күңелегездә шушындый начар сыйфатлар баш калкыта башлый икән, аларны тамырыннан йолкып ташларга ашыгыгыз! Бу сыйфатлар сезне кайчан да булса бер барыбер бәла-казага китереп җиткерәчәк, гөнаһ ясарга этәрәчәк. Үз күңелегезне үзегез тәрбияләргә өйрәнегез, холкыгызда бары тик яхшы сыйфатларны гына булдырырга

тырышыгыз. Моның өчен *кешеләрне яратыгыз*, аларга карата түзем, мәрхәмәтле булыгыз, кулыгыздан килгәнчә, кешеләргә ярдәм итәргә тырышыгыз, беркайчан, беркемгә, бернәрсәгә зыян салмагыз! Онытмагыз: Аллаһы Тәгалә барысын да күреп тора, хәтта безнең күңелләребездә, уйларыбызда нәрсә барын да! Кешенең күңеле яхшылыкта икән, Аллаһы Тәгалә аңа һәрвакыт ярдәмгә килә. Бары тик моны бик нык теләргә, сорарга һәм Аллаһы Тәгалә өйрәткәнчә гомер итәргә генә кирәк. Аллаһ гыйлеме белән күңелләребезне хуш исле гөлбакчага әйләндерергә мөмкин. Әгәр инде Аллаһтан башкаларга табынабыз икән, ярдәмне дә алардан сорыйбыз, алардан көтәбез икән, һаман нәфес азгынлыгына ияреп яшибез икән, үз күңелләребез үк безгә җәһәннәм чокыры булып күренергә мөмкин. Күрәсез, балалар, хисләрдән генә торган күңел дөньясы безне адаштырырга да, туры юлга чыгарга да ярдәм итәргә мөмкин икән. Монда иң мөһиме: күрсәткеч маягы итеп нәрсәне аласың, нәрсәгә таянасың? Бала яшьтән күңелен, тәртипкә китереп, дөрес юлга салса, ул алдагы тормышында адашмый, саташмый, бәхетсезлекләрнең күбесен әйләнеп үтә ала. Әгәр бала яшьтән чуар күңелле, рәхәт, ләззәтләр колы икән, әгәр бала күңеле һаман тыелган әдәпсезлекләргә, вакытны бушка сарыф итүләргә тартыла икән, бу кешене алдагы тормышында бәхетсезлекләр, кайгы-хәсрәтләр, бәла-казалар сагалап кына торачак. Күңелең начарлыкта, бозыклыкта икән, бернинди дан-дәрәҗә дә, мал-мөлкәт тә, нәсел-нәсәбәң дә сине саклап кала алмаячак — начарлыкның ахыры начар бетә! Бүгеннән үк күңел гөлбакчаларыгыздагы агулы чүп-чарларны тамырыннан утап, чыгарып ташлагыз, балалар! Тормышны чиста күңел, якты, яхшы хисләр белән башларга кирәк. Хәерле юллар сезгә, милләтнең киләчәге, бәхетле тормыш сезгә, Аллаһның сөйгән иманлы яшьләре!

## ТАРИХ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Менә син тормышка аяк басып киләсең… Сиңа кадәр дә бу дөньяда бик күп кешеләр яшәп киткәнен, төрле көчле дәүләтләр, мәшһүр шәһәрләр, куәтле цивилизацияләр булганын белдең. Аларның күбесе инде җир йөзеннән юкка чыккан, сөйләргә бары тик истәлекләре генә калган… Сиңа кадәр дә бу дөньяда күпме милләтләр, халыклар яшәгәнен белдең. Аларның да инде күбесе юкка чыккан, шулай итеп, тарихта үле телләр, үле халыклар барлыкка килгән… Син, әлбәттә, үз милләтеңнең, үз телеңнең киләчәктә үлеләр исемлегенә керүен теләмәс идең. Моның өчен нәрсә эшләргә соң? Әйдә, бергәләп тарих турында, милләт, җәмгыять турында сөйләшик әле… Шуны да истә тотыйк: без тарихта, нигәдер, бары тик фиргавеннәр тарихын, фиргавеннәр чорын һәм аларның канун-тәртипләрен генә өйрәнәбез. Дөреслектә, кешелек тарихы ул пәйгамбәрләр чоры белән, Аллаһның шәригате белән башлана һәм билгеләнә. Барлык басымны менә шул икенче тарихны өйрәнүгә юнәлтергә кирәк.

Кешелек гомер буе идеаль җәмгыять төзергә омтылган. Галимнәр, акыл ияләре, язучылар, сәясәтчеләр төрле чорларда төрле идеяләр белән чыгып карыйлар. Һәм кешеләрне шулар нигезендә тәрбияләргә, җәмгыятьне шул идеяләр тирәсенә тупларга тырышалар. Кешене теге яки бу идеягә буйсындыра алмагач, адәм баласын азмы-күпме тәртәдә тоту өчен, алга таба төрле законнар уйлап табалар, бу законнарга буйсынмаганнарны җәзага тарталар. Шулай итеп, меңләгән илнең миллионлаган закон һәм кагыйдәләре барлыкка килә. Әмма кешеләр барыбер бу законнарны да әйләнеп үтү юлларын табарга тырышалар, үз нәфесен канәгатьләндерү өчен кеше һаман тәртип бозуга, җинаятькә бара тора… Бүгенге көндә дә бер генә илдә дә кешеләрне тулысынча тәртиптә тота алырлык законнарның уйлап чыгарылганы юк әле… Техник яктан гаять алга киткән Европа илләре бүген наркоманиядән, әхлаксызлыктан җимерелә, болар белән хәтта көрәшүче дә юк, чөнки бу әхлаксызлыклар закон белән рөхсәт ителгән. Ягъни бу әхлаксызлыклардан җәмгыятькә зыян юк, кешенең үзенә генә зыян, ә ул үз иркендә дип карыйлар. Әйе, кеше бозылыр өчен, аягүрә череп харап булыр өчен үз ирегенә куелган. Болай барса, тагы берничә буын, һәм бу илләрдә бала табарга — хатын-кыз, тормыш алып барырга ир-ат калмаячак. Боларны инде бернинди законнар да коткарып калмаячак… Шушы әхлаксызлык дулкыны инде безнең тормышыбызга да үтеп керде. Һәр көн эчкечелектән, наркоманиядән, СПИДтан, төрле йогышлы чирләрдән, бер-берләренә күрсәткән җәбердән, үз-үзләренә кул салудан йөзләгән, хәтта меңләгән кеше үлә! Сугыш юк, җир тетрәүләр, су басулар юк, ә миллионлаган халык чебен урынына кырыла. Җинаятьләрнең нинди генә төрләре юк: бала анасын үтерә, ир — хатынын, туган — туганны, күрше — күршене, кеше — кешене… Бер сәбәпсезгә — ачу килгәнгә, акча кирәккә, ерткычка әйләнгәнгә… Пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам әйткәнчә: *«Заман ахырында үтерүче ни өчен үтергәнен белмәс, үлүче ни өчен үлгәнен белмәс»*. Үлемнең кара кулы инде һәр йортны, һәр ишекне, һәр җанны шакый… Кайда соң кешеләр гомер буе хыялланган идеаль җәмгыять? Шушы тормышмы? Нигә XXI гасыр бусагасыннан кеше ерткычка әйләнеп, мүкәләп кереп бара? Нигә компьютерлар, интернетлар, цивилизацияләр, демократия, җыр-биюләр

кешене хайванга әйләнүдән саклап кала алмый? Җавап бер: кешелек ялгыш юлга кереп китте. Кешелек дөрес яшәми. Кешелек үзен барлыкка китерүче Аллаһы Тәгаләне онытты, Аның кушканнарын үтәми, Аллаһ кануннары буенча яшәми… Әгәр кеше, милләт, җәмгыять Аллаһ кануннары буенча яши башламый икән, аны алда һәлакәт, юкка чыгу көтә. Әйе, балалар, болай барса, кешелек үзенең һәлакәтен якынайта. Кешелекне бары тик күктән иңгән кануннар гына коткарып калачак…

*«Аларга бу газап шул сәбәпледер — Аллаһ бер кавемгә биргән нигъмәтен үзгәртми, ул кавем үзләрен үзгәрткәнгә чаклы» («Әнфәл» сүрәсе, 53 аять).*

Без үзебез үзгәрми торып, дөнья үзгәрмәячәк. Бүгенге көн — моның гыйбрәте, тарих та шул турыда сөйли, кисәтә.

*«Аларны һәлак итмәс борын, һәрберсенә әвәлдә һәлак булган кавемнәрнең хәлләрен гыйбрәт өчен бәян кылдык, ләкин алар гыйбрәтләнмәделәр, һәм Без һәммәләрен каты һәлак итү белән һәлак иттек» («Фуркан» сүрәсе, 39 аять).*

Ишеттегезме, балалар, моны бит Аллаһы Тәгалә әйтә! *«Һәрберсенә әвәлдә һәлак булган кавемнәрнең хәлләрен гыйбрәт өчен бәян кылдык»,*— ди.

Күрәсезме, балалар, Аллаһ әхлагы бозылган халыкларны юк итә һәм сөйләр өчен тарихларын гына калдыра. Бу тарихны белү безгә үткәндәге хаталарны яңадан кабатламау өчен кирәк. Коръәндә кешелек тарихы башыннан ахырына кадәр бәян ителгән, нинди халыклар кайчан яшәгәнлеге, ни сәбәпле юкка чыгулары тасвирланган. Шушы бихисап мисаллар нигезендә Аллаһы Тәгалә безне кисәтергә тели, ялгыш юлдан барсагыз, менә шушы халыклар кебек һәлак булырсыз, ди, туры юлның кайда икәнлеген безгә кат-кат искәртә. Без тарихка карап гыйбрәтләнәбезме соң? «Нигә илләр, дәүләтләр, тулы бер халыклар, цивилизацияләр юкка чыккан?» дип үз алдыбызга сорау куябызмы?

*«Һәм аларны һәлак итүдә Без берсен икенчесенә иярттек, үзләрен һәлак итеп, сөйләргә хикәяләрен генә калдырдык, Аллаһуның рәхмәтеннән ераклык ышанмаган кешеләргәдер» («Мөэминнәр» сүрәсе, 44 аять).*

Һәлак булган нинди кавемнәр һәм нинди милләтләр, илләр һәм дәүләтләр турында сүз бара соң Коръәндә? Бүгенге тарих фәне бу милләтләр һәм дәүләтләр турында ни яза? Шул хакта бергәләп уйланыйк әле. Бүгенге фән тарихны, нигездә, ханнар һәм патшалар, корольләр һәм императорлар язмышы аша күрсәтсә, Коръәндә милләтләрнең язмышы пәйгамбәрләр тарихы аша бирелә. Шуларның кайберләре хакында бүген сезгә дә сөйләп китәргә уйлыйбыз.

Аллаһы Тәгалә дөньяга беренче кеше итеп Адәм галәйһиссәламне барлыкка китергән, дидек. Адәм галәйһиссәламнең буе — 60, иңе 7 терсәк буе булган. Ягъни гәүдә озынлыгы —30 метр, аркылыга исә 3 метрдан артык булган. Хәер, ул вакытта кешеләр барысы да эреләр, алыплар булганнар, әмма тән төзелешләре, әгъзаларының эшчәнлеге буенча бүгенге кешедән башка берниләре белән дә аерылып тормаганнар. Аннан кешеләр әкренләп үзгәрүгә, кечерәюгә таба барганнар, Аллаһ кешеләрнең санын арттырып, аларның гәүдә зурлыкларын киметкән, чөнки кешеләргә яшәү өчен шулай җайлырак булган. Бу дөнья гел үзгәреп торган, һәм һәр үзгәрешнең үз вакыты, үз заманы булган. Кешелекнең башы булган кебек, ахыры да булачак. Коръәндә бу хакта да хәбәрләр бар.

Шулай итеп, беренче кешеләрне алыплар булган, дидек. Бу хакта тарих, әдәбият дәреслекләрендә дә бераз мәгълүмат бар. Бигрәк тә татар халык авыз иҗатында, дастаннарда, әкият һәм мифларда алыплар турында хикәяләр укыгансыздыр. Татарстанда алыпларның исемнәре белән бәйле авыл һәм тау атамалары да бар. Димәк, бу эре гәүдәле кешеләр безнең якларда, безнең милләттә дә яшәгәннәр дигән сүз.

## Алпамшалар

Бу беренче кешеләр нинди дин тотканнар соң, ышанулары, тормыш тәртипләре ничек булган? Коръәннән билгеле булганча, беренче кешеләр — Адәм белән Һава күктә — җәннәттә яшиләр, Аллаһның сүзен тыңламаганнары өчен, күктән җиргә сөреләләр. Димәк, беренче кешеләр күктән төшкәннәр, алар зур гәүдәле булганнар, Аллаһны белгәннәр, хәтта күргәннәр, үзләренең ялгышларына бик нык үкенгәннәр, калган гомерләрен Аллаһка буйсынып үткәргәннәр. Җир йөзендә беренче булып ислам динен таратучы Адәм галәйһиссәлам булган. Сез: «Ислам дине бит моннан 1400 ел элек кенә барлыкка килгән, ә Адәм галәйһиссәламнең тууы миллион еллар белән исәпләнә, ничек инде ул ислам динен тарата алсын?» — диярсез. Ислам ул — Аллаһка буйсыну дигән сүз, Адәм галәйһиссәлам үзенең балаларына, нәселенә Аллаһка буйсынып яшәргә кирәклеген аңлата да инде. Ул аларга үзен Аллаһы Тәгалә барлыкка китерүе турында сөйли, җәннәт бакчаларын, андагы фәрештәләрне исенә төшереп елый, дөрес яшәмәгәннәрне җәһәннәм дигән утлы газап көтеп торуы турында кисәтә. Атабыз Адәм белән анабыз Һава балаларына ислам тәртибе буенча яшәү кагыйдәләрен өйрәтеп калдырырга

тырышалар. Әмма аларның беренче балалары Кабил үк үз туганы Һабилне үтерә. Шулай итеп, җирдә тормыш кеше үтерүдән башлана. Адәм галәйһиссәламнең балалары да әкренләп аталары сөйләп калдырганнарны оныталар, Аллаһ кушканча түгел, үзләре теләгәнчә яши башлыйлар. Алар азгынлыкка, әхлаксый пычракка, бәла-казаларга кереп баталар. Әмма Аллаһы Тәгалә ул чагында да адәм балаларын ташлап бетерми, һәр заманда, һәр халыкка хакыйкатьне аңлата торган илче-пәйгамбәрләрен җибәреп карый. Дин тарихыннан күренгәнчә, Аллаһ рәхмәте белән, җиргә барлыгы 127 мең пәйгамбәр килгән, аларның барысы да бер генә максат — бер Аллаһка табынырга чакырып килгәннәр. Һәр халыкка пәйгамбәр шул милләттән килә, ягъни шушы халык телендә сөйләшеп, аларга Аллаһның барлыгын, берлеген һәм бары тик Аңа буйсынып, Ул кушканча гына яшәргә өйрәтә. Дөньяда Аллаһ тарафыннан пәйгамбәр җибәрелмәгән, хак дин аңлатылмаган бер генә халык та юк, шул исәптән татар халкы да. Әйе, балалар, безнең дә үз пәйгамбәрләребез, Аллаһ динен аңлатучылар, безне дөрес итеп яшәргә өйрәтүчеләр булган. Милләтебез бүгенге көнгә кадәр юкка чыкмаган икән, димәк, ул әле үзенең күңелендә Аллаһ сүзен, Аллаһ нурын йөртә, пәйгамбәрләре өйрәтеп калдырганнарны үти… Ә башка халыклар Аллаһ илчеләренең кайберләрен тыңлаганнар, кайберләрен — юк, кайберләрен исә тотып кыйнаганнар, мыскыл иткәннәр, хәтта үтереп тә ташлаганнар! Югыйсә пәйгамбәрләр бары тик Аллаһка ышанырга һәм Аңа буйсынырга гына чакырганнар бит! Ә кешелек, үҗәтләнеп, ярсып, нәкъ менә шуңа каршы барган…

Аллаһның беренче илчесе Адәм галәйһиссәлам булса, соңгы пәйгамбәр — Мөхәммәт галәйһиссәлам, ул инде аерым бер кавем өчен генә түгел, бөтен кешелек өчен җибәрелгән соңгы илче. Мөхәммәт галәйһиссәламнән соң инде пәйгамбәрләр булмаячак — бу хакта Коръәндә әйтелә. Ислам дине — Аллаһның беренче һәм соңгы дине, кешеләрнең соңгы тапкыр кисәтелүләре…

*«Өммәтләрнең һәрберсенә рәсүлләр күндердек, фәкать Аллаһуга гына гыйбадәт кылыгыз вә Аллаһудан башкага гыйбадәт итүдән сакланыгыз, дип. Ул өммәтләрнең итагать иткәннәрен Аллаһ һидәяткә салды вә итагать итмәгәннәренә адашуны беркетте. Инде җир өстендә йөрегез вә күрегез: ялганчыларның ахыры ничек булган?» («Нәхел» сүрәсе, 36 аять.)*

Әйткәнебезчә, кешеләр Аллаһ өйрәткәннәрне бик тиз бер читкә ташлап, үз азгынлыкларына һәм адашуларына кереп баталар. Алар, үзләренең наданлыклары һәм тәкәбберлекләре сәбәпле, Аллаһны ташлап кояшка, айга, йолдызларга, утка һәм суга, агачка, хайваннарга, аерым кешеләргә, аерым идеяләргә, хәтта үз-үзләренә табына башлыйлар, һәр милләт үзенең мәҗүси динен, мәҗүси тәңреләрен, кыргый гореф-гадәтләрен булдыра. Хәтта шушы кыргый көчләргә, «илаһәләргә» кеше хәтле кешене корбан итү йолалары башлана. Шушы төрле ышанулар, ырымнар нигезендә капма-каршылыклар, зур низаглар, шау-шу, фетнә, сугышлар китә, һәркем бары тик үзен, үз динен генә дөрес дип саный. Бер Аллага түгел, мең «аллага» табыну кешелекне бик күп тапкырлар һәлакәт чигенә китереп җиткерә. Тарих — менә шушы ялган идеяләр бәрелешенең, хаклык белән хаксызлык көрәшенең кешелек көзгесендә чагылышы ул. Иман белән имансызлык арасында бер кеше гомерендә нинди аяусыз көрәш барса, кешелек тарихында бу көрәш гасырларга җәелеп, дәверләр дәвамында булып ята…

Инде сез укый торган тарих дәреслекләренә килик. Анда да беренче кеше Адәм галәйһиссәлам, аның нәселе турында мәгълүматлар бар. Мәктәп дәреслекләре бу беренче кешеләр турында менә нәрсәләр яза:

«Адәм белән Һаваның күп санлы балалары, балаларының балалары туган. Кешеләр җирдә таралып яши башлаганнар. Тормыш җиңел булмаган, ризыкны авыр хезмәт белән тапканнар. Кешеләр начарлык, хәтта җинаятьләр эшли башлаганнар. Адәм белән Һаваның олы улы игенче Каин үзенең энесе терлекче Авельне үтергән, шулай җирдә явызлык арткан. Шунда Алла, бөтен дөньяны су басу (туфан) оештырып, тереклекне юк итәргә уйлаган. Бары тик Ной (Нух) исемле кешене генә кызганган. Аллаһ кушканча, Нух зур көймә төзегән. Шунда ул хатынын, өч малаен, аларның хатыннарын, һәртөрле җәнлектән берәр пар алган. Яңгыр кырык көн яуган. Бары тик Арарат тавының түбәсе генә судан күренеп торган. Нухның көймәсе шунда барып терәлгән. Көймәдәгеләрдән кала бөтен кеше һәлак булган. Хәзерге дөньяда яшәүчеләр шуларның нәселе инде» (Борынгы заман тарихы. Казан, 1997 ел, 76 бит).

Әйе, кешеләрнең азгынлыклары өчен Аллаһы Тәгалә җир йөзен суга батыра, дөньяда бары тик Аллаһ тарафыннан сайлап алынган иманлы кешеләр генә кала. Туфан башланганчы, Аллаһы Тәгалә кешеләр арасыннан Нух исемлесен үзенең илчесе итеп билгели, аларны азгынлыктан тыелырга чакырырга куша. Әмма кешеләр Нух галәйһиссәламне мыскыллап көләләр генә, хәтта аны кыйнап та ташлыйлар. Нух пәйгамбәрнең бер хатыны һәм бер улы Аллаһка иман китермиләр, азгынлыкларында калып, башкалар белән бергә батып үләләр. Бу хакта Коръәндә менә нинди хәбәр бар:

*«Нухны кавеменә рәсүл итеп җибәрдек, ул әйтте: «Ий каумем! Фәкать Аллаһуга гына гыйбадәт кылыгыз, Аллаһудан башка сезнең Илаһәгез юк, каһәре зур булган туфан көненең газабы сезгә ирешер дип куркам»,— дип. Нух кавеменең аксакаллары әйтте: «Ий Нух! Без сине тәхкыйк адашкансың дип*

*күрәбез»,— дип. Нух әйтте: «Ий кавемем! Миндә адашмаклык юк, ләкин мин барча галәмне тәрбия кылучы — Аллаһның рәсүлемен. Сезләргә Раббымның хөкемнәрен ирештерермен вә сезләрне үгет-нәсыйхәт кылырмын һәм Аллаһ белдерүе белән сез белмәгән нәрсәләрне белермен. Әйе сез арагыздан үзегез кеби иргә Аллаһудан китап иңдерелүегә гаҗәпләнәсезме? Ул китап килде Аллаһ газабы белән сезне куркытмак өчен, һәм Аллаһуга гөнаһлы булудан сакланырга юл күрсәтер өчен килде, вә тәкъвалык кылганыгыздан соң Аллаһуның рәхмәтенә ирешмәклегегез өчен». Кавеме Нухны ялганчы диделәр, Нухны вә аңа ияргән мөселманнарны көймәдә туфан суыннан коткардык вә аятьләребезне ялган дию-челәрне туфан суында батырдык, тәхкыйк алар хакны күрми торган сукыр булдылар» («Әгъраф» сүрәсе, 59—64 аятьләр).*

Күрәсез, балалар, дөньяны туфан суы басу вакыйгасы булган, бу хакта хәзер тарих дәреслекләрендә язылa, галимнәр дә кешелек тарихында шундый зур фаҗига булуын археологик, биологик һәм башка фәнни ачышлар буенча исбатладылар инде. Коръәнгә ышанмаучыларга, аны кеше уйлап чыгарган диючеләргә каршы да бу — бик ныклы дәлил. Чөнки моннан 1400 ел элек ком чүлендә яшәп яткан, укый-яза белмәгән Мөхәммәт галәйһиссәлам кайдан белергә тиеш иде кайчандыр дөньяны туфан суы басуы турында? Әлбәттә, бары тик Аллаһы Тәгаләнең хәбәре аша гына. Аллаһы Тәгалә, Җәбраил фәрештә аша Мөхәммәт галәйһиссәламгә дөньяның ничек яратылышы, беренче кешеләр, аларның нинди фаҗига-бәлаләргә юлыгулары турында хәбәр бирә. Аллаһы Тәгалә туфан басу турында да пәйгамбәребезгә хәбәр итә, шулай итеп, Нух пәйгамбәрдән соң калган буынны — безнең барыбызны да яңа бәла-казалардан кисәтә, кешелекне саклап калу өчен, ничек яшәргә кирәклеген тагы бер тапкыр адәм балаларының исенә төшерә.

Коръән — Аллаһ сүзе, яхшылык, изгелек, гаделлек, хакыйкать гыйлеме, шуны белми торып, шуны үтәми торып, кешелек дөрес юлны таба алмаячак, бәхетсезлекләренең башы-ахыры булмаячак.

*«Ий Мөхәммәт галәйһиссәлам! Ошбу үзебез һәлак иткән шәһәр хәбәрләрен сиңа сөйлибез. Тәхкыйк рәсүлләре аларга ачык дәлилләр вә могҗизалар белән килделәр, иман китерер булмадылар әүвәлдә Аллаһ аятьләрен ялган дигәннәре өчен.*

*Әнә шулай Аллаһ кяферләрнең күңелләрен мөһерләр, һичнәрсә аңламаслар» («Әгъраф» сүрәсе, 101 аять).*

Әйткәнебезчә, Коръәндә милләтләр һәм илләр тарихы пәйгамбәрләр язмышы аша бирелгән. Коръәндә 25 илче-пәйгамбәрнең исеме зекер ителә. Шулар арасыннан безгә аерата мәгълүмнәре: Адәм, Идрис, Нух, Һуд, Салих, Лут, Ибраһим, Исмәгыйль, Исхак, Якуб, Йосыф, Әйүп, Шогаеп, Муса, Һарун, Давыт, Сөләйман, Юныс, Ильяс, Әлйасаг, Зөлкифел, Зәкәрия, Яхъя, Гайсә, Мөхәммәт галәйһиссәламнәр. Коръәнгә ышанган кешеләр бу пәйгамбәрләрнең барысын да танырга һәм хөрмәт итәргә тиешләр. Менә шушы илчеләре язмышы аша Аллаһы Тәгалә безгә бөтен кешелек тарихын ачып бирә.

Азгынлыклары өчен җирнең беренче кешеләрен Аллаһы Тәгалә туфан суына батырып үтерүен без инде укып белдек, җирдә Нух пәйгамбәр нәселенең генә торып калганын да аңладык. Нух пәйгамбәр нәселе күз алларында булган бу фаҗигадән гыйбрәт ала белгәннәрме соң, Аллаһ билгеләгән тәртип буенча озак яшәгәннәрме? Тагы пәйгамбәрләр тарихына күз салыйк.

Нух пәйгамбәрнең оныгының оныгы Һуд пәйгамбәр алып бәдәнле, бик көчле-кодрәтле гад халкының бер кешесе була. Гад кешеләре җиргә басканда, аяклары җиргә батып керә икән, шулкадәр таза һәм көчле булганнар. Менә шушы һичнидән курыкмый торган көчле халыкны Һуд пәйгамбәр кырык җиде ел буе иманга чакырып караган, әмма гад халкы, үзләреннән дә зуррак сыннар ясап куеп, шуларга табынуларын дәвам иткәннәр, Аллаһны онытканнар, пәйгамбәрләрен тыңламаганнар. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә аларның җирләренә корылык җибәргән, күктән бер тамчы яңгыр төшермәгән. Һуд пәйгамбәр боларга әйткән: «Аллаһ сезнең өстегезгә җил җибәреп, үлемгә хөкем итте»,— дигән. Гад халкы барыбер иманга килмәгән, кяферлекләрен дәвам иткән. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә бу динсезләр өстенә кара болыт җибәргән, бик көчле давыл гад халкы өстенә ташланган. Бу өермә ташка ябышып исән калырга тырышкан кешеләрнең итләрен сөяктән аерып аткан, үзләрен җиргә китереп сылаган. Алып гәүдәле, беркем җиңә алмаган гад халкы, сөякләре таралып, көлгә әйләнә, барысы да үлеп бетә, бары тик Һуд пәйгамбәргә ияргән берничә мөэмин генә исән кала…

Бу вакыйга хакында Коръәндә менә ничек тасвирлана:

*«Ул җилне аларга җиде төн һәм сигез көн ирекле кылып, ул җилдә кешеләрне буылып һәлак булган кеби күрер идең, гүя алар эче куыш хөрмә агачының төбе кеби булып калганнар. Алардан калган берәр кешене күрерсеңме? Юк, әлбәттә, алардан һичкем калмаган» («Хакка» сүрәсе, 7—8 аятьләр).*

*«Һудны вә аңа ияргән мөэминнәрне коткардык үз рәхмәтебез белән вә аятьләребезне ялган диючеләрнең нәселен кистек, һәлак итеп бетердек, чөнки алар иман китермәделәр» («Әгъраф» сүрәсе, 72 аять).*

Аллаһы Тәгалә азгын халыкны, иманга килмәүчеләрне менә шулай һәлак иткән. Бу нисбәттән Лут пәйгамбәр кавеменең тарихы бик гыйбрәтле. Бу халык җенси яктан бик азгын, юлдан язган була. Лут пәйгамбәр аларны оялтып та, кисәтеп тә, Аллаһ җәзасы белән куркытып та карый, әмма бу бозык халык аны тыңламый. Һәм Аллаһы Тәгалә Лут пәйгамбәргә бу азгыннар илен ташлап чыгып китәргә куша, иртә белән шәһәрләрен таш яудырып һәлак итәсен әйтә.

*«Ул — Аллаһ беренче Гад кавемен һәлак итте, алардан һичкемне калдырмады. Дәхи болардан элек Нух кавемен һәлак итте, алар бик залим вә бик азгын иделәр. Дәхи Лут кавеменең шәһәрләрен күтәреп әйләндереп ыргытты. Ул шәһәрләрне бер каплый торган нәрсә каплады. Ий адәм баласы, Раббының кайсы нигьмәтләрендә низаглашырсың, шик төшерерсең?» («Нәҗем» сүрәсе, 50—55 аятьләр.)*

*«Лут кавеме җәһәннәм белән куркытучы пәйгамбәрләрен ялганга тотты. Без аларга таш ата торган каты җил җибәрдек, мәгәр Лут пәйгамбәрнең өй җәмәгатен сәхәр вакытында коткардык. Бу кавемгә таң вакытында кыямәткә чаклы дәвам итүче газап иреште» («Камәр» сүрәсе, 33—38 аятьләр).*

*«Өсләренә таш яудырып һәлак ителгән Лут кавеменең шәһәре янынннан кяферләр үтеп йөриләр, алар шул шәһәр янынннан үткәндә Аллаһның газап әсәрен күрмиләрме?» («Фуркан» сүрәсе, 40 аять).*

*«Кояш чыгып торганда, аларга бер ямьсез каты тавыш иреште. Шулвакыт шәһәрнең өстен аска әйләндереп һәлак иттек һәм җәһәннәмдә кыздырылган ташларны өсләренә яудырдык» («Хиҗер» сүрәсе, 73—74 аятьләр).*

*«Ул шәһәрләрне бер каплый торган нәрсә каплады...» «Җәһәннәмдә кыздырылган ташларны өсләренә яудырдык...» «Шәһәрләрнең өстен аска әйләндереп һәлак иттек...»* Коръәннән бу сүзләр, бу хәбәрләр сезгә җир тетрәп, хәрабәләр астында калган шәһәрләр, вулкан атып, кайнар ләмгә күмелеп калган йортлар, кешеләр турында сөйләмиме? Кешелек тарихында мондый фаҗигаләр күп булган бит, тик без генә аларның сәбәбен дә эзләмәгәнбез, гыйбрәт тә алмаганбыз. Тарих дәреслекләрегездән аермалы буларак, Коръән мондый вакыйгалар турында сөйли һәм шунда ук аларның сәбәбен дә әйтеп бирә. Без исә тарихны патшадан — патшага, сугыштан сугышка кадәр генә өйрәнәбез, бу хәлләрнең төбенә, сәбәбенә төшеп тормыйбыз.

Хәзер сезгә тарихтан бер гыйбрәтне күрсәтеп үтик әле. Атаклы бер рәсемне барыгыз да хәтерли булыр, ул «Помпейның соңгы көне» дип атала. Исегезгә төшерегез: якындагы таудан шәһәр өстенә ярсыган ут ташкыны ыргыла... Зиннәтле йортлар, мәрмәр бассейннар, алтынланган сарайлар күз ачып йомганчы таш һәм балчыктан торган кайнар ләм астында күмелеп калалар... Кешеләр аягүрә янып көлгә әйләнә, җирдә, кая качарга белмичә, карт-карчыклар шуыша, ата — улны, ана кызны танымый, белми... Кайберәүләр диңгезгә качып котылмакчы булалар, әмма диңгез өсте дә дөрләп яна... Су белән бергә, кораб-көймәләр, диңгезгә сикергән кешеләр, аларның котылуга соңгы өметләре яна...

Шәһәр өстенә җәһәннәмдә кыздырылган ташлар ява...

Шәһәрләрне кайнар ләм каплап китә...

Сүз вулкан ату нәтиҗәсендә тулысынча һәлак булган Помпей шәһәре турында бара.

Помпей... Тарих дәреслекләре буенча сез инде беләсез, ул — Рим империясе чорында булган шәһәр. Ул зәңгәр диңгез буена, Везувий тавы итәгенә урнашкан булган. Бөтен Рим империясендәге кебек, Помпей шәһәрендә дә ул чорда, ягъни безнең эраның I гасырында, бик зур гаделсезлекләр, рәхимсезлекләр, оятсызлыклар, әхлаксызлык хөкем сөргән. Рим императорлары үзләрен аллалар дип игълан итә башлаганнар, үзләренә атап, храмнар һәм һәйкәлләр салдырганнар, халыкны бары тик императорларга гына табынырга чакырганнар, хәтта мәҗбүр иткәннәр. Бу империядә бөтен авыр, кара эшләрне коллар башкарган, аларны бөтенләй кешегә санамаганнар, колларны сатканнар, бүләк итешкәннәр, җәзалаганнар, үтергәннәр... Колларның бернинди дә хокуклары булмаган. Моның өстенә, коллардан гладиаторлар әзерләп, аларны бер-берләре белән үтергәнче сугыштырганнар, бу канлы тамашаларны карарга бөтен шәһәр җыела торган булган. Бу кол-гладиаторлар өстенә ерткыч хайваннарны җибәрә торган булганнар, я кол — ерткычны, я ерткыч колны үтерергә тиеш булган. Биредә кол булмаган гади кешеләрнең дә хокуклары бик аз булган, ил алар өстеннән шымчылар, әләкчеләр, үтерүчеләр белән шыплап тулган булган. Шушы вакытта империядә, аның колониясе саналган Фәлистин җирләрендә беренче христианнар — бер Аллага табынучылар күренә башлаган. Исегезгә төшерегез: дин тарихы буенча бу —дөньяга Гайсә пәйгамбәр килгән заман. Ул кешеләрне бер Аллага табынырга өнди, кешене, түрә-императорларны Алла итеп тотмаска куша, гаделлеккә, рәхим-шәфкатькә чакыра. Римлылар бу яңа дин тотучыларны бик нык җәберли башлыйлар, аларга хайван тиресе кидертеп, өсләренә котырган этләрне җибәрәләр, бер Аллага табынучыларны терелэй так-таларга кадаклап куеп, җәберләп үтергәннәр. Ил белән исә тиле, канечкеч, азгын патшалар хакимлеге дәвам иткән... Явызлык, әхлаксызлык, гаделсезлек иң азган бер вакытта сүнгән дип уйлаган Везувий вулканы ата башлый! Ут-ялкын телләре дистәләгән чакрым күккә сикерә, кояш каплана, таудан ишелеп аккан ут елгасы Помпей шәһәренә бәреп керә, шәһәр 10 метр биеклектәге утлы ләм астында кала. Ут

елгасы кешеләрне, йортларны, малларны агыза, аннан диңгезгә ыргыла, диңгез өсте яна башлый… Бозыклыкның чигенә барып җиткән шәһәр кешеләре, үкерешеп, бер-берләренең күз алдында тереләй янып үләләр… Аларны байлыклары да, дан-дәрәҗәләре дә, ясалма илаһәләре — сыннары да коткара алмый…

Бу хакта сезнең тарих китапларыгыз сөйли…

XVIII гасырда Помпей шәһәрен көл астыннан казып чыгаралар, аны ачык һавада музей итеп, килгән туристларга күрсәтеп сөйли башлыйлар. Әмма бу азгын шәһәр халкына Аллаһы Тәгаләнең шулай җәза бирүе турында аңлаталармы икән бирегә килгән кешеләргә? Коръәндә менә шушындый шәһәрләрнең халкы, аларга килгән җәза-афәтләр турында бик ачык итеп әйтелгән бит!

*«Әгәр безнең газабыбыз ул кавемгә иңсә, куркытып та курыкмаган кавемнең таңы нинди яман таң булыр» («Саффат» сүрәсе, 177 аять).*

*«…алар, йортларында тезләнеп, үлек булдылар» («Гәнкәбут» сүрәсе, 37 аять.)*

*«Минем куркытуым һәм газабым ничек булды аларга?» («Камәр» сүрәсе, 21 аять).*

*«Алар зур хаталары сәбәпле туфан суына батырылдылар вә утка кертелделәр, алар Аллаһ газабыннан котылырга ярдәмче тапмадылар» («Нух» сүрәсе, 25 аять).*

Иң борынгы тарих буенча сез мәктәп дәреслекләреннән Мисыр патшасы фиргавеннәр турында укыган идегез инде. Тарих китапларыгыздан күренгәнчә, Фиргавен үзен җирдә кешеләрнең алласы дип игълан иткән, кешеләр генә түгел, хәтта табигать тә Фиргавенгә буйсынырга тиеш дип әмер биргән. Мисырдагы мәҗүсилекнең, кыргыйлыкның иге-чиге булмаган. Мисырлылар Фиргавенне җирдәге «алла» дип уйласалар, күктәге «алла» дип кояшны исәпләгәннәр. Шул ук вакытта җирнең дә үз «алиһә»се булган, аны елан башлы кеше итеп сурәтләгәннәр. Моннан тыш, күктә әле тагы хатын-кыз «алиһә»се булган, аны зур чуар сыер кебек итеп күз алдына китергәннәр. Кош башлы зирәклек «алиһә»се кешеләрне, имеш, укырга-язарга өйрәтсә, мәче сынлы «алиһә» хатын-кызларны һәм матурлыкны яклаган, имеш. Шул ук вакытта алар үгезгә, крокодилга, мәчегә һәм башка, имеш, «изге» хайваннарга да табынганнар, аларга хәтта кешеләрне дә корбан итеп биргәннәр. Гомумән, Мисырда кешенең, бигрәк тә сугышларда әсир төшкән колларның бернинди хокуклары булмаган. Аларны шул ук пирамидаларны төзүдә аяусыз файдаланганнар, егылып үлгәнче, кыйный-кыйный эшләткәннәр, крокодилларга корбан итеп ыргытканнар, кояш «алиһә»сенең күңелен күрер өчен кыя-тау башларыннан тотып атканнар, башларын чабып өзгәннәр, каннарын агызып эчкәннәр… Мисырлылар алтыннан-көмештән кешеләрнең сыннарын ясап, шуларга да табына башлаганнар. Хәтта шуңа барып җиткәннәр, Исраил нәселенең ир балаларын үтертеп, кыз балаларны гына калдыра башлаганнар. Бу хакта тарих китаплары да дөрес яза.

Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә җир йөзендәге бу кадәр явызлыкка, азгынлыкка түзә алмаган, Мисыр халкын, Фиргавенне иманга чакыру өчен үзенең пәйгамбәрләрен җибәргән. Шуларның берсе — Муса пәйгамбәр. Аллаһы Тәгалә шулай итеп китереп чыгара ки, исраиллеләрнең бөтен ир балаларын үтертеп барган Фиргавен кечкенә Мусаны үзе уллыкка алып үстерергә мәҗбүр була. Ягъни үзенең юкка чыгуына сәбәпче буласы кешене үзе карап үстерә. Аллаһ кушуы буенча, Муса пәйгамбәр Мисыр халкын күпме генә иманга чакырып караса да, Фиргавен үзе дә, халкы да азгынлыкта калуын дәвам иткән, бик азлары гына иман китергән. Фиргавен Муса пәйгамбәрне һәм аңа ышанучыларны үтерергә боерган, кешеләрне рәхимсез җәзалый башлаган. Шул чагында Аллаһы Тәгалә Муса пәйгамбәргә үз нәселен Мисыр җиреннән алып чыгып китәргә боерган. Бу хакта сезнең тарих дәреслегендә менә ничек язылган:

«Шунда еврейлар Моисей (Муса) җитәкчелегендә качарга карар кылганнар. Кызыл диңгез янына килеп җиткәннәр. Артларыннан Фиргавеннең арбачылар гаскәре куып килгәнен күреп, соңгы сәгатебез җиткән икән дип уйлаганнар. Тик Алла диңгез суларын ике якка аерып куйган, һәм еврейлар коры җир буйлап шунда кереп киткәннәр. Алар артыннан куып килүче Мисыр арбачылары да шул юлга кергәч, сулар яңадан үз урынына кайткан, Фиргавен гаскәре су астында калган. Израильлеләр диңгезнең теге ягына, Синай чүленә килеп чыкканнар һәм кырык ел буена шунда көтүләре белән күчеп йөргәннәр» *(Борынгы заман тарихы. Казан, 1997 ел, 76—77 битләр).*

Бу хакта Коръән менә нәрсә хәбәр итә:

*«Муса кавеменең яртысы Фиргавеннең вә аның олугъларының фетнәсеннән яки үтерүеннән куркып, Мусага иман китермәделәр, мәгәр курыкмаучылары иман китерделәр, чөнки Фиргавен Мисыр җирендә бик тәкәббер, бик усал иде вә ул явызлыкта чиктән аша китте, хәтта: «Мин — аллаһ»,—дия башлады. Муса, кавеменең Фиргавеннән курыкканын күргәч, әйтте: «Ий кавемем! Әгәр Аллаһуга иман китереп ислам динен тотучы мөселман булсагыз, Аллаһуга тәвәккәл кылыгыз! Фиргавеннән курыкмагыз!» Мусага ияргән мөселманнар әйттеләр: «Аллаһуга тәвәккәл кылдык, ий Раббыбыз, безләрне залимнәр кулына фетнә кылма. Вә безләрне кяфер булган Фиргавен кавеменнән коткар,*

*үзеңнең рәхмәтең белән». Муса белән Һарунга вәхий кылып әйттек: «Кавемегезгә Мисырда өйләр хәзерләгез вә ул өйләрегезне мәсҗидләр кылыгыз һәм намазларыгызны шул өйләрегездә үтәгез, вә мөэминнәрне шатландыр, аларга дөньяда — һидәят, ахирәттә җәннәт булачак». Муса әйтте: «Ий Раббым! Кешеләрне аздырмак өчен Фиргавенгә вә аның олугъларына дөньяда зиннәт һәм мал биргәнсең. Ий Раббыбыз, син аларның малларын һәлак итеп, күңелләрен каралт ки, һәлак итүче газапны күрмичә иман китермәслек булсыннар». Аллаһ әйтте: «Сезнең догаларыгыз кабул ителде, боерылган эшегездә туры торыгыз һәм хакны белми торган наданнарга һич иярмәгез». Бәни Исраилне дәрья аркылы үткәрдек, тәкәбберлек вә дошманлык белән алар артыннан Фиргавен вә аның гаскәре куып чыктылар. Бәни Исраил өчен ачылган су аралыгына кереп бата башлагач, Фиргавен әйтте: «Иман китердем, гыйбадәт кылырга яраклы Илаһә юк, мәгәр Бәни Исраил иман китергән Аллаһу Тәгалә генәдер вә мин мөселманнарданмын». Аллаһ әйтте: «Хәзер иман китерәсеңме? Башта Аллаһуга гасый булдың вә бозыклык кылучылардан идең». Сездән соң киләчәк кешеләргә гыйбрәт булсын өчен тәнегезне бүген су өстенә чыгарабыз. Ләкин кешеләрнең күбрәге Безнең гыйбрәтләнерлек аятьләребездән гафилләр, һич вәгазьләнмиләр» («Йунус» сүрәсе, 83—92 аятьләр).*

Күрәсез, Коръәндә хәбәр ителгәннәрне бүген тарих дәреслекләре дә яза. Ләкин монда Бәни Исраилнең милләт түгел, ә бер нәсел балалары, ягъни Якуп пәйгамбәр балалары икәнен искәртеп үтәргә кирәк. Югыйсә тарих дәреслекләре бик тиз генә алардан яһүдиләр ясап куйганнар.

Ләкин әйтәсе килгән сүзебез башка иде. Сез югарыда, «Йунус» сүрәсеннән китергән мисалда, соңгы аятькә бик нык игътибар итегез әле, балалар! *«Сездән соң киләчәк кешеләргә гыйбрәт булсын өчен тәнегезне бүген су өстенә чыгарабыз...»* — диелгән анда. Ягъни Аллаһ Фиргавеннең тәнен су өстенә чыгарырга сүз бирә. Һәм бу хәл була да бит! 1898 елда, Сүэеш каналын казыганда, эшчеләр нәкъ менә шушы явыз Фиргавен мумиясен табып алалар! Фиргавеннең кипкән гәүдәсе, таралмыйча, 3000 елга якын башта — суда, аннан җир астында ята. Галимнәрнең әйтүенчә, бу нәкъ менә Исраил балаларын эзәрлекләгәндә Кызыл диңгезгә батып үлгән Фиргавен-Рамзес II гәүдәсе була. Бүгенге көндә бу Фиргавеннең мумиясе Лондон музеенда саклана һәм бөтен дөнья аның Коръәндә һәм Библиядә хәбәр ителгән Фиргавен гәүдәсе икәнен таныды.

Әйе, *«Коръәндә хәбәр бирелгән һәрнәрсәнең урыны һәм вакыты бар, Коръәндә әйтелгән сүзләрнең хак икәнлеген тиздән белерсез» («Әнгам» сүрәсе, 67 аять).*

Инде шушы могҗизалардан, шушы хикмәтләрдән соң да уйланмасак, гыйбрәт алмасак, кем соң без?!

Тарих буенча безнең эрага кадәр XIII гасырда Иордан елгасы буенда Давыт һәм Сөләйман патшалар яшәгәнлеген беләсез. Бу җирләрдә озак еллар буе бик күп канкойгыч сугышлар булган, бу сугышларның сәбәбе милләтнең, Аллаһ рәхмәтеннән ерагаеп, тәкәбберлеккә һәм бозыклыкларга кереп батуларында була. Тарихта патшалар дип аталган Давыт һәм Сөләйман хәзрәтләр дә Аллаһның илчеләре — пәйгамбәрләре булалар һәм үз кавемнәрен бары тик бер Аллаһка табынырга өндиләр. Әмма Аллаһ ярдәме белән зур бәлаләрдән — Фиргавен җәбереннән котылган Бәни Исраил кавеме бик тиз Аллаһны оныта һәм яңадан төрле сыннарга (әйтик, алтын бозау сынына), байлыкка һәм нәфескә табына башлыйлар. Һәм Аллаһы Тәгалә алар өстенә башка көчле кавемне җибәрә, Бәни Исраилне рәхмәтеннән кисә һәм гомер буе каргалып, бәрелеп-сугылып, куылып йөрергә мәҗбүр итә.

*«Раббыгыз әйтте: «Якуп балалары өстенә кыямәт көненә чаклы каты газап кылучыны әлбәттә җибәрербез, тәхкыйк, Раббың тиз үч алучы вә тәүбә итүчегә рәхимле вә ярлыкаучы» («Әгъраф» сүрәсе, 167 аять).*

*«Өстегездән вә аяк астыгыздан сезгә газап җибәрергә яки сезгә азгын халыкны аралаштырырга Аллаһ, әлбәттә, кадир» («Әнгам» сүрәсе, 65 аять).*

Нәкъ шулай була да. Сез инде тарих буенча беләсез: Аллаһ гыйлемен дөнья малына алыштырган Бәни Исраил кавемен каты, рәхимсез ассириялеләр басып ала. Тимер сөңгеләр һәм кылычлар белән коралланган, инде ат өстенә менеп алган Ассирия гаскәрен туктатырлык көч булмый. Алар Мисырны, Бабил илен, хәтта Кавказ буйларын басып алалар. Ассириялеләр җиңелгән халыкны коточкыч җәзалый башлыйлар: тереләй казыкка утырталар, күзләрен чокып чыгаралар, тиреләрен тунап алалар. Әмма тора-бара бу мәҗүси, явыз халыкны да җиңүче табыла — Бабил халкы, аларны сугышып җиңеп, ул җирләргә хуҗа булып ала. Алар да, бар дөньяга явызлык таратып, үзләре уйлап тапкан «аллаларга» табынып, мәҗүсилектә яшәүләрен дәвам итәләр. Боларга каршы инде фарсылар күтәрелә һәм җиңеп чыга. Әмма фарсылар да мәҗүсилеккә, кыргыйлыкка, җәза-үтерүләргә, шымчылыкка кереп баткан була. Тора-бара аларны җиңүче көч тә табыла… Күрәсез, дәүләтләр бер таралган, бер җыелган, гасырлар буе кеше каны аккан, сугышлар туктап тормаган. Кешеләр бәндәгә, байлыкка, көчкә табынуларын дәвам иткәннәр…

Әлбәттә, монда озак итеп борынгы греклар, аларның мәҗүси «аллалары», Урта һәм Үзәк Азиядәге кыргый йолалар, диннәр, ышанулар турында сөйләргә булыр иде. Европа илләрендәге ул чактагы караңгылык, вәхшилек, туктаусыз булып торган үтереш-сугышлар турында да җентекләп язарга мөмкин булыр иде, ул хакта тарихи материаллар бик күп. Әмма сез инде үзегез дә күреп инандыгыз: кешелек тарихы сугышлардан тора икән. Берәүләр — җиңү, үтерү өчен, икенчеләр җиңелмәс, үлмәс өчен сугышкан. Кая монда бер Аллаһка буйсынып яшәү, кая монда мәрхәмәтлелек, гаделлек, кая монда иман?! Әле моннан 2 мең ел элек, Гайсә пәйгамбәр Аллаһның илчесе булып, хакыйкать белән килгәч тә, дөнья аны танырга теләми, күпләр үзләренең кыргый, явыз юлларыннан баруларын дәвам итәләр. Тарихта Гайсә пәйгамбәрдән алып Мөхәммәт пәйгамбәр туганчы булган араны «җаһилият чоры», ягъни караңгылык, наданлык чоры дип атыйлар. Кешеләр азгынлыкның, бозыклыкның, мәкернең инде соңгы чигенә барып җиткән булалар — кеше үтерү берни тормый башлый, эчкечелек китә, зина, сихер котырына… Кешеләр хайваннан да түбән дәрәҗәгә төшәләр, оят, намус, акыл дигән нәрсәләр юкка чыга. Һәм җирдә шушы хәлләрне күреп, моннан 1400 ел элек, кешелекне иманга өндәү өчен Аллаһы Тәгалә соңгы пәйгамбәрен — Мөхәммәт галәйһиссәламне җибәрә, аңа 23 ел буе күктән Коръәнне иңдерә.

Әйе, инде менә Коръән иңгәнгә дә 14 гасыр үтте… Кешелек Аллаһ күрсәткән юлга кереп киттеме соң? Үзебез Аллаһ кушканча яшибезме? Нигә һаман сугышлар туктамый, нигә кешеләр бер-берләрен җәберлиләр, явызлык-мәкер эшлиләр, үтерешәләр? Галәмгә очарга акылы җиткән кеше нигә һаман җирдә үзен хайван кебек тота, үзен дә, башкаларны да бәхетсез итә?

*«Берәү Аллаһуның нигъмәтләре булган һидәятне кяферлеккә алыштырса, ул нигъмәт Аллаһудан килгәннән соң, Аллаһ андый кешеләрдән каты газап белән үч ала» («Бәкара» сүрәсе, 21 аять).*

*«Алар, Аллаһ биргән белемне хак юлга кулланмыйча, һәлак булдылар» («Гәнкәбут» сүрәсе, 38 аять).*

Кая китте, эссез югалды дөньяны тетрәткән бөек империяләр: Төрки, Хәзәр каганатлары, Алтын Урда, Госманлы, Рим империяләре? Кайда мәшһүр Атлантида, майя-ацтек цивилизацияләре, кайда йөзләгән-меңләгән үле телләр, үле милләтләр, үле дәүләтләр? Боларның күтәрелү һәм юкка чыгу сәбәпләре нәрсәдә? Атлантида иле халкы белән суга баткан, майя-ацтек кабиләләренең авыл-шәһәрләрен җир йоткан, читләр басып алган, империяләр бер-берләрен юк иткәннәр… Әмма илләр беткәндә дә, дәүләтләр, милләтләр юкка чыкканда да, хак дин — Аллаһ сүзе барыбер җир йөзендә урнашып калган! Сез игътибар итегез әле: моннан 14 гасыр элек, Гарәбстан ярымутравында бер кеше — Мөхәммәт галәйһиссәлам кабул итүдән башланып киткән ислам дине бүген дөньяның бөтен кыйтгаларына таралып, җир шары буйлап килә! Ислам дине тотучыларның саны бүген 1 миллиардтан артып китте! VII гасырда Мәдинә шәһәрендә берничә мең кеше бердәнбер ислам дәүләте төзегән булсалар, бүген Коръәнне Төп Канун итеп алучы илләр санап бетергесез. Менә алар: Әфганстан, Бангладеш, Бахрейн, Бруней, Индонезия, Иордания, Иран, Гыйрак, Йәмән, Катар, Кувейт, Малайзия, Мальдивы, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Оман, Пакистан, Согуд Гарәбстаны, Сүрия, Алжир, Ливия, Мавритания, Марокко, Мисыр, Тунис һәм башкалар. Шулай ук Албания, Төньяк Кипр, Төрек җөмһүрияте, Ливан, Палестина, Төркия, Комор утраулары, Судан, Чад кебек илләрдә дә, дәүләт төзелешләре дөньяви булса да, халык, нигездә, ислам динен тота.

Шунысын да әйтергә кирәк: бу мөселман илләренең күпчелегендә иминлек, муллык хөкем сөрә, аларның күпчелеге инде ком чүлләрендә дә гөлбакча ясый алганнар. Шул ук вакытта әле үзара сугыш-низаглардан, фетнәләрдән, мәкердән газап чигүче мөселман илләре дә бар. Димәк, бу илләрнең, бу кешеләрнең яшәешендә, инде ислам динен кабул иткәннән соң да, кайдадыр ялгыш-хата киткән, дин тышкы бер билгегә, гадәткә генә әйләнеп кала башлаган… Яки җитәкчеләре, зур акча һәм дан-дәрәҗәләр хакына, иленә кяферләр һәм кяферлек керткән, милләтен мәкер корбаны иткән…

*«Аллаһ ничек хак юлга күндерсен иман китергәннән соң кяфер булган кавемне?» («Гыймран» сүрәс, 86 аять).*

Мөселманнарның шулай ук Европа илләрендә: Югославия, Болгария, Германия, Франция, Англиядә дә күп булуын, Американың үзендә дә миллионлаган мөселман барын әйтеп үтәргә кирәк. Ә инде элеккеге Советлар Союзына килгәндә, аннан аерылып чыккан бәйсез дәүләтләрдә: Азәрбайҗанда, Казахстанда, Үзбәкстанда, Кыргызстанда, Таҗикстанда, Төркмәнстанда, Украинаның Кырым республикасында, нигездә, ислам динен тотучы төрки һәм фарсы халыклар яши. Дөрес, бу илләрдә әле Коръән Төп Закон булып тормый, әмма халык ислам кануннары буенча яшәргә омтыла, һәм бу дәүләтләрнең җитәкчеләре, иртәме-соңмы, барыбер халык фикере, халык теләге белән килешергә мәҗбүр булачаклар.

Бүгенге Россиянең үзендә дә 20 миллионнан артык мөселман бар. Рәсми булмаган мәгълүматлар буенча, бу санны ике тапкыр күбрәк, диләр. Шулай булган очракта, мөселманнар Россия халкының биштән берен тәшкил итәләр дигән сүз. Бу — бик зур сан, бик зур көч һәм әле бик күп хәл ителмәгән

проблемалар да. Россия мөселманнары бигрәк тә Идел буйларында: Татарстанда, Башкортстанда, Чувашстанда, Себердә, Мәскәү һәм Мәскәү тирәсендә, Үзәк Россиядә, Төньяк Кавказда: Дагстанда, Ингушетиядә, Карачай-Черкесиядә, Кабарда-Балкариядә һәм канга батырылган Чечняда яшиләр. Россия мөселманнарының төп өлеше — 80—90 проценты ул без — татарлар, әлхәмдүлиллаһ!

Күрәсез, ком чүлләрендә, 60—70 градуслы эсселек шартларында, берничә кешедән башланган ислам дине үзенең кодрәте һәм нуры белән инде ярты дөньяны яулап алган, 60—70 градус салкынлы кар-боз илләренә — Себерләргә хәтле килеп җиткән. Дөньяның иң салкын кыйтгаларында, Себер, Төмән урманнарында, мәңге туң тундраларда, кар-буран эчендә ислам динен тотучылар, әлхәмдүлиллаһ, без — татарлар! Бүген Россиянең Мәскәү, Петербург, Казан, Уфа, Әстерхан, Төмән, Оренбург, Самара, Саратов, Ульяновск һәм башка бик күп шәһәрләрендә һәм авылларында йөзләгән, меңләгән мөселман-татар мәчетләре эшләп тора… Тарих шаһит: безне, татарларны, беркем дә кылыч тотып ислам динен кабул итәргә мәҗбүриләмәде, без — үз теләгебез белән бу гүзәл динне кабул иткән милләт. Әле 922 елда ук, бу изге динне безнең әби-бабаларыбыз Болгар-Биләр җирләрендә үз ихтыярлары белән кабул итәләр. Шушы дин нигезендә алар көчле, кодрәтле Болгар, Казан дәүләтләрен төзиләр, гасырлар буе бәхетле мөстәкыйль тормыш алып баралар. Дөрес, шушы меңьеллык тарих дәверендә, татар халкы да күпне күрде, күпне югалтты. Көчле-куәтле дәүләтләребез дә, иксез-чиксез җирләребез дә инде юкка чыкты, башкалар кулына күчте. Әмма мең ел эчендә нинди генә бәла-казалар килсә дә, милләтебез исән калды, шушы 10 гасырлык гарасаттан да күңелендә иман нурын саклап алып чыкты. Менә шушы нурны, шушы гыйлемне, шушы бәхетне без бүген сезнең белән дә уртаклашырга телибез, газиз балалар, дәвамчыларыбыз безнең…

Үзебезнең тарихыбызга җентеклерәк бәя бирүгә күчкәнче, мөселманнарга Аллаһның ярдәме турында берничә гыйбрәтле мисал китереп үтәсем килә. Чөнки тарихта могҗизага тиң вакыйгалар бар, зур җиңүләр һәм хурлыклы җиңелүләр бар… Галимнәр бүгенге көнгә хәтле җавап таба алмаган хикмәтле хәлләр бар…

Хәзер сөйләячәк вакыйга Коръәндә тасвирланган. Бәдер сугышы турында бу хәбәр соңыннан гарәп тарихына да язып калдырылган. Бу хакта хәзер бөтен дөнья мөселманнары белә. Хиҗринең икенче елында, ягъни 624 елда, Рамазан аеның 17нче көнендә, җомга иртәсендә була бу хәл. Мөселманнарны гел эзәрлекләп, газаплап, җәзалап, юк итү максаты белән яшәгән мәҗүси көрәешләр төркеме хак мөселманнар белән очрашалар. Алар арасында каты сугыш китә. Бу сугышта пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәлам дә катнаша. Кыргый мәҗүсиләр күп булалар, аларга ярдәм арты ярдәм килеп тора, бу явызлар пәйгамбәребезне дә, башка мөселманнарны да суеп-үтереп бетерү максаты куялар. Мөселманнар бу сугышта җаннарын да аямый сугышалар, динебезне, пәйгамбәребезне саклап калу өчен соңгы тамчы каннарына хәтле көрәшәләр. Тау араларында тәкбир тавышы, атларның ярсып кешнәве, кылыч чыңлавы һәм яралыларның үлем ачысы белән кычкырулары гына ишетелеп тора. Мәҗүси кяферләр, бөтен көчләрен куеп, пәйгамбәребез Мөхәммәт галәйһиссәламне юк итәргә, тураклап ташларга ыргылалар. Ләкин алар пәйгамбәребезне Аллаһы Тәгалә Үзе саклаганын, хак мөселманнарга да Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәм иткәнен белмиләр шул! Бу сугыш хакында Аллаһы Тәгалә Коръәндә менә нәрсә дип әйтә:

*«Сездән ике төркем, сугыштан куркып, кире кайтырга теләделәр, ләкин ул ике төркемнең хуҗасы Аллаһтыр. Ягъни Аллаһ күңелләренә батырлык салды, аннары сугышка катнаштылар. Мөэминнәр һәрвакыт Аллаһуга тәвәккәл итсеннәр, курыкмасыннар! Ий мөэминнәр, дөреслектә Аллаһ сезгә Бәдер сугышында ярдәм бирде, сез аз идегез, Аллаһуга гөнаһлы булудан сакланыгыз һәм нигъмәтләренә шөкер итегез! Мөхәммәт галәйһиссәлам мөэминнәргә әйтте: «Раббыгыздан сезгә ярдәм өчен өч мең фәрештәнең иңдерелүе җитмиме?» Бәлки өч мең фәрештә җитәдер, әгәр авырлыкка чыдасагыз һәм сугышта чиктән үтүдән саклансагыз, Раббыгыз сезгә биш мең фәрештә белән ярдәм бирер, ул фәрештәләр ак маңгайлы атларга атланган булырлар, башларында ак чалмадыр. Бу эшне Аллаһ сезгә шатлык булсын өчен һәм фәрештәләрнең иңүеннән күңелләрегез канатланып куәт тапсын өчен эшләде. Бернинди заттан ярдәм юк, мәгәр кодрәт вә хикмәт иясе Аллаһудан гынадыр. Аллаһ фәрештәләр белән ярдәм кылды, кяферләрдән бер җәмәгатькә җәза бирмәк өчен яки җиңелсеннәр өчен, әгәр җиңелсәләр, хәсрәт белән кайтырлар» («Гыймран» сүрәсе, 122—127 аятьләр).*

Күрәсез, балалар, Аллаһ ярдәм итсә, беркем дә сине җиңә алмый икән, әгәр инде Аллаһ ташласа, сиңа инде беркем дә ярдәм итә алмаячак…

Мөселманнар бу Бәдер сугышында җиңеп чыгалар, һәм шуннан соң инде аларны беркем дә туктата алмый…

Мондый могҗизага тиң хәл үзебезнең татар тарихында да булган. Бу хакта урыс һәм литва елъязмалары теркәп калдырган. Бу хәл 1437 елның кара көзендә була. Алтын Урда ханы Олуг Мөхәммәт Мәскәүдән ерак булмаган Белев шәһәренә килеп төшә, андагы халыкны дус, тату яшәргә

чакыра. Әмма урыслар аңа каршы 40 меңләп гаскәр җибәрәләр. Тарихи елъязмалар күрсәткәнчә, Олуг Мөхәммәтнең үзе белән нибары 3 мең сугышчысы була. Белев шәһәре янындагы кырда урыслар белән татарларның каты, тигезсез сугышы башлана. Олуг Мөхәммәт, гаскәренең азлыгына борчылып, ак кар өстенә тезләнеп намаз укый, Аллаһтан ярдәм сорый. Һәм ярдәм килә…

*«Сугышка кергәндә Раббыгыздан ярдәм сораган вакытыгызда Аллаһ догагызны кабул итте һәм әйтте: «Мин сезгә аллы-артлы барып тоташучы мең фәрештә белән ярдәм итәчәкмен»,— дип. Аллаһы Тәгаләнең ул фәрештәләрне иңдерүе мөэминнәргә бәшарәт өчендер вә күңелләрегез карар тапсын өчен. Ягъни гайрәтләре вә батырлыклары артсын өчен. Ярдәм һичкайдан, һичкемнән юк, мәгәр Аллаһудан гынадыр. Шиксез, Аллаһ кодрәтле вә хикмәтле»* («Әнфаль» сүрәсе, 9—10 аятьләр).

Берничә көнгә сузылган бу сугышта урыс гаскәре татарларның кимү түгел, күзгә күренеп арта, күбәя баруын күреп, шашып калалар. Әйтерсең лә татарлар, атка атланып, кулларына кылыч һәм сөңге тотып, күктән иңәләр! Инде менә бөтен кыр татар сугышчылары белән тула, аларны, нигәдер, ук та, кылыч та, хәтта үлем дә алмый! Бу сәер сугышчылар, нур чәчеп, тәкбир әйтеп, 40 меңлек урыс гаскәрен Аллаһ исеме белән тар-мар итәләр. Бу серле күренеш теләсә кемне акылдан шаштырырлык була. Урысларның исән калганнары сугыш кырын ташлап качалар, бу хәл турында бөтен дөньяга хәбәр итәләр. Олуг Мөхәммәт исә Белевны да ала, бернинди каршылыксыз, урыс арасыннан үзебезнең борынгы мишәр җирләренә килеп чыга, гаскәре белән Идел-Кама буйларына килеп җитә. Аның исәбе: күптән түгел урыслар җимереп ташлаган Болгар дәүләтен яңадан торгызу була. Әмма шәһре Болгар урынында ул бары тик хәрабәләр, җимерек өеме генә күрә, исән калган мөселманнарның кара урман эчләренә, Казан суы буйларына күчеп киткәннәрен белә. Олуг Мөхәммәт алар артыннан эзләп барып, Казан шәһәренә килеп чыга. Казан халкы сөенеп, бу мөселман кешесен үзенә хан итеп сайлап куя. Бу хәл 1438 елда була, Казан ханлыгына нигез салу да шушы вакыттан билгеләнә.

Күрәсез, Олуг Мөхәммәт Аллаһ ярдәме белән тигезсез сугышта җиңеп чыга, соңыннан татар иленең хөрмәтле патшасы булып китә, дәүләткә нигез сала. Дөрес, безнең тарихыбыз гел мондый гүзәл җиңүләрдән генә тормый, анда югалтулар да бик күп булган. Шуңа күрә үзебезнең тарихыбызга — татар тарихына бераз җентекләбрәк тукталыйк әле. Һәм бу тарихка, бу табыш һәм югалтуларга ислам дине күзлегеннән бәя бирергә тырышыйк…

Әйткәнебезчә, бик борынгы заманнарда безнең татарның да төрле чаклары булган — ул күк тәңресенә табынган. Ничек табынган — без белмибез, ул бераллалык булганмы, әллә инде борынгы татарлар күккә аерым җисем буларак кына табынганнармы, анысы да билгеле түгел. Әмма инде моннан мең еллар элек Идел буенда яшәүче әби-бабалар үз теләкләре белән ислам динен кабул иткәннәр. Аңа кадәр дә инде Болгар-Биләр шәһәрләрендә мәчетләр булганы билгеле. Югары катлам дәүләт дине буларак ислам динен кабул итсә дә, гади халык әле озак еллар буе үзенең гореф-хорафатлары, ырым-шырымнары, сихерче-багучылары, төрле мәҗүси ышанулары белән яшәгәнгә охшый, чөнки халык авыз иҗаты шул хакта сөйли. Халыкның бер өлеше һаман шул, имеш, «изге чишмәләренә», «изге тауларына», нindидер «изгеләр» каберлекләренә баруын һәм табынуын дәвам иткән, һәрхәлдә, бу ислам дине тарафыннан тыелган эш булса да. Шул ук вакытта борынгы татарлар төрле йорт «ияләренә», су «ияләренә» һәм шуның ише мәҗүси ия-пәриләр, убырлар, әрвахлар дөньясы белән дә үзенчә «аралашып», киңәшләшеп яшәгән. Ислам дине мондый кыргый күренешләргә дә каршы төшә, Коръәндә мондый эшләрнең адашу-саташуга китерүе кат-кат әйтелә, алар катгый тыела. Бу — күпаллалыкка керә, ә ислам дине, инде белгәнегезчә, бары тик бер Аллаһка гына табынырга чакыра. Әмма милләтнең бер өлеше шушы сәер гамәлләреннән аерылырга теләми һәм, Аллаһның ачуын китереп, бар халык өстенә зур бәлаләр килүгә сәбәпче була… Мондый мәҗүсилекнең әле бүгенге көндә дә милләт тормышыннан китеп беткәне юк, ә мең ел элек яшәгән татарлар гомумән дә төрле хорафатларга, ырым-шырымнарга бик тиз ышанучан булганнар. Халыкның менә шулай чуарлыгы, дингә дөрес итеп кереп китә алмавы, авырлык килгәндә Аллаһ яклавына түгел, һаман үзләренең «изге-ияләренә» сыенуы бәлки Болгар һәм Биләр илләренең, Алтын Урда, Казан ханлыкларының юкка чыгуына китергәндер? Чөнки Коръәндә әйтелгән бит:

*«Әгәр Аллаһ сезгә ярдәм итсә, сезне җиңүче булмас»,*—диелгән *(«Гыймран» сүрәсе, 160 аять).* Ә без — җиңелгәнбез. Коръәндә моңа да җавап бар:

*«Аллаһ ничек хак юлга күндерсен, иман китергәннән соң кяфер булган кавемне»,*— диелгән *(«Гыймран» сүрәсе, 86 аять).* Ягъни без, татарлар, иман китергәннән соң, бер тапкыр хакыйкатьне белгәннән соң, яңадан әкренләп мәҗүсилеккә, көферлеккә кереп киткән милләт, ахры. Ягъни халыкның бер өлеше, чынлап та, хак дингә ике кулы белән чытырдатып ябыша, Аллаһтан курка, иманын югалтуга караганда, башын, гомерен җуюны артыграк күрә. Ә халыкның бер өлеше дингә, Аллаһ кушканнарга җиңел карый, тормышын үзгәртергә ашыкмый, иманнан да артык күреп, дөнья малына табына, көферлеккә төшүне гөнаһ эш дип санамый…

Казан ханлыгы чорын гына искә төшерегез. Казан әле Мәскәү тарафыннан алынмаган, әмма анда инде урыс сәүдәсе гөрли, урыс тормышы, аның гореф-гадәтләре тамыр җибәреп ята. Сәүдә битлеге астында, татар халкы арасына чит-ятлар белән бергә эчкечелек, хәрам ризык, алдау, мәкер, зина кебек яман сыйфатлар үтеп керә башлый. Татар сәүдәгәрләре, кыйммәткә мал сатып, очсызга алу өчен шайтанның үзен дә Казан уртасына кертеп утыртырга әзер торалар, үзләре дә дөнья малы артыннан «җир читенә» барып җитәләр. Казан, нигездә, сәүдәгәрләр оясына әйләнә, сәүдә, мал җене кагылган татарлар ил турында түгел, күбрәк үз кесәләре турында кайгырталар. Бер яктан — Аллаһның куәтле дине, икенче яктан куәтле гаскәр белән сакланырга тиешле Казан Мәскәү белән ике арада сату-алу итеп йөрүче сәүдәгәр татарлар кулына кала. Алар Мәскәү белән әшнәлекне, элемтәләрне өзәргә теләмиләр, бары тик башлары шул урыслар тарафыннан киселә башлагач кына, кулга Коръән һәм кылыч алырга өнди башлыйлар. Ләкин инде соң, һай, бик соң була…

Дәүләте, җиңелмәс борын, үзенең ханбикәсен сабый баласы белән бергә дошман кулына биреп җибәрергә тиеш идеме соң? Әле 1551 елда ук, Казан алынырга бер ел кала, Сөембикә ханбикәне Мәскәү урыслары кулына әсир итеп биреп җибәрәләр. Ислам кануннары буенча, бер генә мөселман хатын-кызы кяферләр кулына әсир булып төшсә дә, аны азат итү өчен бөтен милләт күтәрелергә тиеш. Нинди рәнҗеш, канлы күз яшьләре белән киткәндер Сөембикә Казаннан! Урыс арасында әсирлектә, таш зинданнарда ятканда ниләр уйлады икән ул Казанның сатлык татарлары турында? Үзен җиңел генә кяферләр кулына биреп җибәргән милләте турында ни уйлады икән? Бөтен милләтен үз язмышы — 500 еллык коллык көткәнен белдеме икән Сөембикә ханбикә? Моны хәзер без беләбез. Тарихтан гыйбрәт алырга өйрәнергә кирәк, балалар! Әниләрегез, апаларыгыз, хатын-кызларыбыз яңадан кол булмасын, дисәк, алар өчен көрәшергә өйрәнергә кирәк. Һәм тарихта бер ясаган хаталарны яңадан ясамаска. Бу хакта безне татар тарихы кисәтә…

Аллаһы Тәгалә безгә — татарларга байлык-нигъмәтләрен бинипһая күп, кызганмыйча биргән. Ул безгә искиткеч гүзәл, тыныч, мул табигатьле җирләр, эчеп туйгысыз саф сулы чишмәләр, дәрья кебек зур елгалар биргән. Бездә бит, шагыйрь әйтмешли, «җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява»! Бездә, шөкер, җирләр дә тетрәми, өскә ишелерлек утлы тауларыбыз, су басып китәрлек диңгез-океаннарыбыз да юк. Безнең җир асларыбыз тулы нефть, битум, газ, башка байлыклар… Без инде мең ел элек Аллаһ гыйлеме белән гыйлемләнгән, бүләкләнгән милләт. Безнең зур дәүләтләребез, күз карашы җитмәслек җирләребез һәм илләребез, үзебезнең милли мәдәниятебез, әдәбиятыбыз булган. Әмма шушы зур байлыкның күпчелеген без саклый алмаганбыз. Халык шөкрана итә белмәдеме икән, кяфер арасында яшәп, көрәшмичә, сату-алу белән генә исән калырга уйладымы икән, әллә Аллаһ күрсәткән чикләрдән үк чыгып киттеме икән? Үз милләтеңә бәя бирү бик авыр. Әмма бүген шунысы ачык күренә: үз бәхетсезлегебезгә без күп вакыт үзебез дә сәбәпче булмадыкмы икән? Дәүләтләребезне, җирләребезне югалтсак та, әле ярый динебез, иманыбыз калган, һаман үз телебездә — татарча сөйләшәбез, әле ярый милләтебез исән! Аллаһ кушканча яшәсәк, иншаллаһ, милләтебезне дә саклап калырбыз, бәйсез дәүләтебезне дә булдырырбыз, үз җирләребезгә үзебез хуҗа да булырбыз. Сезнең һәрберегез менә шуның өчен көрәшергә тиеш, татар балалары! Сез иман өчен, ил өчен, тел өчен көрәшергә тиешсез! Бу — безнең буынның сезгә васыяте, аманәте…

*«Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Коръән хөкемнәренә ныклап ябышыгыз! Аннары Коръән хөкемнәреннән һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! Янә Аллаһ сезгә биргән нигъмәтләрен күңелегездә саклагыз, бит мөселман булмас борын, бер-берегезгә дошман идегез. Аллаһ ислам дине белән күңелегезгә дуслык, өлфәт мәхәббәтен салды да, бер-берегезгә дин кардәше булып әвереледегез. Сез җәһәннәм ярының читенә килгән идегез, җимерелеп төшәргә генә калган идегез, Аллаһ рәхмәт кылып, җәһәннәмгә төшүдән сезне ислам дине белән коткарды. Әнә шулай Аллаһ сезгә аятьләрен ачык бәян итәр, шаять, дөрес аңлап, дөрес гамәл кылып туры юлга керерсез!» («Гыймран» сүрәсе, 103 аять.)*

Амин.

## ГАЛӘМ СЕРЛӘРЕН АЧКАНДА…

Менә, балам, син инде җирдә дә йөрдең — җирдә йөреп, биек тауларга, тирән дәрьяларга, күктән иңгән яңгыр суларына карап, аларда Аллаһның хикмәтләрен күрергә өйрәндең. Аяк астында кыймылдаган бөҗәкләр, кош-кортлар, судагы балыклар, тирә-юнеңдә шаулап үскән гөл-чәчкәләр сиңа Аллаһның могҗизалары турында сөйләделәр. Син бөтен дөньяны: менә бу елга-тауларны да, күктә очкан кошларны, суда йөзгән балыкларны, җирдә йөргән җәнлекләрне дә, үлән-үсемлекләрне дә — барысын да Аллаһы Тәгалә хикмәт вә мәгънә белән барлыкка китерүен аңладың. Һәм шуннан соң син үзеңә карадың. Тәнеңдәге һәр әгъзаң, һәр күзәнәгең, тетрәнеп, сиңа Аллаһ турында сөйләделәр,

күңелең, аңың, җаның сиңа ни өчен бу дөньяга килүеңне һәм нәрсә эшләргә тиешлегеңне аңлаттылар. Аннан син шәһәр-авылларга, җимерек хәрабәләргә карадың — синең алдыңда, үткәннәрнең тере шаһиты булып кешелек тарихы таралып ята иде. Син шуны аңладың: күп халыкларның, сөйләргә гыйбрәт итеп, Аллаһы Тәгалә бары тик хикәяләрен генә калдырган иде…

Менә шушы зур гыйлем белән син хәзер дөнья уртасында басып торасың. Синең карашың инде хәзер иксез-чиксез күкләргә төбәлгән… Синең инде җиргә караганда да серлерәк тоелган күкләр серен дә беләсең килә: бу бихисап йолдызлар, якты кояш, нурлы ай үзләрендә нинди хикмәт-могҗизаларны яшереп торалар икән? Алар кемгә буйсына, нинди кодрәт белән галәм киңлегендә хәрәкәт итәләр, ничек көнне — төн, төнне көн алыштыра да, нинди тәртип-системага буйсынып, һәр таңда яңадан кояш чыга, һәр төндә ул яңадан юкка чыга? Менә бу күк гөмбәзен, утлы ташлардан торган йолдыз-планеталарны, күләме белән җиргә караганда миллион тапкыр зуррак булган кояшны, җиргә иң якын урнашкан күк җисеме — айны кем тотып тора да, айны — җир тирәсендә, җирне кояш тирәсендә әйләндереп йөртә? Ничек алар бер-берләре белән бәрелешмиләр дә, ничек ул күк җисемнәре берәм-берәм җиргә коелып төшмиләр? Бу дөнья турында гыйлемебез тулырак булсын өчен, әйдәгез, балалар, кулга Коръән тотып, күк серләренә дә җавап эзлик әле! Безне анда да Аллаһның хикмәт һәм могҗизалары, дөньяның ачылмаган серләре көтеп тора бит! Аллага тапшырып, күккә, галәм киңлекләренә дә юл алыйк, балалар!

Әгәр өлкән классларга җиткән булсагыз, сез инде астрономия фәнен, ягъни күк җисемнәрен өйрәнә торган дәреслекләр укыгансыздыр. Алар буенча инде сез күп нәрсәләр беләсез. Әйтик, ул дәреслекләр буенча инде сез галәмнең билгеле бер тәртип-структура белән төзелгәнлеген, күктәге атом төшеннән алып гигант галактикаларга кадәр билгеле бер системага буйсынып хәрәкәт итүен белдегез. Әмма сезнең күңелегездә бер сорау калгандыр: галәмдәге ул тәртипне кем төзегән соң? Ул күк җисемнәре кем әмеренә буйсынып шулай хәрәкәт итәләр икән? Әйткәнебезчә, ай — җир тирәсендә, җир — кояш тирәсендә, кояш исә үзе, барлык йолдызлар белән бергә, галактиканың үзәге тирәсендә (Укчы йолдызлыгы тирәсе) әйләнә бит! Һәм галәм-галактикада йолдызлар теләсә ничек түгел, Киек Каз Юлы дип аталган чикләргә якты юл ясап тезелгәннәр икән. Безнең Кояш системасы да кергән бу галактикада йөз миллиард чамасы йолдыз булып, кояш шуларның нибары берсе икән! Һәм мондый галактикалар җиһанда ун миллиард чамасы икән…

Сез инде белдегез: галәм-галактиканың буш кебек күренгән урыннары да буш түгел — ул йолдыз тузаныннан һәм газдан (төтеннән) тора икән. Галәмгә, умарта кортларыныкы кебек, кәрәз сыман челтәрле төзелеш хас. Һәм менә шушы кайнап торган дөнья, галактикалары, метагалактикалары белән, туктаусыз хәрәкәт итеп, бер системага буйсынып яшәп ята! Әле без тәндәге күзәнәкләрнең шулай бер системага буйсынып эшли белүләренә шаклар каткан идек. Ә монда миллиардлаган-миллиардлаган йолдызлар, планеталар, кояшлар бер тәртипкә буйсынып хәрәкәт итә… Инде белгәнебезчә, метагалактикалар да хәрәкәт итә, киңәя һәм үзгәрә икән, шулай итеп, күкләр дә киңәяләр, бер-берләреннән ерагаялар, күкләр дә тере җан кебек яшәп яталар икән… Шулай итеп, күктәге һәр җисем үз бурычын үти икән. Я Раббым, җансыз кебек күренгән күкләрне, бездән ерак йолдызларны, галәмдә йөзеп йөргән һәр җисемне хәрәкәткә китерүче, тотып торучы, эшкә җигүче Син бит, Син бит, Раббыбыз Аллаһ! Синең бөеклегең каршында башларыбызны иябез, бер Сиңа гына буйсынабыз, кояш, ай, йолдызлар, күк вә галәмнәр Сиңа буйсынган кебек…

*«Ул — Аллаһ кичне вә көндезне һәм кояшны вә айны бар кылды, кояш, ай вә йолдызлар һава бушлыгында йөзеп йөрерләр» («Әнбия» сүрәсе, 33 аять).*

*«Кояшның айга ирешмәклеге һәм кичнең көндездән элек килеше дөрес түгел, ягъни бу эш булмас, кояш белән ай һәм башкалары һәммәсе һава бушлыгында йөзеп йөриләр» («Йәсин» сүрәсе, 40 аять).*

Бөтенләй укый-яза белмәгән, фәннән хәбәрдар булмаган Мөхәммәт галәйһиссәлам үзлегеннән шушындый фикергә килә аламы? Игътибар итегез: кояш та, ай да, йолдызлар да һәм башкалары да хәрәкәт итәләр, диелгән бит! Шул исәптән җир дә! 1400 ел элек мондый хәбәр, мәгълүмат бары тик Аллаһтан гына була ала. Галимнәр бары тик 600—700 елдан соң гына, бик күп өйрәнү һәм күзәтүләрдән соң гына айның — җир тирәсендә, ә җирнең исә үз күчәре һәм кояш тирәсендә әйләнеп йөрүен ачалар. Бу мәсьәләдә чагыштырмача дөрес фикер йөртүче поляк галиме Николай Коперник була (1473—1543). Ә аңа кадәр яшәгән антик галимнәр исә, шул исәптән Аристотель дә (безнең эрага кадәр 384—322 еллар) һәм Клавдий Птоломей (бу эраның II гасыры), җир хәрәкәт итми, дип баралар. Хәер, соңгысы, җир хәрәкәт итмәсә дә, аның янында башка планеталар әйләнә, дигән фикер әйтә. Бүгенге фән күзлегеннән чыгып караганда, дөрес җавапның ул чор өчен дә, бүген дә бары тик Коръәндә генә икәнен күрәбез.

*«Раббыгыз Аллаһ алты көн эчендә җирне вә күкләрне төзеде, соңра бойрыгы Гарешкә карарланды. Аллаһы Тәгалә төн караңгысы белән көнне каплар, ул төн көнне ашыгып өстәр, ягъни туктамыйча,*

*бер-бер артлы килеп торырлар, кояш, ай вә йолдызлар Аллаһ әмере буенча йөриләр, уяу булыгыз! Барлыкка китерү, һәр эшкә әмер бирү Аллаһ эше түгелме? Барча галәмне тәрбия итүче Аллаһ бәрәкәт иясе булды» («Әгъраф» сүрәсе, 54 аять).*

Бүгенге галимнәр дә җир һәм күкләрнең периодлап барлыкка килүен, кайчандыр аларның тоташ бер масса булуын, күктәге ниндидер шартлау нәтиҗәсендә җир һәм күкләрнең аерылуын язып чыктылар. Хәер, бу хакта Коръәндә моннан 1400 ел элек хәбәр ителгән иде бит инде!

*«Әйә кяферләргә белдерелмәдеме, җир вә күкләр бергә кушылган иделәр, Без аларны аердык вә һәр терек мәхлукны судан бар иттек. Инде шуларны белеп тә иман китермиләрме?» («Әнбия» сүрәсе, 30 аять.)*

Аллаһның алты көн эчендә җир вә күкләрне төзүе периодлар-чорларны аңлата, дидек. Чөнки күктә җир вакыты йөрми, моны инде бүгенге фән дә исбат итте. Әйтик, айда көн озынлыгы җир исәбе белән ике атна чамасы, төн озынлыгы да шулай ук. Димәк, айның бер тәүлеге җирдәге бер ай була икән. Венера планетасында исә тәүлек озынлыгы җирдәге бер елга туры килә. Венера — җиргә иң якын урнашкан планеталарның берсе, әле анда да бездәге бер ел — анда нибары бер тәүлек! Ә җирдән тагы да ераграк урнашкан Юпитер, Сатурн, Уран, Нептун, Плутон планеталарында, галәмнең чиксез төпкелләрендә бездәге бер гасыр анда нибары бер мизгел генә булып исәпләнергә мөмкин. Шуңа күрә күкләр исәбе белән алты көнне без дәверләр белән исәпләнгән периодлар дип өйрәнәбез һәм бу очракта дин белән фәннең өйрәтүләре тәңгәл килә дип әйтәбез. Хәер, җир белән күк вакыты арасында зур аерма барлыгы турында Коръәннең үзендә дә хәбәр бар бит:

*«Аллаһ үзенең әмерен күктән җиргә иңдерер, соңра ул әмер яки тәдбир Аллаһуга менәр, сез саный торган дөнья еллары белән мең ел озынлыктагы бер көндә» («Сәҗдә» сүрәсе, 5 аять).*

Коръәндә шулай ук галәмнәрнең (галактикаларның) күп икәнлеге, шуларның барчасына да Аллаһы Тәгалә Хуҗа икәнлеге әйтелә:

*«Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга яраклы һичбер зат юк, мәгәр Аллаһ Үзе генә, Аңа буйсынырга кирәк. Ул һәрвакыт тере, галәмнәр хәлен күзәтеп, белеп тора» («Гыймран» сүрәсе, 2 аять).*

Бүгенге астрономия фәне дә галәм-галактикаларның күплеген ачты, аларда хәтта ниндидер формада тереклек булу мөмкинлеген дә әйтте. Галәмнең кайчандыр төтеннән торганлыгы турында Коръәндә дә әйтелә, моны инде бүген фән дә раслады. Танылган француз галиме Морис Букель бу хакта: «Галәм башта төтен-томан рәвешендә булып, аннан бүленүләр барлыкка килгән һәм аерым галактикалар, йолдызлар, планеталар барлыкка килгән»,— дип яза. («Коран и современная наука», Казан, 1993 ел, 7 бит.)

Коръәндә бу хакта менә ничек әйтелгән:

*«Әйә кяферләргә белдермәдемме, җир һәм күкләр бергә кушылган иделәр. Без аларны аердык вә һәр терек мәхлукны судан бар иттек. Инде шуларны белеп тә иман китермиләрме?»*

*«Соңра Аллаһ күкне бар итәргә теләде, ул вакытта күк төтен иде, Аллаһ күккә һәм җиргә: «Теләп яки теләмичә Миңа итагать итегез, Мин әйткәнчә булыгыз»,— диде. Күк һәм җир: «Я Рабби, теләп үз ихтыярыбыз белән баш иябез»,—диделәр» («Фуссиләт» сүрәсе, 11 аять).*

Коръәндә шулай ук җир белән күк арасында булган нәрсәләргә дә ишарә бар:

*«Ул — Аллаһ җирне, күкләрне вә алар арасында булган нәрсәләрне барлыкка китерде алты көндә, соңра рәхимле Аллаһ Гарешкә беркетелде, ул хакта галим кешедән сора» («Фуркан» сүрәсе, 59 аять).*

*«Ул Раббың җир вә күкләрнең, һәм җир белән күкләр арасында булган нәрсәләрнең Раббысыдыр, рәхмәтенә һәрнәрсәне сыйдыргандыр» («Нәба» сүрәсе, 37 аять).*

Галимнәрнең әйтүенчә, чыннан да, җир һәм күкләр арасы буш түгел икән, эчке бер тәртипкә буйсынган матдәләр системасы җир белән күк арасында күпер-арадашчы ролен үтиләр икән. Ягъни без бушлык дип уйлаган бушлык та буш түгел, аның да җир белән күккә нисбәтле үз роле бар икән! Ягъни бу бушлык та нәрсә өчендер кирәк булган төтен-газдан тора, бу бушлыкта да гравитация һәм магнит кыры бар. Бу исә, үз чиратында, планеталарның бер-берләренә бөек тартылышына китерә, ягъни аларның кояш тирәсенә тартылып, әйләнеп йөрүен, шулай ук бу планеталарның үз тирәләрендә дә иярчен-спутниклар әйләнүен тәэмин итә. Планета-йолдызларның бу бөек тартылышында да бөек бер тәртип, идарә ителү системасы бар. Чөнки шушы бөек идарә, бөтен җиһанны кодрәт, гыйлем белән тотып тору булмаса, миллиардлаган тонналы бу таш, тимер, ут һәм боз катламнары күптән инде бер-берләре өстенә җимерелеп төшеп, дөньяның асты өскә килгән булыр иде. Шул исәптән җирнең дә… Хәер, заман ахырында ул хәл дә булачак, ягъни планета-йолдызларның бөек тартылышы, бөек идарә юкка чыгып, күкләр җир өстенә ишелеп төшәчәк, күкләр яңадан җир белән кушылачак. Бу көн турында Коръәндә менә нәрсә әйтелә:

*«Кайчан кояшның нуры китәрелсә, чорналса караңгылык белән. Вә йолдызлар җиргә коелсалар. Вә таулар урыннарыннан кузгалсалар…» («Тәквир» сүрәсе, 1—3 аятьләр).*

*«Әгәр күк ярылса...» («Инфәтар» сүрәсе, 1 аять).*

*«Кайчан күк ярылса, вә йолдызлар чәчелсә. Вә дәрьялар агып бергә кушылсалар...» («Инфәтар» сүрәсе, 1—3 аятьләр).*

*«Беркөнне сурда өрелер дә хисап өчен төркем-төркем булып килерсез. Күк ачылыр да, анда ишекләр булыр...» («Нәба» сүрәсе, 18—19 аятьләр).*

*«Ул күкне җиргә төшүдән тотадыр, мәгәр кыямәт көнне Аның теләге белән җиргә төшәр, әлбәттә, Аллаһ кешеләргә йомшак вә рәхимледер» («Хаҗ» сүрәсе, 65 аять).*

*«Вәгъдә ителгән кыямәт булачак. Әгәр йолдызларның нуры сүнсә, күк ярылса, таулар тетелеп очсалар...» («Мүрсәләт» сүрәсе, 7—10 аятьләр).*

Күрәсез, дөньяның бетүе күк белән, йолдызларның сүнүе, кояшның нуры бетүе, күкләрнең ярылуы, ягъни җимерелүе һәм җир өстенә төшүе белән бәйләнгән. Я, инде әйтегез, VII гасырда яшәгән бер гарәп кешесе үзлегеннән мондый нәрсәләрне уйлап чыгара алыр идеме? Әлбәттә юк! Бу хәбәрләр, бу кисәтүләр барысы да — Аллаһы Тәгаләдән. Бу хәбәрләр барысы да хак, барысы да булачак... Дөнья бер халәттән икенчесенә күчәчәк, шул исәптән — без, кешеләр дә... Дөнья бетү ул әле үлем дигән сүз түгел, ул бер яратылыш бетеп, икенчесе — инде мәңгелеге башланды дигән сүз. Ул мәңгелектә һәр кеше яшәячәк, әмма берәүләр — бу дөньяда Аллаһ кушканча яшәгәннәр — җәннәттә, рәхәттә, ә Аллаһ куйган тәртипкә буйсынмаучылар җәһәннәмдә, мәңгелек газапта булачаклар... Киләчәк тормышын бүген һәркем үзе яза, үзе төзи... Без бүген барыбыз да Аллаһның сынавын үтәбез, шуның өчен яшибез...

Инде без һәр көнне күреп иянләнгән кояш турында, һәр төнне нур сибеп торган ай турында да бераз мәгълүмат биреп үтик. Сез укый торган астрономия дәреслегендә: «Кояш энергия саклау һәм әверелү законына буйсына,— дип язылган.— Димәк,— дип дәвам итә дәреслек,— кояш энергиясе юктан бар була алмый һәм кояшның өзлексез нур таратып торуын тәэмин итә торган чыганаклар булырга тиеш».

Сөбханалла! Галимнәребез дә хакыйкатькә якын ук килгәннәр түгелме соң?! Әлбәттә бар андый чыганак! Ул кояшның бертуктамый нур таратып торуын да тәэмин итә, шул нурларны җиргә дә китереп җиткерә, җирне — кояш тирәсендә, кояшны Үзе тирәсендә әйләнергә мәҗбүр итә! Ул илаһи көч —барча галәмнәрнең Хуҗасы Аллаһы Тәгалә!

*«Олуг вә бөек Аллаһ күктә йолдызлар кылды вә аларга урыннар билгеләде, вә анда яктыртучы кояшны һәм ялтыраучы айны бар итте» («Фуркан» сүрәсе, 61 аять).*

Сез игътибар итегез: Коръәндә кояш — яктыртучы (сираҗ), ә ай ялтыраучы (нур) дип бирелгән. Ягъни кояш туктаусыз янып, яктыртып һәм җылытып тора, ә ай шушы яктылыкны, нурны чагылдыра гына икән, ә үзе янып якты чыгармый. Бүгенге фән дә моның нәкъ шулай икәнен раслады: кояш яктырта, ә ай шул яктылыкны чагылдырып ялтырый гына икән! Бу сезнең дәреслекләрдә дә нәкъ шулай дип язылган. Коръәндә йолдызлар хакында да «яна» дип әйтелгән, бүгенге фән дә йолдызларның янып яктыртуын, төн карасын кисеп, җиргә йолдыз нуры килеп ирешүен исбат итте. Коръәндә планеталар «каукаб» дигән исем белән билгеләнгән, аларның, яктылык чыганагы булмыйча, бары тик башкалардан килгән яктылыкны чагылдыручылар гына булуы әйтелгән. Бүгенге фән моңа өстәп тагы нәрсә әйтә алды әле? Әйтсә дә, Аллаһ рөхсәт иткәнне генә әйтә алачак...

Тагы кояшка килик. Бүгенге фән әйтүенчә, кояшта 70 тән артык химик элемент табыла. Димәк, кояшта җир өчен ят булган бер генә химик элемент та юк. Бу хәл исә тагы бер тапкыр җир белән күкләрнең кайчандыр бер булуын, береккән булуын, Аллаһның кодрәте белән бер-берләреннән аерылуларын күрсәтә. Кояш һәм ай тотылу күренешләренең дә, кояш активлыгының да билгеле бер циклы барлыгы ачыкланды, алар билгеле бер тәртиптә һәм төгәллектә кабатланып торалар икән. Әйтик, кояш активлыгы 11 елга бер кабатлана, кояш һәм ай тотылулары елына икешәр тапкыр кабатланып торуы мәгълүм. Игътибар итегез: цикл, система, закончалык бар икән, димәк, идарә итү бар дигән сүз!

Көн һәм төн кебек нигъмәтләрнең без инде Аллаһтан икәнен беләбез, теләсә Ул безне мәңгелек төндә яки мәңге якты булган көндә дә калдыра алыр иде! Шуның галәмәте, мисалы итеп, Аллаһ безгә җәйләрен гел көннәр генә була торган урыннарны (аларны «ак төннәр иле» дип тә атыйлар) һәм кышларын гел төннәр генә була торган җирләрне дә (аларны «Поляр төннәр» дип тә атыйлар) күрсәтте бит инде! Һәм, безләрне каты кисәтеп, болай диде:

*«Әгәр Аллаһ кичне караңгы хәлендә кыямәткә хәтле калдырса, Аллаһудан башка илаһә бармы сезгә яктылык китерә торган? Әгәр Аллаһ көндезне якты хәлендә кыямәткә чаклы калдырса, Аллаһудан башка илаһә бармы рәхәтләнеп ял итә торган кичегезне китерергә? Аллаһ үзенең рәхмәтеннән сезгә көндез белән кичне бар кылды, кичтә ял итүегез өчен, көндез кәсеп белән шөгыльләнү өчен, шаять, Аллаһуның бу нигъмәтләреннән шөкер итәрсез» («Касас» сүрәсе, 71—73 аятьләр).*

Коръәндә шулай ук кешенең кайчан да булса бер галәм киңлегенә чыгарга тырышуы һәм зур авырлыклар белән космоска очачагы да тасвирланган! Тыңлагыз һәм тетрәнегез! Тыңлагыз һәм уйланыгыз!

*«Ий кеше һәм җен таифәсе! Әгәр көчегез җитсә, җир вә күкләр чигеннән үтеп китәргә, ягъни галәм бушлыгына чыгарга, үтегез! Юк, үтә алмассыз, мәгәр күп көч вә күп белем, күп мал белән үтәрсез» («Рахмән» сүрәсе, 33 аять).*

Ягъни кешелек дөньясы, үзе яратылганнан соң миллион еллар үткәч кенә, бик күп көч куеп, зур белемнәр һәм чыгымнар (миллиардлар!) тотып кына җиһанга оча алды! Анда да бары тик Аллаһ рәхмәте белән генә, Аллаһ рөхсәт иткән урынга гына. Коръәндә күкләр җиде кат, диелгән, бүгенге галимнәр дә аның җиде катламнан торганлыгын расладылар. Кеше әле хәзергә күкнең беренче катламына да менеп җитә алмады. Ул биеклеккә бары тик безнең җаннарыбыз гына менеп җитә ала, анысы да бу дөнья белән мәңгегә хушлашкач кына.

Әйе, күк — җаннарның килер урыны, күк — җаннарның китәр урыны да… Күк — җаннарның заман ахырын көтеп торыр урыны… Шуңадыр, ахры, без күзләребезне күктән алмыйбыз, җаныбыз гел күккә — биеклеккә тартыла, без төшләребездә дә гел очабыз, күкләргә менәргә тырышабыз…

Җир белән кояш арасына ай урнашкан. Ай — җирнең иярчене һәм аңа иң якын урнашкан күк җисеме. Аллаһы Тәгалә Коръәндә айны вакытны билгеләү өчен барлыкка китерүен әйткән. Монда вакыт төшенчәсен тәүлек яки бер ай вакыт микъдары белән генә чикләү дөрес булмас иде. Вакыт төшенчәсенә бик күп нәрсәләр: кеше гомере дә, бөтен кешелек өчен билгеләнгән вакыт та, дөньяның үзе өчен күрсәтелгән вакыт та керергә мөмкин. Ислам дине буенча, бу дөньядан аерылган җаннар җир белән күк арасындагы «барзах» дип аталган урында кыямәт көне җиткәнне, ягъни *үз вакытларын* көтәргә тиешләр. Вакыты белән елаткан, вакыты белән моңайткан нурлы ай да бәлки безнең җаннарыбызның җыелу урыныдыр? Шулайрак фикер йөртергә Америка космонавтларының айда азан тавышы ишетеп төшүләре дә этәргеч ясый. Матбугатта басылып чыккан бу язманы укучыларга да тәкъдим итәбез. Шушы хәлләрдән соң бик нык тетрәнгән Америка космонавтлары, җиргә кайткач, ислам динен кабул итәләр…

«1969 елның июлендә «Аполлон-II»дә айга очкан Америка астронавтлары Олдринг, Коллинс, Армстронг — өчесе дә инанган христианнар булалар. Айның өслеген күзәткәндә алар башта Тынлык диңгезе өстендә ачык китап рәвешендәге әйбер күрәләр. Аннан соң җир белән элемтәгә кергәндә ниндидер тавыш комачаулый башлый… (Бу хакта аларның җир белән сөйләшүләре магнитофон язмасында саклана.) Икенче көнне Армстронг корабтан ай өслегенә үзе генә чыга һәм сигналга охшаш тавыш ишетә. Аннан соң моңлы итеп «Әшһәдү-әл- лә-иләһә-иллалаһ…» сүзләренә якын авазлар яңгырый (бу да язмада сакланган). Моңа кадәр бу сүзләрне ишетмәгән Армстронг: «Шуны тыңлагач, миңа ничектер җиңел, рәхәт булып китте»,— ди. Соңыннан, магнитофон язмасыннан алынган шул тавышларны белгечләрдән тикшерткәч, аның изге азан сүзләре булуы ачыклана. Шул ук сүзләрне, моңны берничә елдан соң «Аполлон-16»да очкан астронавт Ворден да ишетә» («Заман» газетасы, 2001 ел, 26 гыйнвар саны).

Әйе, *«Коръәндә хәбәр бирелгән һәрнәрсәнең урыны һәм вакыты бар, Коръәндә әйтелгән сүзләрнең хак икәнлеген тиздән белерсез» («Әнгам» сүрәсе, 67 аять).*

## ФАТИХА БЕЛӘН ОЛЫ ЮЛГА…

Инде күрдегезме, балалар, Аллаһы Тәгаләнең могҗиза һәм хикмәтләре белән җир вә күкләр тулы, хәбәрләре, билгеләре бөтен дөньяны чорнап алган… Әле кешеләр өчен ачылмаган серләр дә бик күптер. Һәм, һичшиксез, Аллаһы Тәгалә җир вә күкләрнең серләрен хакыйкатькә омтылучы, иманлы, эзләнүчән бәндәләренә ачачак. Шуңа күрә, балалар, Коръәнне өйрәнегез, җир вә күк серләрен ачарга ачкыч итеп Коръән гыйлемен алыгыз, дөньяны танып-белүдә Аллаһы Тәгалә өйрәткәннәргә таяныгыз. Шулвакытта дөнья сезгә үзенең серләрен ачар. Әле кешелек дөньясының галәмне, җир йөзен, үсемлекләр һәм тереклек тормышын, ниһаять, кешенең үзен Коръәнгә таянып өйрәнә башлаганы да юк. Менә бүген сезнең алдыгызда бөтен дөнья. Күкләргә менеп, галәм серләрен өйрәнегез, әмма Аллаһ күрсәткән чикләрдән узмагыз, дөньяга зыян китермәгез. Җир астында һәм җир өстендә ниләр бар — аларын да ачыгыз, әмма монда да Аллаһ күрсәткән чикләрдән узмагыз, тереклек дөньясына зыян китермәгез. «Бу дөнья үзеннән-үзе барлыкка килгән» дигән ялган фикергә иярә күрмәгез, киресенчә, бу дөньяны Аллаһы Тәгалә барлыкка китерүен кешеләргә аңлатырга тырышыгыз. Яхшылап биология, анатомия, медицина фәннәрен, кеше төзелешен өйрәнегез, әмма беркайчан да: «Кеше маймылдан килеп чыккан» дигән сүзне әйтмәгез, ул сүзгә ышанмагыз. Киресенчә, Коръән гыйлеменә таянып, бүгенге фәнне яхшы үзләштереп, кешене Аллаһы Тәгалә барлыкка китерүен кешеләрнең үзләренә

аңлатыгыз. Намаз укый торган врачлар, намаз укый торган инженерлар, галимнәр, укытучылар, намаз укый торган яхшы кешеләр булыгыз. Ислам динен тормыштан аерып карамагыз, киресенчә, аны тормышыгызны дөрес алып бару өчен кулланыгыз. Беркайчан да гыйлем алудан туймагыз, әмма алган белемнәрегез Аллаһны тануга юнәлдерелсен, милләтегезгә хезмәт итсен.

Кешеләргә мәрхәмәтле булыгыз, Аллаһ та сезгә карата мәрхәмәтле булыр. Ата-ананы кадерләгез, шуңа карап, Аллаһ сезне дә кадерләр. Туганнар белән элемтәләрне өзмәгез, кешеләргә гел яхшылык кына эшләргә тырышыгыз, Аллаһ сезгә дә гел яхшылык кына эшләр. Егетләребез батыр, тәвәккәл, кызларыбыз тыйнак, әдәпле булсын, намазлы, никахлы гаиләләр төзесеннәр, милләтебезгә иманлы балалар тәрбияләсеннәр! Халык бәхете өчен яшәргә һәм көрәшергә өйрәнегез, динебезне, милли телебезне башкаларныкына алыштырмагыз, мөстәкыйль үз дәүләтебезне төзеп, анда Аллаһ кушканча яшәргә омтылыгыз. Урынсызга чит милләтләрне, башка диндәгеләрне рәнҗетмәгез, алар белән тыныч яшәргә тырышыгыз, шул ук вакытта Аллаһ юлыннан да чыкмагыз, мөселман булып, татар булып, ирекле булып калыгыз! Аллаһтан башка беркемгә, бернәрсәгә кол булмагыз, башкаларны да үзегезгә буйсындырырга, кол итәргә тырышмагыз. Гадел булыгыз, Аллаһ та сезгә карата гадел булыр. Һәм сез дөньяда иң бәхетле кешеләр булырсыз…

Бәхет ачкычы…

Аны кайлардан, ничек итеп эзләп табарга соң?! Кайберәүләр, гомер буе эзләп тә, бу хикмәтле ачкычны таба алмый, булган байлыклары да, дан-дәрәҗәләре дә аларны бәхетле итә алмый. Чөнки бәхет — ул җан тынычлыгында, ә җан тынычлыгы Аллаһ кушканча яшәүдән килә. Моның шулай икәнен сез инде үзегез дә күрдегез, бәхет ачкычының Коръән гыйлемендә икәнен яхшы аңладыгыз. Шушы изге Коръәнебезгә ике куллап тотыныгыз, газиз балалар, аннан беркайчан да аерылмагыз, бары тик Аллаһ кушканча гына яшәгез. Һәм сез дөньяның иң бәхетле кешеләре булырсыз…

*«Коръән белән күрсәткән бу юлым сезнең өчен туры юлымдыр, шул туры юлга керегез! Вә Мин күрсәткән юлдан башка юлга кермәгез, әгәр башка юлларга керсәгез, ул юллар сезне Аллаһ юлыннан аерырлар. Аллаһ сезгә Коръән белән юл күрсәтеп, шул юлдан барырга әмер кылды, әмма башка юлга китүдән тыйды, шаять, башка юлга китеп, һәлак булудан сакланырсыз» (Коръән. «Әнгам» сүрәсе, 153 аять).*

**ЭЧТӘЛЕК**


«Йөз ирнең эшен эшләр» Фәүзия. *Хатыйп Миңнегулов* ...........

Каһарман татарлар ..........................................................................................

Нух пәйгамбәр көймәсе ....................................................................................

Бәхет ачкычы ......................................................................................................



Литературно-художественное издание
Серия «Наш след в истории»

**Байрамова** Фаузия Аухадиевна

**ВОСКРЕСШИЕ ИЗ ПЕПЛА**
Казань. Издательство «Магариф». 2004

*На татарском языке*
Әдәби-нәфис басма
«Без тарихта эзлебез» сериясе

**Бәйрәмова** Фәүзия Әүхәдиевна

**ТУФАННАН ТАРАЛГАН ТАТАРЛАР**

Редакторы *Р. К. Аймәтов*
Рәссамы *Р. Ф. Ахияров*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы һәм компьютерда
биткә салучысы *М. И. Данилевская*
Корректорлары *Р. Ә. Фәйзуллина, Г.Г.Мөхәммәтҗанова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүче *Л. Р. Вафина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 25.12.2004. Форматы 60х90$^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 28,0.+форз. 0,25. Нәшер-хисап табагы 27,69+форз. 0,38. Тиражы 2000 д. Заказ А-87.
«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif @ mail.ru
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.